Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ XX–XXI ГАСЫРЛАР МӘДӘНИ ХӘЯТЫНДА

ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ

2021 елның 23 апреле. Казан

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ В КУЛЬТУРНОМ ПРОСТРАНСТВЕ XX–XXI ВВ.

МАТЕРИАЛЫ МЕЖДУНАРОДНОЙ КОНФЕРЕНЦИИ

23 апреля 2021 года. Казань

# CABDULLA TUKAY IN THE CULTURAL SPACE OF THE XX–XXI CENTURIES

PROCEEDINGS OF INTERNATIONAL CONFERENCE

April 23, 2021. Kazan

КАЗАНЬ
2021

УДК 821/512/145(082)
ББК 83.3(2Рос=Тат)я43
Г 12

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ*

**Составители:**

***Л.Р. Надыршина, Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева***

**Г 12** **Габдулла Тукай в культурном пространстве XX–XXI вв.:** материалы международной научно-практической конференции, посвященной 135-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Тукая / сост.: Л.Р. Надыршина, Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. – Казань: ИЯЛИ, 2021. – 408 с.
ISBN 978-5-93091-362-0

В сборнике представлены материалы международной научно-практической конференции «Габдулла Тукай в культурном пространстве XX–XXI вв.», посвященной 135-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Тукая.

В статьях сборника творчество Габдуллы Тукая освещается в историко-культурном и общественно-политическом контексте эпохи, а также раскрываются социально-философские, общественно-политические, эстетические и языковые аспекты художественного и публицистического наследия писателя, рассматриваются вопросы литературных взаимосвязей в творчестве поэта, особенности перевода произведений Г. Тукая на языки народов мира, методические аспекты изучения наследия поэта в контексте преподавания родных языков и литератур.

Издание адресовано филологам, преподавателям, аспирантам и студентам, а также всем, кто интересуется данной темой. Материалы публикуются в авторской редакции.

**ISBN 978-5-93091-362-0**

© Оформление. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2021

## КЕРЕШ СҮЗ

Татар халкының күпләгән талантлы уллары һәм кызлары арасында Габдулла Тукай үзгә урын алып тора. Ул үзенең кыска гына гомерендә (1886–1913) халыкның «моңлы көен җырлаучы» шагыйрь, талантлы публицист, үткен тәнкыйтьче булып танылa һәм күпкырлы иҗаты белән XX йөз башы татар Яңарышына җитди өлеш кертә. Әдип яңа татар әдәбиятының нигез ташларын салыша, аның халыкчанлык юнәлешендә үсеп китүенә хезмәт итә.

Иҗатка беренче адымнарын ясаганда, ул таянычны халык авыз иҗатында, күпгасырлык язма мирас җәүһәрләрендә таба. Яшүсмер елларыннан башлап, мөселман Шәрык дөньясының гаҗәеп серле, бай әдәбияты аның иҗатын сугарып тора, ә инде рус һәм көнбатыш әдәбиятлары белән танышу яшь шагыйрьнең иҗат офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрә. Шәрык һәм Гареб дөньяларының шифалы йогынтысы Тукай иҗатының тиз арада популярлашуына, әдәби-эстетик, фәлсәфи планда яңа башлангычларга юл салуына китерә. Әнә шул рәвешле, татарның үз җирлегендә, традицияләрендә формалашкан шагыйрь реалистик юнәлешле һәм халыкчан рухлы әсәрләрендә милли яшәеш мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә. Халкының шатлык-куанычы белән яшәгән Тукай мәгърифәткә, аң-белемгә омтылышны яклап чыга, яңарыш юлында киртә булып торган һәртөр искелек-артталыкны усал фаш итә. Ул заманның социаль-иҗтимагый мәсьәләләрен укучылары каршына куя, аларны хәл итү юллары турында уйлана. Төрле буын һәм төрле социаль катлау кешеләре өчен актуаль сораулар аша татарның яшәеш кыйбласын билгеләүгә килә: социаль һәм милли тигезлеккә ирешү.

Халыкның үз улы булып танылган Тукай иҗаты тема-мотивлар киңлеге, жанрлар төрлелеге, сурәт чаралары байлыгы белән үз чоры әдәбияты күгендә балкый. Аның нуры меңнәрнең күңелендә өмет-ышаныч хисе булып урын ала, халык бәхете, киләчәге өчен көрәшкә өнди. Тукай һәм аның замандашлары булган Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Дәрдемәнд, С. Рәмиев һ.б. эшчәнлеге XX йөз башы сүз сәнгатенең «алтын чор»ын тәшкил итеп, алдагы чор әдәбиятының үсеш-үзгәреш юлын билгеләде, әдипләргә көч һәм илһам биреп тора.

Тукай иҗаты һич тә тар кысаларда калмый. Милли эчтәлек белән сугарылган шигырьләре әхлакый кыйммәтләрне яклавы, гаделлеккә, матурлыкка, кеше шәхесен югары күтәрүгә, аны бәхетле итеп күрүгә юнәлгән булуы белән гомумкешелеккә хезмәт итә. Шуңа да ул үз вакытында ук төрки дөньяда һәм Идел-Урал буе халыклары арасында киң танылу ала, аларның язма әдәбиятына, иҗтимагый фикер үсешенә зур йогынты ясый.

Тукай иҗаты татар халкы яшәешеннән аерылгысыз. Гаять катлаулы чорларда да әдип әсәрләре халыкка таяныч булып, көч биреп тора. Ә инде XX–XXI гасыр сүз сәнгатен Тукай традицияләреннән башка күз алдына китереп тә булмый. Тукайның «Туган тел»е хаклы рәвештә халык гимнына әверелде, ә әсәрләре һәр буын укучылар күңелендә яңгыраш таба. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Тукайның алты томлык академик басмасы әзерләнү, «Тукай энциклопедиясе»нең дөнья күрүе халык шагыйре мирасын өйрәнү һәм халыкка җиткерү юлында җитди бер гамәл булды. Тукайга бәйле фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләрнең дәвамы буларак, әдипнең тормыш һәм иҗат хроникасы буенча материалларны үз эченә алган өч китаптан торган хезмәт басмага әзерләнә, мирасын халыкка җиткерү максатында фәнни хезмәтләр, альбомнар һ.б. чыгып килә.

Бөек Тукайның тууына 135 ел тулуга багышлап үткәрелгән «Габдулла Тукай XX–XXI гасырлар мәдәни хәятендә» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе шагыйрь иҗатына булган кызыксынуның арта баруын, аны төрле аспектта тикшереп бәяләү юлларын һәм мөмкинлекләрен күрсәтә. Әлеге мәртәбәле фәнни мәҗлестә Азәрбайҗан, Казакъстан, Төркия, Үзбәкстан кебек илләрдән һәм Россиянең Махачкала, Симферополь, Мәскәү, Казан, Уфа, Саранск, Чаллы, Алабуга һ.б. шәһәрләреннән белгечләр катнашу да шуның бер чагылышы булып тора. Конференциядә Тукайның шәхесен һәм иҗатын чорның тарихи-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси мохитенә; XX–XXI гасырда әдәбиятара, бигрәк тә төрки әдәби багланышларга; милли сәнгатькә, дөньяның тел картинасына; тәрҗемә итүгә һәм шәрехләүләргә; туган телләр һәм әдәбиятларны укыту мәсьәләләренә нисбәтле тикшеренүләр буенча докладлар тыңлау, фикер алышу күздә тотыла.

Тукай иҗатын һәр яңа буын үзенчә аңлый, кабул итә һәм бәяли. Шуңа да шагыйрьнең бай мирасын заман биеклегеннән һәм яңа фәнни тәгълиматларга нисбәтле өйрәнү дәвам итәр дигән теләктә калабыз.

## ВВЕДЕНИЕ

Габдулла Тукай занимает особое место среди множества талантливых сынов и дочерей татарского народа. В течение своей короткой жизни (1886 – 1913) он был признан как поэт – «певец откровений народной души», как талантливый публицист и острый критик, который своим многогранным талантом внес значительный вклад в татарское Возрождение начала XX века. Писатель был одним из основателей новой татарской литературы и способствовал её развитию в русле народности.

Делая свои первые шаги в творчестве, он находил опору в выдающихся произведениях устного народного творчества и многовековом письменном наследии. Начиная с подросткового возраста его творчество находилось под влиянием удивительно богатой и таинственной литературы мусульманского Востока, а знакомство с русской и западной литературой ещё более расширило творческие горизонты молодого поэта. Целительное влияние Восточного и Арабского мира помогло творчеству Тукая в короткий срок обрести свое звучание, раскрыло дорогу его литературно-эстетическим и философским начинаниям. Благодаря этому, сформировавшийся на татарских традициях поэт, обращается к проблемам национальной жизни в произведениях реалистического направления, проникнутых народным духом. Живший радостями и чаяниями народа, Тукай защищает стремление к просвещению и образованию, зло высмеивает и обличает препоны устаревших традиций, стоящих на пути Возрождения. Он ставит перед читателями социально-общественные проблемы своего времени, думает о способах их разрешения. Через актуальные для разных поколений и социальных групп вопросы, он выходит на определение главной цели татарской жизни – достижение социального и национального равенства.

Творчество Тукая, признанного сына своего народа, сверкает на литературном небосводе своей эпохи благодаря широте тем и мотивов, разнообразию жанров, богатству изобразительных средств. Его сияние в образах надежд и стремлений занимает свое место в душах тысяч людей, зовет к борьбе за счастливое будущее. Тукай и его современники – Г. Исхаки, Г. Ибрагимов, Ф. Амирхан, Г. Камал, Дэрдменд, С. Рамиев и другие деятели составили «золотой период» искусства слова начала XX века, определили развитие и преобразования предстоящего этапа литературного процесса, дали силу и вдохновение писателям.

Творчество Тукая не умещается в тесные рамки. Его стихи, проникнутые национальным содержанием, своей защитой нравственных ценностей, справедливости и красоты, возвеличиванием человеческой личности

и стремлением видеть её счастливой, служат всему человечеству. Поэтому в свое время он получил широкое признание среди тюркских и волго-уральских народов и оказал сильное влияние на развитие их письменной литературы и общественной мысли.

Творчество Тукая неотделимо от жизни татарского народа. В очень сложные периоды произведения писателя были опорой народа и давали ему силу. А искусство слова XX–XXI веков невозможно представить вне традиций Тукая. По полному праву «Родной язык» Тукая превратился в народный гимн, а его произведения созвучны душам читателей всех поколений.

Значительным достижением в изучении наследия народного поэта и доведения его до широкой общественности стали академическое издание шеститомника Тукая и выход в свет «Энциклопедии Тукая», подготовленные Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Как продолжение связанных с Тукаем фундаментальных и практических исследований, происходит сбор материалов хроники жизни и творчества поэта, с целью возвращения его наследия народу постоянно издаются научные труды, альбомы и т.п.

Посвященная 135-летию великого поэта международная научно-практическая конференция «Габдулла Тукай в культурном пространстве XX–XXI веков» показывает рост интереса к творчеству поэта и даёт возможности его исследования в различных аспектах. Наглядным проявлением этого стало участие в данном научном форуме ученых из Азербайджана, Казахстана, Турции, Узбекистана, из российских городов – Москвы, Казани, Уфы, Махачкалы, Симферополя, Набережных Челнов, Саранска, Елабуги и других. На конференции планируется прослушать доклады и провести обмен мнениями с опорой на исследования личности и творчества Тукая в историко-культурном и общественно-политическом контексте эпохи, с учетом межлитературных взаимодействий XX–XXI веков, особенно тюркских литератур, с позиций национального искусства и принципов перевода, комментирования языковой картины мира, а также вопросов преподавания разных языков и литератур.

Каждое новое поколение по-своему понимает, воспринимает и ценит творчество Тукая. Поэтому мы надеемся, что изучение богатого наследия поэта с опорой на современные приоритеты и новые научные доктрины, будет продолжаться.

УДК: 821.512.145

# ТУКАЕВЕДЕНИЕ В ИНСТИТУТЕ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА ИМ. Г. ИБРАГИМОВА АКАДЕМИИ НАУК РТ: ОСНОВНЫЕ НАПРАВЛЕНИЯ

***К.М. Миннуллин***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматривается формирование тукаеведения в Татарском научно-исследовательском институте языка и литературы; прослеживаются главные труды и открытия, определяется вклад ученых-гуманитариев в развитие тех или иных научных проблем. В частности, основными направлениями выделяются: изучение биографии и творчества Тукая; исследование творчества поэта в контексте литературы и культуры начала XX века; возвращение художественного наследия Тукая; Тукай и русская литература; популяризация жизни и твочества поэта. Прослеживается появление таких направлений как: образ Тукая в литературе и искусстве; Тукай и устное народное творчество; религиозно-эстетические и коранические воззрения Г. Тукая; языковые и стилистические особенности произведений Тукая. Доказывается, что рассматривая перспективу тукаеведения как самостоятельной междисциплинарной науки, старшее поколение ученых ставит его во главу угла гуманитарных исследований вообще.
**Ключевые слова:** тукаеведение, Г. Тукай, татарская литература, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, междисциплинарность.

The article examines the formation of Tukay studies at the Tatar Research Institute of Language and Literature; traces the main works and discoveries, determines the contribution of humanitarians to the development of various scientific problems. In particular, the main directions are: the study of the biography and creativity of Tukay; the study of the poet's work in the context of literature and culture of the early twentieth century; the return of the artistic heritage of Tukay; Tukay and Russian literature; the popularization of the poet's life and work. The author races the emergence of such trends as: the image of Tukay in literature and art; Tukay and oral folk art; religious-aesthetic and Koranic views of G. Tukay; linguistic and stylistic features of Tukay's works. It is proved that considering the perspective of Tukay studies as an independent interdisciplinary science, the older generation of scientists puts it at the forefront of humanitarian research in general.
**Key words:** Tukay studies, Tukay, Tatar literature, Ibragimov Institute of Fine Arts, interdisciplinarity.

# ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМ. ТЕЛ ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНДА ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНҮ ФӘНЕ: ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘР

***К.М. Миңнуллин***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татарстанда үстерелә торган гуманитар фәннәрдәге бик күп казанышлар Г. Тукай исеме, мирасы белән бәйләнгән. Инде бер гасырдан артык

шагыйрьнең иҗаты яңадан-яңа фәнни эзләнүләргә илһам бирә, ачышларга рухландыра. Әдәбият белеменең бер тармагы буларак формалашкан Тукайны өйрәнү, тиз арада мөстәкыйль дисциплинаара фәнгә әверелеп, үзенең колачы-масштабы, тирәнлеге белән гуманитар өлкәдә кыйбла билгеләүчегә, юл ярып баручыга әйләнә. Бу хакта без махсус материал әзерләгән идек [12]. Бүгенге язма шушы мәсьәләнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында ничек гамәлгә ашырылуын күзәтүгә багышлана.

1939 елны ачылган Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институтында әзерләнгән иң беренче зур хезмәт Габдулла Тукай турында була [24]. Ул фәнни җәмәгатьчелектә XX йөз башы татар әдәбияты тарихын, Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә яңа старт бирә. Хезмәтнең авторы, яшь галим Гали Халит, гуманитар фәннәрдәге совет идеологиясе сызган чикләрдән чыкмаган хәлдә, Тукай иҗатына карата вульгар социологизм тайпылышларының нигезсезлеген күрсәтүгә, инде ясалган хаталарны төзәтүгә ирешә, шигырьләренең халыкчанлыгын, идея-эстетик камиллеген, үзенең ил, туган җир, татар халкы исеменнән җырлаган бөек шагыйрь булуын ассызыклый.

Якуб Агишевның шагыйрь биографиясе турында очерклары [2, 3] да шушы эзләнүләргә килеп кушыла. Ул 1946 елны Мәскәүдә Тукай иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе яклап кайта һәм шушы темага беркетелә. 1956 елны Г. Халитның «Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века» [20] китабы басылып чыга. Шушы зур хезмәтләр татар гуманитар фәннәрендәге 1930 еллар ахырында идеологик сәбәпләр белән килеп чыккан «өзеклекне ялгый» һәм 1940–1950 еллар аралыгында Институтта Тукайны өйрәнү фәненең оешып җитүен хәбәр итә.

Тукай иҗатына мөнәсәбәттә галимнәр Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ф. Борнаш кебек күренекле фикер ияләре формалаштырган принципларга йөз тота, шуның белән Тукайны өйрәнү фәненең баштан ук классик нигезләргә таянуын һәм дәвамчанлыкны тәэмин итә. Моннан тыш, беренче хезмәтләрдә үк галимнәр Тукайны өйрәнүгә тарих, иҗтимагый фикер һәм фәлсәфә тарихы, культурология, тел белеме, сәнгать белеме, фольклористика кебек фәннәр материалларын актив җәлеп итеп, аны дисциплинаара мөстәкыйль фән кебек күзаллыйлар, планлаштыралар. Бу галимнәрнең карашлары киңлеген, аларның Тукай бөеклеген һәм татар гуманитар фәннәренең зур мөмкинлекләргә ия булуын аңлап эш итүе турында сөйли. Чыннан да, Тукайны өйрәнү фәне – Институттагы беренче академик фән мәктәбе булып, үз чиратында, ул гуманитар фәннәрдә башка күп темаларга юл ача.

Бу фәннең беренче юнәлеше – **Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын тикшерү**. Шунысын да искәртергә кирәк: шагыйрь үзе исән вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр бу хакта фикер әйтмәгән, аңа үз мөнәсәбәтенбәясен белдермәгән татар галиме яки иҗатчысы юктыр. Шуңа күрә без аерым мәсьәләләргә зур өлеш керткән, Тукайны өйрәнү фәненең үсүен һәм киңәюен тәэмин иткән хезмәтләргә генә тукталырбыз.

Әлбәттә, бу юнәлештә Г. Халит эшчәнлеге, аның теоретик яктан көчле фикере-карашы, гыйлем-мәгълүматлылыгы зур роль уйный. Галим бу юнәлештәге тикшеренүләрен туктатмый, гомере буе тукайчы булып кала [22, 23 һ.б.]. Тукай – милли татар поэзиясенә нигез салучы дигән карашны фәнгә Г. Халит урнаштыра һәм дәлилли. Бу юлдагы эшчәнлегенең үзенчәлекләрен билгеләп, үзе дә тукайчы И. Нуруллин галимнең беренче хезмәтләреннән үк аның, беренчедән, «корифейларга сугылган «вак буржуа» яисә

«буржуа язучысы» дигән мөһерне кырып ташлап, бу язучыларның халыкчан, демократик йөзен ачуы»н, икенчедән, «демократик язучылар иҗатын андагы каршылыкларга күз йомып, берьяклы күрсәтүгә» [14: 29] каршы торуын билгели. Чыннан да, шагыйрьгә багышланган монографияләрендә, йөзләгән мәкаләләрендә Халит Тукайның XX гасыр башы татар әдәбиятында тоткан урынын, аның дөньяга карашын һәм эстетик эзләнүләрен киң тарихи-мәдәни фонда карый һәм Тукайны өйрәнүнең югары дәрәҗәдә алып барылуын тәэмин итә.

1956 елны «XX йөз башы татар әдәбияты» [10] дигән коллектив хезмәт басылып чыгу, анда Г. Тукай иҗаты XX йөз башы татар әдәбиятындагы яңарышның үзәгенә куелу әлеге юнәлештә тагын бер тармак хасил итә. **Г. Тукай иҗатын XX йөз башы әдәбияты һәм мәдәнияте фонында тикшерү** була ул.

Россия һәм татар халкы тарихын, мәдәният тарихын файдаланып гамәлгә куелган бу дисциплинаара тармакны үстерүгә, Г. Халит белән беррәттән, Мөхәммәт Гайнуллин зур өлеш кертә. Аның рус телендә нәшер ителгән «Татарская литература и публицистика начала XX века» (1966) [9] хезмәте тарихи, әдәби фактик материалның байлыгы, чор мәдәни барышына ясалган тарихи анализның тирәнлеге, файдаланылган чыганакларның күплеге белән аерылып тора. Ул галимнең 1946 елда якланган кандидатлык һәм 1958 елда якланган докторлык диссертацияләре материалында әзерләнгән була. Хезмәттә татар журналистикасы тарихы, аерым шәхесләрнең татар яңарышына керткән өлеше, татар китабы тарихы, мәдәни тормыш хроникасы һ.б. бик күп мәсьәләләрдә махсус гыйльми тикшеренүләр өчен сукмак салына.

М. Гайнуллин 1905–1907 елларда татар әдәбиятында һәм иҗтимагый фикердә яңа дәвер башлануга аеруча игътибар бирә. Ул Тукайның газета-журналлардагы эшчәнлеген, публицистикасын, тәнкыйди иҗатын анализлау белән җитди шөгыльләнә. Н. Юзиевнең, аның хезмәтләрен бәяләп: «Галим әдәбияттагы яңалыкларны тулы итеп күз алдына бастырырга омтыла. Шуның өчен төрле шәһәрләрдә чыга башлаган газета-журналларны җентекләп өйрәнә, аларның иҗтимагый-мәдәни юнәлешләрен билгели, аларда катнашучы авторларны ачыклый. Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, Ш. Мөхәммәдов, Ф. Әмирхан кебек классик әдипләрнең илдәге иҗтимагый-мәдәни күтәрелеш хәрәкәте белән тыгыз бәйләнешләре, дөньяга карашлары аларның публицистик хезмәтләрен, журналистлык эшчәнлеген галимнең тәфсилле өйрәнүе нигезендә тагы да тирәнрәк ачылып китте» [26: 639–640], дигән сүзләре бу тикшеренүләрнең киң колачлы булуын искәртә. М. Гайнуллинның татар яңарышын мәгърифәтчелек хәрәкәте белән чагыштырып, дәвамчанлыкта һәм үз характерлы сыйфатларын билгеләп өйрәнүе, бу вакытта милли тарихи-иҗтимагый һәм мәдәни хәл-ситуацияне күздән ычкындырмавы Яңа заман һәм XX йөз башы татар мәдәниятенә карата яңа концептуаль караш кебек кабул ителә. Хезмәт үзе, әдәбият тарихы чикләреннән чыгып, татар иҗтимагый-сәяси фикер тарихы белән үрелеп китә.

Бу тармакта да Г. Халитнең «Яңа гасыр поэзиясе: егерменче йөз башы (1905–1917) татар поэзиясендә иҗат методы, лирик герой, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре» (1979), «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән» (1975) һ.б. күпсанлы хезмәтләре юл яручы, әйдәп баручы була. Г. Тукай шигърияте галимне татар әдәбиятының метод-стиль үзенчәлекләренә караган

теоретик ачышларга китерә. Аерым алганда, шигъриятне реализм кысаларында тикшерергә мәҗбүр иткән идеологик басымнан котылып, Г. Халит татар әдәбиятында реализм һәм романтизм синтезы турында яңа концепция белән чыга, 1910 еллар татар әдәбиятында (Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ.б.) романтизм яралуны раслый, әдәби күренешләрне иҗтимагый-тарихи, милли-фикри чынбарлык белән бәйли.

Бу юнәлештә Институтта Тукайны өйрәнү фәнен булдырган олы галимнәр эшчәнлеген Зөфәр Рәмиев дәвам итә. Аның күпсанлы фәнни мәкаләләре, монографияләре Тукай әсәрләренең текстологиясе мәсьәләләрен, ягъни әсәрләрне барлау, аларның авторлыгын ачыклау, псевдонимнарын табу, дөресләп уку, язылу вакытын, төп текст һәм вариантларын чагыштыру кебек күпсанлы сорауларны колачлый [15, 16]. Фәнни эшчәнлегенең зур бер тармагын Тукай мохитен, аның каләмдәшләрен һәм замандашларын өйрәнү алып тора [17]. З. Рәмиев Тукай белән шәхси яки рухи-иҗади бәйләнышлы бик күп шәхесләрнең исемнәрен, иҗатларын халыкка кайтаруга хезмәт итә. Бу исемлектә Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Камал, М. Гафури, Н. Думави, С. Сүнчәләй дә, М. Укмасый, З. Бәшири, З. Ярмәки, Н. Исәнбәт, З. Сәгыйдә һ.б. бар. Галим XX йөз башында иҗат иткән бик күп шагыйрьләр хакында мәгълүматларны фәнни әйләнешкә кертә, әдәбиятта «Тукай мәктәбенең» чикләрен билгеләүчеләрдән була [18]. Аның бу эшчәнлеге, шулай ук, татар яңарышын тарихи-мәдәни хәрәкәт буларак күрсәтүгә хезмәт итә.

Г. Тукайның тууына 130 ел тулган көннәрдә Институтта «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар» дигән зур бер проект башланып китте. Ул татар һәм рус телләрендә 3 китап әзерләү белән төгәлләнергә тиеш. 2018 елны Г. Тукайның Казан арты һәм Уральскидагы тормышын һәм иҗатын яктырткан беренче китабы басылып чыкты [8]. Анда төрле чыганаклар: тарихи мәгълүматлар, рәсми документлар, шагыйрьнең үзенең әсәрләре, замандашларының хатирәләре, газета-журналларда сакланган материаллар һ.б.лар нигезендә Тукай тормышы, иҗаты, аралашу даирәсе турында бүгенге көнгә иң тулы картина тергезелә. Тукайның 135 еллык юбилеена тагын ике кисәге – шагыйрьнең Казан чорын яктырткан китаплар да укучы кулына барып җитәр, өч томлык Тукайны өйрәнү фәненең шушы юнәлешендә бүгенге көнгә берничә буын Институт галимнәре тырышлыгы белән ирешелгән зур казаныш буларак бәяләнер дип ышанабыз.

**Тукай әдәби-мәдәни мирасын кайтару** – Тукайны өйрәнү фәнендә өченче юнәлеш булса, ул Институт тарихында фәнни текстологиягә нигез салу рәвешен ала. Илебез һәм халык өчен иң авыр чорда – Бөек Ватан сугышы елларында галимнәр Якуб Агишев, Хәй Хисмәтуллин Тукай әсәрләренең 2 томлык академик басмасын эшлиләр [19]. 1956 елда шул ук галимнәр тырышлыгы белән 4 томлык әсәрләр дөнья күрә. Тукайның 90 еллык юбилее уңаеннан Институт белгечләре, әсәрләргә яңадан бер кат текстологик тикшерүләр үткәреп, шәрехләмәләр язып, «Әсәрләр»не кабат басмага әзерли. Бу гаять четерекле эшне Рашат Гайнанов алып бара: 1975–1977 елларда ул әзерләгән 4 том дөнья күрә; 1985 елны тулыландырып, 5 томлык буларак басыла. Совет чорының идеологик чикләүләренә карамастан, анда элекке томлыкларга керми калган 100 дән артык әсәр урнаштырыла, басмаларның фәнни аппараты киңәйтелеп, искәрмәләр һәм аңлатмалар өлешендә бай мәгълүмат китерелә.

З. Рәмиев, өлкән текстологларның хезмәтен дәвам итеп, Тукай иҗатын кайтаруга, моңа кадәр Тукайны өйрәнү фәнендә күзәтелгән фактологик ялгышлыкларны төзәтүгә, әсәрләренең фәнни басмаларын әзерләүгә зур өлеш кертә. 2002 елны ул докторлык диссертациясен яклый, анда материалның күп өлешен Тукай әсәрләренең текстологиясе мәсьәләләре алып тора. 2010 елда З. Рәмиев җитәкчелегендә Институтның бер төркем текстолог-галимнәре Тукай әсәрләренең 6 томлык тулы академик басмасын әзерләүгә алына, ул Г. Тукайның 130 еллык юбилеена бүләк булып, 2016 елны басылып чыга. Академик басма таләпләренә җавап биреп, шәрехләүләрдә гуманитар белемнәрнең өр-яңа казанышларын исәпкә алып төзелгән 6 томлык Тукай әсәрләренең барлык билгеле чыганакларын тагын бер кат укып-тикшереп әзерләнә, шагыйрь иҗатын совет идеологиясе берьяклылыгыннан арынган хәлдә, бернинди кыскартуларсыз, тулысынча күзалларга мөмкинлек бирә. Бу юнәлештә дә Институт галимнәре XXI гасыр гуманитар фәннәре югарылыгында күптән көтелгән олы нәтиҗәгә ирешәләр.

**Тукай библиографиясе** дигән тармак тестология юнәлеше эчендә борынлый: 1955–1956 еларда әзерләнгән 4 томлыкның 4 нче томына кушымта итеп Мәсгудә Бурнашева әзерләгән «Г. Тукай әсәрләренең басылуы турында кыскача мәгълүмат» (257–276 битләр) урнаштырыла. «Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсен төзегәндә (1998) дә бу юнәлештә шактый күп яңа мәгълүматлар туплана. Тукай тормышы, аның замандашлары хакында мәгълүмат кырын киңәйтү барышында библиографик мәгълүматлар тулылана бара [6].

XXI гасырга чыгып, чит илләрдәге чыганакларны иркен файдалану мөмкинлеге тугач, әлеге тармакта күп кенә көтелмәгән эзләнүләр башлана. Шуларның матур бер нәтиҗәсе дип Зөфәр Мөхәммәтшин төзегән «Ил йолдызы» [13] җыентыгын күрсәтергә кирәк. Ул татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукайның әсәрләре, аңа багышланган язмалар, әдәби әсәрләр, гомумән, туган илләреннән аерылып, читтә яшәп калган татарлар өчен Тукайның әһәмияте хакында сөйли.

Институтта Тукайны өйрәнү мәктәбе формалашкан вакытта ук тагын бер фәнни юнәлеш күзаллана: **Тукай һәм рус әдәбияты.** Шулай ук 1917 елга кадәрге Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һ.б.лар фикер-карашларына таянып, бу юнәлеш шагыйрь иҗатына рус әдәбиятының йогынтысы, Тукайның тәрҗемәләре мәсьәләсе белән кызыксынудан башлана. 1958 елны Рөстәм Башкуров «Переводы Г. Тукая из русской литературы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый, шул ук елны китабы басылып чыга. Ул Тукайның мәсәлләрен, Пушкин һәм Лермонтовтан тәрҗемәләрен игътибар үзәгенә куя [4]. Институтта әлеге тема белән Вячеслав Воздвиженский да шөгыльләнә. Алар бергәләп рус һәм татар телләрендә шагыйрьнең тормышы-иҗаты хакында китапчыклар әзерләп бастыралар [5].

Бу юнәлештә дә Г. Халит хезмәтләре аерым әһәмияткә ия булганлыкны әйтергә кирәк [21]. Галим Тукай иҗатының синтетик характерын халык иҗаты, шәркый һәм рус-европа әдәбиятлары тәэсире белән аңлата, Җ. Вәлиди фикерләрен үстереп, биредә ияру, кабатлау түгел, әдәби-мәдәни тәэсирләр астында өр-яңа әдәби күренеш тудырылу турында сүз барганлыкны ассызыклый. Татар әдәбиятының үз милли асылын табу, аның үз кыйммәтен билгеләү омтылышы була бу. Соңгы елларда шушы өлкәгә кагылган яшь

галимнәр (М. Ибраһимов һ.б.) рус әдәбияты контекстында шагыйрь иҗатының милли үзенчәлекләрен барлау тенденциясенә өстенлек бирә.

**Тукай иҗатын пропагандалау һәм популярлаштыру**ны да Тукайны өйрәнү фәнендәге махсус юнәлеш буларак аерып чыгару мөмкин. Әлбәттә, бу юнәлеш хакында бик күп сөйләргә була. Чөнки Институт галимнәре 80 ел дәвамында бастырып килгән меңләгән мәкалә-язмалар шушы юнәлешкә карый.

Моннан тыш, Институтта әзерләнгән күптомлыкларда (6 томлык (1984–2001), 8 томлык (2014–2021) «Татар әдәбияты тарихы» һ.б.), тематик җыентыкларда («Татар теле һәм әдәбияты», «Әдәби мирас: эзләнүләр һәм табышлар» һ.б.) яңартылган, тулыландырылган мәгълүматлар урнаштырыла килеп, алар Тукай иҗаты хакында караш-фикерләрне киңәйтә, шагыйрь иҗатының яңадан-яңа якларын укучы күз алдында калкытып куя. Тукай иҗатына караган аз билгеле яки бөтенләй мәгълүм булмаган материаллар туплап махсус җыентыклар әзерләү тәҗрибәсе дә дәвам итә: мисалга, «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең беренче китабы (2016) шундыйлардан.

Әмма фәндә бу эш, иң беренче чиратта, гыйльми җыеннар форматында алып барыла. 1950 еллардан башлап, шагыйрьнең юбилейларына багышлап конференцияләр уздыру, аларның материалларын бастырып чыгару системалы рәвештә башкарыла. 1948 елны Тукайның тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары [11] Тукайны өйрәнү фәненең күп кенә галимнәр тырышлыгы белән чикләре киңәя башлаганлыкны, анда өр-яңа кызыксыну объектлары, өйрәнү темалары хасил булуын күрсәтә. 1968 елны – 80 еллыгына, 1979 елны – 90 еллыгына, 1997 елны – 110 еллыгына, 2001 елны – 115 еллыгына, 2006 елны – 120, 2011 елны – 125, 2016 елны – 130 еллыгына зур-зур җыентыклар нәшер ителә. Нәкъ менә фәнни конференцияләр Тукайны өйрәнү фәненең тармаклануын тәэмин итә, яшь галимнәрдә Тукай иҗатына карата кызыксыну уята, үз чиратында, Тукайга кагылышлы күзаллауларны гуманитар фәннәрнең төрле тармакларына урнаштыра.

Шул рәвешле, Тукайны өйрәнү фәнендә яңа дисциплинаара тармаклар барлыкка килү күп яктан Институт галимнәре һәм җитәкчеләренең күзаллавы белән бәйле була дияргә нигез бар. Үзгәреп торучы тормыш үзе дә яңадан-яңа мөмкинлекләр ача.

**Әдәбиятта һәм сәнгатьтә Тукай образы** дигән тема күп еллар дәвамында Институтта сәнгать юнәлешендә эшләүче галимнәр тарафыннан төрле яклап үстерелеп килә. «Тукай һәм театр», «Сынлы сәнгатьтә, рәсем сәнгатендә Тукай образы», «Тукай һәм музыка» кебек темалар белән җитди шөгыльләнүчеләр төркеме хасил була (Г. Арсланов, Р. Солтанова, А. Салихова, Д. Хисамова һ.б.). 1986 елны басылып чыккан «Октябрьгә кадәрге татар театры» (авторлар Һ. Мәхмүтов, И. Илялова, Ф. Гыйззәтуллин) дигән коллектив монографиядә Тукайның театр, артистлар һәм режиссерлар белән мөнәсәбәтләре яктыртылса, «Татар совет театры» (1975), «Татарский театр (новаторские искания татарского советского театра» (1981) һ.б. җыентыкларда Тукай әсәрләрен, образларын сәхнәләштерү нечкәлекләре игътибарга алына. Әдәби мирас һәм Тукай текстологиясе белән шөгыльләнүче яшь галимнәргә диссертация темалары да шушы юнәлештә бирелә. Мисалга, Заһир Шәйхелисламов 1999 елны Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай образы

хакында кандидатлык диссертациясе яклап, монография бастырып чыгара [25]. «Тукай һәм татар әдәбияты» турында басмалар да һәрдаим әзерләнеп тора (Харрасова Р.Ф. Уйлар Тукайга илтә (2016) һ.б.). Динә Әхмәтова төзегән «Тукай в фотографиях» (2016) альбомы исә шагыйрьнең визуаль сурәтен заманча тергезә.

**Тукай һәм халык авыз иҗаты,** шулай ук, Институтта беренче кузгатылган темалардан булып, 1940–1950 елларда ук беренче академик фольклорчыбыз Хәмит Ярми Тукайның халык авыз иҗаты турындагы карашларын анализлый, иҗатының фольклор белән бәйләнешләрен тикшерә. Ул Тукай һәм халык авыз иҗаты багланышларын өйрәнүнең чикләрен шактый киң итеп билгели. Аның эзләнүләрен дәвам итеп, Хуҗи Мәхмүтов Тукай иҗатында канатлы гыйбарәләрне махсус игътибар үзәгенә куя. 1993 елны Ленар Җамалетдинов Г. Тукай иҗат иткән әкиятләрне татар халык әкиятләре белән янәшә куеп чагыштыруга багышланган кандидатлык диссертациясе яклый. Тукай иҗатындагы фольклор эзен барлауга бүгенге яшь галимнәр дә үз өлешләрен кертә.

XX–XXI гасырлар чигендә илдә идеологик ситуация үзгәреп, динирухани мирасны өйрәнү мөмкинлеге ачылуга, Институтта **Тукай иҗатында дини-әхлакый фикер-карашларны һәм Коръәни кануннар**ны өйрәнү махсус бер тармак буларак аерылып чыга. Айсылу Садекова, Фәрит Яхиннарның докторлык, Диләрия Абдуллинаның кандидатлык диссертацияләре шушы юнәлештә әзерләнә. Тулысынча Тукай иҗатында Коръән мотивларын тикшерүгә багышланган диссертация һәм монография [1], асылда, совет чорында урнашкан шагыйрь әсәрләренә атеистик мөнәсәбәтне тамырдан җимерә, мотивлар һәм образларга, аерым әсәрләрнең шәрехләмәләренә яңадан әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә.

**Тукай әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү,** шулай ук, Институтта даими алып барыла торган фәнни мәсьәләләрдән санала. Бу өлкәдә, аеруча, Илидә Бәширова хезмәтләрен аерып күрсәтергә кирәк. Аларда Тукай иҗатының татар әдәби теле формалашудагы роле ачыклана һәм дәлилләнә, галимә Тукай телендәге үзгәрешләрне, шагыйрь тел-стиле үзенчәлекләренең халык иҗатына, классик шәрык әдәбиятына барып тоташа торган тамырларын барлый. И. Бәширова эзләнүләре Тукай телен – XX йөз башы әдәби телен өйрәнүнең үзәгенә куя.

Хәлиф Курбатов Тукай шигырьләренең төзелеше, үлчәме-вәзене турында хезмәтләр яза, шагыйрь кулланган гаруз һәм силлабика хакында мәгълүматлар системасын формалаштыра. Ул Тукай шигыре төзелешен шәрык һәм гареб метрик системалары контекстына урнаштыра, татар шигыренең Шәрыктан – Гаребкә юнәлгән үзгәреш юлын шигырь төзелеше, форма һәм стильгә карап реконструкцияли.

Д. Рамазанова, Ф. Баязитова, Ф. Гарипова, М. Зәкиев, И. Сабитова һ.б. тел галимнәре хезмәтләрендә дә Тукай теле игътибардан читтә калмый. Тукай телен өйрәнү – татар тел белеме тарихының аерылгысыз бер өлешенә әйләнә.

Әлбәттә, Институт галимнәре арасында Тукай белән бәйләнешле аерым бер темаларны еллар дәвамында ялгызы эшләп баручылар да күп була, бу эш бүген дә дәвам итә. Тукайның тормышы-иҗаты хакында мәгълүматларны архив материалларын, истәлекләрне файдаланып яңарту юлында М. Гайнетдинов шактый хезмәт куя. Шагыйрьнең шәҗәрәсен эшләү, туганнарын

барлау, нәсел-нәсәбенең эпиграфик истәлекләрен өйрәнү мәсьәләләрендә Марсель Әхмәтҗановның тырышлыгын аерып күрсәтергә кирәк. Фатыйма Ибраһимова Тукайның балалар өчен иҗатын махсус өйрәнә, текстологик мәсьәләләр белән дә шөгыльләнә. Шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси һәм милли-фәлсәфи карашларын ачыклауга Яхья Абдуллин зур өлеш кертә. Нурмөхәммәт Хисамов, Кадрия Габбасова, Ләйсән Надыршина һ.б.лар – шагыйрь иҗатының әдәби-эстетик үзенчәлекләренә игътибар бирә. Әлфәт Закирҗанов, Равия Зарипова һ.б.лар Тукай иҗатын әдәби тәнкыйть, әдәбият белеме контекстында тикшерәләр.

Институтта моннан ярты гасырдан артык элек формалашкан Тукайны өйрәнү фәненең иң олы казанышы булып, 2016 елны Габдулла Тукай энциклопедиясе басылып чыга [7].

Мондый фундаменталь белешмәлек төзү фикере 1978 елларда әйтелә, аны күп еллар дәвамында Тукай текстологиясе, Тукай әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре белән шөгыльләнгән Нил Юзиев күтәреп ала. 1993–1996 елларда Институт галимнәре басманың гомуми концепциясен әзерлиләр. Башта аның сүзлек-белешмәсе басылып чыга, материаллар туплау барышында бер цикл китаплар языла (Хисамов Н.Ш. Тукайны төшенү юлында (2003) һ.б.).

8 юнәлешне колачлаган энциклопедия, асылда, бик күп яңа материаллар әзерләүгә юл ача, булганнарын системага салуны тәэмин итә. Анда әдипнең һәр әсәре аерым алып анализлана; моннан тыш, иҗатчының сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре җентекле күрсәтелә; шагыйрьнең туганнары, нәсел-нәсәбе, дуслары, ул аралашкан шәхесләр турында мәгълүматлар энциклопедик форматта языла; Тукайны өйрәнгән галимнәр, үз иҗатларында аның образын гәүдәләндергән яки ул тудырган образларны, детальләрне, мотивларны кулланган сәнгатьчеләр, аларның Тукай фәненә, милли мәдәниияткә, Тукайны популярлаштыруга керткән өлеше хакында материаллар әзерләнә. Мондый шәхесләрнең саны гына да 170 тән артып китә. Тукай иҗатын өйрәнгән башка миллләт галимнәре, аларның бөек шагыйребезгә карашы, Тукайның чит телләрдә, илләрдә тәкъдим ителеше һ.б. бик күп мәсьәләләр калкып чыга. Энциклопедия Тукай мирасын һәм шәхесен өйрәнүгә комплекслы якын килергә, шул ук вакытта Тукай фәне ачышларын барысын бер баш астына тупларга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Тукайны өйрәнү фәне XX гасырның 50–60 нчы еллары чигендә оешып бетә. Татарстанда Тукайны өйрәнү, аңа кагылышлы материалларны фәнни әйләнешкә кертү, анализлау һәм бәяләү, популярлаштыру эшен шушы академик фән җитәкли һәм алып бара.

Яңа ачылган Институтның үзен, андагы бүлекләрне җитәкләгән галимнәр, асылда, Тукайны өйрәнү фәненең структурасын планлаштырган, нигез баганаларын утырткан һәм төп темаларны билгеләгән, бу эшне гамәлгә ашырган шәхесләр дә булалар. Алар Тукайны өйрәнү фәнен гаять колачлы, масштаблы итеп күзаллап, баштан ук дисциплинаара махсус фән булып оешуын һәм үсүен тәэмин итәләр. Күп шәхесләрнең туктаусыз эзләнүләре, акыл хезмәте нәтиҗәсендә, аның күп тармакларында зур уңышларга ирешелә.

Үз чиратында, Тукайны өйрәнү фәне – гуманитар фәннәрнең әйдәп баручысы, аеруча XX йөз башы татар тарихын һәм мәдәниятен, рухи дөнья-

сын һәм милли омтылышларын тикшергәндә, XX гасыр дәвамында һәм XXI гасыр башында татар әдәбиятының, мәдәниятенең, сәнгатенең һәм фәненең, теленең үсеш үзенчәлекләрен билгеләгәндә – концептуаль нигез хезмәтен башкара. «Без – Тукайлы халык» (Р. Миңнуллин), Тукай рухи тормышыбызда гына түгел, югары мәдәнияттә һәм сәнгатьтә, фәндә дә кыйбла күрсәтә, менәр үрләрнең биеклеген билгели, татар дөньясына киләчәктә урын барлый.

ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллина Д.М. Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: Дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2005. – 225 б.; Абдуллина Д.М. Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 190 б.

2. Агишев Я. Габдулла Тукай – патриот. – Казан: Татгосиздат, 1942. – 53 б.

3. Агишев Я., Пехтелев И. Габдулла Тукай: биогр. очерк. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 40 с.

4. Башкуров Р. Тукай һәм рус әдәбияты: шагыйрьнең тәрҗемәләре турында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.– 120 б.

5. Башкуров Р., Воздвиженский В. Навсегда в сердце народа. – Казань, 1966. – 32 с.; Башкуров Р., Воздвиженский В. Һәрвакыт халык йөрәгендә. – Казан, 1966. – 32 б.

6. Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы / төз.: Ә.Х. Алиева, Ф.И. Ибраһимова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 271 б.

7. Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөх. З.З. Рәмиев. – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б.

8. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) / З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Г.М. Ханнанова, Ә.Х. Әлиева, Н.Ш. Насыйбуллина, Р.Ф. Харрасова, А.И. Әхмәтова. – Казан, 2018. – 448 б.

9. Гайнуллин М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во,1966. – 435 с.

10. XX йөз башы татар әдәбияты: Очерклар / Б. Гыйззәт, Г. Халит, Х. Хисмәтуллин. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 386 б.

11. Габдулла Тукай: Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары: 1886–1946. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 246 б.

12. Миннуллин К.М. Тукайны өйрәнү фәне: үткәне, бүгенге казанышларыбыз, киләчәк хакында уйланулар // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 3. – Б. 122–127.

13. Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз. З.Г. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 190 б.

14. Нуруллин И. Галим һәм тәнкыйтьче // Күренекле әдәбият галиме (Гали Халит тууына 100 ел). – Казан: Ихлас, 2015. – Б. 28–31.

15. Рамиев З. Текстология татарской литературы начала XX века. – Казань: Алма-Лит, 2008. – 188 с.

16. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. – Казан: Школа, 2000. – 180 б.

17. Рәмиев З.З. Тукай һәм замандаш әдипләр. – Казан: ТаРИХ, 2004. – 111 б.

18. Татар шигърияте: XX гасыр башы / төз. З. Рәмиев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 447 б.

19. Тукай Г.Академик басма. 2 томда. Т. 1. Шигырьләр: 1905–1913. / төз. Я.Х. Агишев, Х.Х. Хисмәтуллин. – Казан: Татар. дәүләт изд-восы, 1943. – 471 б.; Т. 2. Прозаик әсәрләр / төз. Х. Хисмәтуллин. – Казан: Татар. дәүләт изд-восы, 1943. – 567 б.

20. Халит Г. Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во,1956. – 232 с.

21. Халит Г. Многоликая лирика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 336 с.

22. Халит Г. Тукай үткән юл: Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 228 б.

23. Халит Г. Тукай и его современники. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. – 227 с.

24. Халит Г. Халык шагыйре Тукай: мәкаләләр. – Казан: Татгосиздат, 1939. – 91 б.

25. Шәйхелисламов З.Р. Аңлыем дип шагыйрь җанын...: Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай. – Казан: Фикер, 2001. – 144 б.

26. Юзиев Н. Мөхәммәт Гайнуллин // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 6: 1956–1985 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 635 –645.

УДК 821.512.145

# ПРЕДСТАВЛЕНИЕ О «ТАТАРАХ» И «ТАТАРСТВЕ» В ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ НАЧ. XX ВЕКА: Г. ТУКАЙ И М. ГАФУРИ

***Д.Ф. Загидуллина***
*Академия наук Республики Татарстан (Казань)*

В статье рассматривается формирование в татарской поэзии начала XX века мотива «татары», уточняющего образы «нация» и «мусульмане». В социально-политических стихотворениях Г. Тукая и М. Гафури 1905–1907 годов презентуется разговор лирического героя с соплеменниками о современном состоянии и перспективах этнического сообщества. Поэты называют себя представителями татарского народа. Параллельно проявляется представление о «татарстве». Опираясь на славную историю татар, идеализируя национальных героев, прибегнув к символизации, поэты воссоздают путь к прогрессу и в светлое будущее. Благодаря творчеству Г. Тукая и М. Гафури, мотив «татары» становится основной темой татарской литературы начала XX века.
**Ключевые слова:** татарская поэзия, Г. Тукай, М. Гафури, мотив, «татары», «нация», «татарство».

The article discusses formation in the Tatar poetry of the beginning of the XX century the «tatar» motif, clarifying the images of «nation» and «muslims». In the socio-political poems of G. Tukai and M. Gafuri 1905–1907 the conversation of the lyrical hero with his fellow tribesmen is presented on the current state and prospects of the ethnic community. Poets call themselves representatives of the Tatar people. In parallel, the idea of «Tatarism» is manifested. Based on the glorious history of the Tatars, idealizing national heroes, resorting to symbolization, poets recreate the path to progress and a bright future. Thanks to the work of G. Tukai and M. Gafuri, the motif «Tatars» becomes the main theme of Tatar literature of the early twentieth century.
**Key words:** Tatars poetry, G. Tukay, M. Gafuri, motive, «tatars», «the nation», «tatarstvo».

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА «ТАТАР» ҺӘМ «ТАТАРЛЫК» ТУРЫНДА КҮЗАЛЛАУ: Г. ТУКАЙ ҺӘМ М. ГАФУРИ

***Д.Ф. Заһидуллина***
*Татарстан Фәннәр академиясе (Казан)*

XX гасыр башы татарларда рус һәм европа мәдәниятләре үрнәгендә заманча дөньяви әдәбият формалашу һәм тизләнеп үсү чоры буларак билгеле. 1905–1907 еллар аралыгында сүз сәнгатебездә татар мотивы пәйда була һәм тиз арада татар әдәбиятының төп темасына әверелә. Шигърияттә бу үзгәрешне Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафури иҗатлары башлый һәм гамәлгә ашыра. Дөньяви татар әдәбиятының нигезенә милли идея, татар җәмгыятен үзгәртү омтылышы салына.

Шунысын да искәртергә кирәк, асылда мәгърифәтчел, җәмгыятьне гыйлем һәм мәдәният ярдәмендә үстерергә өндәү кысаларында шагыйрьләр башта этник бердәмлекне «милләт» яки «мөселманнар» дип исемлиләр. Күпчелек очракларда әлеге ике төшенчә бер-берсенә тәңгәл килә.

Бу катлаулы мәсьәләгә беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән Г. Ибраһимов Тукайның «И каләм!» (1906), «Шагыйрь вә Һатиф» (1906) кебек шигырьләренә сылтама ясап, болай ди: «Анда әле милләт «татар» түгел, «мөселман» иде, һәм тәдәнни вә тәрәкъкыйнең бердәнбер сәбәбе диннең

бозылуы һәм, төзәлеп, әүвәлге сафлыгына кайтуыннан вә шуңа багъланган гыйлем вә җәһаләттән дип кенә ышаныла...» [3: 150].

Шушы фикергә таянып һәм аны үстереп, әдәбият галиме Г. Сәгъди «Татар әдәбияты тарихы» (1926) хезмәтендә шулай ук Тукай иҗатында бу күренешнең хронологик чикләрен билгеләү омтылышы ясый: «Тукай башта ук динче, милләтче булып чыккан иде. Ләкин әле аның «милләт»е ул вакытта татар түгел, бөтен «әһеле ислам», «ислам милләт»е иде. Аның 1907 елгача булган дәверендәге шигырьләре аркылы энә шул юлда «ислам» һәм «милләт» кайгысы белән яну гайрәте чәчелә» [6: 91]. Аныңча, шагыйрь «1907 елдан башлап татар милләтчелеге баскычына күчә»; «Дин, милләт сүзен татар милләте мәгънәсенә күчереп, үзен шул «милләт»нең куркусыз, көчле бер көрәшче шагыйре булуын җырлый башлый» [6: 92].

Совет дәверендә шагыйрь иҗатын өйрәнү барышында «милләт» төшенчәсе «ил» һәм «халык» төшенчәләре белән якынайтылып каралды. Шуңа да әлеге мәсьәлә махсус өйрәнү объектына әйләнмәде.

Соңгы чорда, шагыйрьнең тууына 130 ел тулуга нисбәтле язмасында күренекле галим Юлай Шамилоглы кабат бу сорауга әйләнеп кайтты: «Тукайның милләтне аңлавы нәрсәдән гыйбарәт иде: Яңа заманга кадәр булган дини мәгънәдәме (ягъни күп кенә галимнәр тарафыннан кулланылган «мөселман милләте»ме), әллә хәзерге милли җәмгыять мәгънәсендәме? Бу сорауга минем төгәл җавабым юк» [7: 101].

Г. Тукайның «Милләтә» шигыренә мөрәҗәгать итеп, ул мондый сорау куя: «Милләткә мәхәббәт дигәндә милләт исеме астында кемнәр күздә тотыла? Биредә дини җәмгыять, этник җәмгыять яисә хәзерге аңлаешта милләт турында сүз баруны дәлилләрлек билгеләр юк. <...> Бу шигырьдә халыкка карата булган хисләр, дәрт һәм мәхәббәт турында сүз бара, әмма халык милләт белән тәңгәлләштерелми. Монда башка, әйтик, «татар» атамасына яки туган җиргә сылтамалар да юк. Аларның булмавы, бәлки, милли үзаңның формалашып кына килүе, башка «үзаңнар» арасыннан арынып чыга башлавы турында сөйлидер дә» [7: 102].

Чыннан да, Г. Тукай «Милләтә» (1906 ел, октябрь) шигырендә, милләтенә эндәшеп, аны «бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле» дип атый, милләт ваемы белән янып яшәвен, аңа каләм көче белән хезмәт итәргә теләвен яңгырата:

*Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;*
*Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем.*
*Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;*
*Сатмазым бу Кяинатә милләтем, миллиятем* [3: 127].

Шигырьдә «татар» сүзе кулланылмый, әмма 1906 елның ахырына поэзиядә, Г. Тукай һәм М. Гафури тырышлыгы белән, «милләт» төшенчәсе «татар» мәгънәсендә урнашып җиткән була. Лирик герой: «Дөнья бирсәләр дә, милләт, миллиятемне сатмам» дип раслый, текстка «миллият» – милли үзаң, миллилек мәгънәсендәге яңа төшенчә килеп керә.

Чыннан да, XX гасыр башы татар шигърияте күзәткәндә, 1905 ел дәвамында Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатларында «татар» сүзенең бүген без куллана торган «татар милләте» мәгънәсендә калкулануы күренә. Алай гына да түгел: «татар милләте» турындагы күзаллауның «мөселман милләте» чикләреннән аерылып чыгуы татар поэзиясенең мәгърифәтчелектән – миллилеккә борылуын тәэмин итә.

Беренче тапкыр «татар» атамасы шагыйрьнең 1905 елның җәй аенда язылган [4: 327] «...Голүмең бакчасында…» («Гыйлемнәр бакчасында») шигырендә кулланыла. Белемне җәмгыятьне яктылыкка чыгару юлы дип ассызыкланган шигырьдә Г. Тукай татар әдәбияты өчен магистраль фикерне формалаштыра: «*Татарлар рәфгате, шаны сикез кат күкләрә китсен; / Әбәд-сәрмәд бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен!*» [4: 35]. Текстта «татар» белән янәшә килгән «милләт» тагын бер кабатлана: «*Сарылды милләтең яшь каһарманлары каләмләргә...*». Әмма милләтнең кем икәне аңлашыла: шагыйрь аны болгарлар варисы дип ассызыклый. Шул рәвешле, милләтнең бер битараф булмаган улы булып күренгән лирик геройның журналларның төрен күбәйтик, мәгарифтә шөһрәт казаныйк, газеталарны арттырыйк, уяныйк дигән мөрәҗәгате татар җәмгыятенә юнәлтелә.

Тукай «милләт» төшенчәсен «мөселманнар» дип шәрехләү мөмкин булган шигырьләр дә яза. «Шигырь» (1905 ел, декабрь), «Алла гыйшкына» (1906, гыйнвар) шундыйлардан. Әйтик, әхлаклылыкка, мәгърифәткә өндәгән «Алла гыйшкына» шигырендә, «милләт» белән бергә, «Мөхәммәд өммәте» сүзе кулланыла һәм төшенчәнең аңланылыш кырын киңәйтеп җибәрә. Күрәсең, бу хәл лирик герой омтылышының дини күзаллау чигендә: милләтнең алдынгы, әхлаклы, белемле, һөнәрле булуы – илаһи таләп, Алла теләге; милләт мәнфәгатен кайгырту, аны үстерү – мөселман өчен фарыз эш – дип шәрехләнүенә бәйле була.

Публицистикасында да шулай. Уральск шәһәрендә 1906 елның апрелендә язылган «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» язмасында «милләт» сүзе беренче карашка татарларга карый кебек тоела. Әмма Тукайның әңгәмәдәшенә «...синең бабаларың булган Бәгъдад вә Әндәлес әһалисе...» [5: 42] дип эндәшүе аның өммәт мәгънәсен алга чыгара.

Иҗтимагый-сәяси лирикада Тукай 1905 елның ахырыннан татар милләте төшенчәсен даими куллана башлый. «Хөррият хакында» (1905 ел, декабрь) шигырендә ул милләтләрне «татар урыс, япун» дип санап үтә [4: 53]; «Дустларга бер сүз»дә (1905 ел, декабрь) «милләт» сүзе шулай ук этнос мәгънәсендә килә; «Иттифакъ хакында» (1905 ел, декабрь) шигырендә «*Кайчанга чаклы татар / Ушбу уйкуда ятар*?» [4: 58] дип борчыла. Публицистикасында төшенчә 1906 елның июнь санында басылган «Иске заманда татарларның пайтәхете улан бер шәһәрдә бер мөсафир илә шул шәһәрдә торучы кешеләр арасында» язмасының исемендә кулланыла. 1906 елның сентябрендә басылган «Хиссияте миллия»дә «милләт» төшенчәсе «татар» белән тәңгәлләштерелә: Тукай татар дөньясы, аның ваемы һәм ихтыяҗлары турында сөйли.

1905 елны язылган иң соңгы шигырьләреннән булган «Хәзерге хәлемезә даир»дә «татарлык» сүзе килеп керә, шуның ярдәмендә шагыйрь халкына хас менталитет, холыкны күзаллый, шул идеаль сурәткә туры килмәгән сыйфатларны тәнкыйтьли. Шагыйрь татарлык асылын тарихта, милли холыкта, хыял-омтылышларда, эш-гамәлләрдә таба. 1906 ел дәвамында иҗат ителгән һәм кызларга, яшьләргә, сәясәтчеләргә, сәүдәгәрләргә, руханиларга, шәкертләргә адресланган күпсанлы багышлауларда («Татар кызларына», 1906; «Хатыннар хөррияте», 1906; «Гәзитә мөрәттибләренә», 1906; «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», 1907; «Мөхәрриргә», 1906; «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә», 1906; һ.б.) татар характеры шундый үлчәүгә салынган. Тукай, әйтерсең лә, татар җәмгыятенең төрле катлауларына юнәлтелгән риторик эндәш ярдәмендә халкының бүгенгесе – караң-

гы, ә киләчәге һәркемнең шәхси ныклыгына һәм активлыгына бәйле булуны ишеттерергә тели.

Һәр шигырьдә укучысы – татар кешесе белән әңгәмә корган шагыйрь 1906 елның ноябрендә иҗат ителгән «Үз-үземә» шигырендә үз күңеле белән сөйләшүне тергезә, үз максаты турында сөйли, татар булуын ассызыклый: *«Күңел берлән сөям бәхтен татарның, / Күрергә җанлылык вактын татарның. // Татар бәхте өчен мин җан атармын: / Татар бит мин, үзем дә чын татармын»* [4: 133].

М. Гафури иҗатында да «татар» сүзе, Тукай иҗатындагы кебек үк, 1905 елны күренә: «Алмашыну» (1905, ноябрь) шигырендә, каләмен кузгаткан максатны күрсәтеп, ул болай ди:

*Караңгы бары бетеп, таңнар атар,*
*Ни сәбәпле безнең халык гафил ятар?*
*Һәрничек гафил яту ярамас дип,*
*Шигырь язды Габделмәҗид – ибне татар* [2: 16].

Ягъни *татар улы Габделмәҗит*нең халыкны йокыдан, ваемсызлыктан уяту максаты белән шигырь язуын хәбәр итә.

М. Гафури иҗатында татар улының – үз халкы, үз кавемдәшләре белән сөйләшү сурәте тудырыла. Шуннан соң иҗат ителгән күпсанлы шигырьләренең һәркайсы диярлек шундый сөйләшү-диалог формасын ала: «*Йә татар! Вакыт йитте кузгалырга, / Мәгариф шәмгыданын кулга алырга; / Тәфәккерсез, гафил булып карап ятмый, / Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!*» («Өндәү», 1905) [2: 20]; «*Кояш чыкты, эш башланды ушбу көндә, / Иншә Алла, инде татар карап ятмас*» («…Ничә йөз ел изелгәнгә татар юаш…», 1906) [2: 21] һ.б.

Бигрәк тә 1907 елны басылып чыккан «Милләт мәхәббәте» дигән күләмле җыентыкка тупланган шигырьләрдә ике кабатлана торган ачкыч-образ пәйда була: милләт (татар) һәм ватан: «Мәкъсуд», «Безнең хәл», «Татар милләтенең лисане хәле илә шикаяте», «…Сән күрендең күзләрә…», «…Милләтем улганга татар, бән дә улдым бер татар…» һ.б. Әмма шагыйрь үзенең татар милләтен мәгърифәткә, уяныырга, башка милләтләр кебек үсәргә генә чакырып калмый, ул мәгърифәтчелек мотивларын милли мотивларга буйсындыра. Әйтик, «…Алар бездән оялганнан…» (1907) шигырендә милләтнең алгарышы «татарлык» дигән хис, тойгының булуы белән бәйләнә. Күп кенә шигырьләрдә шушы «татарлык»ны үстергән сыйфатлар барлана: тарих («Бер татар шәкертенең Казанда мәшһүр хан мәсҗеденең манарасыны күргәндәге иншад итдеге шигыредер»), дин («…Алар мәгъбүд дигән бәндә…»), акыллы әйдәманнар («…Милләткә хадим улган яхшыларга…»), милли мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен кую («…Һәр кешенең үз нәфсенә йитсә көче…»), әдәбият («Күңел»), туган тел («Әдәбият кичәсенең соңында укылган шигырь») шундыйлардан. Бу яктан да М. Гафури иҗаты Г. Тукай иҗаты белән аваздаш.

Шагыйрь шәхесе белән тәңгәл килгән лирик герой монологы (үз-үзе белән сөйләшүе) кебек язылган «…Гафури, сән онытма милләтеңне…» (1907) шигырендә риторик эндәш ярдәмендә үзен милләткә хезмәт итәргә, бу юлда тырышырга, татарның җитешсезлекләрен үзенә күрсәтергә чакырып, суфи шигырьләрдәгечә, милләт юлында корбан булу мотивы («*Тәләф улсаң тәләф ул ушбу юлда*» [2: 50]) калкуландырыла, милләткә хезмәт идеясе әйтелә. «Икенче сада» (1907) шигырендә милләтне ярату халәте

тасвирлана, үзенең милләткә хезмәтне изге юл дип санавы хакында сөйләүче лирик герой укучыга, милләттәшләренә дә чакыру белән эндәшә: «*Безләр, и туган, анадан туган / Булырга корбан милләт юлына*» [2: 51]. «…Һәр кешенең үз нәфесенә җитсә көче…» (1907) шигырендә М. Гафуриның бөтен иҗаты буйлап сызылып барачак, кеше өчен кирәкле, мөһим сыйфатлар төсендә аерылган – хаклыкка хезмәт итү, уйлап эшләү, башкалар мәнфәгатен кайгырту мотивлары алга чыга. «*Иң әүвәл үз-үзеңне яхшы саклап, / Шуннан соң милләтеңә бул көтүче*» [2: 31], дип, милләтне әйдәп бару өчен, кеше үзе көчле шәхес булырга тиеш дигән иҗтимагый характерлы идея әйтелә.

Шулай итеп, яшь Тукай һәм М. Гафуриның 1905 елда иҗат ителгән беренче шигырьләре үк халыкта милли үзаң булдыруга, милли җәмгыятьнең – татар милләте булуын халык күзаллавына урнаштыруга хезмәт итә. Бу урында күренекле әдәбиятчы Виссарион Григорьевич Белинский сүзләрен искә төшереп үтү урынлы булыр: «Әдәбият – халыкның сүздә чагылыш тапкан иң соңгы һәм иң бөек фикере <...>. Җәмгыять әдәбиятта үзенең идеал югарылыгына күтәрелгән, чын тормышын таба, шуны аңында ныгыта» [1: 87]. 1906–1907 елларда татар шагыйрьләре милли алгарыш турында татар халкының фикерләвен үзгәртерлек күзаллау булдыралар. Үз иҗатлары белән алар әдәбиятта милли идеянең – өммәт турында күзаллаудан алга чыгуын, татар мәсьәләсенең лейтмотивка әйләнүен тәэмин итә. Татар булуың белән горурлану, татарлыкны сакларга һәм ныгытырга чакыру шигъриятебездә иң гүзәл фикерләрдән берсе булып ныгый.

ӘДӘБИЯТ

1. Белинский В.Г. Общее значение слова литература // Белинский В. Г. Собрание сочинений в трех томах. Т. 2. – М.: ОГИЗ Гослитиздат, 1948. – С. 86–114.

2. Гафури М.Н. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 351 б.

3. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 6: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Б. 112–181.

4. Тукай Г.М. Әсәрләр. 6 томда. Т. 1: шигъри әсәрләр (1904–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.

5. Тукай Г.М. Әсәрләр. 6 томда. Т. 3: мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр (1904–1906). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.– 415 б.

6. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы // Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз. Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. – Казан: «Җыен» нәшр., 2008. – Б. 52–189.

7. Юлай Шамилоглы. Габдулла Тукай һәм татар үзаңы: чит илдән бер караш // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 4. – Б. 100–105.

УДК 821.512.145

## К ВОПРОСУ ОБ ИЗДАНИИ ЛИТЕРАТУРНОГО НАСЛЕДИЯ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ В АЗЕРБАЙДЖАНЕ

***Иса Габиббейли***

*Национальная Академия наук Азербайджана*

*Институт литературы имени Низами Гянджеви (Баку)*

Литературное наследие великого сына татарского народа, публициста, журналиста, общественно-политического деятеля, поэта-классика татарской литературы, великого друга Азербайджана Габдуллы Тукая (1886–1913), 135-летний юбилей которого отмечается с большой торжественностью, изучается и пропагандируется в нашей стране на протяжении многих лет. Его произведения были переведены на азербайджанский язык видными поэтами и переводчиками, опубликованы на

страницах газет и журналов, избранные образцы его поэзии изданы отдельной книгой.
Стихи и эпические произведения Габдуллы Тукая включены в учебники для студентов высших учебных заведений, его творчество преподается в высших учебных заведениях Азербайджана.
В этой статье говорится о переводе и издании произведений великого поэта на азербайджанский язык до настоящего времени.
**Ключевые слова**: Азербайджан, Габдулла Тукай, поэзия, вопросы перевода, литературные связи, татарская литература.

The literary heritage of Gabdulla Tukay (1886–1913), the outstanding representative of the Tatar people, publicist, journalist, socio-political figure, classic of Tatar literature, great friend of Azerbaijan, whose 135th anniversary was marked, has been studied and promoted in our country for many years. His works have been translated into our language by the prominent poets and translators of Azerbaijan, printed on the pages of newspaper and journals, and selected examples from his poetry have been published as a book.
Gabdulla Tukay's poems and epic works are included in textbooks prepared for students, and his creativty is taught in the universities of Azerbaijan. In this paper is dealt with the issues of translation and publication of the great poet's works published in the Azerbaijani language so far.
**Keywords**: Azerbaijan, Gabdulla Tukay, poetry, translation issues, literary relationships, Tatar literature.

Благодаря природному таланту и неисчерпаемому вдохновению, отличающих творчество Габдуллы Тукая (1886–1913), он и сегодня считается самым популярным татарским поэтом в нашей стране. Однако, к большому сожалению, азербайджанские читатели знакомы с его поэзией только с 50-х годов XX века и это имело объективные причины.

Как известно, через несколько лет после кончины поэта, 25 октября 1917 года, в царской России произошла октябрьская революция. Волна этой революции прокатилась по всей Российской империи, в которую входили многие подвластные народы, в том числе азербайджанский, татарский и др. В этот период в Азербайджане в результате национально-освободительной борьбы против царской России было создано первое на Востоке парламентское государство – суверенная Азербайджанская Демократическая Республика (28 мая 1918 – 28 апреля 1920 г.), в которой начали действовать демократические институты, прежде всего парламент. Однако пришедшие к власти в России большевики очень скоро захватили власть в Азербайджане и 28 апреля 1920 года АДР пала. Начиная с этого периода, большая часть прогрессивной интеллигенции была истреблена либо вынуждена была эмигрировать за рубеж. Многие из оставшихся в стране, как известно, стали жертвами жестоких репрессий 1933–1937 годов. Среди них были и представители творческой интеллигенции, знакомые с творчеством Габдуллы Тукая. Таким образом, применительно к определённому периоду говорить о хорошем знакомстве с литературно-журналистской деятельностью Габдуллы Тукая Азербайджане практически не приходится.

Аналогичная историческая ситуация имела место в Татарстане. И это, естественно, нанесло большой урон многовековым литературным связям между Азербайджаном и Татарстаном.

Реформа алфавита, проведённая в эти годы в Азербайджане, также послужила барьером к широкому распространению в стране литературного наследия Тукая.

Другим негативным фактором явилась дискриминационная политика большевистской власти в отношении тюркских народов. Не случайно в употребление был введён термин «тюркоязычные народы», акцентировавший тот факт, что общим у этих народов является только язык. К великому сожалению, этот штамп до сих пор ещё не вышел из оборота. В силу указанных причин за 70 лет коммунистического правления в Азербайджане не было издано ни одной книги татарского поэта. То же относится к изданию в Татарстане произведений азербайджанских писателей.

После смерти Сталина 5 марта 1953 года, как известно, в СССР начался период, вошедший в историю как «оттепель», коснувшаяся и гуманитарной сферы. Начиная с этого периода, в стране устанавливаются определённые связи между народами в области культуры, проводятся различные декады, юбилейные мероприятия. Причём юбилеи видных деятелей культуры, литературы проводились как в республиках, так и в Москве.

С данного периода как в самом Татарстане, так и за его пределами было положено начало широкому изучению творчества Габдуллы Тукая. Что касается перевода и издания в Азербайджане образцов творчества Габдуллы Тукая, следует подчеркнуть, что первая работа в этой области связана с именем известного литературоведа, имеющего видные заслуги в изучении и пропаганде в нашей стране литературы тюркских народов, профессора Панаха Халилова. Дело в том, что, несмотря на идеологические препоны, татарский народ ещё в 1953 году отметил 40-летие со дня смерти своего великого сына. Данное событие имело резонанс в Азербайджане, где начали интересоваться творчеством Габдуллы Тукая. Профессор Панах Халилов в последующие годы в подготовленные им учебники для студентов Азербайджанского Государственного Университета включил очерк о Габдулле Тукае и образцы из его поэзии. В «Хрестоматию литератур народов СССР», подготовленную учёным в 1956 году, после кратких сведений о татарском поэте, были включены такие образцы его поэзии, как «Своему народу», «Раздумья татарского поэта», «Не уйдём», «Сочувствие», «Кто тебя знал, любимая», «Той девушке», переведённые самим профессором на азербайджанский язык [19: 485–489].

В советскую эпоху в Азербайджане было крайне недостаточно опубликованных образцов поэзии Габдуллы Тукая. Рубежным в этом плане стал 1976 год, когда в Татарстане был торжественно отмечен 90-летний юбилей народного поэта, отклики которого были услышаны в Азербайджане, где состоялись юбилейные мероприятия в честь Г. Тукая. Прежде всего в печати были опубликованы стихи поэта, переведённые на азербайджанский язык. В частности, в журнале «Азербайджан» были напечатаны стихотворения Габдуллы Тукая «Родной земле» и «Книга» в переводе Лятифа Велиева [8: 158–159].

В газете «Азербайджан муаллими» была опубликована статья «Великий гражданин, могучий поэт» талантливого азербайджанского поэта, борца за независимость Халила Рзы Улутурка (21.X.1932–22.VI.1994), имеющего видные заслуги в развитии азербайджанско-татарских литературных связей [4: 4]. Статья Халила Рзы, не скрывавшего своё восхищение творчеством безвременно ушедшего из жизни татарского поэта, начиналась следующими предложениями: «Нельзя без восхищения читать четырёхтомник стихов прожившего всего 27 лет гениального татарского поэта, творчество которого

сегодня является народным достоянием; за отведённый ему судьбой очень короткий срок этот человек удостоился прожить мудрую,.. закалённую в борьбе жизнь рыцаря искусства поэзии и ушёл, познав все четыре смены времён жизни» [4: 4].

Чествование в нашей стране юбилея поэта явилось важным стимулом к созданию переводов его произведений на азербайджанский язык. Первые переводы принадлежали перу Халила Рзы, который, в частности, дал два из них («Голос горького опыта» и «Звезда души») в конце своей статьи, о которой говорилось выше [6: 4].

В том же году Халил Рза Улутурк перевёл несколько стихов Габдуллы Тукая на азербайджанский язык, которые были опубликованы в печати. Такие стихотворения, как «Придёт», «Душа», «На память», были опубликованы в журнале «Азербайджан» [9: 157–158], стихи «Сожаление», «Цену твою» – в газете «Азербайджан гянджляри» [14], «Есть ли надежда?» и «Ель» – в газете «Адабият ве инджесенет» [15: 5].

Однако обращение Халила Рзы Улутурка к творчеству Габдуллы Тукая не исчерпывается отмеченным. Проявлявший большой интерес к поэзии народов советского пространства, неустанно занимавшийся переводами из творчества братских народов, Халил Рза в 1982 году издал отдельной книгой выборку из своих переводов под названием «Венок братства», в который включил 5 стихотворений Тукая, переведённых им в разные годы [21: 126–133].

В статье народного поэта Мамед Араза «Великий певец татарского народа», написанной по случаю юбилея Тукая, отметившего проявление поэтического таланта татарского поэта ещё с его ранних лет, указывается: «Поэтическое мышление Тукая сформировалось очень рано, проявившись в изложении языком поэзии сложных событий эпохи. Словно судьба, ведавшая о заранее отведённом великому певцу коротком сроке жизни, одарила его талантом создания множества стихов, причём совершенных творений» [17: 63]. Высоко оценивая переводческий дар Тукая, автор статьи отмечает: «не каждому мастеру суждено за столь короткий срок прочувствовать глубину Гейне, Шиллера, Шекспира, Пушкина, Лермонтова и передать её в своих переводах» [17: 63]. Мамед Араз особо акцентировал большую ответственность в подходе Тукая к каждому произведению: «Тукай всегда высоко оценивал роль поэта, поэзии, отмечая необходимость постоянной учёбы у народа, познания народа, твёрдости на этом пути. Может, поэтому татарский народ видит в памятнике Тукая, возвышающемся в самом достопримечательном месте Казани, памятник своей совести» [17: 63].

В конце статьи автор указывает на большую любовь азербайджанских читателей к произведениям Тукая и представляет свой перевод стихотворения «Ученик» татарского поэта [17: 64].

После обретения Азербайджаном государственной независимости в нашей стране ещё более возрос интерес к творчеству Г. Тукая. Так, в 1992 году увидела свет книга Халила Рзы Улутурка под названием «Венок Турана», составленная из его переводов произведений поэтов тюркского мира. В книгу включено стихотворение Г. Тукая «Два пути» [10]. В 2007 году в газете «Каспий» были опубликованы стихотворения Тукая в переводе Х. Рзы [12].

В 1994 году народный поэт Халил Рза Улутурк, оставивший своё имя и в истории борьбы за независимость Азербайджана, покинул этот мир. Память поэта высоко почитаема его народом, произведения неоднократно

издавались после его смерти. И, можно сказать, во все издания включались его статьи о ГабдуллеТукае и переводы из творчества татарского поэта, которого он высоко ценил. В частности, статьи Х. Рзы «Жизнь, превращённая в факел», «Большой гражданин и могучий поэт», посвящённые Тукаю, о которых шла речь выше, вновь увидели свет в 2000 году, в книге «Будь похож на меня» [8], переводы стихов «Две дороги», «Душа» и «Ценю» вошли в книгу «Венок Турана» [11], переводы стихов «Голос горького опыта», «Две дороги», «Сильный мужчина», «Безнадёжность», «Душа» были включены в книгу «Окно в мир» [16].

Статья Халила Рзы «Большой гражданин и могучий поэт», написанная в честь 90-летия Г. Тукая, была перепечатана в 2008 году в «Адабият газети» [3: 3], в которой вновь увидели свет переводы азербайджанского поэта из Г. Тукая («Голос горького опыта», «Душа») [7: 1].

В 2000 году народным поэтом Азербайджана Анаром был издан II том антологии «Полуторатысячелетняя огузская поэзия», над которой автор трудился долгие годы. Составитель включил в избранные образцы творчества известных поэтов тюркского мира два стихотворения Габдуллы Тукая в собственном переводе – «Родной язык» и «Две дороги» [18].

С завоеванием Азербайджаном государственной независимости в стране ещё более возрос интерес к литературам тюркских народов, что было связано с общей тенденцией переосмысления и переоценки прошлого, возрождением генно-этнической памяти. Примерно за последние 30 лет в Азербайджане были изданы монографии, защищены диссертации в области исследования с новых методологических позиций литературного наследия видных представителей литератур тюркских народов, произведения которых были опубликованы в переводах на азербайджанский язык. Одна из таких книг была подготовлена и издана в 2011 году профессором Рамизом Аскером. В эту книгу под названием «Очерки по литературе тюркских народов – 1» были включены исследования о ряде классиков и современных мастеров слова тюркского мира, начиная от известного поэта и государственного деятеля Султан Гусейна Байкары до видного туркменского поэта Ораза Ягмура и гагаузского поэта Тодура Занета, а также образцы из их творчества. В том числе в издание вошли очерк о жизни и творчестве Габдуллы Тукая и его очерк-воспоминание «Что я помню о себе», а также азербайджанские переводы его стихов «К нации», «Родной отчизне», «Нищий», «Пара лошадей», «Показывает», «Горькая правда», «Родной язык», «Сон земли», «О свободе», «Балканские песни» и др., выполненные Рамизом Аскером [20: 208–249].

В честь 125-летия Габдуллы Тукая в Азербайджане была издана первая книга (тиражом в 1000 экземпляров) переводов стихов татарского поэта, выполненных профессором Рамизом Аскером. Книга открывается объёмной вступительной статьёй переводчика под названием «Великий татарский поэт Габдулла Тукай (1886–1913)». Включённые в книгу стихи даны на татарском и азербайджанском языках. В данное издание под названием «Моя нация» включены автобиографический очерк поэта «Что я помню о себе», поэмы «Мать воды», «Саманный базар, или Новый Кесикбаш» и множество образцов лирики [1].

Вторая книга, изданная в том же году профессором Рамизом Аскером, называется «Габдулла Тукай. Избранные сочинения» [2]. Составитель, как

и в первой книге, представил включённые в издание произведения на двух языках – татарском и азербайджанском. В данную книгу, предназначенную для широкого читателя, Рамиз Аскер включил свою объёмную вступительную статью «Великий татарский поэт Габдулла Тукай (1886–1913)».

По случаю же юбилея Габдуллы Тукая его поэма-сказка «Саманный базар, или Новый Кесикбаш» была издана в подстрочном переводе в виде отдельной книги сотрудником Института литературы им. Низами Гянджеви Хураман Гумматовой [13].

Габдулла Тукай является видным поэтом, оставившим после себя богатое литературное наследие. За последние годы в Татарстане проделана большая работа по приобщению широкого читателя к этой богатой сокровищнице, исследованию творчества поэта. И эта работа продолжается. Особого внимания заслуживает работа в области издания литературного наследия Г. Тукая. Большую источниковедческую значимость имеет шеститомное академическое издание литературного наследия Г. Тукая, а также двухтомника, в котором собраны воспоминания о нём современников, некоторые из которых были в своё время опубликованы. Все эти инициативы стимулируют новое поколение исследователей на дальнейшие разработки в области наследия поэта. Хочется надеяться, что и в Азербайджане в скором будущем появятся новые исследователи Габдуллы Тукая, авторы будущих серьёзных трудов о творчестве этой незаурядной личности.

Большое уважение, проявленное в Азербайджане к жизни и творчеству выдающегося классика татарской литературы Габдуллы Тукая, в широком смысле отражает дружественное и братское отношение к татарскому народу в нашей стране. В то же время исследования и ценные идеи азербайджанских литературоведов, поэтов и писателей о Габдулле Тукае являются братским вкладом в дальнейшее обогащение тукаеведения.

ЛИТЕРАТУРА

1. Abdulla Tukay. Millətim. Tatarcadan çevirən, tərtib edən və ön sözün müəllifi: Ramiz Əskər. – Bakı: MBM, 2011. – 268 s.

2. Abdulla Tukay. Seçilmiş əsərləri. Tatarcadan çevirən, tərtib edən və ön sözün müəllifi: Ramiz Əskər. – Bakı: «Nağıl Evi», 2011. – 268 s.

3. Xəlil Rza. Böyük vətəndaş, qüdrətli şair (Tatar şairi Qabdulla Tukayın anadan olmasının 90 illiyi münasibətilə). Ədəbiyyat qəzeti, 2008, 10 oktyabr. – S. 3.

4. Xəlil Rza. Böyük vətəndaş, qüdrətli şair // «Azərbaycan müəllimi» qəzeti, 1976, 23 aprel. – S. 4.

5. Xəlil Rza. Məşələ çevrilmiş həyat (Qabdulla Tukay); Böyük vətəndaş, qüdrətli şair // Xəlil Rza Ulutürk. Mənə bənzə: məqalələr. Toplayanı və tərtib edəni: F. Ulutürk; redaktoru: Z. Şahsevənli. – Bakı: Gənclik, 2000. – 708 s.

6. Qabdulla Tukay. Acı təcrübənin səsi; Könül ulduzu: [şeirlər]. Tərcümə edəni: Xəlil Rza // «Azərbaycan müəllimi» qəzeti, 1976, 23 aprel. – S. 4.

7. Qabdulla Tukay. Acı təcrübənin səsi; Könül: [şeirlər]. Tərcümə edəni: Xəlil Rza Ulutürk. Ədəbiyyat qəzeti, 2011, 4 fevral. – S. 1.

8. Qabdulla Tukay. Doğma torpağa; Kitab: [şeirlər]. Tatarcadan işləyəni: Lətif Vəliyev // «Azərbaycan» jurnalı. –1976. – № 4. – S. 158–159.

9. Qabdulla Tukay. Gələr; Yadımda: [şeirlər]. Tərcümə edəni: Xəlil Rza // «Azərbaycan» jurnalı, 1976, № 4. – S. 157–158.

10. Qabdulla Tukay. İki yol // Xəlil Rza Ulutürk. Turan çələngi. Redaktoru: Ş.Salmanov. Bakı: Elm, 1992. – S. 523.

11. Qabdulla Tukay. İki yol; Könül; Qədrini // Xəlil Rza Ulutürk. Turan çələngi. Tərtib edəni: F.Ulutürk; redaktoru və ön sözün müəllifi: Ə.Əsgərli. – Bakı: QAPP-POLİQRAF, 2005. – 873 s.

12. Qabdulla Tukay. Qədrini; İki yol; Könül: [şeirlər]. Tərcümə edəni: Xəlil Rza Ulutürk // «Kaspi» qəzeti. – 2007. – 17–19 fevral. – S. 18.

13. Qabdulla Tukay. Saman bazarı, yaxud Yeni Kəsikbaş. (Azərbaycan tərcüməsinə uyğunlaşdıran və ön sözün müəllifi Xuraman Hümmətova). – Bakı: Elm və Təhsil, 2011. – 152 s.
14. Qabdulla Tukay. Təəssüf; Qədrini: [şeirlər]. Tatarcadan işləyəni: Xəlil Rza // «Azərbaycan gəncləri» qəzeti. – 1976. – 24 aprel.
15. Qabdulla Tukay. Ümid varmı?; Küknar ağacı: [şeirlər]. Tatarcadan işləyəni: Xəlil Rza // «Ədəbiyyat və incəsənət» qəzeti. – 1976. –1 may. – S. 5.
16. Qabdulla Tukay. Vaysınma; Acı təcrübənin səsi; İki yol; Qüdrətli kişi; Ümidsizlik; Könül // Xəlil Rza Ulutürk. Dünyaya pəncərə. Tərtib edəni: F.Ulutürk; redaktoru: Ə. Əsgərli; ön sözün müəllifi: Ə. Əsgərli, N. Tağısoy. – Bakı: Çinar-Çap, 2010. – 1151 s.
17. Məmməd Araz. Tatar xalqının böyük nəğməkarı // «Ulduz» jurnalı. – 1976. – № 4. – S. 63–64.
18. Min beş yüz ilin oğuz şeiri. Antologiya. İki cilddə. II kitab. Şeir mətnlərinin, müəlliflər və əsərlər haqqında məlumatların, lüğətin tərtibçisi, ön və son sözlərin müəllifi Anardır. – Bakı: Azərbaycan, 2000. – S. 909.
19. Pənah Xəlilov. Qabdulla Tukay // SSRİ xalqları ədəbiyyatı müntəxabatı. Tərtibçi: Pənah Xəlilov. Ali məktəblərin filoloji fakültəsi üçün dərslik. – Bakı: Azərbaycan Universitetinin nəşriyyatı, 1956. – S. 485–489.
20. Ramiz Əskər. Türk xalqları ədəbiyyatı oçerkləri-1. – Bakı: MBM, 2011. – S. 208–249.
21. Tatar poeziyası. Abdulla Tukay // Qardaşlıq çələngi. Tərtib və tərcümə edəni: Xəlil Rza. Elmi redaktoru: Abbas Abdulla. – Bakı: «Maarif» nəşriyyatı, 1982. – S. 126–133.

УДК 82.091

## ПОЭТИЧЕСКАЯ РОДИНА Г. ТУКАЯ

***Н.С. Камарова***
*Каспийский университет технологий и инжиниринга им. Ш. Есенова*
*(г. Актау, Казахстан)*

В этой статье говорится, что поэтической родиной Г. Тукая является Уральск. А так же рассказывается о музее Г. Тукая г. Уральске и о том, что в конце XIX века, времени когда рано осиротевший Г. Тукай был привезен на жительство к своим уральским родственникам. Живя в Уральске, Г. Тукай не мог оставаться в стороне от устремлений и вековых чаяний казахского народа. В этом городе родились основные стихи поэта и поэт записывал казахские песни и легенды. Культурное многообразие Уральска способствовало становлению многоликого творчества Тукая, открытого межлитературным и межкультурным диалогом.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, поэт татарского народа, поэтическая родина, Уральск, музей, межкультурный диалог.

This article says that the poetic homeland of G. Tukai is Uralsk. It also tells about the museum of G. Tukay in Uralsk and that at the end of the 19th century, when the early orphaned G. Tukay was brought to live with his relatives in the Urals. Living in Uralsk, G. Tukai could not stay away from the aspirations and age-old aspirations of the Kazakh people. The main poems of the poet were born in this city and the poet wrote down Kazakh songs and legends. The cultural diversity of Uralsk contributed to the formation of the many-sided creativity of Tukay, open to interliterary and intercultural dialogue.
**Key words:** Gabdulla Tukai, poet of the Tatar people, poetic homeland, Uralsk, museum, intercultural dialogue.

4 ноября 1906 года в Уральске было создано Уральское мусульманское благотворительное общество. Его председателем был избран Валидулла Хамидуллин, казначеем – Муртаза Губайдуллин, секретарем – Камиль Мутыги. Общество оказывало благотворительную помощь мусульманскому населению, татарским учебным заведениям города, а в годы Первой мировой войны – в пользу Временного мусульманского комитета по оказанию помощи раненым воинам.

Таким образом, в конце XIX века, времени когда рано осиротевший Г. Тукай был привезен на жительство к своим уральским родственникам (в семью Галиасгара Усманова), Уральск был одним из городов, в котором проживало значительное число татар, а татарское население Уральска играло весомую роль в экономической, социальной и культурной жизни города и региона.

Живя в Уральске, Г. Тукай не мог оставаться в стороне от устремлений и вековых чаяний казахского народа. Он ездил в казахские аулы, общался с молодой казахской интеллигенцией, записывал казахские песни и легенды. Большое впечатление на Тукая производили айтысы акынов. Позже, выступая в Казани с лекцией о татарском народном творчестве, он расскажет о поэтическом мастерстве «встречных песнопений у казахов». Он старался привлечь казахскую интеллигенцию к сотрудничеству в тех газетах и журналах, которые он редактировал. Так, в газете «Фикер» находили место корреспонденции и письма из Кустаная и Петропавловска, Гурьева и Атбасара, Челкара и Казалинска. Не случайно 1 января 1906 года за подписью: «Сын казаха» была опубликована заметка, в которой были и такие строки: «Пусть “Фикер”, горящий, как светильник на крыше в темную ночь, светит долго и пусть живет долго». Это было выражением сердечной признательности читателей-казахов тукаевской газете. Очень близко принимал к сердцу Тукай несправедливое, высокомерно черносотенное отношение к нерусским народам. Некий Черевинский выступил в реакционной печати со статейкой, в которой грубо и неуважительно отозвался о жителях степи. Тукай с негодованием дал отповедь шовинисту. Двадцатилетний поэт выдвинул идею создания в Уральске учительского института, в котором могли бы учиться казахи, и представители других тюркоязычных народов. В газете «Фикер» систематически освещалась эта проблема. Совместно с казахскими друзьями, Тукай организовал сбор средств в фонд будущего учебного заведения. Коллективное письмо в Санкт-Петербург с просьбой открыть в Уральске учительский институт подписали наряду с Тукаем Б. Каратаев, И. Арганчеев и другие. Однако разрешение не было получено.

Последний год жизни Тукая в Уральске – 1907-й – был для поэта тяжелым и нерадостным. Татарские журналы и газеты были закрыты. Но имя молодого поэта было уже широко известно не только в Казани. Весть о талантливом поэте прокатилась по всему тюркоязычному миру. Тукай возвращается в отчие края, куда его настойчиво приглашали виднейшие деятели литературы и общественной мысли Казани. Расставаясь с Уральском, поэт посвятил ставшему родным городу полные сыновьей любви строки:

В Казани Тукай прожил недолго – он умер 15 апреля 1913 года. Это горестное событие было отмечено некрологами и в казахских газетах и журналах. Ведь казахский читатель воспринял творчество гениального татарского поэта как близкое, свое еще при его жизни. Оно вдохновляло Султанмахмуда Торайгырова, Сабита Донентаева и других казахских поэтов на создание своих талантливых произведений. Стихи Габдуллы Тукая в переводах на казахский язык, увидели свет еще в дореволюционные годы, а позже они, в переводах Ж. Сыздыкова и других казахских поэтов издавались неоднократно. «Гордой и прогрессивной» называл поэзию Тукая Мухтар Ауэзов. Другой выдающийся представитель казахской литературы Сабит Муканов в автобиографическом романе «Школа жизни» писал, что Тукай открыл ему глаза на мир. «Многие писатели и поэты тюркоязычных народов – утверждал

он, – прошли литературную школу Тукая, учились у него художественному мастерству, явились его учениками в буквальном смысле этого слова».

12 декабря 2006 года в городе Уральске был открыт музей Габдуллы Тукая. Здание Дома-музея расположено в исторической части города, в районе Татарской слободы, в доме имама Красной мечети Мутыгуллы хазрата Тухватуллина – учителя и наставника Г. Тукая в Уральске. Здесь Тукай проводил много времени в богатой библиотеке учителя а в подвале этого здания располагалась типография, где начинал работать наборщиком молодой Тукай. Постройка 19 века (зданию более 150 лет) отличается строгостью, лаконичностью и изысканным архитектурным вкусом и во многом являет собой культурную среду обитателей этого дома. Экспонаты музея воссоздают Уральск тукаевского периода конца XIX начала XX веков. В музее представлены разнообразные материалы – письменные источники, фотографии, ценные книги, предметы городского быта, столовая посуда, произведения изобразительного искусства, изделия декоративно-прикладного искусства, татарского народа конца XIX – начала XX веков. Некоторые экспонаты были установлены в музее, чтобы воссоздать общую картину жизни горожанина того времени, однако многие вещи действительно принадлежали семье Тухватуллиных. Наиболее высокой мемориальной ценностью обладают предметы, принадлежавшие людям из ближайшего окружения Габдуллы Тукая.

В Доме-Музее два этажа и подвальное помещение. На первом этаже воссоздана столовая – гостиная. Здесь собраны экспонаты домашнего быта: мебель, посуда, предметы домашнего обихода. Экспонаты в основном собраны горожанами из личных коллекций и вещей. На втором этаже три зала. В большом зале собраны письменные свидетельства, книги, документы, черно-белые фотографии, копии писем, написанные рукой поэта и пожелтевшие от времени полосы газет 12-летнего уральского периода жизни и творчества Г. Тукая. Здесь представлен экземпляр газеты, которую Габдулла Тукай набрал сам в Уральской типографии. Здесь собрано более 100 экспонатов, во многом свидетельствующих о том, что в Уральске, он состоялся зрелым журналистом, признанным поэтом, неистовым публицистом, сатириком, общественным деятелем, великолепно владеющим, помимо татарского, русским, арабским, персидским и турецким языками.

Особую ценность представляет застекленный кабинет Мутыгуллы Тухватуллина, где представлены подлинные экспонаты: письменный стол и стул из гостиной Мутыгуллы-хазрата – обивка на нем растрескалась и кое-где пошла морщинками, железная люстра, часы.

В целом внутри дома воссоздана атмосфера ушедших времен, что помогает посетителям дома музея зримо окунуться в то время, в котором жил Тукай. С открытием музея 130-летия со дня рождения Г. Тукая исполнилась давняя мечта казахстанцев. Город Уральск обогатился еще одним памятником истории, который зримо хранит богатую и славную культурную историю татарского народа. Татарская диаспора в Приуралье одна из самых активных в деятельности Ассамблеи народа Казахстана Западно Казахстанкой области.

Время, когда Г. Тукай начинал свою творческую деятельность совпало со временем обновления тарасой поэзии, которая в начале XX века переживает сой ренессанс. Средневековая татарская литература (вплоть до второй половины XIX века) развивалась, преимущественно, в диалоге с восточны-

ми литературами: арабской, персидской, тюркоязычными. В начале XX века диалогическое пространство татарской литературы расширяется, в ее орбите, наряду с восточными, оказываются русская и европейская литературы.

Поэзия Габдулла Тукая уральского периода была многоликой. Эта многоликость проявляется в тематическом, стилистическом, жанровом многообразии. В поэзии сосуществуют традиции восточной поэзии, вольные переводы из русской поэзии, стиховые формы средневековой тараской поэзии («Бакырган», «Сказание о Юсуфе», «Бадавам», «Мухаммадия») и фольклора, высокая книжная лексика и бранные слова.

Множественность не исключает тематической общности стихотворений, повторяющихся в них мотивов, образов. Таковыми являются мотивы просвещения, прогресса нации и связанный с ними тип авторского сознания – *миллэтпэрвэр* (тат. *милләтпәрвәр*). Именно эта точки зрения выражена во многих уральских стихотворениях поэта («К нации» («Милләтә»), «В чем сладость?» («Ләззәт вә тәм нәрсәдә?»), «Самому себе» («Үз-үземә») становясь основой самоидентификации автора:

Татар бәхте өчен мин жан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын

Я душу отдам за счастье татар:
Ведь я татарин, истинный татарин.
(«Самому себе». Подстрочный перевод)

Вместе с тем субъект сознания в стихотворениях Г. Тукая в большинстве стихотворений предстает как человек, не приемлющий лжи («Приятелю, который просит совета – стоит ли жить на свете»), искажения веры («Поэт и небесный голос»), безнравственности («В память о «Баквргане»). Авторская идентичность в этих стихотворениях определяется как точка зрения, основывающаяся на общечеловеческих ценностях.

Габдулла Тукай – не только поэт татарского народа, но и всего цивилизованного тюркского мира. Мы не забываем имя Габдуллы Тукая. Надеемся, что будущие поколения будут искать и читать произведения поэта.

ЛИТЕРАТУРА

1. Габдулла Тукай. Жизнь и творчество. Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая. – Казань: Академия наук Республики Татарстан Институт языка и литературы и искусства имени Г. Ибрагимова, 2018. – 448 с.

2. https://tatar-congress.org/ru/blog/uralsk-poeticheskaya-rodina-tukaya/

УДК 821.512.145

## ТУКАЙ И КАЗАНЬ

***Л.Р. Надыршина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье освещается казанский период жизни и творчества Габдуллы Тукая. Автор дает представление об окружении, повлиявшей на мировоззрение поэта, описывает основные направления его литературной деятельности. Творчество поэта рассматривается в литературно-культурном и историческом контекстах эпохи.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарская поэзия, национальный идеал, национальное возрождение, тема, мотив.

The article covers the Kazan period of the life and work of Gabdulla Tukai. The author gives an idea of the environment that influenced the poet's worldview, describes the main directions of his literary activity. The work of the poet is considered in the literary, cultural and historical contexts of the era.
**Key words:** Gabdulla Tukai, Tatar poetry, national ideal, national revival, theme, motive.

## ТУКАЙҺӘМ КАЗАН

***Л.Р. Надыршина***
*Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Уральскидан Казанга килеренә ярты ел кала, Тукай «Пар ат» шигырен иҗат итә, әсәр «Фикер» газетасының 1907 елгы 6 май санында басылып чыга. Строфадан строфага хисләр көчеше үзенчәлекле экспрессия тудырган бу шигырьдә лирик геройның күңел халәте Казан белән бәйле киләчәгенә олы өметләр баглаган шагыйрьнең эчке дөньясы белән тәңгәл укыла. Шул ук вакытта шигырь үзе Казанның татар дөньясының үзәге, татарларны туплап якты киләчәккә алып чыгасы изге урын буларак мифлаштыруны башлап җибәрә. Тормышындагы һәм иҗатындагы үзгәрешләрнең символик яңгырашы буларак кабул ителгән әсәрендә *«Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур»* дип ашкынулы өметләр белән янган шагыйрь шушы елның көзендә Казанга күчеп килә, татар халкының рухи мәркәзендә кайнап торган әдәби-мәдәни мохит аны үзенә алып кереп китә. Замандашлары билгеләвенчә, Тукайны «редакцияләрдә, көтепханәләрдә, «Шәрык клубы»нда, үзенә якын торган яшьләр – иптәшләре җыелып кала торган урыннарда» еш очратырга мөмкин булган [5: 138]. С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, Ә. Хәсәни, В. Бәхтияров, Г. Камал, Х. Ямашев, С. Сүнчәләй һ.б. күренекле шәхесләрдә ул үзенә фикердәшләр таба. Күргәнебезчә, шагыйрь аралашкан яңа даирә – милли җанлы, алдынгы карашлы, XX йөз башы татар иҗтимагый-мәдәни хәятендә күренекле урын алып торган, яңарыш дулкынында кайнаган шәхесләр, милли зыялылардан гыйбарәт була. 1907 елның 30 декабрендә үк Уральскидагы дусты Габдулла Кариевка язган хатында Тукай бу хакта үзе дә әйтеп үтә: *«Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп беттеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыкым Казанда иде. Әлхәмделиллаһ. Монда күңелле. Дуст-иш, зыялылар күп, сөйләшәбез, көлешәбез, укыйбыз, тәгаттый-е әфкярдә (фикер алышу) булынабыз»* [7: 415]. Гомумән, Тукай Казанга килгән вакытлар – милли яңарыш, үсеш дәвере, инкыйлаб китергән ирек-хөрлек сулышы белән рухланган татар зыялылары бер-бер артлы милли газета-журналлар чыгарган, татар театры сәхнәгә менгән, әдәби түгәрәкләр, «татар дөньясында гына түгел, империянең бөтен төрки-мөселман галәмендә беренчеләрдән булып оешкан» [4: 4] «Шәрык клубы» эшләгән чор ул. Тукайның Казандагы тормыш һәм иҗат юлы шушы милли күтәрелеш дулкыны белән үрелеп-керешеп бара, шагыйрь әдәби түгәрәкләрдә катнашып китә, төрле әдәби-мәдәни чараларда еш чыгыш ясый, ашкынып иҗат эшенә бирелә: инде Уральскида чакта ук Г. Шәрәф белән шигырьләр җыентыгын бастыру турында хат язышкан Тукайның бер-бер артлы шигырь җыентыклары дөнья күрә башлый.

Мәркәздә беренче айларыннан ук Тукай матбугат дөньясында кайный: Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров, Г. Камал кебек шәхесләр белән фикердәшлек, максат-карашлар һәм милли-мәдәни омтылышлар уртаклыгы «Әл-ислах»,

«Яшен» кебек татар басмаларында хезмәттәшлеккә китерә (*«Җитди вә көлмичә язган нәрсәләрне «Әл-ислах»ка бирәм. Һөҗүви вә көлке нәрсәләремне «Яшен»гә тапшырам» [7: 204]*, Ә. Урманчиев мөхәррирлегендә һәм наширлегендә дөнья күрсә дә, «Ялт-йолт» журналына нигез салучы, оештыручысы һәм идея җитәкчесе дә Тукай була (К. Бәкер, Г. Камал истәлекләрендә вафатына кадәр Тукайның журналда берүзе эшләве турында искәртелә), соңрак күренекле татар матбагачысы Ә. Хәсәни тырышлыгы белән чыгарылган «Аң» журналының «исем кушучысы, мөәссисләреннән (нигез салучыларыннан) берсе, иң эшлекле мөхәррире» [8: 177] сыйфатында танылa. Үз чиратында, тормышындагы бу үзгәрешләр шагыйрь иҗатында да чагылыш тапмыйча калмый: иҗтимагый лирикада матбугат темасы әледән-әле калка тора. Әйтик, аның ««Яшен» журналы хакында» (1908), «Нәрсәдән?» (1908), «Аң» (1912) һ.б. шигырьләре шушы юнәлештә иҗат ителгән. Милләтнең киләчәген мәдәният, сәнгать үсеше белән бер үремтәдә күргән шагыйрьнең матбугатның халыкны караңгылыктан алып чыгарлык көч булуы турындагы фикерләре XX йөз башы татар иҗтимагый-мәдәни идеаллары контекстында укыла: «*Юл табар золмәттә калганнар – төшерсен шәүләсен»,* – дип билгели Тукай ««Яшен» журналы хакында» шигырендә [6: 35]. Гомумән, шагыйрьнең беренче чор әсәрләрендә үк аерылып чыккан һәм иҗатының төп лейтмотивына әйләнгән милләтне үстерү, милли тәрәккъыять, милләт язмышы мәсьәләсе Казан чоры шигъриятендә дә әдипнең иҗади кыйбласын билгеләүче төп күренеш булып тора. Тукай шигырьләрендә урын алган матбугат, театр, сәнгать темалары, шушы әдәби-мәдәни мохит белән алшартланган образлар галереясе милләтнең үсеш юнәлешен, киләчәккә барыр юлын ачыклау-аныклау максатына буйсындырыла. Шагыйрь милләткә хезмәт итү юлына багышланган яшәешнең генә мәгънәле булуын ассызыклый. Милләткә хезмәт итү идеясе милли идеал эзләү омтылышы белән бер үремтәдә килә, «Улмы? – Ул» (1910), «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» (1912), «Шиһап хәзрәт» (1913), кебек шигырьләрдә халык алгарышы юлында хезмәт куйган милли образлар галереясе калка. Шушы бәйләмдә каралган «Даһигә» (1913) шигырендә «мәңге төн» метафорасы белән аныкланган дөньяны яктыртырга теләп, «идеал уты»н эзләп юлга чыккан романтик герой көчле шәхес образының бер модификациясе буларак кабул ителә, даһинең милли хәятне яктырту, алгарыш-тәрәккъыять юлына чыгару омтылышы илаһияткә юл белән тәңгәл куела: *Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул; / Алга барганнарга тик табыла табылса – Алла ул!* [6: 280].

Уралськидагы шигърияте башлыча мәгърифәтчелек традицияләре кысаларында үскән шагыйрьнең Казан чорын иҗатында тәнкыйди дискурсның позициясе ныгый, җәмгыятьтә әһәмиятле булган, халык күңелен борчыган проблемалар белән сугарылган әсәрләр киң урын ала, ул, чорга хас иҗтимагый-сәяси вазгыятьне сурәтләү объекты итеп алып, социаль гаделсезлек проблемасын үзгә бер тирәнлек, кискенлек белән ачып бирә. Әйтик, Тукайның 1911 елда пароход белән Идел буйлап Әстерханга сәяхәте вакытында күргән корылык фаҗигаләре тәэсирендә язылган «Сайфия», «Золым», «Көзге җилләр» кебек шигырьләрдә лирик герой кичерешләрендә халык хәсрәте, халык моңы тоемлана. Шагыйрь тәнкыйтенең тагын бер тармагы яшәеш, чынбарлыкка бәя бирү, җәмгыять, кешелекнең чын йөзен фаш итү максаты белән алшартлана, хакыйкать/ялган, гаделлек/икейөзлелек, әхлак/әхлаксызлык кебек оппозицияләрдән оешкан дөнья сурәте милли

тәрәккыять юлындагы киртәләрне калкытуга буйсындырыла («Күрсәтә», 1909; «Шөһрәт», 1913; «Монафикъка», 1912, «Әхлаксызлык», 1912 һ.б.).

Казан чорында әдипнең сатирик иҗаты яңа баскычка күтәрелә, моңа, һичшиксез, сатирик журналларда – «Яшен» һәм «Ялт-йолт»тагы эшчәнлеге этәргеч була. Шагыйрь иҗатының башлангыч чорында өстенлек иткән искелеккә, схоластикага каршы чыгу, шуңа мөнәсәбәтле кадими фикерле дин әһелләрен, яңалыкка каршы шәхесләрне фаш итү белән бәйле юнәлешкә реакция елларында көн кадагында торган мәсьәләләр килеп өстәлә, холкына хас кискенлек, туры сүзлелек Тукай сатирасын гаҗәеп үткен, үтемле итә. «Ысулы кадимче» (1909), «Бәгъзе зыялыларымыз» (1909), «Тотса мәскәүләр якаң» (1908), «Казан мулласы һәм булачак депутат» (1912), «Авыл мәдрәсәсе» (1912) һ.б. сатирик шигырьләрендә Тукай җәмгыятькә хас кимчелекләрне һөҗү утына тота, чоры өчен әһәмиятле иҗтимагый проблемаларга укучының игътибарын юнәлтә. XX йөз башы милли яшәешен фаш итеп, тәнкыйтькә дучар иткән әсәре – «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) поэмасында сатирик дискурс лиро-эпик калыпта үстерелә. Гомумән, Тукайның сатирасы – иң беренче чиратта, милләт яшәеше белән бәйле проблемалар турында ачынып уйланган шагыйрь гамьнәрен чагылдырган иҗат ул. Галимә Р. Ганиева фикерен кабатлап әйтсәк, «авыр, катлаулы язмышлы халык язмышы, тормышка ашмаган идеаллар белән бәйле хәсрәт катыш көлү – 1907–1910 еллар Тукай иҗатының иң төп үзенчәлекләреннән берсе» [1: 64]. «Көлке түгел» (1912) шигырендә шагыйрь бу хакта үзе дә искәртә: *Көлке булса кайвакыт шигърыятемнең кыйссасы, / Анда бар бер җанлы хәсрәт, канлы ләгънәт кыйссасы* [6: 246].

Шул рәвешле, Тукайның Казан чоры иҗатында милләт темасы, лирик-психологик кичерешләр сәбәбенә әйләнгән төп темаларның берсе булып, шәхси хиссият призмасы аша ачып бирелә, шагыйрьнең лирик герое милләт язмышын уйлап сызланучы, борчулы гамьнәр белән яшәүче шәхес буларак күз алдына килә. Мәсәлән, «Милли моңнар» (1909), «Милләтчеләр» (1908) кебек шигырьләрдә татар халкы язмышы үткән – бүгенге – киләчәк чылбырында карала, лирик геройның психологик кичерешләре милләт белән бәйле гамьнәрдән оеша. Әйтик, беренче әсәрдә милли тарих, халык язмышы сызлану, моңлану хиссиятенең төп сәбәбенә әйләнә, милли тарихның фаҗигале сәхифәләрен ачкан изелү, михнәт чигү, күз яшьләре түгү мотивларын бер бәйләмгә туплап, шагыйрь хис дәрәҗәсен көчәйтә, гомуми эчтәлекне үкенү, ачыну халәте белән тулыландыра. Шигырьгә килеп кергән Болгар һәм Агыйдел хронотоплары автор уйлануларында үткән һәм бүгенгене кисештерә, сызланулы, сыкраулы хиссиятне милли тарихтан хәзергегә кадәр суза.

Гомеренең соңгы көннәренәчә Тукай милләт гаме белән яна, шигырьләрендә милләт язмышына бәйле нечкә моң сызылып бара. Татар халкының тарихы, язмыш белән бәйле тетрәнүле уй-кичерешләр, сагышлы-хәсрәтле гамьнәр, шагыйрьнең вафатына берничә ай кала, Романовлар династиясенең Россиядә патшалык итә башлавының 300 еллыгы уңаеннан язылган «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» (1913) шигырендә дә лирик герой сызлануларының сәбәбенә әйләнә. Шигырьне каймалап алган мәдхия текстлары фонында милли гамьнәр бер үзәккә туплана: татар халкының данлы тарихы (*Рус җирендә без әсәрле, эзле без, / Тарихында бер дә тапсыз көзге без*), михнәт-газаплы бүгенгесе (*Дип: гариб башларга энҗүләр төшәр, / Мәңге михнәт, мәңге рәнҗүләр китәр*) турындагы уйла-

нулар милләтнең бөеклеген раслау, халык хокукын хаклау омтылышы белән үрелеп килә: *Без сугышта юлбарыстан көчлебез, / Без тынычта аттан артык эшлибез. /Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? / Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!* [6: 282]

Казан чорында шагыйрнең иҗат дөньясы романтик аһәңнәр хисабына киңәя, катлаулана. Бер яктан бу процесс милли тематикага язылган әсәрләрдә шәхсиләштерү, психологик кичерешләргә игътибар арту рәвешендә барса (мәсәлән, югарыда каралган «Милли моңнар» шигыре – шуның бер мисалы), романтик һәм сентименталь кичерешләр бәйләме төсендә күзалланган күңел лирикасында исә Тукай туган авыл, туган тел, ана, табигать образларына мөрәҗәгать итә, лирик герой хис-кичерешләре сагыну, юксыну, җирсү чикләрендә тирбәлә. Ретроспектив хатирәләр белән тулыландырылган, эчтәлеге үткәндә калган рәхәт, хөр чакларны сагынудан гыйбарәт «Туган авыл» (1909), «Исемдә» (1909), «Сагыныр вакытлар» (1912) шигырьләрендә кеше гомеренең иң гүзәл бер дәвере – самимилек, гамьсезлек, бәхет көтү белән бәйле балачак еллары, яшүсмерлек чоры – өлкән лирик геройның күңелен еллар үткәч тә җылытып торуы турындагы идея алга чыга. Балачакны идеаллаштыру, үткәннән гармония эзләү омтылышы, күрәсең, Тукайның бу елларда балалар өчен иҗатка зур тырышлык белән тартылуының бер сәбәбе була. Мәгърифәтчел-дидактик юнәлешне алга куйган («Эш», 1909; «Эш беткәч уйнарга ярый», 1909; «Имтияз алган бала», 1910; «Кызыклы шәкерт», 1910), әхлакый-тәрбияви эчтәлектә язылган («Кышкы кич», 1909; «Бәхетле бала», 1909 һ.б.), табигать, тирә-як дөнья белән таныштырган («Кошларга», 1909; «Кошчык», 1909; «Бала белән күбәләк», 1909; «Бичара куян», 1910; «Күгәрчен», 1910 һ.б.) шигырьләрдә шагыйрь, кешене бизәүче рухи кыйммәтләрне калкытып, кечкенә укучысын кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек турында уйландыра.

Мәхәббәт лирикасына нисбәтләнгән «Мәхәббәт» (1908), «Гашыйк» (1909), «Соңра» (1908), «...гә» (1908), «Төш» (1910) һ.б. әсәрләрендә мәхәббәт фәлсәфәсе сөю – кешене яшәтүче, яшәешне мәгънәле итүче көч дигән идея яссылыгында ачыла. Сөйгән ярны тасвирлауда, хис-кичерешләрне ачуда шагыйрь гипербола алымын яратып куллана, шәркый традицияләрдә кулланылган сурәтләү алымнарына, образларга мөрәҗәгать итә.

Милли традицияләр, халыкчанлык Казан чорында да Тукайның иҗат стилен билгеләгән әһәмиятле күренеш булып кала бирә. Мәсәлән, төрле буыннарны берләштергән, татар халкының милли гимнына әйләнгән «Туган тел» (1909) шигырендә көчле позиция алып шигырь исеменә чыгарылган тема шәхеснең үзен һәм дөньяны танып белү омтылышын алшартлый, шагыйрь милли-мәдәни кодларны (нәсел җепләре, бишек, бишек җыры, әкият, дини-әхлакый кыйммәтләр һ.б.) бер бәйләмгә туплый, кешенең милли асылы, тамырлары аның дөньяга карашларын билгеләүче фактор буларак раслана. Шагыйрьнең әдәби офыгы башка милли әдәбиятлар йогынтысы тәэсирендә дә киңәя: аның иҗатында көнчыгыш, рус һәм көнбатыш әдәби традицияләре үзенчәлекле үрелеп китә. Әгәр иҗатының беренче чорында ул әдәби тәрҗемәләр белән мавыкса, Казан чорында инде шагыйрь күбесенчә чыганак тексттан эчтәлек һәм сәнгатьчә эшләнеш ягыннан аерылган, әдипнең үз иҗат йөзе тоемланган әдәби үрнәкләр тудыра («Сәрләүхәсез», 1909; «Теләү бетте», 1909; «Газаптап соң», 1910; «Мәҗлес», 1910; «Җәй көнендә» (1910), «Җәйге таң хатирәсе», 1910 һ.б.).

Казан чорында Тукай әсәрләре фәлсәфи яктан да тирәнәя, нигездә, мотивларда, детальләрдә табылган фәлсәфилек әсәрләрне яшәү мәгънәсе, яшәеш кануннары, вакыт, яшәү һәм үлем кебек төшенчәләр турындагы күзаллау белән тулыландыра. Әйтик, иҗат һәм шагыйрьлек мотивлары үзәктә торган шигъри үрнәкләрдә шәхеснең яшәештәге урыны, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи кыйммәтләр урын ала («Шагыйрь», 1908; «..гә» («Ядкяр»), 1908; «Пәйгамбәр», 1909 һ.б.). Яшәеш-чынбарлыкны танып белү омтылышы дуалистик дөнья сурәтен нигезли: өмет – өметсезлек, караңгыллык – яктылык/нур, фәрештә – иблис һ.б. шундый антонимик каршылыклар лирик геройның яшәешкә бәя-мөнсәбәте белән алшартлана. Мәсәлән, «Өмид» (1908), «Күңел йолдызы» (1909) шигырьләрендә өмет/өметсезлек структурасы нигез итеп алына. Икенче шигырьдә, мәсәлән, яшәеш ямьсезлеген тәкърарлаган лирик герой *(Минем гомрем караңгы төн – кояшым һәм аем тугъмас)* һәр күренештә яктылык күрә, өметен җуймый *(Шуңар да шөкер итәм мин: бу төнем йолдызлы, йолдызлы)*. Яшәешкә «мәлгунь көч», «кара көчләр», «караңгы төн» символик образлары аша бирелгән бәя «якты, һаман нурлы» күңел йолдызы образына салынган эчтәлеккә каршы куела. Шигырьдә кешенең дөньяда үз эзен калдырырлык итеп яшәргә тиешлеге турындагы фәлсәфи фикер дә, һичшиксез, милли яссылыкта укыла: *Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!* [6: 65].

1905–1907 елгы инкыйлаб дулкыннары тынгач, илдә башланган кара реакция елларын, аның милли мәдәният үсешенә китергән зыянын анык татыган, рухи тынычлык таба алмаган Тукай шигырьләренә шәхси җирлекле экзистенциаль мотивлар да үтеп керә. Бу рухи гасабилык шагыйрьнең авыруы белән көчәйтелә. Киләчәккә өмете сүнгән, гомеренең азагына якынлашуын аңлаган әдип иҗатында дөньяны экзистенциаль тоемлау зур урын ала башлый. Төп эчтәлеге төшенкелек, өметсезлек, чарасызлык хисләреннән гыйбарәт «Өзелгән өмет» (1910), «Өмидсезлек» (1910), «Үкенеч» (1910), «Тәләһһеф» (1910) кебек шигырьләр иҗтимагый-сәяси һәм биографик факторлар белән алшартлана, җәмгыятьтәге һәм шагыйрьнең үз тормышындагы авырлыклар эчтәлекне билгели. Әйтик, «Тәләһһеф» шигырендә – җәмгыятьтә хөкем сөргән ялган, икейөзлелек, шуны үзгәртә алмаудан туган психологик халәт әсәрне экзистенциаль укылышка көйләгән хис – хәсрәт сәбәбенә әйләнә. Шушы ачы хакыйкатьне аңлап сызланган лирик геройның күңел газабы риторик шәкелдә җиткерелү яшәеш ямьсезлеге каршында шәхеснең көчсезлеген, җәмгыять кануннарын үзгәртүнең кыенлыгын раслый: *Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк; / Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?!* [6: 154].

Гомеренең азагында инде каты авыруы сәбәпле дөньяга сызлану, газап, хәсрәтле моң күзлегеннән караган шагыйрь әсәрләрендә экзистенциаль мотивлар аеруча киң кулланыла башлый. Мондый әсәрләрдә җәмгыятькә бәя белән шәхси кичерешләр катламы үзара тыгыз үрелеп килә, «лирик геройның күңел дөньясы тагын да катлаулана, газаплы кичерешләре, драматик психологизмы көчәя» [2: 17]. Гомернең ахырына якынлашуын аңлау, үлем көтү, сүнү/бетү кебек мотивлар «Кичке теләк» (1912), «Үтенеч» (1912), «Кыйтга» (1913) кебек шигырьләрне бер бәйләмгә туплый, караңгылык/золмәт төшенчәләре әсәрләрдәге дөнья сурәтенең төп категорияләренә әйләнә.

Нигездә экзистенциаль эчтәлеккә йөз тоткан фәлсәфи яңгырашлы шигырьләрендә шагыйрь традицион образ-детальләрне, мотивларны яңа

яссылыкта ача, әсәрләрен аллюзияләр, интертекстуальлек алымнары, ассоциатив сурәтләү чаралары белән тулыландыра, катлауландыра. Мондый ассоциатив-шартлы күзаллаулар шагыйрь әсәрләренең эмоциональ-психологик эшләнешен баета, лирик кичерешләр дөньясын катлауландыра, XX йөз башы татар әдәбияты өчен традицион символик һәм метафорик образлар системасы (золмәт/караңгылык, кояш/ут/нур, таң, йолдыз, яшен һ.б.) сәнгатьчә үстерелә.

1913 елга кергәндә, Тукайның авыруы инде тәмам көчәя, хәле бик нык авырая. 26 февральдә шагыйрь Клячкин больницасына кереп ятарга мәҗбүр була. Хәле ничек кенә авыр булса да, ул биредә дә иҗат эшен ташламый. Больницада яткан көннәрендә Тукай «Хәстә хәле», «Толстой сүзләре», «Буш вакыт», «Шөһрәт», «Кыйтга (Көчләремне мин... )» һ.б. шигырьләрен иҗат итә, аларның күбесе «Аң» журналында дөнья күрә. Әҗәленә санаулы сәгатьләр калганда да хастаханәгә хәлен белешергә килгән Әхмәтгәрәй Хәсәнидән журналның 8 нче санына бирелгән өч шигыренең корректурасы турында сорашуы да шагыйрьнең иҗаттагы фидакарьлеге турында сөйли.

Гомумән, үз чорында ук инде ул милли шигъриятнең үсеш юлын сызучы бөек талант иясе генә түгел, татар халкының милли-иҗимагый фикерен формалаштыруда әйдәп баручы лидерларыннан берсенә әйләнә. Үзе исәнендә үк халкы данлаган, китаплары басылып чыгуга ук таралып барган (замандашларының: *«Китап чыгаручылар аның әсәрләрен бастыру өчен үзара талашалар иде»*, – дигән сүзләре бу фактны раслый булыр [3: 337]) шагыйрьнең үлеме дә бөтен татар халкы өчен олы тетрәнү була, «Аң» журналында җеназа мәрасименнән бирелгән тулы репортажда бу көн «бөтен татар дөньясы өчен иң кайгылы көн» дип игълан ителә, Тукай вафатыннан соң төрле газета-журналларда басылган мәтам телеграммалары, истәлекләр, шагыйрьне милли идеал югарылыгында сурәтләгән күп сандагы шигырьләр – болар барысы да халыкның шагыйрьгә хөрмәтенең никадәр зурлыгын, аның вафатының милләт өчен нинди зур югалту булуын раслый. «Ваксынмыйм» (1912) шигырендә: *Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим. / Вакътыны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп, / Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып* [6: 237], – дип язган Тукай, чыннан да, инде гасырдан артык вакыт дәвамында татар халкының рухи юлбашчысы, милли идеалы булып кала.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Тукая. – Казань: Изд-во КГУ, 1961. – 84 с.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

3. Латыйпов Г. Тукай турында истәлекләр // Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 337.

4. Миңнуллин Җ.М. Шәрекъ клубы. – Казан: Татар. кит. нәшр., Заман, 2013. – 95 б.

5. Рәмиев И. Хәтеремдә саклангannардан // Тукай турында замандашлары: Истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 138–140.

6. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 384 б.

7. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 415 б.

8. Хәсәни Ә. Тукаев үлем көткәндә // Аң. – 1913. – № 10. – Б. 176–177.

УДК 821.512.145

# КРИТИЧЕСКАЯ ПРОЗА ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ И КОРАН

***Д.М. Абдуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ*

В произведениях Тукая довольно свободно использованы отрывки из Корана и хадисов. В статье анализируются произведения, в которых Тукай вводит читателя в постоянный диалог с кораническим текстом для утверждения идеалов национального прогресса или сатирического обличения моральных и социальных пороков татарского общества начала XX века.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, Коран, татарская поэзия XX века, коранические мотивы, коранические цитаты.

The article analyzes a large number of works in which Tukai introduces the reader to a constant dialogue with the Koranic text to affirm the ideals of national progress or to satirically denounce the moral and social vices of the Tatar society of the early twentieth century.
During the analysis it was revealed that the Qur'anic quotes are constantly present in the poetry and prose, journalism of Gabdulla Tukai. Koranic quotations abound not only religious lyrics of the poet, but also works of secular content.
**Key words:** G. Tukai, Koran, Tatar poetry of the twentieth century, Quranic quotes.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТӘНКЫЙДИ ПРОЗАСЫ ҺӘМ КОРЪӘН

***Д.М. Абдуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ*

XX йөз башы – татар әдәбияты тарихының Шәрекъ һәм Гареб традицияләре кисешкән, бергә аралашкан һәм синтез халәтенә кергән дәвере. Ислам канунары, Коръән белән бик якыннан таныш булган, мәдрәсә белеме алган шагыйьләребез иҗаҗында Коръән, хәдисләрдән алынган өзекләр аның әсәре тукымасында еш очрый гына дип әйтү дә аз булыр. Аның әсәрләре бу яктан гаять дәрәҗәдә бу текстлар белән үрелеп китә. Кайсыларын гарәпчә яңгырашы белән бирә, яки татарча тәрҗемәләрен куллана. Коръән, хәдисләрдән алынган бу текстлар авторның масатына бик уңышлы хезмәт күрсәтәләр һәм әсәр идеясен укучыга җиткерүдә зур эш башкаралар. Мәсәлән, «Әдәбият ахшамы, яки литературно-музыкальный вечер» мәкаләсендә дә ул, Коръән аятьләре һәм хәдисләрне, образ, гыйбарәләрне бик иркен файдаланып, кешеләрне барлык дөнья рәхәтләреннән баш тарттырып, кол хәлендә яшәтергә омтылучы дин әһелләренә җавап бирә. Башта аларның татар милләтенең аңын томаларга тырышуларын, үз максатларына ирешү өчен Коръән, хәдискә дә каршы чыгуларын күрсәтә: «Әвәлдәрәк хатын-кызга язу өйрәтергә ярамый дип, «Taлəбел-гыйлми фәризатен галә көлли мөслимин вә мөслимәтин» («Белем алу һәр мөселманга – иренә дә, хатынына да фарыздыр» хәдисен дә сүгеп маташтылар», ди. Соңыннан ишаннарның Корьәнгә нигезләнеп, дөньялыкта күңел ачу, гыйбадәттән башкадан рухи рәхәтлек алырга омтылу булмаска тиеш дип, төрле кичәләрне, музыканы тыярга теләүләрен Корьәндәге «иннәмәл хәятет дөнья лягабен вә ләһүн вә тәфәхир» иләх аяте кәримәсе (Дөнья тереклеге алдый торган уенчыклардан башка нәрсә түгелдер» //

وَمَا الْحَيَوٰةُ الدُّنْيَآ إِلَّا لَعِبٌ وَلَهْوٌ وَلَلدَّارُ
الْاٰخِرَةُ خَيْرٌ لِّلَّذِيْنَ يَتَّقُوْنَ اَفَلَا تَعْقِلُوْنَ ﴿٣٢﴾

(6 аять, 32 сүрә, алга таба саннар гына күрсәтелә) аша сурәтли. Моның белән ул дин әһелләренең Коръән аятьләрен кирәкле максатлары өчен, теләгән җиреннән әләктереп алып, үзләренә хезмәт итерергә тырышуларын күрсәтә. Алга таба үзе дә шул ук алым белән аларга хәдис кулланып җавабын бирә: «мөкаддимәи хәер хәердер». «Милләтнең тәрәккыйсенә вә башка милләтләрнең аяк астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә сәваплы вә хәерле бер эштер» [4. 226 б.] дип, милләт файдасына булган эшләрнең Аллаһ тарафыннан якланачагына басым ясый. «Зинага чакыра торган музыка хәрам булса да, алга китәргә, тәрәккыйгә чакыра торган музыка мөстәхәб, (*эшләнүе гүзәл эш*) хәтта важиб (*мәҗбүри*) уктыр» [4. 226 б.], ди. Шуңа өстәп, «музыка вә җырлаулар тавышы ишеткәндә: «Ах, Дәҗҗәл чыккан икән инде! – дип «Кяһәф» сүрәсен укып ятмаска тиешбез» [4. 227 б.], ди.

Күрүебезчә, «Әдәбият ахшамы, яки литературно-музыкальный вечер» мәкаләсендә Коръән аятьләре, хәдисләр үзгәртелмичә әсәр тукымасына кертелгәннәр, әле моннан тыш Лут пәйгамбәр, Дәҗҗал, «Кяһәф» сүрәсе кебек образ, гыйбарәләр дә Коръән текстына ишарә булып тора. Мәкаләнең эчтәлеге татар халкын рухи караңгылыктан котылуга чакыру рәвешендә, әмма моңа иске карашлы дин әһелләре теш-тырнаклары белән каршы булып, үзләренең эшләрен Коръән белән дәлилләргә телиләр, Тукай да аларга шул ук алым белән җавап бирә.

«Кызыкка очрау» (1906) мәкаләсендә мулла образы аша, кырын эшләрен яшереп калырга халыктан яклау эзләүче дин әһеле сурәтләнгән. Ул: «хәзер шәһәребездә әллә нинди гәзитчеләр чыгып, һәрбер гаепле кешенең гаебен үзләренең гәзитләрендә яза башладылар», – дип зарлана. Һәм үзенең гаебен йолып калу өчен, гәзитчеләрнең гамәлен Коръәнгә каршы бару дип күрсәтә. Моны раслау өчен мисалга әлеге аятьне китерә: «Аллаһы Тәгалә хәзрәте Коръәндә: «Вә ля тәҗәссесү фәтәһиликү вә ля ягътәбә бәгъзекем бәгъза» (Бер-берегез артыннан шпионлык итмәгез, юкса һәлак булырсыз, бер берегезне шелтәләмәгез 49:12). Сүзен тагын да раслап, гәзитчеләрнең Коръәнгә хилафлыкларын тагын да ныграк күрсәтү өчен, менә Коръәндә: «Йа әйеһәннәбие, къоль ли әзваҗикә вә бәнатикә яминә галәйһиннә мин зәлабиһиннә (И пәйгамбәр, хатыннарыңа әйт: алар кимчелекләрен кисеп ташласыннар (бетерсеннәр) //

يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَٰجِكَ وَبَنَاتِكَ
وَنِسَآءِ ٱلْمُؤْمِنِينَ يُدْنِينَ عَلَيْهِنَّ
مِن جَلَٰبِيبِهِنَّ ۚ ذَٰلِكَ أَدْنَىٰٓ أَن
يُعْرَفْنَ فَلَا يُؤْذَيْنَ ۗ وَكَانَ ٱللَّهُ
غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٥٩﴾

33:59) дигән, «Гәзитчеләр: «хатыннар качмасын» дип әйтәләр, – аларның бу сүзләренә ышаган кешеләр кяфер», ди [4. 234 б.]. Автор бу урында ахунның «зинһар, һичкемнең гаебен гәзиткә яздырмагыз», – дип ялынуыннан, үзен саклау өчен Коръән аятьләренә ябышып аны «шул кадәр сындырып, изүен»нән, гаебен капларга «Коръән пәрдәсе тартуы»ннан көлә. Ахун авызыннан аятьләр әйттереп, аның наданлыгын күрсәтә: «Кәләмулланы бу кадәр ялгыш укыганлыгыннан бу хәзрәтнең «Фәзаилеш шөһүр»дән имтихан биреп кенә имамлыкның рәсүлулла урынына калу икәнлегеннән хәбәре булмаганлыгы кояш шикелле заһир иде» [4. 234 б.], ди.

Ә менә «Җәһаләт вә сәфаләт» (1906) мәкаләсендә Шәригать законын бозып, золым итүче ирдән аерылырга теләгән хатынны аермыйча, акча хисабына аның ирен яклаучыларга каршы чыга. Коръән өйрәтүенчә (2: 229), ир хатынны җәберләп үзендә тотарга хаклы түгел. Тукай шуңа нигезләнеп хатынны яклый. Мулла акчага алданып, Коръәнне бозса да, әлеге хатын аны бозмас, «Вә ля тульку би әйдикүм иля әт-тәһликәти» аяте кәримәсененә әмсаль идәчәк, – ди [4. 276 б.].

«Хәсәнҗан бин Әхмәтҗан әл-Хөсәенинең хиҗаб хакында улан мәзһәбе» (1913) мәкаләсендә дә үзенең фикерләрен «Язмышны сүкмә, чынлыкта язмыш – ул Алланың үзе» һәм «Минем өммәтем(халкым) яңгыр тамчылары кебек бер-берсенә охшаш, кайсы яхшы, кайсы яман икәнен алдан белмисең», дигән хәдисләр ярдәмендә нигезли.

Габдулла Тукай Коръән аятьләрен турыдан-туры сатира тудыру максатыннан да бик теләп файдалана. Әйтик, «Актык сүзләр» (1909) мәкаләсендә төрле сәбәпләр аркасында чыгудан туктаган матбугат органнарын һәм аларның тоткан кыйбласын, кайчандыр бастырып чыгарган мәкаләләрен «чеметеп» үтә. Мәкаләнең исемен үк, «үлгәннәрегезне яхшылык белән телгә алыгыз» дигән хәдис белән шәрехли, ягъни «үлгән» журналларны искә алуына ишарә бирә. «Әддин вәл әдәп» («Дин һәм әдәп – 1906–1910 елларда Казанда имам Г. Баруди редакторлыгы һәм нәширлегендә чыккан дини журнал) журналының басмасы тукталуын белдереп:»Йа әйятеһен-нәфсел мотмәиннәте иржигый иля раббики» («И нык иманлы җан, тәңреңә кайт!» 89: 27, 28.) аятенең мәгънәләрен язды да үзе дә тәңресенә кайтты да китте» [4. 89 б.] ди. Бу, беренчедән, журналның чыгудан туктавына ишарә булса, икенчедән, аның күпчелек басмаларының дини характерда булып, яшәп килгәндә дә гел Коръән аятьләренә, хәдисләренә аңлатма бирүдән артык файда китермәгән бу журналның «үлемен» шулай тасвирлый. «Яшен мәрхүм» мәкаләсендә Галиәсгар Камал тарафыннан чыгарылган юмор-сатира журналының тукталуын сурәтләгәндә шулай ук Коръәннән аятьләре куллана. Монда инде журналның динчеләрне тәнкыйтьләвенә игътибар иттерә: «Мин мөселман булдыгымнан, «Яшен» мәрхүмнең тере заманда динчеләрнең теңкәсенә тиеп, үзәгенә үткәнгә имансыз китүеннән куркып, бичараның янында һаман: «Әшһәде әнлә илаһә» («Аллаһыдан башка Илаһ юклыгына иман китерәм» 2:163, 225; 4:171; 44: 8 һ.б.) кәлимәи мөбәрәкәсен укып тора идем. <…> Тәңере табәрәкә вә тәгаләдән фәрман булды. «Яшен» мәрхүм, вафат булып, үлеп – дөньядан кайтып, дәрелфәнадан дәрелбәкага рихләт әйләде. Иннә лиләһи вә иннә иләйһи раҗигун («Аллаһыдан килгәнбез, Аллаһыга кайтабыз» 89: 28. ) [5. 108 б.].

Әдәби тәнкыйть өлкәсенә караган хемәтләрендә дә Коръәнгә мөрәҗәгать итеп сатира тудырган урыннар еш очрый. Мәсәлән, М. Гафуриның «Замана шигырьләре» («Сөбател гаҗизин» өслүбендә») исемле җыентыгының мәгънә ягыннан зәвекъсыз, иске әдәби үрнәккә иярү икәнлеген күрсәтү максатыннан «Акыллы башлар» мәкаләсендә аятьләр белән аралаштырып төзелгән түбәндәге шигъри юлларны китерә:

«Сәна лил-халикый габра вә әфлакъ»
(«Җирне һәм күкне яраткан Аллага дан һәм мактау» 1: 2; 61:1; 62:1, 2 )
Пич астыннан песи чыкты прахлап.
«Сәмават әвене тотты могалләкъ»,
(Күк йортын тора торган итте» (31: 10)
Песине судка алдылар богаулап [5. 117 б. ].

«Милләткә файда урынына зарар» мәкаләсендә дә мәгънәсез шигырь язучы «Җамид Фигури» әфәндедән көлә. Фикерен шулай ук «Коръән»дәге 4 сүрә 92 аятькә һәм хәдискә нигезли: «Хәдис шәрифтә әйтә: **«Мөселман кеше мөселманнарны теле белән дә, кулы белән дә рәнҗетмәс»**. Ә китапчылар Җәмид Фигуриның теленнән дә, кулыннан да интегеп йөдәп беттеләр. Бу инде милли шагыйрьгә бер дә ярамый», ди.

«Килештерүче» хикәясендә исә тиешсезгә ир белән хатын арасына кысылып, аларны «килештерергә» теләгән Галимҗан: «Китапта күргәнең юкмыни? «Мослихләр, кешеләр арасын татулаштыручылар, зур әҗерле булырлар» дигән», ди. Автор бу урында, юктан гына телгә килеп, инде татуланып беткән ир һәм хатынны кабат сугышу дәрәҗәсенә китергән Галимҗан авызыннан әлеге хәдисне әйттереп, аның мәгънәсезлеген, телдән әйткәне белән кылган гамәленең туры килмәвен мыскыл итә.

«Уральск имамнарына ачык хат» (1906) мәкаләсендә иске карашлы имамнар һөҗүменнән ахун Мотыйгулла Төхфәтулинны яклап чыга. Мәкалә тулысы белән дин һәм динне бозып, үз кесәләрен кайгыртучыларны фаш итүгә корылган. Уральск имамнары, миллионер Хәйрулла Гаделшиннең байлыгына ияреп, «Фикер» газитәсенә һәм аның мөхәрриренә, мөхәррирнең әтисе булган, җәдитчелек яклы ахун Мотыйгулла Төхфәтуллинга каршы чыгалар. Хәйрулла, «духовный собраниегә качып китте, динне сатып кайтачак» дип, ахунны халыкка каршы куярга омтыла. Тукай акча өчен аның үзенең дә ислам кануннарына каршы килгән күп гамәлләрен күрсәтә. Беренчедән, Хәйрулла үзе үлгән агасының хатынына тиешле малны бирдермәскә йөргән (Коръәндә ире үлгән хатынга (үзенә генә, балаларның үз өлеше үзенә санала) малның сигездән берен бирергә куша 4:12). Икенчедән, үзенең гөнаһсыз хатынын аерып җибәреп, балалары белән дә күрешүдән тыйган. «Аналары тәрбиясе алар өстенә фарыздыр. Әй, муллалар, сез ничөн: «Аналарын карасыннар, тәрбия итсеннәр, чөнки оҗмах аналар аяк астында табыла, дип пәйгамбәребез әйткән сүзне ничөн укып әмре мәгъруф итмисез?» дип, Тукай бу урында имамнар алдына шундый сорау куя: «Сез кемне яклыйсыз, диннеме, әллә акчалы Хәйрулланымы?» Һәм аларга киңәш итеп, теләсә кем сүзенә ияреп, кеше өстенә пычрак атып йөрмәскә, Коръән кушканча эш йөртергә куша: «Шәригатемез – Коръән хәдистер, Коръән хәдис тә кыямәт барачак, анда бер дә шик-шөһбә юктыр», ди.

Күргәнебезчә, Тукай әсәрләрендә Коръән һәм хәдисләрдән алынган өзекләр шактый иркен файдаланылган. Шагыйрь аларны күпчелек үзе үк «Коръәндә әйтелгәнчә», «аятьтә күрсәтелгәнчә», «аять кәримәсеннән могътәбәс» яки «пәйгамбәребез әйткәнчә» кебек сүзләр белән раслап, искәртеп бара, яки бернинди искәрмәләрсез генә куштырнаклар эченә урнаштыра.

ӘДӘБИЯТ


1. Священный Коран. Перевод смыслов и комментарий Мухаммада Маулана Али. – Ахмадийа Анджуман Ишаат Ислам, Лахор ИНК. – США, 1997. – 1312 с.

2. Тукай Г. Әсәрләр. Г. Халит редакциясендә. 5 томда. Т. 1.: Шигырьләр. Поэмалар (1901–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.

3. Тукай Г. Әсәрләр. Г. Халит редакциясендә. 5 томда. Т. 2: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 400 б.

4. Тукай Г. Әсәрләр. Г. Халит редакциясендә. 5 томда. Т. 3: Проза. Публицистика (1904–1906). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 389 б.

5. Тукай Г. Әсәрләр. Г. Халит редакциясендә. 5 томда. Т. 4: Мәкаләләр, хикәяләр, фельетоннар. (1907 – 1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 350 б.

УДК 82.091

# ОЗНАКОМЛЕНИЕ С ТВОРЧЕСТВОМ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ НА ВЕЧЕРНИХ КУРСАХ

***С.Х. Айдарова, В.М. Гарипова-Хасаншина, Г.Г. Батыршина***
*Российский исламский институт (Казань)*

Татарский язык и Габдулла Тукай не отделяются друг от друга. Кто знает татарский язык, знает и Г. Тукая. Авторы статьи большое внимание уделяют ознакомлению с творчеством поэта и на вечерних курсах. В данной статье авторы делятся формами и приемами работы по данной теме.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарский язык, вечерние курсы, формы и приёмы работы.

The Tatar language and Gabdulla Tukai are not separated from each other. Who knows the Tatar language, knows and G.Tukai. The authors of the article pay great attention to getting acquainted with the work of the poet and at evening courses. In this article, the authors share the forms and techniques of work on this topic.
**Key words:** Gabdulla Tukai, Tatar language, evening courses, forms and methods of work.

Стало традицией обучение татарскому языку на вечерних курсах «Без – татарлар» населения города Казани. Наряду с изучением основ ислама, истории татарского народа, арабского языка слушатели изъявляют желание изучать и татарский язык.

По уровню владения татарским языком обучающиеся делятся на начинающих и продолжающих. В начинающую группу записываются русскоязычные татары, которые по разным причинам не смогли изучить свой родной язык на уровне общения. В эту же группу записаны люди разных национальностей, приехавшие в столицу Татарстана из разных регионов Российской Федерации, которые совершенно не владеют татарским языком. Таким образом, в начинающей группе оказываются две подгруппы по уровню владения татарским языком. Русскоязычные татары в основном понимают татарскую речь, но не владеют родным языком на уровне общения. Их цель посещения уроков – научиться общаться на родном языке. Цель второй подгруппы – научиться понимать татарскую речь и владеть ею на уровне общения [1].

В группе продолжающих занимаются люди, владеющие родным языком на бытовом уровне. Их цель – изучить литературный татарский язык, чтобы уметь общаться на более высоком уровне. Продолжающие занимаются по специальному учебному пособию [2; 3], где авторы вместе с фонетическим, лексическим, грамматическим материалом, текстами и упражнениями включают и социокультурный материал, который дает сведения о Республике Татарстан, национальных особенностях татарской культуры, о религии Ислам, мусульманах, достопримечательностях, музеях, праздниках, природе, деятелях литературы и искусства, этикете и др.

Татарский язык и Габдулла Тукай не отделяются друг от друга. Кто знает татарский, знает и Г. Тукая. Авторы статьи большое внимание уделяют ознакомлению с творчеством поэта и на вечерних курсах. Занятия, посвященные жизни и творчеству великого Тукая начинаются задолго до дня рождения поэта – до 26 апреля. В данной статье авторы делятся формами и

приемами работы, в рамках названной темы. Представим нашу работу поэтапно в группе для продолжающих:

1) преподаватель готовит презентацию на татарском языке по биографии и творчеству Габдуллы Тукая. Здесь особо отмечается труднейшее детство Тукая. Поэтапно идёт знакомство с рождения будущего поэта до его совершеннолетия, как места жительства маленького Апуша менялись через каждый малый промежуток времени из-за смерти или болезни близких, родных ему людей, как после чёрной полосы жизни маленького ребёнка появлялось незначительное просветление, а потом снова потеря дорогих ему людей, как эти жизненные обстоятельства повлияли на его состояние здоровья и.т.д. На этом же занятии преподаватель знакомит с автобиографической повестью Г. Тукая «Исемдә калганнар» («Мои воспоминания»). Читается небольшой отрывок из этого произведения: «...Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып тәрке дөнья итмештер. Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә, бераздан өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканча көтеп торам икән»... («...Через пять месяцев после моего рождения папа мой умер после недолгой болезни. Моя мама прожила со мной недолго, она отдала меня на воспитание бабушке по имени Шарифа, сама вышла замуж и уехала в деревню Сасна. В то время родители моего папы (бабушка и дедушка) были уже на том свете, родственников у меня не осталось. Поэтому для этой бабушки я был обузой, она меня не воспитывала. Я сам не помню это время. Мне тогда было 2–3,5 года. По рассказам деревенских женщин я ходил в холодные зимние дни в одной рубашке, босой, не мог открыть тяжелую входную дверь и примерзал голыми ногами к порогу. Бабка говорила: не сдохнешь, подкидыш, и нехотя впускала в дом…»);

2) в процессе презентации обучающиеся записывают план по биографии и творчеству поэта;

3) преподавателем предлагается домашнее задание «подготовить небольшой монологический рассказ про поэта»;

4) глубоко впечатляющую биографию поэта без предварительной подготовки сложно рассказывать, поэтому преподаватель задаёт соответствующие вопросы, вместе составляются предложения;

5) при составлении рассказа параллельно идет процесс ознакомления с новой лексикой. Надо отметить, что характеризующая человеческие качества лексика запоминается попарно с антонимами. При описании окружающих маленького Апуша людей, встречаются и положительные и отрицательные герои. Если для описания Шарифы карчык (старухи Шарифы), о которой было написано выше в отрывке, мы используем прилагательные «явыз» (вредная), «саран» (жадная), «икейөзле» (двуличная), «усал» (злая), то Сагди абзый, который взял Габдуллу на воспитание, характеризуется антонимами этих прилагательных, как «ягымлы» (добрый), «юмарт» (щедрый), «күңелле» (весёлый) и т.д.;

6) в конце этого занятия обучающиеся читают вслух составленный ими рассказ, который на следующем занятии рассказывается;

7) параллельно с лексической темой изучается и грамматическая. Во-первых, несмотря на то, что о Тукае рассказываем в прошедшем

времени, используется форма настоящего времени. В татарском языке это возможно. Например: (*туа* (рождается), *яши* (живёт), *алып китәләр* (увозят), *күрә* (видит), *укый башлый* (начинает учиться), *карый* (смотрит) и др.);

8) проходим сложноподчиненное предложение времени с аффиксами *-ганда/-гәндә, -канда/-кәндә.* Например, Тукай кечкенә бул*ганда*, ... (*Когда* Тукай был маленьким ...), Кырлайга кит*кәндә...*» (*Когда* уезжал в Кырлай ...), Казанда яш*әгәндә... (Когда* жил в Казани) и т.д.;

9) уральский период жизни изучается отдельным уроком. Здесь Тукай обучается в русской школе, знакомится с творчеством А.С. Пушкина, М.Ю. Лермонтова и др., появляются его первые стихи, начинается трудовая деятельность в типографиях... Данный этап работы предлагается для самостоятельного изучения материала обучающимися. По аналогии с ознакомлением начального периода биографии Г. Тукая, преподаватель предлагает обучающимся самим находить материалы по уральскому и казанскому периоду жизни и творчества. Обучающиеся должны стараться находить интересные материалы, составить презентацию и, используя свои слайды, рассказывать о Тукае. Это своего рода проектная деятельность в изучении языка. Обучающийся становится соучастником учебного процесса, поиска материалов и презентует свою работу. На данном этапе на задний план «уходят» сомнения по своему уровню владения языком, стеснительность, исчезает «языковой барьер»;

10) специальный урок посвящается творчеству поэта, где читаются стихи и поэмы Г. Тукая. В начинающей группе преподаватель на татарском языке читает и переводит стихи для детей, которые доступны для начинающих. Это такие стихи, как «Бала белән күбәләк», «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Акбай», «Су анасы» и другие. Обязательно используется книга «Шүрәле» («Шурале»), где представлена эта поэма на 15-ти языках мира. Так как начинающая группа многонациональная, очень часто представители разных национальностей читают в этот день про Шурале на своем родном языке перед аудиторией. Обычно это переводы на русский, узбекский, таджикский, казахский, башкирский языки. В продолжающей группе помимо оригинального татарского текста читаются переводы на английский, немецкий, персидский, французский, турецкий, арабский языки. Эта форма работы помогает узнать о Тукае еще больше, доказывает то, что Г. Тукай и его произведения известны всему миру. Огромную заслугу имеют составители данной книги. Она оформлена как подарочный экземпляр, обложка украшена татарским национальным орнаментом, каждый перевод оформлен произведениями наших художников, которые каждый по своему «видят» Шурале и изображают это мифическое существо [4].

Современный учебный процесс требует от учителя тщательной подготовки, профессионального мастерства, эрудиции. Одно из главных условий эффективности учебной деятельности – атмосфера доброжелательности, взаимопонимания, доверия, творчества, поощрения познавательной активности обучающихся.

Таким образом, обучаемый, по мере все более активного, глубокого и всестороннего участия в процессе учебной деятельности по усвоению языка, превращается из пассивного объекта воздействия учителя в полноправного соучастника учебного процесса. Педагогическая актуальность, формируемая в информационно-обучающей среде системы языковых знаний и

умений состоит в том, что обучаемому должна быть предложена для усвоения именно такая система знаний, которая ему необходима на данном этапе своего развития.

ЛИТЕРАТУРА

1. Айдарова С.Х., Гарипова-Хәсәншина В.М. Татар теле: башлап өйрәнүчеләр өчен. – Яр Чаллы: Ислам нуры, 2016. – 151 б.

2. Гарипова-Хәсәншина В.М., Гимазова Р.А. Татар теле: башлап өйрәнүчеләр өчен. – Казан: Хозур, 2018. – 192 б.

3. Гарипова-Хәсәншина В.М., Гимазова Р.А. Татар теле: башлап өйрәнүчеләр өчен. – Казан: «Хозур» –»Тынычлык» нәшрият йорты, 2020. – 224 б.

4. Тукай Г.М. Шурале: сказка-поэма: на 15 языках / Габдулла Тукай; сост.: Ф. Ахметова-Урманче, Р. Корбан. – 2-ое изд. – Казань: Татар. кн. изд., 2011. – 100 с.

УДК 070:82.992(470)

## ПОЕЗДКА ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ В УФУ

***А.Х. Алеева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В результате изучения жизненного пути и творческого наследия великого поэта татарского народа Г. Тукая выявляются все новые источники и факты связанные с его биографией. В данной статье рассматривается визит в 1912 году Г. Тукая в город Уфа, во время его поездки в Троицк, для лечения. Свои впечатления и путевые приключения поэт описывает в очерке под названием «Мәкаләи махсуса» («Специальный репортаж»), которую сам называет «Путевые заметки». В рамках статьи расскрыты важные наблюдения поэта за умеренной социальной жизнью города, литературно-культурной обстановкой Уфы в начале XX века. Поэта поражает ланшафт и городостроение, а также окружающая город природа. Кроме этого, освещается, наблюдения и проблемы интересующие поэта, на основе воспоминаний современников Тукая, с которыми поэт встречался и беседовал. К ним относятся: поэт М. Гафури, педагоги и работники печати Х. Забири, Г. Баттал, М. Амиров, певец и музыкант А. Даутов и другие. В воспоминаниях каждый автор дополняют биографию поэта отдельными деталями и фактами. В итоге, в статье сделана попытка систематизации событий биографических данных поэта, с учетом новых фактов и источников.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, г. Уфа, путевые заметки, литературно-культурная жизнь, воспоминания современников Тукая.

As a result of studying the life path and creative heritage of the great poet of the Tatar people G. Tukay, new sources and facts related to his biography are revealed. This article examines the visit in 1912 by G. Tukai to the city of Ufa, during his trip to Troitsk, for treatment. The poet describes his impressions and travel adventures in an essay called «Məkaləi Makhsusa» («Special Report»), which he himself calls «Travel Notes». The article reveals the poet's important observations of the moderate social life of the city, the literary and cultural situation in Ufa at the beginning of the 20th century. The poet is amazed by the terrain and urban development, as well as the nature surrounding the city. In addition, it highlights the observations and problems of the poet, based on the memoirs of Tukay's contemporaries, with whom the poet met and talked. These include: poet M. Gafuri, teachers and press workers H. Zabiri, G. Battal, M. Amirov, singer and musician A. Dautov and others. In the memoirs, each author supplements the poet's biography with individual details and facts. As a result, the article attempts to systematize the events of the poet's biographical data, taking into account new facts and sources.
**Key words:** G. Tukai, Ufa, travel notes, literary and cultural life, memoirs of Tukai's contemporaries.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ УФАГА СӘФӘРЕ

***Ә.Х. Алеева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ (Казан)*

Г. Тукайның географик яктан киң территорияне иңләгән маршрутлы Казаннан пароход белән Самарага, поездда Уфага, аннан Петербургка, поезд белән Мәскәү аша янә Уфага, аннан Чиләбе аркылы Троицкига баруы, казакъ даласындагы җәйләүдә ял итүе һәм вакыт ягыннан 3 айдан да артыкка сузылган сәфәре «Мәкаләи махсуса» [7] исемле юлъязмасында сурәтләнә. Билгеле булганча, сәламәтлеге шактый какшаган, авыруы көчәйгән шагыйрьне дуслары Казаннан китеп, һавасы әйбәт җиргә барып дәваланырга өндиләр һәм күндерәләр дә. Габдулла Гыйсмәти (1883–1939) Кырымга барырга үгетли, әмма Тукай, Троицк мулласы Габдрахман Рахманкулов (1879–1937) чакыруын кабул итеп, җәй буе казакъ даласында кымыз белән дәвалануны күздә тотып Троицкига барырга, бераз сәламәтләнгәч, көз көнендә Петербургка барып докторга күренергә ниятләп 1912 елның 14 апрелендә «Фултон» пароходына утырып юлга чыга [6]. Шагыйрьне Казаннан дуслары Әхмәт Урманчиев (1187–1937) белән Шиһаб Әхмәрев (1182–1966) озатып җибәрәләр [5: 37].

15 апрельдә кичен пароход Самарага килеп җитә. «...икенче көндә бугай, төнгә табарак Самарага җиттем», – дип яза Тукай үзе «Мәкаләи махсуса» әсәрендә [7: 49]. Биредә ул шәһәрнең иң шәп «Бристоль» дигән кунакханәсенә туктый. Шул көнне үк Самараның мулласы, «Икътисад» журналы мөхәррире һәм нашире Фатыйх Мортазин (1875–1937) белән очрашып, озаклап сөйләшеп утыралар. 16 апрель сәяхәтен дәвам итеп, Самарадан поездга утырып Уфага юнәлә.

Поезд Уфага 17 апрельдә иртәнге якта килеп төшә. Шагыйрьнең Уфада беренче генә мәртәбә булуы. Сәяхәтнамәсендә иң элек анда күргәннәрен, тәэсиратләрен яза. Шулардан жанрның үзенчәлеген дә тәшкил итә торган ике нәрсә игътибарга лаек: беренчесе – юда күргән табигать күренешләрен, ланшафтны сурәтләү. Икенчесе – сәяхәт вакытында очрашып сөйләшкән кешеләр, күреп яки ишетеп белгән вакыйгаларны бәян итү. Мәсәлән Уфа шәһәренең тасвиры. Тукай аны менә ничек күрә: «Уфага җиттем. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самарныкы түгел. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-кырлы сикерә иде. Таудан әкренләп менәсең. Җулның әтрафында җәһәннәм кеби тирән чокырлар хисабы юк...

Уфага кергәндә бер дә шәһәргә кергән кебек булмый. Әллә нинди ачык-тишек вә рәтсез һәм пустынный урамнар белән барасың. Эч поша. «Кая соң моның шәһәрлеге?», – дип сукранганда, көчкә беркадәр яхшырак урамнарга кердек.» [7: 52].

«Уфаның мәгъмурият (төзеклек) ягы Казаннан күп начар», – дип шагыйрь үзе яраткан, туган җире дип санаган Казан шәһәрен Уфадан өстен куя (үзеңнеке һәрвакыт күңелгә якын бит). Әмма шагыйрь гаделлек яклы: «Уфаның табигать ягы күп шәһәрдән өстен, әүвәл үк ул тау башында, димәк җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларыбызда шул кадәр күп җырланган Агыйдел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек, – дип объектив фактларны саный. – Өстән караштa Уфаның халкы да

айнык вә саф күренә», – дип, моның сәбәбен пивнойларның сирәк булып чат саен сөт кибетләре очрап торудан күрә [7: 54].

XX йөз башында Уфа, Казан, Оренбург, Троицк, Әстерхан шәһәрләре кебек үк, татарларның иҗтимагый тормышында мөһим булган милли, дини һәм мәдәни үзәкләрнең берсе була. Монда Диния нәзарәте, 1887 елдан «Госмания» мәдрәсәсе эшләп килә. 1906 елда «Галия» мәдрәсәсе ачыла. Бу яңа типтагы уку йорты татар, башкорт, казах һ.б. төрки халыклар яшьләре өчен мәгърифәт үзәгенә әйләнә. «Сабах» көтепханәсе, «Шәрекъ» матбагасы, 1912 елда «Нур» татар театры оеша.

«Галия»нең беренче уку елларында ук шәкертләрдән төрле түгәрәкләр оеша. Шундыйлардан иң зурысы һәм актив эшләгәне «Милли көй, сәхнә һәм әдәбият түгәрәге» эшли. Бу түгәрәк әгъзалары җәен халык иҗаты үрнәкләре җыю белән шөгыльләнгәннәр. 1910 елда, мәсәлән, алар үзләре җыйган әсәрләрне туплап, берничә җыентык та бастырып чыгаралар. Айга ике тапкыр шәкертләрнең кульязма журналы да чыгып килә. Татар мәдәнияте һәм әдәбиятына яңа көчләр, яшь буын килә. Алар Тукай иҗаты белән рухланып, Тукай традициясен дәвам итеп, иҗат итәләр. Нәкъ шул чорда Уфада «Галия» мәдрәсәсе шәкерте, әле 16 яштә генә булган Шәехзадә Бабич 1911 елда ук Г. Тукайга багышлап «Габдулла әфәнде Тукаев» дигән шигырен яза:

> Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай,
> Ул караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай.
> Алса, укыса халык шигырен аның – истә кала.
> Һәм аның шигыре халыкның күңеленә зур хис сала.
> Билгеле, безнең мабиһел – ифтихар (*горурлыгыбыз*) ул, мөхтәрәм,
> Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә дип шатланам.

Үзен шулай мәшһүр шагыйрь, халыкның горурлыгы, мактанычы дип таныган шәһәргә – Уфага килеп җиткәч, Тукай «Сабах» көтепханәсендә туктала. Биредә аның күптәнге танышы Хәбибрахман Зәбири (1881–1942) эшли. Зәбиринең 1906 елда «Әлгасрел-җәдит» журналында хикәяләре, сәхнә әсәрләре һәм дистәгә якын юмористик мәзәкләре басыла. Тукай шул вакыттан ук аның иҗаты белән таныш була. Казанда да иҗади аралашулары дәвам итә, еш очрашалар. «Сабах» көтепханәсе дә Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсе астында гына урнашкан була. «Сабах» ширкәтендә эшләүчеләрне, бигрәк тә Х. Зәбири һәм Шиһаб Әхмәровны, ул аеруча үз итә.

Тукайның Уфага килүе вакыйгасын Х. Зәбири болай тасвирлый: «1912 ел яз иртә килде. Апрель башыннан ук костюм белән йөрерлек иде. Апрельнең ничәнче көне булганын хәтерләмим, бик матур бер көнне иртә белән сәгать 10 нарда “Сабах” ширкәтенең Уфадагы магазины алнына беренче дәрәҗә җиңел извозчик килеп туктагач, мин, тәрәзәдән күреп, Тукайны танып алып шаккаттым. Әле ул экипаждан да төшеп өлгермәгән иде, мин атылып чыгып өлгердем. Бер яктан күрешәбез. Икенче яктан мин: “Нигә телеграм бирмәделәр”, – дип сөйли башлагач: “Мине Шиһаб озатканда: Уфа зур түгел, вокзалдан чыгып извозчикка “Сабах” дип әйтсәң, шул җитә. Синең поездың Уфага иртә белән барып керәчәк, дип сөйләде”, – ди. Нәкъ шул вакытта Хөсәен Булгаков дигән кеше үтеп бара иде. Аның йорты Мәҗит Гафури белән бер урамда

булганлыктан мин: “Хөсәен абзый, Гафурига әйт әле Тукай килгәнлеген”, – үтендем.

Тукайда юл мәшәкъкате белән арыганлык, рух төшенкелеге хис ителми. Ашыгып-ашыгып бер-беребезгә сөальләр биреп, бер-берсенә бәйләнешсез сүздән туктый алмыйбыз, һаман сөйләшә бирәбез. Ахырында: “Йә, Тукай, кайда, сиңа нумир алыйкмы, әллә берәр гаиләгә урнаштырыйкмы?” – дигән сөальгә каршы: “Син бит әле өйләнмәгәнсең, Казанда миңа әйттеләр: Зәбири үзе магазин артында тора, шунда бергә оешырсыз”, – дигән җавабын ишеткәч: “Менә минем бүлмәм: көндез кантур була, кич белән минем йокы бүлмәм. Язу өстәлен бер читкә тартам да үземнең күчмә койкамны куеп, шунда йоклыйм”, – дидем. Ул моңа каршы: “Бу инде бик яхшы, шунда без бергә торырбыз”, – дип, башка бер урынга барырга теләмәгәнен аңлатты. Һәм без шул рәвешчә тора башладык. Үзем ни хәлдә булсам, Тукай да нәкъ бер үлчәүдә иде һәм ул моннан риза булып иң рәхәт моментларын үткәреп китте. Мине шул шатландыра.

Тукай 150 сум акчасыны миңа сакларга биреп куйды. “Минем әле вактөяк расхутка тагын акчам бар”, – дип, байлыгын да сөйләп алды.

Кесәсеннән чыгарып, Муса Бигиевтән (1873/75–1949) килгән хатны укырга бирде. Бигиев, иптәшләре Галим Максудов, Лотфый Исхаковлар исеме белән, аны Петербургка кунакка чакырып язган иде. “Әйдә, әле башта Уфада кунак бул, бу турыда соңрак уйлашырбыз”, – дидем.

Уфада минем белеш-танышларымнан кайберләре безне кунакка чакырсалар да, Тукай һичбер йиргә барырга теләмәгәнлеген аңлатты.

Мәҗит Гафури һәр көнне килә. Ике шагыйрь рәхәтләнеп көн үткәрәләр...» [4: 268–270].

Әлбәттә Мәҗит Гафури Тукайның Уфага килүен ишеткәч тә «Сабах»ка килеп җитә. Моңарчы әле аларның шәхсән очрашканнары булмый. Танышлыклары язылган әсәрләре аркылы гына һәм Тукайның Гафури әсәрләренә үткен тәнкыйть рецензиясе дә язганын[1] уйласак, бу очрашу икесен дә дулкынландырмый калмагандыр. Г. Тукай бу очрашуны түбәндәгечә тасвирлый: «Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез (*әңгәмәбез*) күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше икемез әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кайнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек – әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек – әле күздән яшемез дә кипкән...» [7: 55]

---

[1] «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 13нче (15 сентябрь) санында Тукайның «Милләткә файда урынына зарар» исемле фельетон характерындагы рецензиясе басыла. Анда ул М. Гафуриның 1910 елда Уфа шәһәрендә «Шәрекъ» матбагасында «Кызларга махсус милли шигырьләр» дигән һәм «Милли шигырьләр» исемле Казанда һәм Уфада «Шәрекъ», «Сабах», «Борадәран Кәримовлар матбагалары» тарафыннан алты басмада чыгарылган җыентыкларын анализлап, аларның талымсыз булуын, арзанлы такмаклардан торуын тәнкыйть итә. «...хәтта тавыкларга махсус «милли шигырьләр» дә язып ыргытыр» әле дип ачы көлә. Шундый типтагы китапларны бастырып чыгарган матбагачылар адресына авыр сүзләр әйтә. Мондый җыентыкларның булуыннан бигрәк булмавы яхшы дигән фикер уздыра. Авторның исемен исә, сүз уйнатып, «Җамид Фигури» дип атый.

Үз адресына мондый тәнкыйть мәкаләләре уку М. Гафури өчен «майлы ботка» булмагандыр. Әмма ул боларны шәхси дошманлык яссылыгына күчерми.

Ул көрешү хакында М. Гафури үзе болай ди: «...Тукай гаилә тормышын артык сөймәгәнгә, аны гаилә эченә алып барырга теләү бушка китәчәк булганга, ул якны әйтеп тормадым.

Без, язгы кояш астында бераз йөреп, берәр җиргә кереп утырырга карар бирдек. Без бүген матуррак бер җиргә керергә муаффәкъ булдык (*кереп утыра алдык*). Кояшка каршы булган бу залны Тукай үзе дә яратты.

Без инде монда бик иркенләп утырмакчы булдык. Эшләр, Тукай теләгән рәвештә, бик шәп китте.

Бик кәефле утырган вакытта, Тукай бизгәк тоткан кебек калтырана башлады. Аның шундый вакытта йота торган порошогы "Сабах"та калганга күрә, даруны җибәртеп алдырырга туры килде. Шул даруны эчкәннән соң, Тукайның калтыравы басылып, бераз кәефе төзәлде.

Баштарак Тукай да, мин дә, сүз таба алмаган кебек, бер-беребезнең күзебезгә карашып, тик утыра идек. Бара торгач, безнең мәҗлес бик күңелле булып китте. Күбрәк сүзләребез шигырь вә шагыйрьләр, Казан һәм дә мохитебез хакында иде. Тукай Казандагы тормышыннан ялыкканлыгын, шул сәбәпле, кымызга иртәрәк булса да, Казаннан китәргә ашыкканын сөйләде.

Тукай хәссас (*сизгер*) күңеленнән чыккан бик гади генә сүзләре, аның бу дөньядан һәм дә үзенең мохитеннән разый булмавы миңа яхшы ук зур тәэсир бирде. Бу вакытта безнең икебезнең дә күзләребездә ихтыярсыз атылып чыккан күз яшьләре ялтырый иде...» [3: 136–137].

Тукай Уфага беренче мәртәбә аяк басуында ук ике шагыйрь бик тиз уртак тел табалар, уй-фикерләренең бер юнәлештә булуын аңлыйлар.

Мәҗит Гафуриның иҗатын Тукай һәрвакыт кызыксынып, яратып күзәтә. Аңа теләктәшлек белән карый. Бу турыда иптәшләре белән сөйләшкәндә дә телгә ала торган була. Каюм Мостакаев (1885–1974) истәлегендә дә очратабыз: «...Тукай Мәҗитне сүз уңае чыккан саен хөрмәт белән телгә ала, аны башлап татарча беренче буларак шигырьләр яза башлаган өлкән шагыйрь булганлыгы өчен генә түгел, һәр икәвесенең арасында идея уртаклыгы һәм дә шул юлда бөтен каршылыкларга күкрәк киереп туктаусыз алга баруында дәвам иткәнлеге өчен дә, Тукай Мәҗитне күңеленә якын күреп хөрмәт итә иде...» [8: 122–127].

Ике-өч көн бик тиз узып китә. Габдулла күптән күрәсе килгән Мәҗит Гафури белән очрашып таныша, озак-озак утырып сөйләшеп, шактый фикер алышалар. Гафури аны аз булса да Уфа шәһәре белән дә таныштыра. Тукайга ул артык тыныч шәһәр булып тоела. Мәдәният учаклары да шушы «Сабах» көтепханәсе дә «Шәрекъ» матбагасы. Бер генә газета, бер генә журнал да чыкмый икән.

Әмма шагыйрь озаклап шәһәрне карап, танышып йөри алмаса да күп нәрсә аның игътибарын җәлеп иткән: Уфада трамвайларның юклыгы, шәһәр бакчасында «Йолдыз» исемле кинемотографның эшләп килүе, һәм, әлбәттә, андагы кешеләрнең үзенчәлекле якларын, бигрәк тә, тышкы кыяфәте белән масаеп йөргән, әмма рухый яктан буш, күңеле ярлы шәхесләрне «фаш итү», «кәмит» оештыру, гомумән, аның иҗатына хас сыйфат, юлъязмасында да чагыла.

«...шәһәр бакчасында, өстенә җөббә, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка "батинкә", авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп

барган бер мәгърур шәкертне туктатып, җүри, “вәкар вә мәһәбәтен” бозар өчен: “Син курай уйный беләсеңме?” – дип сорыйсым килде дип, тасвирлауны көлкеле нотада дәвам иттерә дә аннары җитди итеп:

“Мин үзем гомумән шундый “кәмитле” мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек, аның “вәкар”ен бозарга кирәк», – дип яза [7: 56].

Шагыйрьнең җитди авыруы аңа Уфаның эче һәм әтрафлары белән озаклап карап, танышып йөрергә комачаулый.

Дөрес, Тукай кымыз эчеп дәвалану өчен Казаннан ук Троицкига барырга карар биреп чыккан. Әмма анда да әле кымыз сезоны җитмәгәнлеге билгеле була. Фикер алышканнан соң Троицкига хәзердән үк китү иртәрәк дип табыла.

Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм. Җитмәсә аның «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем әле хасил булмактагы европалылыгымны, культурный шәһәр кешеселегемне үчекләгән кеби булды. Китәм Петербургка! Кымызга кадәр торам», – дигән уйлар белән Тукай карарын бераз үзгәртеп, Уфадан поезд белән Петербургка барып килергә уйлый. Петербургка сәяхатендә өч атналар чамасы йөреп, майның 9–10 нарында Тукай яңадан Уфага әйләнеп кайта. Бу сәфәрдән ул гаять йончып кайта. Бу вакытта инде Уфа яшеллеккә күмелгән, агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән була. Чалт аяз. Җылы. Һава саф. Һәр җирдә агач исе, чәчәк исе. «Уфага кайтсам, Уфа мине кияү көткән кыз кебек көтеп торган. Әтраф киенгән. Ямь-яшел. Кояш көлә. Яз җиткән, яз!» [7: 62]

М. Гафури да бу хакта яза: «Тукайның Уфага икенче мәртәбә килүенә бакчаларда агачлар яфрак ярган, җир өсте ямь-яшел үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән иде. Бик матур кояшлы көндә шәһәр бакчасына чыктык. Анда кымыз эчкәннән соң, агачлар арасындагы ачык җиргә яшел үлән өстенә барып яттык.

Кымыз эчеп, саф һавада яту Тукайның сәламәтлеген кайтарган кебек булды. Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын бик яратты. Шуның өчен, Уфада торганда, аз гына кояшлы вакыт булса, бакчага чыга, кымыз эчеп, яшел үлән өстендә ята иде. Бакчада яшел үлән өстендә йоклап киткән вакытлары да булды» [3: 138].

Уфага кайткач та 11 майда Казанга Әхмәт Урманчиевкә хат яза. Анда ул үзенең Уфадан Петербургка барып кайтуын хәбәр итә. Петербургның һава шартлары начар тәэсир итүеннән канәгатьсезлеген белдерә.

Уфада гына торган булсам, хат түгел, мәкаләләр да язган булыр идем, ди ... «Ялт-йолт»ның үзе Казаннан киткәч чыккан 37, 38 саннары хакында фикерләре белән уртаклаша, журналның сыйфатын яхшырту хакында киңәшләрен бирә. Басма сүзгә, әдәби телгә карата таләпчәнлеген, матбугат этикасына мөнәсәбәтен белдерә.

Тиздән Троицкига китәсен хәбәр итеп, Габдрахман Рахманкулов адресын күрсәтә: «Хатларны анда җибәрерсең ... минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне да җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем «Жан азыклары» дигән почти шул маҗмугалык шигырьләрем бар», – дип үтенечен белдерә [9: 115–116].

12 нче майда Уфадан Петербургка дусты Кәбир Бәкергә (1185–1945) хат яза. Петербургтан Уфага кайту унайлы җайлы булды, дип хәбәр итә.

Үзенең хәлен сөйләп, Уфада докторга күренеп канын тикшертү өчен анализ бирергә баргач, проблема килеп чыгуын яза: «Доктор башта тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген һәм бу кадәр беткән тәнне анализ үткәрергә һәм анда микроб булган тәкъдирдә дә, аңар агулы дару җибәрү мөмкин түгеллеген сөйләде. Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты», – ди. Уфа һаваның җылы, бик уңай булуын әйтеп: «Теге аспирин җотыра торган авыру (бизгәк) күптән бетте...», – дип яза. Петербургта күрешкән, аралашкан иптәшләре Кәрим Сәгыйдов, Шәриф Әхмәтҗановка (Манатов) сәлам тапшыруны үтенә. Шакир Мөхәммәдъяровка пәйгамбар төсле кешесе өчен (доктор) аеруча рәхмәтен белдерә. «Сафа әфәндегә хосусый хат яздым...»[1], – дип хәбәр итә.

Тиздән Троицкига китәсен хәбәр итеп: «Хатны шушы адрес белән язарсың: «Троицк, Оренбургская губерния. Габдрахман Рахманкуловка (Тукаевка)» дип күрсәтә [9: 117].

Уфада Тукай «Сабах» көтепханәсенең гади генә бер буш бүлмәсенә урнашса да, көннәре күңелсез үтми; «Квартир, гомумән, куңелле. Кеше күп килә. Эч пошырлык түгел. Монда һәр көнне мөхәддисе кәбир (*күп белүче әңгәмәдәш*) Әхмәтфәиз Даутов белән күрешәбез. Ул скрипкәдә мараштыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый жыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голувиятен изһар итә (*бөеклеген күрсәтә*)... Әгәр Фәиз әфәнде кеби чын башкорт рухы вә башкорт моңы белән җырланган җырлар да граммофоннарга алынып калса, моны башкорт инкыйразыннан соң азмы әһәмияте булыр иде?!», – дип язып, татар-башкорт көйләрен тыңлап җаны рәхәтләнгәнен аңлата.

Тукай башкорт көйләре һәм җырлары белән кызыксына, музыкасы һәм аны башкаручылар турында зур ихтирам белән телгә ала.

Даутовның башкорт фольклорын яхшы белүе Тукайның игътибарын үзенә тарта. Аның талантын югары бәяли һәм башкорт көйләренең моңлы да, дәртле дә булуын күрсәтә.

Уфада Тукайны күргән аның белән очрашып сөйләшкән кайбер кешеләрнең истәлекләре дә сакланып калган. Шундыйлардан Мөбарәк Әмиров (1886–1968) шагыйрь белән очрашуын болай тасвирлый: «1912 елның май айлары иде булса кирәк, Габдулла Тукай, Троицкига кымызга барышлый, Уфага тукталган иде. Габдулла Тукайның туктаган урыны булган «Сабах» китап магазинына кереп, Тукай белән күрешергә батырчылык итми йөргән бер вакытта, һич уйламаганда, Мәҗит Гафури белән Габдулла Тукай урамда каршы очрадылар. Мәҗит Гафури, мине туктатып: «Бу Әмиров әфәнде була, Ерак Сибириядән, каторгада балалар укыткан», дип, Тукай белән таныштырды. Бердән, «Ерак Сибирия» сүзе, икенчедән «каторга» сүзе Тукайга аерым тәэсир итте булса кирәк, ул миннән Себергә кайчан баруым,

[1] Сафа әфәнде – Сафа Гатаулла улы Баязитов (1887–1937 елдан соң), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, нашир, мөфти (1915–1917). Тукай Петербугка килгән вакытта С. Баязитов ахун һәм «Нур» газетасының мөхәррире дә була. Шагыйрьгә хөрмәт күрсәтеп, материаль якны тәэмин итә (кунакханә өчен түләү, поездга билет алып Уфага озату һ.б.). Тукай «Нур» газетасы идарәсендә һәм С. Баязитовның өендә дә берничә мәртәбә кунак була, китапханәсе белән таныша. Шагыйрь үзе «Мәкаләи махсуса» мәкаләсендә «тик Сафа әфәндегә барганда гына җан рәхәте була иде» дип искә ала.

Прогрессив карашлы бу затны ихтирам итеп һәм хуҗа хакын хаклап та Тукай аңа рәхмәтле булып хат яза. Әмма ул хат сакланып калмаган.

анда нинди шартларда эшләвем һәм кемнәрне укытуым турында гаять кызыксынып сораша башлады. Ләкин кемдер берәү килеп чыгу сәбәпле, сүз киселеп калды. «Хәзергә хушыгыз, Габдулла әфәнде», – дип, аерылып китәргә туры килде.

Тукай бу вакытта кара-көрән төстәге озын гына җөббәдән (*җиңел пальтодан*), тар кыркулы каракүл бүректән иде. Бөек шагыйрь белән очрашып күрешү минем өчен никадәр кыйммәтле бер вакыйга булса да, ул дәвамлы була алмады. Минем өчен беренче һәм соңгы очрашу булып калды...» [1: 43–44].

1. Аминева В.Р. Габдулла Тукай и русская литература XIX века: типологические параллели. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2016. – 160 с.
2. Ананьева С. Казахская русскоязычная литература // Современная литература народа Казахстана / Под ред. С.В. Ананьевой. – Алматы: Evo Press, 2014. – С. 445–482.
3. Айтматов Ч., Шаханов М. Плач охотника над пропастью (Исповедь на исходе века) // Айтматов Ч. Собрание сочинений: в 7-ми томах. Т. 6. – М., 1998. – С. 137–590.
4. Казахстан в моей судьбе. Хрестоматия современной литературы / Ответственный редактор С.В. Ананьева. – Алматы: Print Express, 2019. – 478 с.
5. Линков В.Я. Введение в литературоведение: История идей от Вико до Бахтина и Гадамера. – М.: ЛЕНАНД, 2019. – 232 с.
6. Тукай Г. Энциклопедия. – Казань: Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2016. – 864 б.

УДК 82.091

## ОБРАЗ Г. ТУКАЯ В РОМАНЕ Р. ТУФИТУЛЛОВОЙ «ЯЗМЫШ ҖИЛЕ»

***Г.А. Ахметгараева***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье анализируются особенности изображения образа великого татарского поэта Габдуллы Тукая в романе Р. Туфитулловой «Язмыш җиле» («Ветер судьбы»). Доказано, что образ поэта служит для раскрытия образа главной героини произведения Гульсум Камаловой, при этом обнаруживая себя на различных уровнях романа. Важным композиционным элементом произведения выделены эпиграфы к главам, где в сильную позицию вынесены цитаты из стихотворений поэта. Также для композиции важен и сам образ поэта, активно участвующего в развитии сюжета произведения, составляющего основу «поэтического сюжета», любовной линии романа и усугубляющего ведущий конфликт – столкновение личности и эпохи.
**Ключевые слова:** образ, герой, роман.

The article analyzes the features of the image of the great Tatar poet Gabdulla Tukai in R. Tufitullova’s novel «Yazmysh zhile» («The Wind of Fate»). It is proved that the image of the poet serves to reveal the image of the main character of the work Gulsum Kamalova, while revealing itself at various levels of the novel. An important compositional element of the work is the epigraphs to the chapters, where quotations from the poet’s poems are placed in a strong position. Also important for the composition is the

image of the poet himself, who is actively involved in the development of the plot of the work, which forms the basis of the «poetic plot», the love line of the novel and exacerbates the leading conflict – the clash of personality and era.
**Key words:** image, hero, novel.

В 2019 году публикуется роман писательницы и публициста Розы Туфитулловой (1945) «Язмыш җиле» («Ветер судьбы»), посвященной истории жизни татарской просветительницы Гульсум Камаловой, снискавшей славу во всём тюрском мире. По мнению исследователя М. Хабутдиновой, произведение является образцом очерковой прозы и представляет собой цикл из фрагментов, каждый из которых описывает определенный этап биографии главной героини через реконструкцию её контактов с знаменитыми татарами, имеющими отношение к тому или иному периоду татарской общественной жизни (Г. Тукай, Г. Исхаки, М. Бигиев, Ф. Карими, Ю. Акчура, И. Нуруллин, А. Расих, М. Ногман) [2: 313].

Особое место в романе занимает образ Габдуллы Тукая, который выполняет ряд важнейших функций в системной образе всего произведения, но прежде всего служит для раскрытия образа главной героини – Гульсум Камаловой. Образ поэта находит отражение на различных уровнях произведения.

Композиционно произведение делится на семь частей, каждая из которых, помимо последнего, открывается эпиграфом из стихотворений Тукая.

Первая глава «Кара төннең ак фәрештәсе» открывается цитатой из стихотворения «Хәстә хәл» (1913): Ауру җанның бишмәте-тәнне дәваның төрлесе / Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм. / Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым, / Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм! [1: 6], и хронотопом Петербурга, гуляя по которому автор размышляет о судьбе великого татарского поэта Габдуллы Тукая, в конце 1912 года посетившего этот город на Неве. Таким образом, по мнению исследователя М. Хабутдиновой, автор разрабатывает в образе Петербурга хронотоп литературного города, где рассказчик, путешествуя по Казанской улице, вспоминает имена польских и русских поэтов А. Мицкевича, А. Пушкина, А. Дельвига, Б. Пастернака [2: 313].

С первых упоминаний Тукая, в канву произведения включается образ «язмыш җиле», ветра судьбы, который далее перерастает в символ и предвосхищает основной конфликт произведения, описываемой далее на примере судьбы Гульсум Камаловой – столкновение личности и эпохи: «Бары тынгысыз уйларым гына гасырларның нәни Габдулланы саткан, елаткан, Тукай итеп моңландырган, җырлаткан, “милләтем” дип җан аттырган, ачы язмыш, тәкатьсез авырулар белән тилмерткән тарафка юнәлә» [1: 7].

Также здесь намечается любовная линия Гульсума и Габдуллы – робкая, чистая и с безмерной заботой, уважением друг к другу, где Гульсум предстает читателю в потоке сознания больного поэта: «Кызлар арасында чаялыгы белән аерылып торган Өммегөлсемнең үзенә җан атып йөрүен белә иде Тукай. (Казанның укымышлы кызлары арасында азмыни аңа җан атучылар?) Әмма кызны күрмәмешкә салышып, һәрчак бүлмәдән тизрәк чыгып китү ягын карый торган иде. Тик менә бүген, мосафирханәдә аның белән икәүдән-икәү, күзгә-күз калгач, күрмәмешкә салышу мөмкин түгел. Ишетүенчә, Өммегөлсем Петербургның данлыклы Бестужев курсларында белем ала. Күр, әнә ничек үзгәргән!.. Русның аксөяк кызларына биргесез...

Юк, юк, аңа иң килешкәне – ак фәрештә сурәтендә йөрү» [1: 10–11]. Гульсум предлагает поэту поехать на лечение в Крым, собирает средства. Расширяет границы их любовной линии упоминание о Зайтуне Мавлюдовой, которая в истории татарского народа упоминается единственной женщиной, покорившей сердце поэта.

В романе не раз подчеркивается народная любовь к поэту, обозначенной уже в первой главе – в посещении передовой татарской молодежи больного поэта, где его устами в публицистическом ключе даётся им оценка: «Тукай аңлады: болар чын татар балалары, чөнки татар җаны беркайчан да моңсыз, сагынуларсыз була алмый. Алар әнә Тукайның үзен дә җылы, сагынулы-яратулы хисләргә төреп куйдылар» [1: 14].

Вторая глава «Шәфкать туташы» открывается цитатой из стихотворения «Алтынга каршы» (1907): «И Тәгалә! Җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал, / Яндыручы бу мөкаддәс җирне – бу ялкынны ал!» [1: 25] и описывает службу Гульсум в турецкой армии в роли сестры милосердии.

В целом, в произведении используется много биографических фактов из жизни поэта, подкрепляемых сносками из различных источников. Например, описывается курьезная ситуация по приезде Тукая в дом Мусы Бигиевых в Петербурге. Так, перед отъездом в Турцию у Гульсум происходит неприятный разговор с Асма апасы по поводу путевых заметок Тукая в Петербург «Мәкаләи махсуса», опубликованных в июльском журнале «Ялт-Йолт» (1912 г.). Как известно, Тукай был очень талантлив на произведения сатиристического характера.

По дороге в Турцию девушка часто обращается про себя к Габдулле, вспоминает его стихотворения. Тукай для Гульсум является национальным героем, его совестью, внутренним стержнем. В разговоре с Марьям она детализирует, что её любовь к поэту – благородная, как к одному из самых достойных сыновей татарского народа: «Тукайны да яратмасак, аннан без кем, нинди милләт булабыз?!.» [1: 35], что снова даёт возможность охарактеризовать героиню («Син – чын әүлия, Гөлсем-җаным» [1: 35]). Образ Тукая в романе отображает и степень отчаяния главной героини: «Аны бүген хәтта Тукай да юата алмый...» [1: 35].

Третья глава «Аерылабыз, ахрысы...» открывается цитатой из стихотворения «Читен эле»: «Ни була тугъмак сыйратын кичмәсәм, Бу ачы гомрем шәрабен эчмәсәм?!» [1: 53] и описывает возвращение Гульсум из Турции, новость об умирающем поэте, последнюю их встречу и её отъезд в Чистополь. Интересно, что в оценке Гульсум столица предстает как «Тукайлы Казан» – образ поэта идентифицирует её родной край.

Далее в оценке русской медсестры Ольги Николаевны усугубляется проблема недооцененности татарских личностей: «Кызык сез татарлар. Кергән берегез, шагыйрьне иң якын, иң кадерле кешебез, туганыбыз, ди. Шаккатам, шулай кадерле булгач, нигә аны "Печән базары"на алып килеп сатканнар соң?! Нигә алданрак дәвалау юлларын эзләмәгәннәр. Нинди яшь килеш китеп бара…» [1: 55].

Примечателен следующий отрывок, приведенной после съемки последней фотографии поэта Шигабом Ахмаровым и Ахметов Урманчеевым, где через обращение к понятиям «Мгновение» и «Вечность» личность поэта раскрывается в космическом масштабе: «Тукта, Мизгел, син Мәңгелек! Әмма әлегә бу гаҗәеп кадерле Мизгел белән илаһи Мәңгелек арасында, соң

көченә егерме җиде еллык гомерне иңләп, ахыргы егерме җиде сәгать ярсып чаба... Соңгы минутында аңа тагын “кара төннең ак фәрештәсе” иңәр. Тукай аның үҗәтлегенә, самимилегенә тагын бер кат гаҗәпләнеп, сокланып елмаер» [1: 58]. Татарский народ воспринимает гибель поэта как личную трагедию.

По приезде в Чистополь Гульсум узнает, что возлюбленная Тукая не смогла проститься с ним до смерти, после чего Камалова искренне сокрушается над этим, проявляя искренние чувства и помыслы: «Гөлсем Чистайга алданрак кайтып өлгергән булсамы?! Ул Зәйтүнәне, ташып аккан бозлар өстеннән җитәкләп, җәяүләп булса да, Казанга алып килеп җиткерер иде. Юкса шагыйрь Зәйтүнәсе юлына нинди мәхәббәт шигырьләрен җәеп куйган иде...» [1: 62]. В следующей главе, когда после смерти Тукая, заболевает и Зайтуна, Гульсум её выхаживает и проявляет смиренность, признает любовь Габдуллы и Зайтуны, заявляя: «Ә Гөлсем нишләрме?! Гомере буена Тукайны яд итеп яшәр» [1: 76]. Такая смиренность присуща татарским женщинам, что отсылает, например, к образу главной героини Сагиды в романе Гаяза Исхаки «Остазбикә», принявшей в семью вторую жену, которая родила им ребенка.

Четвертая глава «Чистай кызлары» открывается цитатой из стихотворения «Хатыннар хөррияте» (1909): «Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга! / Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга! / ...Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең! / Кеше булмак өчен иң беренче шартыбыз безнең!» [1: 63], которое является вольным переводом и адаптацией на татарскую реальность стихотворения русского поэта В.В. Князева (1887–1937) «Либерал средней руки перед банкетом» из еженедельного петербургского журнала «Сатирикон», которая издавалась в 1908–1914 гг. Данная цитата предвосхищает описание деятельности татарских женщин-просветительниц. Так, после смерти Тукая, гибель известной просветительницы Фатыймаи-Фәридә становится очередным ударом для татарского народа.

Пятая глава «Акчуриннар килене» открывается цитатой из стихотворения «Җыр»: «Тимай бай булсаң да – азанчы күмәр» [1: 77]. В главе описывается замужество Гульсум за симбирского фабриканта Габдуллу Акчурина. Косвенно Тукай закладывает мостик между ними, потому что именно при чтении Гульсум его стихов, её будущий муж еще больше влюбляется в неё. Образ Тукая внедряется в текст произведения через образ бабочки: «Әллә каян гына бер ут күбәләге очып керде. «Тәгаләм, Тукай җаныдыр бу», – дип юрап, эчтән генә көрсенеп тә алдылар» [1: 84]. Между Гульсум и Акчуриным возникает большая, осознанная любовь. Её муж также любит читать стихи Тукая, Гульсум же продолжает чтить его память, преподает его творчество в школе для девочек, проводит мероприятия, делает пожертвования: «Гөлсем исә кызлар мәктәбендә укытуын яратып дәвам иттерде. Ә ул булган һәр җирдә Тукай иҗатына чиксез мәхәббәт, ихтирам хөкем сөрә. Казанда «Шәрык» клубында, «Яңа клуб»та, Эрмитажның җәйге театрында, Панаев бакчасында әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда җиң сызганып йөрүче Гөлсем, бөек шагыйрьнең вафатына ике ел тулу уңаеннан, Гурьевкада «Тукай кичәләре» оештыра. Соңгысында Гөлсем Акчурина үзенең 50 сум хезмәт хакын кушып, «Кояш» газетасы идарәсенә 97 сум акча җибәрә. Бу – шагыйрьнең каберенә чардуган һәм хәтер ташы куюга керткән иң зур хәйрия булып теркәлә» [1: 100].

Шестая глава имеет одно и тоже имя с названием романа «Язмыш җиле» и открывается цитатой из стихотворения «Киңәш» (1908): «Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул: / Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул. / Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел, / Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл» [1: 101], где находят отражение печальные события после замужества Гульсум и скитания с мужем по стране из-за революции. В этой главе упоминается и другой тюркский – казахский поэт Магжан Жамабаев.

В последней седьмой главе «Сөйләттерде миңа йөрәгем...» автор объясняет причины обращения к материалу, приводит условный библиографический список произведений, посвященных освещению жизни Гульсум Камаловой и Габдуллы Тукая. Кольцевая композиция произведения осуществляется за счет повторному обращению к хронотопу Петербурга, но автор облегченно вздыхает, так как смогла превратить свои мысли и поиски в материю – в книгу: «Ак фәрештә» хакындагы хикәятемнең кабатланмас бер мизгел белән тәмамлануына сөенә-сөенә, җәяүләп, Казанский урамына юл тотам. ...Ә Петербургка тагын сихри ак төннәр килә» [1: 142].

Таким образом, образ Габдуллы Тукая занимает важное место во всей образной системе романа Р. Туфитулловой «Язмыш җиле» (2019). Важным композиционным элементом произведения являются эпиграфы к главам, где в сильную позицию вынесены цитаты из стихотворений поэта. Также для композиции важен и сам образ поэта, активно участвующего в развитии сюжета произведения, составляющего основу «поэтического сюжета», любовной линии романа, раскрывающего образ главной героини Гульсум Камаловой и усугубляющего ведущий конфликт – столкновение личности и эпохи.

ЛИТЕРАТУРА

1. Туфитуллова Р.Р. Язмыш җиле. Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 143 б.
2. Хабутдинова М.М. Идейно-художественное своеобразие романа Р. Туфитулловой «Язмыш жиле» // Литература и художественная культура тюркских народов в контексте Восток Запад: материалы Международной научно-практической онлайн-конференции. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. – С. 312–314.

УДК 821.512.145

## НЕМНОГО О БИОГРАФИИ Г. ТУКАЯ

***Г.Р. Ахметзянова, Г.М. Насыйрова***
*Казанский юридический институт МВД России (Казань)*

В статье описывается детство поэта, которое повлияло на его творческую жизнь. Определено, что биография Г. Тукая помогает нам оценить его творческий путь. Идеи Г. Тукая повлияли на поколения. Г. Тукай признал необходимость борьбы народа против старых форм жизни. Поэзия Г. Тукая заставляет думать о жизни. Стихи поэта – пример для начинающих поэтов.
**Ключевые слова:** поэзия, детство, жизнь, культура, поколение, возрождение.

The article describes the poet’s childhood, which influenced his creative life. It is determined that the biography of G. Tukay helps us to evaluate his creative path. G. Tukay’s ideas influenced the generation. G. Tukay recognized the necessity of the people’s struggle against the old forms of life. Poetry of G. Tukay makes us think about life. The poet’s poems are an example for novice poets.
**Key words:** poetry, childhood, life, culture, generation, revival.

Я в мечтаньях возвращаюсь к школе,
Я тоскую по своей «неволе»;
Говорю: «Зачем я взрослый ныне
И от школьной отошел святыни?
Почему никем я не ласкаем?
Не зовусь Апушем, а Тукаем?
(Г. Тукай)

Всем известный и глубоко любимый Г. Тукай родился 26 апреля 1886 года в Татарстане, в деревне Кошлауч. С детства его жизнь была сложной, на его пути встречалось много испытаний, которые не дали ему упасть духом, а наоборот помогли ему стать великим поэтом не только татарского, но и тюркских народов.

Когда Габдулле было только шесть месяцев, он лишился отца. Его мать стала воспитывать сына одна, но вскоре решает отдать ребёнка на воспитание старушки. Спустя некоторое время она решает забрать сына обратно и вместе с новым мужем начинают воспитывать Габдуллу. К сожалению, дни, которые он провёл рядом со своей матерью, были ничтожно малы, поскольку она вскоре умирает. В возрасте четырех лет мальчик стал круглым сиротой, и отчим решает отдать мальчика в семью деда Зиннатуллы. В этой семье его невзлюбили, поскольку он был нежеланным ребенком. Зиннатулла решает найти ему новую семью и с ямщиком его отправляет в г. Казань. Ямщик передал Габдуллу в семью бездетного жителя Ново-Татарской слободы по имени Мухамметвали, где он провёл около 2 лет. В дальнейшем его обратно вернули в семью Зиннатуллы, потому что его приёмные родители умерли. Позже ему находят новую семью купца Галиаскара Усманова, где была хозяйкой его тётя по линии отца. В Уральске Габдулу отдали в школу при мечети медресе «Мутыгия». Преподавателем был просветитель Мутыгулла Тухватуллин, у которого дети были воспитаны на европейской манер, знали несколько языков. Г. Тукай решил последовать их примеру и решил выучить несколько языков, вскоре он владел арабским, персидским и турецким, изучил и русский язык. В доме просветителя была большая библиотека, в которой он любил заниматься чтением книг разных жанров. Это и повлияло на его творческую жизнь, а события его детства стали основой для его идеи написания литературных произведений.

Биография Г. Тукая помогает нам осознать тот факт, что творчески одарённым человеком можно стать не только благодаря знаниям, но и упорству, силе духа, умению оставаться самим собой при любых жизненных обстоятельствах.

Г. Тукай за свою короткую жизнь смог захватить сердца многих читателей, поскольку в своих произведениях он затрагивал насущные вопросы, касающиеся не только жизни людей, но и политики в целом [1: 8]. В своих стихотворениях он также главной целью ставил раскрытие значимости сохранения культурного наследия и культурного возрождения своего народа. Раскрытие таких актуальных тем стали основой для его популярности не только среди татарских, но и тюркских народов. Идеи и взгляды Г. Тукая повлияли на целые поколения.

Среди всех поэтов этого периода никто не смог получить межнациональной популярности, кроме Г. Тукая. Его мастерство идеально раскрыло суть затронутой темы и получило большую популярность у тюркских

народов. А так же раскрытие тем с нравственной точки зрения позволило сравнить величайшего поэта с мировыми литераторами Востока и Запада. Поэтому Г. Тукая часто называют представителем Восточного Ренессанса.

Тюркские народы, в том числе и татарский, стремились к национальному возрождению. Это вскоре приводит к тому, что начинают выпускаться журналы, которые положили основу для борьбы с устаревшими устоями тюркских народов. Г. Тукай проявлял постоянный интерес к творчеству азербайджанских писателей, которые поддерживали данные журналы, но особенно он обращал большое внимание творчеству Алекбера Таирзаде, который был известен под псевдонимом Сабир. Эти два поэта верили в то, что с развитием просвещения, будет развиваться и общество. Их миропонимание было связано с «признанием необходимости борьбы народных масс против устарелых форм жизни» [2: 50–60]. Они в своих литературных произведениях критиковали существующий порядок.

В творчестве Сабира и Г. Тукая прослеживается одинаковый образ сна, который они стремились реализовать. Г. Тукай призывал татарское общество проснуться и брать пример с передовых стран, которые развивались быстрее. В творчестве Сабира образ сна используется для оценки сложившегося устоя в обществе. Он критиковал своих соплеменников из-за того, что они не предпринимали попытки, чтобы «разбудить» свой народ.

Данный пример показывает нам то, что в литературах тюркских народов возникли узловые связи, которые стали символом процесса национального возрождения. Это объясняется тем, что не только социокультурные процессы, но и пути развития национальных литератур были схожими.

Г. Тукай смог коренным образом повлиять на мышление татарского и тюркского народа. Его стихотворения проникали в душу, заставляли задумываться о различных аспектах жизни. Дагестанский поэт Расул Гамзатов, говоря о Г. Тукае, утверждал: «Он оставил нам большое наследство. Оно принадлежит не только татарскому народу, но и всем народам».

Обобщая все выше сказанное, хочется отметить, что Г. Тукай, как один из величайших поэтов XX в., вошел в историю не только татарского, но и тюркских народов. Его стихотворения стали примером для многих начинающих поэтов. Он за свою короткую жизнь смог доказать, что есть на земле величайшие люди, которые не боятся трудностей, преодолевают любые препятствия на пути, чтобы достичь поставленных целей и осуществить реализацию идей в жизнь.

Я очень горжусь тем, что могу прочитать стихотворения Г. Тукая на родном мне языке, а именно на татарском.

Вечная память!
Многие люди желали возвыситься,
Хотели свое творчество людям показать,
Чтобы взгляд их разделялся и ценился,
И людьми признанной личностью стать.

Габдулла Тукай один из таких людей,
Кто мнение свое стремился обсуждать
Чтобы все знали, что он один из таких личностей
И тот, кто способен у людей интерес вызывать.

Вся страна гордится таким поэтом,
Кто без слов достоин всех наград

Способный проникнуть в душу стихом,
И готовый перепрыгнуть любой из преград!
(Насыйрова Г.М.)

ЛИТЕРАТУРА

1. Абдуллин Я.Г., Амирханов Р.К. Развитие общественно-политических взглядов Тукая // Габдулла Тукай: материалы науч. конф. и юбилейных торжеств, посвященных 80-летию со дня рождения поэта. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. – С. 50–61.

2. Закиев М.З. Тукай и татарский литературный язык // Слово о Тукае. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 8.

УДК 821.512.145

## ТВОРЧЕСТВО ТУКАЯ И ТАТАРСКАЯ ПОЭЗИЯ В БАШКОРТОСТАНЕ

***Р.К. Амиров*** *(Уфа);*
***И.С. Мансуров***
*Стерлитамакский филиал Башкирского государственного университета (Стерлитамак)*

В статье анализируется влияние творчества Габдуллы Тукая на становление и развитие татарской поэзии в Башкортостане. Анализируется эволюция образа коня в творчестве Тукая и его социально-смысловое наполнение в творчестве современных татарских поэтов республики.
**Ключевые слова:** современная литература, татарская литература, татарская поэзия Башкортостана, творчество Тукая, образ коня.

The article analyzes the influence of the work of Gabdulla Tukai on the formation and development of Tatar poetry in Bashkortostan. The article analyzes the evolution of the image of the horse in the works of Tukai and its social and semantic content in the works of modern Tatar poets of the republic.
**Keywords**: modern literature, Tatar literature, Tatar poetry of Bashkortostan, creativity of Tukai, image of a horse.

## ТУКАЙ ИҖАТЫ ҺӘМ БАШКОРТСТАНДАГЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ

***Р.К. Әмиров*** *(Уфа);*
***И.С. Мансуров***
*Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы (Стәрлетамак)*

Тормышы һәм иҗаты милләтнең яңарыш чорына туры килгән Габдулла Тукайның исеме үзе исән чакта ук татар халкының милли аң, милли үсеше символына әверелде. Ә инде «дөнья читлегеннән» бакыйга – мәңгелеккә күчкәч, халык тетрәнеп, аның табутын дәррәү күтәргән җеназа көненнән башлап, Тукай исеме ул үзе данлаган Мәрҗәни, Каюм Насыйри ише шәхесләр белән янәшә кулланыла башлап, татарлыкның, татар әдәбияты, сәнгате, татар милли аңының символына әверелде. Казан сүзе белән янәшә Тукай исеме бер үк сыйфатта татарлык, татар милли рухының символы мәгънәсен алды. «Абау алла, уф алла, үлде шагыйрь Габдулла» сүзләре белән башланып киткән бәетләрдә, без, нәкъ ул замандагыча, мәрсиянең мәдхиягә, вафат шәхес хакында кайгыруның аның хезмәтләрен, җәмгыятьтә тоткан урынын данлап сурәтләү шаһиты булабыз.

«Милли әдәбият китапханәсе» сериясендә чыккан «Татар шигърияте» исемле китапта XX гасыр башында иҗат иткән сиксәннән артык шагыйрьнең яртысы әсәрләрен Габдулла Тукайга багышлаганнар [4]. Димәк, аның белән бер дәвердә яшәп иҗат иткән шәхесләр – замандашлары тарафыннан Тукай шагыйрьлек, шәхес өлгесе, милләт символы мәгънәсендә кабул ителгән. К. Патиның

Тукай, син бриллиант халкың күзендә
Һаман ялт-йолт итәр ялт-йолт йөзеңдә,

яисә К. Курмашевның

Арамызда нурлы Чулпан, якты Кояш, Ай идең
Милли гөлләр сандугачы – син идең, сайрый идең –

ише шигъри юллары Тукайның замандашлары арасында ук ничек югары башланганын күрсәтеп тора.

Тукай шигърияте тәэсире астында язылган дистәләрчә шигырьләр арасында шундый гыйбрәтле мисал да бар. Габдрахман Сөнгати «Исте җилләр» шигырен (1914) Дәрдмәндкә ияреп язганын ачыктан-ачык әйтә. Әмма әсәрнең беренче өлеше табигатьне Дәрдмәнд «Карабы» рухында кабул итеп сурәтләүгә корылса, икенче өлештә автор ирексездән, нәкъ Тукайча, «Пар ат» әсәре тәэсиренә бирелеп китә. Тукайдагы ритмик алымнар, чагыштырулар әсәрнең табигый өлешенә әйләнә. Бу бигрәк тә ат образының үсешендә ачык чагыла[1].

Төрки халыклар тормышында атның тоткан урыны хакында сөйләп торасы да юк. Абруйлы ике исемгә генә игътибар итү дә җитә. «Тарихта билгеле булганча, – дип язды академик Ә. Кәримуллин, – цивилизация тәгәрмәчен кызулатучы бер зур ачышны төркиләр уйлап чыгарган. Бу ыштан уйлап табу. Ыштан уйлап табу – атка атлану дигән сүз. Инде атка атланган төрки халыклар өчен бу зур пространстволар кыскарган, шулай итеп, төрки халыклар Евразия далаларында зур-зур дәүләтләр, цивилизацияләр төзегәннәр, дөньяны айкап яши башлаганнар» [2: 12].

«Тискәре образлардан башка башкорт әкиятләрендә уңай образлар да гәүдәләнә, – дип яза күренекле башкорт галиме Ә. Харисов. – Алар – ат һәм һәм сәмрекош. “Күз ачып йомганчы” батырны теләгән җиренә очыртып итүче ат Толпар – батырның чын дусты, максатка ирешү юлында беренче ярдәмчесе. Башкорт әкиятләре өчен ат (толпар, бүз ат, акбузат) – аеруча характерлы персонаж» [6: 69].

Бәлки, нәкъ шул сәбәптәндер бары тик төрки халыкларда гына ир-ат гыйбарә – кушымтасы янәшә куллана торгандыр да әле.

Башкорт халык җыры «Азамат»ның герое «ир-егеткәй белән ат башы» күргән-кичергән хәл-вакыйгалар нәкъ героик-романтик сыйфатта, яуда да, дауда да шигъри-поэтик биеклектә сурәтләнә.

Гражданнар сугышы елларында, Бөек Ватан сугышы чорында Мәҗит Гафури («Татар егетенә»), М. Кәрим («Мин фронтка китәм, иптәшләр!») һ.б. иҗатында, татар-башкорт шигъриятендә һәм прозасында, бу халыклар тормышын сурәтләгән рус әдәбияты нәкилләре К. Федин, И. Эренбург, К. Симонов, Ариадна һәм Петр Турлар әсәрләрендә ир-егет белән ат образлары туган ил образы белән бербөтен буларак сурәтләнде. Традицион халык иҗаты образының бу очракларда заман таләпләренә җавап йөзеннән сәяси төс алып кулланылуының шаһитенә дә әйләнәбез без.

Әлбәттә, ат малының халык тормышында, аның эстетик аңында тоткан урынын Габдулла Тукай бик яхшы аңлаган. («Аты бар бик начар өч тәңкә торырлык»). «Мужик йокысы»ннан башланып киткән бу алым-образ Тукай иҗатында арытаба ике мәгънә ала. Берсе – шагыйрьнең Уральскида чагында язылган «Пар ат» әсәрендәге романтик образ. Чыннан да, бу әсәрдә хыялый фараз тудырган хыялый ат образы вазыйфасы белән дә зур өметләр баглаган яшь әдипне, ул, «нурлы Казанга, моңлы Казанга» ыһ дигәнче итеп җиткерергә сәләтле әкиятләргә якын.

«Пар ат» шигыре шул ук ашкынулы хисләр белән үтәдән-үтә сугарылган» – дип язды бу әсәр хакында Гали Халит [5: 11]. Шуңа да сирәк-саяк кайбер профессиональ җырчыларның әсәргә прозаик элементлар кертергә тырышуларын, («тырр!» дип сәхнә яңгыратып кеше көлдерү сыман ялган халыкчан ишарәләре һ.б.), акбузатны алашага әйләндерергә тырышып көчәнүләрен автор фаразына туры килә, дип әйтеп булмый. Мондый очраклар, әсәрдәге образ ике халык иҗатындагы (нәкъ Тукай Сибәгатуллины кебек: «инде алай да булмаса, рестораннарга кереп акырып җырлап йөри») әкияти дөл-дөл урынына, чынлап та, алҗыган алаша китереп чыгара.

Вакыт үтү белән төрки халыклар әдәбиятында Тукай исемен, аның әсәрләреннән алынган гыйбарәләрнең әдәби әйләнешкә яки, киресенчә, әдәбияттан көндәлек әйләнешкә кереп, кулланыла башлау аның миллилегенә, милләтенә тугрылык символына әйләнә баруын дәлилләде.

Акбузат – изгелек, ә Тукай үзе, теле – миллилек, милли аң, милли тарих символы буларак кабул ителде. Шагыйрьнең «Мин – Тукай баласы!» дип кычкырып әйтүе дә һич тә сәер түгел икән ләбаса: аннан җир дә убылмый, дөньяның да чите кителми. Бары бу гыйбарәне матур итеп әйтүче шагыйрьнең (Марис Нәзиров), аны укучы-ишетүченең күңеле була да рухы күтәрелә.

Хәреф таный гына башлаган балага тәгаенләп язылган шигъри юлларның (сүз «Туган тел» әсәре турында бара) бөтен халык гимнына әйләнүе, Башкортстан шартларында һәр милли-мәдәни, сәяси чараның шушы әсәрне күмәкләп башкару белән тәмамлануның сәбәбе дә, бәлки, Тукайны милли әләм буларак күрү теләгеннән киләдер.

Шуңа ахры, бу әсәр Идел-Урал буенда яшәгән барча халыкларның да уртак милли гимнына әйләнде. Башкортстандагы татар иҗтимагый-мәдәни оешмаларның, башкорт, рус, мари, чуваш, удмурт, яһүд һ.б. халыкларының оешмалары белән уртак «Туган тел» әсәрен иң яхшы башкаручыга бәйге үткәрергә ниятләнеп йөрүләре генә дә ни тора?!

Олы вакыйгалар казанында Казанда кайнаган Тукайның зәвыгы да, фикерләү дәрәҗәсе дә кискен үзгәрә. Чынлап та, «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык теләкләре» (1913) әсәрендә халык мөнбәренә күтәрелеп, халык исеменнән Русия дәүләтенә тәкрарлаулар һәм яңа раслаулар белән мөрәҗәгать иткән әдип иҗатында ат образы да күпкә киң мәгънә ала.

1960–1980 елларда да ат образы буыннар, шәхес язмышы белән бергәттән традицион героик-романтик яссылыкта да сурәтләнү белән бер үк вакытта икенче фәнни-техник революция һәм ул тудырган рухи-әхлакый югалтулар яссылыгында җитди үзгәрешләр дә кичерде.

Бөтен совет әдәбиятында (Ч. Айтматов, «Хуш, Сарыгөл!» («Прощай, Гульсары!»), Г. Матевосян «Үгез-сыер» («Буйволица»), В. Белов «Сыер турында җыр» («Песня о корове»), җөмләдән Башкортстан әдәбиятында да ат язмышы ил язмышы белән берлектә сурәтләнә башлады. Бу җәһәттән

күзгә күренерлек фикерләү йөге сугыш елларында балигъ булып, 1960–1970 елларда «ил язмышын төпкә җигелеп тарткан ат»ка әйләнгән әдәби буын җилкәсенә төште. Шул ук Ә. Атнабаев, Р. Сафин, М. Кәримов әсәрләре фәнни-техник революция һәм соңыннан торгынлык дип аталган еллар барлыкка китергән күренешләргә кинаяле җавап булды. Ат һәм башка йорт-кура малы халык язмышының, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләренең символы дәрәҗәсенә күтәрелде (Р. Гарипов, З. Солтанов, Р. Мифтахов, Р. Бикбаев һ.б.). Әйтик, «Без – егерме сигезенчеләр!» шигырендә Ә. Атнабаев, үз буынын шул ук атка тиңләп, «безнең буын төпкә җигелеп тарта торган ат бүген», «җилкәләрдә заман йөге», дип язды.

Чынлап та, ат язмышы ир язмышы гына түгел, ил язмышы да ул [7]. Атның тормыштан читләтелә баруы халыкның ихласлык, эчкерсезлек кебек сыйфатлардан ваз кичүе буларак кабул ителде бу елларда.

«Заманында тизлек һәм көч берәмлеге
Булган атлар хәзер бездән көнләшәләр.
Азбарларның кәртәсеннән башын тыгып
Моңсу гына кешнәп, безгә эндәшәләр»,

дип моңая Ә. Атнабаевның лирик герое, колга әйләнгән атка карап. Ә инде икенче әсәрдә, нәкъ атнабайча мыек аша елмаеп, атны алыштырачак.

«Акыллы да, акылсыз да машиналар,
Сәбәпчеләр яманга да, яхшыга да…
Тора-бара, бара-тора үзебез дә
Әйләнмәсәк ярар иде машинага» (1973) –

дип безне кисәтеп тә куйды.

Рим Идиятуллинның «Җирән бия вафаты» (1984) әсәренең шагыйрь-фронтовик Г. Әмири сугыш елларында язып, соңыннан халык җырына әйләнгән «Җил, җирәнем!» әсәренә аваздаш-адаш булуында да тирән мәгънә бар иде. Яу юлларын үтеп, ачлык-ялангачлык елларын бергә үткәргән атның үлеме үзе үк халык язмышының фаҗигале бер сәхифәсе тәмамлануга тиң.

«Аһ итәрлек кайгы булмаса да,
Күңелемне сагыш биләде», –

ди шагыйрь, көрсенеп.

Дөрес, бу чорда да ат образының романтик сыны шигърияттә яшәвен дәвам итә иде әле. Рафаэль Сафинның Акбузатка багышланган лирик-эпик циклы, Н. Нәҗминең «Уфа юкәләре», Ә. Атнабаевның «Җиз кыңгырау моңнары» әсәрләрендә ат еракта калган, кире кайтмас яшьлекнең романтик символы буларак сурәтләнде.

Татарстандагы татар шигъриятендә исә ат образы халык рухының күтәренке мизгелләрен сурәтләүгә, искә төшерүгә корылды.

Һәр татарда егылып ат ята.
Атын җуйган өчен оят ята.
Аның атын яулап ал кабат.
Шундый теләктә без, «Аргамак»! –

дип фатиха бирде Мөдәррис Әгъләмов яңа журналга.

«Менә күптән түгел генә кулыма шундый китапларның (әйбәтлеге беркемдә дә шик тудырмый торган) берсе килеп керде. Исеме генә дә ни тора! – «Ак вә кара»!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады.
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары!
(Р. Әхмәтҗанов «Бәйрәм»).

«Шигырьдәге рухи көч, эчке шатлык, эчке горурлык ташкынына игътибар итегез, – дип шәрехли тәнкыйтьче шигырьне. – Ә инде татар күңеле турында ничек төгәл һәм матур итеп әйтелгән: «Безнең йөрәк бәйрәмнәренең»… Бер яктан, монда коллык хәлендәге халыкның бәйрәме күздә тотыла, эчтән генә, тышка чыгармыйча, чит-ятка белдермичә генә уздырыла торган бәйрәм… ә инде икенче мәгънәсе: бу – чын бәйрәм, бөтен җаның-тәнең, бөтен йөрәгең белән тантана итеп, ихластан шатланып, горурланып үткәрелә торган бәйрәм! Көчле талант иясенең бер әсәрендә әнә шундый мәгънә катламнары – һәр икесе дә дөрес һәм гадел булган фикерләр – бергә үрелеп, бер шигъри тән, бер җан булып яши» [1: 230–231].

Әмма, яңа заманалар килеп, укучының аң-зиһене ачыла башлагач, Башкортстан шартларында дистә еллар буе «Кызыл таң» газите авторы гына булып гомер сөргән татар телле авторлар, башта үз акчасына, соңрак дәүләт исәбенә китаплар чыгару мөмкинлеге барлыкка килүгә, халык аңын уяту эшенә тотындылар, Г. Тукайның мин «коеп куйган шагыйрь генә түгел, дипломат та, социалист» та гыйбарәсен искә төшергәндәй, үз халкы белән янәшә басып, халык теләк-таләпләрен хакимияткә образлы шигъри тел аша җиткерү вазифасын үз өсләренә алдылар.

Табигый, иң башта халыкның, җөмләдән, Башкортстан татарының, хәләтен аның үзенә генә аңларлык телдә әйтеп бирергә кирәк булды. XX гасыр башындагы татар-башкорт әдәбиятында шактый киң урын алган «Ялкау ат – ялкау мужик» гыйбарәсе (М. Гафури «Мужик йокысы») инде мәсьәләне бераз гадиләштереп, тормыш тудырган проблемаларны геройның шәхси сыйфатларына гына кайтарып калдырмакчы иде. Шуңа үз вакытында Тукайның патша хөкүмәтенә ишеттерергә теләп, халыклар тигезлеген яулап кулланган гыйбарәсе бик урынлы һәм, әйтергә кирәк, уңышлы, заманча яңгырашлы булып чыкты.

«Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» (1913) әсәрендә ул:

«Без сугышта арысландай көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез», –

дип язган иде. Шагыйрьнең Рус дәүләте, рус милләте белән тиңләшергә, мөрәҗәгать-хитап аша өлгереп җиткән дөньяви-сәяси мәсьәләләрне хәл итәргә омтылуында, халык көткәнчә фикер йөртергә тырышуы күзгә ташланып тора.

Ә бүгенге әдипләребез күзаллавынча, Тукай гыйбарәсенең икенче өлеше («без тынычта аттан артык эшлибез») Башкортстан татарының хәләхвәлен дөресрәк, ачыграк чагылдыра. Нишлисең, татар һәрчак татарча хыял йөртә, фикер туплый.

Бу җәһәттән Фәрит Габдерәхим, Салават Рәхмәтуллаларның әсәрләре аерым игътибарга лаек, чөнки нәкъ менә шушы авторлар иҗатында ат образы эш аты мәгънәсен алып, Башкортстан татарының хәләтен эченә сыйдырды һәм аерым бер символ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнә башлады. Шунысын әйтү дә урынлы булыр. Бу ачышлар традицион толпар, аргамак образларын инкяр итми, андый фикерләү белән бәхәскә дә керми: бары тик

ат образының ни дәрәҗәдә дөньяны тоемлау, кеше язмышын үз эченә алу мөмкинлеген ассызыклый иде.

Башкортстан татар әдәбиятында бу образга, яңача яңгыраш биреп, әдәби кулланылышка беренчеләрдән Салават Рәхмәтулла кертте, ахры.

«Йөк тартканда
Төптә – атлар без.
Улаклардан читтә –
Ятлар без».

Берәүләр суверенлык өчен көрәшеп, икенчеләр, пыр тузышып, мал бүлешкән мәлдә туган бу әсәрнең беренче ике юлы Тукай гыйбарәсен турыдан-туры кабатлый: шунлыктан монда артык яңалык та юк сыман. Әмма нәкъ соңгы икеюллык әсәрне урындагы җирлеккә, югарыда әйтелгән бәхәсләр заманына кайтара. Кайтарып кына калмый, бөтен әсәргә яңа мәгънә бирә. Моңарчы шагыйрьнең «сабантуйга әзерләнгән аргамаклар», аларга атланыр «сөлек кебек егетләр» турында күтәренке рухлы:

«Ил язмышын илдә кем күтәрсен,
Ирләр белән атлар күтәрми»

ише юлларында (1967) вакыты җиткәч туачак образның оеткысы чагылып калган иде. Халык аңыннан, халык фикерләвеннән килгән бу гыйбарәгә нәкъ тукайча-заманча яңа социаль-сәяси аһәң бирү традицион образның яңаруына да китерде. Әсәргә кереш сүз – эпиграф формасында куелган җөмлә («Башкортстанда яшәгән милләттәшләремнең язмышын уйлап») дә аңа үзенчәлекле юнәлеш биреп тора.

Күренекле татар шагыйре Фәрит Габдерәхим иҗатында да ат образының үсеше шулай ук гыйбрәтле. Үзгәрешләр заманы башлану белән (Әнгам Атнабаев исемендәге бүләк иясе Ф. Габдерәхимнең үзе раславынча, ул хәзер милли шигырьләр генә яза) аның әсәрләрендә ике капма-каршы оппозиция урын алды. Бер яктан, империячелек рухы, икенче якта – милләт, милли тел, милли әдәбият язмышы. Мәсьәлә уңай хәл ителсә, бөтен милләтләрнең, шул җөмләдән, Башкортстан татарының да, язмышы яхшыга-юньлегә борылыр кебек иде, Шуңа бәрабәр ат та әле империя аты рәвешендә, ә халык талчыккан ат чанасына утырыпмы, тагылыпмы бара. Аның (халыкның) үз тормышы фаразлар дөньясында гына кала әле: «Булыр микән, бер чак булыр микән Үзеңнеке чана-атларың?»

Ә инде «Эш аты», «Алдану» әсәрләрендә, исемнәреннән күренүенчә, әдипнең төп игътибары турыдан-туры татар халкына, тәгаен, Башкортстан татарының язмышын сурәтләүгә юнәлтелә.

Ә ул тарихи-икътисади, заманындагы сәяси шартлар нәтиҗәсендә урталай суккан еландай икегә бүленеп калган.

Чынлап та, 1921 елның язында Уфа губерна партия комитетыннан Стәрлетамак, Бөре, Бәләбәй өяз партия комитетлары исеменә телеграмма килеп төшә. 1919 нчы елда оешкан Бәләкәй (Кече) Башкортстан белән Уфа губернасын берләштереп, Олы Башкортстан төзү алдыннан бу өязләрдә яшәгән татарлардан яңа оештырылган Олы Башкортстанда калыргамы яки Татарстанга кушылыргамы – шул турыда фикерен белеп, тиз арада җавап бирүне таләп итә бу җитди тарихи документ.

Халык фикерен ишетеп, аңа таянып эш итү кирәклеген уңайлырак форсатка калдырып (референдум кайгысымыни – әле генә ил өстеннән граж-

даннар сугышы афәте узган: ачлык-ялангачлык, ятимлек, җитмәсә, юллар өзелгән вакыт), төрле олыслардан (волость) җыелган Бөре өязе партия комитеты әгъзалары шундый карар кабул итә: «Казан безнең рухи башкалабыз. Әмма, Башкортстанның фуражиры (ашатып-эчертүчесе, тамагын туйдыручысы, димәк) буларак, без аның составында калабыз». Фуражир вазифасын Башкортстан татары аклаганмы, моның өчен рәхмәт сүзе ишетә алганмы, – анысы тарих хөкемендә. Әмма совет империясе яшәгән 70 ел эчендә татар күңелендә кузгып килгән бихисап проблемалар берзаман калкып чыгачак иде.

Чынлап та, Советлар Союзы исемен йөрткән империя оешканда ук үзара килешеп яшәү урынына «олы абзыйга» мөрәҗәгать итеп торсыннар өчен Азәрбайҗан белән Әрмәнстан арасында Карабах шынасы, үзбәк белән таҗик арасында Сәмәрканд, казах, үзбәк, кыргыз арасында Наманган өлкәсе, Латвия, Белоруссия, Литва арасында Игнали «дуслык ГЭСы» бәхәсләр чыганагы буларак махсус калдырылган, XVIII гасыр башында ук әле Казан губернаторы князь Волконский тәкъдим иткән «Добро бы эти народы жили в мире, а не худо бы, если бы и ссорились» [3: 304] сәяси тәкъдиме – проекты үтә дә озын гомерле булып чыккан шул. Шушы шартларда үзен югалта язган халәттә дә йөзен саклап калырга тырышкан (һәм тиешле!) Башкортстан татарының бүгенгесе – аяныч язмышы тынгы бирми әдипләребезгә.

Тукай әсәрендәге («Без тынычта аттан артык эшлибез») ат образының эш аты формасын алуы табигый һәм тарихи яктан аңлашыла да.

Шуңа Тукай сынын әдәбият, тормыш белән янәшә куеп карау антиутопиягә охшаш нәтиҗәләргә китерүе дә бар. Әйтик, Ә. Атнабаевның, гадәтенчә, мыек аша елмаеп (һәм бу елмаю аша кинаяле ачынып), язылган бер әсәрендәге «сыңар медаль дә юк, к чуртым!» юлларына иярепме, Р. Идиятуллин, гадәтенчә, кыска гына,

«Тукайны күреп төшемдә
Тетрәндем: бу ни хәл?
Калтырап торган түшендә
Ялтырап тора медаль», –

дип тавыш бирде. Яисә «базарда кырылышып дуңгыз башы сайлаучы татар картларын» күргән шагыйрь Мөнир Вафин нәкъ Тукайча ясаган ирония катыш нәтиҗәгә игътибар итик:

Якын да үрелә алмый
Башка милләт затлары…

Шуны ачтым: безнең халык
Җегәрле, тешле икән…
Тукай хаклы, ул чыннан да
Зур икән, көчле икән.

Башкортстан татарының язмышы тынгы бирми Ф. Габдерәхимгә дә. Шуңа да күп мәгънәле эш аты төшенчәсе юкка гына күрше утарга ябылган тышаулы ат образы формасын алмый. Бу образлы гыйбарәдә автор тарихи практикага турыдан-туры ишарә ясый һәм, шуңа таянып, халыкның бүгенге хәленә мөрәҗәгать итә.

Авызлык, йөгән, тышау, тәртә, чыбыркы кебек ат белән эш иткән кешенең һәрберенә таныш әйберләргә Башкортстан шартларында гомер сөрүче татарга үтә дә аңлаешлы образлы мәгънә салынган. Башка очракта гүзәллек

символы буларак сурәтләнгән ат образы белән мондый прозаизмнар әсәрне памфлетка якынайтып, аның публицистик яңгырашын киңәйтә һәм тирәнәйтә.

Әйе, Башкортстандагы татар әдәбияты, Тукай традицияләренә тугры калып, проза һәм шигъриятнең төрле жанрларында иҗат иткән хәлдә, бүгенгә күбрәк менә шул эш аты образының төрле яклап эшләнешенә игътибарны көчәйткәннән-көчәйтә. «Тукай тәэсирен бу образга гына кайтып калдыру бүгенге Башкортстан татар шигъриятен чикләмиме, аны үтә ярлыландырмыймы соң?» дигән сорау тууы да бар. Аннары «эш Тулпар, ат образы белән генә чикләнми бит», диюче дә булыр. Әйе, без анысын да инкяр итмибез. Әмма әдәби процесстагы яңалыкның, әдәбиятны халык тормышы, аның бүгенге үзаңы белән бербөтен итеп бәйләп торучы җеп әлегә шул.

Тукайның «Без сугышта арысландай көчлебез» юлларын халкыбыз, аның әдипләре үзенең гасырларга тиң каһарманлыгы һәм акыл, әдәби сынланышы белән расласа, «без тынычта аттан артык эшлибез» гыйбарәсен шул халыкның XX гасыр ахырындагы хәләтен эш аты сурәтендә күрде. Әдәбиятта шулай бит: бер юл алган юнәлеш торган саен киңәя, зуррак урын ала бара. Эш аты образы да торган саен тирәнәя, Р. Шаммас, Р. Хәкимжан, Р. Фазлый, М. Кәбиров, Р. Рысаев, Х. Мөдәрисова, К. Шәфыйкова һ. б. әдип һәм әдибәләр иҗатында урын ала бара. Тик Тукайны үзенчә күрү, заманча сурәтләүдән туган бу әсәрләр әдәби чүп-чар белән ыгы-зыгыда күмелеп калмасын иде. Аларның зиһенле үз укучысы бар: ул аны табар дип ышанасы килә.

Бу образың гел генә күңелгә ятеш булмыйча, кайчакта укучыны гарьләндерү-чәмләндерү, аның намусына тиярлек, борчыр-уйландырырлык килеп чыгуы да бар. Заман заруратына җавап йөзеннән болар икесе дә кирәк шәйләр.

Әдәбиятның үсеш мантыйгы, тормышның барышы бүген нәкъ Тукайча эш итүне таләп итә.

Башка мохиттә, башкачарак милли хисләр белән яшәүчеләр, бәлки: «Каләмдәшләр мәсьәләне куерта, шуңа сурәт тә көткәнгә караганда тонырак, дөресен әйткәндә, караңгырак килеп чыккан», – диярләр. Әмма, нишлисең, әдип-автор үз мохитендә үз халкы белән яши һәм аның тормышын-булмышын ничек күзаллый, шулай сурәтли.

Бу темага алынган һәрбер әсәрдә дип әйтерлек, монда да ат милләт кенә түгел, ат тәненең һәрбер әгъзасы (муен, кабырга), сбруйның һәрберсе (дуга, камыт, ыңгырчак) бары шул гомум контекстта гына аңлашыла: башка урында алар шигырьнең бәсен төшерүче натуралистик деталь буларак кабул ителер иде.

Ат образының халык иҗаты традицияләренә таянган толпар, акбузат мәгънәсе дә әдәби процесстан бөтенләй китәргә җыенмый, әлбәттә. Әмма Башкортстан татарының бүгенге хәләтеннән туган тарихи-әдәби хаҗәт турында сүз алып барганда, шул хәлләргә сизгер әдипләребез тудырган яңача яңгырашлы образның заманында Тукай гомумиләштереп биргән ат образына якынлыгы турында сүз кузгатып була икән, бик хуп.

Янә Башкортстан халык шагыйре Марат Кәримовның нәкъ Тукай туган көннәрдә, 2006 елның мартында дөнья күргән әсәренә игътибар итик.

Әле җитмешенче елларда ук, «алга, дибез, алга дибез, алга таба барабыз!» дип җырлап яисә «әйтмәек без Ленин булсачы» дип, нишләр идек әгәр булмаса!» дип такмаклап йөрелгән мәлләрдә үк, «Күтәрелгән Чирәм» әсәрендәге хәлләрне үзебезнең шартларга күчереп, ул «Чегән аты» шигырен язган иде.

«Булды минем Щукарь карт шикелле
Бер катлырак булган чакларым.
«Дөлдел» дидем, өреп тутырылган
Кабарынкы чегән атларын». (1976)

Дөресен әйткәндә, исемләнгән «Чегән аты» әсәре белән «Милләтебез» (2006) шигыре арасында үткән 30 ел гомерне милли-әдәби аңның айнуына сарыф ителгән дәвер дип тә атарга мөмкин булыр иде.

Милләтебез
Уңган милләт, тырыш милләт,
Тукай сүзе хак кебек:
Яу чапканда без – арыслан,
Эш дигәндә – ат кебек.
Арысланлык онытылган,
Ат эше – безнең гамәл.
Йөк тартырга җигелгәнбез,
Котылырга юк әмәл.
Кайда тимер тәртәләрне
Җимерерлек елгыр чак?
Борылырга ирек бирми
Дуга, камыт, ыңгырчак.
Ил арбасы тәгәрмәчсез,
Кучермы эчкән сатып?
Әй сөйрибез шул арбаны,
Тозлы тирләргә батып.
Сыртка камчы төшеп ала,
Муенны кыра бөят.
Бу дөньяда niләр күрми
Атка әйләнгән милләт…

Тукай әсәрендәге юлларны сүзмә-сүз дип әйтерлек кабатлаудан башланган әсәр, күренүенчә, икенче строфада ук бөек шагыйрь әсәренә «заман тудырган төзәтмәләр» кертә. Дистәләрчә башка әсәрләрдәге кебек, монда да ат гәүдәсенең һәр әгъзасына, аны җигү коралларына символик мәгънә салына.

Шулай итеп, Башкортстан татар шигърияте ун-унбиш ел эчендә олы мәгънә – тарихи-социаль символ дәрәҗәсенә ия булган эш аты образын сынландырып, аның тарихи һәм зәүкый булмышын раслады.

Ниһаять, яза-уйлана торгач, әдипләребез дә, нәкъ Тукайча

«Шул халыкныңмы җирдә яшәргә хаккы юк?
Хаклыбыз без җирдә шактый ук», –

дип әдәби мәйданга, халык аңына яңадан толпар-акбузатларын йөгәнләп, күптәнге әле уфалы шагыйрь Марат Кәбиров язганча, «өзәңгегә басар чак»ка өмет белән яши.

ӘДӘБИЯТ


1. Вәли–Барҗылы М. Тормыш дулкыннары: әдәби әсәрләрдә ничек чагыла?: [эссе, язмалар]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 287 б.
2. Кәримуллин А. Безнең кардәшлек: мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 335 б.
3. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.1. – М.; Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1936. – 631 с.
4. Татар шигърияте: XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 447 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда, т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1985. – 406 б.
6. Харисов Ә. Башҡорт халҡының әҙәби мираҫы. – Өфө: Башҡорт. кит.нәшр., 1965. – 416 б.
7. Хәкимов Р. Ат – безнең тарих ул // Кызыл таң.– 2006.– 17 июнь.

УДК 82.091

# ИСТОРИЧЕСКИЕ КОРНИ И СРЕДА, ПОВЛИЯВШИЕ НА ФОРМИРОВАНИЕ ЛИЧНОСТИ И ТВОРЧЕСТВА ТУКАЯ

***М.Р. Багаутдинов***
*Музей Габдуллы Тукая в Уральске (Уральск, Казахстан)*

В статье рассматривается проблема сохранения памяти и наследия великого татарского поэта Г. Тукая на его поэтической родине – городе Уральске. Анализируются исследования жизни и творчества Тукая конца XIX – начала XX веков краеведами г. Уральск.
**Ключевые слова:** Уральск, Мутыгулла Тухватуллин, музей, татарская перидоика.

The article deals with the problem of preserving the memory and heritage of the great Tatar poet G. Tukay in his poetic homeland – the city of Uralsk. Analyzed are the studies of the life and work of Tukai at the end of the 19th and beginning of the 20th centuries by local historians of the city of Uralsk.
**Key words:** Uralsk, Mutygulla Tukhvatullin, museum, tatar periodicals.

Дом Тухватуллиных – альбом,
Тукая жизни целый том ...
Пройдем в открытые ворота,
Слышна мелодий дальних нота.
За скрипкой тянется хазрат.
Жена – за пианино.
И дети, за сестрою брат –
Арфа, мандолина.
В семье татарской Ференц Лист.
Где видано: хазрат – артист?
Поет Камиль, поет Тукай
О светлой Гуль Джамал.
Лучился песней темный край
И слушал стар и мал.
Хазрат не только музыкант,
Владел он и пером.
Ему знаком Вольтер и Кант,
Омар – Хаямовский бином.
Хранил трактаты Аль-Хайсама,
Вникая в суть его задач.
Любил в театре мелодраму
И был к тому ж еще и врач.
Ночами мерил Млечный путь.
Его ночное бденье
Давало сдуть с невежды муть
И предсказать затменье...
Те же там перила,
Те же стояки
Время сохранило
Поэта след ноги...
(Р. Нафигов «Край весенних разливов»)

Я начинаю свою статью стихами нашего земляка Рафика Нафигова, эти строчки как нельзя лучше характеризуют ту среду, в которую попал девятилетний Апуш, приехавший декабрьским студёным вечером в 1895 года, в Уральск.

Уральск, до 1775 года Яицкий городок, по татарски – Жаек из глубины веков выплывают к нам, с обрушенных в половодье берегов Урала – Жаека, бытовые вещи живших на этом благодатном месте слияния трёх рек (Урала, Чагана, Деркула) народов: булгарские вещи вперемешку со славянскими. Сначала Булгары охраняли переправы на шёлковом пути через Жаек реку, затем племена нугаев пасли свой скот и ловили здесь рыбу, затем яицкие Казаки основали здесь свою крепость. Рядом с златоглавыми церквами стояли в Яицком городке и мечети в которой молились казаки мусульмане.

Во время своего посещения Яицкого городка в 1769 году известный российский ученый-путешественник П.С. Паллас писал: «Потом начинается в сей же улице татарская слобода, в которой живут Татары и имеют деревянную выбеленную мечеть». В 1826 году приход Белой мечети насчитывал 816 человек мужского пола. Учитывая, что Белая мечеть была тогда единственной в городе, вместе с женщинами и детьми татарское население Уральска могло в то время составлять 1700–1800 человек. Белая мечеть считалась соборной. В дни торжеств по случаю учреждения Уральской области в 1869 году, службу в мечети посетил оренбургский генерал-губернатор Крыжановский: «Генерал губернатор, выслушав литургию в Александро-Невском соборе посетил соборную мечеть г. Уральска, где при многочисленном стечении народа, между которыми было много и киргиз, читались молитвы по случаю открытия новой области». После службы, генерал-губернатор вручил ахуну уральской мечети Сапараеву серебряную медаль за усердную службу

До XIX века горд делился на две половины с одной стороны Большой Михайловской, главной улице горда, стояли церкви, а по другую мечети. Именно это и привлекало в город татарских купцов, а затем и ремесленников в наш город. Уральск стал воротами в среднюю Азию для татарских переселенцев. В канун приезда в Уральск в городе действовало две каменные мечети (Белая войсковая и Красная связанная с Тукаем и его учителем Мутыгулой Тухватуллиным) и деревянная мечети. При мечетях было три медресе, работали мектебы и русские школы для детей мусульман. При Тукае построили Новобазарную мечеть и при ней ещё одно медресе. Медресе были известны, не даром ведь сюда приехал учиться Габбулла Кариев, один из основателей профессионального татарского театра.

Много шакирдов приезжало из близлежащих городов таких как Самара, Саратова Оренбурга и других.

После разрешения селится на казачьих землях иногородцам началось переселение татар из за Казанья.

От местных татар-казаков, «иногородцы» отличались большей активностью и предприимчивостью. И это понятно, срывались с обжитых мест в поисках лучшей доли люди отчаянные и решительные. Из перенаселенного Поволжья и Заказанья в поисках лучшей доли, к уже устроившимся на новых местах родственникам, прибывали сородичи и знакомые. Вместе с людьми непрерывно текли товары, деньги, новости. В декабре 1894 года юный Габдулла Тукай прибыл из Заказанья в Уральск именно таким способом, с торговым обозом. Среди татар была развита традиция помогать неимущим родственникам, брать на воспитание осиротевших детей. Так Галиаскар Усманов, тоже выходец из Заказанья, помимо сестры Габдуллы – Газизы (младшей) приютил еще двух сирот – дальних родственников – Файрузу и Мухаметгали.

Наличие в Уральске значительной татарской общины, привело к возникновению чисто татарских, или как писали газеты «мусульманских» торговых заведений. В начале XX века для татарской публики в Уральске действовало четыре специальных татарских магазина. С конца 1905 года на Казанской площади, в здании бывшего Коммерческого клуба открылась татарская гостиница «Казань». Здесь же было устроено татарское кафе – чайхана. Обслуживание в них велось исключительно татарскими приказчиками и на татарском языке. Примечательно, что в том же 1905 году владельцы татарских торговых заведений просили власти дать им возможность торговать в православные праздники и отдыхать в мусульманские.

Уральску повезло, в сентябре 1857 года был назначен наказным атаманом Уральского казачьего войска Аркадий Дмитриевич Столыпин. (отец российского реформатора Петра Аркадьевича Столыпина) Оставил большой след в благоустройстве и реформировании городского хозяйства Уральска, устроении народного просвещения и общественных садов, один из бульваров города долгое время носил имя Столыпинского. В 1858 году Столыпиным был построен в Уральске городской театр (этот театр входит в десятку старых старейших театров СНГ), открылась библиотека, и даже музыкальная школа. В январе1859 года за отличие по службе был награждён чином генерал-майора с зачислением в Свиту Его Императорского Величества. В 1862 году, Столыпин основывает в Уральске войсковую типографию, на территории войска открывается около ста школ, издаются учебники для казаков, он посылает их учиться в Петербург и Москву.

В Уральске хранилась память о пребывании А.С. Пушкина, приехавшего в Уральск осенью 1833 года в сопровождении оренбургского чиновника, будущего автора словаря, В.И. Даля для сбора материалов к «Истории пугачёвского бунта», беседовал с казаками, знавшими Пугачёва лично. «Последнее письмо моё должна ты была получить из Оренбурга. Оттуда поехал я в Уральск – тамошний атаман и казаки приняли меня славно, дали мне два обеда, подпили за моё здоровье, наперерыв давали мне известия, в которых имел нужду, и накормили меня свежей икрой, при мне изготовленной» – из письма поэта жене.

Габдулла Тукай к 9 годам на своём коротком веку пережил многое, сиротское детство, тяжёлый крестьянский труд, в Кырлае ему приходилось наравне с приёмной семьёй трудиться в поле. И вот его снова привезли в Казань, где он в ожидании торгового каравана прожил несколько дней. Что думал он тогда? Перед ним стояла неизвестность, он уже не раз переезжал из одной семьи в другую, из дома в дом, и не всегда ему были рады. И вот дорога в неизвестность. 18 суток добирался он в Уральск, о чём он думал долгими днями запертый в кибитке, не имея возможности выйти побегать, на свежем воздухе. Впереди его ждала неизвестность ...

И вот его привели в большой двухэтажный дом, встретили приветливые люди, накормили, уложили в мягкую тёплую кровать, которая после долгой дороги в тесной кибитке показалась раем.

А утром, ему не надо было с утра пораньше идти давать корм, скотине и делать другие дела по дому.

С утра его встречают приветливые глаза его сестры Газизы, ласковый голос Тети, сытный завтрак.

С Галиаскаром абый идут в Красную мечеть на утренний намаз. Здесь его знакомят имамом мечети Мутыгулой хазратом. Который радостно приветствует сына своего друга детства. Тут же договариваются, что Габдулла будет учится в медресе «Мутыгия», у Мутыгуллы хазрата. У Тукая только одна обязанность учиться. Галиаскар видит в своём воспитаннике, будущего помощника в своих торговых, по тому отдаёт его в русскую школу, где учителем был Ахметша Серазитдинов. (Уральские татарские купцы поддерживали обучение татарских детей. Купец Муртаза Губайдуллин купил двухэтажное здание и отдал его под русскую школу, в ней и учился Г. Тукай. В местной газете русским купцам это было выставлено как пример, ведь русские школы ютились в арендованных помещениях. Муртаза также помогал содержать медресе «Мутыгия».)

Желание учиться у Габдуллы было, но до этого времени не хватало, хорошо, что научился читать и считать. А тут он учится в медресе и не простом, а в новометодном. Мутыгулла хазрат очень образованный человек, и свои знания он отдаёт своим ученикам-шакирдам. У него прекрасная библиотека и Габдулла получает доступ к разнообразной литературе, с жадностью изучает её. Кругозор юноши расширяется, он читает литературные произведения восточных авторов, в русской школе читает стихи Пушкина, Лермонтова, Кольцова и других авторов. Сын Мутыгуллы, Камиль вернувшись с учёбы в Каире, становится близким другом и наставником Габдуллы. Они вместе мечтают о Выпуске газет и журналов, и начинают выпускать рукописный журнал, который с удовольствием читают шакирды медресе.

По воспоминаниям знаменитого режисёра Кариева, близкого друга Тукая, в медресе он считался самым образованным, бойким и сметливым шакирдом. Новые веяния, предвещавшие подъем революционного движения, оказывали на него заметное влияние. При активном непосредственном участии Тукая выпускается рукописный журнал «Аль-гаср-аль-джадид» («Новый век»), в котором он публикует свои первые ученические стихи и статьи. Также он переводит басни Крылова и предлагает их к изданию.

В 1899 году в Уральске широко отмечается столетие со дня рождения А. С. Пушкина, в театре Макарова ставятся спектакли по произведениям Пушкина, в пушкинском доме проходят лекции о жизни и творчестве поэта, чтения стихов. Тукай старается не пропустить ни одного мероприятия, с жадностью впитывает в себя, творчество великого поэта.

Таким образом будущий поэт впитал в себя поэзию востока и запада, и со временем переработав их стал по-новому писать стихи, которые стали близки всем окружающим его людям. Его стихи стали доступны и учёному, и образованному человеку, и простому ремесленнику, и торговцу.

В 1900 году после смерти Г. Усманова, чтобы не быть обузой своей тёте, Габдулла переходит жить в медресе.

Здесь же Габдулла делает успешные попытки перевода с русского языка на татарский. Переводит басни Крылова (детство баснописца прошло в Яицком городке, его отец был одним из командиров гарнизона, и руководил обороной крепости, во время восстания Емельяна Пугачёва)

Камиль Тухватуллин получает возможность выпускать газету «Уралец», он становится её издателем. Камиль приглашает Тукая работать наборщиком. Наборщик – это тяжёлый труд, но Габдулла соглашается, это даёт

возможность зарабатывать деньги на жизнь, и быть не зависимым. Камиль в декабре 1905 года начинает выпускать газету «Фикер» на татарском языке, и в ней появляются статьи и стихи начинающего поэта. Затем Камиль и Тукай выпускают литературный журнал «Аль-гаср-аль-джадид», где печатаются новые произведения Габдуллы его переводы. Благодаря уральским купцам газеты и журналы начинают распространяться по всей Российской империи, и стихи Тукая становятся близкими многим читателям этих газет и журналов. К Тукаю приходит известность. Камиль и Тукай не останавливаются на достигнутом и начинают выпускать сатирический журнал «Уклар» в котором раскрывается сатирический талант Тукая.

– Перо Тукая было острым, смелым, он, не боясь, подвергал критике царившую социальную несправедливость, по этой причине «Уралец» закрыли, и тогда Камиль стал выпускать литературно-общественную газету на русском языке «Уральский дневник». Эту газету назвали одной из лучших независимых газет Российской Империи.

Бурные революционные события первой революции не прошли мимо Габдуллы. Он вместе со своим другом Гладышевым участвуют в стачках, маёвках и других революционных мероприятиях, проходящих в городе. Возможно благодаря этому революционному периоду в советское время имя Тукая и его произведения не были преданы забвению как произведения многих дореволюционных поэтов и писателей.

Весною 1906 года открывается серия молодежных вечеров в актовом зале гостиницы «Казань» (Клуб приказчиков) Тукай вместе с друзьями в числе активных организаторов и участников. Эти вечера – первые официальные культурные программы татар и казахов в Уральске. Помимо литературно-музыкальных вечеров проходят чтения и обсуждения докладов на актуальные политические и социальные темы. «Фикер», «Уральский дневник» и «Уральский листок» информируют о них читателей. «Сегодня в татарском ресторане, бывшем помещении коммерческого клуба на Казанской площади, назначается студенческая вечеринка» – 5 марта 1906 г. сообщает «Уральский листок» «В воскресенье 5 марта, студенческая вечеринка в зале татарского ресторана «Казань» прошла весьма оживленно.

Последний год Габдулла вместе, со своим другом Габдуллой Кариевым снимают номер в гостинице «Казань». Здесь же по согласию её хозяина Муртазы Губайдуллина планируется открыть учительский институт, но к сожалению, не находят средства на его открытие. Подробно о всех этих событиях я посоветовал прочитать в книге «Господин издатель», нашего земляка Рустама Вафеева.

Прогулки в Ханской роще навивают Габдулле воспоминание о Кырлае, и он пишет Свою знаменитую поэму «Шурале», и стихотворение «Пар ат».

Но демократические преобразования заканчиваются, местные власти закрывают газеты и журналы. И Тукай вынужден после 12 летнего уральского периода уехать из Уральска в Казань. Но уехал он не паре лошадей, на поезде из Уральска до Покровской слободы.

И вот приехав в наш город никому не известным сиротой, он уезжает известным всему тюркскому миру поэтом.

Уральск хранит память о своём великом воспитаннике, ведь именно та среда в которой жил и формировался юный Апуш и привела к его духовному и профессиональному росту. Это переплетение европейской и азиатской

культур, которые сформировали образ жизни города, его культуру, отложили отпечаток на творчество юного поэта.

В Уральске сохранились здания, связанные с жизнью Тукая, Дом Галиаскара Усманова – куда привезли девятилетнего сироту, Красная мечеть, Медресе «Ракыбия», в которую шакирды медресе «Мутыгия» приходили на диспуты, Русская школа, Дом Мутыгуллы Тухватуллина – учителя Тукая, Типография газеты «Уралец» в ней Габдулла постигал секреты наборщика, Коммерческий банк в котором находилась редакция Газет и журналов выпускаемых Камилем Тухватуллиным и типография «Прогресс» где на современном оборудовании печатались многотысячные тиражи. Гостиница «Казань», где последний год жил Тукай в одном номере с Габдуллой Кариевым. Здесь были написаны поэма «Шурале», стихотворение «Пар ат».

Типография долгие годы носила имя Габдуллы Тукая. Местные краеведы по крупицам собирали сведения о жизни Тукая в Уральске: Пышкин, Нафигов, Тугушев, Вафеев и другие. Р.А. Абузяро при подержке Педагогического института, а затем Гуманитарного Университета проводил международные конференции, посвящённые творчеству поэта в нашем городе.

30 октября 2001 года в городе Уральске (Республика Казахстан) был открыт памятник-бюст Тукаю (скульптор М.М. Гасимов, архитекторы С.С. Айдаров, А.М. Галеев, Р.А. Вафеев). Присваивают одной из улиц в Татарской слободе имя Габдуллы Тукая.

В августе 2006 году по инициативе председателя татарского центра Ришата Хайруллина восстановлена из руин Красная мечеть, в декабре при финансовой поддержке «Татнефти», в доме учителя Тукая, Мутыгуллы Тухватуллина, был открыт музей Поэта.

Экспозиция музея расположена в нескольких залах двухэтажного здания.

На первом этаже расположен зал посвящённый жизни современников Тукая, татар города Уральска, экспозиция зала рассказывает о жизни и быте татар конца XIX начала XX веков.

На втором этаже дома музея, в трёх залах рассказывается об учителе Тукая, М. Тухватуллине, в кабинете создана обстановка того времени.

Зал Тукая рассказывает о жизни Поэта, он состоит из трёх разделов:

– Уголок Заказанья – повествует о жизни маленького Габдуллы в Татарстане;

– Поэтическая родина Тукая – рассказывает об уральском периоде его жизни, о становлении поэта;

– Казанский период рассказывает о последних годах жизни Тукая в Казани.

Следующий зал рассказывает посетителям об имамах города, об оперной певице Г. Кайбицкой, композиторе Н. Жиганове, скульпторе Х. Шамсутдинове и других знаменитых уральцах.

В подвале готовится экспозиция, посвящённая типографии.

Дом Г. Усманова, по настоятельной просьбе председателя «Евразийского центра Г. Тукая» профессора Р.А. Абузярова и поддержке Всемирного конгресса татар, в 2014 году был капитально отремонтирован, в результате чего приобрёл вид такой, какой имел при жизни в нём юного Габдуллы. Отремонтирован памятник в Ханской роще, посвящённого маёвке, в которой в 1905 году принимал участие Тукай со своими товарищами наборщиками.

Ежегодно в день поэзии у бюста, в сквере Габдуллы Тукая, проходят торжественные чествования поэта с возложением цветов и чтением стихов, а затем в Татарском культурном центре проходит областной конкурс чтецов, на котором стихи поэта звучат не татарском, русском и казахском языках, и для участников конкурса проводятся экскурсии по музею.

Воспитанниками воскресных татарских классов ставятся пьесы о жизни поэта в Уральске, которые восторженно приветствуются зрителями.

Мы приглашаем Вас к нам на родину Камиля Мутыги, Назиба Жиганова, Галии Кайбицкой, Сары Заровой, Р.И. Нафигова. На поэтическую Родину Габдуллы Тукая.

УДК 821.512.145

## ГАБДРАШИТ ИБРАГИМ И ТУКАЙ

***Ф.А. Байрамова*** *(Набережные Челны)*

В статье дается информация об отношении Тукая к деятельности Габдерашита Ибрагимова. Автор статьи дает объективную оценку памфлетам Тукая, описывает некоторые аспекты жизненного пути и общественно-национальной деятельности Габдерашита Ибрагимова.
**Ключевые слова:** Тукай, Габдерашит Ибрагимов, татары, памфлет.

The article provides information about Tukai's attitude to the activities of Gabderashit Ibragimov. The author of the article gives an objective assessment of Tukai's pamphlets, describes some aspects of the life path and socio-national activities of Gabderashit Ibragimov.
**Key words:** Tukay, Gabderashit Ibragimov, Tatars, pamphlet.

## ГАБДРӘШИТ ИБРАҺИМ ҺӘМ ТУКАЙ

***Ф.Ә. Бәйрәмова*** *(Яр Чаллы)*

Габдрәшит Ибраһим Тукайдан утыз яшькә өлкәнрәк булган. Тормышта алар очрашканмы-юкмы – монысы билгеле түгел, әмма очрашкан булулары да бар. 1904 елның ахырында һәм 1905 елның башларында Габдрәшит Ибраһим, Рәсәй мөселманнары корылтае уздыру нияте белән, Идел-Урал, Себер шәһәрләрен гизеп чыга, аның Җаекта (Уральск) булуы һәм Мотыйгулла хәзрәтләр даирәсендә Тукай белән дә очрашуы мөмкин. Габдрәшит Ибраһимов шулай ук 1908 елда Казанда була, монда да аның Тукай белән очрашуы ихтимал. Әмма алар бер-берсен матбугат аша яхшы беләннәр, бигрәк тә Габдулла Тукай Рәшит казыйның һәр адымын диярлек күзәтеп барган һәм аның гамәлләренә төртмәле шигырь-памфлетлары белән җавап биргән. Тукайның матбугат битләре аша Габдрәшит Ибраһимга биргән бәясе тискәре, әмма иҗатының башында яшь Тукай Рәшит казыйга һәм ул Петербургта чыгара башлаган «Өлфәт» газетасына уңай бәя биргән бит!

Рөшеде вар, кауле гүзәл, наме Рәшид;
Җөмлә бу иршад илә улсын рәшид!
Шатлык илә итәлийез өлфәт илә «Өлфәт»и:
– Тәрк идәлем иддигани һәм тәкәллеф-көлфәти! –

дип яза ул «Фикер» газетасының 1906 ел, 1 гыйнвар санында. (Бу шигырь «Тукайга нисбәт ителгән өйрәнчек шигырьләр» кушымтасында Ту-

кай томнарына кертелгән. Кара: Габдулла Тукай. 1 том. – Казан, 1985, 319 бит.)

Шигырьнең бүгенге татар теленә тәрҗемәсе болай яңгырый:

> Зиһене бар, сүзе гүзәл, исеме Рәшит,
> Шундый җитәкчене һәркемгә җитәкче ит!
> Бик куанып, «Өлфәт» беләи без дусларча сүз ачыйк;
> – Дошманлык, тәкәллеф ише кимчелекләрне ташлыйк!

Искәрмәләрдән күренгәнчә, «Шигырьдән алда: «Декабрьнең 22 көнендә Петербургта фазыйль Рәшид әфәнденең «Өлфәт» наменда улан гәзитәсенең икенче номеры чыкты. Мөндәриҗате гүзәл вә фасих үзрә язылмыштыр», – дигән сүзләр бар», диелгән. Ягъни, Тукай Рәшит хәзрәтне галим кеше дип бәяли, ул чыгарган «Өлфәт» газетасын «гүзәл эчтәлекле, матур тел белән язылган» дип хәбәр итә.

Әмма алга таба Тукайның Габдрәшит Ибраһимга да, ул чыгарган газета-журналларга да фикере кискен рәвештә кирегә үзгәрә, Рәшит казый Тукай иҗатында көлү объектына әйләнә. Моны Тукайның яшьлеге-максималистлыгы белән дә, аның янында, бигрәк тә, Казанда, сул фикерле дусларының шактый булуы белән дә аңлатырга була. Шулай ук Габдрәшит Ибраһимов үзе дә татар кысаларына сыймаган шәхесе һәм Казан күзлегеннән караганда гайре табигый булып күренгән адымнары белән моңа сәбәпче булгандыр...

> Бер заманнарда Рәшидкә «габде милләт» нам виреб,
> Хәзер инде «габде корсак»ка төшергән дөньядыр, –

дип яза Тукай, «Шүрәле» измзасы белән, «Уклар» журналының 1906 елгы 5 (октябрь) санында, «Дөнья бу, йа!» шигырендә. Ел башында гына Рәшит казыйны «зиһенле, гүзәл сүзле», дип атаган Тукай ел ахырында аны «корсак колы» дип атый. Ягъни, заманында «милләт колы» исемен йөрткән Габдрәшит Ибраһимовны Тукай уенча, дөнья шушы түбәнлеккә төшергән икән... Мәккә-Мәдинәләрдә укып, Коръән-хафиз булып чыккан, туган шәһәре Тарада мәчет-мәдрәсәләр тоткан, имамлык иткән, Уфа Диния нәзарәтендә бөтен Россия мөселманнарының баш казые булган, вакыт-вакыты белән мөфтине дә алыштырган, инде бу вакытта ярты дөньяны әйләнгән, Төркия-Мысырларда татарларны яклап брошюра-китаплар чыгарган, Петербургта татарча газеталар чыгара башлаган, империядә таралып яшәгән мөселманнарның беренче корылтайларын уздыруга ирешкән, инде сакалы агарган, яше алтмышка җиткән Габдрәшит Ибраһимов турында бик ямьсез һәм урынсыз бәя бит бу! Ни өчен Тукай мондый фикергә килгән соң? Хәзер шул заманнарга күз салып алыйк...

Билгеле булганча, 1906 елда «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең съездлары булып үтә, аларны уздырырга рөхсәт алу өчен Габдрәшит Ибраһимов Россия эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була, ул шулай ук урыс либераль партияләре белән дә элемтәгә керә. Эчке эшләр министрына язган хатында ул мөселманнарның социалистларга һәм анархистларга каршы көрәшергә берләшергә тиешлеген әйтә, һәм шушы сүзләре өчен «сулчы» татарлар тарафыннан каты тәнкыйтькә дучар була. Гаяз Исхакый «Иттифак» партиясенең август аенда булган соңгы корылтаенда үзе дә катнаша, алар сулчы яшьләр белән анда тавыш чыгаралар, мөселманнар корылтаен өзәргә тырышалар, аны булдыра алмагач, ташлап чыгып китәләр. Һәм Гаяз Исхакый 1906 елның август (икенче өлеше) һәм сентябрь айларында

Гаяз Исхакый, «Чыңгыз» һәм «Кодаң Биктимер» имзалары астында, «Таң йолдызы» газетасында Габдрәшит Ибраһимовның абруен төшерә торган мәкаләр белән чыгыш ясый. Ул бу мәкаләләрендә Рәшит казыйны милләт акчасын үзләштерүче, дип тә, карагруһчылар белән эш йөртүче, дип тә атый, татар эшчеләрен урыс эшчеләреннән аерырга тырышканы өчен дә, социалистларга каршы сөйләгәне өчен дә гаепли... «...Ул сатучы да, ул язучы да, ул өшкерүче дә, ул төкерүче дә, ул бетерүче дә, ул динле дә, ул динсез дә, гакыллы да, тиле дә, ул телле дә, телсез дә», дип яза [4: 99].

Әлбәттә, Тукай боларның барысын да укыган, мөгаен, күбесенә ышангандыр, чөнки яшьләр күп вакыт яшьләр ягында булалар, Тукайда сулчылык идеяләре дә шактый көчле була. Шушы хәлләрдән соң Габдрәшит Ибраһимов Тукайның да, Гаяз Исхакыйның да көлү, түбәнәйтү, тәнкыйтьләү объектына әйләнә, һәм бу гомер буе дәвам итә. Ул гына да түгел, Габдрәшит Ибраһимовка карата бу мыскыллы бәя Тукай һәм Исхакый иҗатын өйрәнүче галимнәргә дә күчә, алар да Рәшит казыйга остазлары күзлегеннән чыгып бәя бирә башлыйлар... Кызганычка каршы, Габдрәшит Ибраһимовка карата Тукай һәм Исхакыйлар сугып калдырган мыскыллы тамга әле бүген дә дәвам итә... Тукай һәи Исхакый томлыкларын әзерлүчеләр искәрмәләрдә Габдрәшит Ибраһимовны «милләт исеме белән капланып, буржуазия мәнфәгатен яклап килүче», «татар либераль буржуа идеологы», дип тамгалап, аны мәсләксезлектә гаепләп, ул чыгарган газеталарны «дини-клирикаль» дип бәяләделәр.

Инде тагы Тукай чорына кайтыйк. «Яшен»нең 1909 ел, 8 нче (29 апрель) санында Тукайның «Дәүре галәм» дип аталган икеюллык шигыре басылып чыга, ул анда Йосыф Акчура һәм Габдрәшит Ибраһимнан көлә:

> Йосыф китте сәяхәткә, Рәшит икенчеләп китте,
> Рәшитнең сурәтендә бер дегет тулган чиләк китте, –

дип яза Тукай. Искәрмәдән күренгәнчә, «Шигырь Й.Акчураның Фәләстыйнга (Палестинага), Г. Ибраһимовның Япониягә сәяхәткә китүе уңае белән язылган» [6: 347]. Әйе, нәкъ шул чорда Габдрәшит Ибраһимның Себер, Маньчжурия, Япония, соңрак Корея, Кытай, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Һиндстан, гарәп илләре буйлап сәяхәте башлана һәм ул язмаларын «Дәүре галәм» (Дөнья тирәли») исеме астында Казанда чыга торган «Бәянелхак» газетасында бастырып бара. 1909 елда «Дәүре галәм» Казанда аерым китап булып та басыылып чыга. Бу хезмәт 1910 елда «Галәме ислам» исеме астында Истанбулда басылып чыга һәм бүгенге көнгә кадәр Азия илләрендә, Төркиядә, Японидә иң күп укылган һәм файдаланылган китап булып тора, чөнки XX гасыр башында дөньяда ислам диненең торышын шушы хезмәттән өйрәнергә мөмкин. Бүгенге көндә Төркиядә, Японияда Габдрәшит Ибраһимның тормышы һәм эшчәнлеге буенча халыкара фәнни конференцияләр уздырыла, аның хезмәтләрен төрек, япон, алман, гарәп, фарсы, кытай, корея галимнәре өйрәнә, соңгы вакытта татар тарихчылары да бу бөек милләттәшебез шәхесенә игътибар итә башладылар.

Шунысын да әйтергә кирәк: Габдрәшит Ибраһимовның Япониягә бу инде беренче генә сәяхәте булмый, ул биредә инде 1902, 1906 елларда булган була. Бу юлы Рәшит казый кояш чыгышы илендә берничә ай яши, шактый гына шәһәр һәм авылларда була, халык тормышы белән таныша, аларга Россия мөселманнарының хәле турында сөйли. Габдрәшит Ибраһи-

мов шулай ук бу килүендә Япониядә зур дәрәҗәдәге хөкүмәт кешеләре, министрлар, милли сәясәтчеләр, япон зыялылары белән таныша, алар «Бөек Азиячелек» идеясе тирәсендә берләшәләр. Япония хөкүмәте Габдрәшит Ибраһимовка зур хөрмәт һәм ышаныч күрсәтә, аны Россиянең мөселманнар башлыгы, татар президенты, итеп кабул итәләр. Рәшит казый шулай ук японнарга хак ислам турында аңлата, аның тәкъдиме белән 1909 елда Япониядә беренче ислам җәмгыяте төзелә, Токиода мәчет салу мәсьәләсе күтәрелә, японнар моңа рөхсәт бирәләр, әмма ул Габдрәшит Ибраһимов Япониягә соңгы тапкыр килүендә генә салына һәм 1938 елда ачыла, Рәшит казый аның беренче имамы була. Аның тырышлыгы һәм тәкъдиме белән, 1939 елда ислам дине Япониядә рәсми дин буларак игълан ителә, мәктәп дәреслекләренә төрки-татар тарихы кертелә.

Габдрәшит Ибраһимов менә шундый дөньякүләм миссияләр белән йөргәндә, Тукай аны Казанда һаман тынычлыкта калдырмый. 1910 елның 2 нче (1 апрель) санында аның «Ялт-йолт» журналында «Шүрәле» имзасы белән түбәндәге шигырь юллары басылып чыга:

Ала карга, кара козгын әрсезләнә, тук була;
Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит – мәчет Токиода, –

дип яза ул. Һинди дигәне – Сарытау төбәгендә Һиндстандагы кебек университет салдырам, дип хыялланып йөрүче татар булса, Габдрәшит Ибраһимов – Япониядә мәчет салдырырга йөри... Әлбәттә, Тукай мондыйлардан кәһкәһә белән көлә, ул үз милләтең өчен эшләүне өстен куя, калганнарын буш хыялга саный. Әмма Габдрәшит Ибраһимовка килгәндә, ул инде алтмыш яшенә кадәр үз милләте өчен эшлисен эшләгән – имам да булган, казый да булган, газеталар да чыгарган, китаплар да язган, милли партияләр дә төзегән, дәүләтчелек турында хыялланган... Берничә тапкыр төрмәләрдә утырган, бу юлы да патша хөкүмәтенең үзен кулга алырга дигән хөкем карарыннан соң, 1908 елда илдән чыгып качарга мәҗбүр булган. Һәм Габдрәшит Ибраһимов Төркиядә дә, Япониядә дә юкка чыкмаган, бер кулына – ислам байрагын, икенче кулына – татар тарихын тотып, дөнья гизгән, китаплар язган, ислам динен дәгъвәт иткән, әсирлектә калган Россия мөселманнарын, татарларны яклап, дөнья парламентларына, чит илләрнең президентларына мөрәҗәгать иткән...

Инде тагы Тукайлар чорына кайтыйк... Менә Тукайның «Төрле хайваннар тугрысында бераз мәгълүмат («Хәятел хайваннан»)» памфлет-язмасы, ул «Хәятел хайван»нан күчерүче» имзасы белән «Яшен»нең 1908 елгы 4 нче (5 ноябрь) санында басылган. Тукай монда кайбер хайваннар белән билгеле шәхесләр арасында охшашлык табып, параллель уздыра, әлбәттә, Габдрәшит Ибраһим да читтә калмый.

«ГЫЙБРАҺИМ. – Бу хайван, йорт хайваны булса да, күчмә мәгыйшәтне сөя торган бер хайвандыр, – дип яза Тукай. – Шөйлә ки: ул бүген Петербургта, иртәгә Сибириядә, берсекөнгә Истанбулда яки Казан вә Уфада буладыр. Үзе җуаш вә «өлфәт»ле хайван булып, кешеләр вә галәлхосус байлар кулына ияләшүчән буладыр.

Башлыча тереклек итә торган ашы «мәсләксезлек» нам бер «яшел» үләндер. Рәсеме беренче номер «Яшен»дә дәреҗ ителмеш» [7: 74–75].

Китапның «Искәрмә һәм аңлатмалар» өлешендә Тукайның бу язмасына түбәндәге аңлатма бирелгән:

«Гыйбраһим – Габдрәшит Ибраһимов (1853–1944), татар либераль буржуа идеологы, публицист, Октябрьдән соң эмигрант; «өлфәтле» – Габдрәшит Ибраһимов чыгарган «Өлфәт» («Бердәмлек») газетасына ишарә; ... «яшел» үләннәр – Монда мөселманлык байрагы – яшел төстәге әләм (Коръән тышы да яшел) күздә тотыла; 75 бит. Рәсеме... дәреҗ ителмеш иде. – «Яшен»нең 1908 ел 1 нче (3 август) саны 8 нче битендә киртәгә кунган карчыга гәүдәле, ак чалмалы Габдрәшит Ибраһимовныкына охшаш башлы кош карикатурасы бар. Астына «Капитал ахутнигы «Гыйбраһим кошы» дип язылган» [7: 303–304].

Бу искәрмәдә Габдрәшит Ибраһимовның туган елы дөрес күрсәтелмәгән, ул 1857 елның 23 апрелендә, Тара шәһәрендә туган, бу хакта Рәшит казый үзенең «Тәрҗемәи хәлем» китабында хәбәр итә (Ибраһим Г. Тәрҗемәи хәлем яки башыма килгән хәлләр. – СПб. 1907). Шулай ук «Өлфәт» сүзе дә бердәмлек дип түгел, дуслык, дип тәрҗемә ителә. Тукай томлыкларын әзерләүчеләрнең Габдрәшит Ибраһимовның тәрҗемәи хәлен белмәүләре, хезмәтләрен укымаганнары күренеп тора. Тукай томлыкларында Рәшит казый турында тагы берничә төртмәле бәя очратырга мөмкин, әйтик, «Гаҗәп талантлар» язмасында Тукай «Рәшит казыйның үз-үзен мактарга» гадәттән тыш сәләтле булуын яза [7: 107]. «Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк» язмасында «Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе ишетмәгән-күрмәгән эшләрен ялганлап язмый иде. Икенчесе Рәшит казый иде», дип хәбәр итә [7: 198]. Әмма Тукай биргән бу бәяләр Габдрәшит Ибраһимовның холкына бөтенләй туры килми, ул шактый мавыгучан, зур идеяләр белән янып йөрүче кеше булса да, аны мактанчылыкта һәм ялганчылыкта беркем дә гаепләми, тарихта андый язмалар юк, мөселман кешесе андый була да алмый...

Шунысын да онытмыйк: 1907–1908 еллар Габдрәшит Ибраһимов өчен авыр еллар була – патша хөкүмәте аның Петербургта чыга торган газеталарын яптыра, үзен, «Мең дә бер хәдис шәрехе» китабы өчен, 1907 елда бер елга крепостька ябарга хөкем итәләр. Рәшит казый Петербургтан чыгып качарга һәм ил буйлап яшеренеп йөрергә мәҗбүр була. Һәм шушындый авыр вакытта «үз татарларымыз» аны матбугат битләрендә тәгәрәтеп талый башлыйлар... Ул чордагы татар матбугаты битләрендә Габдрәшит Ибраһимов турынданиләр генә юк, бу үзе үк Казанның Печән базарындагы «Көфер почмагы»н хәтерләтә башлый! Һәм әле шушылардан соң да бәгъзе бәндәләр Рәшит казыйдан милләткә мәхәббәт таләп итәләр! Һәм әле шушылардан соң да Габдрәшит Ибраһим милләткә хезмәт итәргә үзендә көч таба! Рәшит казый матбугатта үзен пычратучыларга җавап мәкаләләре язмый, һәрхәлдә, безгә очрамады, ул аларга үзенең тау-тау хезмәтләре, гомеренең ахырына кадәр милләткә һәм дингә хезмәт итүе белән җавап бирә...

Тукай һәм Исхакыйларның Габдрәшит Ибраһимовка карата матбугат битләрендә бу һөҗүмнәрен шәхси көрәшкә һәм карашка гына кайтарып калдырырга ярамый. Бу – XX гасыр башында милли хисләр белән сугарылган татар яшьләренең, татар зыялыларының милләтнең алга китүенә зыянлы, дип санаган күренешләр белән көрәш чагылышы да ул, үзләренчә, искелек белән көрәш. Искелек билгесе итеп алар динне күргән, ә татарлар арасында диннең иң билгеле шәхесе ул вакытта Габдрәшит Ибраһимов булган. Һәм үзе дә яңалыкка каршы булмаган, җәдитчелекне хуплап каршы алган, сәясәт белән нык кызыксынган, Россиядә беренче милли-дини «Иттифак» партиясен төзегән, беренче татарча газеталар чыгарган милли җанлы татар, шул

ук вакытта намазын да калдырмаган, дөнья дип динен ташламаган, иманлы мөселман, зур шәхес! Ул гомер буе татар халкын бәйсез, үз дәүләтле итү турында хыялланган, шуның өчен көрәшкән, Евразия туфраклары өстендә ислам байрагын күтәргән... Казан татары күзлегеннән караганда, ул бәлки хыялый бер дәрвиш, утопияче булып та күренергә мөмкин, әмма вакыт Габдрәшит Ибраһимовның хаклыгын раслады, татар милләте – бәйсез булганда, Евразия халыклары ислам байрагы астында туплансалар гына исән калырга мөмкиннәр...

Габдрәшит Ибраһим да, Габдулла Тукай да ятим булганнар, күкрәкләре белән замананың бозлы диварларын ватып, үз максатларына барганнар, милләткә хезмәт иткәннәр. Тукай Казанга омтылган һәм 26 яшендә шунда янып бетеп, җир куенына кереп яткан, Габдрәшит Ибраһим кояш чыгышына таба ашкынган, Тукайдан соң да әле утыз ел яшәп, 1944 елның көзендә Токиода мәңгегә күзләрен йомган... Алар безгә икесе дә кадерле, икесенең дә хезмәтләре милләтнең алтын хәзинәсе булып тора, кешелек дөньясына хезмәт итә...

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһим Габдерәшит. Фәнни-биографик җыентык. – Казан, 2011.
2. Ибраһим Габдерәшит. Бөгрәдәлек көндәлеге. – Казан, 2013.
3. Ибраһимов Габдеррәшит. Дәүре галәм (Дөнья тирәли). Тәрҗемәи хәлем. – Казан, 2001.
4. Исхакый Гаяз. Әсәрләр. 15 томда. 6 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 203 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1903–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.
6. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 2 т: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). Җырлар дәфтәре. Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 400 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 4 т: Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.


УДК 811.512.1

## ТЕОРИЯ ТЮРКО-ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА: ТВОРЧЕСТВО ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ (ТЕЗИСЫ)

***И.Б. Баширова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В конце XIX – начале XX века татарский литературный язык функционировал в трех вариантах. В зависимости от адресата и содержания текстов, одни и те же писатели-просветители оформляли свои произведения: а) традиционным старотатарским с преобладанием арабо-персидских заимствований; б) традиционным старотатарским с преобладанием огузо-турецких слов и словоформ; в) традиционным старотатарским близким к татарскому разговорному языку. Все классики татарского народа, в том числе и Г. Тукай, в теоретическом плане резко отрицали традиционный тюрки, хотя в практическом плане, на начальном этапе творчества, все они, по-своему обновляя традицию, подражали и старотатарскому, и новоосманскому тюрки; они не писали на турецком языке, как утверждают некоторые наши ученые.
**Ключевые слова**: история татарского литературного языка, варианты письменного языка, арабо-персидские и огузо-турецкие заимствования, разговорный язык.

In late nineteenth – early twentieth century, the Tatar literary language functioned in three versions. Depending on the recipient and the content of the texts, the same writers filled their works with: a) the traditional Old Tatar with a predominance of Arab-Persian borrowings; b) the traditional Old Tatar with a predominance of Oguz and Turkish

words and phrases; c) the Old Tatar close to the spoken language. All the classics of the Tatar people, including G. Tukay, in theory rejected the traditional Turki, but in practical terms, at the initial stage of their writing, continued the tradition of writing in the Old Tatar Turki. This article analyzes the first (published 1905–1907.) works of G. Tukay that were written in the Old Tatar language version with a predominance of Arab-Persian borrowings, rather than the Turkish language as some of our scientists claim.
**Keywords:** history of the Tatar literary language, variants of the written language, Arabic-Persian and Oghuz-Turkish borrowings, spoken language.

## ТӨРКИ-ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ НӘЗАРИЯТЕ: ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ (ТЕЗИСЛАР)

***И.Б. Бәширова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Хәзерге тюркологиядә төрки телләрнең әдәби теле нәзарияте/теоретик нигезе дигәндә, язма телнең табигатен һәм вазифасын барлыкка китерә торган билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше күздә тотыла. Бу хакта танылган тюрколог Э.Р. Тенишев болай дип белдерә: «Әдәби тел тарихы белән шөгельләнгәндә, әдәби телнең табигатенә хас булган төп үзенчәлекләрен күрә белергә кирәк:1)ул билгеле бер дәрәҗәдә эшкәртелгән, шомартылган була, 2) функциональ-стилистик вариантлылыкка ия, 3) норма вариантлылыгына ия, 4) диалеклардан өстен һәм 5) традициясен-дәвамчанлыган саклый» [11: 72–73].

Татар халкының бөек шагыйреГабдулла Тукай иҗат итә башлаган XX гасырның бишенче елларында, төрки-татар әдәби теленең ун гасырдан артык үсш-үзгәреш традициясе булуы мәгълүм. Әлеге тарих, гомумтөрки гаилә кочагында, VI–VIII гасырларда рун язуларыннан башланып, IX–XI дәверләрдә, төркиләр ислам дине кабул иткәннән соң, гарәп графикасына күчеп, XII–XIII йөзләрдә Болгар дәүләтендә, XIII–XIV гасырда Алтын Урдада, XV–XVI йөзнең беренче яртысына кадәр Казан ханлыгында дәвам итеlә, аннан соң инде Мәскәү/Русия дәүләтенең Урта Идел буендагы төрки-татарларның теле буларак, эзлекле рәвештәкулланылышта була.

Әдипләр үзләренең иҗатларында, язма традицияне саклаганы хәлдә, һәр дәүләттә көн күрүче җирле халыкның җанлы сөйләмә/диалекталь үзенчәлекләре белән баета, эшкәртә, шомартабаралар: әдәби тел аерым төбәктә яшәүчеләрнең барысына да аңлаешлы, диалектлардан өстен булган хәлгә китерелә.Бу юнәлештә, төрки тел төшенчәсе, аерым төбәктә яшәүчеләрнең исеме-атамасын кабул итеп тәгаенләнә: Болгар төрки тел, Алтын Урда/Җучи Олысы төрки-кыпчак теле, Казан төрки-кыпчак – иске татар теле, Русия дәүләтендәге Урта Идел буендагы классик татар теле. XX гасыр башында, «Русия төркиләре»дигән төшенчә / атама рәсмиләштерелә [10: 21–232].

Дәверләр буена әдәбиләштерелүнең эзлекле баруы, хәрәкәттә булуы нәтиҗәсендә, үзенчәлекле язма норма ныгытыла: а) гарәп-фарсы алынмалары үз әлифбасы белән, катгый рәвештә үз чыганак теленең кагыйдәләре таләбенчә языла; ә) төрки-татар теленең сүзләре, билгеле бер дәрәҗәдә тотрыкланган, иске имля нигезендә дәвам итеlә. Аларның үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте язма телдәге вариантлылык күренешен барлыкка китерә. Татар сөйләмендәге 10 сузык авазны, гарәп теленең 3 шәкеле белән күрсәтергә, бер төрле генә әйтелә һәм языла торган бер тартык авазны, гарәп теленең 3–4 формасында язарга кирәк була һ.б.

Төрки-татар телендә, иҗтимагый тормышны алып бару өчен кирәк булу максатына ярашып, әдәбиязма телнең аерым сөйләм төрләретотрыклана, аң тарафыннан кабул ителә,функциональ стильләре дип яшәеш ала. Үзенә хас булган төрле жанрлары белән Рухани-диниәдәбият стиле дәвам ителә. Поэзия һәм проза жанрлары белән хәрәкәттә булган Сәнгати-матур әдәбият стиленең драма жанры, Иҗтимагый публицистика стиленең газета теле дигән үзенчәлеклежанрлары гамәлгә куела. Фәнни әдәбият стиле яңа тармаклары белән баетыла. Дәүләти-хокукый эш кәгазьләре, Эпистоляр-хатлар стиле, Көндәлек-һөнәри әдәбият стиле чор таләпләренә җавап бирү юнәлешендә яңара бара [3: 10–25]. Бу жанр/стильләрен яшәтә торган әдәби тел, адресатның кем булуына карап, өч төрле: а) гарәп-фарсы алынмалары, ә) угызтөрек алынмалары мул файдаланыла торган аристократ/абруйлы, б) татар халкының җанлы сөйләменә нигезләнгән халыкчан/гавами норма вариантла ры белән кулланылышта була. Менә шушы вакытта, татар халкының даһи шагыйре Габдулла Тукай беренче шигырьләрен яза башлый. Шагыйрь иҗа тына нисбәтән языла торган хезмәтләрдә, Г. Тукай – татар әдәби теленә нигез салучы / основоположник татарского литературный языка, дигән фикернең кабатлануы мәгълүм. Әмма «Габдулла Тукай. Энциклопедия» хезмәтендә, Г. Тукай иҗатының татар язма әдәби теле белемемәсьәләләре белән бәйләнеш-мөнәсәбәте, аерым тематик юнәлеш буларак күтәрелеп бирелми [16: 6–8]. XIX гасыр ахыры XX йөз башында беренче әсәрен яза башлаган классикларыбызның барысының да, шул исәптән, Габдулла Тукайның да, гарәп графикасы белән иске татар телендә иҗат итүләре мәгълүм. Без аларның әсәрләрен хәзерге татар әдәби теленә, кириллицага күчереп укыйбыз. Бу юнәлештә, катлаулы мәсьәләләрне аңларга һәм аңлатырга кирәк булуы күренә. Җөмләдән берсе – классик әдипләрнең иҗатына **татар язма әдәби теле тарихының бер дәвере итеп карау зарурлыгы**. Г. Тукайның күп кырлы, катлаулы иҗатын, татар әдәби язма теле тарихының бер буыны буларак тикшергәндә, үзенә кадәр салынган нигезнең мөһимлеген аңлап, аны камилләштерүче булуы аңлашыла. Габдулла Тукайның даһилы гы, мең еллар буена дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигатен һәм вазифасын зиһенгә алып, аны инкарь итмичә, бәлки тулаем мөмкинлеген файдалануы уңаенда, төрки-татар әдәби телен, аңа кадәр күрелмәгән югары дәрәҗәдә, үзенчә үстерә/яңарта белүендә чагыла. Әлеге эшчәнлекнең, татар әдәби телен өйрәнгәндә кабул ителгән тәртипне саклап, иске татар теленең язма төрләрендә ничек баруына кыскача (тезислар) рәвешендә тукталабыз.

1) Иске татар телнең гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланыла торган аристократ/ абруйлы юнәлешенең яңартылып дәвам ителүе. 1905 елда, Тукайның «Әлгасрел-җәдид»журналының чыгасы белдерелгән программада, «Голүмең бакчасында...»дигән шигыре басыла: Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран, / Сәгадәт бәхтемезгә калсын инсе, җинниләр хәйран, / Татар рифгате, шаны сикез кат күкләрә китсен / Әбәд-сәрмәт бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен, / Борынгы уйкуларны дөшенүбән улалым надим / Тәрәкъкый вә Тәгали йулларына улалым надим. ... Гыйлемле, белемле булыйк, Ходаем татарларны мәңге сәгадәт-бәхетле итсен, дөньяда болгарларның барлыгына ышандырыйк, төрле журналлар күбәйсен, милләтнең яшь каһарманнары кулында каләм булсын, йоклап ятмыйк, мәгариф мәйданында ат уйнатыйк... Шушы ук тема «Шәкерт, яхуд бер Тәсадеф», «И каләм!», «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел», «Пушкинә», «Гәзитә

мөрәттиб ләренә», «Хөрриятә» һ.б.шигырьләрендә дәвам ителә [14: 24–139]. Гыйлемгә-белемгә омтылу фикеренең бөеклеге, XI–XII гасырдан («Котадгу Билек», «Кыйссаи Йосыф»тан) башланып, болгар төркисе –төрки-кыпчак – иске татар телендә язылган дәверләр буена тасвир ителә килеп, XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең беренче яртысында,татар халкының талантлы фикер иясе – шагыйрьләре булган, Г. Утыз-Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б. иҗатында, иҗтимагый тормыш шартлары таләбенә җавап бирү юнәлешендә, тагын да югары күтәрелә. Әлеге авторлар үзләренең әсәрләрен,гомумтөрки нигезне саклаган хәлдә, укымышлы кешеләргә багышлап, алар аңлый торган гарәп вә фарсы алынмаларын мул кулланып, аристократ-абруйлы төрки тел белән иҗат итәләр. Яшь Тукай да, Аллаһы Тәгалә, Коръәни Кәрим сүзләре белән куәтләнеп, гыйлем-мәгърифәтле, затлы – зыялы булып, милләткә хезмәт итүнең зарурлыгы тасвирлана торган шигырьләр, нәкъ шул әсәрләрнең теле кебек язылырга тиеш дип аңлый һәм шулай яза. Димәк, Г. Тукай, әлеге нисбәттән ниндидер яңалык ача дип әйтә алмыйбыз, дәверләр буена гамәлгә куелып тормышка ашырыла торган язма ысул дәвам ителә. Бу юнәлештә, дини-рухани яшәеш белән бәйле һәм традиция буларак килә торган, Алла, Коръән, Фәрештә, Пәйгамбәр һ.б. төшенчәләр файдаланыла. Алла төшенчәсенең, Аллаһи, Илаһ, Хәкъ-Хак, Мәүла, Мәгъбуд, Раббе, Тәңре, Хода/Ходай, Хәзрәт, Шәкүр, Гафур һ.б. Әсмаи-Хөснә/Исме-Әгъзам күркәм исемнәре кулланыла. Аларның һәрберсе сүзмәгънә һәм грамматик чолганышында, сүз җаена туры китерелеп, сүз, сүзформа, сүзтезмә буларак,-берничә мәртәбә, мәсәлән, Аллаһы атамасы – 55 (15: 48–49), Ходай – 66 (15: 286–287), Тәңре – 45 (15: 176–177), Илаһ – 7 (15: 7), Мәүлә – 7 (15: 21), Раб/Раббасы – 4 (15: 91) һ.б. мәртәбә кабатланып бирелә.

Сүзлектә теркәлгәнчәкараганда, бу төшенчәләр дин тәгълиматына бәйле булган төп мәгънәләре белән аңлашыла. Авторның шигъри әсәрләрендә дә әлеге атамалар үзләренең асыл мәгънәләрен саклый, әмма иҗтимагый тормышта бара торган вакыйга-хәлләргә, авторның мөнәсәбәте нинди булуга һәм аның ничек итеп белдерелүенә карап, сүзмәгънә эчтәлегенең яңартылуы күренә. Лексик-семантик мәгънә эчтәлегендәге яңарышы дигәндә, традиция буларак килә торган төшенчә/атамаларда: а) мәгънәнең нигезе саклануы; ә) төрлесүзләрбелән грамматикчолганышындатөп мәгънәнең яңа төсмер алып киңәйтелүе; б)шәхси хис-кичерешләргә бәйле хәлдәге мөнәсәбәт чагылышында, сүзмәгънә эчтәлеге үзенең капма-каршысына әверелүе истә тотыла. Әлеге яңарыш нәтиҗәсендә, ягъни сүзләрнең лексик-семантик вариантлылыгы кебек катлаулы күренеше хасил булуын, ГабдуллаТукайның корама телдә язылган, халыкка аңлашылмый дип, кире кагыла торган беренче шигырьләрендә үк урын алуын ассызыкларга мөмкин. Мәкаләнең күләме белән чикләнеп, мисал өчен, аерым бер «Алла гыйшкына» («Алла яратсын өчен») шигыре алына. 10 икеюллыгында, 18 мәртәбә кабатлана торган әлеге сүзтезмә: Бар һөнәремезгә канигъ улмыйк Алла гыйшкына / Тәңренең лотфенә манигъ улмыйк Алла гыйшкына, – дигән соңгы юлында, Тәңре сүзе белән чиратлаштырыла, мәрхәмәтнә каршы килмик дип, традиция нигез мәгънәсен саклап кулланыла. Калган барлык очракларда: Алла яратсын өчен, дус булыйк, милләтнең күңелен аңа юнәлтик, омтылыйк, шул юлда тырышыйк, гайрәт итик, наданлык безне измәсен, гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын, дөньяны хәйран калдырыйк, милләтне күтәрергә күңелем ашыга, ашкына, мәгърифәт, һөнәр тусын, дус

булыйк, и Мөхәммәт өммәте дип, мөрәҗәгать итеlә. «Алла яратсын өчен Тәңре мәрхәмәтенә каршы килмик» дигәндә, дини нигез сакланганы хәлдә, милләт, аң-акыл, гыйлем, мәгариф юлында тырышыйк дип, дөньяви сүзләр белән грамматик бәйләнеш-мөнәсәбәтендә, төп мәгънәнең эчтәлеге киңәйтелә. Нәтиҗәдә, аерым бер Аллаһы төшенчәсе нең төрле лексик-семантик вариантлары хасил була, язма әдәби тел берәмлегенең саны арта, колачы, кулланылыш даирәсе киңәйтелә [14: 46]. Шулай итеп, авторның гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланылып язылган бер шигырендә, Аллаһы сүзе белдерә торган бер төшенчә/атаманың, туры-төп-дини мәгънәсе нигезендә,аның эчтәлегенә хас сәнгатьчә-дөньяви мөмкинлеге ачылуы белән, Г. Тукайның әдәби телебезне ничек итеп үстерүгә/ камилләштерүгә күзаллана. Бу юнәлештә тагын, Ходаем бәхтияр итсен һәм Мөхәммәт өммәте сүзтезмәләрнең мәгънә эчтәлегендә, татар милләте дип дәвам ителешенең ничек баруын күзәтергә була. Әлеге яңарышның төрле жанрларда (сатирик, мәхәббәт, публицистик, балаларга багышлап һ.б.) язылган әсәрләрендә ничек баруын җентекләп анализларга кирәк булачак. Сатирик шигырьләрдә, Аллаһы төшенчәсенең мәгънә эчтәлеге, үзенең капма-каршысына әйләндерелә: ...«Ишан, ишәкөкешер / Өкешмәктә (мактанышуда) мәгънә бар», – дип башлана торган шигырьдә: ...Булсаң син хайван надан / Синнән бигрәк мин надан / Ялкаулык та наданлык / Бүләк безгә Алладан» [14: 123] һ.б.

2) Иске татар теленең, угыз-төрек алынмалары мул файдаланыла торган ысулының дәвам ителеше. Г. Тукайның гарәп-фарсы алынмалары мул кулланылып языла торган шигырьләрендә, угыз төркеме телләренең җанлы сөйләменә хас булган үзенчәлекләрнең дә эзлекле файдаланылуы күзәтелә: бән, вар, идәлем, улаем, күстәрү, безем һ.б. Бу төрдәге сүз, сүзформалар,таш язмаларыннан ук, угыз-уйгыр-кыпчак кабилә телләренең катнашмасы булган гомумтөркидән килә торган язмачылыкның нигез/традициясен күрсәтә торган берәмлекләр булып санала [12: 35] иске татар теленең төрле чорында, теләсә кайсы жанр-стильдә язылган текстларда, төрле дәрәҗәдәге эзлеклелектә кулланылышта була; Г. Тукай иҗатының башлангыч чорында, гыйлем-белем, милләт язмышы турында язганда, аристократ/абруйлы төрки-татар телнең күрсәткечләре буларак, эзлекле рәвештә дәвам ителә. Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре тарафыннан, шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына үзенчә лекле мөнәсәбәт белдерелә: халыкчан тел берәмлекләре файдаланылган шигырь ләре күтәрелеп мактала да, гарәп-фарсы алынмалары күп кулланыл ган шигырьләре «төрек-госманлы телендә языла» дип ассызыклана. Ф. Әмирхан: «иске вә яңа төрек әдәбияты тәэсире», автор өчен гөнаһ эш дип белдерә [1: 11–14]; Җ. Вәлиди: «Тукаевның беренче (шәкердлек) дәверендә, госманлычарак язган шигырьләре эчендәтәрҗемәләре юк диярлек дәрәҗәдә аз иде, ...Фатих әфәнде Тукаевның госманлыча язылган шигырьләрен тел җәһәтен яратмый һәм «Шүрәле», «Алтынга каршы»кеби-татарча шигырь ләренә бик зур кыйммәт бирә иде», – дип (4: LXI, XXXIX), Г. Ибраһимов: «Тукай кебек шагыйрьләр (башлангыч “Мөхәммәдия дәвере”) байтак вакытлар ярым “Тәрҗеман”, ярым госманлы тәэсирендә бардылар», – дип тәгаенли [6: 38]. Ш. Рамазанов: «Бер яктан, әле “төрки тел” дип аталган борынгы феодализм чорының корама “китап теле” дәвам итә. ...Тукай ике телдә – татар һәм төрек телләрендә язды», дип аларны санап күрсәтә [7: 58–61]. Г. Тукайның беренче шигырьләре госманлы-төрек телендә язылган, дигән фикер ныгытыла. Иң гаҗәбе, безнең көннәрдә, тагын

да пафослырак булып, әлбәттә чынбарлыкка туры килмәгәнчә: «...Кардәш төрек халкының теле барлык төрки милләтләр өчен әдәби теле буларак та хезмәт иткән, Г. Тукайның да иҗатын башлаган вакытта кайбершигырьләре сиксән-туксан проценты төрек телендә язылган», «Габдулла Тукай, классик шагыйрьләребезнең күбесе кебек үк иҗатының башлангыч чорында, госманлы телендә язган. Татарның барлык мәдрәсәләрендә дә иске төрек теле фән буларак укытылган, ә аңарда әсәрләр иҗат итү югары өслүб үрнәге саналган, үзенә күрә бер мода булган» дип, Г. Тукайны модага иярүчегә саный торган методологик хата фикерләр языла [8: 46]. Без, татарларда, гарәп теленең дә, төрек-госманлы теленең дә, һич бер вакытта да, тулаем әдәби тел буларак вазифа үтәмәүләре, татар әдәби теленең, гомумтөркидә нигезләнеп, гасырлар буена килә торган үз тарихы булуына игътибар ителми. Тикшерү барышында, бу шигырьләрнең берсенең дә төрек телендә түгел, бәлки татар әдәби телендә гасырлар буена килә торган, аристократ/абруйлы юнәлешендә язылуы күренә [2: 74–82]. Әлеге мәсьәлә, Л. Җәләйнең: «Тукай телен өйрәнү-татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз», – дип раславында билгеләнә [5: 11].

3) Иске татар телендәге, халык авыз иҗаты әсәрләре һәм җанлы сөйләменә нигезләнгән, гавами ысулның илаһи югарылыкка күтәрелеп эшкәртелүе. Г. Тукайның аристократ / абруйлы шигырьләре белән бер үк вакытта: Ник йоклыйсың мужик? / Яз житте һәм үсте / Чирәмләр йортында; / Тор, уян, күтәрел! / Үз-үзеңә кара:/кем идең, кем булдың? – дип, «мужик»-ның үз телендә, асылда, халыкның җанлы сөйләмендәге сүз, сүзформа, сүзтезмәләре кулланылып та иҗат ителә [14: 31]. Татар әдәби теленең бу юнәлеше, XII гасыр Идел буе Болгар дәүләтендә, Әхмәд Ясәвинең: «Аять, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ / Мәгънәсенә йиткәнләр йиргә куяр бүркине...», – дип, суфи шагыйрьнең фәкыйрьләр, гарипләргә багышлап, аңлауны җиңеләйтү максатыннан, гарәп-фарсы алынмаларын азайтыбрак, төркиләрнең барысы өчен дә мәгълүм булган уртак сүз, сүзформаларын кулланып язылган «Диване хикмәтләр»е белән башлана [9: 139]; XVIII–XIX гасырлардагы «Илаһи бәетләр»дән, Баһави, Г. Кандалый, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акмулла һ.б. авторларның әсәрләре белән дәвам ителә. Г. Тукай үзенең иҗатында, халыкчан тел чараларын эстетик эчтәлекне сәнгатьчә тасвирлау югарылыгына күтәрә: «...әдәбиятымызның асылы, җәүһәре булган безнең Казан теле...» икәнлегенә инануын белдерә [13: 118], традиция булып килә торган алымнарны үзенчә яңартып үстерә. Бу хакта бик күп мәкаләләр язылган, монографияләр басылган, диссертацияләр якланган.

**Нәтиҗә.** Төрки-татар әдәби теле нәзариятенең тарихи нигезе буларак тикшерелә торган күренеш, ягъни Болгар-Казан/иске татар телендә, XII–XIII гасырлардан, аерым авторларның әсәрләрендә, адресатка карап: а) гарәп-фарсы алынмалары, ә) угыз-төрки сүз, сүзформалары белән туендырылган аристократ-абруйлы һәм б) халык авыз иҗаты тәэсирендә, татарларның үз сөйләмә тел байлыгын файдаланып язу юнәлешләре, татар әдәби теле тарихында Г. Тукай иҗатында бергә берләшә.Шагыйрь әсәрләрендә, бер яктан, язма традициянең куәтле мөмкинлеге, аның һич бер вазифасы инкяр ителми, икенче яктан, авторның таланты беләнсөйләмә тел дә, әдәби тел вазифасын үтәрлек, ягъни эстетик эчтәлекне тасвирлап бирерлек сәнгати чара югарылыгында әдәбиләштерелә. Татар әдәби теле үзенең алтын чоры дигән дәверендәге үсешенә күтәрелә. Хәзерге татар телендә, Г. Тукай

әсәрләренең телүзенчәлеге өйрәнелгәндә, менә шушы нигезләргә игътибар ителеп, аларда башланган мөмкинлек бәйләнеш-мөнәсәбәтендә яктырту сорала. Г. Тукай иҗатында гасырлар буена эзлекле кулланылышта булган төрки-татар әдәби теленең көче-куәте-байлыгы күтәрелеп эшкәртелә, норма буларак ныгытыла һәм норма вариантлары белән бергә файдалана алуы күрсәтелә. Әлеге мөмкинлекне төгәлрәк күзаллау максатыннан, авторның үз вакытында, гарәп графикасы белән язылган/басылган аерым әсәрләрен, кириллга күчерелгән шигырьләре белән бергә, чагыштырып бирү яхшы булыр иде. Г. Тукай теле – саф татар теле, дигән беркатлы бәяләрдән саклану булыр иде.

ӘДӘБИЯТ

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр: дүрт томда. 4 том: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.

2. Бәширова И.Б. Тукай төрек телендә шигырь язганмы ? // Казан утлары. – 2015. – № 4. – Б. 110–120.

3. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. – Казан: КДУ, 2005.

4. Вәлиди Җамал. Мөхәммәдгариф угълы Тукаев // Г. Тукаев Мәҗмугаи асәре, 1914.

5. Җәләй Л. Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. – 1938. – № 3. – Б. 58–66.

6. Ибраһимов Г. Яңа татар теленең беренче баскычларында // Сайланма хезмәтләр. – 2007. – Б. 32–39.

7. Рамазанов Ш.А.Татар теле буенча очерклар. –Казань: Таткнигоиздат, 1954. – 200 б.

8. Сафиуллина Р. Кутлу һәм аның олы мәхәббәте // Идел. – 2015. – № 4. – Б. 44–46.

9. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 415 б.

10. Татар әдәби теле тарихы (ХШ гасыр – ХХ йөз башы). 1 т.: Фонетика. Графика:язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – Казан:ТӘҺСИ, 2015. – 696 б.

11. Тенишев Э.Р. Принципы составления исторических грамматик и историй литературных тюркских языков // Сов. Тюркология. – 1988. – № 1. – С. 67–78.

12. Тенишев Э.Р.Тюркоязычных письменных памятников языки // Языки мира. Тюркские языки. – Бишкек, 1997. – С. 35–46.

13. Тукай Г. Әсәрләр: Дүрт томда. 4 т.: мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар (1909–1913). – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 288 б.

14. Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. 1 т.: шигырьләр, поэмалар (1901–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.

15. Тукай Габдулла. Шигърият теле. Сүзлек. 2 китапта. – Казан: Мәгариф, 2009.

16. Тукай Габдулла. Энциклопедия (баш. мөх.З.З. Рәмиев). – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б.

УДК 76

## ИЛЛЮСТРАЦИИ ХУДОЖНИКОВ НАЧАЛА XX ВЕКА К ПРОИЗВЕДЕНИЯМ Г. ТУКАЯ

***Ф.Г. Вагапова***

*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье анализируются иллюстрации к детским произведениям Г. Тукая, выполненные художниками начала XX в. Отмечается, что в создании иллюстраций принимали участие профессиональные художники, а также художники, не имевшие специального художественного образования. Иллюстрации к стихам Г. Тукая позволили проследить генезис и динамику развития татарской книжной графики начала XX века. Автором сделан вывод, что в творчестве художников начала XX в. прослеживаются черты, характерные для восточной миниатюры, русской лубочной картинки, а также стилистики искусства модерн.

**Ключевые слова:** восточная миниатюра, детская книга, иллюстрация, искусство, лубок, модерн, художник.

The article analyzes the illustrations for children's G. Tukaya works made by artists beginning of XX century. It is noted that in the creation of illustrations attended professional artists as well as artists who had no formal art education. Illustrations to poems G. Tukai possible to trace the genesis and dynamics of development of the Tatar book charts the beginning of XX century. The author concludes that in the works of artists of the early XX century can be traced features typical of oriental miniatures, Russian print style, and the style of art nouveau.
**Key words:** oriental miniature, children's book, illustration, art, popular print, modern, artist.

Габдулла Тукай – один из родоначальников новой татарской литературы. Детские годы поэта, омраченные тяготами потерь и жизненных испытаний, не могли не отразиться на его творчестве, в котором большая часть произведений адресована детям. Поэзия для детей написана в разных жанрах. Это и произведения в жанре назире и сатиры, к ним относится, например, поэма «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» («Сенной базар, или Новый Кисекбаш»), это и поэзия на темы татарского фольклора («Шурале», «Су анасы» («Водяная»). Поиск новых форм и приемов приводит его к возможности обращения к русской классике. Он переводит стихотворение А.С. Пушкина «Золотой петушок», создав произведение «Алтын әтәч».

Уже прижизненные издания произведений поэта, написанные для детей, оформлялись иллюстрациями. В оформлении первых изданий использовались наборные типографские элементы и политипажи. В начале XX века в книжной культуре татар произошли колоссальные изменения, в художественном оформлении книги [1]. Наряду с типографскими наборными элементами появляются иллюстрации.

В создании иллюстраций к произведениям поэта принимали участие как профессиональные, так и непрофессиональные художники. Говоря о профессионализме, мы имеем в виду наличие специального художественного классического образования. На рубеже XIX–XX веков только единичные представители татарской национальности осмеливались обучаться в художественных учебных заведениях столицы России. С этой точки зрения художники, оформлявшие первые печатные книги, были профессионально не подготовлены. Но с позиции той эпохи, в которой жили и творили, в контексте мусульманской культуры они были, несомненно, профессионалами. Они, являясь образованной и прогрессивной частью татарской интеллигенции, осваивая традиции русского и европейского изобразительного искусства, создавали собственные произведения. В статье мы будем использовать термины: «профессиональный», «непрофессиональный», «самобытный» художник.

Анализируемые работы мы условно подразделяем на две группы. К первой относятся книги, оформленные художниками, не имевшими специального образования. Как известно, идеология ислама не приветствовала изобразительную деятельности. Этот факт стал одной из причин того, что первые татарские художники-иллюстраторы не подписывали свои работы. Можно предположить, что они являлись представителями татарской, в основе своей мусульманской, культуры.

Исследования показали, что издателями к оформлению книг все чаще начинают привлекаться профессиональные художники. Их работы мы выделяем во вторую группу. Среди них также имеются авторы, не подписывавшие свои работы, что делает возможным предположить, что они, являясь представителями татарской культуры, не могли в течение короткого времени

отойти от данной традиции. В статье автор придерживается хронологического порядка изложения материала, соответствующего времени издания произведения.

В 1908 году в лито-типографии И.Н. Харитонова в двух вариантах издается, переведенная Тукаем, сказка А.С. Пушкина «Золотой петушок» («Алтын әтәч») [2; 3]. В первом для оформления были использованы готовые политипажи. Во втором – наряду с теми же клише использовались иллюстрации, выполненные в технике цветной литографии (хромолитографии). Каждая из них расположена на отдельной странице и носит сюжетный характер. Художник тщательно прорисовывает детали: орнамент на костюмах, лепные барочные детали на стенах в интерьере комнаты, окно в мавританском стиле, в проеме которого виднеется силуэт мечети с полумесяцем.

Очевидно, рисунки выполнены профессиональным художником, имя которого не известно. Новые принципы оформления сближают его с творчеством русских иллюстраторов детской книги круга «мирискусников» («Мир искусства» – общество художников, существовавшее с 1898 по 1904 г.) [4: 326], в частности И.Я. Билибина – русского художника, книжного иллюстратора и театрального оформителя [5: 5]. Стилистика И.Я. Билибина отразилась в цветовой гамме и использовании орнаментальной линии, ограничивающей цвета. Также в работах художника прослеживается стилистика модерна, которая выразилась как в оформлении обложки, так и в иллюстрациях. Элементы модерна проявляются в характерном изгибе напряженной текучей гибкой линии рамки, в экспрессивном движении растительного орнамента, обрамляющего текст, в использовании орнаментальных мотивов различных стилей прошлого: помпезное барокко в синтезе с мавританским стилем создают ощущение пышности и богатства.

Электро-типографией «Магариф» в 1914 году издается произведение Тукая «Сенной базар» [6], оформленное гравюрами безымянного художника. Человеческие фигуры в рисунках переданы гротескно: они то приземистые, то заостренно-вытянутые. Словно следуя идее, вложенной автором в содержание произведения, художник, изображая разнохарактерную толпу, не дает буквального толкования и расшифровки образов, не наделяет лица индивидуальными чертами. Одна из гравюр может стать иллюстрацией к строкам: «Один на рынке властвует закон: // В свое лишь дело каждый погружен» [7: 326]. Художник не ограничивает гравюры рамкой, расширяя тем самым границы происходящего, создавая эффект присутствия, дает возможность читателю включиться в пространство рисунка.

В 1914 г. типография «Магариф» издает сборник произведений Тукая [8], куда вошли «Шурале», «Водяная», «Сказка о козе и баране» и другие стихи. Можно предположить, что все иллюстрации выполнены одним художником, но свои инициалы «Б.Э.» он оставил только к рисункам к «Шурале», что видимо, связано с тем, что это произведение стоит в сборнике первым.

В выразительных иллюстрациях к «Шурале», выполненных самодеятельным художником, примечательно стремление образного решения в изображении природы, что помогает раскрытию содержания произведения. Сплошной темной стеной стоит лес, на фоне которого разворачивается сюжет. На переднем плане изображен пролесок с вековыми деревьями, переплетающиеся ветви которых ассоциируются с длинными пальцами Шурале.

Акцентируя внимание на деталях, художник передает состояние природы в разное время суток. На первом рисунке, где события происходят ранним утром, солнце поднимается из-за густой стены лесной чащи, озаряя все вокруг мерцающим светом; на втором оно высоко стоит над лесом, освящая поляну и оставляя блики на стволах деревьев; на третьем – солнце уже исчезло, спрятавшись в вершинах деревьев. От иллюстрации к иллюстрации заметно меняется и характер главных персонажей сказки. Вначале лесной див смело выходит навстречу человеку, чувствуя свое физическое превосходство. На другой иллюстрации, где Шурале защемил пальцы в стволе поваленного дерева, он уже менее агрессивен, в его облике – беззащитность наивного существа, пытающегося разгадать хитрость Батыра.

Средствами художественной выразительности передается внешний облик Шурале и Батыра: не залитый краской глубокий штрих, оставленный штихелем, подчеркивает рисунок длинных пальцев, крючковатый нос, рога, длинные пальцы, шерсть лесного чудища. Герои одеты в национальные костюмы: длиннополый казакин, полусферической формы меховая шапка, валенки. В целом же в передаче образов отсутствует та живая динамика, которая характерна для произведения. Анализ иллюстраций к «Шурале», дает возможность сделать предположение, что для художника были близки восточные, мусульманские традиции изобразительного искусства, что проявилось в композиционном построении рисунков, где прослеживается ее прочтение слева направо, что соответствует движению глаз при чтении арабского словесного текста.

Образы героев произведений Г. Тукая заняли особую нишу в творчестве многих художников, чей творческий путь связан с татарским дореволюционным печатным книжным искусством. В большинстве своем, оставшись безымянными, они внесли огромный вклад в развитие татарского изобразительного искусства. В оформлении печатных книг большую роль играли не только книжные знаки (обрамления, концовки, орнаменты), готовые политипажи, но и иллюстрации, для которых характерно следование тексту и стремление уловить дух произведения. Художники, чаще интуитивно, отказываясь от изображения реального мира, используют такие приемы, которые помогают читателю свободно воспринимать литературное произведение. К ним относятся: изображения без фона или без рамы, преувеличение, замалчивание.

Художественное оформление татарской дореволюционной печатной книги за короткий срок проходит различные этапы стилистического развития: от восточной миниатюры, традиций русской лубочной картинки до искусства рубежа XIX–XX веков, выразившегося в стиле модерн.

ЛИТЕРАТУРА

1. Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 319 с.
2. Тукай Г. Алтын этэч. – Казань: Лито-типография И.И. Харитонова, 1908.
3. Тукай Г. Алтын этэч. – Казань: Лито-типография И.И. Харитонова, 1908.
4. Аполлон. Изобразительное и декоративное искусство. Архитектура. – М.: ЭЛЛИС ЛАК, 1997. – 735 с.
5. Голинец Г.В. И. Я. Билибин. – М.: Изобразительное искусство, 1972. – 226 с.
6. Тукай Г. Печэн базары. – Казань: Электро-тип. «Маарифъ», 1914.
7. Тукай Г. Избранное. Стихи, поэмы, сказки. – Казань: Татар. кн. изд-во. 1969.
8. Тукай Г. Мәҗмугаи әсәре. Ж. Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хәле. – Казань: Мәгариф, 1914. – 442 б.

УДК 800.81-112.2

# ПРЕЦЕДЕНТНЫЕ ИМЕНА СОБСТВЕННЫЕ В ЛИРИКЕ Г. ТУКАЯ

***М.З. Валиева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена исследованию прецедентных имен в лирике великого татарского поэта Габдуллы Тукая, отражающих литературные вкусы и пристрастия поэта и играющих важную роль в раскрытии авторского замысла и воссоздании индивидуально-авторской художественной картины мира.
**Ключевые слова:** лирика Г. Тукая, антропонимы, прецедентные имена.

The article is devoted to the study of precedent names in the lyrics of the great Tatar poet Gabdulla Tukai, reflecting the literary tastes and preferences of the poet and playing an important role in revealing the author's idea and recreating the individual author's artistic picture of the world.
**Keywords:** Lyrics of G. Tukai, anthroponyms, precedent names.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ЛИРИКАСЫНДА ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМНӘР

***М.З. Вәлиева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Прецедент исемнәр – теге яки бу милләтнең, халыкның тарихында, әдәбият-мәдәният дөньясында, тормыш-көнкүрешендә яхшы мәгълүм булган, киң таралган текстлар яисә прецедент ситуацияләргә бәйле булган ялгызлык исемнәр [3: 197]. Алар аерым бер кешене (шәһәрне, торак пунктны, оешманы һ.б.) атау өчен түгел, ә мәдәни знак, яки аерым бер сыйфатларның символы буларак кулланыла. Прецедент исемнәр милли дөнья картинасының халык аңында милли чынбарлыкны, милләтнең холкын, милли менталитетны чагылдыра торган әһәмиятле өлеше булып тора. Бу төр исемнәр текстта милли-мәдәни традицияләрне мифологик, тарихи, дини карашлар аша күзалларга ярдәм итә. Тик теге яки бу кеше исеме прецедент исемгә әйләнгәндә, шул геройга, шәхескә хас сыйфатлар арасыннан калку булып саналган бер яки берничә сыйфаты гына нигез итеп алына. Мәсәлән, Хозыр-Ильяс прецедент исемендә мескеннәргә ярдәм итүче сыйфаты, Зөләйха исемендә матурлык, гүзәллек сыйфатлары өстенлек итә. Әлеге китерелгән исемнәр һәм татар мәдәнияте, тарихы, күзаллавы белән бәйле башка төр прецедент исемнәр Габдулла Тукай иҗатында актив кулланыла, шагыйрь иҗатының аңа гына хас авторлык үзенчәлеге булып тора. Гомумән, ялгызлык исемнәр Габдулла Тукай иҗатында тарихи, милли-мәдәни мәгълүматка бай дөнья тел картинасын тудыруда зур роль уйный [2: 256–258]. Шуларны күздә тотып, әлеге мәкаләдә Габдулла Тукай шигъриятендәге прецедент исемнәрнең кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерүне максат иттек. Тупланган фактик материалдан чыгып, шагыйрь лирикасында урын алган прецедент исемнәрнең, чыганагына карап, өч төрен күрсәтергә мөмкин:

1. Дини мифологиягә, дини текстларга барып тоташа торган прецедент исемнәр. Биредә, нигездә, ислам дине белән бәйле текстларга, беренче чиратта, Коръән аятьләрендә сурәтләнгән вакыйга-сюжетларга бәйле антропонимнар күздә тотыла. Аларның байтагы бүгенге көндә прецедент исем

рәвешендә актив кулланыла. Шундыйлардан Г. Тукай шигъриятендә Нух исеменең кулланылышы кызыклы:

> Та әзәлдән ул сәфилләр үз-үзеннән бетмәдә:
> Кауме Нухи – су белән йә кауме Лути – ут белән [4: 12].

Борынгы дини мифология буенча, Нух белән Лут – пәйгамбәрләр. Коръәндә Нух пәйгамбәргә нисбәтле «Нух сүрәсе» урын алган. Нух пәйгамбәр үз халкын ислам диненә өндәү максаты белән Аллаһ тарафыннан җиргә җибәрелгән. Әмма Нух пәйгамбәр үзенең кавемен иманга китерә алмый, халык аңа ышанмый. Ахыр чиктә халыкны туфан суы баса, Нух пәйгамбәр иманга килгән һәр җан иясен коткарып кала. Коръәндә Нух пәйгамбәр белән бәйле сюжет бик кырыс, фаҗигале итеп сурәтләнә. Биредә сүз аның Аллаһы Тәгалә кодрәте белән җир йөзен һәлакәттән коткарып калуы хакында бара. Бу сюжет татар фольклорына, язма әдәбиятына үтеп керә [6: 230–231]. Әдипләр, шагыйрьләр бу образны еш кына чагыштыру максатыннан куллана. Китерелгән мисалдан күренгәнчә, Габдулла Тукай иҗатында да бу прецедент исем милләтне, җир йөзен түбән рухлы, вөҗдансыз кешеләрдән коткаручы образ, ә иманга килмәгән халкы бетүгә йөз тоткан кавем буларак күзаллана.

Габдулла Тукай иҗатында телгә алынган прецедент исемнәр арасында хәзрәти Муса антропонимы үзенчәлекле образны атый:

> Ул түнә, хәлсезләнә шул, очраса үз хурына,
> Хәзрәти Муса тәхәммелсез тәҗәли нурына (4: 41].

Дини мифологиягә күз салсак, Муса пәйгамбәр имеш, Синайдагы Тур тавы башына Аллаһы Тәгалә белән күрешергә килә һәм Тәҗредән бер генә мизгелгә булса да йөзен күрсәтүен үтенә. «Күзең чагылып сукыраерсың», – дип кисәтә аны Аллаһы Тәгалә тавышы. Ләкин пәйгамбәр бик үтенгәч, бер мизгелгә йөзен ача. Муса пәйгамбәр шунда ук һушы китеп егыла. Хәзрәти Муса Габдулла Тукайның югарыда телгә алынган «Гашыйк» шигыренә исә яраткан, гашыйк булган кеше хисләренең ни дәрәҗәдә көчле булуын чагылдыра торган образны атаучы прецендент исем булып кереп калган.

Дини текстларда үлем фәрештәсе буларак телгә алына торган Газраил галәйһиссәлам – язма әдәбиятка, сөйләмгә күчкән, киң кулланылышка ия көчле прецедент исем. Язма әдәбиятта, халык иҗатында, шул исәптән Габдулла Тукай иҗатында да Газраил, беренче чиратта, җан алырга килүче фәрештә исемен атаса да, икенчедән, ул үлем, әҗәл символы булып күзаллана, кешенең гомере бетүе белән бәйле семантиканы җиткерә:

> Син җаныем белән кавышмасам,
> Җаннарымны алсын Газраил [4: 282].

Гомумән, Габдулла Тукай шигъриятендә дә Газраил исеме еш телгә алына һәм үлем, җан алучы образын атый. Әмма шагыйрь кайчак бу образны йомшарта, хәтта «җылата»:

> Бер сынык юктан гына үлгән таза ирләр күреп,
> Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый [4: 196].

Татар фольклорында һәм әдәбиятында еш телгә алына торган прецедент исемнәрнең тагын берсе – *Хозыр Ильяс.* Бу изге зат пәйгамбәрләргә тиңләштерелә. Халык риваятьләрендә бу исемнең килеп чыгышына карата Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләрне тәңгәлләшетерүдән барлыкка килгән дигән карашлар да яши. Хозыр Ильяс терек суы эчеп, мәңге яшәү көче алган,

көтүче, юлчы, хәерче кыяфәтендә йөри, төрле изгелекләр эшли, бәла-казага тарыган һәм адашкан мөселманнарга ярдәм итә дә шунда ук күздән югала дип ышанганнар [5: 507]. Гомумән, төрки халыклар фольклорында һәм әдәби әсәрләрдә Хозыр образы, аның белән бәйле ышанулар киң урын алган. Хозыр Ильяс культы әдәбиятчы галимнәрнең генә түгел, хәтта теологларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Күп кенә төрки телләрдә, мәсәлән, төрек, азәрбайҗан илләрендә бу образның әдәби әсәрләрдә, халык авыз иҗатында кулланылышын өйрәнүгә зур урын бирелгән [1: 84]. Габдулла Тукай иҗатында да Хозыр Ильяс прецедент исеме аша гади халыкка авыр вакытларда көтмәгәндә ярдәм итә, изгелекләр эшли торган илаһи образ күзаллана:

Булса – бир, булмаса исә, җайлап сөйлә булмаслыгын, –
Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр-Ильяслыгын! [4: 92].

Дини текстларда барып тоташа торган прецедент исемнәрнең тагын берсе Җәбраил фәрештә. Бу прецедент исемдә кешеләргә яхшылык, игелек эшләү сыйфатлары калкып чыга:

Хәзерәте Җәбраил бәшарәт әйләде, дип: «Йа рәсүл,
Хак тәгалә хәзрәте тәгъйинләде бу кич вөсул [4: 113].

Түр тирәзәләрнең төпләрендә
язу язган микән Җәбраил [4: 282].

2. Халкы авыз иҗаты, фольклор белән бәйле прецедент исемнәр. Башка төр прецедент исемнәрдән аермалы буларак, халык авыз иҗатына барып тоташа торган антропонимнарның байтагы прецедент текстка яисә вакыйгага үзенең бәйлелеген югалтмый. Алар килеп чыгышы белән дә, дини яисә мифологик исемнәр белән чагыштырганда, соңгырак чорларга карарга мөмкин:

Сак белән Сок – халык авыз иҗатында ана каргышыннан икесе ике кош булып очып киткән, берсен-берсе күрә алмыйча «сак-сок» дип кычкырып йөргән ике бала. Алар бары тик кыямәт көнне генә очрашу бәхетенә ия. Аерылу, күрешә алмау, ялгызлык кебек сыйфатларны чагылдыра торган әлеге прецедентлы исемне Габдулла Тукай да шигъриятендә дә очратабыз:

Сак белән Сок кыямәттә берсен-берсе очрата,
Биш талчокчы, өч фәхишә театрны пычрата [4: 10].

Г. Тукай иҗатында халык авыз иҗаты белән бәйле прецедент исемнәрнең тагын берсе – Убырлы карчык яратып кулланыла:

Әгәр дә басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса,
Убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса [4: 20].

Убырлы карчык дөнья тел картинасында кан эчүче явыз зат буларак күзаллана. Габдулла Тукай иҗатында да әлеге прецедент исем явыз, ямьсез хатын-кызларны атау максатыннан телгә алына. Гомумән, бу герой бүгенге көндә дә теге яки бу автор тарафыннана язылган әкияти текстларда, мультфильм сюжетларында һ.б. актуаль геройларның берсе, ягъни Убырлы карчык прецедент исеме үзенең чыганагы белән тыгыз бәйләнешен югалтмаган антропонимнарның берсе.

3. Язма әдәбиятка бәйле прецедент исемнәр.

Көнчыгыш классик әдәбиятында сурәтләнгән төп геройлардан Фәрхад белән Ширин исеме бүгенге көндә көчле мәхәббәт символын гәүдәләндерә. Татар әдәбиятында, шул исәптән Габдулла Тукай иҗатында бу прецедент

исемнәр, беренче чиратта, шул язма геройлары буларак телгә алынса, икенчедән, мәхәббәт, ярату, көчле хис-тойгыны гәүдәләндерә. Шушы прецедент исемнәр аша бу җирнең сөю, дуслык җире булмавын укучы шунда ук аңлап ала:

Калмасын дуслык, мәхәббәт, чын сөешмәк дөньяда,
Бу җәһәннәмдер, түгел Ширин илә Фәрһад җире [4: 128].

Габдулла Тукай иҗатында татар әдәбиятында матурлык чибәрлек символы буларак күзаллана торган традицион Зөләйха, Ләйлә прецедент исемнәре телгә алына. Бу исемнәр шагыйрь иҗатында күплектә кулланылып, аларга хас күркәм сыйфат тагын да гомумиләштереп бирелә:

Ул Зөләйхалар вә Ләйләр кеби булса матур?
Көнләшәм... (әстәгъфирулла!) йа шәкүр вә йа гафур! [4: 195].

Язма әдәбияттан алынып, прецедент исемгә әйләнгән антропонимнар арасында һәрбер татар укучысына мәгълүм Таһир – Зөһрә исемнәре бар. Бу исемнәр XIX йөз шагыйре Әхмәт Уразаев-Кормашыйның «Таһир вә Зөһрә» поэмасыннан соң тарала. Соңрак Таһир – Зөһрә исемнәре бер-берсенә гашыйк булган, кавыша алмаган парларны атау, көчле сөю хисләрен тасвирлау максатыннан гомумиләштерә торган прецедент исемнәргә әверелә. АларГабдулла Тукай иҗатында да телгә алына:

Шул вакыт яшьләр күзеңдә: җан ачып, җан сызланып
Егълыйсың, Җан-Зөһрә берлән Җан-таһирны кызганып [4: 225].

Габдулла Тукай иҗатында кулланылган прецедент исемнәр арасында рус теленнән алынганнары да бар. Мәсәлән, Обломов исеме – рус телендә иң кызыклы һәм көчле прецедент исемнәрнең берсе булып тора. Мәгълүм булганча, Обломов И.А. Гончаровның шул исемдәге романының төп героеның исеме. Ялкаулык, ихтыяр көче булмау, әкерен кыймылдау, нәрсәнедер хәл итәргә алына алмау һ.б. шундый сыйфатлар Обломовны онытылмаслык герой итә һәм аның исеме прецедент исем буларак кулланыла башлый. Бүгенге көндә дә шушындый тискәре сыйфатларга ия кешеләрне атау өчен еш кына Обломов антропонимы кулланыла. Габдулла Тукай иҗатында да бу чагыштыру урын ала:

Тик болай бер аурумыни? Әллә Обломовтамы?
Көн саен йөз сулса сулсын, җанда ни кытлык күрәм?! [4: 265]

Шулай итеп, Габдулла Тукай иҗатында татар антропонимнарының күп төрләрен очратырга мөмкин. Алар арасында прецедент исемнәрнең аерым урын алып торганлыгы күренде. Шагыйрь бу төр исемнәр арасында аеруча дини текстларга, Коръән аятьләренә барып тоташа торганнарын яратып куллана. Бу, бер яктан, шагыйрьнең Коръән аятьләре искиткеч яхшы белүенә ишарә ясаса, икенчедән, шагыйрь аларны үзенә генә хас мәгънә төсмерләре, коннотация белән баета. Болардан тыш, язма текстка бәйле булган прецедент исемнәрнең шагыйрь иҗатында актив булуы күренә. Аеруча ярату, сөю, аерылу кебек хис-тойгы символларына әверелгән антропонимнарга Г. Тукай еш мөрәҗәгать итә. Татар дөньясы белән бәйле булганнар гына түгел, көнчыгыш, рус, хәтта Европа әдәбиятыннан үтеп кергән Фәрһад-Ширин, Обломов кебек прецедент исемнәр дә Тукай шигъриятендә үз урынын тапкан. Гомумән, прецедент исемнәр Г. Тукай иҗатын коннотатив төсмерләргә баетып, халыкның әдәбияты, тарихы, мәдәнияте хакында

өстәмә мәгълүмат биреп, милли тел картинасын тудыруда катнаша, бөек шагыйребезнең үзенә генә хас авторлык стилен булдыруда зур роль уйный.

ӘДӘБИЯТ

1. Бабаева Х.А. Общность образа Хызыр у тюркских народов // Литература и художественная культура тюркских народов в контексте восток-запад. – Казань: Отечество, 2015. – С. 83–88.

2. Вәлиева М.З. Габдулла Тукай иҗатында тарихи шәхес исемнәре // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). – Казан, 2011. – Б. 256–258.

3. Красных В.В. «Свой» среди «чужих»: миф или реальность? – М. – 375 с.

4. Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. – Том 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 399 б.

5. Тимергалин А.К. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек. 3 томда. – Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018 – 725 б.

6. Яхин Ф.З. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан, 2000. – 268 б.

УДК 821.512.145

## ПОЭМА С. ХАКИМА «СОРОКОВОЙ НОМЕР»: ЭПОХА И ОБРАЗ ТУКАЯ

***Ф.И. Габидуллина***

*Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета (Елабуга)*

Статья посвящена анализу поэмы татарского поэта С. Хакима «Сороковой номер» в аспекте раскрытия своеобразия эпохи и особенностей изображения образа великого поэта Г. Тукая. Особое внимание уделяется художественным деталям, приемам, средствам изображения, а также выявляется их роль в раскрытии основной идеи произведения.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, С. Хаким, поэма, эпоха, образ, прием, деталь, идея.

The article is devoted to the analysis of the poem of the Tatar poet S. Hakim «The Fortieth Number» in the aspect of revealing the originality of the era and the features of the image of the great poet G. Tukai. Special attention is paid to artistic details, techniques, and means of representation, as well as their role in revealing the main idea of the work.

**Key words:** tatar poetry, S. Hakim, poem, epoch, image, reception, detail, idea

## С. ХӘКИМНЕҢ «КЫРЫГЫНЧЫ БҮЛМӘ» ПОЭМАСЫ: ЧОР ҺӘМ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

***Ф.И. Габидуллина***

*Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты (Алабуга)*

Г. Тукай иҗаты С. Хәким өчен буй җитмәс биеклек, соклангыч иҗат үрнәге булып тора. Ул бөек шагыйрьнең әдәби образына 1930 еллар ахырында ук мөрәҗәгать итә. «Пар ат» (1938–1939), «Шагыйрьнең бала чагы» (1940) поэмаларында, Тукай биографиясенә бәйле уйланулары аша, аның иҗатына килә, бу мирасның үзе өчен кыйммәте, халык рухына тәэсире турында уйлана. С. Хәким шул еллардан башлап Тукайны үзенең остазы итә, әсәрләреннән образлар, әдәби детальләр ала, үзе язганча – *«Тукай аша карыйм дөньяга»*. Бу темага соңрак тагын әйләнеп кайта һәм нәтиҗәдә «Тукай

һәйкәле алдында» (1960), «Тукай дәфтәреннән» (цикл, 1971), «Кырыгынчы бүлмә» (1971), «Тукай белән очраштырды заман...» (1975), «Тукайга» (1984) кебек шигырь-поэмалары языла. Тукайга китергән җитди сәбәпләрнең берсен шагыйрь үзе болай аңлата: «Тукай берәүне дә кабатламаган, үзе булып, Тукай булып калган. Аны без үз милли җирлегебездә туган милли шагыйрь, дибез. Милли үзенчәлек һәм интернационализм бер-берсен баета, тулыландыра торган сыйфатлар. Бу сыйфатлардан шагыйрьнең эчке нуры арта төшә, ул башка халыклар өчен дә кадерле, уртак шагыйрьгә әйләнә. Шагыйрь – тудырган халкының сулышы, үстергән җиренең сулышы, җиренең, халкының язмышын уртаклаша» [4: 134]. Р. Вәлиев билгеләп үткәнчә, «Тукай иҗаты Сибгат Хәким өчен гомер буена рухи юл күрсәткеч, шигъри кыйбла булды. Аның һәр көне, һәр кылган гамәле Тукай бисмилласы белән башлана иде. Шуңа күрәдерме, еллар үткән саен, Сибгат аганың шигъри сурәтләре һич тә тоныкланмый, төсләре уңмый, фикерләре искерми» [1: 7]. Алар арасында сәнгати эшләнеше, Тукайның шәхесен, иҗатын үз чоры һәм автор яшәгән чорга нисбәтле сурәтләү ягыннан «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы аерым игътибарга лаек. Әлеге әсәрдә С. Хәкимнең сәнгати эзләнүләре, фикерләү үзенчәлеге тулы чагылыш табып, аның бөтен иҗатына хас сыйфатларны ачыклауга да уңышлы җирлек булып тора.

С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы бөек Тукайның әдәби образын чагылдырып, эш-гамәлләренә, әдәби мирасына үз чоры һәм автор яшәгән чорга нисбәтле бәя бирүне максат итә. Автор «шагыйрь образын сурәтләүне эпик әсәр мөмкинлекләрен файдаланып тирәнәйтә һәм аны төрле катламнарның синтезында тасвирлый» [2: 288]. Әсәрне халык иҗаты традицияләре кысасында өйрәнү, аның халыкчанлыгын, милли асылын тирәнрәк аңлау мөмкинлеге бирә. Әлеге мәсьәлә исә ике яссылыкта карала. Берсе – вакыйгалар һәм образлар катламы аша халыкның яшәү рәвешен, аны борчыган, уйландырган мәсьләләрне ачу, икенчесе – халык иҗатыннан килүче шигъри алымнарга, гади-гадәти күренешләргә, халыкчан тәгъбирләргә мөрәҗәгать итү. Поэмада төрле катламнар үзара керешеп, бөтенлекле күзаллауны барлыкка китерә. Әсәр лирик геройның хатирәләре, этисенең Әтнә базарыннан кайту күренеше белән башлана. Ат чанасындагы печәнсалам арасыннан бик тә кирәкле ике әйбер чыга – күмәч һәм Тукай китабы. Әнә шул рәвешле герой тормышына *«әкиятләре белән, кар белән...»* Тукай керә һәм китмәскә дип шунда кала.

Поэмада үткән һәм бүгенге бәйләнеше үзара бәйләнеп, үрелеп бара. Аңа автор образы, аның Тукайга караш-мөнәсәбәте дә кушылып китә. Шуңа нисбәтле әдәби катлам аерымлана. Автор өчен Тукай яшәеш таянычы, хыял чыганагы, киләчәккә юл күрсәтүче: *«илаһи рух – Тукай рухыннан».* Тукай иҗатының кыйммәтен ачу аша ул әдәби иҗатның кеше тормышындагы урыны турында уйланырга этәрә. Бөтен күңеле белән иҗатка тартылучы лирик герой остазы әсәрләрен үзе өчен маяк итә. Әнә шул аны сугыш фронтыннан исән-имин алып чыга һәм күңелендәге иҗат хисен баетып, үстереп җибәрә – *«Фронтта да бары бер генә чир – / Тукай чире белән чирләдем».* Бөтен барлыгы белән шигърияткә тартылган, әдәби иҗат белән яшәгән автор гомере буе Пушкин, Лермонтов,Тукайлардан көч-илһам алып яши. Әлеге өч бөекнең янәшә килүе юкка түгел. Автор үзенең Тукаен дөньякүләм танылган рус шагыйрьләре белән янәшә куя, иҗат биеклеген шулар белән чагыштырып бәяли.

Поэмада мөһим урынны иҗтимагый катлам алып тора һәм ул Тукайны үз чоры белән бәйләнештә аңларга ярдәм итә. Тукайдан көч алып яшәгән лирик герой өчен бөек шагыйрь белән бәйле һәрбер әйбер кадерле. Шуңа ул һәр татар өчен изге урынга – Тукай торган йортка – «Болгар» номерларына килә. Әлеге иске йортны ул үзе өчен «сихерле», «изге» дип саный. Ул исә Тукай яшәгән чор, мәдәни-иҗтимагый мохит, шагыйрьнең әйләнә-тирәсе белән аерылгысыз бәйле. Тукай яшәгән чор символы булып Печән базары, аның янындагы мәчет (әсәр язылган вакытта айсыз-манарасыз) калка. Печән базары – татар өчен дөнья үзәге. Бу сату-алу урыны гына түгел, монда татарның борынгы тарихы да, бүгенгесе дә саклана – *«халык монда җанын бушатты».* Дөнья буйлап сибелгән татарлар өчен Казан мәркәз булган кебек, Печән базарында һәр татарның бару һәм кайту юлы кисешә. Язмыш Тукайны да Кырлай һәм Җаек аша Казанга – Печән базары чатындагы «Болгар» номерларына алып килә. Әмма ул монда иске дөнья каршылыклары белән очраша. Барыннан да бигрәк зур тарихлы үткәнебезнең моң, сагыш, фаҗига белән тулы сәхифәләре үкенү хисе белән җанны яралый.

Поэмадагы фәлсәфи катлам халык язмышыннан аерылгысыз Тукай язмышы аша ачылган яшәү һәм үлем, фани һәм бакый, үткән һәм хәзерге, хакыйкать һәм ялган кебек мәсьәләләргә барып тоташа. Автор нинди генә кыенлыклар алдында да башын имәгән, тешен кысып аларны үтеп чыга алган халкы алдында баш ия. Авыр вакытларда мәйданга Ш. Мәрҗани, Тукай, Х. Ямашев кебек бөек шәхесләр чыккан һәм *«җан богавын, фикер богауларын»* өзеп, халыкка юл күрсәткән. Автор шагыйрьлекнең төп вазифасын да халкына хезмәт итүдә күрә:

*Иң бәхетле хис, дим, халкым белән*
*Горурланып язган чагымны;*
*Шул хис икән – җиз кыңгырау җанда,*
*Шул яшәтә икән шагыйрьне* [5].

Халкың белән горурлану... Никадәр якын һәм кадерле төшенчә. Ә бит поэма язылган еллар – интернационализм идеяләре көчәеп, татар теле, мәдәнияте кысрыкланган вакыт. Шагыйрь шундый шартларда да киләчәккә өмет белән карый. Шуңа да аның өчен алыштыргысыз хакыйкать булып халык акылы, рухы тора: *«Сыен аңа, таян аңа һәрчак».* Татар халкы тарихы фаҗигале һәм данлы сәхифәләргә бай булып, кызганыч ки, югалтулар күбрәк. Кан саркып торган яра – дәүләтчелекне югалту. Әмма халкыбызның эчке потенциалы зур. Ул гаять кыен шартларда да үз-үзен саклап калу мөмкинлеген тапкан. Шуңа да әлеге халыкка хөрмәт, аның белән горурланудан башлана.

Лирик геройның халык турындагы уйланулары яңадан Тукай, Әмирхан (Фатих), Рәмиләргә (Сәгыйть) барып тоташа. Автор үз чоры белән әлеге бөекләр яшәгән елларны чагыштыра һәм җанына тынычлык таба алмый:

*Чорны чорга якын куеп карыйм,*
*Вөҗданына аның – вөҗданым.*
*Өч гомерен аның яшәп җирдә*
*Чагыштырыр эшем бармы соң* [5].

Автор Тукайны татар халкына Аллаһыдан җибәрелгән дип кабул итә, шуңа да татарны Тукайдан аерып булмаган кебек, Тукайны да татардан аерып булмый. «Намус, вөждан, хакыйкать турында уйланулар аркылы лирик герой, Тукайда әлеге хасиятләрне барлап, изгелеккә ия шагыйрьне вөждан, намус һәм хаклык символы итеп күтәрә...» [3: 230].

Поэмада җитди бер катламны Тукайның эш-гамәлләренә, иҗатына бирелгән бәя, аларның тарихи, милли әһәмиятен ачу алып тора. Бөек шагыйрь үзенең иҗаты белән халыкны «йокы»дан уята, күңеленә өмет хисе сала, хокуклары өчен көрәшкә чакыра – *«Язганнары безгә бүләге».* Бу исә «Болгар» номерларындагы Тукай яшәгән кырыгынчы бүлмә белән бәйләнештә ачыла. Әлеге бүлмә тар, кечкенә, салкын булса да, рухы белән зур, ирекле, *«бердәнбер бәйсез дәүләт».* Монда Тукай рухы, Тукай моңы, Тукай җаны калган. С. Хәким төрле сурәт чаралары аша әлеге хөрлекне, Тукайга хас үзенчәлекләрне ача. Йозагы-ачкычы да булмаган бүлмәгә ярты «дөнья» сыйган. Дуслары аңа Казан, Уфа, Җаек яңалыкларын алып килгән. Бу бүлмәдә Пушкин, Лермонтов шигырьләре дә, Байронның шашкын хисле поэмалары да яңгыраган. Әлеге бүлмә уты Тукай иҗатыннан нур алып, татар халкының киләчәген яктырткан, төрки халыкларга барып җиткән. Әмма чорның салкын җилләре кырыгынчы бүлмәгә үтеп кереп, Тукайны өшетә. Ул җылы эзләп туган ягына кайта, казах далаларына бара, Петербургны урый, язмыш исә *«Һаман да шул салкын номерга...»* озата. Автор күңелендә әрнү, үкенү хисе:

*Тырыш та син, ярлы да син, халкым,*
*Күршеләрең нинди бай бар да!*
*Берүзенә утыз өч бүлмәле*
*Йорт биләгән Гете Веймарда* [5].

Ул риторик сорау белән үткәнгә карый: «Нигә Тукайны саклап кала алмадык?» Шагыйрьнең ачы язмышы һәрберебезгә сабак булып, бөекләребезнең кадерен белсәк иде, дип киләчәккә эндәшә автор: *«Халкым, алда улларыңны сакла, / Авыр чорлар кичерә улларың...»*

Поэманың соңгы өлешендә автор яңадан үз чорына әйләнеп кайта һәм Тукайның урыны турында уйлана. Иҗатында халык җаны, халык идеаллары чагылган Тукай милләт яшәеше символы булып тора:

*Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,*
*Тукайдагы кебек тел кайда?*
*Мең елдан соң да бер синең, илем,*
*Кайтасыңны беләм Тукайга* [5].

Автор горурлыгын яшерми, әнә Тукайга һәйкәлләр салына, аның исеме белән урамнар, уку йортлары атала, «Туган тел»е гимн буларак яңгырый. Поэма өмет-ышаныч хисләре белән тәмамлана.

Әлеге поэмада Тукайның үлемсез образы торгызыла. Автор халык җырларыннан килә торган хис-кичерешләр байлыгыннан, халыкчан афоризмнардан файдаланып, ике чор бәйләнешендә халык шагыйренең тормыш сәхифәләрен, теләк-омтылышларын һәм халыкның рухи дөньясына тәэсир итү көчен сурәтли. С. Хәким халык иҗатыннан килә торган тәгъбирләр, әдәби детальләр, символлар ярдәмендә яшәеш каршылыкларын ача, халыкның хыялында яшәгән дөнья сурәте тудыра. Шул нигездә Тукай иҗатының үз чорындагы, автор яшәгән дәвердәге һәм киләчәк буыннарга барачак кыйммәтен билгеле.

ӘДӘБИЯТ

1. Вәлиев Р. Сезгә баш ияр көннәр // Хәким С. Сусау: шигырьләр, җырлар, поэмалар [кереш сүз авт. Р. Вәлиев]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 3–8.

2. Йосыпова Н., Мозаффаров Р. Сибгат Хәким // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т.: 1960–1980 еллар [фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 285–296.

3. Йосыпова Н.М. XX гасырның икенче яртысы татар поэмаларында Тукай образы (С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» һәм М. Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» поэмалары

мисалында) // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – Б. 228–232.
4. Хәким С. Тукай // Үз тавышың белән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – Б. 132–137.
5. http://gabdullatukay.ru/in-art/in-literature/poems/sibgat-hekim-kyrygynchy-bulme-poema/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 18.03.2021).

УДК 821.512.145

## ОТНОШЕНИЕ АМИРХАНА ЕНИКИ К ТРУДУ О ГАБДУЛЛЕ ТУКАЕ

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Классик татарской литературы Амирхан Еники (1909 –2000) в научном и творческом сообществе известен тем, что в свое время среди интеллигенции первым встал на защиту доброго имени Г. Ибрагимова, Г. Исхаки, Г. Тукая. В статье анализируется критическая статья писателя относительно труда З.А. Ишмухамметова «Тукай – атеист» (1971).
**Ключевые слова:** Амирхан Еники, Габдулла Тукай, творчество, поэзия.

The classic of Tatar literature, Amirkhan Eniki (1909–2000) is known in the scientific and creative community for being the first among the intelligentsia to defend the good name of G. Ibragimov, G. Iskhaki, and G. Tukai. The article analyzes the writer’s critical article on the work of Z. A. Ishmukhammetov «Tukai-atheist» (1971).
**Key words:** Amirkhan Eniki, Gabdulla Tukai, creativity, poetry.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТУРЫНДАГЫ ХЕЗМӘТКӘ ӘМИРХАН ЕНИКИ БӘЯСЕ

***Г.Р. Гайнуллина***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Фәнни һәм әдәби җәмәгатьчелек Әмирхан Еникине милләт хадимнәренең исемен халыкка кайтаруга зур өлеш керткән кыю фикер иясе итеп таный. Киң җәмәгатьчелеккә әдипнең 1955 елның 30 мартында Г. Ибраһимовны аклау мәсьәләсен карауларын сорап, партиянең үзәк һәм өлкә комитетларына хат юллавы мәгълүм. Гаяз Исхакый исемен кайтаруга беренчеләрдән булып сүз әйткән зыялы да – Әмирхан Еники. Ниһаять, Зиннәт Алим улы Ишмөхәммәтовның 1971 елда дөнья күргән «Тукай атеизмы» дип исемләнгән фәнни хезмәтенә китап дөнья күргән елны ук телдән чыгыш вакытында тискәре мөнәсәбәтен белдергән, әдәби җәмәгатьчелекне Тукай шигъриятенең фәлсәфи нигезләре хакында уйланырга чакырган бердәнбер шәхес тә ул.

«Казан утлары» журналының 1994 елгы дүртенче санында Әмирхан Еники «Ялганны яклау» дигән баш астында Тукай клубында 1971 елны ясаган бер чыгышы хакында мәкалә бастыра [1]. Әдип язучыларга философия фәннәре кандидаты З.А. Ишмөхәммәтовның «Тукай атеизмы» дигән китабына мөнәсәбәт белдерү уңае белән мөрәҗәгать итә. Ә. Еники язганча, бу хезмәт турында аңа «Тукайны дәһри иткән бер китап дөньяга чыкты, син шуны табып укы әле», – дип Тукай иҗаты белән махсус шөгыльләнгән Ибраһим Нуруллин башлап әйтә [1: 692].

Ә. Еники әлеге китапның шул чорда дөньяга чыгу алшартларын болай нигезли: «Ишмөхәммәтов китапның кереш сүзендә үк ачыктан-ачык “Тукай – атеист” дип белдерә. Тукаебыз әнә шундый кеше икән! Минем өчен бу

өр-яңа бер ачыш булса да, артык гаҗәпләнмәдем. Идеология таләпләреннән чыгып, бездә Тукайны төрле вакытта төрлечә бәяләү аз булмады; кайчандыр аны милләтче дип тә, вак буржуа шагыйре дип тә атадылар. Соңгы елларда инде аңа революцион-демократ дигән исем беркетелде. Гомумән, Тукаебызны коммунистик идеологиягә кыскарак тезген белән ныграк бәйләп куярга тырышу һаман үзен сиздереп килде. Ишмөхәммәтовның бу хезмәте дә шуның бер үрнәге түгел микән?» [1: 693].

Язучы үзенә хас зыялы сарказм белән Г. Тукайның дәһри булмавын күрсәтер өчен китаптан өзекләргә мөрәҗәгать итә, әдипнең йогынтыларга бирелеп язмавын, үзфикерле шагыйрь булуын раслап чыга: «Дөресен әйтергә кирәк, Ишмөхәммәтов Тукай иҗатын шактый тирән сөреп чыккан. Тукайга таккан һәр сәяси тезисын ул шагыйрь иҗатыннан күп мисаллар китереп, үзенчә дәлилләп тә бара. Ә Тукайдан барысын да табарга була. («Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!») Турыдан-туры атеизм тегермәненә су коярдайларын да! Тормыштан аерылган кадим мәдрәсәләрдән, кара, надан ишан-муллалардан, комсыз-азгын байлардан әче көлеп яки ачынып язган юллар азмыни аңарда?! Алар барысы да безгә мәгълүм. Тик биредә шуны гына ачыклап үтәсе килә: Тукай атеизмга хезмәт итәрдәй әнә шул шигъри юлларын кем йогынтысына бирелеп язды икән? Китап авторы «марксизм-ленинизм йогынтысында» ди. Ләкин минем моңа нигәдер ышанып бетәсем килми. Бик яшьли, бик вакытсыз үлеп киткән шагыйрь Маркс белән Ленин исемен, ихтимал, ишетеп белгәндер, әмма аларның тәгълиматын төннәр утырып «моталәгә кылырга», мөгаен, өлгермәгәндер. Минем фикеремчә, шагыйрьгә иң көчле йогынтыны тормыш үзе ясаган булырга тиеш» [1: 694]

Әдип З. Ишмөхәммәтовның хезмәтендә бер-берсенә каршы яңгыраган фикерләрне аерып күрсәтә: «Билгеле, китап авторы теләсә-теләмәсә дә: “Тукай иҗатында дини мотивлар да юк түгел”, – дип әйтергә мәҗбүр була. Хәтта әле, кемнәр беләндер килешкәндәй, “Тукай Аллага ышанган дигән фикер табигый” дип әйтергә дә мәҗбүр... Ләкин шуның артыннан ук ул бу “табигый фикерне” тизрәк кире кагарга да ашыга» [1: 695].

Хәлбуки, Ә. Еники китап авторы белән бәхәскә керми, чөнки язучы көн кебек ачык хакыйкать турында сүз алып бара, аны нигели генә. Г. Тукайның «Туган тел», «Васыять», «Күңел» шигырьләрен мисал итеп алып, дәлилләү кирәк тә булмаган дөреслек турында ул болай яза: «Китап авторы шагыйрьнең «Үземнән гыйлавә» дигән икеюллык шигырен китерә:

Ышандык бер Ходайга, бер вә бардыр, дип, вә ялгыз, дип,
Сөйли тел: кайнигәч, кайне, кәләш, дип һәм дә балдыз, дип.

Һәм шушы гүя уйнап кына язылган ике юллыктан чыгып, философ иптәш үзенең гаять җитди нәтиҗәсен ясый да инде: «Тукай бу әсәрендә гүяки: әгәр дә мин «Алла» сүзен еш кулланам икән, аны Алла барлыгына ышанганлыктан кулланмыйм, бары тик «кайнигәч», «кайне» сүзләрен кулланган кебек кулланам, ди. Димәк, бу әсәр нигезендә (нинди көчле дәлил!) Тукай Аллага ышанган дип әйтеп булмый, киресенчә, әсәрдән моңа капма-каршы нәтиҗә килеп чыга» [1: 695].

«Ишмөхәммәтов «нәтиҗәсен» юкка чыгарыр өчен шагыйрьнең күпләргә мәгълүм «Васыятем»не искә төшерү дә җитә, – дип яза Ә. Еники. – Тукайны җирләгәч, Касыйм хәзрәт аның васыятен кабере өстендә кычкырып укый да [1: 696]. «Туган тел», «Аллаһе тәбарәкә вә тәгалә» шигырьләреннән мисал китереп, Ә. Еники болай фараз кыла: «Инде уйлап карыйк: үзе Алла-

га ышанмаган шагыйрь балаларны ышанырга өндәп шигырь яза алыр иде-ме? Бигрәк тә һәртөрле яраклашудан өстен торган Тукай?..» [1: 696]. Ахыр килеп, әдип «динне, муллаларны тәнкыйть итү – ул әле Алладан ваз кичү түгел», – ди. – Дини догмаларны тәнкыйть итеп тә, Аллага ышанучылар тарихта аз булмаган. Тукай яшәгән заманда моның бик ачык үрнәге – Лев Толстой. Шушы бөек зат гомере буенча диярлек рәсми чиркәүне һәм аның иң югары әһелләрен рәхимсез тәнкыйть итеп килде. Шуның өчен аны, бәддога укып, чиркәүдән аердылар. Әмма Толстой соңгы сулышына кадәр Аллага беткәнче ышанган кеше булып калды. Һәм берәүнең дә башына аны атеист итү кебек тузга язмаган уй килмәячәк» [1: 699].

Әдипне аерата сагайтканы менә нәрсә: «Тик шулай да күрәләтә ялганга бару нигә кирәк иде? Нигә Тукайның рухи халәтенә саграк килеп, аны тирәнрәк аңларга тырышып карамаска? Кешенең рухи дөньясы бик катлаулы, бик серле, кайчагында ул үзе дә аңлап бетерә алмый аны... Чынлап та, «Болгар»ның тар бүлмәсендә яткан, мәчетләргә йөрмәгән, мәгәр Коръәнне укырга яраткан, кайбер хәрәм эшләрдән дә тыела белмәгән хөрлек сөюче Тукай шулай да ни өчен әле Аллага инанган, Аллага сыенган? Моңа җавапны, бәлки, аның ачы язмышыннан – ятимлегеннән, ялгызлыгыннан, әҗәленә тигән авырудан эзләргә кирәктер. Ни үкенеч, шундый иртә ачылган даһилык, тумыштан ук гарше әгъляләргә җилкенгән күңел, ә япь-яшь көенә аны нинди тәкъдир көтә?.. Караңгы салкын кабер... Мондый хәлдә ничек итеп ул изге бер кодрәт иясенә сыенмасын, шуңардан үзенә юаныч өмет итмәсен ди?!» [1: 697].

Әмирхан Еникине Язучылар җыелышында үз чыгышыннан соң уйга калдырган җитди күренеш бар: «Халык никтер тик кенә, тын гына утыра. Президиумда да хәрәкәт сизелми. Бу хәл миндә гаҗәпләнү катыш ниндидер бер ямьсез шик тудырды: мин сөйләгәннәрнең аз гына да тәэсире булмады микәнни? Сүз бит Тукай турында, нинди дә булса бер реакция уятырга тиештер бит инде ул! Ләкин ни өчен бөтенесендә дә мондый салкын битарафлык?.. Янәшәмдә утыручылар да гүя шул битарафлыкны бозмас өчен таш сындай селкенмиләр дә...» [1: 700].

Җыелышта чыгыш ясаган олпат язучылар Г. Ахунов, Х. Туфан да Ә. Еники фикерләренә теләктәшлек белдермиләр. Әдип «Тукайның замандашы, шагыйрьне иҗатын энәсеннән җебенә чаклы белгән, дөресен әйтүдән курыкмаган исәннәр арасында иң карт шагыйрь» [1: 702] Сәйфи Кудашка мөрәҗәгать итәргә карар кыла: «Гаҗәп тә түгел, чөнки ул – читтә яшәүче, бездәге хәлләргә бертөрле дә мөнәсәбәте юк, димәк, аңа чын үз фикерен әйтү бер дә читен булмаячак. Һәм менә аның 15 октябрь куелган 34 битлек хаты озакламый миңа килеп тә җитте. Гаҗәеп бер хат бу!.. Иң элек минем хатым Сәйфи агайның бик борчулы һәм мәшәкатьле чагына туры килгән. Җәмәгате Мәгъфүрә апа каты авырып киткән булган. Сәйфи агай көне-төне диярлек авыру карчыгын карау-дәвалау хәстәренә керешкән. Мондый чакта каяндыр, кемнәндер килгән хатны онытып тору да бер дә гаеп булмас иде. Ләкин кайгысы-мәшәкате нихәтле генә зур булуга карамастан, Сәйфи агай минем хатны бер генә минут та онытып тора алмаган. «Чөнки Тукай мәсьәләсе безнең үз язмышыбыз. Тукай – халкыбызның вөҗданы, намусы һәм иманы! Шуңар күрә мин мондый вакыйгаларга тамашачы булып кына кала алмыйм», – дип яза ул җавап хатының башында ук. Әйе, минем мөрәҗәгать хатым карт шагыйрьне чын-чынлап дулкынланырга мәҗбүр

иткән икән; «Әгәр дә дулкынланмасам, бу хатны язарга кулга каләм дә алмаган булыр идем мин», – ди ул үзе дә. Мине хәзер ике нәрсә беләп алды: Тукай һәм аның намусын, сафлыгын һәм дөреслеген яклаган өчен әрләнгән Әмирхан Еникиев дигән язучы беләп алды» [1: 703].

Әдип язмада хатның эчтәлеген сөйләвен дәвам итеп, болай ди: «Иң элек Сәйфи агай “Тукайның дини хискә сугарылган һәм Алла кодрәте алдында баш игән шигырьләрен”нән күп кенә аерым юлларны тезеп чыга. 32 шигырьдән ул, махсус сайлап тормыйча, бары күзенә ташланганнарын гына күчереп алган. Һәм бу шигырьләр барысы да бишенче елдан соң, “Урал”да чыгуыннан туктагач, 1908 белән 1913 еллар арасында (үлгән көненә кадәр) язылганнар. Ягъни алар Тукайның шагыйрь һәм акыл иясе буларак тәмам җитлеккән, фикри хөрлеккә ирешкән чагына туры киләләр. Сәйфи агай әлеге шигъри юлларны китергәннән соң, менә нинди нәтиҗә ясый: “Тукайның халык күпчелеге тарафыннан шулай бик тиз танылуын, сөелүен һәм табыныр дәрәҗәдә культка әйләнүен мин үзем шушы рухтагы шигырьләрнең катнашуыннан башка күз алдына да, акыл капкасы төбенә дә китерә алмыйм”. Янә болай диеп тә яза: “Әгәр дә Тукай шушы шигырьләрен язмаган булса, киң халык катламы аны ул чакта шулай кабул итмәгән һәм йөрәк кәгъбәсенең түренә утыртып та куя алмаган булыр иде!” Димәк, Сәйфи агай Тукайның халык шагыйре булып танылуын турыдан-туры дини рухтагы шигырьләре белән дә бәйләп карый» [1: 704].

Тукайның дини рухтагы шигырьләрен халык ни өчен шулкадәр яраткан, моның сере нәрсәдә, дип, Ә. Еники С. Кудаш уйлануларын болай җиткерә: «Сәйфи агай моны болай аңлата: “Алар (ягъни ул шигырьләр) дини, илаһи булулары белән түгел, бәлки, балаларда сафлык, пакьлек, тугрылык, аңлылык, туганлык, кешелеклелек, намуслылык һәм ата-анага, олыларга хөрмәт итү тойгылары тәрбияләүләре белән әһәмиятлеләр”... Һәм бу аңлату белән килешмичә һич мөмкин түгел – кайсыбыз гына бала чагыбызда Тәңрене даими исебезгә төшерүче Тукай абыебыздан әхлак сабагы алмадык соң?!» [1: 705].

Шул ук вакытта журналга басылган язмада Әмирхан Еники каләмдәшләренә, чордашларына мөнәсәбәттә кырыс, ләкин гадел бәясен җиткерүне тиеш таба: «Озак газаплы уйланудан соң, мин ахырда шундый нәтиҗәгә килергә мәҗбүр булдым: күрәсең, Тукайның Аллага ышануын исләренә төшерүне язуылар үз вөҗданнарына кагылу, үз намусларына тукыну шикеллерәк кабул иттеләр. Чыннан да, Тукайның Алланы инкяр итмәвен исбатлап тору, бигрәк тә дини шигырьләрен укып күрсәтү, аларга нигә кирәк? Болай да беләләр ич! Ә менә Ишмөхәммәтов язганча, Тукай, чынлап та, алласыз дәһри булса, аларның җаннары тынычрак булыр иде... Әнә шул рәвешчә, моннан егерме ел элек мөхтәрәм язучыларыбыз җан тынычлыгын саклау өчен һәм безне тәмам биләп алган рәсми идеология хакына, Тукай турындагы ялганны, теләпме-теләмичәме, күмәкләшеп якларга мәҗбүр булдылар. Дөреслектән качуны мин башкача аңлый да алмыйм, аңлата да алмыйм» [1: 707].

XXI йөздә Тукай фәне иң катлаулы шартларда да шагыйрьнең якты исемен яклый алган, купшы ялганга берүзе каршы тора алган классик язучыларыбызга игътибарлы булырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Еники Ә.Н. Ялганны яклау // Әсәрләр. 3 томда.– Казан: Татар. кит. нәшр, 2019. – Б. 692–707.

УДК 82-34 (398.2)

# ПРОИЗВЕДЕНИЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ «СУ АНАСЫ»

***А.С. Гайнутдинова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Людей всегда привлекало волшебство, которое окружала элементы воды, своей загадочностью и недоступностью. Мифы и легенды о русалке (водяной мужчина, водная женщина) уходят в глубокую древность. Всемирно известное существо Русалка содержит вселенские верования. Сначала их воспринимали как богинь, позже была сделана критика, о том, что это легенда придуманная. Например, с одной точки зрения, люди путают русалок, в связи со схожестью их морскими коровами. Другие исследования предполагают, что русалка, вероятно, всего, когда-то жила, а затем исчезла с лица земли так же, как и динозавры, но, несмотря на это на сегодняшний день было написано много романов и снято много фильмов о русалках.
**Ключевые слова:** Девушка Озера, Мать Воды, девушка-рыба, русалка, Тукай, легенда.

People were always attracted by the magic that surrounded the elements of water, with their mystery and inaccessibility. Myths and legends about the mermaid (water man, water woman) go back to ancient times. The world-famous creature mermaid contains universal beliefs. At first, they were perceived as goddesses, later, criticism was made that this legend was invented. For example, from one point of view, people confuse mermaids, due to the similarity of their sea cows. Other studies suggest that the mermaids most likely once lived and then disappeared from the face of the earth as did the dinosaurs, but despite this, many novels have been written to date and many films about mermaids have been made.
**Key words:** Lake Girl, Mother of water, fish girl, mermaid, Tukay, legend.

**Введение.** О существовании получеловека полурыбы впервые упоминается в шумерской мифологии. Бо Эа (Энки), владыка океана подземных вод, один из трех великих богов в шумерской мифологии, изображался с верхней частью человеческого тела и нижней частью тела рыбы, играл важную роль и передавал свою мудрость людям [10: 319]. Первой получеловека полурыбы в женской обличие, является Атаргатис (Деркето), великая богиня Северной Сирии. В поздних источниках же греки стали упоминать о сиренах с девичьей головой и рыбьим хвостом [3].

Согласно легендам средних веков, о русалках начали описывать, как о существах, которые нуждаются в душе человека. Например, согласно швейцарской легенде, русалка была бездушной, и она всячески пыталась найти душу. О данных сходствах говорится и в сказке Ганса Христиана Андерсена «Русалочка».

Русалка на разных языках именуется по разному, однако каждый из них имеет смысл относящийся к воде. Существуют разные мнения о появлении русалке. Например, согласно представлениям восточных славян, «ушедшие из жизни неправильно» превращаются в русалок. Под «неправильным уходом» подразумеваются, суицидисты, дети убитых их матерями, тех, кто не был крещен, тех, кто погиб в результате несчастного случая, и те кто был проклят их родителями, магами и т. д. [5].

В тюркских народных верованиях также присутствуют существа живущие в водах, о жизни которых говорится во многих народных творчествах в виде рассказов, легенд и повествований разных авторов. Например, среди татарских произведений творчества известного писателя Габдуллы Тукая «Су анасы» [9].

**Су анасы Габдуллы Тукая.** Габдулла Тукай в своих трудах часто использует педагогическую элементы и мудрость народов. Народная мудрость, которую использовал Габдулла Тукай, характеризует героев произведений и в различных ситуации, таким образом помогает отразить мысли героев и состояние души. Маленькие фольклорные персонажи с кратким повествованием не только определяют истину, но и позволяют читателю думать, читать между строк и делать выводы. Все его работы – это эффективный инструмент умственного, нравственного и эстетического воспитания. Это оказывает большое влияние на общее развитие ребенка и напрямую способствует его готовности к обучению. В своих поэтических образах он объясняет жизнь природы и общества, сложный мир отношений человека с ребенком. В то же время он способствует развитию правильной речи, давая примеры правильного литературного языка. Произведения Габдуллы Тукая учат его эмоционально реагировать на чужую боль, горе или, наоборот, радость. Габдулла Тукай – прекрасный психолог и знаток чувствительной души ребенка. Во всех своих трудах он показывает, что мир ребенка особенный, которых мало понятный для взрослого. Юмористические рассказы помогают увлечь юного читателя, принять собственное решение, выразить эмоциональное отношение к случившемуся, поставить вопросы, оценить действия героев [2].

Произведение «Су анасы» очень конкретное: цвета, звуки, запахи настолько реальны, что у читателя возникает непроизвольное желание участвовать в происходящем. На страницах своих произведений автор создал дикую энциклопедию родных земель, благодаря которой выделил много важной информации.

Автор в своем произведении «Су анасы» описывает происходящее из уст ребенка. «В жаркий летний день ребенок плавал и плескался один в воде. Когда он шел домой, он оглянулся, и увидело ужасное существо, которое вышло из воды и сило на ступеньке расчесывать свои волосы золотой гребеньком. Когда она закончив расчесывание собрала их и оставив гребень вернулась в воду. Мальчик в свою очередь втайне наблюдал за происходящим, при этом его глаза видели только золотой гребень. Как только она нырнула в воду, он украв гребень убежал прямоком в свою деревню. Однако, когда он только удалился от воды он услышал зов су анасы, которая кричала ему вслед. Обернувшись мальчик обнаружил, что су анасы начала его преследовать. Как только она собиралась поймать его, собаки воспрепятствовали ей и, таким образом, она была вынуждена вернуться обратно в озеро. Ребенок прийдя домой сказал матери, что этот гребенть он где-то нашел. У матери появились подозрение, но она все же доверилась своему ребенку. Наступила ночь, кто-то ударил оконное стекло. Ребенок от страха спрятался под пуховое одеяло и задрожал. В это время его мать проснулась от шума. Она подошла в сторону шума, чтобы узнать, что происходит. Как только она подошла, увидела перед собой су анасы, которая говорила вернуть ей ее гребень, который был выкраден ее мальчиком. Узнав об этом его мать быстро нашла вернула его через окно, которое следом мгновенно заперла. После этого случая его мать хорошенько отругала ребенка. Ребенок же, с того самого дня больше не прикасаться к оставленным без присмотра предметам» [4: 191–192].

В вышеупомянутой работе автор упоминает о сущестование су анасы и дает наставления детям не воровать. Основы для написания данного произведение легла мифология о жителей вод.

**Су анасы в мифологии казанских татар.** Су анасы в мифах описывается, как жена хозяина вод, которая больше похожа на русалку. Су анасы, в сравнение с другими жителями воды, более часто видиться с людьми. Ее волосы черного цвета заплетены в косу, длинною почти до земли, голова большая и длинновата. Глаза большие, черные и выпуклые. Тело имеет слегка красноватый цвет.

Су анасы обитает в больших и малых реках, озерах. Люди ее обычно встречают, расчесывающим свои длинные волосы, иногда она забывает о своем золотом или серебряном гребне. В разных версиях ее гребень ворует нежданных зритель. Обнаружив исчезновения гребня она начинает преследовать вора, таким образом давая ему возможность его вернуть [6: 24–25].

Однако обычно она их не отпускает. Эти события по обыкновение происходят по вечерам, но бывает и в в дневное время. Также известно из повествований, что Су анасы питалась человеческим мясом. Поэтому матери убеждали своих детей не идти в одиночку. По одной легенде, су анасы просила у мельника прислать к ней человека. Она мельника вначале не смогла убедить, но когда же су анасы пригрозила ему в том, что разрушит его мельницу, все изменилось. В связи с угрозами мельник велел одному охотнику, за определенную сумму, пойти на охоту с мальчиком лет 14–15. Таким образом охотник и мальчик охотились до самого вечера. К завешению дня он застрелили одну утку, которая же упала в воду. Мальчик, чтобы достать утку, вошел в воду, которая была не слишком глубокой. Охотник же лишь увидел, как мальчик вошел в воду и вдруг, по мгноению ока, он исчез. На следующий день бездыханное тело мальчика нашли совсем в другом месте. Мальчик был хорошим плавцом и всех удивило, что он утонул в воде. Вполедствии инцидента к мельнику снова пришла су анасы, но в этот раз она хотела его отблагодарить и пригласила его к себе в гости. Мельник не удержался от настойчивого приглашения су анасы и согласился. Су анасы велела мельнику закрыть глаза, когда он подойдет к реке. Мельник так и сделал, как только он подошел к реке, закрыл глаза и в мгновение ока оказался в доме из стекла. В гостях к нему относились, как к королю. Они проводили время за приятной беседой с мельником, как если бы он был ее зятем. Здесь в качестве наставления выделяют тот факт, что и жители вод, также как и люди, могут быть как хорошими, так и плохими [6: 24–29].

**Девушка Озёра Турции.** История жителей вод с разными подробностями принадлежит не только казанским татарам, но и всем тюркским народам. Например, возьмем Турцию сегодня, мы находим легенду о возникновении названия озера, известного как «озеро Девушки» в Артвине. У легенды возникновения имени озера есть три версии.

Главные герои первой легенды – пастухи и русалка. Основная тема данной легенды заключается снова в драгоценном гребене. Пастух, когда взял гребень, русалка просила вернуть его. Однако пастух не хотел возвращать, поэтому русалка смогла обменять его на камень из озера. Пастуху объяснила, как пользоваться данным камнем и о том, что положив камень в свой подвал, он сможет достичь бесконечного изобилия. Пастух, вернув ее гребень, выполнил все указания и в действительности смог достичь изобилия.

По другой версии, русалка столкнулась с более амбициозным охотником. В результате того, что не он отдал ее гребень, русалка подвергла его проклятием и влюбилась его в себя. Когда он обнаружил, что стал увядать

на глазах, он вернул ей гребень и извинился. Несмотря на все это он все еще увядал и в конце умер.

По третьей версии, однажды охотник увидел на краю реки супружескую пару русалок. Муж, увидев охотника, смог спрятаться в воде, но его жена оставалась в руках охотника. Узнав об этом, муж русалки стал умолять охотника отпустить его жену. Охотник пожалел его и оставил девушку на берегу озера. Таким образом, русалка смогла воссоединиться со своим мужем [1: 114–115].

**Су анасы в современности.** Упомянутые в нашем исследовании легенды имеют общие точки соприкосновения. Событие происходит на берегу озера, где главную роль берет на себя девушка-русалка. Согласно первым мифам, о русалке упоминается, как об очень старом, внушающем страх людям существе. По более поздним мифам, русалка становиться очень молодой и красивой девушкой. Другая деталь эта украденная у русалки золотой или серебряный гребешок. Русалка сначала дает каждому шанс искупить вину за свое преступления, а затем наказывает преступника. Кроме того, опираясь на мифологию казанских татар, мы можем установить связь между легенд. Русалки в легендах изображены как полноценная семья. Существо, которое описывается, как муж русалки является в то же время хозяином вод, а также супруга, которая проявляется во многих мифах. Основываясь на вышеупомянутых легенды, мы становимся свидетелями того, что, хотя водные существа имеют разные характеры, которые так же, как и люди, на одни и те же события реагируют по-разному.

В наши дни русалка становится все более и более известной. Например, в столице республики Татарстан, в 2000 году на улице Баумана был установлен памятник «Су анасы», изображенный в сказке Габдуллы Тукая. Кроме того, по произведениям Габдуллы Тукая сняты мультфильм [7] и фильм [8]. Что же касется Турции, то мы также видим памятники, в которых русалки выглядят прекрасными девами.

Заключение. Русалки хоть и принадлежат к фантастическому миру, у них есть общие черты с мифологией тюркских народов. По этой причине народ начал связывать странные события с этими убеждениями. Например, они обвинили русалку во внезапном утоплении в воде хорошего пловца. В связи с этом народ решил не ходить к воде в одиночку. А также человеку, который провенился перед русалкой, велели просить прощение при помощи соли и других веществ. Утверждалось также, что, если эти советы не сработали, значит русалка очень разозлилась либо извинения было приподнесены слишком поздно. Следующим поколениям было сказано, что такого рода поведения следует избегать.

Сегодня русалка смогла взять важную роль, которая иногда бывает хорошей, а иногда и плохой. Поэтому, хотя в прошлом русалка была очень устрашающей, в нынешних описаниях она стала более красивой и привлекательной. Настолько, что русалка стала сниматься во многих фильмах в образе красавицы.

## ЛИТЕРАТУРА

1. Pınarbaşı, Gülenay. Anadolu’ya adını veren kadınlar. 3. Baskı, İstanbul: Okur Kitaplığı, 2016. – 158 s.

2. Агишев Я. Творчество Габдуллы Тукая (Общественно-политические мотивы). 2-е испр. изд. – Казань: Таткнигоиздат, 1954. – 92 с.

3. Акимушкин И.И. Сирени сказочные и натуральные. Трипою легенд. – М.: Молодая гвардия, 1961. – 312 с.
4. Габдулла Тукай. Произведения в четырех томах. Т. 1. – Казань: Таткнигоиздат, 1955. – 384 с.
5. Зеленин Д. К. Очерки русской мифологии. – Петроград: Типография А.В. Орлова, 1916. – 312 с.
6. Коблов Я.Д. Мифология казанских татар. – Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1910. – 49 с.
7. Мульфильм для маленьких. Водяная (Су Анасы). Мульфильм на татарском языке. (6 февраля 2013). https://www.youtube.com/watch?v=qYSVkfT4Ht4 (дата доступа 31.01.2021).
8. Нафигова А., Абзалова Л. «Татарстанский фильм-сказка «Водяная» выходит в российский прокат». (8 февраля 2019) http://mincult.tatarstan.ru/rus/index.htm/news/1399744.htm (дата доступа 31.01.2021).
9. Халит. Г. Тукай үткән юл: (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк). – Казан: Татар. кит. нәшр. 1962. – 228 б.
10. Чжоу Яньянь. «Образ Русалки» в русской и китайской традиции // Общее и особенное», научный диалог. – 2017. – № 5. – С. 319–329.

УДК 821.512.145

## ТВОРЧЕСТВО ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ НА ПОЛЬСКОМ ЯЗЫКЕ

***Л.Ш. Галиева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматривается история создания переводов произведений Габдуллы Тукая на польский язык. По имеющимся на данный момент источникам, отдельные стихи поэта были переведены на польский язык в 30-е годы XX столетия. Есть и современные переводы. Все они были выполнены с целью ознакомить польских татар с выдающимся мастером пера из казанского края.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, переводы, польско-татарская литература, эмигранты, периодика.

The article deals with the history of the creation of translations of the works of Gabdulla Tukay into Polish. According to the sources available now, some of the poet's poems translated into Polish in the 30s of the twentieth century. There are also modern translations. All of them made in order to acquaint the Polish Tatars with an outstanding master of the pen from the Kazan region.
**Key words:** Gabdulla Tukay, translations, Polish-Tatar literature, emigrants, periodicals.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ ПОЛЯК ТЕЛЕНДӘ

***Л.Ш. Галиева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның аерым әсәрләре дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителгән. Хәзерге вакытта аларның саны ике дистәдән артып китә. Шулар арасында поляк телендә башкарылган тәрҗемәләр да бар. Әлеге факт әдип биографиясенә зур яңалык алып килмәсә дә, гомумән татар дөньясы, мөһаҗирләр тормышы хакында кызыклы гына мәгълүматлар тупларга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта әлеге тәрҗемәләр Польшада яшәүче татарларның Г. Тукай иҗатына карата булган мөнәсәбәтен дә күрсәтеп тора. Гасырлар дәвамында телләрен югалткан, әмма төрки-татар дөньясына, Татарстанга йөз тотып яшәгән поляк татарлары өчен әлеге шигъри тәрҗемәләр аеруча кадерле.

XX гасырның утызынчы елларында Казан ягыннан Польшага эмигрантлар буларак килгән татарлар Г. Тукайга багышлап төрле чаралар, кичәләр үткәргәннәр. Әлеге мәгълүматлар белән Гаяз Исхакый редакцияләгән «Яңа милли юл» мәҗмугасыннан, шулай ук Польша татарлары тарафыннан чыгарылган төрле басмалардан, эмигрантлар нәшер иткән журналлардан танышып була. Нәкъ менә Г. Исхакыйның Польшадагы мөһаҗирлек чорын өйрәнү Г. Тукайның да әле утызынчы елларда поляк теленә тәрҗемә ителгән шигырьләренә юлыктырды.

Г. Тукайның поляк теленә тәрҗемә ителгән дүрт шигыре 1933 елда поляк телендә дөнья күргән «Daleki wschod» («Ерак Шәрык») журналында бастырылган [7: 5]. Татар шагыйренең үлеменә 20 ел тулу уңаеннан әлеге басманың беренче мәкаләсе дә Тукайга багышланган – «Тукай юбилеена» [4]. Аның авторы – галим Хатыйп Миңнегулов сүзләре белән әйтсәк, – «Ерак Шәрыктагы татар мәдәни тормышының үзәгендә кайнаучы, аны оештыручы, нурландыручы фидакяр затларның берсе, Тукайга фидаиләрчә бирелгәнлеген гомере буе саклап калган әдип, шагыйрь, журналист, артист, режиссер, мөгаллим, тәрҗемәче Хөсәен Габдүш (1901–1944) [8: 166–167]. Язмадан күренгәнчә, шагыйрьне искә алу чаралары Манчьжурия, Кытай һәм Япониядә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан югары дәрәҗәдәге тантана рәвешендә оештырыла. Х. Габдүшнең Г. Тукайга багышланган әлеге мәкаләсенең кыскартылган варианты поляк телендәге «Życie» («Тормыш») газетасында да бастырыла [6]. Шунысы кызык: «Daleki wschod» журналының азагында гарәп шрифтында «Безнең барыш» – «Ошбу исемдә Харбинда әледән-әле чыгып торачак татар тормышына багышланган сәхифәләр» урын алган. Биредә сәхифәләрнең идарәсе тарафыннан шулай ук Тукай тантанасы яктыртыла [9]. Кушымтаның икенче мәкаләсе булып Гаяз Исхакыйның «Ерак Шәрык» язмасы урнаштырылган.

«Daleki wschod» журналында поляк теленә Г. Тукайның түбәндәге шигырьләре тәрҗемә ителгән: «Милли моңнар», «Үз-үземә», «Өзелгән өмид», «Туган тел». Кызганычка каршы, тәрҗемәченең исеме күрсәтелмәгән. Галим Г. Червинский фикеренчә, әлеге тәрҗемәләр әдәби тәрҗемә омтылышы булып торалар, әмма рифма, ритм сакланмау да күзәтелә. Шулай ук, галим фаразлавынча, поляк теленә тәрҗемә ителгән шигырьләр рус телендәге тәрҗемәләргә таянып башкарылган.

1938 елгы «Wschod-Orient» («Көнчыгыш») журналының икенче санында поляк телендә Г. Тукайның үлеменә 25 ел тулу уңаеннан Мехмед Вейсинең «Идел-Уралның халык шагыйре Габдулла Тукай» дип исемләнгән мәкаләсе дөнья күрә [5]. Мәкаләдә, укучыларны шагыйрьнең биографиясе белән таныштырудан тыш, аерым шигъри юллар уңышлы тәрҗемә ителгән, рифма сакланган. Әмма тәрҗемәче күрсәтелмәгән. Мәкалә авторы Г. Тукайны милли телне үстерүгә керткән өлеше өчен данлый, «Туган тел» әсәренең исә татар халкының гимнына әйләнүен ассызыклый.

Польша татарлары әдәбияты тарихы буенча хезмәтләре билгеле поляк галиме Гжегож Червинский (соңрак, 2017 елда поляк телендә басылып чыккан поляк-татар әдәбиятының 1918 елдан соңгы тарихы буенча «Мин күчмәннәр ыруыннан» дип исемләнгән монография авторы) 2011 елда «Przegląd Tatarski» («Татар күзәтүе») журналында татар шагыйренә багышланган «Татар халкының бөек шагыйре» мәкаләсендә: «Кызганычка каршы, Польшада Тукай шигърияте белән танышу – шактый авыр мәсьәлә,

чөнки татар әдәбияты буенча поляк телендә басылган публикацияләр юк дәрәҗәсендә», – дип белдерә. Мәкаләдә галим поляк татарларын шагыйрьнең кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштыра. Г. Червинский поляк шагыйре Адам Мицкевичның филомат юллары һәм Г. Тукайның «Дустларга бер сүз» шигъри юллары арасында уртаклык таба. Филомат традицияләре, галим фикеренчә, бигрәк тә «*** Голүмең бакчасыда...» шигырендә ачык чагыла. Шагыйрьнең «Чыршы», «Ай һәм Кояш», «Җәй көнендә», «Иртә» шигырьләрен исә Чеслав Милошның шигъри юллары белән чагыштыра [3: 30].

Г. Тукай шигырьләре поляк теленә соңрак та тәрҗемә ителгән. Алар 2015 елда «Rocznik Tatarów Polskich» («Польша татарларының елъязмасы») басмасында дөнья күргән. «Туган тел», «Бер татар шагыйренең сүзләре» әсәрләрен татар теленнән Антони Саркади, «Хөррият хакында», «Милләтә», «Алтынга каршы», «Шагыйрь», «Күңел», «Нәсыйхәт», «Иртә», «Яз галәмәтләре», «Кичке теләк», «Тәфсирме? Тәрҗемәме?», «Казан» шигырьләрен рус теленнән Муса Чахоровски тәрҗемә иткән [1: 201–214]. Муса Чахоровски – «Rocznik Tatarów Polskich» җыентыгының, шулай ук Польшада дүрт айга бер чыга торган «Przeglad Tatarski» («Татар күзәтүе»), «Lietuvos totoriai» («Литва татарлары») басмаларының редакторы һәм унике шигырь җыентыгы авторы да. Шигырьләр алдыннан Зайонц Гражина Г. Тукай һәм аның иҗаты хакында кыскача мәгълүмат биреп уза [2: 197–199].

ӘДӘБИЯТ

1. Gabdułła Tukaj: Wiersze Rocznik Tatarów Polskich. seria 2. – Tom II (XVI). – S. 201–214.

2. Grażyna Zając. Tatarski to jest poeta // Rocznik Tatarów Polskich. seria 2. – Tom II (XVI). – S. 197–199.

3. Grzegorz Czerwinski. Wieszcz narodu tatarskiego // 2011. – № 1. – S. 29–31.

4. Hussein Abdiusz. W rocznice Tukajowa // Daleki wschod. – 1933. – № 7–8. – S. 1–4.

5. Mehmed Weysi. Abdullah Tukaj, narodowy poeta Idel-Uralu // Wschod-Orient. – 1938. – № 2. – S. 51–54.

6. Tukaj, najwiekszy poeta narodowy Tatarszczyzny // Zycie. – 1933. – 25 czerwca.

7. Ze spuscizny poetyckiej Tukaja // Daleki wschod. – 1933. – № 7–8. – S. 5.

8. Миңнегулов Х. Чит илләрдәге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

9. Тукай тантанасы // Безнең барыш. – 1933. – Апрель. – № 1. – Б. 1–2.

УДК 821.512.145

# ХРЕСТОМАТИЯ Г. ТУКАЯ «УРОКИ НАЦИОНАЛЬНОЙ ЛИТЕРАТУРЫ В ШКОЛЕ» В ВОСПРИЯТИИ Г. ИБРАГИМОВА

***Э.М. Галимзянова, Ф.Г. Файзуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматривается рецензия Г. Ибрагимова на хрестоматию Г. Тукая «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе»). Раскрываются его литературно-критические взгляды на данный труд.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, Г. Ибрагимов, учебная хрестоматия, татарская литература, педагогика.

The article deals with the review of G. Ibragimov on the anthology of G. Tukay «Maktapta milli adebiyat dareslare» («Lessons of national literature at school»). His literary and critical views on this work are revealed.
**Key words:** G. Tukay, G. Ibragimov, educational anthology, Tatar literature, pedagogy.

# Г. ТУКАЙНЫҢ «МӘКТӘПТӘ МИЛЛИ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ» ХРЕСТОМАТИЯСЕ Г. ИБРАҺИМОВ ТӘНКЫЙТЕНДӘ

***Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Габдулла Тукайның 1911 елга нисбәт ителгән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дәреслек-хрестоматиясе укучыларына барып җиткәнче үк, «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 4 гыйнвар санында Галимҗан Ибраһимовның «Декабрь, 28» датасы белән тамгаланган «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле мәкаләсе басылып чыга [1].

Әлеге хрестоматиянең басылу елын төгәл күрсәтүдә ачыклык таләп ителә. Татарстан Республикасы Милли архивында «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларны теркәү дәфтәре» («Книга Казанского временного комитета по делам печати на запись всех вышедших произведений») саклана. Анда Казанда басылган һәр китапның дөньяга чыгу датасы һәм тиражы күрсәтелгән. Шушы дәфтәргә Г. Тукайның дәреслек-хрестоматиясе «1910 ел, 18 декабрь» датасы белән теркәлгән. Ләкин китапның каты тышлыгында 1911 ел дип куелган [5]. Димәк, китапның басылып чыгу һәм халыкка таралу вакытында аермалык бар. Мондый даталар төрлелеге XX гасыр башындагы ел азагында басылган шактый китапларда күзәтелә.

XX гасыр башында укучыларны үз халкының теле, әдәбияты аша матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләрлек хезмәтләрнең булмавы татар теле һәм әдәбиятының фән буларак укытыла башлавында җитди тоткарлык булып тора. Бу чорда мәктәп-мәдрәсәләр алдына ана телендә яңа уку китаплары кирәклеге мәсьәләсе килеп баса. Шушы юнәлештә Тукайның дәреслек-хрестоматиясе күптән көтеп алынган хезмәт булганлыктан, Г. Ибраһимов аңа беренчеләрдән булып игътибар итә. Аның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле мәкаләсе – Тукайның шушы китабына язылган беренче бәяләмә.

Әлбәттә, Тукайга кадәр үк тә бу өлкәдә хезмәт куючы галимнәребез була. Мәсәлән, 1842 елда М. Иванов, милли әдәбият әсәрләре җитәрлек булмаганлыктан, башкорт, кыргыз, Оренбург якларындагы татарлар тормышын өйрәнеп, халык арасында сакланган әсәрләрне, Крылов мәсәлләрен тәрҗемә итеп, тарих, география һәм башка фәннәр буенча төрле мәкаләләрне үзенең «Татарская хрестоматия» китабына туплап бирә. 1859 елда С. Кукляшевның татарча-русча сүзлектән һәм халык телендә йөргән хикәяләр, мәкальләр, җырлардан гыйбарәт «Диване хикәяте татар» хезмәте басыла.

XIX йөзнең икенче яртысында хрестоматияләр төзү активлашып ала. К. Насыйриның «Буш вакыт» (1868), В.В. Радловның «Белек» (1872), Г. Рахманколыйның «Тәнбиһес-сыйбиян» («Сабыйларның зиһененә салу», 1898), Х. Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» (1890) һәм 1904 елда Касыйм Бикколовның «Нәмүнәи тәрәкъкый» («Алга бару өчен юл күрсәткеч») хезмәтләре дөнья күрә [2].

Әлеге дәреслекләр барысы да дидактик характерда булганлыктан, замана таләпләренә җавап бирмиләр. Шуңа күрә дә Г. Ибраһимов үзенең мәкаләсен «Күптән көтелгән вә теләнгән нәрсә, ниһаять, вөҗүдкә килде», – дип башлый һәм, – бу бабта Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан иң беренче адым атланды», – дип, дәреслекнең әһәмиятен ассызыклый [1].

Алдагы хрестоматиялəрдəн аермалы буларак, Тукай укучыларны шул чорда иҗат иткəн 26 татар язучысының исеме белəн таныштыра, аларга татар əдəбиятының төрле жанрларын иңлəгəн əсəрлəр, тарихи язмалар тəкъдим итə.

Китап Гафил бине Габдулланың «Сəлимə» əсəреннəн вəгазъ белəн ачыла. Анда З. Һадиның «Мəгъсүм», Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Телəнче кызы», «Корбан гаете», «Калуш», Ф. Əмирханның «Татар кызы», Ф. Кəриминең «Салих бабайның өйлəнүе», С. Максудиның «Мəгыйшəт» кебек əсəрлəреннəн өзеклəр урын алган. Поэзия үрнəклəреннəн Тукайның «Туган илемə», «Китап», «Җəйге таң хатирəсе», «Кабан күле төбе» («Кисекбаш»тан), «Бəйрəм вə сабыйлык вакыты», «Хикмəтле этəч» («Алтын этəч»тəн) кебек əсəрлəре, шулай ук М. Гафуриның «Яшь гомерем»еннəн өзек, «Электрик фонарена хитаб», М. Кəримбаевның «Бəхет», М. Укмасыйның «Таң», С. Рəмиевнең «Минутлар», З. Бəширинең «Болыт» шигырьлəре кертелгəн. З. Бигиев, З. Акчурина-Гаспринская, Г. Барудиларның тəрҗемəи хəллəре, Г. Əхмəровның «Казан каласының ничек салынганлыгы хакында бер хикəя», «1445 нче елны Казанның яңадан яңаруы һəм Казан падишаһлыгының башлануы» һəм «Иван Грозный тарафыннан Казан каласының мөхасирəсе (чолганышта калуы) һəм алынуы» дигəн язмалары һəм тəрҗемə үрнəклəре, милли мəкальлəр урнаштырылган.

Г. Ибраһимов бəялəмəсендə «əсəрнең эчен актарудан» элек, мондый мəҗмугаларны төзегəндə алга куелырга тиешле максатларны барлап китə. «...алынган парчаларның милли оригинальный һəм əдəбияты нəфисəдəн булмактыр». Һəм «...əдəбияты нəфисə эченнəн сайлауда да, соңгы агышларга нəзарəн, бернəрсə хакында вəгазе тəгълим түгел, хəтта тəгълиме əхлак та монда баш иттерелми, монда күзəтелгəн нəрсə алынган əдəби кисəкнең художественный һəм балага аңлаешлы, рухына яраклы, бигрəк тə мөһиме – анда гүзəл хислəр вə матур мəеллəр кузгатылырлык булуыдыр», – дип, төп ике шартны күрсəтə.

«Мəктəптə милли əдəбият дəреслəре»н баштанаяк күздəн кичергəннəн соң, əдип «мөəллифнең күзəттеге нəрсə əдəбияты нəфисəмезнең художественный парчаларын җыю түгел, бəлки вəгазь вə фəлсəфə чүплəгəн икəн диярлек урыннары күптер» дигəн нəтиҗəгə килə. Шунлыктан, җыентыкка кертелгəн тəрҗемəи хəллəрне, тарихи парчаларны, төрле үгет-нəсихəткə корылган өзеклəрне Г. Ибраһимов биредə урынсыз дип таба. Җыентыкка кергəн өзеклəр арасыннан Ф. Кəрими һəм З. Һадидан алынганнарын гына чагыштырмача зарарсыз, Г. Исхакыйдан, Ф. Əмирханның «Татар кызы»ннан алынганнарын гына яхшы ук уңышлы дип саный.

1914 елда Г. Ибраһимов үзе дə Г. Баттал белəн берлектə «Яңа əдəбият» исемле дəреслек төзеп бастыра. Г. Ибраһимов Г. Тукайның «Мəктəптə милли əдəбият дəреслəрен» үзе санап чыккан кимчелеклəрсез ничек күз алдына китергəнсə, «Яңа əдəбият»ны шул рəвешле төзи.

Бу дəреслек-хрестоматиядə барлыгы 30 авторның 121 əсəре, яки тулысынча, яки өзеклəр рəвешендə урнаштырылган. Һəр əсəрнең авторлары билгеле булса да, аларның кайсы əсəрдəн алынулары күрсəтелмəгəн. Күп очракта өзеклəргə исемнəр, темасына туры китереп, төзүчелəр тарафыннан куелган.

Җыентыкта күбрəк Г. Тукай, М. Гафури, М. Укмасый, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Əмирханнарның балалар рухына туры килə торган

әсәрләренә мөрәҗәгать ителгән. Шул ук вакытта исемнәре аз билгеле булган Ф. Туйкин, М. Атлаши, И. Шәммаси, К. Хамадев кебек авторлар да җыентыкта урын алганнар [3].

Төзүчеләрнең төп максаты татар әдәбияты белән киң рәвештә таныштыру булганга, җыентыкка тәрҗемәләр кертелмәгән, әдәбиятның мөстәкыйль бер дәрес булып китүенә сәбәп булсын өчен, фәнни язмалар алынмаган, сайланган әсәрләрдә тел, өслүбнең матур һәм әдәби булуын күрсәтү җәһәтеннән бары «яңа әдәбият» үрнәкләренә генә мөрәҗәгать ителгән.

Бу урында тагын бер фактка игътибар итмичә мөмкин түгел. Г. Ибраһимов «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»енә бәяләмәсендә Тукайның үз әсәрләрен әлеге җыентыкка кертүе хакында ачык фикерен чагылдырмый. Тукай шигырьләре шактый алынуга да карамастан, «Балалар күңеле»ннән алырга ни манигъ *(киртә)* булды икән?» – дип кенә куя [1]. Г. Ибраһимовның Г. Тукайга мөнәсәбәте аның 1913 елда язылган «Татар шагыйрьләре» [4: 157] мәкаләсендә ачык күренә. Биредә әдип, «Тукай шагыйрьме, түгелме? дип, Тукай шигъриятен берникадәр шик астына ала. Г. Ибраһимов Тукайның халык шагыйре булуын таный. Аның халыкчан булуын, халык мәнфәгатьләрен, иҗтимагый мәсьәләләрне яктыртуын да хуплый. Әмма бу елларда үзен романтик әсәрләр, хикәяләр язучы буларак таныткан Г. Ибраһимов Тукайның шигъриятендә хиссият, мәхәббәт, табигать лирикасы күрергә тели. Шул ук вакытта ул «Шигырьдә соң гел назик вә мөәссәр хисләр... шигъриятә сыймыймыни?» сөале килергә мөмкин, дип, үзалдына сорау да куя. «Шигырьдә әхлакый, теләсә фәлсәфи вә иҗтимагый булсын – әллә нинди мәгънәләр, фикерләр булырга бик тә мөмкин, тик шагыйрь, үзенең ялчысына йомыш кушкан бай кебек, үз авызыннан: «Менә акча, бар базарга, бәрәңге ал... – дигән шикелле туп-туры әйтеп, шигъриятә зарар китерелмәве шарт», – ди [4: 159]. Г. Ибраһимов «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясенә әсәрләр сайлаганда да Тукайда шул нәзакатьлелек, шул хиссиятнең җитмәвен күрсәтә. Шулай да үзе дәреслек төзегәндә, иң беренче чиратта аның шигырьләренә мөрәҗәгать итә һәм китапның күп өлешен дә Г. Тукай әсәрләре биләп тора.

Г. Тукай да, Г. Ибраһимов та үзләренең дәреслек-хрестоматияләренең кереш сүзендә русларның «Живое слово» хезмәтенә таянулары хакында язалар. Димәк, алар икесе дә А.Я. Острогорскийның 1907 елда Петербургта басылган «Живое слово» исемле рус әдәбиятыннан хрестоматияне үрнәк итеп алганнар. Г. Тукайның 1909 елда басылган үз әсәрләреннән генә торган «Яңа кыйраәт» җыентыгы да рус мәктәпләре тәҗрибәсеннән, К.Д. Ушинский, Л.Н. Толстой дәреслекләреннән файдаланып төзелгәнлеге билгеле.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»ннән аермалы буларак, «Яңа әдәбият» тулысынча «Живое слово» нигезендә төзелгән. Җыентыкка матур әдәбият үрнәкләре, авыл баласының рухына туры китереп, рус әдәбияты хрестоматиясендәге кебек, ел фасыллары тәртибендә урнаштырылганнар.

Тукай, «Живое слово» китабын үрнәк итеп алдым дисә дә, аның кысаларыннан чыгып китеп, дәреслекләрнең эчтәлеген киңрәк планда күзаллый. Китабына биографик әсәрләрне дә, тарихи, географик хикәяләрне, тәрҗемәләрне, халык-авыз иҗатыннан мәкальләрне дә урнаштыра. Бу хакта Ибраһимов: «“Исемдә калганнар” кергән. Моны кертүнең сәбәбен аңлап

булмый... Заһир Бигиев, Зөһрә ханым вә Галимҗан хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлләрен күргәч, тагы аптырыйсың», – дип гаҗәпләнә. «“Сәлимә”дән “Казан” парчасын алырга ни нәрсә иҗбар итте *(мәҗбүр итте)* икән? Аны җәгърафия мөгаллиме сөйләр иде, “Гасры сәгадәт” кебек сыйрыф тарих сияргә гаид бернәрсәгә урын бирә. Бу бит ят. Бу тарих китабы түгел ич», – дип, шагыйрьне тәнкыйть утына ала. Шул ук вакытта: «Милли мәкальләрне кертергә онытмавы бик яхшы булган исә дә, аларны өеп китерү бик үк мөнасиб түгел...» – ди [1].

«Бу китап өчен мин үземчә яхшы вә матур дип белгән кыйтга вә шигырьләрне генә сайларга тырыштым, – ди Г. Тукай. – Русларның “вкуста шарик юк” (зәвыкта иптәшләр юк) дидекләренчә, бәлки, минем бу интихабымны *(сайлап алуымны)* тәнкыйть итүчеләр булыр, ләкин мин андый кешеләргә алдан ук:

...Кеше теләсә ни әйтсен,
Үземнең җаным сөйгәч, –

дип җырлап кына җавап биреп куям», – дип, тәнкыйтьчеләргә алдан ук җавабын да бирә [5: II] һәм Г. Ибраһимовның бәяләмәсенә үз мөнәсәбәтен белдерүне кирәк тә тапмый.

Күргәнебезчә, Г. Тукай белән Г. Ибраһимовның әдәбияттан дәреслекләр төзүдә фикерләре төрлечә булган. Тукай дәреслекләрнең эчтәлеген киңрәк планда күзаллап, анда биографик әсәрләрне дә, тарихи, географик хикәяләрне, тәрҗемәләрне, халык-авыз иҗатыннан мәкальләрне дә урнаштыруны уңышлы саный. Беренчедән, әлеге дәреслек аша балаларга рухи азык, тәрбия бирүне максат итеп куйса, икенче яктан, әдәбиятыбызның Русия мөселманнары арасында таралуына да өмет итә. Шуңа да хрестоматиягә жанр ягыннан да, тематика ягыннан да төрле әсәрләрне урнаштырырга омтыла. Г. Ибраһимовның исә, дәреслекләр төзүгә карашы үзгәрәк була. Аның фикеренчә, дәреслеккә урнаштырыласы әсәрләрнең милли үзенчәлекле һәм матур әдәбияттан булуы шарт. Әсәрләр балага аңлаешлы, рухына яраклы, балада гүзәл хисләр һәм матур уйлар кузгатырлык булырга тиеш.

Ничек кабул ителүләренә карамастан, XX гасыр башында әлеге дәреслек-хрестоматияләр мәктәп-мәдрәсәләрдә ана теле дәресләре укытыла башлауда зур роль уйнаганнар. Алар киләчәктә төзеләсе дәреслекләрнең төп нигезен тәшкил иткәннәр. Иң мөһиме, милли әдәбиятыбызның үсүенә һәм таралуына, балаларда милли үзаң тәрбияләүгә зур йогынты ясаганнар.

## ӘДӘБИЯТ


1. Габди. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» // Йолдыз. – 1911. – 4 гыйнвар.

2. Галимзянова Э.М., Файзуллина Ф.Г. Структурно-жанровые особенности «Уроков национальной литературы в школе» Г. Тукая // Современные исследования социальных проблем. – 2019. – Т.11. – № 1–2. – С. 49-54.

3. Ибраһимов Г., Баттал Г. Яңа әдәбият. – Казан: «Сабах», 1914. – 230 б.

4. Ибраһимов Галимҗан. Татар шагыйрьләре // Әсәрләр. Академик басма. 15 томда. 6 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр, 2019. – 327 б.

5.Тукаев Габдулла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: «Мәгариф», 1911. – 144 б.

УДК 821.512.145.0

# ВЗАИМОТНОШЕНИЯ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ И ЕГО НАСТАВНИКА МОТЫГУЛЛЫ ХАЗРАТА В ВОСПОМИНАНИЯХ ГАЛИИ КАЙБИЦКОЙ

***Ф.Г. Галимуллин***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье исследуются взаимоотношения будущего великого татарского поэта Г. Тукая с его тнаставником Мотигуллой хазратом в городе Уральске, где он приобщился к творчеству и был признан талантливым поэтом в начале XX века.
**Ключевые слова.** Татарская литература, Габдулла Тукай, Мотигулла хазрат, Уральск.

The article examines the relationship of the future great Tatar poet G. Tukai with his mentor Motigulla khazrat in the city of Uralsk, where he joined creativity and was recognized as a talented poet at the beginning of the twentieth century.
**Key words:** Tatar literature, Gabdulla Tukai, Motigulla khazrat, Uralsk.

# ГАЛИЯ КАЙБИЦКАЯ ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ АНЫҢ ОСТАЗЫ МОТЫЙГУЛЛА ХӘЗРӘТ

***Ф.Г. Галимуллин***
*Казанский (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Җаек ахуны Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның халкыбыз өчен кылган игелекле гамәлләре бихисап. Аның бөек шагыйребез булачак Габдулланы кеше, шәхес һәм шагыйрь буларак тәрбияләп үстерүдәге хезмәте бүген аеруча хөрмәт белән тәкъдир ителергә тиеш. Халык артисты, күренекле җырчы Галия ханым Кайбицкая үзенең истәлек язмаларында бу хакта еш искә ала. Без аның хатирәләре буенча хатирәләрне бер эзлеклелектә бирүне максат итеп куйдык.

Мәгълүм булганча, Кайбыч егете Мотыйгулла, Кышкар мәдрәсәсендә укыганда, Кушлавыч авылыннан килгән Мөхәммәтгариф белән шәриктәш була (Үзенең улларының берсенә Гариф исеме кушуы да шушы дуслык хөрмәтенә була. Сүз уңаенда әйтик, Гариф Төхфәтулла улы 1909–1913 елларда Казанда укытучылар мәктәбендә укый. Аннан соң күп еллар Җаекта укытучы булып эшли. Советларның IX Бөтенроссия съездында делегат була. Лаеклы ялга чыккач та төрле уку йортларында лекцияләр укый). Каһирәдән укуны тәмамлап кайтып, Җаекта урнашып күпмедер яшәгәннән соң, Мотыйгулла Кушлавычтагы дустына хат яза. Мөхәммәтгариф та аңа үзенең авырып китүе турында хәбәр җибәрә. Бу аның соңгы хаты була. Байтак вакыттан соң, шәриктәшенең вафаты турындагы хәбәрне ишетеп, Мотыйгулла кайгылы хисләр кичерә.

Күрәсең, Кушлавыч мулласы өендә Мотыйгулла исеме еш телгә алынган. Мөхәммәтгариф хатынына дустын әйбәт яктан сөйләгән булырга тиеш. Үләр алдыннан Мәмдүдә абыстай шушы исемне телгә ала. Габдулласының аның кебек кеше кулында тәрбияләнергә теләвен әйтеп калдыра. Болай дип әйтү өчен, Мотыйгулланың яхшы кеше булуына күңеле ышанган булу кирәк. Ә үзенең Сасна Пүчинкәсендәге ирен баласына ата булырга яраклы дип санамаган, күрәсең (Сүз уңаенда әйтәсе килә, әгәр дә шушы ир, үги бул-

са да, малайны үз күреп тәрбияләгән очракта Габдулла бер өйдән икенчесенә, бер урыннан башка җирләргә йөреп азапланмаган да булыр иде дә бит, әмма нихәл итәсең, кагылып-сугылып йөрүләр, «азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем» дип әйтүгә китергән хәл-әхвәлләр ләүхелмәхфүздә (аның язмыш тактасына) язылгандыр, күрәсең.

Баланың ятим калуын белү Мотыйгулланы авыр кичерешләргә сала. Аның язмышын ничек тә җиңеләйтергә кирәклеген үзенең намус эше икәнлеген аңлый. Сүз дә юк, ул баланы турыдан-туры үз карамагына алыр иде. Әмма балага кан-кардәшлек ягыннан якынрак кешеләр бар бит. Алардан узу яхшы булмас. Әйтик, Җаекта Габдулланың әтисе ягыннан апасы яши. Җизнәсе белән апасы ару тормышлы кешеләр. Мотыйгулла малайга җизни тиешле Галиәсгар янына китә. Бу гаилә әле яңа гына зур кайгы кичергән икән, малайлары үлеп киткән. Малай урынына малай булыр дип, алар Мотыйгулланың Габдулланы уллыкка алырга дигән киңәшен мәгъкуль күрәләр.

Габдулланың ни рәвешле Җаекка килгәнлеген шагыйрьнең «Исемдә калганнар» әсәреннән яхшы беләбез.

Галиәсгар җизнәсе Габдулланы үз баласыдай әйбәт каршы ала. Укырга Мотыйгыя мәдрәсәсенә урнаштыра. Шул ук аңа вакытта русча уку мөмкинлеге дә тудырыла. Әмма Газизә апасы тора-бара балага кырынрак карый башлый. Күңеле сизгер ятим бала моны авыр кичерә. Остазы Мотыйгулла хәзрәттән рөхсәт алып, торырга да мәдрәсәгә күчеп килә. Җизнәсе үлеп киткәч, бала бөтенләй Мотыйгулла карамагында кала.

Кечкенә Габдулла Мотыйгулланың җылы мөнәсәбәтен әллә каян ук сизә. Шушы ачык күңелле остазын күрү өчен, көн саен мәдрәсәгә килер вакыты җиткәч, аның каршысына чыга, бу ир кешегә сыенасы килә. Мотыйгулла да төрле юллар белән якынлыгын сиздерә, үз йортына килеп йөрергә куша. Балаларын да Габдулланы якын итү кирәклегенә ышандыра. Мөхәммәтгариф дустының баласын үз өенә ияләштерүгә ирешкәч, Мотыйгулла хәзрәт тәмам тынычланып, бурычын үтәгәннән соң була торган канәгатьләнү кичерә.

Мотыйгулла үз чорының алдынгы карашлы кешесе булу ягыннан аерылып тора. Бөтен көчен игелекле эшкә салырга тырыша: мәдрәсәсендәге программаны баетып тора, кызларны укыта башлауны оештыра. Татар мәктәбенең заман таләпләренә җавап бирүен тәэмин итәрә омтылучы новатор карашлы кеше була. Укучы кызлар һәм малайларның төрле яклап сәләтләрен ачарга тырыша. Мәсәлән, кызларның да күмәкләп җырлауларын оештыра. Җыр текстларының кайберләрен хәтта үзе язып бирә. Җаек якларында аның кайбер җырлары мәдрәсәдән тыш та кеше телендә йөри:

Хәзер заман – шундый заман:
Укымаган эттән яман.
Укыт мине, газиз атам,
Укымасам, надан калам.

Укымасын ирләр генә,
Надан калмыйк безләр генә.
Ирләр генә белсен дигән
Сүздән кеше көләр генә.

Аннан соң газета-журнал чыгару хәстәренә керешә. Бу яңа эшкә үз мәдрәсәсендә укучы яшьләрне тарта. Шәкертләре белән мәкалә, хәбәрләр язу буенча дәресләр уздыра. Хәтта аеруча талантлыларын шигырь язарга

өнди, хәреф җыючы һөнәрен алу белән кызыксындыра. Габдуллада исә остаз шагыйрьлек көче сизә. Аның беренче тәҗрибәләрен хуплый, канатландырып тора. Каһирәдән кайткан Камилгә аның «язуга остаруы» турында әйтә. Габдулла Мөхәммәтгарифов һәм Җаектагы иҗатка омтылучы яшьләр кулъязма газета-журналлар да чыгара башлыйлар. Алар төрле урыннардагы татар язучыларына хатлар язалар, шул мөхтәрәм шәхесләр белән элемтәләр урнаштырырга телиләр. Бу хакта безгә Мотыйгулла хәзрәтнең кече кызы Галия апа кулындагы язма документлардан укырга туры килгән иде. Ә инде Камил кайткач, аның исеменә этисе ачып биргән типографиядә «Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» кебек газета-журналлар чыгару төпле нигезгә куела. Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ш. Мөхәммәдев кебек исемнәре танылган авторлардан әлеге матбугат органнары өчен махсус язылган әсәрләр, материаллар килә һәм басыла башлый.

Әлбәттә, Габдула өчен дә бу басмалар шигырьләре, мәкаләләре дөньяга чыгу мәйданы булып хезмәт итә. Яшь Габулла язган әсәрләрен баштарак Мотыйгулла хәзрәткә күрсәтеп ала, ул хуплагач, әлеге матбугат органнарында урнаштыра. Әмма мондый басмаларның чыга башлавына каршылык күрсәтүче көчләр дә юк түгел. Төп һөҗүм типография хуҗасы Камил Мотыйгыйга каршы юнәлдерелә. Максатлары – аның бу эштән күңелен кайтару. Әмма Камил белән Габдулла мондыйларга игътибар итмәскә тырышалар. Теләгән әйберләрен курыкмыйча басалар, халык та аларны кызыксынып укый. Шулай да аларга вакыт-вакыт шактый басым астында эш итәргә туры килә. Нәкъ шушы хәлләр Габдуллага җәмгыяттәге төрле катламнарның ниндилеген аеруча ачык аңларга ярдәм итә. Камил белән Габдулла хәтта рус телендә басма булдыруга ирешәләр. Ул «Уралец» дип атала. Тукай биредә русчага тәрҗемә итү буенча да тәҗрибәләр ясый. Газета-журналларга булган һөҗүм бер генә көнгә дә тукталмый. Каршы көчләр шикәяте буенча К. Мотыйгыйның типографиясе һәм «Уралец» газетасы ябыла. Хәтта К. Мотыйгый ирегеннән дә мәхрүм ителә. Дини юнәлештәге басмалар да Җаек тәрәккыйпәрвәрләрен тынычлыкта калдырмый. Г. Тукай бу күңелсезлекләрдән соң «Мөхәрриргә» дигән шигырь дә яза.

Китмәсен кәефең, мөхәррир, денсез дисәләр дә;
Син аларга бал биргәндә сиңа агу бирсәләр дә.

Һәр заман хакны сөючеләр сездәй каһәрләнгән булыр;
Килер бер көн: милләтең сиңа шәфкатен күрсәтер.

Әйе, яшьләр куркуны белмиләр. К. Мотыйгый, төрмәдән азат ителгәч, яңадан газета чыгару артыннан йөри. Ул Г. Тукай белән берлектә «Яңа тормыш» исемле басма булдыру эшенә керешә. Әмма бу юлы К. Мотыйгый, патша хакимиятенә каршы кеше дип саналып, Җаектан ук куыла.

Ата улының хак эшен яклап чыга. Тик бу Мотыйгулла хәзрәткә каршы һөҗүм оештыру өчен уңайлы сәбәп булып чыга. Яше җитмәгән улыңа типография ачарга рөхсәт алып биргәнсең дигән сылтау белән аның муллалык итү хокукын юкка чыгаралар, үзенең төрмәгә ябылу куркынычы туа. Аңа бары тик мәдрәсә укытучысы булып кына калырга туры килә. Бу исә аңа мәдрәсәдә үзе башлаган уңай үзгәрешләрне дәвам иттерергә комачаулый. Ник дисәң, ул инде баш мөдәррис түгел, бары гади укытучы гына.

Мотыйгулла үзенең яшәү рәвешенә дә яңалыклар өстәп торырга ярата. Янгыннан соң салынган йортына электр кертә, анда пианино һәм скрипка тавышларын еш ишетергә туры килә. Камил белән Габдулла биредә әдәби-

ят кичәләре уздыргалыйлар. Камил тумыштан җырга сәләтле була, аны үз чорының күренекле җырчысы дип санарга була. Кичәләрдә Габдулла шигырьләр укый, Камил исә җырлый. Чыгыш ясау өчен шәһәрдәге башка талантлы яшьләр дә җәлеп итеlә.

Әйтик, шәһәрнең Югары оч мәдрәсәсендә Миңлебай Хәйруллин дигән шәкерт укый. Габдулла көннәрдән бер көнне шул мәдрәсәгә бара, әлеге шәкертне очрата һәм алар танышып китәләр. Миңлебай укымышлылыгы белән карый (ягъни «Коръән»не яттан белүче, аны тирән аңлаучы һәм аңлатучы) дәрәҗәсен алырлык әзерлекле егет була. Шулай да Габдулла аның сөйләшүендә, күз карашларында, аралашу үзенчәлекләрендә, фикерләвендә бу егетнең дин белән генә мәшгуль булмаска тиешлеген аңлый. Миңлебайны әдәби-музыкаль кичәгә чакырып кайта. Килә Миңлебай. Карый буласы кешегә авыз күтәреп җырлаучыларны тамаша кылу ничектер җайсыз кебек тоелса да, ахырга кадәр утыра. Шуннан соң ул әлеге кичәләргә тагын да килә башлый. Күңеле үзгәреп китә. Тора-бара үзенең дә биредәге халык алдында нәрсә дә булса эшлисе килә башлый. Габдулла аңа үзенең бер көлкеле әсәрен бирә. Икенче көнне Миңлебай аны яттан сөйли. Үзенең биредәгеләр арасында иң оста сөйләүче икәнлеген күрсәтә. Ул инде даими чыгыш ясый башлый, осталыгы да арткannan-арта бара. Мондый чыгышлар аның үзенә дә ошый башлый, ул алардан иҗади ләззәт ала. Бу хәл ул укыган мәдрәсәгә дә ишетелә. Шушы эшләре өчен аны биредән куып чыгаралар. Чөнки нәфис уку дин әһеле буласы кеше өчен ниндидер кирәкмәгән гамәл булып бәяләнә. Миңлебайның бу хәлгә артык исе китми. Ул кадими мәдрәсәдән сәнгать юлына кереп китүне бу очракта артыграк күрә.

Баштарак алар Г. Тукай белән бергә «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә торалар. Аннан икесе дә кунакханәгә күчәләр. Шушы вакыттан алып Миңлебай да үзен Габдулла дип атый башлый. Соңыннан исә фамилиясен Кариев дип үзгәртә – ягъни Габдулла Кариев булып китә. Шушы тәхәллүс белән ул татар профессиональ театры тарихында үзенең күренекле урынын ала.

Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камил эзәрлекләнә башлагач, Габдуллалар да Җаекта тыныч кына яшәп кала алмыйлар. Г. Кариев артистлык юлыннан китә, К. Мотыйгый җырчы булып ил буйлап гастрольләрдә йөри, Г. Тукай исә Казанга таба юл ала.

Габдулла Казанда, остазы һәм әтисенең дусты Мотыйгулла хәзрәт белән аның хатыны Гыйззинас биргән адрес һәм хат буенча, аларның якын танышлары Хафиз белән Маһирә гаиләсенә килеп төшә (Ул йорт XX йөзнең җитмешенче елларында университетның хәзерге татар факультеты бинасы урнашкан күп катлы бинаны салганда сүтелде). Шулай итеп, Г. Тукай биредә дә Мотыйгулла гаиләсенең дус-ишләренә килеп сыена.

1909 елда Мотыйгулланың малае Гариф та Казанга килә. Габдулла аны пристаньда каршы ала. Әлеге малай да шушы Хафиз-Маһирә гаиләсендә тора. Гариф аның белән аралашып яши. Габдулла абыйсына аның әсәрләрен акка күчереп язуда булыша, башка йомышларын үти.

Мотыйгулла белән Гыйззинас күчтәнәчләрне Җаектан икесенә дә атап җибәрәләр. Г. Тукайның сәламәтлеге бөтенләй начарлангач, әлеге Хафиз абыйсы белән берлектә авыруны Клячкин хастаханәсенә илтеп салышучы да Гариф була. Бу турыда Гариф әти-әнисенә хат та яза. Бу хатны алгач, Гыйззинас ханым белән килене (Камил хатыны) Казанга килеп җитәләр. Алар Габдулланы күмүдә катнашып, иңнәренә зур хәсрәт төяп кайтып китәләр.

Шул рәвешле, 1895 елдан алып вафатына кадәр Габдулла Мөхәммәтгариф улының хәяте Мотыйгулла хәзрәт гаиләсе белән шактый эзлекле һәм даими бәйләнештә була. Аның тиз арада шагыйрь булып танылуында да Мотыйгулла дигән затлы шәхес тудырган шартларның әһәмияте зур булды.

Мотыйгулла Төхфәтуллин 1920 елда вафат була. Аны Җаек халкы шулкадәр хөрмәт итә, җәсаден дә Кызыл мәчет ишек алдындагы бакчада җирлиләр. Әмма байтак еллар үткәч, кызы Галия һәм оныгы Хәмит (Камилнең улы) тарафыннан гомуми зиратка күчереп күмелә. Билгеле булганча, 2001елның 29 октябрендә безгә, ягъни бу юлларның авторы белән шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Р. Хариска, Җаекка Г. Тукайга һәйкәл ачу тантанасында катнашу өчен барырга насыйп булды. Бер уңайдан без, әлбәттә, Мотыйгулла хәзрәтнең каберен дә зыярәт кылдык. Габдулла Тукаебызга һәм гомумән халкыбызга бик күп игелекләр эшләргә өлгергән хәзрәтебез кабере алдында баш идек.

УДК 821.512.145

## ОБРАЗ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ РЕНАТА ХАРИСА

***А.Ф. Галимуллина***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Личность и творчество Габдуллы Тукая сопровождает народного поэта Республики Татарстан, лауреата Государственной премии имени Г. Тукая Рената Хариса на протяжении всего его творческого пути. В стихотворениях, в литературной критике, в поэме «Любовные сны Г. Тукая» («Тукайның мәхәббәт төшләре»), в либретто к опере Резеды Ахъяровой «Любовь поэта» Ренат Харис обращается к классику татарской поэзии как к эталону самоотверженного служения Поэзии, как воплощению высокой нравственности. В статьях и художественных произведениях Рената Хариса раскрывается значение наследия Г. Тукая для развития современной литературы.
**Ключевые слова:** татарская литература, татарское литературоведение, Габдулла Тукай, Ренат Харис, татарская поэзия

The personality and work of Gabdulla Tukai accompanies the People's Poet of the Republic of Tatarstan, laureate of the State Prize named after G. Tukai Renat Haris throughout his entire career. In poems, in literary criticism, in the poem «Love Dreams of G. Tukai» («Tukainyң məkhəbbət tushləre»), in the libretto for Reseda Akhyarova's opera «The Love of a Poet» Renat Kharis refers to the classic of Tatar poetry as a standard of Poetry of selfless service, high morality. In the articles and works of art by Renat Haris, the significance of G. Tukay's heritage for the development of modern literature is revealed.
**Key words:** Tatar literature, Tatar literary criticism, Gabdulla Tukai, Renat Kharis, Tatar poetry

Народный поэт Республики Татарстан Ренат Харис не ограничивается поэзией, подкрепляя свое художественное творчество и литературно-критическими статьями. Не является исключением в этом плане и творчество классика татарской поэзии Габдуллы Тукая (1886–1913). В статьях «Пусть сольются мысль и труд (К 100-летию со дня рождения Габдуллы Тукая)», «О поэтическом мире Тукая и о гениальном (К 125-летию со дня рождения)», во многочисленных интервью современный поэт дает оценку личности и поэтическому наследию Габдуллы Тукая. Например, в статье

«О поэтическом мире Тукая и о гениальном» Ренат Харис отмечает: «юноша в 20 лет дерзнул сформулировать и задать самому Всевышнему несколько таких вопросов, которые могут поставить в тупик и высокообразованных философов современности:

Почему ты, Боже, столь разными создал людей?
Почему я ничтожней ничтожнейшей твари твоей?..
Иль во мне и начало и устье потока скорбей?..
Иль таит в себе ад эта жалкая связка костей?..
Слышишь, Господи? Я вопрошаю, ответь мне скорей!..
Ибо разум мой тёмен, не может он справиться с ней…
Не в моей ли недоле злосчастного мира исток?
Не родиться бы вовсе – так было б, пожалуй, умней…

По глубине проникновения в суть явлений, по мастерству оформления мыслей, особенно в оригинале стихотворения, Тукай предстает перед нами как высоко образованнейший, зрелый человек. А в стихотворении «Не стану мелочиться» он не только задаёт вопросы, даже предлагает себя Всевышнему в качестве помощника:

Это солнце пусть погаснет, я взойду ему взамен.
Люди путь по мне сверяют далее свои часы…

Это – подстрочник, а в переводе М. Талова, к сожалению, ничего этого нет» [7: 13]. Показательно, что по глубине постановки философских вопросов, по мнению Рената Хариса, Г. Тукая можно с полным правом сопоставить с мировыми поэтическими именами: Г.Р. Державиным, А.С. Пушкиным, М.Ю. Лермонтовым, Дж. Байроном, Ф.И. Тютчевым, Бараташвили, Кандалыем, Дэрдмендом, Джалилем, Сеспелем. В качестве примера современный татарский поэт сравнивает выше процитированные строки Г. Тукая со строчками Несими и Г.Р. Державина: «Стихотворения «Вопросы» и «Не стану мелочиться» по своей философской глубине, простоте и чёткости изложения, поэтическому накалу и страстности созвучны с произведениями не только средневековых гениев восточной поэзии, скажем, Несими, сказавшего: «В меня вместятся оба мира, но в этот мир я не вмещусь», но и с гениальным стихотворением Гавриила Державина “Бог”, где он осмеливается сказать Всевышнему: “Я есмь – конечно, есть и Ты!”» [7: 13].

Ренат Харис, на примере поэзии Габдуллы Тукая размышляет о природе гениальности и приводит убедительные доказательства сопоставимости поэтических образов татарского поэта начала XX века с выдающимися русскими поэтами такими, как Г.Р. Державинии и М.Ю. Лермонтов, в художественном осмыслении образа космической тишины и безграничного звёздного неба:

«Вот как выглядит подобный образ 20-летнего Тукая в переводе Анны Ахматовой:

Свет вечерний тих и ласков, под луною всё блестит,
Ветерок прохладный веет и ветвями шевелит.
Тишина кругом, только мысли что-то шепчут мне,
Дрёма мне глаза смыкает, сны витают в тишине…» [1: 14].

Вывод Рената Хариса однозначен и категоричен: «В этой тишине Лермонтов внимает Богу и слышит разговоры звёзд, а Тукай слышит, как сказано в оригинале, *пение* собственных мыслей и *чтение* ими чего-то. Обратите внимание – *пение мыслей!* У Тукая, как и у Державина, космос в нём самом.

Космос души Тукая по своим масштабам ничуть не уступает вселенскому Космосу.

О, взойди, светило мысли! Туча, прочь уйди скорей!
Совесть мёртвую, о солнце, оживи, лучом согрей!..
Мой светильник несравненный, драгоценная свеча!
Что мне светочи Вселенной, если ты не дашь луча?

Но самым ярким подтверждением вселенской души Тукая, как мне кажется, являются строки стихотворения “Разбитая надежда”:

Посчитав тесной клетку мира, птица души вылетела из неё,
Хоть и создал Аллах её в радости, но для вселенной чужой»
(Курсив – Рената Хариса) [1: 14]

Такая полемически обостренность, нарочитая публицистичность статьи Рената Хариса объясняется сомнениями в гениальности Габдуллы Тукая, которые иногда высказывают читатели, воспринимающие татарского классика через переводы на другие языки. В частности, Ренат Харис упоминает такой случай: «Однажды произошел случай, который не дает мне покоя и по сей день. Дело в том, что мы получили письмо из одной прибалтийской республики, в котором говорилось о том, что по переводам произведений Тукая на русский язык нельзя сказать, что он действительно велик, что Тукай им кажется обычным поэтом. Этот ответ, наверное, был частным, искренним, честным, но мог бы быть и более доказательным. Он заставил меня ещё глубже погрузиться в творческий мир Тукая» [1: 14].

Убедительно раскрывая гениальность и своевременность поэзии Г. Тукая, Ренат Харис дает свои построчные переводы стихотворений поэта-классика, попутно сравнивая с переводами М. Талова, А.А. Ахматовой, показывая существенные искажения смысла при переводе стихов татарского текста.

Приведем лишь один пример: «Я цитировал Тукая в подстрочном переводе, так как в целом замечательный перевод Анны Ахматовой не тождественен с самыми значительными стихами оригинала:

В клетке мира было тесно
Птице сердца моего;
Создал Бог её весёлой,
Но мирской тщете чужой.

Согласитесь, разница ощутимая. Тукай чётко определяет понятие “мир” как вселенную людей, мироздание людей, со всеми человеческими перипетиями, законами, пороками и достижениями. Именно этот мир воспринимается птицей души поэта как тесная клетка. И она вылетает из неё в безграничную в своей чистоте, беспорочности божественную Вселенную, но и там оказывается чужой, ненужной. И Тукая, всецело уверовавшего в то, что он “… не вмещается во Время бренного мира и его условностей…”, в очередной раз посещает душераздирающая мысль:

… О страдалица моя,
Миру чуждому зачем ты человека родила?»
[Харис 2016: 14–15].

Вывод о гениальности Тукая звучит в статье Рената Хариса метафорично и категорично: «Тукай, не обучаясь ни в каких институтах и университетах, стал высокообразованным, передовым человеком своего времени, хорошо знающим не только родную культуру и литературу, но и русскую,

персидскую, арабскую, турецкую литературы, чётко разбирающимся в политике, экономике, педагогике, шариате. Его сердце, словно сейсмограф, реагировало, отзывалось на любое колебание души народа, его интеллект мог разобраться в сложных перипетиях общественно-политической жизни и вынести своё суждение, его любовь и ненависть стали умными. Огромный творческий талант и мощный гражданин слились воедино в человеке по имени Габдулла Тукаев, и появился великий поэт татарского народа – Тукай!» [1: 16]. Статью «Пусть сольются мысль и труд», опубликованную в газете «Правда» (1986. – № 162) к 100-летию Г. Тукая, Ренат Харис завершил следующим образом: «Тукай – один из тех счастливых поэтов, творчество которых всегда современно» [1: 11]

Литературно-критические статьи Рената Хариса позволяют осознать, что систематическое обращение поэта к творчеству Габдуллы Тукая закономерно и обусловлено стремлением показать современность и востребованность поэта начала XX века в современной литературе и культуре.

Ренат Харис часто ведет поэтический диалог с Тукаем, например, в стихотворении «В саду Тукая» строчку Г. Тукая «Скажи, зачем в семью Вселенной / ты чужаком меня ввела?..» берет в качестве эпиграфа.

Традиционный для восточной и мировой поэзии образ сада в стихотворении Рената Хариса предстает в необычном ракурсе – зимнего сада, в котором вместо традиционных садовых цветов тихо падают, кружатся снежинки:

В саду Тукая – снежная пороша
Так невесома, сказочна, легка.
Земля – на двор на мельничный похожа,
в котором всё усыпала мука [3: 177].

Сад Тукая предстает в белоснежном сказочном виде, в то же время сравнение «*земля – мельничный двор»,* усыпанный мукой, подчеркивая белизну сада, вносит оттенок плодородия. Сад Тукая в контексте образов сказочной пороши, белоснежной земли становится метафорой поэзии великого татарского поэта, воплощая ее красоту, нравственную чистоту и плодородие. Во второй строфе эта метафора развивается, обрастая емкими метафоричными оригинальными образами снежинок, рожденных «с горячею душой»:

Снежинки тают прямо на ресницах
(знать, родились с горячею душой).
Снег над землёй так радостно кружится,
он, как Тукай, для космоса – чужой [3: 177].

Традиционный образ Вселенной, мироздания, Космоса, усыпанного звездами, равнодушного к суетливой земной жизни, в стихотворении Рената Хариса дополняется образами тающих на ресницах снежинок, не удержавшихся на небесной тверди. Начавшись, как пейзажная зарисовка, стихотворение неожиданным сравнением: «он [снег – *А.Г.*], как Тукай, для космоса – чужой» – переходит в разряд философских, понятных только для тех немногочисленных читателей, которые хорошо знают поэзию Габдуллы Тукая, могут расшифровать строчки, вынесенные в качестве эпиграфа к стихотворению.

В третьей строфе сад Тукая предстает в восприятии лирического героя, добавляющего еще один штрих к восприятию поэзии поэта-классика: трагизм судьбы, трагизм в мироощущении:

Здесь мной давно исхожены тропинки,
Но как же сильно изменился сад,
Если на мир – смотреть через снежинки,
Что, словно слёзы, на глазах висят… [3: 177].

Традиционная метафора «поэзия – сад», «стихи – цветы души» опровергается Ренатом Харисом в стихотворении «Шигыйрь турында шигырь» на примере драматических судеб известных поэтов: Рудаки, Пушкина, Гарсиа Лорки, Назима Хикмета. Среди них названа и политически острая поэзия Г. Тукая:

Тукай ишеген,
Газраилдән узып,
Жандармнар какмас иде… [5: 369].

В поэзии Рената Хариса – Тукай предстает прежде всего мерилом нравственной, духовной и поэтической состоятельности. Эта мысль может проводиться как в объемном произведении (поэме, либретто), так и в поэтических миниатюрах и даже в юмористическом ключе. Так, например в стихотворении «Тукай боза»:

Бакыр Тукайга шигырьләр
укыйбыз без кызып-кызып...
Бер тәнкыйть сүзе әйтмичә
Бетерә ул безне бозып... [4: 104]

В миниатюре создается емкий образ ежегодного праздника поэзии, приуроченного ко дню рождения выдающегося татарского поэта и одновременно метко подмечена актуальная проблема – отсутствия конструктивной критики. В стихотворении «Тукай туган көнне һәр ел кояш...» тема праздника поэзии от пейзажной зарисовки перерастает в философское обобщение через развернутую метафору. Как в дни поэзии часто утреннее солнце сменяет весенний дождик, так и поэзия Тукая как солнце освещает путь современным поэтам и как дождик орошает их «корни»:

Тукай туган көнне һәр ел кояш.
Ә төштән соң бик еш – яңгырлар.
Тукай кояш булып ымсындыра
Һәм сут суза шигъри тамырга [5: 229].

В стихотворении «Тукай» из цикла «Каурый каләм» по улицам Казани идет Г. Тукай. Камни мостовых не выдержали тяжелой поступи Поэта. Неожиданная метафора «тяжелый поэт» по отношению к Г. Тукаю разрешается риторическим вопросом и риторическим ответом: на плечах Поэта – вся Вселенная:

Ә бармы соң
Җирдә
җиңел
шарыйрь–
шагыйрь иңләрендә ил гаме! [2: 185]

Таким образом, Ренат Харис находится в постоянном диалоге с Г. Тукаем,осмысливая его личностҗ и поэзию не только в стихотворениях, но и в литературной публицистике. А в драматической поэме «Тукайның мәхәббәт төшләре» создает полнокровный образ Г. Тукая – Поэта и выдающейся Личности. На основе этой поэмы впоследствии Р. Харис написал либретто к опере «Любовь поэта» Резеды Ахияровой (премьера 18 ноября 2006 г.), ко-

торая стала знаменательным событием в культурной жизни России и внесла достойную лепту в увековечении памяти о Г. Тукае.


ЛИТЕРАТУРА

1. Харис Р.М. Замана һәм каләм: әдәбият, сәнгать, публицистика: мәкаләләр, истәлекләр, әңгәмәләр = Время и перо: литература, искусство, публицистика: статьи, воспоминания, интервью. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 316 с.

2. Харис Р. Морщины лба. Стихи, песни, поэмы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 368 с.

3. Харис Р. Певчая ночь: стихотворения и поэмы в переводе Н. Переяслова. – М.: Вече, 2011. – 239 с.

4. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. Т. 3. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 367 с.

5. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. Т. 2. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 367 с.



УДК 821.512.145


# ТЕМАТИЧЕСКИЕ И ЖАНРОВО-ХУДОЖЕСТВЕННЫЕ ОСОБЕННОСТИ МУНАЖАТОВ Г. ТУКАЯ


***Т.Н. Галиуллин***

*Академия наук РТ*



Мунажаты как самостоятельный жанр, рожденные в результате взаимодействия поэзии и фольклора, пронизаны религиозным содержанием, культом Всевышнего и философией суфизма. В предлагаемой работе рассматриваются мунажаты, созданные великим татарским поэтом Г. Тукаем, которые так же выдержаны духовной идеологией, религиозной моралью. Удивительно многообразен жанровый состав его поэзии, где наряду с лиро-эпическими, сатирическими поэмами, соседствуют газели, рубаи, таухиды, маулиды, мадхии, марсии и хикмэты, собранные под общим названием мунажаты.



**Ключевые слова:** мунажат, пейзаж, лирика, напев, народ, национальное сознание, преклонение.



Munajats as an independent genre, born as a result of the interaction of poetry and folklore, are imbued with religious content, the cult of the Almighty and the philosophy of Sufism. In the proposed work, we consider the munajats created by the great Tatar poet, G. V. Shishkin.Tukayem, which are also sustained by spiritual ideology, religious morality. The genre composition of his poetry is surprisingly diverse, where along with lyric-epic, satirical poems, ghazals, rubai, tawhids, mawlids, madhiyas, marsiyas and hikmats, collected under the common name munajats, are side by side.



**Key words:** munajat, landscape, lyrics, chant, people, national consciousness, worship.


Первые же стихи Тукая, появившиеся в печати, были тепло встречены его современниками, потому что это была «по настоящему наша мелодия». С годами созвездие Тукая раскрывает все новые и новые литературно-эстетические возможности, просветляя души читателя. Ибо он, «продолжая и развивая многовековые идейно-эстетические традиции как восточных, так и русско-европейских литератур, опираясь на собственно – национальные истоки и живые родники устного народного творчества, создает поэтическую школу» [9: 248].

В его наследии значительное место занимает жанр мунажат-пронизанный верой в Аллаха, разнообразный по содержанию и по жанровым особенностям. Его обращение к мунажату было закономерным явлением, ибо трудно назвать более или менее известного татарского поэта не внесшего

свой вклад в развитие жанра. По мнению ученых, после принятия многими Восточными народами ислама, появились и первые образцы мунажатов сперва на территории современной Сирии и Ирака, постепенно проникая в фольклор, и в поэзию тюркоязычных народов, в том числе и татар.

В развитие жанра мунажат внесли и вносят свой вклад татарские поэты Кул Шариф, Мухамедьяр (XV в.), Мавля Колый, Габдрахим Салихов, Шамсетдин Заки, Г. Утыз Имяни, Гали Чокрый (XIX в.), Акмулла (конец XIX в.), М. Гафури, З.Башири, поэты наших дней К. Булатова, Р. Гаташ, Э. Гарифуллина, Г. Мурат, Ф. Тарханова, Ф. Зиятдинова и многие другие. За короткий период жизни и творчества, благодаря своим ярким, общественно-значимым и религиозным стихам, Тукай занял достойное место в одном ряду с выдающимися поэтами всех времен, имевшими свой неповторимый поэтический голос, стиль и звучание, и заслужил высокое звание народного поэта.

Веками притесняемый народ воспринял его творчество как подарок свыше, как посланника Аллаха, как долгожданную путеводную звезду.

Опираясь на учение и поэтику Корана, хадисы Мухаммеда и наследие суфийских поэтов, на социально-политические перемены в начале XX века, Тукай и его поколение подняли татарскую литературу на новую качественную ступень [8: 318]. Ясно, что поэт такого уровня, как Тукай, не мог возникнуть на пустом месте, вне живой и многобразной литературной среды. Выросший под влиянием книг Ясави «Мухаммадия», Мухаммеда Галяви, «Мавлид», Сулеймана Челяби «Бадавам» Тукай не мог обойти жанр мунажат.

Кроме стихов, вошедших в фольклорные сборники как мунажаты, в наследии Тукая есть произведения по религиозному и философскому содержанию, и звуково-ритмическому строю отвечающие требованиям жанра. Ибо, как отмечает литературовед Н. Хисамов в предисловии к собранию сочинений поэта «все стихи Тукая ритмичные и по звучанию музыкальные» [4: 215]. Вот некоторые произведения поэта, по моему мнению, отвечающие канонам мунажата: «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» (Праздник в детстве, 1907), «Бәйрәм бүген» (Сегодня праздник, 1908), «Киңәш» (Совет, 1909), «Таян Аллага» (Опирайся на бога, 1909), «Нәсихәт» (Наставление, 1910), «Мигъраҗ» (Вознесение, 1910), «Үтенеч» (Просьба, 1910), «Кадер кич» (Вечер после уразы, 1911), «Бала оҗмахта» (Дитя в раю, 1912). Эти стихи Тукая, проникнутые духом преданности к Всевышнему, учениям Корана привлекают тонким психологическим анализом, лиризмом, глубоким раскрытием переживаний личности.

Вот отрывок из стихотворения «Сегодня праздник», где религиозному празднику радуется вся окружающая среда:

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:
Сөйләшәләр үзара: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җиленең.
Анысы да сөйли тагын: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
(«Бәйрәм бүген»)

(Стою на берегу реки, воде внимаю шумной.
Она волнуется сильней: сегодня праздник, праздник!
И ветер праздничного дня мне тихо-тихо шепчет:
«Тревоги прежней развей: сегодня праздник, праздник!»).
(Пер. С. Липкина)

Поэт восторженно встречает и воспевает религиозный праздник, он как бы вдыхает дивный аромат, замечает, что «расчувствовался богатей», обняв бедняка. Не равнодушна к празднику вся окружающая природа, волнуется река, к ней присоединяется и ветер, который тихо-тихо шепчет на ухо, напоминая о наступившем празднике. Здесь мы видим лирического героя раскованного, освободившегося от мелочей жизни, романтика глубоко религиозного человека.

Через все творчество поэта проходит призыв к внимательному отношению к бедным, обездоленным и обиженным. Тому яркий пример стихотворение «Нәсыйхәт» (Наставление), которое является ярким образцом дидактической поэзии. Лирический герой напоминает современнику, что перед Богом все равны и не надо укорять нищего за то, «что он нарушил твой покой!»

Син кеби ул теләнчеләр дә – Алланың колы,
Кул суза мискин! – бәхетсезлек вә ачлык аркылы.
Булса – бир, булмаса исә, җайлап сөйлә булмаслыгын, –
Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Иьяслыгын!

(«Нәсыйхәт»)

Когда к тебе приходит нищий с протянутой рукой,
Не оскорбляй его за то, что он нарушил твой покой!
Имеешь – дай, а нет – ответствуй спокойно, не хуля,
Как знать, быть может, этот нищий старик – пророк Илья?

(«Наставление», пер. Р. Морана)

Таким образом, и в мунажатах Тукай находил возможность затрагивать многие проблемы бытия и народной жизни. Не случайно он подчеркивал, «я ведь и дипломат, и общественный деятель. Мои глаза видят многое, мои уши слышат многое» [6: 92].

Он не забывает и о молодом поколении и о его достойном воспитании. Так, поэт в стихотворении «Таян Аллага» («Вверься Аллаху») в искренном внутреннем монологе советует безвинному и чистому в помыслах и делах ребенку во всем опираться на Аллаха.

Әй, бәһале, әй кадерле, әй гөнасыз яшь бала,
Рәхмәте киң аның һәрдам таян син Аллага!

(«Таян Аллага»)

О безгрешное, святое, драгоценное дитя!
Береги любовь Аллаха, дорожи, молись и чти.

(«Вверься Аллаху! Пер. В. Думаевой-Валиевой)

В мунажатах, вошедших в сборник К.Хуснуллина(«Мөнәҗәтләр һәм бәетләр», 2001), как «Тәэссер», (Волнение 1908), «Васыятем» (Завещание, 1909), «Ана догасы» (Молитва матери 1909) и др., человек ищет жизненную опору в учении Ислама и в Коране. В этих произведениях Тукая ощущается близость к традициям философии суфизма, проявляющаяся в беспредельной преданности Аллаху, стилистическом плане к произведениям народного творчества, и поэтому они собирателями записаны как мунажаты. Потом только учеными были уточнены авторства указанных стихотворений. Опубликованный 21 января 1908 года в газете «Аль-ислах» «Тәэссер», хотя и вышел с пояснением автора, как подражание стихотворению Лермонтова «Молитва», по содержанию и своей направленностью, и в толковании основ сущности ислама, глубоким раскрытием благотворного влияния Корана на духовный мир человека произведение Тукая является оригинальным. Когда

персонаж стихотворения впадает в уныние, горит в огне тревоги и душевной горечи, он обращается к Корану:

Укыйм тиз-тиз күңелдән гаҗәиб сүрә Корьәннән, –
Газаплар бер кул илән алынадыр җаннан.
(«Тәәссер»)

Читаю суру из Корана я быстро-быстро про себя,
И кровоточащая рана не саднит сердце у меня.
(«Волнение», пер. В. Думаевой-Валиевой)

Освободившись от колебаний и сомнений, он от радости начитает плакать и все его лицо покрывается золотистыми каплями слез, что свидетельствует об избавлении от гнетущей скорби и склонив голову, повторяет «Аллаһе хак, Аллаһе акбар» (Нет ничего выше Бога).

«Тәәссер» Тукая раскрытием мощного влияния Корана на внутренний мир человека и богатым арсеналом художественных средств (Яңакларны мөкаддәс күз яшемдә энҗели башлыйм), является классическим образцом мунажата. («Начинаю промывать лицо священными каплями слёз»).

«Васыятем» (Завещание) поэта из-за религиозного и национального содержания до конца двадцатого века не включалось в сборники Тукая. Между тем, этот мунажат, состоящий всего из трех строф, очень важен для понимания общественно-политической позиции автора. Противоречие, во многом искусственно созданный между кадимистами и джадидистами поэтом оцениваются на фоне жизни той эпохи. «Завещание» довольно детально проанализирован профессором Р.К. Ганеевой. Защищая поэта от нападок невежд и врагов, стойкость и нравственный героизм проявили Ф. Амирхан, Дж. Валиди, Ф. Бурнаш, Г. Рахим, подчеркивает ученый [2: 44–45].

«Ана догасы» (Молитва матери) начинается как обычная пейзажная лирика с описания обычной большой деревни в лунный вечер. Народ, уставший за день, спит сладким и крепким сном. Только одна набожная старуха сидит на коврике и, подняв руки, читает молитву:

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын;
«Ходаем, ди, бәхетле булса иде сөйгән, газиз углым»;
Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь.
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?
(«Ана догасы», 1909).

Вот она, сложив ладони, их приблизила к лицу:
«Осчастлив, господь, сыночка!» молится она творцу.-
Слезы капают у старой, бледный лоб давно иссох,
Ту молитву неужели не услышит вышний Бог?
(«Молитва матери», пер. В. Ганеева).

«Завещание» воспринимается как продолжение выше рассмотренного произведения. Персонаж этого стихотворения, подчинив себя полностью Богу, находит в этом полное успокоение, убеждая самого себя (монолог обращенный единоверцам), что к Всевышнему ранее склонялся спиной, наконец, «повернусь лицом к нему». Во втором двустишии, обращаясь к друзьям, родным, всем тем, кто считал его безбожником, кяфиром, заявляет:

Кто считал меня неверным, устыдись прощальных слов:
Моего Корана веру я всегда хранил в груди.
(«Мое завещание», пер. С. Малышева)

Как видно из стихотворения «Васыятем», лирический психологизм восточной классики и народной поэзии явились для Тукая немеркнущим образцом воплощения изменений и колебаний в духовном мире человека.

В мунажате «Молитва матери» образ матери раскрывается через ее обращение к Аллаху: «Осчастлив, господь, сыночка!», – молится она творцу Поэт (лирический герой) полностью на стороне матери, у которой «Слезы капают», «бледный лоб давно иссох».

Отсюда рождается стремление к светлому идеалу и надежда на покровительство Всевышнего. Здесь и молва, и покаянное, и нежное обращение.

Ту молитву неужели не услышит вышний Бог.
(«Молитва матери», пер. В. Ганиева)

В своих мунажатах Тукай, стремясь затрагивать различные аспекты народной жизни, не избегал и трагических коллизий.

Так, стихотворение «Уянмас йокы» (Беспробудный сон», 1909), вошедший в сборники народной поэзии как мунажат, своим драматизмом и неподдельной искренностью не может оставить равнодушным самого черствого человека. Ибо здесь речь идет о преждевременной смерти ребенка.

Фатма күрде үзенең бүлмәсендә бер рәсем:
– Әнкәем, бу кем? – диеп сурды, кочаклап әнкәсен..
Әнкәсе бирде җавап: «әүвәлге улым бу минем,
Дөньда юк ул хәзер дә, бер туган абзаң синең».
(«Уянмас йокы»)

Мама, кто это? – спросила, ластясь к маме Фатима.
В её комнате на стенке фотография была.
Отвечала мама: «Раньше у меня был сын,
Это брат твой, но на свете его нет, он раньше был».

На настойчивые просьбы наивной дочери «разбуди же его мама» она вынуждена была дать исчерпывающий ответ:

Ах, сокровище! – Нет средства разбудить его суметь,
Сон тот вечный, беспробудный, называется он смерть!
(«Беспробудный сон», пер. В. Думаевой-Валеевой).

Кажущимся простым приемом незатейливого диалога поэт заставляет каждого из нас думать о скоротечности жизни и неминуемой смерти, т.е. однодневного существования в вечности. Написанный гарузом, с рифмовкой ааба, ввгд, четырехстрочным куплетом, изложенный на чисто татарском языке стихотворение доказывает, что у мунажата широкий тематический и художественный диапазон. Тукай и в этом жанре не был эпигоном. В первую очередь он, отказавшись от ортодоксальных представлений поэтов суфиев – дервишей, наполнил жанр жизненными и рациональными реалиями и самое, удивительное, даже в этот строгий, серьезный, во многом канонический жанр, ввел элементы сатиры, продолжая вытаскивать на солнечный свет лживых, лицемерных служителей культа, «Бер шәехнең мөнәҗәте» – (Мунажат одного шейха, 1908), состоящий всего из шести спрессованных, но многозначных строк тому пример.

И, Ходай! Мәгълүм сиңа яхшылыкта касдымыз;
Зимкеребез казы, кузый яшь кенә кыз, каз, кымыз.
Награда есть для добрых дел! В одно для нас слились:
Красотка, кура, колбаса, и кубок, и кумыс.
(«Песнопение шейха», пер. В. Любина).

Как видим, переводчик на другом языке нашел фонетическое созвучие слов.

В данной статье были рассмотрены мунажаты, созданные великим татарским поэтом Г. Тукаем, удивительно богатые по содержанию и по жанровому составу,где соседствуют рубаи, газели, таухиди, маулиды, марсии и хикметы, обыденные под общим названием и определением мунажаты, которые являются неотъемлемой частью нашего духовно-культурного наследия, способствуя сохранению этническую и религиозную самобытность татарского народа. Беглый анализ мунажатов Тукая хочется завершить словами татарско-киргизского писателя Чингиза Айтматова, что «Значение Тукая в том, что он совершил переоценку истории и культуры своего народа… Все тюркоязычные народы испытали поистине неизгладимое, по сей день свято хранимое, воздействие, впечатление от творчества Габдуллы Тукая» [7: 219–220].

ЛИТЕРАТУРА

1. Бакиров Марсель. Татарский фольклор. – Казань: Изд. АН РТ, 2018. – С. 326–335.

2. Габдулла Тукай әсәрләре. Белешмә-сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 44–45.

3. Галиуллин Т.Н. Мы – потомки страны «Тартария». – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – С. 15–26.

4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 271 б.

5. Тукай Г. Последняя капля слезы. Стихотворения. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2016. – 375 с.

6. Тукай Габдулла. Избранное. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. – 420 с.

7. Тукай Габдулла. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. – Казань, 1979. – С. 219–220.

8. Фридрих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 341 с.

9. Халит Г. Габдулла Тукай (1986–1913) // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX века). – Казань: Фикер, 2003. – С. 248–265.

10. Хисамов Нурмөхәммәт. Тукай: бөеклеге һәм фаҗигасе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 125 б.

УДК 811.512’373

## РАЗГОВОРНАЯ ЛЕКСИКА В ПОЭЗИИ Г. ТУКАЯ

***Г.Р. Галиуллина***

*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье анализируется лексика разговорной речи, которая функционирует в сатирических стихотворениях Г. Тукая. Объектом анализа выбраны просторечные слова и варваризмы. Поэт тщательно подходит к отбору разговорной лексики. В его произведениях данная лексика выступает как отражение действительности и реального состояния народно-разговорного татарского языка. Включая в стихотворный текст лексических средств живой разговорной речи, Г. Тукай сумел демонстрировать их семантический и функциональный потенциал, создать высокую эмоциональную тональность стихотворения и экспрессию.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, татарский язык, лексика, разговорная речь, просторечные слова, варваризмы.

The article analyzes the vocabulary of colloquial speech, which functions in the satirical poems of G. Tukay. The object of the analysis is selected colloquial words and barbarisms. The poet carefully approaches the selection of colloquial vocabulary. In his

works, this vocabulary acts as a reflection of the reality and the real state of the folk-spoken Tatar language. Including in the poetic text the lexical means of lively colloquial speech, G. Tukay was able to demonstrate their semantic and functional potential, create a high emotional tone of the poem and expression.
**Key words:** G. Tukay, Tatar language, vocabulary, colloquial speech, colloquial words, barbarisms.

## Г. ТУКАЙ ПОЭЗИЯСЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫ

***Г.Р. Галиуллина***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Г. Тукай иҗаты татар халкының милли горурлыгы санала, ул буыннан-буынга тапшырылып килгән рухи хәзинәбез арасында күренекле урынны били. Халкыбызның әдәби мирасы, милли теле турында сүз барганда, беренче чиратта, Г. Тукай иҗатын мисал итеп китерү тәҗрибәсе дә инде татар фәнендә үзенең лаеклы урынын тапкан. Шагыйрьнең төрле чорларда иҗат иткән әсәрләре дә татар милли теленең формалашуын һәм аның төгәл, татар теленең табигый агышына туры килгән вариантларын, тел өлгесе булырлык формаларын эзләү юлларын да күрсәтә. Г. Тукай иҗатының башлангыч чоры иске татар теленең гарәп-фарсы алынмалары һәм язма традицияләргә нигезләнгән формасы белән халык авыз иҗаты тәэсирендә халыкчан сөйләмә формасы янәшә кулланылган чорга туры килә [5: 101]. XX гасыр башы татар милли әдәби теле нормаларының формалашу этабы буларак характерлана. Бу чорда иҗат иткән әдипләрнең төрле форма һәм стильләр өлкәсендә эзләнүләре мәгълүм. Г. Тукай иҗатында да телебездә барган эзләнүләрне, милли телебезнең нигезен тәшкил иткән формаларның ныгуын ачык күрәбез. Күренекле галим В.Х. Хаков билгеләвенчә, «Г. Тукай әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайтуда, аны нормалаштыруда, эшкәртүдә, матур әдәбият телен һәм иҗтимагый-публицистик стильне үстерүдә зур өлеш кертте, гасырлар буенча килгән классик язма тел үзенчәлекләрен гомумхалык теле элементлары белән оста итеп үреп бирә белде» [8: 190].

Татар фәнендә Г. Тукая иҗаты, шул исәптән әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре турында шактый фикер әйтелгән һәм әйтелеп килә, шуңа карамастан, әдипнең татар теленең бай һәм күпкырлы мирасын оста файдалануы турында игътибар итәсе өлкәләр дә шактый әле. Без шундый өлкәләрнең берсенә – Г. Тукай поэзиясендә кулланылган сөйләм теле үзенчәлекләренә тукталабыз.

Сөйләм теле – милли телнең көндәлек аралашуын тәэмин итә торган формасы. Аралашу чарасы буларак, ул милләт формалашкан чорда оеша. Тел күзлегеннән караганда, ул беркадәр каршылыклы булган ике тенденция белән характерлана: бер яктан, сөйләм теле актив рәвештә яңа берәмлекләр барлыкка китерсә, икенче яктан, клише, шаблон, стереотип кебек әзер конструкцияләр белән эш итә [4: 178]. Сөйләм теленең төп лингвистик үзенчәлекләре булып фонетик вариантлылык, лексик планда исә көнкүреш сүзләрен, гади сөйләм һәм диалект лексикасын, диалекталь һәм гади сөйләмдә таралыш тапкан грамматик формаларны куллану тора [3: 14].

Г. Тукай поэзиясендә халыкның җанлы сөйләм теле үзенчәлекләре шактый иркен һәм урынлы кулланылганлыгы күзгә ташлана, әмма сөйләм теленнән аермалы буларак, шагыйрь бу төр лексиканы әсәр тукымасына югары сәнгати чара буларак урнаштыра, әдип кулланган һәр берәмлекнең семантик,

тирән тәэсири, эмоциональ-экспрессив көче күзгә ташлана. Мондый алым, бер яктан поэзия телен халыкның сөйләмә теленә якынайтса, икенче яктан, телебезнең мәгънәви тирәнлеге, кулланылыш мөмкинлеге, киңлеге турында сөйли. Әдипнең шигырьләре теленә игътибар итсәк, XX гасыр башы татар теленең сөйләмә тел җирлегендә фонетик, лексик, сүз ясалышы, грамматик һәм стилистик яктан үсеш процессын тулаем күзалларга мөмкин. Шул ук вакытта әлеге чор татар язма әдәби телендә күзәтелгән үзгәрешләр, тенденцияләр дә Г. Тукай шигъриятендә ачык күренә, мәсәлән,

*Сәдакать бездә юкмыш; булмаса, ялганымыз бардыр;*
*Нифак выставкасында күп медаль алганымыз бардыр.*
*Нәзафәткә ригаять юк имеш бездә, – нә бөһтандыр!*
*Аның чөн йорт саен безнең берәр комганыбыз бардыр* [1: 113].

Әлеге өзектә XX йөз башы язма телендә актив кулланылган гарәп һәм фарсы алынмалары, төрек теле үзенчәлекләре белән бергә, татар сөйләм телендә кулланылган рус һәм Европа телләре берәмлекләрен дә күрәбез. Шулай ук грамматик үзенчәлекләрдән хәзерге татар әдәби телендә пассивлашып барган хәбәрлек кушымчасының активлыгы, *чөн* сүзендә сүз башындагы [ө] авазын төшереп калдыру кебек традицион үзенчәлекләр күзгә ташлана[1].

Г. Тукай шигырьләрендә татар теленең үз сүзләре башында [ж] авазын куллану еш күзәтелә, мәсәлән, *Җөгералмадым, җибәлмадым, тоталмадым үрдәкне...* [1: 182]; *Җаңгыр җава сибәләп, төймә-төймә төймәләп* [1: 183] *сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә* [1: 87]; *бу вахытта шулар җөри Ботанский бакчага* [2: 180] һ.б.

Галимнәр искәртүенчә, XIX гасыр – XX гасыр башы татар язма телендәге истәлекләрдә сүз башында [й] кулланылу традицион язма тел үзенчәлегенең дәвамы саналса, [й] ~ [ж] чиратлашуы сөйләшләргә хас үзенчәлек булып тора. Соңрак бу үзенчәлек, таралыш табып, норма буларак ныгый [5: 598–626].

Г. Тукай үзенең иҗатында халыкның җанлы сөйләм телендә киң таралган гади сөйләм сүзләрен гаять дәрәҗәдә оста кулланып, сатирик характеристика тудыра:

*Яманлыклар тәмам мине котырталар,*
*Таяк берлә гүя корсакка төртәләр,*
*– «Нигә болай?» «Ярамый», – дип сөйләндереп,*
*«Тфү, чортлар! Ахмаклар!» – дип төкертәләр* [1: 104].

Әлеге өзектәге рус сөйләм телендә канәгатьсезлек, өнәп бетермәү кебек тискәре хисләрне белдерә торган *чорт* сүзе татар сөйләм теленә дә шул ук мәгънәдә үтеп кергән һәм ул, *ахмаклар* сүзе белән бергә кулланылып, тискәре мәгънә төсмерен тагын да көчәйтә. Өзектәге *төкертәләр* сүзенең дә сөйләм телендә ‘кемгә яки нәрсәгә дә булса кискен ризасызлык, нәфрәт, ачу, җирәнү белдерү’ күчерелмә мәгънәсе билгеле [7: 679–680]. Шулай ук *тфү* ымлыгы да телебездә сөйләүченең берәр кешегә, җанлы-җансыз нәрсәгә һ.б. кимсетүле, җирәнүле мөнәсәбәтен яки ачуын белдерү өчен кулланыла. Шулай итеп, каралган тел чараларының семантик мөмкинлекләре шигырьнең эмоциональ-экспрессив фонын көчәйтә.

---

[1] XIX гасыр – XX гасыр башы язма әдәби телендә мондый үзенчәлекләрнең даими күзәтелүе турында «Татар әдәби теле тарихы», 1 том (2015) хезмәтенең 443–457 битләрендә шактый тулы яктыртыла.

*Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!*
*Вә һәрберсе – губернатор, кикерәләр дөбер-шатыр* [1: 42].

«Сарыкортларга» шигыреннән алынган әлеге өзектә *бирән* һәм *ну* гади сөйләм элементлары кулланыла. Гади сөйләм сүзе *бирән* ‘күп һәм теләсә нәрсәне талымсыз ашый яки исерткеч эчемлекләр эчә торган кеше, гуҗ, туймас тамак’ дигән мәгънәне белдерә [6: 534]. Г. Тукай әлеге сүзнең мәгънәви экспрессиясен *кикерәләр дөбер-шатыр* тезмәсе белән тагын да көчәйтә. Рус сөйләм теленнән татар теленә үтеп кереп, шактый актив кулланыла торган *ну* ымлыгы гаҗәпләнү төсмерен тагын да арттыру өчен кулланыла.

Габдулла Тукай сатирик әсәрләрендә градация алымын да бик оста файдалана. Мисал өчен, аның «Ник? Нигә?» шигырендә гади сөйләм сүзләре, бер-бер артлы тезелеп, экспрессив вазифа башкаралар, ягъни акылсызлык сыйфатын арттырып күрсәтәләр:

*Нәрсәгә каптырмакчы, әфьюнчыга «Карга» язу?*
*Ах, мие чергән чүбек баш, ах, ишәк, ахмак, дурак!* [2: 102]

Белгәнебезчә, XX гасыр башында кулланылган антропонимнарның рәсми вариантлары катлаулы структура хасил итә, алар, нигездә, ике компонентлы, әмма сөйләм телендә алар кыскартылган вариантта кулланылышта йөриләр. Башлыча сатирик әсәрләрендә Г. Тукай кеше исемнәрен дә сөйләм телендәгечә куллануга өстенлек бирә. Мәсәлән, «Авыл җырлары» шигырьләр көлтәсендә *Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфәнүн саласы* (Минһаҗетдин Кадермәтов); *Шул музыкан уйнаганда, Ишми ничек түзәйкән* (Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов); *Сотрудниклар булса булсын Җөҗҗәт, Нәүрузи кебек* (Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов); *Бай хәерче Морадлары чыкмый ята Мәккәдән* (Морадел-Мәкки Рәмзи) һ.б.

Әзер модельләр буенча көлкеле рухтагы исем һәм фамилияләр ясау үзенчәлекләрен дә Г. Тукай әсәрендә еш очратабыз, мәсәлән, «Казанда бөлгән Әхмәтҗан бабай Сәйдәшев кыйссасы»да *Әхмәтҗан – Ахмакҗан;* «Бер гәзитә идарәсе хәленнән» шигырендә *Шалканов, Талканов, Балканов* һ.б.

Сөйләм телендә шактый таралыш тапкан рус сүзләрен, реалий атамаларын Г. Тукайның шигъри тукымасында күпләп очратырга мөмкин. Аларның зур күпчелеге сатирик характеристикаларда, образ тудыру максатыннан, комик сыйфатлау өчен бирелгән.

Г. Тукай кулланган варваризмнар реаль тормышны, халыкның җанлы сөйләм теленең үзенчәлекләрен чагылдыра. Сөйләм телендә рус теле сүзләре, грамматик конструкцияләр кулланылышы XX гасыр башында басылган газета-журнал битләрендә дә урын алган. Мисал өчен, «Шура» журналының 1909 ел, 14 нче саныннан кайбер мисалларны карап үтик: ***Учительски ышкула, семинария*** *кеби мәктәпләргә төркем-төркем ташый башладылар*.; *Хатын вә кызлары рус* ***барышнялары*** *кия торган «**куфтачка**» рәвешендә бернәрсә ясап кияләр.*

Г. Тукай шул чорның яшәеш үзенчәлекләрен сатира утына тоткан әсәрләрендә мондый төр тел берәмлекләре шактый иркен кулланыла. Алар, халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнеп, үтемле, укучыга тәэсир итәрлек һәм көлкеле образ тудырырлык бирелгән. Шул ук вакытта алар халыкның сөйләм телен, аның чынбарлыктагы халәтен дә тулаем чагылдыра. Әдипнең сатира рухында язылган «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» әсәрендә генә дә моңа шактый мисал очратырга мөмкин: *Мәскәүски якка күз салсам,*

*күрәм...; полный ход килгән трамвайдан узып; алды «пересадка» берлән бер билет*; *һич мондый сарай салмагандыр Кәчимский Ибырай* һ.б.

Шагыйрь рус теле лексикасын реаль чынбарлыкны тасвирлаганда да мул куллана, мисал өчен, «Ысулы кадимче» шигырендә реалий атамаларын, аерым грамматик конструкцияләрне, тулаем рус телендәге репликаларны бик оста файдалана:

*... Шулук хәлдә килеп керде афисиант,*
*Рәхимсез йөртәдер күзләрне ялт-ялт.*
*Диде: «Барин, двадцать рублей с вас.*
*Давайте скорей, – скоро уж час!»*
*Дидем: «Динге маи иптәшләр украл;*
*Сабакылар, они украл да удрал»* [1: 174].

Шул ук шигырьдә *пивнойда сирра, гүләйт иттек, пичәтләнгән шәраблар, эчемлекләр бөтенләй бесплатный* кебек варваризмнар да реаль чынбарлыкны көлкеле рухта күрсәтү максатыннан оста файдаланыла. Гомумән, Г. Тукайның сатирик әсәрләрендә рус сүзләре һәм гыйбарәләренең шактый актив кулланганлыгы күзгә ташлана.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Тукай үзенең иҗатында, аеруча сатирик шигырьләрендә, халыкның сөйләм теле үрнәкләрен яратып, мул һәм урынлы куллана белгән. Алар эстетик вазифа белән бергә, XX гасыр башы татар теленең халәтен, сөйләм теленең үзенчәлекләрен дә шактый тулы күзалларга ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1904–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 430 б.

2. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. 2 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 399 б.

3. Галиуллина Г.Р. Современная татарская разговорная речь: идентификационные признаки и социальная дифференциация: монография / Г.Р. Галиуллина, Э.Х. Кадирова, Г.К. Хадиева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2020. – 222 с.

4. Словарь социолингвистических терминов / под ред. В.Ю. Михальченко. – М.: Институт языкознания РАН, Институт иностранных языков, 2006. – 312 с.

5. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова; фәнни ред. Ф.М. Хисамова. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – 696 б.

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I т.: А–В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V т.: С–Т. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 908 б.

8. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.

УДК 811. 512. 145’38

## СРАВНЕНИЯ В ПОЭЗИИ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

***Ф.Г. Галлямов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются особенности употребления сравнительных конструкций в поэзии Г. Тукая. Анализируются их структурно-семантические особенности. Выделены простые, распространенные и расширенные (эпические) сравнительные конструкции. Проведена классификация на основе выделения средств сравнения. Определены стилистические функции рассматриваемых единиц.

**Ключевые слова:** сравнения, средства сравнения, структура сравнительных конструкций, эпические сравнения, стилистические функции сравнительных конструкций.

The paper covers the characteristics of the usage of comparative constructions in G. Tukay's poetry. The author studies their structural and semantic features and singles out simple and extended (epic) comparative constructions. The paper presents the classification on the ground of the means of comparison as well as the stylistic functions of the units under the study.
**Key words:** comparison, means of comparison, structures of the comparative constructions, epic comparisons, stylistic functions of the comparative constructions.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ПОЭЗИЯСЕНДӘ ЧАГЫШТЫРУЛАР

***Ф.Г. Галләмов***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Чагыштыру, стилистик чара буларак, татар телендә киң таралган алымнарның берсе булып санала. Чагыштырулар, тел-сурәтләү чарасы буларак, матур әдәбият стилендә киң кулланыла, шулай ук публицистик сөйләмдә, фәнни әдәбиятта, эпистоляр стильдә, гади сөйләм телендә дә актив.

Татар тел белемендә чагыштырулар лексик-грамматик һәм стилистик планда, беренче булып, С.Ш. Поварисов тарафыннан өйрәнелгән [4]. Шул ук елны С.М. Ибраһимовның чагыштырулы конструкцияләрне өйрәнүгә багышланган күләмле мәкаләсе дөнья күрә [2: 248–269]. Алдагы хезмәтен автор чагыштырулы төзелмәләрнең синонимлыгын өйрәнүгә багышлый [3]. Чагыштырулар күчерелмә мәгънәлелеккә мөнәсәбәтле рәвештә В. Хаков хезмәтләрендә дә өйрәнелгән [5: 24–37, 6: 37–51]. Татар синтаксисында чагыштырулы төзелмәләр гади җөмләне катлауландыручы чара буларак та карала [1: 55–66]. Татар тел белемендә аерым язучының, шагыйрьнең иҗатына бәйләп, чагыштырулы берәмлекләр тикшерелмәде. Г. Тукай иҗатына игътибар зур булуга карамастан, аның тел-сурәтләү чаралары җитәрлек өйрәнелмәгән әле. Шуны күздә тотып, бу мәкаләдә Г. Тукай поэзиясендә урын алган чагыштырулы төзелмәләргә кагылышлы мәсьәләләргә тукталуны максат итеп куйдык. Түбәндә чагыштыруларның кулланылу үзенчәлекләренә, чагыштыру чараларына, аларның төрләренә, стилистик әһәмиятенә игътибар ителде.

Стилистик-экспрессив нагрузкасы шактый көчле булган образлы чагыштырулар Г. Тукай әсәрләрендә дә күпләп кулланылган. Аларда бик күп төрле чагыштыру чаралары урын алган, төркемләү шуларга мөнәсәбәтле рәвештә алып барылды.

1. Бәйлекләр. Чагыштыруларда бәйлекләрнең бик күп төрләре кулланыла. Тарихи яктан карасак, төрле чорда аның төрле формалары, вариантлары кулланылган.

*Шикелле, төсле, сыман* синоним бәйлекләре чагыштыру-охшату төшенчәсен белдерәләр. Үзара синоним булуга карамастан, аларның мәгънәви үзенчәлекләре дә юк түгел. Кайбер очракларда әлеге бәйлекләрнең берсе урынына икенчесен бөтенләй кулланып булмый. Шуңа күрә бәйлекләр предметларның нинди үзенчәлекләре буенча чагыштырылуларына карап кулланылалар. Бу бәйлекләрдән Г. Тукай поэзиясендә иң активы – *төсле* бәйлеге:

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә *төсле*, ихтыярсыз акты китте яшьләрем. (Г. Тукай)

Шикелле бәйлеге предметларны форма охшашлыгы буенча чагыштырганда кулланыла:

Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә *шикелле* итә җем-җем. (Г. Тукай)

Г. Тукай чагыштыруларында, бик үк актив булмаса да, *сыман* бәйлеге дә катнаша, сөйләмгә аерым стиль төсмерләре бирүдә аның үзенә хас үзенчәлекләре бар. Ул предметларны килеш-килбәт ягыннан чагыштыру өчен кулланыла:

Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван,
Күтәреп башыны арыслан *сыман.* (Г. Тукай)

*Кебек, күк* предметларны күбрәк эчке табигатьләре белән чагыштырганда кулланыла: «Синең шигырең якты кояш *кебек*», – ди Тукай Пушкин шигыре турында. *Кебек* бәйлеге белән килгән чагыштыруга тагын бер мисал:

Кашың кара «хи» *кебек*, әлептәге «би» *кебек;*
Сотрудниклар булса булсын Хөҗҗәт, Нәүрузи *кебек.* (Г. Тукай)

*Кебек* бәйлеге Г. Тукайда бик үк актив түгел, аның иң еш кулланылган варианты – *кеби.* Аннан файдалану XX гасыр башына кадәр дәвам итә:

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез *кеби*;
Бинибая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз *кеби.* (Г. Тукай)

Бу баш килешне таләп итүче бәйлек, алмашлык белән килгәндә дә, баш килеш формасында кулланылган:

Син *кеби* һәм ул теләнчеләр дә – алланың колы;
Кул суза, мискин! – бәхетсезлек вә ачлык аркылы. (Г. Тукай)

*Кебек, кеби* бәйлекләре урынында, сирәк кенә булса да, аның кыскартылган варианты *күк* бәйлеге дә кулланыла. Мәсәлән:

Карны җиңгән *күк*, төшә җиргә тонык ай яктысы;
Ай да куркынган шикелле: бер сары, бер ак төсе. (Г. Тукай)

*Кадәр* бәйлеге предметны күләм ягыннан чагыштырганда кулланыла:

Кыш, буран, салкын һава, яфрак *кадәрле* кар төшә,
Җил куа карны, һаман да кар «төшәм» дип тартыша. (Г. Тукай)

Г. Тукай әсәрләрендә *кадәр* бәйлеге урынына шул ук тамырдан булган һәм шундый ук мәгънәдәге *микдар* сүзе дә кулланылган:

Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак;
А йа корсак, вә йа корсак, җиһанны капладың, вай-вай!
Боларның һәрберсе Каф, яки Кавказ, таулары *микдар;* (Г. Тукай)

Чагыштыру чарасы булып, XX йөз башларына кадәр *мисле* сүзе дә кулланылган, Г. Тукай шигырьләрендә ул бик актив. Татар теленнән аермалы буларак, ул гарәп-фарсы изафәсендәгечә, үзе бәйләнгән сүздән алда килә. Мондый сүз тәртибе татар теле өчен ят нәрсә, шунлыктан ул, актив булуына карамастан, кулланылыштан төшеп калды. Мәсәлән:

Ашап яткан сорыкортларга кадалдым *мисле* хәнҗәр мин; (Г. Тукай)

Салынып төшкән килешсез мыегы –
Бик озындыр, *мисле* күсе койрыгы. (Г. Тукай)

Сирәк кенә булса да, бу сүзнең *мисале* варианты да очраштыргалый:

Була кайчак бөтен уйдан күңел буш,
Туза уйлар, *мисале* гыйһне мәнфүш. (Г. Тукай)

Нәтиҗә ясап, шуны әйтик: чагыштыруларда бәйлекләрнең роле зур, алар башка барлык чараларга караганда да актив.

2. Кушымчалар. Вакыйгаларны, табигать күренешләрен сурәтләгәндә, чагыштыру чараларыннан язучылар, шагыйрьләр элек-электән иркен файдаланганнар. Алар арасында кушымчалар да зур урын алып тора. Чагыштыруны белдерүче кушымчаларга *-дай*/*-дәй*/*-тай*/*-тәй, -ча*/*-чә,* чыгыш килеш кушымчалары *-дан*/*-дән*/*-тан*/*-тән*/*-нан*/*-нән*, дәрәҗә белдерүче *-рак*/*-рәк* һ.б. кертеп карала. Кушымчалар арасында әдип әсәрләрендә иң еш кулланылганы – *-дай*/*-дәй*/*-тай*/*-тәй*:

Атылган кош, адаштырган *эттәй*,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың; (Г. Тукай)

Әйберләрне, предметларны, күренешләрне, эш-хәрәкәтләрне чагыштырганда, *-ча*/*-чә* кушымчалары да актив кулланыла. Мәсәлән:

Яңак, маңлай җыйрылмаган, тешләр дә сау,
*Яшьләрчә* саф, ачык чыга аның сүзе. (Г. Тукай).

3. Теркәгечләр. Чагыштыруларда теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр дә катнаша. Матур әдәбиятта *гүя* теркәгече, *әйтерсең* теркәгеч сүзе актив кулланыла. Аналитик чара булганлыктан, әлеге чаралар Г. Тукай поэзиясендә бик аз, синтетик чаралардан бәйлек һәм кушымчаларга өстенлек бирелгән:
Бетәдер ярасы рухның вә хиснең,

Тигәндәй куллары *гүя* мәсихнең (Г. Тукай).

*Гүя, гүяки* теркәгечләре урынына Г. Тукайда шул ук мәгънәдә *санки* сүзе кулланылган, аның кулланылышы *гүя* теркәгеченә караганда активрак:

Очып киткәндә ул шундый матурлап сайрады моңлы:
Миңа, *санки,* азат иткән өчен изге дога кылды. (Г. Тукай)

Бу бәйләгечнең *санкем* варианты XX гасыр башында язылган әсәрләрдә, бигрәк тә Дәрдмәнд иҗатында шактый еш очрый [5: 30]. *Санки, санкем* сүзе соңыннан кулланылыштан төшеп кала.

4. Мөстәкыйль мәгънәле сүзләр. Бәйлекләр, кушымчалар, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләрдән тыш, телдә чагыштыру чарасы булып хезмәт итә торган мөстәкыйль мәгънәле сүзләр дә бик күп. Шуларның кайберләре Г. Тукай әсәрләрендә дә урын алган:

Бер ишан хәзрәт симертттем, күркә, тавык ашатып;
Сагынсам, корсагын карыйм, чүмәләгә *охшатып.* (Г. Тукай)

Чагыштырылучы предметлар, әйберләрнең исемнәре алмашлыклар белән бирелеп тә, чагыштыру белдерелә:

Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, –
Болар булган *берсеннән дә берсе* арык. (Г. Тукай)

Әйберләр тиңләштерелеп чагыштырылганда, *бер, бердер* сүзләре кулланыла:

Өйләнмәк бер-берәүнең җәбре-каһре өсткә менмичә –
Егылмак берлә *бердер*, һичбер әйбергә абынмыйча. (Г. Тукай)

Түбәндәге мисалда *буйлыгы* сүзен *кадәрле* бәйлеге белән алыштырып була:

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак *буйлыгы* бар маңгаенда мөгезе. (Г. Тукай)

Г. Тукай әсәрләренең тагын бер үзенчәлеге: шактый актив булган чагыштыру чаралары алда килгән исемнәр белән бергә шигъри юлларны еш кына рифмалаштыру өчен дә кулланылганнар:

Нинди күзләрне зурайткан, ачкан инде шар *кеби,*
Шул тирәдә бик кирәкле бер кызык хәл бар *кеби.* (Г. Тукай)

Чагыштыру барлыкка китерүче чаралар кыскалык файдасына, сөйләмне җыйнакландыру максатыннан чыгып, бөтенләй кулланылмаска да мөмкин, Бу исә поэзиядә ритм, рифма таләбе белән дә эшләнергә мөмкин. Түбәндәге мисалда *милләтче ата күркә* белән чагыштырыла:

*Милләтче* бик куркак бит ул, судан курка,
Гәрчә милләт диеп авыз суын корта.
Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит,
Теге, ишек алдындагы *ата күркә* (Г. Тукай).

Чагыштыруларның төзелеше ягыннан гади һәм җәенке төрләрен күрсәтергә мөмкин. Гади төрләре бер мөстәкыйль мәгънәле сүздән һәм бер ярдәмлектән генә торалар: *бүре кеби, черки төсле* һ.б. Ә җәенке төрләре исә, үз эчләренә сүзтезмәләрне һәм бәйләүче чараны алалар:

Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш,
*Усал эт төсле* чәйнәш; (Г. Тукай)

Нәшир исә, *читлектәге бүре төсле*,
Идән буе арлы-бирле атлап йөри. (Г. Тукай)

Чагыштыруларның тагын киңәйтелгән төрен дә күрсәтергә була. Анда төп ике әйбер, күренеш алынып, чагыштыру бөтен әсәргә җәелә. Мондый чагыштырулар эпик чагыштырулар дип атала [5: 32]. Моңа мисал итеп, Г. Тукайның киңәйтелгән чагыштыруларга корылган «Мактанышу», «Иссез чәчәк», «Картлар», «Кызык гашыйк», «Теләү бетте» һ.б. шигырләрен китерергә була.

Галимнәр фикеренчә, татар телендә чагыштырулар, башка сурәтләү алымнарына караганда, күбрәк кулланыла. Бу төзелмәләрнең актив булуын без синтаксик яктан карап та күрә алабыз. Алар җөмләдә чагыштыруны белдерә торган аергыч, тәмамлык, хәбәр, аныклагыч, рәвеш хәле, максат хәле, күләм хәле, сәбәп хәле, вакыт хәле, урын хәле һ.б. функцияләрне башкаралар [1: 64–66]. Сөйләмне мәгънә һәм эчтәлек ягыннан баетуда, матурлауда аларның әһәмияте гаять зур. Сөйләм төзелеше һәм мәгънә үзенчәлекләреннән чыгып, сөйләмдә төрле әйберләр һәм күренешләр бер-берсе белән чагыштырыла алалар:

1. Җанлы предметларның чагыштырылуына мисаллар:

Депутатларны кудылар
*Черки төсле* «көш» тә «көш»! (Г. Тукай)

2. Җансыз предметлар үзара чагыштырыла:

Бөтен сахра гарип төсләр аладыр,
Болыт *төсле* ала булып каладыр. (Г. Тукай)

3. Җанлы һәм җансыз күренешләрнең чагыштырылуына да күп мисаллар китерергә мөмкин. Түбәндәге өзектә Г. Тукай шәкертләрнең эшсез ятып саргаюларын таякка охшата: Кибеп беттек, Саргайдык без, Корып беттек *Таяклардай.* (Г. Тукай)

Чагыштыру, сурәтләү чарасы буларак, әсәрдә күп максатларда кулланыла. Персонажларның характерлы үзенчәлекләрен индивидуальләштерү, табигать күренешләрен сурәтләү, төрле тарихи, социаль вакыйгаларны җанлы итеп тасвирлауда чагыштыруларның роле гаять зур. Чагыштырулар сөйләмне образлар белән баета.

Г. Тукай поэзиясендә чагыштырулар бәйлекләр, кушымчалар, теркәгечләр, охшату-чагыштыру мәгънәсенә ия булган мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән барлыкка китерелгәннәр. Шагыйрь чагыштыруларны бик күп стилистик максатлардан чыгып кулланган. Кайберләрен шигъри юлларны үзара рифмалаштыру өчен дә файдаланып, чагыштырыла торган предмет, әйберләргә игътибарны ныграк юнәлтә, мәгънәләрен көчәйтеп бирә.

Шагыйрь чагыштыруларның гади, җәенке, киңәйтелгән төрләреннән бик оста файдаланган. Анда җанлы предметлар үзара, җансыз әйберләр бер-берсе белән, җанлы һәм җансыз предметлар, төрле эш-хәлләр үзара төрле грамматик һәм лексик чаралар ярдәмендә чагыштырылып, бик матур образлар тудырылган.

ӘДӘБИЯТ

1. Галлямов Ф.Г. Синтаксис осложненного простого предложения в татарском языке. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2006. – 296 с.

2. Ибрагимов С.М. Сравнительные конструкции в татарском языке. // Вопросы татарского языкознания. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1965. – С. 248–269.

3. Ибраһимов С.М. Чагыштырулы төзелмәләр һәм аларның синонимнары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 55 б.

4. Поварисов С.Ш. Сравнение в татарском языке: (В лексико-грамматическом и стилистическом планах): автореф. дис. … канд. филол. наук. – Уфа, 1965. – 19 с.

5. Хаков В.Х. Стилистика һәм сүз сәнгате. – Казан: Таткнигоиздат, 1979. – 158 б.

6. Хаков В.Х. Татар әдәби теле. Стилистика. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

УДК 821.512.145

## ОБРАЗ ТУКАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ РАБИТА БАТУЛЛЫ

***А.Ф. Ганиева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Рабит Батулла – писатель, уделявший в своём творчестве большое место воплощению образа Тукая. Он создал и драматические произведения на эту тему, и рассказы, повести, и киносценарии. Автор статьи обращает особое внимание на повесть писателя «Острее меча, тоньше струны». Анализируя систему образов, определяет идею и значение произведения. Батулла показывает раннюю смерть поэта как большую трагедию и размышляет о причинах, приведших к ней, проводит параллели между судьбами поэта и нации.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, Рабит Батулла, татарская литература, проза, образ, герой.

Rabit Batulla is a writer who devoted a great place in his work to the embodiment of the image of Tukai. Batulla created dramatic works on this topic, as well as short stories, novellas, and screenplays. The author of the article pays special attention to the writer's story «Sharper than a Sword, thinner than a string». Analyzing the system of images, it determines the idea and meaning of the work. Batulla shows the early death of the poet as a great tragedy and reflects on the causes that led to it, draws parallels between the fate of the poet and the nation.
**Key words:** Gabdulla Tukay, Rabit Batulla, Tatar literature, prose, image, hero.

# РАБИТ БАТУЛЛА ИҖАТЫНДА ТУКАЙ ОБРАЗЫ

***А.Ф. Ганиева***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай, бер яктан, иҗаты белән халыкның милли аңын яшәтүдә әһәмиятле урын тотса, икенче яктан, тарихи шәхес буларак әдәбиятта-сәнгатьтә сурәтләнеп, шул ук вазифаны башкарып килә.

Сүз сәнгатенең төрле өлкәләрендә уңышка ирешкән Рабит Батулла Тукай образын гәүдәләндерүгә үзеннән шактый өлеш кертә. Аның «Имче» (1976) хикәясе булачак шагыйрьнең балачагын, «Зәйтүнәкәй туташ» (2010) романтик хикәясе инде танылган шагыйрьне мәхәббәт өлкәсендә ачса, «Сират күпере» (1986) драмасы һәм «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» (1995) кыйсса-повесте Тукай гомеренең соңгы көннәрен тасвирлый. Шулай ук Батулла әлеге әсәрләре нигезендә «Апуш-Тукай», «Күк капусы ачылганда», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» исемле киносценарийлар эшли һәм аларны татар, рус телләрендә бастыра, фильм итеп куюга ирешә. Шулай итеп, татар халкын һәм аның рухи маягы булган Тукай иҗатын таныту, дөньяга чыгаруда зур эшләр башкарып килә.

Р. Батулла иҗатының күп өлешен тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләр алып тора. Бу, бердән, язучының «тарихны шәхесләр тудыра» дигән гыйбарәгә ышануыннан, икенчедән, милли үзаң тәрбияләүдә һәм саклауда конкрет шәхес образының үтемлерәк тәэсир итүен аңлаудан килә. Әсәрләрен әдип күбрәк милли ракурстан яза. Шул ук вакытта образларының тарихта тоткан роле, халык тормышындагы эзләре алар үскән мохит, тәрбия, шәхси холык-фигыльләрен ачу белән бәйләп алып барыла.

Г. Тукай гомеренең соңгы көннәрен тасвирлаган «Сират күпере» драмасы шагыйрьнең 100 еллык юбилеена иҗат ителә. Шагыйрь яшәгән мохит, чор каршылыгы психологик диалогларда тасвирлана. Вакыйгалар, хис-кичерешләр һәм шартлы детальләрне мул кулланып фикерне тыгызлап бирү җыйнак кына әсәрдә дә Тукай холкын тулысынча ачарга ярдәм итә. «Билгеле, бөек шагыйребезнең тормышын сурәтләгән әсәрләр татар әдәбиятында шактый. Һәркем аның турында үз күзаллавы белән, үз күңеле бөеклегеннән торып яза. Батулланың әсәре алар арасында аерылып тора. Аның төп үзенчәлеге – автор Тукайны бизәмичә, шомартмыйча гына тасвирларга омтыла [5: 259] дип яза Р. Зәйдулла язучының «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» повесте турында. Әлеге повесть белән «Сират күпере» драмасының эчтәлекләрендә аерма юк диярлек. Чәчмә әсәрдә автор драмада шартлы исемнәр белән аталган Ф. Әмирханны (Агабәк), Х. Ямашев (Ядкәр), С. Рәмиев (Сагышлы), И. Бикчурин (Бикчура) һ.б-ны үз исемнәре белән күрсәтә һәм тарихи әсәрнең ышандыру көчен тагы да арттыра. Әлеге яшьләрнең мәсләкләре, фикер-карашлары уртак – барысын да милләт язмышы борчый. Аларның үзара аралашуларында XX йөз башының рухи атмосферасы, төшенкелеккә бирелгән реакция еллары күренә.

Батулла Тукай образына зур җаваплылык белән килә. Кереш мәкаләсендә үк ул Тукайның тормыштагы шәхесе белән тарихи шәхес образы арасында аерма булуын, халык күңелендә яшәп килүче һәм яшәячәк шагыйрьнең «әдәби-сәнгати хакыйкать» кануннарына буйсындырылуын билгели. «Создавая исторический портрет и опираясь на сегодняшнюю научную базу о Тукае, писатель охотно допускает трансформацию образа от конкретики и

достоверности, с которыми так неохотно расстаются наша эпоха и педантичное литературоведение, в сторону большей лапидарности и укрупнения образа: представляя поэта «не с бельмом на глазу, с половиной лёгких и с печатью иссушающей его болезни на челе», а мужественным колоссом, богатырём, погибающим за торжество добра и красоты» [6: 256].

Повесть реализм юнәлешендә иҗат ителсә дә, анда мәхәббәткә бәйле романтик буяулар да, пафослы диалоглар да бар. Символик детальләр (зәңгәр һәм ак чәчкәләр, ике башлы Каракош, Шәүлә һ.б.), кинаяле гыйбарәләр исә повестьнең мәгънә катламын киңәйтә. Әсәрдә Тукай төрле яклап ачыла: шәхси холкы, яшәгән мохиты, даирәсе, мәхәббәте, милләтенә мөнәсәбәте һ.б. Гомумән, аның тормышын психологик яссылыкта карауга, шагыйрьнең иҗат психологиясен аңлауга омтылыш зур. Шулай ук шагыйрь белән аралашкан иҗатташ дусларының тышкы кыяфәтләре, характер сыйфатлары, тормыш позицияләре, Тукайга мөнәсәбәтләре уңышлы штрихларда, тарихылыкка хилафлык китермичә, аңлашылырлык итеп бирелгән. Ф. Әмирхан, мисал өчен, арбада, аны Мәхмүт йөртә. Тукай белән янәшә номерда гына тора һәм шагыйрь җанын аңлаган иң якын кеше – ул. Х. Ямашев, С. Рәмиев тә Тукайның хәле авыр дигән хәбәр ишетүгә, розыскта булуларына карамастан, ерак аралардан килеп җиткәннәр. Ямашев татарга хөррият алып киләчәк инкыйлаб турында хыяллана, Рәмиевне эчке борчу кимерә. Исхак Бикчура, гомумән, күңел төшенкелегенә бирелгән – милләтнең киләчәгенә бөтенләй өмете юк.

Тукай – Зәйтүнә мөнәсәбәте әсәрдә югары хисләр дулкынында сурәтләнә. Автор шагыйрьне эчкерсез саф сөю белән ярата белүче, әмма тормышка реаль карап – гомеренең кыска булачагын тоеп, сөйгәнен бәхетсез итәргә теләмәгән олы йөрәкле герой итеп бирә. Зәйтүнә исә бөек шагыйребезне бәхетле итәргә мөмкин булган, җаны-күңеле белән иҗатын һәм холкын кабул иткән фәрештәдәй изге зат буларак ачыла. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк: язучының «Зәйтүнәкәй туташ» хикәясе «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» повестендагы һәм «Сират күпере»ндәге Тукай – Зәйтүнә мөнәсәбәтенең киңәйтелгән, тулыландырылган өлеше кебек. Зәйтүнә монда да Тукайны аңлый, ярата һәм бөек шагыйрьгә тиң була алырдай кыз итеп бирелә.

Хисаметдин бай һәм тайный советник кызы Гәүһәршад ханым повестька Тукайның үз чорындагы мәшһүрлеген һәм катлаулы холкын тулырак ачу өчен кергәннәр. Шул ук вакытта Сираев XX йөз башында үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан татар баеның бер тибы. Тукайның үзе кебек, Батулла сәясәткә катышмый тыныч кына яшисе килгән байлардан ачы көлә.

Повестьтагы күптавышлылык, ягъни геройлар исеменнән сөйләү, үткәнгә кайтып искә төшерүләр, авторның геройларын кульминацион ноктaларга – иң яшерен серләр кычкырып әйтелә торган моментларга куюы психологизм тудыру алымнарына әйләнә. Тарихи фактларга нигезләнү бу әсәрнең тәэсир көчен киметми, киресенчә, повесть бер тында укыла, бербөтен хисси дулкында кабул ителә [4: 360].

Әсәрдә Шәүлә образы аеруча уңышлы эшләнгән. Билгеле булганча, Күләгә образы төрле халыкларның әдәбиятларында архетип санала һәм күп очракта кеше, предмет яки күренешнең тискәре, караңгы парын чагылдыра. Күләгәдән аермалы буларак, Шәүлә образы мөстәкыйль яши. Батуллада исә аңа, фәлсәфи мәгънәдән тыш, милли-сәяси эчтәлек тә салына. (Рус

телендәге әсәрләрендә «Чёрный человек» дип бирелә.) «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» повестенда Шәүлә татарны юкка чыгарырга, бетерергә омтылучы явыз көч булып тора һәм үзенең мәкерле эшен башкара. Ул – киң мәгънәле символик образ. Тукай бүлмәсенә теләнче кыяфәтендә кереп, соңгы казылыкларына кадәр ашап, Тукайның әйләнә-тирәсен күзәтеп һәм рухи дөньясына тыкшынып йөргән Шәүлә шагыйрьнең үлемен тизләтүгә сәбәпче дә була. Ул Тукайның гына түгел, Х. Ямашев, С. Рәмиев, И. Бикчуриннарның да башына җитүче. «Кем син?» дигәнгә: «Бөек держиморда, патша самодержавиесенең ике башлы Каракошы һәм урыс шовинизмының Шәүләсе» [2: 28] дип җавап бирә. Шул ук вакытта автор Шәүләгә үз иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи карашларын җиткерү вазифасын да йөкли. Мисал өчен, инкыйлаб турында ул Тукайга болай ди: «Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр.Барыбыз да барабыз, кая барабыз соң без, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Зыялылар бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне асалар. Алай-болай булмагаедип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак, һәр палач, гөнаһсыз башны чапканда “Яшәсен революция!” дип акырачак» [2: 132].

Повестьта автор Тукайга бәйле татар язмышы турында уйлана. Шагыйрь язмышы халык язмышы белән тиңләштерелә. Ямашевның «Татар ютәленә дәва юк, Тукай», дип әйтүе генә дә милләтебезне ютәлләп ятучы Тукай белән чагыштыруга китерә [1: 9].

«Сират күпере» әсәренең ахырында Шәүләнең Тукайга: «Синең һәр бәйрәмеңне олылап бөтен Россия, бөтен Европа күләмендә уздырачаклар... Синнән кала Әмирханнар, Рәмиевләр, Кариевлар, Сәхипҗамаллар, Камаллар даһи саналачак» [3: 438] диюе шагыйрьнең һәм аның чордашларының милләтне үстерүгә куйган хезмәте беркайчан югалмаячагына, бөек шәхесләрен хөрмәтләгән милләтнең киләчәге дә якты булачагына өметләндерә.

Шулай итеп, Р. Батулла Тукай образына төрле яклап якын килә, аны аңлауга, бүгенге көн ноктасыннан бәяләүгә омтыла, шагыйрьнең зурлыгын һәм фаҗигасен күрсәтү аша татар халкының ачы язмышын сәнгати юллар белән аңлатуга зур хезмәт куя.

## ӘДӘБИЯТ


1. Абдулвалеева Л.Ш. Рабит Батулла драматургиясендә тарихи шәхесләр образлары // Ученые записи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та. 2008. – С. 7–13.

2. Батулла Р. Кылдан нечкә, кылычтан үткен: Кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 143 б.

3. Батулла. Сират күпере // Кичер мине, әнкәй: пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 440 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. Караш җитмәсне колачлаган әдип // Рабит Батулла: тормыш юлы һәм иҗаты: укытучылар, педагогика көллиятләре һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / төз. Хатипов Ф.– Казан: Яз, 2015. – Б. 345–364.

5. Зәйдулла Р. Бәя // Рабит Батулла: Тормыш юлы һәм иҗаты: укытучылар, педагогика көллиятләре һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / төз. Фәрит Хатипов. – Казан: Яз, 2015. – Б. 259.

6. Шагеева Р. Розы вечности // Рабит Батулла: Тормыш юлы һәм иҗаты: укытучылар, педагогика көллиятләре һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / төз. Фәрит Хатипов.– Казан: Яз, 2015. – Б. 254–258.

УДК 82.091

# ИЗУЧАЯ ПУБЛИЦИСТИЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ ТУКАЯ

***В.З. Гарифуллин***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Общеизвестно, что гуманистическое начало является одним из основополагающих в творчестве Габдуллы Тукая. Наиболее ярко гуманистические идеи нашли отражение в публицистическом творчестве классика. Именно на это обратил внимание в своих трудах известный историк и теоретик татарской журналистики Флорид Имамахметович Агзамов. В статье анализируются подходы к изучению журналистско-публицистического творчества Тукая, заложенные в монографии Ф.И. Агзамова «Тукай – журналист».
**Ключевые слова:** Тукай, публицистика, журналистика, гуманизм, жанр, тема.

It is well known that the humanistic principle is one of the fundamental ones in the work of Gabdulla Tukai. The most vividly humanistic ideas were reflected in the journalistic work of the classic. This is what the famous historian and theorist of Tatar journalism Florid Imamakhmetovich Agzamov drew attention to in his works. The article analyzes the approaches of studying the journalistic and journalistic creativity of Tukai, laid down in the monograph of F. I. Agzamov «Tukai – journalist».
**Key words:** Tukay, journalism, journalism, humanism, genre, topic.

# ТУКАЙНЫҢ ПУБЛИЦИСТИК МИРАСЫН БАРЛАУ ЮЛЫНДА

***В.З. Гарифуллин***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Габдулла Тукай татар әдәбиятында һәм иҗтимагый аңында борынгыдан салынган гуманистик традицияләрне иң уңышлы дәвам итүче әдипләребездән. Әлеге идеяләр классикның публицистик иҗатында аеруча киң чагылыш тапкан. Заманында, Тукайның журналистик-публицистик иҗатын өйрәнергә алынгач, татар журналистикасының танылган теоретигы Флорид Имамәхмәт улы Әгъзамов нәкъ менә шуңа игътибар итте.

Әдипнең 100 еллык юбилеена Ф. Әгъзамов аның публицистик эшчәнлегенә багышланган фундаменталь хезмәтен тәмамлады: 1986 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Тукай – журналист» дигән монографиясе басылып чыкты [1]. Нәкъ менә шушы фундаменталь хезмәттә беренче тапкыр бөек иҗатчының мирасы журналистик һәм публицистик яссылыкта өйрәнелде. Бу китап Флорид Әгъзамов тарафыннан башкарылган киңкырлы фәнни-педагогик эшчәнлекнең иң югары ноктасына әйләнде.

Китапта кызыл җеп булып мондый фикер уздырыла: Тукай иҗатын бернинди арттыруларсыз XX гасыр башындагы милли тормыш энциклопедиясе дип атарга була. Әлеге хезмәттән аңлашылганча, Тукай үз миссиясен бик иртә аңлый: милли үзаңны үстерү өчен көрәш чарасы публицистиканы эшкә җигәргә кирәк. Нәтиҗәдә Тукай күп кенә газета-журналларның фактик редакторы, үткен сүзле публицист һәм полемист буларак тиз танылу ала. Үз чорының иҗтимагый-сәяси һәм рухи-мәдәни тормышында Тукай публицистикасының йогынтысы сизелмәгән өлкә бөтенләй булмагандыр, – ди Флорид Әгъзамов. 1904 елдан, «Әл-гаср әл-җәдид» кульъязма журналында аның беренче әсәрләре чыкканнан башлап, 1913 елга, әдипнең вафатына кадәр, татарның иҗтимагый тормышында тирән эз калдырган йөзләрчә фельетон һәм памфлет, публицистик мәкаләләр иҗат ителә.

Үз халкының иҗтимагый-сәяси фикерен үстерүдә Тукай башкарган нәтиҗәле эшчәнлеккә бәя биреп, Ф.И. Әгъзәмов болай дип яза: «Г. Тукайның публицистик иҗатының әһәмияте шунда, ул татар халкының социаль тәҗрибәсен төрле яклап яктырта, халык тәҗрибәсен, тарих тәҗрибәсен тирән гомумиләштерүе белән һәр яңа буынны социальләштерү процессында катнаша [1: 260]. Тукайны укып, Флорид Әгъзәмов аның публицистик осталыгына гына түгел, карашлары һәм фикерләренең заманча аваздашлыгына да исе китә.

Ф.И. Әгъзамов язганча, Г. Тукайның күпкырлы публицистикасында татар халкы яшәешенең гуманистик принциплары һәм традицияләре ачык чагыла. Аның өчен, шагыйрь һәм публицист өчен, татар халкын мәгърифәтле итүнең данлы традицияләре бар, аларда гомумкешелек әхлакый кыйммәтләр салынган. Тукай халык арасында әдәбият, сәнгатьне тарату, матбугатны үстерү алга таба үсешнең төп чаралары дип саный. Ул газета-журналларның артуына, һәр кешенең көндәлек тормышына басма сүзнең үтеп керүенә аеруча зур өметләр баглаган [1: 146].

Китабында Әгъзамов Тукайның журналистлык осталыгы тамырларын ачыкларга тырыша. Әйтик, монографиядә Тукай публицистикасының жанр дифференциациясен өйрәнү аерым урын алып тора. Флорид ага Тукай иҗатында хәзерге заман журналистикасында яшәп килә торган жанрларның күпчелеге кулланылуын ачыклый һәм Тукай тарафыннан беренче тапкыр татар журналистикасында яңа жанр формаларының әйләнешкә кертелүе турында нәтиҗә ясый. Шулай ук журналистиканың кайбер традицион жанрлары Тукай тарафыннан аның пародия формасында да кулланыла. Татар журналистикасында беренче тапкыр Габдулла Тукай кулы белән публицистиканың юл очеркы, шигъри фельетон һәм памфлет кебек жанр формалары барлыкка килде. Ә менә «Безнең милләт үлгәнме, әллә ул йоклаган гынамы?» дигән программ мәкаләсе публицистик дәлилләүнең иң уңышлы үрнәге булып тора.

Флорид Имамәхмәт улы Габдулла Тукай чын сәяси публицистика остасы булган, дип тә билгеләп үтә. Тукай эсерлар, милләтчеләр, кадетлар, пантюркистлар һәм панисламчылар лагерыннан оппонентлар белән кыю бәхәсләшкән, аларны тәнкыйть утына тоткан, сәяси памфлетлары белән дә дан казанган, – ди ул. 1906 елның июнендә «Уклар» сатирик иллюстрацияле журналы барлыкка килгәч, аны нәшер итүдә актив катнашып, Тукай сатира остасы буларак танылу ала. Бу уңайдан Флорид Әгъзамов үзенең остазларыннан берсе, профессор М. Гайнуллинның «Уклар» журналын Тукайның сатирик әсәрләр җыентыгы дип санарга мөмкин, дип әйткән сүзләренә игътибар итә.

«Тукай – журналист» монографиясендә классикның журналистика теориясенә карата карашлары бер система буларак тәкъдим ителгән. Шунысы гаҗәп, милли вакытлы матбугат тарихына, журналистиканың функцияләренә һәм бурычларына, аның төп принципларына, авторлык хокукларына, басмаларны гамәлгә кую мәсьәләләренә, тәрҗемә теориясенә кагылышлы күп кенә заманча проблемалар Тукай әсәрләрендә күтәрелгән булган икән. Аның эшләрендә XX гасыр башындагы барлык төп басмаларның, шул чордагы әйдәп баручы журналист-публицистлар иҗатының характеристикасын табарга була. Ә хәзерге заман журналисты нинди булырга тиеш дигән сорауга, Әгъзамов сүзләренчә, без Тукайның Хөсәен Ямашевка багышланган әсәрләрендә җавап табабыз. Ямашевның типлаштырылган образы аша ул чын халык журналистының нинди булырга тиешлеген күрсәтә.

Флорид Әгъзамовның бу китабында татар журналистикасының үсеш перспективалары турында Тукайның карашлары бергә туплап бирелгән.

Китапның махсус бүлеге Тукайның публицистик иҗатында фольклорның ролен өйрәнүгә багышланган. Ф. Әгъзамов сүзләренә караганда, Тукай нәкъ менә фольклорда барлык мөһим проблемаларны хәл итүнең иң гуманлы нигезен күрә. Фольклор – шагыйрь һәм публицист өчен иҗат чыганагы, иҗаттагы яңа темалар өчен бетмәс-төкәнмәс алтын чыганак. Беренчедән, халык иҗаты әсәрләрендә ул үзе өчен идеяләр, сюжетлар, сәнгатьлелек чараларын туплаган. Биредә Тукай еш кына фольклордан килгән аллегорик тел алымнарына мөрәҗәгать итә, алар әсәрләрнең идеяле эчтәлеге белән органик рәвештә тәңгәл килә һәм максатка ирешүдә зур роль уйный. Икенчедән, ул үзенең публицистикасында фольклорның иҗтимагый фикер, әдәбият һәм телне формалаштыруга, белем һәм тәрбия процессына йогынтысын ачык чагылдыра. Бу нисбәттән аның «Халык әдәбияты» һәм «Халык моңнары» әсәрләре зур әһәмияткә ия булуы ассызыклана.

Тукай үзенең публицистик чыгышларында тәрҗемә теориясе проблемаларын да күтәрә һәм алар бүгенге көндә гаять актуаль булып тора. Тукай, башка телдән тәрҗемә иткәндә, барыннан да элек, халыкның гореф-гадәтләре, менталитеты исәпкә алынырга тиеш, дип саный. Әйтик, фельетоннарның берсендә ул Сәгыйть Рәмиевнең Лев Толстой исемен «Арыслан Юан» дип тәрҗемә итәргә маташуын тәнкыйть утына тота. Танылган тәрҗемәче буларак, Ф. Әгъзамов үзе дә практикасында Тукай тәкъдимнәрен куллана. Начар тәрҗемәле текстларга карата ул Тукайның яраткан «Чыктым аркылы күпер» гыйбарәсен куллана иде.

Шулай итеп, Флорид Әгъзамов Тукайның искиткеч кыю публицист, ачык һәм аяусыз полемист, нәзакәтле тәнкыйтьче, сабыр, зирәк тәрбияче булуын фәнни яктан нигезләп бирде. Тукайны укып, Флорид Әгъзәмов әдипнең публицистик осталыгына гына түгел, ә аның карашлары һәм фикерләренең заманча аваздашлыгына да исе китә. Тукай публицистикасы татар журналистикасы тарихының иң күренекле сәхифәләренә карый. Бу уңайдан Флорид Әгъзәмов Тукайны өйрәнүче яшь галимнәр алдына да бурычлар билгели: төрки халыкларның журналистикасын торгызуда һәм үстерүдә безнең классигыбызның ролен һәм урынын билгеләү, Тукай җитәкчелегендә басылган газета-журналларның Россия халыкларының иҗтимагый фикерен үстерүгә һәм башка басмаларга йогынтысын өйрәнү, Тукайның милли журналистикага карашларын башка теория һәм журналистика практикалары белән чагыштыру, татар әдәби теленең публицистик стилен булдыруда һәм үстерүдә Тукайның ролен өйрәнү, шулай ук иҗтимагый-сәяси әдәбият тәрҗемәчесе буларак Тукай тәҗрибәсен гомумиләштерү.

Әгъзамов тарафыннан яңа буын галимнәре алдына куелган кайбер мәсьәләләрнең чишелешен без Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әзерләгән зур академик басмада – «Тукай энциклопедиясе»ндә табабыз [2]. Сүз уңаеннан, үз вакытында Флорид Әгъзамов әлеге энциклопедияне әзерләү башында торган эшче төркемнең актив бер әгъзасы да иде.

## ӘДӘБИЯТ

1. Әгъзамов Ф.И. Тукай – журналист. – Казань: Татар. кит. нәшр., 1986. – 271 б.
2. Габдулла Тукай: энциклопедия / под общ. ред. З.З. Рамеева. – Казань, 2016. – 863 с.

УДК 821.512.145

# ТУКАЙ В ЛИТЕРАТУРНО-КРИТИЧЕСКОЙ И НАУЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ФАТИХА САЙФИ-КАЗАНЛЫ

***Т.Ш. Гилазов***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

Статья посвящена литературоведу и критику Фатиха Сайфи-Казанлы. Материалом послужили его научные и критические статьи, посвященные народному поэту, классику татарской литературы начала XX века Г. Тукаю. В статье исследуются принципы и методы оценивания Ф. Сайфи-Казанлы духовного наследия поэта. Выявляются характеристики академического издания Г. Тукая. Оценивается вклад ученого в формирование и становление как науки о Тукае, так и практической и теоретической текстологии в татарском литературоведении.
**Ключевые слова:** научная деятельность, принципы, научное издание, социологизм, творчество поэта, народность, рукописи.

The article is dedicated to the literary critic and critic Fatih Sayfi-Kazanli. The material was his scientific and critical articles dedicated to the folk poet, the classic of Tatar literature of the early twentieth century G. Tukai. The principles and methods of assessing F. Saifi-Kazanli of the poet's spiritual heritage are investigated. The characteristics of the academic edition are revealed. The role of the scientist in the formation and development of the science of Tukai and practical and theoretical textual criticism in Tatar literary criticism is evaluated.
**Key words:** scientific activity, principles, scientific publication, sociologism, creativity of the poet, nationality, manuscripts.

# ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫНЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ҺӘМ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ТУКАЙ

***Т.Ш. Гыйлаҗев***
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Фатих Сәйфи-Казанлы узган XX гасырның беренче утыз еллыгында татар әдәбияты белеме һәм тәнкыйте тарихында мәгълүм роль уйнаган, әмма киңкырлы эшчәнлеге, кызганычка каршы, монографик планда тикшерелеп, үзенә лаек бәя алмаган галимнәр буынының бер вәкиле булып тора.

Ф. Сәйфи-Казанлының өйрәнелү тарихына беркадәр күз ташласак, 1960 елларга кадәр ул социологизм, вульгар социологизм концепциясенә аеруча нык бирелгән әдип һәм галим буларак бәяләнә. «Хрущев җепшеклеге» чорында М. Мәһдиев [6], Р. Мөхәммәдиев [7] фәнни тикшеренүләрендә аңа мөнәсәбәт уңай якка үзгәрә. XX–XXI гасыр чикләрендә Э. Галиева, З. Рәмиев, Ф. Галимуллин, Н. Гыйззәтуллин, Т. Гыйлаҗев һ.б.ларның хезмәтләрендә, тикшерү предметына нисбәтле, Ф. Сәйфи-Казанлының фәнни эшчәнлегенә игътибар ителә. Әмма, еллар үткән саен, бу бай мирас яңача укыла һәм шәрехләнә. Фатих Сәйфи-Казанлының әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми мирасын бүгенге әдәбият белеме ирешкән казанышлар ноктасыннан тикшерү мәкалә темасының фәнни яңалыгын билгели.

Ф. С.-Казанлы 1910 нчы елларда үзен үзенчәлекле каләме булган, туры сүзле, әдәби күренешне фәнни-теоретик яктан гына түгел, ә фәлсәфи, эстетик ноктадан тикшерергә, аларның синтезында бәяләргә омтылган тәнкыйтьче итеп таныта. Әдип һәм галим тормышының һәр баскычы иҗади һәм иҗтимагый активлык белән аерылып тора. Иң нәтиҗәле, продуктив эшләгән

чоры татар әдәби-мәдәни хәятының, әдәбият белеменең катлаулы, каршылыклы һәм фаҗигале 1920–1930 елларына туры килә. Шушы баскычта яңа социокультурологик шартларда бай әдәби мирасны туплау, киләчәк буынга саклау, бүгенге көн укучыларына җиткерүнең юллары, программалары һәм стратегиясе эшләнә. «Ул елларда татар әдәбият белемендә барлыкка килгән культура-тарих мәктәбе безгә Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Гали, Г. Толымбай кебек бик күп әдәбият галимнәрен, әдәбият фәне әһелләрен бирде» [3: 15], – дип яза Э. Галиева. Чор соравына җавап итеп, Ф. Сәйфи-Казанлы татар классиклары Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд әсәрләрен җыеп бастырып чыгаруда зур көч куя.

Ф. Сәйфи-Казанлы Г. Тукай шәхесенә һәм аның кабатланмас бай рухи мирасына ихтирами, игътибарлы мөнәсәбәте белән аерылып тора. Тәнкыйтьченең 1920 елларга кадәр шагыйрьгә багышланган мәкаләләре матбугат битләрендә күренми, әмма алар фани дөньяда бер-берсе белән таныш булганнар, аралашканнар. «Ф. Сәйфи-Казанлы “Ялт-йолт” сатирик журналында байтак кына сатирик парчалары белән чыгыш ясый. Мәгълүм булганча, гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу журналда Габдулла Тукай актив эшләп килә. Шуңа күрә Фатих Сәйфи мәшһүр шагыйрь белән дә таныш булган» [4: 186], – дип яза Нур Гыйззәтуллин. Тукайның Клячкин хастаханәсендә алынган соңгы фотосурәтләренең берсендә шагыйрь янында Г. Кариев, Ш. Әхмәровлар белән берлектә Ф. Сәйфи-Казанлыны да күрәбез.

Академик басма чыгару мәсьәләсе кузгалганчы ук, Ф. Сәйфи-Казанлы Г. Тукай шәхесенең һәм иҗатының бөеклеген төшенеп, аның әлегә кадәр басылмаган, билгеле булмаган әсәрләрен барлау юлында эшне башлап җибәрә. «Онытылган документ» (1927) [10], «Г. Тукайның басылмаган әсәрләре» (1928) [14] кебек язмаларында шагыйрьнең моңа кадәр нәшер ителгән җыентыкларына кертелмәгән, тәнкыйтьчеләр-галимнәр игътибарыннан читтә калган язмаларының (Уянгач беренче эшем»), поэмаларының, сатирик парчаларының («Кечкенә бер көйле хикәя», «Һәзиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа», «Шыер» һ.б.) иҗат ителү тарихын бәян итә һәм аларның текстларын урнаштыра. Шагыйрь шигърияте турында нигезсез хөкемнәр, аерым алганда Г. Ибраһимовның карашлары хакында уйлана. Бу язмаларда автор Г. Тукай әсәрләренең тулы басмасын чыгару турында сүз алып бара башлый.

Татар дөньясында беренче тапкыр (татар матбугатында «Бездә беренче тапкыр» дип билгеләнә дә) [5: 16] классик әдипләр мирасының академик басмаларын бастырып чыгару тәҗрибәсе дә классик шагыйрь Г. Тукайдан башлана. Әлеге олы хезмәткә җитди якын киленеп, «Яңалиф» җәмгыятенең нәшрият бүлеге тарафыннан академик нәшер чыгаруның махсус программасы төзелә [5: 16]. Басмаханә тарихында тәүге мәртәбә эшләнә торган гаять җаваплы яңа хезмәткә бу вакытта «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире вазифаларын башкарган Ф. Сәйфи-Казанлы төзүче һәм мөхәррир итеп билгеләнә. Тукай әсәрләренең дүрт томлыгын әзерләү максат итеп куела. Галим-текстологның фидакарьләрчә тырышлыгы белән 1929 елда академик нәшернең беренче томы дөнья күрә. Шушы уңайдан матбугат битләрендә берничә рецензия, язма дөнья күрә. Араларында үзенең хәерхаклы мөнәсәбәте белән Х. Вәлинеке аерылып тора [1]. Ә тәнкыйди рухлы Г. Галинең «Академик нәшерләрдә гыйльми нигезләр (Г. Тукай әсәрләренең академик нәшере турында)» дигән зур күләмле язмасы «Безнең юл»

журналының 1929 елның 6–7 нче саннарында басыла [2: 59–76]. Ул аны укучы хөкеменә «Кызыл Татарстан» газетасы сәхифәләрендә тагын бер кат тәкъдим итә. Мәкаләдә язучылар мирасының академик басмаларын төзүнең төп, нигез принциплары, аспектлары ачыклана. Шагыйрьнең мирасын барлау, туплау, аны тарихи-гыйльми эшенә яңача якын килү күзәтелә, тукайчы галимнәр алдына яңа, үзгә бурычлар куела. Мәгълүм булганча, академик нәшер Тукай мирасын гыйльми нигездә тулы итеп, төрле яклап яктырту максатын куя. Шагыйрь әсәрләрен барлау, туплау эше планлы рәвештә киң колач ала.

Тукайчы галимнәр тарафыннан бу вакытка кадәр игътибарга алынмаган «шагыйрьнең кульязмаларын» өйрәнү, цензура, охранка архивларыннан, татарча китаплар басылган типографияләрнең билгесез җирләрдә яткан архивларындагы кульязмаларны барлау мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Шушы уңайдан төрле институтлар оештырыла: Тукай җәмгыяте, Татар культура йорты һ.б. Киләсе томлыклар өчен кульязмаларның, аеруча Тукайның биографиясенә караган материалларның аз булуына борчылып, Ф. Сәйфи-Казанлы «Үтенеч» (1929) [13] язмасы белән татар әдәби җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать итә. Автор Рус-Ауропа тәҗрибәсенә таянып, татар классиклары, шул исәптән Тукай белән бәйле материалларны туплау һәм саклау программаларын, юлларын тәкъдим итә. Бу мәсьәләне гыйльми тирәнлек белән өйрәнгән З. Рәмиев болай дип яза: «Классик әдипләребезнең тупланмаларын төзегәндә, кульязмада гына яшәмәктә булган әсәрләренә дә игътибар итү 20 нче еллар ахырында аеруча көчәеп китә» [9: 88].

Тукай әсәрләренең академик басмаларын социологик анализсыз басу һәм бастыру, Г. Гали карашынча, «иң зур принципиаль хаталардан», матбугат өлкәбездәге «бик зур идеология тайпылышыннан» санала. Ф. Сәйфи-Казанлының исә бу эшне иң соңгы планга калдыруы сәяси һәм гыйльми хата буларак ассызыклана. Бу мәсьәлә Өлкә партия комитеты каршында да тикшерелеп, сәяси ялгыш-хата төсендә бәяләнә һәм тиз арада чара күрү сорала. Күренә ки, Г. Гали мәсьәләгә сыйнфый-социаль ноктадан якын килә. «Яңалиф» битләрендә Ф. Сәйфи-Казанлы «Саннан сыйфатка»дигән җавап мәкаләсе белән чыгыш ясый һәм «һәрбер басылган классикның тулы әсәрләренә аерым кеше тарафыннан марксизм анализы ясау мәҗбүр ителүе» [15] хакында әйтеп чыга. Г. Тукайның тулы әсәрләрен баскан чагында кабул ителгән программа буенча аның тәнкыйть макаләсе, гәрчә китапның дүртенче томына калырга тиеш булса да, югарыда сәбәпләрнең кушуынча, шагыйрьнең икенче томына «Г. Тукай әсәрләренең иҗтимагый һәм сәяси йөзе» исемендә сүз башы язылачагын», Г. Гали күрсәткән кимчелекләр-ялгышларның төзәтеләчәген хәбәр итә.

Галим-текстологның «Саннан сыйфатка» язмасын укыганда да, икенче томга язылган мәкалә белән танышканда да, авторның эчке каршылыгы сиземләнә. Ул планлаштырган тәнкыйть мәкаләсендә шагыйрь лирикасының сәнгати ягын калку бәяләү, киңкырлы анализ күздә тотылган була: «Башта язарга уйлаган киң тәнкыйть мәкаләсендәге: Тукай иҗатының үсүе, Тукай шигыренең хасиятләре, аның шигыренең вәзен-кафия законнары, Тукай шигырьләрендәге аһәң, сүз төзелеше, Тукай реалист, романтик шагыйрьме, Тукайның пессимизмга бирелүе, Тукай теленең эволюциясе, Тукай әсәрләрендәге пейзаж, Тукайның гыйшык шигырьләре» кебек моментлар керми» [12: I]. Бу үзенчәлекләр киләчәктә язылачак томнарга кал-

дырылып, «инде күпчелек өчен практик мәсьәлә беренче адымда аның әсәрләрендәге сәяси-иҗтимагый момент булганга, иң элек шушы мәкалә белән канәгатьләнергә карар кылынды» [12: I], – дип яза тәнкыйтьче. Димәк, галим-тәнкыйтьчеләр, шул исәптән Ф. Сәйфи-Казанлы да, шул чордагы команда-административ дәүләтнең корбаннары да булганнар.

1920–1930 еллар татар әдәбият белемендә үз үсеш сукмагын булдырган социологик юнәлеш вәкиле буларак мәкалә авторы Г. Тукай шигърияген иҗтимагый, социаль-сыйнфый ноктадан тикшерә. Тукайның бөтен әсәрләрендә вак буржуаның идеологиясе, сыйнфый йөзе тулы рәвештә гәүдәләнүен һәм шушы яктан шагыйрь рухи мирасының тарихи әһәмиятен билгели. Мәкаләнең башлам өлешендә аның язылу сәбәпләре һәм максаты шәрехләнгәч, Ф. Сәйфи-Казанлы Тукай иҗатының өйрәнелү тарихына: Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Гыйсмәти, Г. Сәгъди, Ф. Агиев, С. Рәмиев һ.б.ларның мәкалә-язмаларына кыскача күзәтү ясый, экскурсны үз карашлары белән синтезлый. Марксистик-ленинчыл идеологиянең дингә мөнәсәбәте үтә дә тискәре булуы һәркемгә мәгълүм. Шуннан чыгып, һәр тәнкыйтьченең үз язмасын Г. Тукайның иҗтимагый-сәяси карашларын, шул уңайдан шагыйрьнең Ислам диненә мөнәсәбәтен ачыклаудан башлавы аңлашыла булса кирәк. Г. Гали, Ф. Бурнаш, Г. Сәгъдиләрнең бу мәсьәләдә бәя-хөкемнәре хәзерге тәнкыйтьне күтәрә алмыйлар. Ә менә Фатих Сәйфи-Казанлы Тукайның дини тойгыларын, Коръән тәгълиматы белән бәйләнешен билгеләүдә бүгенге көн Тукай гыйльмияте билгеләгән ноктада, позициядә тора. Тукайның «динне, милләтне (миллилек. – асс. минеке) татар халкы үсеше өчен иң кирәкле элемент дип ышануы, Алланың барлыгын һәм берлеген тануы, «рәхмәте бик киң булган Аллага», «Алланың әмренә буйсыну», әдәби әсәрләрендә илаһи гаделлеккә омтылуы күрсәтелә. «Г. Тукайның ышанычы, дини йөзе шундый иде. Бу турыда икеләнү, тартып, йолкып аны «алласыз» ясау, материалист ясау, Тукайның үзенә һәм Тукайны тикшерүчеләргә, укучыларга зур хыянәт» [12: XXII]. Тәнкыйтьче шушы мәкаләсендә үк Тукайның Ислам диненә түгел, ә надан, әхлаксыз, дин белән кәсеп иткән руханиларга тискәре, сатирик мөнәсәбәтен ассызыклый. «Коръәнне белгән, хәдис белән гамәл кылган муллаларга, динчеләргә каршы түгеллеге» әйтелә. Бу проблемага мәкаләнең VI нчы «Тукай шигырьләрендә динчелек мәсьәләсе характерлы моментмы?» дигән бүлеге багышланып, авторның гыйльми фикерләре шагыйрь шигърияттеннән мисаллар белән дәлилләнеп, үрелеп бара.

Тагын әһәмиятле бер моментка тукталасы килә. Ф. Сәйфи-Казанлы Тукай иҗатының милли рух, милли хис, аның хакында уйланулар белән сугарылуын кат-кат ассызыклый: «Тукай заманының татар милләтчеләре арасында иң күрекле урын тотучы шагыйрь, ул кулына каләм алып яза башлаганнан бирле милли моментны җырлый, үлгән минутына кадәр шул моментны онытмады һәм һичбер вакыт хыянәт кылмады. <...> Тукай дин белән милләтне аерып йөртмәде, аларга игез бала төсле карап килде» [12: XIII–XIV].

Фатих Сәйфи-Казанлы эшчәнлегенең гамәли һәм теоретик әһәмияте тагын Г. Тукай әсәрләрен төрле шәкелдә нәшер итү тәҗрибәсендә билгеләнә. Тукай башлаган эшне Җамал Вәлиди үз кулына алып, тәүге мәртәбә шагыйрьнең «Г. Тукайның мәҗмугаи асаре»н нәшер итсә, Фатих Сәйфи-Казанлы исә татар дөньясында классикларның күптомлыкларын, академик

басмаларын чыгаруның олы юл башында тора. Әдәбиятчы-текстолог З. Рәмиев аның өч томлыгын «Г. Тукайның мәҗмугаи асаре» белән чагыштырма планда тикшерә. Шагыйрь иҗатын яктыртуда тулылылыкка омтылыш, Тукай әсәрләренә аңлатма һәм искәрмәләр язу һәм текстларның урнаштырылуында хронология ысулының өстенлек итүе Ф. Сәйфи-Казанлы басмасының җитди һәм уңай аерымлыклары төсендә күрсәтелә. Ул галимнең «татар әдәбияты текстологиясенең совет чорындагы казанышы саналырлык хезмәт башкаруын» ассызыклый [8: 341–342]. Моңа кадәр дөнья күргән томлыкларга тукталмастан, 2011–2016 елларда Г. Тукайның Алты томлык академик басмасын төзүчеләр, искәрмә һәм аңлатмаларын язучылар Фатих Сәйфи-Казанлының өчтомлык «Г. Тукай әсәрләре»нә, ул туплаган тәҗрибәгә нигезләнәләр.

Димәк, Фатих Сәйфи-Казанлының Г. Тукайга багышланган мәкаләләре аның иҗатын, тормыш юлын тулы яктырту максатын куймыйлар. Алар шагыйрьнең фәнни биографиясен һәм рухи мирасын барлау,тулыландыру һәм Гарби Аурупа-Рус мәдәниятләре үрнәгендә академик нәшерен чыгару максатында язылганнар. Тәнкыйди язмаларда куелган төп максатларга нисбәтле, Ф. Сәйфи-Казанлының Тукай иҗатына нәзари карашлары, уйланулары да чагыла. Мәкаләләрендә, «Яңалиф» журналының идарә сүзләрендә, сүз башларында галим һәм тәнкыйтьче 1920–1930 елларда әдәбият белеме фәнендә формалашкан социологик юнәлеш, мәктәп вәкиле буларак чыгыш ясаса да, ул вакытта үзенең үсеш тарихында катлаулы һәм каршылыклы дәверенә кергән Тукайны өйрәнү фәненең яңа аспектларын, әһәмиятле катламнарын күтәреп, совет чорында аның үсеш юлларын билгели.


ӘДӘБИЯТ

1. Вәли Х. Г. Тукай әсәрләре // Яңалиф. – 1929. – № 9. – Б. 14.

2. Гали Г. Академик нәшерләрдә гыйльми нигезләр (Г. Тукай әсәрләренең «академик» нәшере турында) // Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә. – Казан: Татиздат, 1931. – Б. 59–76.

3. Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. – Казан: Фэн, 2002. – 360 б.

4. Гыйззәтуллин Н. Үз заманының улы // Казан утлары. – 1998. – № 3. – Б. 185–186.

5. Идарә сүзе. Татар әдәбият мәйданында зур бүләк. Бездә беренче тапкыр // Яңалиф. – 1928. – № 17. – Б. 16.

6. Мәһдиев М.С. Татар совет әдәби тәнкыйте (1917–1932 еллар): филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 1963. – 325 б.

7. Мөхәммәдиев Р.С. Аның якты образы // Әгәр без янмасак. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 144 б.

8. Рәмиев З. Ул Тукайның өчтомлыгын төзегән // Әдәбиятчы-текстолог язмалары (1990–2013). – Казан: Ихлас, 2014. – Б. 338–342.

9. Рәмиев З.З. XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. – Казан: РИЦ «Школа», 2000. – 179 б.

10. Сәйфи-Казанлы Ф. Онытылган документ (Г. Тукайның үлүенә 14 ел тулу уңае белән) // Яңалиф. – 1927. – № 3. – Б. 3–5.

11. Сәйфи-Казанлы Ф. Тукай әсәрләрендә пародия, сатира, ирония һәм юмор // Г. Тукай әсәрләре. 3 т. – Казан, 1931. – Б. III–XXXII.

12. Сәйфи-Казанлы Ф. Тукай әсәрләренең иҗтимагый һәм сәяси йөзе // Г. Тукай әсәрләре. 2 т. – Казан, 1929. – Б. I–XLII.

13. Сәйфи-Казанлы Ф. Үтенеч // Яңалиф. – 1929. – № 15. – Б. 16.

14. Сәйфи-Казанлы Ф. Г. Тукайның басылмаган әсәрләре // Яңалиф. – 1928. – № 6 – 7. – Б. 1–4.

15. Сәйфи-Казанлы Ф. Саннан сыйфатка // Яңалиф. – 1929. – № 21. – 2 тит. бите.

УДК 811. 371

# ОТНОШЕНИЕ Г. ТУКАЯ К ВОСПИТАТЕЛЬНО-ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМУ ПРОЦЕССУ

***Л.М. Гиниятуллина, М.М. Шакурова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье раскрывается отношение великого татарского поэта Габдуллы Тукая на воспитательно-образовательный процесс своей современности. Творчество поэта играет особую роль в детской литературе, как средство развития и воспитания детей. Авторы попытались рассмотреть труды и произведения Тукая именно с данной точки зрения.
**Ключевые слова:** Тукай, воспитательно-образовательный процесс, татарский язык, произведение, стих.

The article reveals the attitude of the great Tatar poet Gabdulla Tukai to the educational process of his modernity. The poet's work plays a special role in children's literature, as a means of developing and educating children. The authors tried to consider the works and works of Tukai from this point of view.
**Key words:** Tukay, educational process, Tatar language, work, verse.

# Г. ТУКАЙНЫҢ УКЫТУ-ТӘРБИЯ БАРЫШЫНА МӨНӘСӘБӘТЕ

***Л.М. Гыйниятуллина, М.М. Шәкүрова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар интеллигенциясе заман таләпләренә җавап бирә алырдай мәгариф системасы формалашуның зарурлыгына төшенә. Җәмгыятьтә реформаторлык хәрәкәте башлана, иске карашлы кадимчеләргә каршы чыккан җәдидчеләр белем бирүнең яңа ысулларын тәкъдим итәләр. Бу еллар аралыгы татар телен укыту методикасының яна юлларын эзләү чоры буларак бәяләнә. Шушы елларда дәреслек буларак кулланылган әлифбалар, үзөйрәткечләр, грамматика китаплары, методик әсбаплар басылып чыга. Башлангыч мәктәпләрдә татар телендә укырга-язарга өйрәтүне җиңеләйтү, җәдид мәктәпләре өчен татарча дөньви әлифбалар төзү турында бәхәс бара. Татар тел белемен үстерүдә, укыту методикасын камилләштерүдә, грамматик төшенчәләрнең терминнарын булдыруда бер төркем тел-әдәбият белгечләре киң эш җәелдереп җибәрәләр (Г. Ибраһимов, В. Богородицкий, Г. Алпаров, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев, Г. Нугайбәк, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Ф. Сәйфи һ.б).

1899 елда Уфа шәһәрендә алфавит һәм орфография мәсьәләләренә багышланган беренче конференция үткәрелә. Анда яңа чор мәктәпләре өчен программалар төзү һәм имля берләштерү турында карар кабул ителә. XX йөз башында татар әдәби теленең фонетик-орфографик нормалары турында бәхәсләр тагы да көчәеп китә, алфавитны алмаштыру турында да сүзләр кузгатыла.

1905 елдан соң төрле төбәкләрдә (Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург һ.б.) татар телендә газета-журналлар чыга башлый («Тәрбияи этфаль» («Балалар тәрбиясе». Мәскәү), «Тәрбия» (Казан), «Мәктәп» (Казан), «Мөгаллим» (Оренбург) журналлары һ.б.). Бу елларда шәкертләр уку-укыту программасына, надан хәлфә һәм ишаннарга ризасызлык белдерәләр, мәдрәсәләрне ташлап китәләр, фәннәрне киңрәк өйрәнүне таләп итәләр.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның әдип, шагыйрь буларак формалашу чоры да нәкъ шушы елларга туры килә. Төрле газета-журналлар чыгаруда актив катнашкан, хаҗга киткән хәлфә Гомәр Хөсәенов урынына дүрт ай буе «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә балалар укыткан Габдулла Тукай да үз чорының укыту-тәрбия өлкәсендәге үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Мәдрәсәдә ул уку бүлмәсенә моңа кадәр булмаган кара такта алып кереп элә, балаларны укытканда язуга, телгә, хисапка игътибар бирә. Шушы чорда язган әсәрләрендә дә Тукай кадими укыту системасын тәнкыйтьли, бердәм, мәгърифәтле булырга чакыра («Туган тел», «Дустларга бер сүз», «Шәкерт, яки бер очрашу», «И каләм», «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару», «Әлифба» һ.б.).

«Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк...
Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди».
("«Дустларга бер сүз»")

«Бер бала атасына:

– Әти, син үзең күзлек киеп китап укыйсың бит, миңа да бер күзлек алып бирсәнә, мин дә китап укыр идем, – диде.

Атасы:

– Ярар, угылым, мин сиңа күзлек алырмын, ләкин ул балалар күзлеге генә булыр, – дип, угылына бер әлифба китабы алып бирде» («Әлифба»).

Шагыйрь «Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәрендә Кырлай авылында башта бер ел кызлар белән бергә абыстайга дини китаплардан «Иман шарты»н өйрәнергә йөрүе, аннары икенче елны мәдрәсәгә баруы турында болай дип яза: “Мин мәдрәсәдә, “Һәфтияк” иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, “Бәдәвам”, “Кисекбаш”ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар» [1: 21].

Г. Тукайның «Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910) һ.б. хезмәтләрендә шагыйрьнең укыту-тәрбия өлкәсенә караган фикерләре, методик уйланулары чагылыш таба [2: 37–44]. Әлеге китапларына Тукай балаларга белем әхлакый, эстетик тәрбия бирә торган әсәрләрен туплаган. Әсәрләрнең геройлары балага табигать кануннарын, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңларга булыша, башка кешенең кайгысын, шатлыгын уртаклашырга өйрәтә һ.б. Аның шигырьләрендә балалар психологиясе ачык чагыла.

Габдулла Тукай әсәрләрен туган як табигатенең кече энциклопедиясе дип атап була. Әдәби әсәр аша туган якны өйрәнүнең тәрбия процессындагы роле әйтеп бетергесез.

Димәк, Г. Тукай, беренчедән, әсәрләрендә балаларга белем һәм тәрбия бирүне алгы планга чыгарса, икенчедән, автор үз чорының мәгариф системасына битараф калмый. Газета-журналлар аша да, үзенең махсус хезмәтләре ярдәмендә дә укыту-тәрбия өлкәсенә булган мөнәсәбәтен, фикерләрен, уй-теләкләрен киң җәмәгатьчелеккә җиткерә.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Габдулла. Әсәрләр: биш томда / төз. Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 21.

2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы: метод. кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 37–44.

3. Шакурова М.М. Халык җырлары турында Г. Тукайның карашлары / Развитие научно-методической мысли: достижения, проблемы, перспективы: Сборник материалов II Республиканской научно-методической конференции (07 апреля 2014 г.). – Казань: Отечество, 2014. – С. 188–190.

УДК 82.091

## О МАЛОИЗВЕСТНОМ ПЕРЕВОДЕ СТИХОВ ТУКАЯ НА РУССКИЙ ЯЗЫК

***Г.И. Гиматдинова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Статья посвящена малоизвестному сборнику «Избранных стихотворений» классика татарской литературы Г. Тукая, увидевшая свет на русском языке в 1920 г. в Ташкенте в переводе с татарского на русский язык литературоведом В. Вольпина. В статье дается анализ содержания книги, объясняются мотивы тематического подбора стихотворений, даются сравнения с оригиналом и аналогичными переводами, выполненными другими переводчиками Г. Тукая. Также в статье рассматривается проблема конъюктурного, вольного перевода, искажающего оригинальный текст в угоду тех или иных идеологических установок.
**Ключевые слова:** литература народов РФ, татарская литература, Г. Тукай (1886–1913), литературный первод.

The article is devoted to little known collection of poems of classic Tatar literature of Gabdulla Tukay. The This poetry collection was published in Tashkent in 1920.The collection was translated from tatar into Russian by literary critic V. Volpin. In article analyzes the content of the book, explains the motives of thematic selection of poems, the poems compare with original and another translations. Also the article deals with the problem of freely translation. It can change the meaning of original poems to satisfy the ideology of that time.
**Key words:** The literature of the nationalities of the Russian Federation, Tatar literature, G. Tukay (1886–1913), literary translation**.**

## ТУКАЙНЫҢ АЗ БИЛГЕЛЕ БУЛГАН РУСЧАГА ТӘРҖЕМӘЛӘР КИТАБЫ ТУРЫНДА

***Г.И. Гыйматдинова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү инде йөз елдан артык дәвам итә. Бу юнәлештә табылган һәр яңа чыганак безнең өчен зур әһәмияткә ия. Әлегә хәтле артык билгеле булмаган, ул чыганак турында артык мәгълүмат күренмәгән хезмәткә багышлана бу мәкалә. Сүз Габдулла Тукайның вафатыннан соң, җиде ел узгач,1920 елда Ташкентта басылып чыккан аның зур булмаган шигырьләр җыентыгы турында бара. Тышлыганда «Абдулла Тукаев "Избранные произведения"» [1: 1] исеме куелган. Җыентык рус телендә басылган, 16 биттән тора. Китап башында Ибнеәмин Янбаев Тукайның кыскача биографиясе 10 биттә бирелеп, аннан соң нибары алты шигыре генә Валентин Вольпинның[1] ирекле тәрҗемәсендә кергән. Бу сирәк саналган китап турында бары тик Лерон Хамидуллин һәм үзбәк галиме Шерали Турдыевның мәкаләсеннән белеп ала [3: 173–175].

[1] Валентин Вольпин (1891–1956) – әдәбиятчы, библиограф.

2019 елда Үзбәкстанга Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгатьинституты тарафыннан оештырылган экспедиция вакытында бу сирәк китапның электрон нөсхасе алына. Бу китапның оригиналы Ташкентта, Галишәр Нәваи исемендәге Милли китапханәдә саклана [3: 173].

Тәрҗемәче һәм язучы Лирон Хамидуллин бу китапны Тукайның рус телендә беренче басылып чыккан җыентыгы дип яза [3: 173]. Әлбәттә,Тукайның моңарчы аерым әсәрләре рус телендә басылган иде, әмма мөстәкыйль бер китапка тупланган килеш юк иде.

Лирон Хамидуллин үзенең хезмәтендә болай яза: «Г. Тукайның русча беренче җыентыгын оештыручы, мөгаен, Ибнеәмин Янбаев булгандыр. Чөнки ул яңарак кына оешкан Төркестан Автономияле Совет Республикасының җаваплы хезмәткәре – Мәгариф халык комиссариатының коллегия әгъзасы һәм комиссар урынбасары булып эшли. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте белән яхшы таныш, комиссариатта эшләү белән бер үк вакытта, 1919 елдан башлап ул Ташкентта, Төркестан дәүләт университеты каршындагы рабфакта һәм курсларда татар теле һәм әдәбияты укытучысы булган кеше. Икенчедән, шагыйрьнең биографиясен русча язып чыгарлык русча белемнән дә мәхрүм түгел, ул Мәскәү сәүдә институтында укый һәм революция башланган елларда аны тәмамлап чыга. Һәм Ибнеәмин Янбаев нәкъ шушы елларда, Октябрь революциясе кузгаткан дулкын белән, Урта Азия якларына барып эләккәндер, анда совет хакимиятен урнаштыруда актив катнашуын искә алып, яшь республиканың җитәкче оешмаларына эшкә җибәрелгәндер, күрәсең, һәрхәлдә, ул калган гомерен Ташкент шәһәре, Үзбәкстан республикасы белән бәйләгән якташларыбызның берсе, шунда 1958 елда вафат була» [3: 175].

Л. Хамидуллин шулай ук Г. Тукай шигырьләрен тәрҗемә иткән шагыйрь Валентин Вольпин турында да мәгълүмат биреп китә: «1894 елда туган. “Дала рәшәсе” исемле беренче китабы 1917, “Ирек һәм камыт” җыентыгы исә 1920 елда Ташкентта басылганнар. Мәшһүр рус шагыйре Сергей Есенин белән дустанә мөнәсәбәттә торганы һәм 1921 елның май аенда Есенинның Ташкентта, Вольпинда кунакта булуы мәгълүм. Шагыйрь Вольпин шулай ук “Революцион шигырьләр антологиясе”н туплап, 1919 елда Ташкентта аның беренче томын чыгара, икенче томына сайланган әсәрләр җыентыгы хәзер Галишер Нәваи исемендәге гыйльми китапханә фондында саклана» [3: 175].

Тукай рус көнчыгыш әдәбияты белән генә түгел, ә рус, европа әдәбияты белән дә кызыксына. Төрки дөньяда абруйлы, халык яратучы шагыйрь буларак билгеле була ул. Ә менә рус укучысына, иҗаты бик үк таныш булып бетми әле ул вакытта. 1920 елда гына Ташкентта Тукайның беренче русча чыккан китабы дөнья күрә.

Ташкент Рәсәй империясенә кергән өлкә иде. Рәсәй империясе таралгач 1917 елда, аерым союздаш республикалар барлыкка килә. Ташкент Туркестан Советлар Союзлар республикасына керә.Ә инде 1924 елда Узбәк Советлар Социалистик Республика игълан ителә. 1920 ел Ленин барлык кешеләр тигез булган, «гадел дәүләт» оештыруны башлап җибәрә, ягъни, Советлар Союзын. Яңа дәүләтнең төп максаты коллективизм фикеренә буйсынган кеше, үз мәнфәгатләрен башка кешеләр өчен корбан итәргә әзер булган шәхес тәрбияләү. Барысы да җәмгыять бәхетенә эшләнергә тиеш булган шәхес үстерү, формалаштыру фикерен пропагандалау юлында радио, пе-

риодик басма, әдәбият һәм сәнгать булып торды. Тукайның 1909–1910 елда язылган җыентыкка кергән шигырьләре бу яңа дәүләт фикеренә бик тә килешле булып чыкты. Аның әсәрләре аркылы да СССР максатын кешеләргә җиткерү кулланылды. Рус телендә Ташкентта бастыру исә төрле халыкларның данлыклы кешеләре дә бу үзгәрешләрне күптән көтеп яши икәнлеген күрсәтү өчен эшләнелде күрәсең. Һәм тәрҗемәләре бераз ирекле рәвештә бирелде. Җыентыкка сайлап кертелгән алты шигыреул заман рухына (үзгәреш, инкыйлаб) туры килә. Ул заманга тәңгәл килгән, җыентыкка кергән шигырьләре:

– «Эшче җыры» исеме астында «Кярханәдә» («Бессилие») шигыре;
– «Алтынга каршы» (Проклятье золоту);
– «Эш» (О труде);
– «Шагыйрь» (Поэт);
– «Кыйтга» (Песня рабочего);
– «Сабыйга» («Ребенку»).

Шигырьләр эчтәлегенә нинди мәгънә салынган һәм оригиналга туры киләме?

Җыентыкта беренче шигырь итеп «Сабыйга» (Ребенку) куелган. Бу шигырьдәТукай балага мөрәҗәгать итеп, риваятьләргә ышанып кына түгел, ә гыйлем алып үз нәтиҗәләрен чыгарып яшәү кирәклеген җиткерә. Вольпин ясаган шигырь тәрҗемәсе Тукайның оригиналына якын.

«Эш» (О Труде) шигырендә дә балага мөрәҗәгать итү дәвам итә, тик өндәү инде эшчән, тырыш булуга куелган.Ягъни, яңа идеологиягә: Советлар Союзындагы бөтен кешеләр дә бер максатка тырышырга тиеш, һәр кеше тигез, якты киләчәк төзибез – дигән бик тә туры килә Тукайның бу шигыре. Тик Вольпин тарафыннан ясалган ирекле тәрҗемәдә совет рухы идеологиясенәтайпылу нык сизелеп тора. Мәсәлән, ирекле тәрҗемәдә якты киләчәк төзү турында юллар өстәлгән.

...Как проснешься, Дитя,
так берись за работу,
Только в ней совершенство и мудрость людей.
Только, вечно трудясь, не поддашься ты гнету
И узнаешь всю радость прекрасных идей.

*В этом мире разумно составлен план жизни,*
*От Аллаха закон – «В день седьмой отдыхай...»*
*Шесть же дней посвящай ты Труду для*
*– отчизны,*
*Воздвигай своим братьям их мечту – светлый рай.*
*Посмотри о, Дитя!*
*Солнце целый день в небе,*

Целый день оно греет, давая нам свет,
И, лишь к вечеру, зная извечный свой жребий,
Оно прячется в горы, за снежный хребет.
Если ты о, Дитя, с малых лет жизни юной
Солнцу божьему будешь в Труде подражать,–
Жизнь твоя будет чистой, как аккорд
полнострунный,
И, как божие солнце, ты будешь сверкать!.. [1: 16]

«Эш» шигыренең оригиналы тәрҗемәгә туры килеп бетми. Оригинал юллар буенча да кыскарак,мәгънәсе дә башкачарак.

Иртә торгач та язарга, дәрсең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн.
Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буенча яктыра.
Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.
Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман! [2: 41]

В творчестве писателей есть произведения, в которых в той или иной степени описываются моменты из их личных биографий. Автобиографическая повесть основывается на воспоминаниях самого автора и имеет хроникальный сюжет, тем самым оно очень ценно для читателей. Эталонами авторской повести в русской литературе являются трилогии Л.Н. Толстого «Детство», «Отрочество», «Юность», А.М. Горького «Детство», «В людях», «Мои университеты». В татарской литературе и в настоящее время этот жанр довольно популярен, например, произведение Ф. Яруллина «Паруса крепнут на ветру» («Җилкәннәр җилдә сынала»), Д. Нагим и Р. Набиева «Жизнь, собранная по крупицам» («Бөртекләп җыелган гомер») и др. У Г. Тукая есть всем известное автобиографическое произведение, написанное и изданное в типографии «Урнэк» в 1909 году «Что я помню о

себе» («Исемдә калганнар»). Во вступлении к ней он пишет: «Поводом к появлению моих записей «Что я помню о себе» послужила главным образом просьба издателей написать для них мою автобиографию. Я взялся за перо с намерением дать краткое описание моей жизни с рождения и до сегодняшнего дня, но – и сам не знаю, как это случилось, – впал в многословие. Моя жизнь (как увидят читатели) была весьма неприглядной, весьма мрачной, но вместе с тем и довольно-таки интересной; поэтому, раз начав, захотел я изложить все, что сохранилось в памяти» (перевод М. Рафикова). Свои воспоминания автор планировал написать в двух книгах: в первой – жизнь его до приезда в Уральск, вторая – до «минут, когда пишу эти строки». К сожалению, вторая часть не была написана, хотя в конце книги указывается «Окончание во второй части». На эту повесть в газете «Юлдуз» от 6 декабря 1909 года Кабир Бакир написал рецензию «“Что я помню о себе”. Произведение Габдуллы Тукаева» [4]. В данном произведении мы видим воспоминания его детских лет, его боль, утраты, переезды, скитания в чужих семьях, голод, нищенство. Есть и радостные моменты, которые он старается показать читателю. Его отношение к учебе, его талант к творчеству можно заметить в этих же воспоминаниях. Детство поэта наложило отпечаток на его будущее. К. Бакир пишет в своей рецензии: «если говорить о данной части автобиографической повести, то видно, что детство Г. Тукая было очень тяжким, но одновременно и интересным; до 7–8 лет сменил 3–4 родительских семьи, из-за разных воспитательных методов в семьях его воспитание так и запряталось в сиротской душе». Этому сыграло немаловажное значение и социальное положение семей в начале XX века: большие семьи, жизнь впроголодь, голодные годы, нищета. К. Бакир также пишет, что «когда ему требовалось настоящее воспитание, он попадает в неумелые, порой злые руки, поэтому наверное до этого времени у него нет стихотворений, в которых описывалась бы природа в красивых картинах». По мнению рецензента, «даже несправедливо ожидать романтичного поэта от человека, прожившего свое детство в муках, страданиях, в сопротивлении с природой», чувствуется «осторожность и равнодушие». Произведение написано легким языком, каждый читающий может окунуться в собственные детские воспоминания. Рецензент советует прочитать произведение учащимся школ, составителям хрестоматий. Г. Тукай сам был автором сборников и хрестоматий, например «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911), «Халык әдәбияты» (1910), «Халык моңнары» (1910). Об этих сборниках подробно рассказывается в статьях ученых-текстологов Э.М. Галимзяновой и Ф.Г. Файзуллиной [1; 2; 5].

В творчестве современника Г. Тукая Галимджана Ибрагимова (1887–1938) имеется рассказ «Изгнание Заки шакирда из медресе» («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»), написанный в 1907 году. Впервые был представлен читателям в том же году в рубрике «фельетон» в газете «Эль-ислах», только в 1912 году издан отдельной книгой в типографии «Умид». В 1980 годах этот рассказ считался в ряду ученических произведений, наряду с рассказами «Жертвы любви» (1908) и «Из жизни молодежи» (1911). В основу этого рассказа легли автобиографические события, произошедшие с автором. Как известно, в 1898–1905 годах Г. Ибрагимов обучается в медресе «Валия» («Медресе Вали муллы»). В данном произведении автор реалистично передает до мельчайших подробностей порядки, обычаи в ка-

димистких медресе, обращает внимание на чистоту, обучение, невежество среди шакирдов. Здесь Заки шакирд – праобраз Г. Ибрагимова. Медресе со своими порядками между мугаллимами-учителями и шакирдами-учениками сделали из порядочного скромного Заки более жесткую, твердую по характеру личность. В рассказе автор показывает как медресе старого порядка не позволяют развиваться татарскому национальному обществу, наоборот оттягивают развитие назад. В 1927 году в журнале «Наш путь» («Безнең юл») Хайретдин Вали издает рецензию ««Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (Г. Ибраһимовның беренче әсәре, 1907–1927)», где подробно анализирует данное произведение. Вот как описывает главного героя рецензент: «Заки не поддается чувствам, он умный человек. Не выделяет личные качества, он является человеком общества, он всегда думает об обществе. Он – выступает в защиту интересов народа. Но его окружение, условия жизни не позволяют жить как хотелось бы. Ему даже не дозволено мыслить, нет свободы в выборе изучаемой литературы. Вот такому окружению он начинает противостоять. Заки не заботится о чужом мнении, ярко выражено в нем красноречие, прямолинейность. Заки смелый, в любом месте он отстаивает свои мысли». Х. Вали о мастерстве писателя пишет так: «Произведение в художественном плане еще слабо, писатель здесь выступает не как мастер художественого слова, а как носитель мысли. ... Идеи переданы не с помощью образов, а напрямую. Писатель своими словами пересказывает событие от начала до конца. Слов главного героя не много, его мысли передаются самим автором». О языке рассказа рецензент дает подробную оценку, сравнивая с другими произведениями Г. Ибрагимова, то есть как изменялся стиль изложения за 20 лет. «Как и другие писатели, Г. Ибрагимов прошел эволюцию формирования художественного стиля. В начале творческого пути было много заимствований из арабского языка, потом стиль написания оттачивался, становился ближе к народному, следовательно становился прекраснее».

В описанных выше произведениях авторы показали определенный автобиографический отрезок своей жизни. Применяя психологические приемы, эти факты из их жизни не оставляют читателей равнодушными, а наоборот происходит сопереживание вместе с героями данных произведений. Еще одна особенность той эпохи: написание рецензий на произведения, что очень важно для литературоведов-исследователей, текстологов, историков.

ЛИТЕРАТУРА

1. Галимзянова Э.М., Файзуллина Ф.Г. Структурно-жанровые особенности «Уроков национальной литературы в школе» Г. Тукая // Современные исследования социальных проблем. – 2019. – Т. 11. – № 1–2. – С. 49–54.

2. Галимзянова Э.М., Файзуллина Ф.Г. Разные издания книги Г. Тукая «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» // Фәнни Татарстан. – 2016. – № 2. – С. 120–123.

3. Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр. Академик басма. 1 т.: хикәяләр, роман / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.Н. Зәйниева; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – 2018. – 462 б.

4. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. – 2016. – Б. 133–149, 364–369.

5. Фәйзуллина Ф.Г. Г. Тукай җыентыклары басылу тарихыннан / Габдулла Тукай и тюркский мир. Материалы международной конференции Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ; сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. 2016. – С. 405–407.

УДК 821.512.145

## Г. ТУКАЙ В ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКЕ Т. ГАЛИУЛЛИНА

***А.М. Закирзянов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье анализируются научные статьи Т. Галиуллина, в которых ученый-критик исследует творчество Тукая в контексте татарской поэзии XX века. В статьях, опубликованных на татарском, русском, турецком языках, в том числе в «Энциклопедии Тукая», личность и творчество Тукая, его литературно-эстетическое влияние на татарскую поэзию, преемственность традиций, творчество представителей «Тукаевской школы» оцениваются в свете новых научных парадигм.
**Ключевые слова:** Тукай, поэзия, статья, интерпретация, личность, творчество.

The article analyzes the scientific articles of T. Galiullin, in which the scientist-critic examines the works of Tukai in close connection with the Tatar poetry of the XX century. In articles published in Tatar, Russian, and Turkish, in the «Tukai Encyclopedia», Tukai's personality and work, his literary and aesthetic influence on Tatar poetry, the continuity of traditions, and the work of representatives of the «Tukai school» are evaluated in the light of new scientific paradigms.
**Key words**: Tukai, poetry, article, interpretation, personality, creativity.

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫ Т. ГАЛИУЛЛИН БӘЯЛӘВЕНДӘ

***Ә.М. Закирҗанов***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Габдулла Тукай – XX йөз башы сүз сәнгатенең халыкчанлык юнәлешендә үсешенә гаять зур өлеш керткән, аны милли эчтәлек, яңа тема-мотивлар, жанрлар, сәнгати алымнар белән баеткан әдипләрнең берсе. Үз чорында ук «халыкның моңлы көен» җырлаучы булып танылган шагыйрь татар поэзиясенең алдагы чорлардагы сәнгати эзләнүләренә ныклы таяныч булып, аны даими сугарып тора, традицияләрнигез сала. Бөек шагыйрьнең шәхесен һәм иҗатын өйрәнү үзе исән вакытта ук башланып, вафатыннан соң эзлекле, системалы төс ала һәм XX гасырның 60 нчы елларына «Тукай фәне» буларак формалашып җитә.

Г. Тукайның XX йөз башы шигъриятенә алып килгән яңалыгы, урыны турында беренчеләрдән булып Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан мәкаләләре язылып, аның табигый сәләте, сәнгати фикерләү үзенчәлеге билгеләнә. Тукай вафатыннан соңгы елларда Г. Исхакый, Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы, Б. Шәрәф, Г. Кәрам һ.б. шагыйрь иҗатының халыкчан рухын, ил-халык тормышы белән тыгыз бәйлеген ачуга киләләр. 1920–1930 елларда Г. Ибраһимов, Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Ф. Бурнаш, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Ф. Сәйфи-Казанлы һ.б. хезмәтләрендә шагыйрь иҗаты шактый каршылыклы бәяләнсә дә, нигездә, аның әдәбият тарихындагы алыштыргысыз урыны кире кагылмый. Тукай иҗаты совет чорында, иҗтимагый-сәяси шартларга бәйле, төрле яссылыкта өйрәнелә. 1960–1980 елларда Г. Халит, Х. Хәйри, Х. Госман, И. Нуруллин, Я. Агишев, Г. Нәфыйгов, Р. Башкуров, Х. Хисмәтуллин һәм соңрак бу төркемгә кушылып киткән Р. Гайнанов, М. Мәһдиев, Н. Юзиев, Р. Ганиева, Т. Галиуллин, Н. Лаисов һ.б. тырышлыгы белән бөек шагыйрь иҗатын тикшерү яңа баскычка күтәрелә. Ә инде ике гасыр чигендә «тукайчылар» төркеме

Ф. Мусин, Н. Хисамов, Ф. Яхин, Х. Миңнегулов, Ф. Галимуллин, З. Рәмиев, Д. Заһидуллина, Р. Исламов, Ә. Алиева, Ф. Ибраһимова, Т. Гыйләҗев, Н. Йосыпова һ.б. белән тулылана. Тукай иҗатына теге яисә бу дәрәҗәдә мөрәҗәгать итмәгән әдәбият белгече сирәктер, шуңа да аларның барысына да тукталу, табыш-яңалыкларын билгеләү махсус тикшеренүне сорый. Без исә әлеге мәкаләдә «Тукай фәне» үсешенә җитди өлеш керткән галимнәрнең берсе – Тәлгат Галиуллинның бу өлкәдәге эшчәнлегенә тукталабыз.

Танылган әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы, публицист Т. Галиуллин әдәбият фәненә 1960 еллар ахырында килеп, татар шигъриятен халык иҗаты белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүгә алына. Шул елларда ук ул XX гасыр татар поэзиясенең Тукайдан аерылгысызлыгын аңлауга килә һәм танылган классиклар иҗатын өйрәнгәндә «төп бәяләү берәмлеге итеп үз халкының язмышына якынлыкны ала» [2: 4]. Шуңа да әдәбиятның кайсы чорларын гына тикшерсә дә, аның өчен Тукай иҗаты бизмән ролен үти, шуннан чыгып һәр әдипнең урынын билгели. Ә инде җәмгыятьтәге үзгәрешләргә нисбәтле, күпгасырлык сүз сәнгатен яңа методологик таләпләрдән чыгып өйрәнү бурычы алга килеп баскач, бай тәҗрибә туплаган галим-тәнкыйтьче Тукай иҗатын XX гасыр татар поэзиясе белән күчемле бәйләнештә тикшерүгә алына һәм, бер яктан, Тукай мирасының яңа хасиятләрен ачуга килсә, икенче яктан, шигъриятнең үсеш тенденцияләрен, аерым шәхесләрнең ролен аңлау-аңлатуда җитди казанышларга ирешә. Т. Галиуллинның татар, рус, төрек телләрендә дөнья күргән күпсанлы мәкаләләрендә, «Тукай энциклопедиясе»ндәге язмаларында Тукай шәхесе һәм иҗаты, аның татар шигъриятенә шифалы йогынтысы, традицияләренең дәвамчанлыгы рәвешендә «Тукай мәктәбе» вәкилләре иҗаты яңа фәнни парадигмалар яктылыгында дөнья әдәбиятының бер өлеше буларак бәяләнә.

Т. Галиуллин бөек шагыйрь иҗатын тикшерүдә фәнни-теоретик һәм методологик нигез итеп XX гасыр татар шигъриятенең эзлекле үсеп-үзгәреп торучы бербөтен күренеш булуын ала. Бу мәсьәләдә ул Тукайга бәйле тупланган бай мираска нигезләнгән хәлдә, яңача бәяләү, эчке хасиятләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен эзли. Үзәккә шагыйрь иҗатын бөтен татар поэзиясе, аеруча үз чоры шигърияте фонында «шул чорның әдәби аң үзенчәлекләренә таянып» [8: 7] тикшерүне, яңача шәрехләүне куя. Галим-тәнкыйтьченең татар, рус һәм чит илләр әдәбиятын яхшы белүе, «фикер киңлеге һәм нигезле фәнни фактларга таяну»ы [9: 9] уңышлы гомумиләштерүләр, җитди нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә.

Тукай шәхесе һәм иҗаты тормыш биографиясеннән, ул яшәгән чор үзенчәлекләреннән аерылгысыз. Шуңа да шагыйрь шәхесенә йогынты ясаган шартлар, иҗатының нигезе, тамырлары турында уйланганда, Тукайның татар әдәбиятының бай һәм зур традицияләре белән бәйлелеге, үзебезнең җирлектә үсеп, формалашып җитүе үзәктә тора. Т. Галиуллин «Тукай: шәхес һәм шигърият бердәмлеге» язмасында, әлеге мәсьәләгә тукталып, беренче әсәрләрен үк халык авыз иҗаты дигән мул диңгез сугаруын билгели. Икенче бер таянычны Шәрык әдәбиятында, атаклы Хафиз, Хәйям, Сәгъди, Фирдәүсиләрнең бай мирасында таба. Шәкертлек елларында рус телен өйрәнүе, булачак шагыйрьне рус әдәбиятының бай мирасы белән кызыксынуга китерә.

Татар әдәбият фәнендә кабул ителгәнчә, Т. Галиуллин шагыйрь иҗатын ике этапка бүлеп өйрәнүне, тикшерүне яклый. Әмма галим кат-кат искәртеп үткәнчә, «Тукайның халыкчан, реалистик поэзиясе бербөтен» [4: 5]. Әлеге

бүленеш шагыйрьнең дөньяга карашындагы, сәнгати үсешендәге эволюциясен ачык билгеләү өчен кирәк. Тукайның Җаек чорына караган әсәрләрен дидактика, үгет-нәсыйхәт кысасында гына калдырмыйча, бу чорда таланты ачылуын, махсус мәкалә исеменә чыгарганча «дөнья әдәбиятлары югарылыгына беренче адым» буларак бәяли. Яшь шагыйрь өйрәнчек чорын бик тиз үтеп, олы иҗатка килә. Аның чор рухын, иҗтимагый хаятне чагылдарган беренче әсәрләре үк җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршы алына. Аларда табигый сәләте, тынгысыз җаны чагыла. Мәдрәсәдә укыган китаплары, Шәрык, бераз соңрак төрек әдәбиятлары йогынтысында һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле, шагыйрь мәгърифәтчелек идеяләрен кайнар яклый. Рус әдәбиятыннан файдаланып язган шигырьләре дә шуңа хезмәт итә. Т. Галиуллин билгеләп үткәнчә, «1906 елда ук инде Тукай фәлсәфи-әхлакый концепциясе калыплашкан шәхес, сәнгатьлелек җәһәтеннән җитлеккән шагыйрь» [1: 25]. Әлеге фикер шагыйрьнең шигъри осталыгы үсеше тизләтелгән адымнар белән баруда да күренә. Үзлегеннән күп укудан тыш, журналистикадагы эшчәнлеге дә моңа уңай йогынты ясый. Җаекта яшәгәндә «Фикер», «Әлгасрелҗәдит»тә эшли һәм үткен шигырьләре, мәкаләләре белән танылa. Тукайның ачыклыгы, ихласлыгы, аерым мәсьәләләрдә Г. Ибраһимов, И. Гаспралы, Һ. Максуди кебек зыялыларны тәнкыйтьли алуы да шәхес буларак өлгергәнлеге билгесе булып тора. Шул чорда язылган тәнкыйди рухлы, яшәештәге кимчелекләрне фаш иткән шигырьләрен анализлау аша, Т. Галиуллин яшь авторның усал телле сатирик буларак та формалашуын искәртә. Аерым традицияләр тәэсирендә шактый чуар тел белән яза башлаган Тукай башка халыклар әдәбиятында булган үзенчәлекләрне үзенең табышлары белән куша бара. Нәтиҗәдә «гасырлар дәвамында Көнчыгышка гына йөз тоткан татар поэзиясен Көнбатышка, рус һәм аның аша Аурупа поэзиясенә борып җибәрә» [4: 7]. Бу елларда Тукай иҗатында бөтен иҗаты буенча сузылып барачак ике өслүб формалаша. Т. Галиуллин беренчесенең үзенчәлеген «халыкчан сөйләм теле нигезендә калыплашкан, мифологик сюжет-мотивларга, лирик җырларга таянып, балалар өчен язылган әсәрләренә хас үтә күренмәле реалистик өслүб» [5: 25] дип бәяли. Икенчесенә хас төп сыйфат буларак «фәлсәфи рухлы, иҗтимагый эчтәлекле, дини мәсьәләләргә кагылышлы шигырьләрендә (...) «югары», элитар өслүбкә өстенлек» [5: 25] бирүне атый. Гомумән, галим-тәнкыйтьче Тукайның Җаек чорын иҗатында гаять мөһим этап дип саный, алга таба урын алачак сәнгати алымнарга әлеге чорда нигез салынуын билгеләп үтә.

Тукай Казанга җитлеккән шагыйрь буларак килә һәм тиз арада үзенә лаеклы урынны яулап ала. Бу, беренче чиратта, шагыйрь әсәрләренең халыкчан рухы, вакыйгаларга аваздаш булуы, яңа җитди башлангычларга нигез салуы белән тыгыз бәйле. Тукай фольклордан һәм мифологиядән килүче образ-сурәтләргә заман рухыннан чыгып мөрәҗәгать итә, аларны әсәрләрендә эретеп, мөһим элемент буларак калкытып куя. Шуңа да «бу бәрәкәтле чыганак бөтен иҗатына таяныч, якты нур, халыкчан рух биреп торачак» [5: 26] сыйфатка әверелә. Шул уңай белән байтак әсәрләргә ясалган анализ Т. Галиуллинны шигъриятне гаять тирән тоемлаучы тәнкыйтьче итеп ача. Тукайның Казан чоры иҗаты милли реализмга аяк басуын күрсәтә. Аның бөтен әсәрләрен дип әйтерлек милли мәсьәләләр иңләп үтә. Галим искәрткәнчә, «милләт яшәеше өчен көрәш идеясе аның һәр әсәрендә диярлек ярылып ята» [1: 29]. Шунысы игътибарга лаек, шагыйрь үз халкын иркәләп кенә

тормый, бәлки шигырь һәм мәкаләләрендә шактый кырыс, кискен рәвештә аны тәнкыйтьләүгә килә. Тукай халыкның үзаңы үсешенә йогынты ясаган рухиналар тормышын даими күзәтеп бара һәм мәгънәсез эш-гамәлләре белән ислам диненең дәрәҗәсен төшерүче муллаларны усал фаш итә. Мондый шигырьләрендә ул гаделлек яклаучы булып алга килеп баса. Т. Галиуллин әлеге шигырьләрнең бүген дә заманча яңгыравын, Тукай карашларының искермәвен билгеләп үтә. Шул уңай белән галим хәзерге шигърият, анда юмор-сатираның торышы турында уйланып, борчулы нәтиҗә ясый: «Ни кызганыч, хәзерге шигъриятгә Тукай яисә Г.Афзал дәрәҗәсендә торган сатира остасы юк шул» [5: 30].

Тукайның байтак шигырьләренә килеп кергән сызлану, сыкрану авазы халык язмышы белән тыгыз бәйле тема-мотивлар булып үстерелә. Т. Галиуллин Тукай шәхесенә дә бәя биреп, аның горур булуын, авырлыкларга бирешмичә яшәвен, беркем алдында да тез чүкмәвен ассызыклап үтә. Шуңа шагыйрьнең барлык әсәрләрендә мәһабәт шагыйрь образы калкып чыга. Ул да шагыйрь биографиясеннән, аның кайгы-хәсрәтеннән дә, куанычын да аерылгысыз. Шуңа Тукай шигырьләренең асылын билгеләгән «моң» төшенчәсе сызланулы күңел халәтен чагылдыра. Т. Галиуллин язганча, «йөрәкләрне парә-парә китергән моң үз халкының язмышына барып тоташкан “җырда” гына туа ала икән» [5: 28]. «Тукай: шәхес һәм шигърият бердәмлеге» мәкаләсендә галим бөек шагыйрьне тормыш фәлсәфәсен бөтен каршылыкларында ачу омтылышы ясаган шәхес буларак бәяли. Иҗатында «дөнья поэзиясенең иң мәшһүр үрнәкләре югарылыгына» [5: 29] күтәрелүен, вакыт чикләрен үтеп, мәңгелеккә, чиксезлеккә алып чыгуын билгели.

Тукай иҗатына хас тагын бер үзенчәлек буларак, Т. Галиуллин әдипнең тар милли кысаларда гына калмавын, бәлки башка халыклар, беренче чиратта, төркиләр өчен дә әһәмиятле булган мәсьәләләргә килеп чыгуын, уй-фикерләре белән уртаклашуын, еш кына аларны хәл итү юлларын да күрсәтүен искәртә. Туган халкы язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчулы уйланулары Тукайны гомумкешелек проблемаларына алып килә, дип билгеләп үтә.

Т. Галиуллин язмаларының тагын бер үзенчәлеге шунда, аларда үзәк урында Тукайның шигырләре тора. Галим «үз мәктәбен тудырган сүз остасының» [6: 31] күп тармаклы, киң кырлы лирикасын белеп, аңлап, яратып бәяли, жанр үзенчәлекләрен аерып чыгара, тема-мотивлардагы яңалыкларын җентекләп шәрехли һәм нәтиҗәләр ясый. Ә инде әсәрләрдә шагыйрьнең үз образы чагылышын өйрәнү аша Тукайның пәйгамбәрләрчә алдан күрүчәнлеген ачуга килә.

«Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте» язмасы Тукайның алдагы чор поэзиясенә йогынтысын ачу һәм әдәбиятта шагыйрьнең әдәби образы чагылышын тикшерү ягыннан әһәмиятле. Галим Тукай үлеменнән соңгы әдәби вәзгыятькә күзәтү ясый һәм күпләрнең халык шагыйре иҗатында рухи таяныч эзләвен ача. Совет чорында Тукайга мөнәсәбәт үзгәрүнең шигърияттә дә чагылыш табуын билгеләүгә килә. 1930 елларда Тукайдан читләшү күзәтелеп, татар поэзиясе «сурәтлелек хасиятен югалта, ясалма купшылык, риторика юлына төшә», ә инде шул гасырның Тукайга якынайган 60 нчы һәм 80–90 нчы елларында татар шигърияте җитди ачышларга килә» [3: 24]. Авторның поэзия үсешендә гаять җитди урын алып торган 1960–1970 елларын, шул чорның әйдәп баручы авторлары иҗатын Тукайга нисбәтле

тикшерүе дә гыйбрәтле. Дәлилле рәвештә әлеге елларда Тукай һәм замандашлары алып килгән тема-мотивларның, милли идеянең заман рухына бәйле кабатланып килүе, шуның белән зур яңгыраш алуы ассызыклана. Традицияләр дәвамчанлыгы мәсьәләсе үстерелә барып, яңартып кору, хөрриятк ә омтылу чорында да Тукайның милли рухы, халык язмышын кайгырткан фикерләре татар поэзиясе өчен олы таяныч булуы турында нәтиҗә ясый Т. Галиуллин.

Тукай иҗатын төрле яссылыкта тикшерү аша, галим татар поэзиясенең һәрвакыт Тукай шигъриятенә сыенып яшәвен ачыклауга килә. Тукай шәхесе төрле буын шагыйрьләрне җәлеп итә, аны аңлау, бөеклегенә төшенү – яшәеш фәлсәфәсен халык аңына сеңдерүгә китерә. Т. Галиуллин эзлекле рәвештә Тукай шәхесен, әдәби образын чагылдырган дистәләрчә шагыйрьгә тукталып, һәрберсенең «үз Тукае» булуын ача. Әлеге әдипләрнең Тукайга килүе нигезендә бөек шагыйрь иҗатының «буеннан-буена сузылган миллилек идеясе, халкын азат һәм бәхетле итеп күрү теләгенең уртак булуы ята» [7: 7] дип билгели.

Бөек шагыйрь мирасы рухи терәк булган кебек, ул мөрәҗәгать иткән тема-проблемалар XX гасырның икенче яртысында да, яңа гасыр башында да актуаль булып кала. Шуңа нисбәтле Т. Галиуллин шагыйрь чоры белән үзе яшәгән чор шигъриятендә чагылыш тапкан мәсьәләләрнең – милләт тарихы, яңарышны тоткарлаган күренешләрне сатирик тәнкыйтьләү, туган телне саклау ихтыяҗы, гражданлык позициясе, коллык психологиясеннән арыну, киләчәккә өмет хисе уяту – төрле чор шагыйрьләре иҗатында чагылышын бәяли, табыш-үзенчәлекләрне ачу омтылышы ясый. Галимнең күзәтүләре, Тукай традицияләренең дәвамчанлыгын билгеләү белән бергә, төрле буын шагыйрьләрнең халык шагыйренә мөнәсәбәтен, бәясен тоемларга, шулай ук «Тукай мәктәбе» төшенчәсенең асылын, шигърияттә чагылышын ачыкларга мөмкинлек бирә. Автор Тукай иҗатының тәэсире чагылышын төрле планда ача. Алар арасында Тукай әсәрләреннән өзекләрне файдалану, тема-мотивларга ияреп язу, Тукайның фикерләү рәвешендә, дөньяны күрүендә чагылган өслүбен файдалану, образ-сурәтләрне, символ-детальләрне куллану һб. бар. Тукай традицияләренең һәр чорда үзенчә яңгырашына нисбәтле, чагыштырып тикшерелә торган чор шигъриятенең эчке хасиятләрен, сәнгати эзләнүләр байлыгын, шагыйрьләрнең шәхси үзенчәлекләрен ачуда Т. Галиуллин хезмәтләренең кыйммәте чагыла.

Шулай итеп, «Тукай фәне»нә җитди өлеш керткән Т. Галиуллин хезмәтләрендә халык шагыйре шәхес һәм иҗатчы бергәлегендә, чорның әдәби барышына нисбәтле тикшерелеп, үз заманы өчен әһәмияте һәм алдагы чорларга йогынтысы ачыла. Шуларга бәйле галим «Тукай мәктәбе» төшенчәсен ачыклауга килә. Тукай тормышын, иҗатын эзлекле тикшерү аша Т. Галиуллин хезмәтләре фәнни монография төсен ала һәм алдагы тикшеренүләргә нигез булып тора. Шуның белән бергә, галим-тәнкыйтьче Тукай иҗатын киләчәктә әдәби юнәлешләргә, жанрларга нисбәтле, татар әдәбиятының гомуми яссылыгына куеп өйрәнү кебек бурычларның алда торуын билгеләп үтә.

ӘДӘБИЯТ

1. Галиуллин Т.Н. «Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь» (Тукайның тууына 120 ел тулу уңаеннан // Әдәбият – хәтер хәзинәсе. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 24–34.

2. Галиуллин Т.Н. Милли үзаң һәм шигърият // Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 3–9.

3. Галиуллин Т.Н. Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте // Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 20–28.

4. Галиуллин Т.Н. Тукайның Җаек чоры иҗаты – дөнья әдәбиятлары югарылыгына беренче адым // Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 5–9.

5. Галиуллин Т.Н. Тукай: шәхес һәм шигърият бердәмлеге // Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 24–32.

6. Галиуллин Т.Н. Тукай шигырьләрен яңадан укыганда // Тукаевские чтения. Материалы выступлений. Выпуск 2. – Казан, 2000. – Б. 31–49.

7. Галиуллин Т.Н. Тукайлы шигърият (Тукай һәм хәзерге татар поэзиясе) // Әдәбият – хәтер хәзинәсе. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 4–23.

8. Заһидуллина Д.Ф. Яңа юллар салучы // Галиуллин Т.Н. Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 5–10.

9. Сайфулина Ф.С. Гордость нации – его поэзия // Галиуллин Т.Н. Мы – потомки страны «Тартария» (Татарская поэзия XX века как единый философско-эстетический процесс). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – С. 7–14.

УДК 398.21

## СКАЗКИ Г. ТУКАЯ И ТАТАРСКАЯ СКАЗОЧНАЯ ТРАДИЦИЯ

***И.Г. Закирова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются татарские народные сказки, сказочные мотивы и образы, используемые Г. Тукаем в его творчестве. Интерес к жанру народных сказок сопровождал Г. Тукая на всех этапах его творчества. Фольклорные элементы естественно входили в поэзию поэта. Г. Тукай доводит сюжеты народных сказок до читателя в поэтической обработке или делится с читателем своими наблюдениями и взглядами посредством сказочных мотивов и образов, используя их для характеристики общественных и социальных явлений своего времени.
**Ключевые слова**: Г. Тукай, народная сказка, сказочные сюжеты, Шурале, татарский фольклор

The article deals with Tatar folk tales, fairy-tale motifs and images used by G. Tukai in his work. Interest in the genre of folk tales accompanied G. Tukay at all stages of his work. Folklore elements naturally entered the poet’s poetry. G. Tukay brings the stories of folk tales to the reader in poetic processing or shares with the reader his observations and views through fairy-tale motives and images, using them to characterize the social and social phenomena of his time.
**Key words:** G. Tukay, folk tale, fairy tales, Shurale, Tatar folklore

## Г. ТУКАЙ ӘКИЯТЛӘРЕҺӘМ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ӘКИЯТ ТРАДИЦИЯСЕ

***И.Г. Закирова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Г. Тукайның әдәби эшчәнлеге халык иҗаты белән тыгыз бәйләнгән, ул үз әсәрләрендә халык әдәбиятыннан килгән сюжетларны яңарта, фольклордан килгән мотив-образларга еш мөрәҗәгать итә, фольклор әсәрләре үлчәвен файдалана,. Халык әдәбиятына караган аерым күзәтүләрен шагыйрьнең публицистикасында һәм фәнни хезмәтләрендә табарга мөмкин. Г. Тукайның гомере буе халык иҗаты әсәрләрен җыюы һәм бастырып чыгаруы да яхшы мәгълүм. Ул фольклор үрнәкләренең халык телендә булуына игътибар юнәлтә, бөтен кешегә аңлаешлы булган жанрларына аерым мәхәббәт белән

карый. Бу мәхәббәтне «Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм» дигән сүзләре дәлилләп тора [4: 4 т., 179]. Тел ягыннан шактый катлаулы, гарәп-фарсы алынмаларына бай булган кыйсса-дастаннарга шагыйрьнең мөнәсәбәте үзенчәлекле, ул аерым әсәрләрнең исемен яки андагы образ-персонажларны искә алу белән чикләнә. Мәсәлән, «Дусларга бер сүз» шигырендә «Юсеф-Якуп китабын» искә ала, шигырьне дә «Кыйссаи Йосыф» поэмасы үлчәвендә иҗат итә [4: 1 т., 55]. «Безне урынсыз яманлыйлар» шигырендә «Таһир-Зөһрә, «Бүз егет» дастаннары телгә алына [4: 1 т., 198]. «Бер рәсемгә» шигырендә «Ләйлә-Мәҗнүн» дастаны герое Ләйлә хатын-кыз матурлыгы эталоны буларак күрсәтелә [4: 1 т., 256].

1910 елда Г. Тукай Шәрык клубында «Халык әдәбияты» дигән темага лекция укый. Бу хезмәттә шагыйрьнең дастан жанрына мөнәсәбәте шактый каршылыклы булуын күрәбез. Ул, бер яктан, аларның халык теленнән ераклашкан телен тәнкыйть итә, икенче яктан, «Таһир-Зөһрә» кыйссасын истә тотып, «Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, еламыйча үскән ирләребез вә хатыннарыбыз сирәктер», дип яза [4: 4 т., 178].

Шагыйрь үзенең иҗатында татар фольклорының аеруча өч жанрына зур игътибар биргән. Болар – халык җырлары, әкиятләр һәм мифологик хикәятләр. Г. Тукайның җырларга яратуы билгеле, бу хакта мәгълүматны аның язмаларында очратабыз. «Мин кечкенәдән җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәләрдә хәлфәләр кече атна кичләрдә бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем», дип яза ул җырларга сәләте турында бәян итеп [4: 4 т., 180].

Г. Тукай татар халык җырларыннан торган берничә җыентык та әзерли. «Халык әдәбияты» дигән лекциясендә дә төп игътибар халык иҗатының җыр жанрына юнәлтелгән. Халык җырлары үлчәвен шагыйрь үзенең иҗатында да актив файдаланган.

Г. Тукай үз иҗатында мифологик персонажларга битараф түгел, аерым мифларга нигезләнеп иҗат ителгән әсәрләре дә бар. Мәсәлән, «Ай һәм Кояш» [4: 2 т., 75], «Җир йокысы» [4: 2 т., 76], «Кышка бер сүз» [4: 2 т., 77] һ.б. шигырьләрендә татар халыкының борынгы космогоник карашлары чагыла. Сүз уңаеннан, Г. Тукай хәзерге вакытта татар фольклор фәненә *мифологик хикәят* термины белән кергән әсәрләрне *хыялый хикәя* дип атый [4: 1 т., 352]. Г. Тукай әкиятләре дигәндә, беренче чиратта аның «Шүрәле» һәм «Су анасы» поэмалары истә тотыла. Хәзерге вакытта бу әсәрләрне әкият-поэма дип атап, татар әдәбиятында беренче әдәби әкияткә үрнәк булып торалар [2: 90 ] Шагыйрьнең иң популяр әсәрләреннән булган бу ике әкият татар халкының мифологик хикәятләренә нигезләнеп иҗат ителгән. Л.Ш. Җамалетдинов бу әсәрләрнең чыганаклары турында «Халыкта киң таралган шүрәле һәм су анасы турындагы кечкенә хикәяләр – чын мәгънәсендәге әкиятләр түгел. Аларда, тасвирлаудан бигрәк, хәбәр итү, белдерү өстенлек ала, һәм кешеләрнең борынгы ышануларын чагылдырган ул нәни хикәя-легендалар әкият белән тиңләрлек эстетик вазыйфа да үтәмиләр» дип

яза [2: 91]. Х. Ярми дә бу әсәрләрнең нигезендә мифик әкиятләр ята, дип яза [7: 52]. Су анасы образы шагыйрь иҗатында шушы поэмада гына җанландырылса, Шүрәлегә шагыйрь берничә тапкыр мөрәҗәгать итә. «Көтмәгәндә» шигырендә Г. Тукайның әлеге образга мөнәсәбәтен күрсәткән:

Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе;
Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул – табигать иркәсе [4: 2 т., 245],

дигән юллар бар.

Г. Тукайның иң еш кулланган псевдонимы да «Шүрәле» була. З. Рәмиев язуынча, ул аны 80 тапкырга якын куллана [3: 43]. Су анасы псевдонимы исә өч тапкыр очрый [4: 6 т., 449].

Татар халкында Су анасы турындагы сюжетлар хәзер дә популяр булып, татарлар яшәгән төрле регионнарда бу сюжетның вариантлары еш очрый. Шүрәле турындагы мифологик хикәятләр онытыла төшкән. Шүрәле образы Урман хуҗасы, Урман иясе, Еш ия буларак хәзерге вакытта нигездә Себер татарларында саклана. Казан татарларында Шүрәле каргаган авыл, Шүрәлегә су башы күрсәтү турындагы легендалар да саклана. Әмма татар фольклорында Шүрәле турында Г. Тукай әкиятенең сюжетын хәтерләткән легендалар һәм мифологик эчтәлекле әсәрләр дә күптәннән мәгълүм. Мәсәлән, «Шүрәле турындагы шушы ук сюжетлы әсәр Габор Балинтның 1875 елда дөнья күргән татар фольклорына багышланган җыентыгына кергән [1: 170]. Шагыйрьнең «Шүрәле» поэмасын иҗат иткәндә нәкъ шушы сюжетка таянуы бәхәссез.

Г. Тукай «Халык әдәбияты» дигән хезмәтендә дә Шүрәле каргаган авыл дигән гыйбарәнең килеп чыгышын аңлаткан Шүрәле турындагы популяр хикәятне бәян итә [4: 4 т., 166].

Г. Тукайның «Шүрәле» һәм «Су анасы» поэмаларыннан башка «Кәҗә белән Сарык» дигән хайваннар турындагы әкияткә нигезләнеп иҗат ителгән «Кәҗә белән Сарык хикәясе», А.С. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» әкиятеннән ирекле тәрҗемә итеп язылган «Алтын әтәч» әкияте бар. Шагыйрьнең «Япун хикәясе»ндә татар халкында «Кем көчле» дигән исем астында мәгълүм әкиятләрнең йогынтысы сизелә.

Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы, бер яктан урта гасырлар әдәби ядкәре «Кисекбаш китабы»на назыйрә булса, икенче яктан ул татар халкының тылсымлы әкиятләре сюжетына да якын. Аның фабуласы «Таңбатыр» әкиятенә туры килә. «Казан вә Кабан арты» шигыре дә Убырлы карчык турындагы әкиятләр нигезендә язылган. Ике әсәрдә дә татар мифологиясенең тылсымлы әкиятләрендә сакланган җир асты дөньясы, мифологик персонажлар искә алына.

Г. Тукай турындагы истәлекләрдә аның үзенең дә әкият сөйләргә яратуы турында хәбәрләр бар. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында (колл. 1, папка 4, сакл. бер. 101–103) Җаек мәдрәсәсендә Тукай белән бергә укыган Шәриф Каюмов 1941 елда язып җибәргән өч әкият тексты саклана. Әлеге әкиятләрне А. Гайнетдинов текстларны бераз әдәбиләштерергә омтылган зур булмаган үзгәрешләр белән 2011–2013 елларда «Мәдәни җомга» газетасында бастырып та чыгарды.

Ш. Каюмов үзенең истәлекләрендә Г. Тукай белән Җаек шәһәрендә бергә мәдрәсәдә укуын, бу әкиятләрне Г. Тукайдан ишеткән булуын, «Тукай сөйләгән әкиятләрнең өчесен дә хәзергә кадәр яхшы хәтерләвен» белдерә,

ишеткәннәрен хәтердә яңартып, шактый вакыттан соң кәгазьгә төшерүе турында яза [5: 46–53; 6: 60–66]. Бу әкиятләрне Г. Тукай ун-унбер яшьлек шәкертләргә сөйли торган булган.

«Хәсән», «Утыз ул, утыз кыз» һәм «Гали» дип исемләнгән әлеге әкиятләр белән танышып чыкканнан соң, текстларның шактый бозылган булуы күзгә ташлана. Ш. Каюмов бу әкиятләрне «бизәп, матурлап» язарга омтылып, шактый үзгәртүләр керткән. Текстларда берничә әкияттән аерым мотивлар үзара кушылып киткән, сюжет формалаштыруда роль уйнаган өлешләр төшеп калган. Мәсәлән, «Хәсән» әкиятенең башлам өлеше татар халкының «Мәрмәр тавы башында» әкиятенең башламының варианты булып тора, әмма ул да эзлеклелеген югалткан, байның нинди максат белән Хәсәнне тау башына юллавы аңлашылмый кала. Мондый урыннар әкияттә шактый күзгә ташлана.

Ш. Каюмов Совет чоры өчен актуаль булган тема – колбиләүчеләрне, байларны гаепләү белән мавыгып та җеп очын югалтып җибәрә. Героеның авыр хәлен, байга эшләвен, бай тарафыннан кыйналуын кайта-кайта сөйли. Бу чигенешләр, тиешсез өстәмәләр әкиятне кабул итүне кыенлаштыра.

«Гали» исемле икенче әкият тә берничә әкияттән кушылып ясалган. Аның «Хәсән» әкияте белән охшаш урыннары шактый.

«Утыз ул, утыз кыз» әкияте – төрки халыкларның «Җиртөшлек» дастанының әкиятләшкән бер варианты. Бу әкиятнең татар халкында да төрле исемнәр белән мәгълүм вариантлары күп. Бу әкият, шактый гына үзгәртүләргә дучар булуына карамастан, сюжет кысаларыннан артык чыкмый, эзлеклелеген югалтмый калган бердәнбер әсәр.

Текстлардагы өстәмәләрне халык әдәбиятын, аның үзенчәлекләрен яхшы белгән Г. Тукай кертә алмый дигән караш торабыз. Габдулла Тукай бу әкиятләрне, үзе белгән халык әкиятләренә нигезләнеп, экспромт юлы белән уйлап чыгарып сөйләгән дип фаразларга мөмкин. Әмма логик эзлеклелек булмаган текстларны Ш. Каюмов хәтерли алмас иде. Шуңа күрә әлеге әкиятләрнең Г. Тукайның «репертуарында» булуын инкарь итмәгән хәлдә, Ш. Каюмов Г. Тукай сөйләгән әкиятләргә бик нык үз үзгәрешләрен керткән дип фикер йөртергә кала. Шулай да бу әкиятләр безнең өчен Г. Тукайның әкият жанрына әһәмият бирүе ягыннан әһәмиятле, Ш. Каюмовның архивка тапшырган текстлары Г. Тукайның шәкертләргә әкиятләр сөйләгән булу фактын раслыйлар.

Бу мәкаләдә Г. Тукай иҗатында татар фольклорының, аерым алганда халык әкиятләренең чагылышына күзәтү ясалды. Шагыйрь кечкенәдән халык әкиятләренә битараф булмый, беренчедән, замандашлары истәлекләренә караганда, ул үзе дә әкиятче була. Соңрак халык әкиятләренә таянып үзенең әкиятләрен, шул исәптән «Шүрәле» һәм «Су анасы» поэмаларын иҗат итә, халык әкиятләре фабуласын кулланып язган әсәрләре дә бар. Бер яктан, фольклор мотивлары иҗатын тулыландырып, аның бөек шагыйрь буларак формалашуында роль уйнаса, икенче яктан Г. Тукай бу әсәрләре аша татар фольклорын дөньяга яңгырата, киләчәк буыннарга җиткерә.

ӘДӘБИЯТ

1. Balint Gabor. Kazáni tatár nyelvtanulmányok. I Fuzet. Kazáni-tatár szövegek. – Budapest, M. Tud. Akadémia, 1875.

2. Җамалетдинов Л. Ш. Тукай һәм әдәби әкият // Җамалетдинов Л.Ш. Татар әкиятләрен барлау юлында. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Б. 89–96.

3. Рәмиев З.З. Әдәбиятчы-текстолог язмалары. (1990 – 2013 еллар). – Казан: Ихлас, 2014. – 436 б.
4. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.; 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 384 б.; 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.; 6 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 471 б.
5. Тукай турында замандашлары / төз. С. Исәнбай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 46–53.
6.Тукай турында истәлекләр / Төз. И.Нуруллин. Р. Якупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 60–66.
7. Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., Б. 19–52.

УДК 821.512.145

# КНИГА СТИХОВ КАК ЖАНР В ПОЭЗИИ Г. ТУКАЯ (на примере книги «Җан азыклары»)

***М.И. Ибрагимов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье анализируется книга стихов Г. Тукая «Җан азыклары» («Пища души»). Ставится проблема книги стихов как жанра поэзии Г. Тукая. Определяются принципы архитектоники книги стихов «Җан азыклары». Установлено, что основополагающим для архитектоники книги становится принцип противопоставления. Трагическому в мировосприятии лирического субъекта противопоставляются пути его преодоления, начиная от отстранения (отчуждения) от окружающего социума и завершая сатирико-юмористическим дискурсом.
**Ключевые слова:** книга стихов, татарская поэзия, Габдулла Тукай, «Җан азыклары», архитектоника.
**Abstract.** The article analyzes the book of poems by G. Tukai «Jan aziklary» («Soul food»). The problem of book of poems as a genre of poetry by G. Tukay is formed. The principles of the architectonics of the book of poems «Jan aziklary» are determined. It has been established that the principle of opposition becomes fundamental for the architectonics of the book. The tragic in the world perception of the lyrical subject is opposed to the ways of overcoming it, starting from detachment (alienation) from the surrounding society and ending with a satirical and humorous discourse.
**Key words:** book of poems, Tatar poetry, Gabdulla Tukay, «Jan aziklary», architectonics.

С 1907 года, момента выхода в печати первой книги Г. Тукая «Габдулла Тукаев шигырьләре», по 1912 год в разных издательствах и типографиях было издано 20 книг поэта (не считая переизданий). Из них 12 – собрания стихотворений.

Как свидетельствуют письма Тукая издателям и литераторам, он трепетно относился к изданию своих книг. Так, в письмах Гильмутдину Шарафу по поводу издания в 1907 году в серии «Китап көтепханәсе»ндән («Из библиотеки поэзии») своего первого поэтического сборника, поэт настаивает на личном участии в его составлении «Возможно, – пишет Г. Тукай в письме от 9 июня 1907 года, – после этого (имеется в виду пересылка Г. Шарафом денежного гонорара в размере 50 рублей. – *М.И.*), – я сам приеду в Казань и лично подготовлю ее (книги. – *М.И.*) правильный вариант для печати» [3: 195][1]. В следующем письме (от 5 июля 1907 года) он просит на первое место в готовящейся к печати книге поставить стихотворения «Кит-

[1] Здесь и далее, кроме оговоренных случаев, смысловой перевод на русский язык выполнен автором статьи.

мибез!» («Не уйдем!»), «Шурале» и «Тәрбиятел әтфальгә» («Журналу «Детское воспитание»«) [3: 196].

В литературоведении существует представление о книге стихов как жанре, близкому поэтическому циклу, характеризующемуся определенным набором жанрообразующих признаков. К таковым в первую очередь ученые относят авторское заглавие и устойчивость текста в нескольких изданиях [1: 133].

Вместе с тем исследователи проблематизируют вопрос о целостности цикла («следует ли считать цикл таким образованием, которое по своим внутренним свойствам приближается к самостоятельному литературному произведению, а отдельные произведения, входящие в цикл, значимы только как части целого?»), указывая на «своеобразную двухмерность цикла» как его отличительное качество: «Целостность цикла находится в прямой зависимости от степени структурной автономности составляющих его элементов, а его единство следует рассматривать как единство противоположностей, характеризующееся действием центростремительных и центробежных сил» [1: 127].

Рассмотрим в указанном ракурсе последнюю прижизненную книгу стихов Г. Тукая «Җан азыклары» (1912).

В эту книгу в общей сложности вошло 44 стихотворения, написанных в 1911–1912 годы. Часть из них была написана в деревне «Өчиле», где поэт прожил с конца декабря 1911 по февраль 1912 года у своего дяди Кашфелькабира. В письме А. Урманчееву из «Өчиле» Г. Тукай упоминает о продолжении работы над сборником стихов: «Вещь, которую я начал писать, обозначая стихотворения цифрами, продвигается. Когда ты ее видел, там было всего 7 (стихотворений. – *М.И.*), теперь перевалило за 20. Если все кончится хорошо, мы так ее и назовем – «Под цифрами». Начинались «Цифры» в пессимистическом духе, но здесь (в деревне. – *М.И.*) я, кажется, стал совсем оптимистом…» [3: 230].

Исходя из слов самого поэта, можно сделать вывод, что задуманная им книга будет включать различные по настроению (эмоциональному тону) стихи. Если в первых стихах книги – «Үтенеч» («Просьба», 1912), «Тәләһһеф» («Грусть», 1910), «Читен хәл» («В трудную минуту», 1912), «Дошманнар» («Враги», 1912), «Кичке теләк» («Вечернее желание», 1912), «Ваксынмыйм» («Не стану мелочиться», 1912), преобладают стихи пессимистического содержания, то в целом ряде других стихотворений присутствуют характерные для Тукая юмор и сатира: «Пушкин вә мин» («Пушкин и я»), «Көтмәгәндә» («Нежданно»), «Бәрәңге вә гыйлем» («Картофель и просвещение»), «“Йолдыз”дан курка» («Боится газеты “Юлдуз”»).

Построение книги (как художественного целого) определяется моментами смыслового, эмоционального, жанрового притяжения и отталкивания входящих в книгу стихотворений, определяющих, в конечном итоге, ее архитектонику – «ценностную структуру эстетического объекта», проявляющуюся в разнообразных архитектонических формах (герой, тип, характер; завершение, юмор, трагическое и комическое; лирическое) [2: 24–25].

В первых стихотворениях книги основным композиционным приемом становится противопоставление: прошлого и настоящего («Просьба»), движения и неподвижности («Вечернее желание»), лирического субъекта и его окружения: «Дошманнар» («Враги»), «Ваксынмыйм» («Не стану ме-

лочиться»). Так, в «Вечернем желании» движению пера по бумаге *(«Якты беткәнчә язый́м дип, сызгалый́м тиз-тиз генә, / Кәгазь өстендә кала тик кәкре-бөкре эз генә. // Ноктлалар да төртмимен, керсә ярар, дип, киртәгә – / Мин үзем сызганны бик яхшы таный́м, дип, иртәгә» – «*Я скриплю пером поспешно, каждым мигом дорожу, / На бумаге след корявый сам никак не разгляжу. // Я пишу не ставя точек, я доверился перу, / Все равно свое писанье завтра утром разберу»[1]) противопоставляется желание неподвижности:

*«Ни бәхет! – дим, – иртәгә кич син тагын да янмасаң,*
*Бу ятыштан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»*

– Ах, какое счастье, если б не зажглась ты никогда!
Если б мне не встать с постели вплоть до страшного суда!

В ценностной структуре книги аксиологически значимыми оказываются возможности преодоления трагического. С одной стороны, это путь возвышения над миром людей, как в стихотворении «Не стану мелочиться», в котором отвергающий навязываемые ему обществом ценности лирический субъект стремится к преодолению эмпирического времени, устремляется к иному миру, в котором он уподобляет себя солнцу:

*Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,*
*Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!*

*Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;*
*Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.*

А я стремлюсь туда, где место, время – вечны. В вечность!
Непреходящи красота, свобода, человечность.

Я буду весел там, красив и вечно молод буду,
Пускай погаснет солнце, я там новым солнцем буду.
(пер. В. Думаевой-Валиевой)

Другой путь – осознание глубинной связи с народом как источником душевных сил для противостояния окружающему социуму. Во «Врагах» для близкого к отчаянию лирического героя (*«Дөньядан туйдым, өмидем юк...» – «*Все постыло, нет надежды…»; *«Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна»* – «Жизнь большой душе не в радость, все на миг в ней, не на век») эта связь выступает как архетипическая (реализация архетипа «сын нации»):

*Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!*
*Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.*

Иль в сиротской доле мало испытать пришлось невзгод?
Кто растил меня с любовью? Только ты, родной народ.

Третий путь преодоления трагического – поиск идеала в самой действительности. В своем творчестве поэт неоднократно обращался к теме идеальной личности. В книгу «Җан азыклары» Г. Тукай включил и опубликованное ранее ( «Йолдыз», 1912, № 10; «Ялт-йолт», 1912, № 37) стихотворение «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре» («Светлой памяти Хусаина»), написаное в связи с внезапной смертью известного публициста, общественного деятеля и одного из друзей Г. Тукая – Х. Ямашева.

Х. Ямашев выступает в стихотворении как идеальная личность, на что указывают традиционные для восточной поэзии приемы поэтики

[1] Перевод В. Тушновой. В ее переводе стихотворение называется «Вечерняя дума».

идеального: сравнение героя стихотворения с недосягаемой звездой, весенним солнцем, семантика света и чистоты, определяющие внешний облик героя и его нравственные качества.

Риторический вопрос, которым завершается стихотворение – «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?!» («Да разве можем при жизни достойным должное воздать?!») – выводит читателя к размышлениям об отношении социума к личностям, подобным Х. Ямашеву. В смысловом поле, определяемым этим вопросом, оказываются и некоторые другие стихотворения: «Дошманнар» (см. перекличку стихотворений на семантическом уровне (семантика светлого лица): «**Якты йөз** берлән алам каршы авырлык, авыруын» в «Дошманнар» и «Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма / Күрмәмен дип уйлыймын **бер якты йөз ул йөз кеби**» в «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре»); «Монафикка» («Лицемеру»).

Значимый в архитектонике книги мотив памяти, помимо стихотворения, посвященного Х. Ямашеву, звучит в стихотворениях «Яңа бер хатирәм» («Еще одно воспоминание») и «Сагыныр вакытлар» («Незабываемое время»). В последнем автор создает образ беззаботного детства, противопоставляемого настоящему лирического субъекта.

Итак, архтитектонику книги стихов Г. Тукая «Җан азыклары» формируют противопоставления (прошлое /настоящее, движение/неподвижность, идеал (идеальная личность) / социальная действительность). В качестве архитектонического принципа в книге выступает поиск ценностей, противопоставляемых трагическому мировосприятию лирического субъекта. Апофеозом трагического в книге становится стихотворение «Көзге җилләр» («Осенние ветры»), написанное в связи со страшным голодом, разразившемся в Поволжье в неурожайный 1911 год.

Образный ряд предваряющего стихотворение эпиграфа («*Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен; / Ядыма Тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен)* – ночь, звезды, бог – создает возвышенный эмоциональный тон, соответствующий мотиву связи человека с богом, но одновременно содержит оттенок трагического, на что, в частности, указывает метафора «кара бәхет» (досл. «черное счастье»). Таким образом, эпитет «кара» дважды повторяется в эпиграфе, усиливая его суггестивность. Возвышенно-трагический эмоциональный тон соответствует содержанию стихотворения – трагедии народа, в изображении которой Тукай использует прием поэтического многоголосия. В стихотворении выделены точки зрения различных героев (молодой девушки, Азраила, Ибрагима и Исмагила). Включение в этот ряд персонажей исламской мифологии усиливает высокое переживание трагического. В то же время все эти голоса объединены плачем – основным мотивом стихотворения. Этот плач объединяет весь народ (слово «ил» (страна) выступает в данном случае именно в таком значении), что позволяет говорить об эпичности стихотворения. Автор выступает здесь как человек, сопричастный этой всеобщей трагедии, не равнодушный к ней (отсюда – мотив бессонницы, которым открывается стихотворение). Его сознание объемлет страдание всего народа, что передается посредством образа осеннего ветра, в завывании которого автор слышит голоса страждущих соплеменников.

На другом полюсе книги «Җан азыклары» оказываются юмористические и сатирические стихотворения. В «Картофеле и просвещении» это юмористическое сопоставление истории распространения картофеля и

просвещения среди народа (*«И бәрәңге! Безгә килдең син ерак Америкадан;/ Мәгърифәт! Син безгә килдең мондарак – Яурупадан»* – «О картофель! Ты явился из Америки далекой. / Просвещенье! Путь твой ближе – от Европы до Востока»); в шуточном стихотворении «Нежданно» – встреча лирического субъекта с Шурале, безуспешно пытающегося добраться до тела лирического героя, чтобы защекотать его (сделать это оказывается невозможно – в лютый мороз герой одет во сто одежек); в сатирическом стихотворении ««Йолдыз»дан курка» («Боится газеты «Юлдуз»«) Тукай – образ татарского крестьянина, который всячески пытается избавиться от случайно оказавшейся у него газеты «Юлдуз». (объектом сатиры здесь становится не только необразованный и страшащийся любых нововведений крестьянин, но и сама газета «Юлдуз», которую поэт уподобляет трусливому зайцу). В этом же ряду и наполненное самоиронией стихотворение «Пушкин и я», в котором поэт в полушутливой форме сравнивает себя с Пушкиным:

*Хәзрәти Пушкин авылда язды үз «Евгениен»,*
*Мин исә җырлыйм фәкать монда бәрәңгенең көен.*

*Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннән түбән;*
*Тугъры күз салсаң эшенә – ул үзе миннән түбән.*

Великий Пушкин писал своего «Евгения в деревне»,
Я же здесь пою только песню о картофеле.

Но все же я не вижу считаю себя ниже Пушкина;
Если прямо взглянуть на его дело – он сам ниже меня.

Габдулла Тукай глубоко уважительно относился к народно-поэтическому творчеству, к его сюжетам, образам, выразительным средствам. Многие его произведения основываются на конкретных народных сказках, легендах и преданиях. Он писал: «Несомненно, народные песни – это подлинное зеркало души народа, зеркало, которому не дано потускнеть. Настоящий народный язык и истинный дух народа мы можем найти только в народных песнях» [1: 342].

Габдулла Тукай обращается к своему перу как к живому существу: «Призови народ к ученью, пусть лучи твои горят. Сделай так, чтобы считали черным черное у нас. Чтобы белое признали только белым – без прикрас!»

Глубоко философично обращение поэта к родимой земле:

*И весна твоя, и осень, лето знойное, зима,*
*Белые чулки, и лапти, да онучи, да сума,*

*И собаки, и бараны – вся родная сторона.*
*Любо мне и то, что плохо, даже то, чем ты бедна…*

Габдулла Тукай был истинным гуманистом. Лирический герой его поэзии начисто лишен тщеславия и яростный противник наживы, предательства.

ЛИТЕРАТУРА

1. Закиев М.З. Тукай и татарский литературный язык // Слово о Тукае. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 340–346.

2. Магомедов М.И. Габдулла Тукай и дагестанская литература // Наследие Габдуллы Тукая в контексте национальных культур. – Казань, 2011. – С. 73–75.

3. Тукай: Дөнья халыклары Тукай турында / төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 222 б.

УДК 821.512.145

## ТРАДИЦИИ САТИРЫ Г. ТУКАЯ В ТАТАРСКИХ РАССКАЗАХ XXI ВЕКА

***В.Ф. Макарова***
*Набережночелнинский государственный педагогический университет*
*(г. Набережные Челны)*

В статье рассматриваются социально-акцентированные сатирические рассказы начала XXI века, касающиеся основной проблемы татарской действительности – судьбы нации. Выделены символы, позволяющие сделать обобщения социокультурного характера. Выявлены традиции Г. Тукая и роль сатирических приемов в сатирических рассказах З. Хакима, Ф. Баттала, А. Ахметгалиевой, Л. Лерона, В. Вафина.

**Ключевые слова:** сатирический рассказ начала XX и XXI веков, ирония, гипербола, сарказм, «смех сквозь слезы», образ «чрево».

The article considers socially accented satirical stories of the beginning of the XXI century regarding the main problem of Tatar reality – the fate of the nation. Symbols that allow making generalizations of a socio-cultural nature are highlighted. The traditions of G. Tukai and the role of satirical techniques in the satirical stories of Z. Hakim, F. Buttal, A. Akhmetgalieva, L. Leeron, V. Vafin were revealed.
**Key words:** satirical story of the beginning of XX and XXI centuries, irony, hyperbole, sarcasm, «laughter through tears,» the image of «womb».

## XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР КӨЛКЕ ХИКӘЯСЕНДӘ Г. ТУКАЙ САТИРАСЫ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

***В.Ф. Макарова***
*Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты (Яр Чаллы)*

2000 еллар башында әдәбият галиме А. Яхин татар сатирик прозасы турында «жанр янып көлгә әйләнгәнгә охшый» дигән иде [9: 144]. Соңрак, 2010 елларда «Казан утлары» журналы «Печән базары» дигән сатирик хикәяләр конкурсын игълан иткәч, бу хәл үзгәрде кебек – күпләп көлке хикәяләр басылды. Әмма аларның күбесе Ә. Еники, Г. Афзал, Х. Сарьян, Ф. Шәфигуллиннарның чынбарлыкны тәнкыйтьләү, җитәкчеләргә кизәнү тыелган елларда фикерне читләтеп, эзоп теле белән, аллегорик образлар аша яктырткан, көчле сарказм белән сугарылган сатирик хикәяләреннән ерак булдылар. 90 нчы еллар башындагы З. Хәким хикәяләрендәгечә үткен иҗтимагый сатира XXI гасыр башында күпмедер демократия шартларындагы көлке хикәяләрендә аз күзәтелде. Бу күренешне бәлки шуның белән аңлатып буладыр: бары «Басым никадәр ныграк булса, сатира да шуның кадәр кискен. Коллык көчлерәк булган саен, сатира шуның кадәр нечкәрәк...» [3: 484].

Г. Тукайның да бит сатирик иҗаты XX гасыр башында нәкъ менә реакция шартларында чәчәк атты, азатлык дошманнарына каршы идеологик һөҗүм коралына әверелде. Халыкның иҗтимагый-мәдәни хәлен тәнкыйтьләү мотивы белән сугарылган, угы наданлык, әхлаксызлык, дини фанатизмга юнәлтелгән («Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?», «Кечкенә генә бер көйле хикәя», «Хатирәи «Бакырган», «Мөритләр каберстаныннан бер аваз», «Сорыкортларга», «Пыяла баш»), демократик үзгәрешләргә чакыручы («Государственная думага», «Китмибез»), үзләрен милли мәнфәгатьләрне кайгыртучылар дип тәкъдим иткән икейөзле, әхлаксыз, динчеләрдән көлгән («Ысулы кадимче», «Милләтчеләр», «Яшьләр», «Казан вә Кабан арты» һ.б.) әсәрләре, конкрет кешеләр һәм тормыш күренешләрен тәнкыйтьләгән фельетон-хикәяләре һәм мәкалә-памфлетлары («Былтырның хисабы», «Шартлар», «Хаҗи», «Төш күрдем» һ.б.) татар җәмгыятен яңарту идеясе белән сугарылган иде.

«Россия өстенә ябырылган иҗтимагый-сәяси явызлыкның татар җәмгыятендәге конкрет бер гәүдәләнешен фаш иткән әсәр-пародия» буларак туган «Яңа Кисекбаш» поэмасында шагыйрь кадимче сәүдәгәрләрнең, татар мещаннарының һәм надан руханиларның идея, мораль түбәнлеген, гомумән, татар феодаль-буржуа җәмгыятенең асылын, «буш урында таптануын» тәнкыйть итү белән генә чикләнмичә, бәлки Россия самодержавиесе һәм аның Дәүләт думасының да реакцион йөзен сарказм белән фаш итте.

Г. Тукай кыю тәнкыйтьләгән шактый күренешләр, проблемалар бүгенге көндә дә актуаль булуына карамастан, XXI гасыр башы татар көлке хикәясендә усал сатира күзәтелми диярлек. Шулай да, тар тематикалы (башлыча

вак-төяк көнкүреш мәсьәләләрен күтәрү, бер типтагы шаблон хикәяләр язылу, гомумәһәмиятле проблемалар күтәрелмәү һ.б.), «урам теле» стиленә мөрәҗәгать иткән бихисап күп сатирик хикәяләр арасында җәмгыятькә, сәясәткә үткен тәнкыйди күзлектән караган, Г. Тукайдан килә торган урта гасыр татар әдәбиятының шартлы романтик стилен, халык иҗаты элементларын, фантастик алымнарын иркен файдаланган, көчле ирония, сарказм, гипербола, пародия, гротеск кебек алымнарга мөрәҗәгать иткән хикәяләр дә юк түгел.

Зөлфәт Хәким, Фәнзаман Баттал, Дамир Гыйсметдин, Ләбиб Лерон, Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләрендә көлке объекты булып, яшәп килгән җәмгыять, сәясәт, хакимият, гаделсезлек, идеология тора.

Әйтик, Ф. Баттал үзенең хикәяләрендә («Сыйнфый сугыш» «Юлсыз юлда») илдә алып барылган сәясәтне, бар нәрсә акчага, әшнәлеккә корылган җәмгыятьне тәнкыйть итә. Аларда милли гамь белән яшәгән тугры сүзле, хөр рухлы язучының сатирик каләмендә сурәтләнгән заман образы күз алдына килеп баса, татар халкының милли азатлык көрәшенә, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга нисбәттә автор кайнар төстә алга сөргән кыю фикерләр, тормыш-яшәешкә кагылышлы фәлсәфи уйланулар, фараз-гөманнар чагылыш таба.

Ф. Батталның «Җәһәннәмдә дәҗҗал» [2] хикәясендә тыныч кына яшәп яткан Ата Шайтанга Иблис Сатанович шалтырата. Имеш, Бөтендөнья тәмуглары башлыгы Маршальский Иблискә әрвахларның хокуклары сакланмый дигән «жалу»лар бара икән. Шул уңайдан Шайтан Чертовичның идарәсенә меңәрләгән кешеләрдән торган тикшерү делегациясе, төрле комиссияләр җибәрергә ниятлиләр. Бу хәлләргә нисбәтле Генеральный Иблис Шайтанга махсус «указания»ләр бирә. Шул көннән башлап тәмугта «ялган оҗмах» төзү эшләре башлана. Исән чагында ук хакимият биргән вәгъдәләргә ышанып көн күргән халыкны Җир асты патшалыгында да матур сүзләр белән алдарга ниятлиләр, ләкин үзгәртеп кору эшләре җиңел генә бармый. Бар әйбернең дә акчага, кәгазь эшенә барып тоташканына күнеккән халык Шайтаннан смета, расценкалар, пичәт сугылган килешү таптыра. Алардан башка эш башларга беркем дә ризалашмый. Шул ук вакытта халыкта оҗмахка хаҗәтлек юклыгы күренә. Кешеләрдә үч алу теләге оҗмахка эләгү теләгеннән өстен булып чыга. Башка төрле тормыш күрмәгән халык газаплауга риза булып, үз хокукларын яклый алмыйча яши.

Кешелекнең үз-үзен юкка чыгаруы турында автор Шайтан авызыннан җиткерә: *«Аларда, зиначылык аркасында, төрле милләтләр буталышып бетте, ни Аллага, ни бәндәгә, хәтта ни җенгә, ни шайтанга диярлек мутантлар үрчеде...»* [2: 71]. Әсәрдә делегация килү вакыйгасында бүгенге көндә тамыр җәйгән ясалмалылык, күз буяу сурәтләнешен күрәбез (*«Килер кунаклар урамнардагы пробкаларда иза чикмәсен өчен»,* тәмугның өстеннән дә, астыннан да үтүче ике метро линиясе, төрле төстәге гәрәбәләр белән бизәлгән биналар төзелү һ.б.). Шулай ук, «коллык психологиясе», халыкның күндәм булып, баш күтәрми эшләве тәнкыйть объектына әверелә.

Дантеның «Илаһи комедия»сендәге кебек үк, «Җәһәннәмдә дәҗҗал»да да реаль шәхесләрнең тәмугта ничек җәзаланулары сурәтләнә. Фани дөньядан аермалы буларак, монда яшәеш башка кануннарга корылган. Кайчандыр ил башында утырган, миллионнарча кешенең рәнҗешен алган шәхесләр үзләре үк коллар сыйфатында йөрергә мәҗбүр. Ясалма оҗмах төзелеп бетте дигәндә генә килеп чыккан «түнтәреш»тән соң Иблис Сатанович урыны-

на идарәгә Иблис Дьяволович килә. Биредә геройларның исемнәре мөһим функция үти – яңа җитәкченең дә «адашы» кебек сәясәт алып барачагына ишарәләнә.

Л. Леронның «Мин президент булгач...» [6] хикәясендә дә исемнәр «сөйли» торган – җитәкче Хәрәмша Бөкәшкин, урынбасарлары – Птичкин, Воронов, Медведкин, Крысин, Зайцев (яңа президент интернационал яклы булуын күрсәтү өчен җыештыручы итеп татар түтиен ала).

Әлеге хикәядә Бөкәшкинның могҗиза ярдәмендә президент булуы сурәтләнә. Моңарчы ярлылыкта яшәгән бу кеше президент кәнәфиенә утыргач, үз тиңнәренең хәлен оныта. Автор аның берсеннән-берсе мәгънәсез указлар чыгаруын, килешүләр төзүен сурәтләү аша җәмгыятебездә барган үзгәрешләрне, ришвәтчелек, түрәләрнең үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәвен тәнкыйть утына тота.

М. Вафинның «Габделҗаббарның төше» [4] хикәясе дә шундыйрак сюжетка корылган. Автор XX гасыр башында яратып кулланылган төш күрү алымын эшкә җигә. Татар агае президент итеп сайлангач, илдә гаҗәеп үзгәрешләр башлана: «*гербтагы ике башлы сәмруг кош аякларына читек, бер башына түбәтәй, икенчесенә калфак киеп алды», «урыс каены да күләгәгә күчеп, аның урынын тагы да кодрәтлерәк агач – «татар имәне» алды. ...Кайбер милләтчеләр хәтта Африкада үскән бук агачын да татарныкы итү теориясен күтәрде»* [4: 170]. Язучы мәңге тормышка ашмаслык, ләкин татар халкы күңелендә хыял булып яшәгән мәсьәләләргә туктала. Кайберләрен хәтта гадәттән тыш арттырып, абсурдлык дәрәҗәсенә күтәрә, шул рәвешле, комик ситуация туа. Тукайның «Яңа Кисекбаш»ындагыча татар җәмгыятенең читтән могҗиза көтеп ятуларына автор шелтәсе сизелә.

Әсәрдә татар халкының дәүләтчелеге юклыгына да ачыну чагылып үтә: «*Заманында татарларны Монголиягә куарга җыенган Жириновский бу сүзләрен татарларны яратып, аларны Монголиядә булса да дәүләтле итү өчен әйтүе белән аңлатты һәм татар либераллары партиясе төзеде*» [4: 170].

Габделҗаббар төшендәге тормыш моделенә өндәге реаль тормыш капма-каршы куела. Татлы хыялларга бирелеп йоклап яткан геройның төше өзелә: «*Шул вакыт кемдер Габделҗаббарны: «Дед, а, дед», – дип тарткалый башлады. Баксаң, җәйге каникулга кайткан оныгы су буена балык тотарга төшәргә чакыра икән. «Ладны, чичас», – дип, Габделҗаббар иренеп кенә киенергә кереште*» [4: 171]. Көтелмәгән чишелештә төштәге «татарлашу» процессы өндәге «руслашу» белән алышына, шул рәвешле, автор укучыга уйланырга урын калдыра.

Күргәнебезчә, Тукай иҗатыннан килгән татар халкын милләт буларак саклап калу проблемасын күтәргәндә, язучылар төрле чаралар ярдәмендә ассимиляция процессының кая алып баруын, җитәкчеләрнең кечерәк милләтләрне юк итүгә корылган сәясәтен чагылдырган әсәрләр иҗат итәләр; укучыны кул кушырып утырмаска, җиң сызганып, милләтне саклап калу өчен бердәм көрәшергә өндиләр.

А. Әхмәтгалиеваның бердәмлеккә өндәгән «Җырлап яши Мөхәммәтҗан» [1] исемле сатирик хикәясендә мәктәптә татар теле укыткан Мөхәммәтҗан, кыскартуга эләккәч, көннәр буе берүзе кәрт сугып, әле «Интернационал», әле Рәсәй гимны көенә салып, «*милләт өчен*» «җырын» кабатлап утыра. Радиодан да көне-төне «миңга», «мөһабәт», «өзек кашы» дип сөйләшүче диктор, Элизабет туташлар җырлавы бирелә.

Хаклык эзләүче герой тарафыннан риторик сорауга җавап эзләнелә: *«...милләт өчен дип эшләттеләр, милләт өчен эштән кудылар, милләт өчен дип хәзер телевизор, интернет, сыра шешәсе белән кыйныйлар. Соравым шул: кем ул милләт һәм кайда ул?»* [1: 36].

Хикәядә, Мөхәммәтҗан кебек «кечкенә кеше» тибы, «яшь аралаш көлү» аша Т. Миңнуллинның «Минһаҗ маҗаралары» романындагыча, бу дөньяда тирән фәлсәфи уйларга бирелмичә, башны җүләргә салып кына яшәп була, дигән фикер җиткерелә.

Татар әдәбиятына Европа һәм рус әдәбиятындагы модернистик һәм постмодернистик алымнарны, концепцияләрне алып кергән З. Хәким сатирик хикәяләрендә үзен оста ироник итеп танытты. Әдипнең соңгы елларда дөнья күргән әсәрләреннән «Сәер никрут» [8] хикәясендә ялганга, икейөзлелеккә, ришвәткә корылган, рухи кыйммәтләр юкка чыга барган тоталитар җәмгыятьтән гипербола ярдәмендә үткен көленә.

Күпчелек яшьләр яраксыз дигән кәгазь-документ юнәтеп армиягә бармый калган заманда Ватанны сакларга атлыгып торучы Булатның армиягә китәргә йөрү тарихы, *«чамадан тыш патриотизм»* диагнозы белән психдиспансерга эләгүе абсурд вакыйгаларда бирелә.

Палатада көн саен бер үк тәртип кабатлана: йокыдан уяну белән бүлмәдәгеләр тарихи-сәяси-фәлсәфи темаларга бәхәсләшәләр, ызгышуның иң кызган моментында я ботка китерәләр, я табиблар обход ясый, я укол кадар вакыт җитә. Сырхауларны «борчыган» мәсьәләләр укучыда ирексездән көлү теләге уята: *алар Гитлерның әбисе Чирмешәннәнме, әллә Аксубай мишәре булганмы, Калашников удмуртмы, урысмы, әллә татармы, Александр Македонский малайлар яратканмы* дигән сорауларга җавап эзлиләр; төрле тарихи вакыйгаларга карата үз фикерләрен белдерәләр. Алогизм белән сугарылган фаразларга Булат та акрынлап ышана башлый, уколлар тәэсирендә үз хәленә апатиясе арта бара.

Прозабызда инде символик образга әйләнгән җүләрләр йорты яшәеш моделе белән реаль тормыш арасында параллельлек үткәреп була. Авыруларның укучыга көлке тоелган диалогын чынбарлыкта халыкның юк-бар белән мавыгуы, әһәмиятле мәсьәләләрне күрә белмәве белән чагыштырырга, ә көндәлек режимга салынган «процедуралар» тәртибен гомумән кешелек яшәешенең шаблон буенча баруына ишарә дип карарга мөмкин.

Автор баш табибның исемен әйтмичә, аны *Ашаев* дип кенә атый. Фамилиянең *аш (ашый)* тамырыннан ясалуы аны йөрткән кешенең дә корсак ягын кайгыртып яшәүче булуына басым ясый.

Әйтеп үтәргә кирәк, XX гасы башы татар әдәбиятында да күп авторларда халык мәнфәгатьләреннән ерак торучыларны гәүдәләндерүче «корсак» образ-символын очратырга була (Ш. Мөхәммәдов «Юанкорсаковка ачык хат!», Г. Исхаки һәм Ф. Кәримиләрнең «Корсак» хикәяләре, Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» һ.б.).

*«Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак;*
*Ә я корсак», вә я корсак, җиһанны капладың, вай-вай!*
*Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак,*
*Тотып ярсак боларны без, заман үткәрми, картаймай*

(«Сорыкортларга») [7].

*«Корсак, корсак! Син берникадәр кешеләрнең тәннәрендә генә түгәрәкләнеп, май белән капланып торыр өчен миллион кешеләрнең тәннәренә кор-*

*сакларын ябыштырасың! Миллионнар кешеләрнең тугры юлдан язып, үзенең туганын, ишен ач калдыруына сәбәп буласың!.. Фазыл әфәнде кебек кешеләрнең халыкка файда урынына зарар итүләренә сәбәп буласың!..»* [5: 37].

Шул рәвешле, XXI гасыр башы татар көлке хикәяләре арасында *XX гасыр башындагыча милли-сәяси мотивларның кыю яктыртылганнары,* Тукайлардан килгән матур традицияләрнең, сатирик образ тудыру алымнары һәм комик чараларның чагылыш тапканнары да бар.

ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәтгалиева А. Җырлап яши Мөхәммәтҗан // Печән базары. – Казан: «Казан утлары» журналы редакциясе, 2012. – Б. 22 –40.

2. Баттал Ф. Җәһәннәмдә дәҗҗал // Печән базары. – Казан: «Казан утлары» журналы редакциясе, 2012. – Б. 60. – Б. 59 –73.

3. Борохов Э. Сатира // Энциклопедия афоризмов (Мысль в слове). – М.: АСТ, 199. – С. 484.

4. Вафин М. Габделҗаббарның төше // Казан утлары. – 2013. – № 8. – Б. 170 –171.

5. Исхакый Г. Корсак: хикәя // Мирас. – 1996. – № 5 –6. – Б. 37 –38.

6. Лерон Л. Мин президент булгач... // Чыктым аркылы күпер: Юмористик хикәяләр, пьесалар, парчалар, мәзәкләр. – Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 212 –215.

7. Хаков В. Г. Тукай әсәрләренең теле һәм стиле: http://gabdullatukay.ru/tukay-science/scientists/hakov-v-g-tukaj-eserlerenen-tele-hem-stile/ – мөрәҗәгать итү вакыты: 25.03.2021.

8. Хәким З. Сәер никрут // Казан утлары. – 2014. – № 11. – Б. 8 –53.

9. Яхин А. Елмаям уйчан гына // Гөлләр үсә көлләрдә...: XX гасырның 50 –60 нчы еллар татар әдәбияты. Поэзия.Драматургия. – Казан: Мәгариф, 2006. – 415 б.


УДК 82.091

## МАНДОЛИНИСТ – ДРУГ ТУКАЯ


***Л.А. Медведева***

*Литературный музей Габдуллы Тукая (Казань)*



Экспозиция литературного музея Г. Тукая посвящена жизни и творчеству татарского поэта. Здесь также представлены фотографии и личные вещи знаменитых современников, друзей и единомышленников Тукая. Залял Мазитов – современник Г. Тукая, один из активистов Восточного клуба в Казани. Он играл на мандолине в первом татарском струнном оркестре при Восточном клубе.


**Ключевые слова:** современник Г. Тукая, музей, Залял Мазитов, мандолина.


The exposition of the literary museum of Tukay is dedicated to the life and work of the Tatar poet. There are also photos and personal belongings of famous contemporaries, friends and associates of Tukay. Zalal Mazitov is a contemporary of G. Tukay, one of the activists of the Eastern Club in Kazan. He played the mandolin in the first Tatar string orchestra at the «Sharyk» (Eastern) Club.


**Key words:** contemporary of Tukay, museum, Zalal Mazitov, mandolin.

## ТУКАЙНЫҢ МАНДОЛИНАЧЫ ИПТӘШЕ


***Л.Ә. Медведева***

*Габдулла Тукай әдәби музее (Казан)*


Г. Тукай әдәби музееның даими экспозициясендә шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты һәм әдәби мирасы гаять әтрафлы яктыртыла. Биредә Г. Тукайның замандашлары һәм фикердәшләренә дә зур урын бирелә. Алар белән җентекләп «Тукай йолдызлыгы» һәм «Шагыйрь мәхәббәте» дип аталган залларда танышырга була. Анда шулай ук шагыйрь белән аралашкан

иптәшләре турында файдалы мәгълүмат алырга, аларның шәхси әйберләрен дә күрергә мөмкин.

Музей залларында күп төрле музыка уен кораллары тәкъдим ителә. Алар арасында скрипка, гитара, гармоннар, курай, кубыз һәм башкалар бар. Уен кораллары арасында үзенчәлекле формадагы мандолина игътибарны җәлеп итә. Аның кызыклы тарихы бар. Мандолинаны музейга 1985 елда, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы тормыш-көнкүреш предметлары, Ф. Әмирханның гаиләсе һәм аларның дуслары Фатыйма һәм Җәлал Мәҗитовларның фотосурәтләре белән бергә, Ф.З. Еферова тапшыра. Музейга кабул итү документларында күрсәтелгәнчә, уен коралының хуҗасы – Җәлал Мәҗитов.

Җәлал Мәҗитов – Г. Тукайның замандашы, «Шәрык» клубы активистларының берсе. «Ул Казанның Яңа бистәсендә Күл урамы, 38 йортта яшәгән. Аның әтисе «Болгар» номерларыннан бер йорт аша гына Татарстан һәм Мәскәү урамнары чатындагы йортта «Сәмәрканд» исемле номерлар, постоялый двор һәм харчевня тоткан» [1: 457]. Җ. Мәҗитов заманының аңлы егетләреннән булган, «Шәрык» клубы ачылган көннәрдән алып татар кыллы оркестрында мандолинада уйнаган. Аның шагыйрь Г. Тукай турында истәлекләре дә бар.

Җ. Мәҗитовның Г. Тукай турында хатирәләре берничә эпизодны сурәтләүдән гыйбарәт. Беренче истәлек «Шәрык» клубы эшчәнлеге белән бәйле. «Клубта һәр атна диярлек әдәбият ахшамнары, төрле темага ликсиәләр һәм кыллы аркестрның кансиртлары, гаилә кичәләре уздырыла иде» [1: 457]. Г. Тукай әдәби музее экспоциясендә «Шәрык» клубы белән бәйле материаллар «Шагыйрь мәхәббәте» залында яктыртыла. Биредә Җ. Мәҗитовның татар кыллы оркестрында уйнаган башка иптәшләре белән төшкән ике фотосы урнаштырылган. Татар оркестрының составы турында Җ. Мәҗитов Тукай турындагы истәлекләрендә болай яза: «“Сәйяр” труппасы эшли башлау белән безнең кыллы аркестр да, көчәйтелеп, “Шәрык” клубында даими эш башлый. Аркестрның җитәкчесе булып Исмәгыйль Галиәкбәрев (винский гармунда), Заһидулла Яруллин (пианина), Солтан Рахманкулов (мандалина), Җәләй Мәҗитев (мандалина), Мөхәммәт Яушев (мандалина), Галиулла (бу кеше талчукчы иде) (эскрипкә), Ибни (гитара), Миңлебай (мандул). Менә аркестр шул кешеләрдән гыйбарәт иде» [1: 462]. Җ. Мәҗитовның мандолинасы да тамашачыларга әлеге залда тәкъдим ителә.

Мандолина кыллы музыка уен коралларыннан санала. Татарлар арасында бу уен коралы XIX йөзнең соңгы чирегендә тарала башлый. Ул башта һәвәскәрләр уен коралы буларак, соңыннан концертларда башкару өчен кулланыла. XX йөз башында беренче милли уен кораллары ансамбльләре составына керә [3: 45]. «В. Апанаев һәм И. Галиәкбәрев җитәкчелегендәге оркестрлар, асылда, кыллы уен коралларыннан (аеруча ул вакытта бик популяр булган мандолинадан) торган» [2: 24]. «Шәрык» клубында оешкан беренче татар кыллы оркестрында мандолина бик популяр уен коралы була. Ул елларда алдынгы карашлы татар яшьләре бу уен коралында яратып уйныйлар. Җ. Мәҗитов – әнә шундый яшьләрнең берсе буларак танылa. Ул уйнаган татар кыллы оркестры Казан сәхнәләрендә бик еш чыгыш ясый һәм танылу ала.

Җ. Мәҗитовның мандолинасы үзенчәлекле яссы формада ясалган, кызыл агачтан җитештерелгән. Тавыш көчәйтү хезмәтен үти торган аскы һәм өске тактасы фигуралы, үлчәмнәре буенча бертигез. Дүрт парлы кылы бар. Өске тактасы инкрустацияләнгән һәм тавыш көчәйткеч тишеме йолдыз фор-

масында ясалган. Өске тактага амур белән лира рәвешендәге агач сын беркетелгән. Уен коралының үлчәмнәре 61×20,5×7 см.

Шунысын да әйтү урынлы булыр, Җ. Мәҗитов Г. Тукайның 1910 елның 15 апрелендә «Шәрык» клубында «Халык әдәбияты» лекциясен тыңлаучыларның берсе була һәм бу хакта болай искә ала: «Йомшак кына аваз белән җылы гына җөмләләр белән башланган бу лекция бара-бара эзгә төшә һәм Г. Тукай үзе дә (су коеныр алдыннан чиркәнеч алган кеше кебек) иркенләп сулу ала һәм сөйли торган сүзен киңәйткәннән-киңәйтә бара. Халык лекцияне бик яратып тыңлый һәм ахырында лекциядән бик риза булып таралалар.

Лекцияне тыңларга килүчеләр арасында Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Гафур Коләхмәтев, Каюм Коләхмәтев, Миргаяз Иманаев, Гайнетдин Әхмәрев һәм башкалар булалар» [1: 459].

Г. Тукай Мәҗитовларның «Сәмәрканд» харчевнясына еш кына ашарга килеп йөри. Бу турыда Җәлал Мәҗитов менә ничек яза: «...артистлар безнең «Сәмәрканд» харчивнасында ашый башлыйлар. Ләкин араларында Габдулла Кариев булмый. Артистлар ашап чыгып киткәннән соң, Г. Кариев Габдулла Тукай белән килеп керә һәм үзләренең бүлмәләренә урнашалар. Мин дә алар белән бергә чәй эчәр өчен бүлмәгә керәм. ... Тукай үзен бик садә һәм салмак тота...» [1: 463]. Истәлекче шагыйрь башка «артистлар белән бергә килмәде, һаман Кариев белән генә килә иде, гаҗәп дәрәҗәдә аны ярата, аның белән бик якын дусларча (...) сөйләшә иде», ди [1: 463]. Сүз мәшһүр артист, режиссер һәм драматург Габдулла Кариев турында бара. Г. Тукай Җаек чорыннан ук Кариев белән таныш һәм дус була, еш аралашып тора, хатлар алыша.

Җ. Мәҗитовның гаиләсе татар әдәбияты классигы, язучы, драматург һәм публицист Ф. Әмирханның энесе Ибраһим Әмирханов гаиләсе белән еш аралаша, хатлар алыша. Мандолина белән бергә музей фондына дистәдән артык открыткалар тапшырыла. Аларда Җәлал һәм Фатыйма Мәҗитовлар, Ибраһим һәм Нәфисә Әмирханнарның фотолары бар. Фотолар арасында Нәфисә белән Фатыйманың кыз чагындагы һәм аларның тормышка чыккач төрле елларда төшкән сурәтләре белән танышырга була. Фотоларның күбесендә Нәфисәнең автографларын укырга мөмкин: «Мөхтәрәмә туганым Фатыйма ханыма гомерлек ядкарем! Нәфисә Әмирхания». Икенче фото Зәйнәб туташка адресланган: «Кыйммәтлү сеңелем Зәйнәб туташ! Онытма мине. Сине сөюче апаң Нәфисә бинте Габдерәхим Катиева. 16.04.1914».

Ибраһим Әмирханов 1924–1926 елларда Согуд Гарәбстанында совет консуллыгында эшли. Нәфисәнең тагын бер хаты Хиҗаздан 1926 елның 17 февралендә язылган һәм Фатыймага юлланган:

«Сәвеклү туганым Фатыйма!

Сине гаять сагынып, зурлыкта очы-кырые булмаган бөек-бөек диңгезләр зурлыгындагы күп-күп сәламнәремне җибәреп, исәнлектә күрешүемезне көтеп калам. Безләр хәзергә, әлхәмделилла, сәламәтләрмез, сез дусткайларымның да исәнлек хәбәрегезне алып, бик шад булдым. Тугankай, көчкә синнән кичә икенче хатыңны алдым, бик озак көтә торгач, синең икенче хатыңны да китереп җиткездем. 5 нче гыйнварда язгансың, никадәр озак килгән. Кичә 16 февральдә генә алдым бары. Мин сиңа никадәр хат язсам да, мин синнән алты айга бөтенләе 2 хат алдым. (...) Туганым, менә сиңа кулымда бар булган рәсемемне генә җибәрәм. Шәп булмаса да, бер рәсем булсын дип җибәрдем. Бер унбиш көннән башка рәсемнәрем дә

булачак. Үзеңнән хат алсам, җибәрермен. Туганым, мин үткән хатымда да язган идем, балаларың берлә карточкага төшеп җибәр дип, төшеп җибәр әле, җәме, күрәсем килә, бик килә. Гаиләңә сәлам. Хуш. Сагынып Нәфисә.

Хәят апага күп сәлам. Нәфисә».

1926 елның 31 августында «Гарибалда» пароходындагы сәяхәт вакытында язылган хат та Фатыймага адресланган:

«Сәвеклү тугankай Фатыйма!

Сиңа Азмарада үткәргән көннәремезнең хатирәсе уларак ошбу рәсемемне җибәрәм. Без бу җыл Азмарада 26 көн тордык. Менә сезгә бу хатларны пароходтан язам. 10 көннән бирле без диңгез өстендә, әле бик сәламәт кенә, бик хозур гына барамыз. Менә сәгать 3 көндезге. 2–3 сәгатьтән Неаполигә барып җитәмез дә, шунда төшәмез. Неаполидә бүген кунып, иртәгә поезд берлә Римгә китәмез (Неаполидән Рим поезд берлә 4–5 сәгатьлек җул). Римдә бер атнадан артык торылмас дип уйлыймыз. Исән булсак күрешер вакытларымыз якынлаша, иншалла, ләкин сезләр исәннәрсез микән инде. 3 айдан бирле сезнең хакта бер нәрсә дә белмимез бит. Соңгы вакытта сине авырып тора дип язалар иде. Барыңыз хакында да «исәннәр микән» дип бик уйлыйм. Гаиләңә күп сәлам сөйлә. Хәят апаларга махсус сәламем. Фирдәвесне минем өчен үп. Хәзергә хуш бул. Сагынып, Нәфисә».

Милли музей җыелмасындагы бу открыткалар күргәнебезчә, дистә елдан артык вакытны үз эченә ала: аларның берничәсе 1914 елларга карасa, калганнары 1926 елда төшерелгән. Открыткалар бу шәхесләрнең сурәтләре белән генә түгел, ә шушы вакыт аралыгында алар тормышында булган вакыйгалар белән дә танышырга мөмкинлек бирә. Шулай итеп, музейда саклана торган кызыклы предметлар аның хуҗасы турында гына түгел, ә даирәсе, аның белән аралашкан башка шәхесләр турында да файдалы мәгълүмат бирә ала.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай турында Җәлал Мәҗитов истәлекләре // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Ж.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – 2 т. – Б. 457–463.

2. Миңнуллин Ж.С. Шәрык клубы: тарихи очерк. – Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2013. – 95 б.

3. Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөхәррир Ә.М. Мазһаров, җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2014. – 4 т. – 632 б.

УДК 821.512.145

## Н. ИСАНБЕТ ОБ АКАДЕМИЧЕСКИХ ИЗДАНИЯХ Г. ТУКАЯ

***Ф.Х. Миннуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В данной статье расматриваются статьи Н. Исанбета, где автор указывае на недостаткии и требования к двухтомным академическим изданиям Г. Тукая. Изучаются текстологические статьи ученого и выявляется его личный вклад в текстологию.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, Н. Исанбет, текстология, татарская литература, проза, поэзия.

This article examines the articles of N. Isanbet, where the author points out the shortcomings and requirements for two-volume academic publications of G. Tukai. The textological articles of the scientist are studied and his personal contribution to textology is revealed.
**Key words:** G. Tukay, N. Isanbet, textual studies, Tatar literature, prose, poetry.

# Н. ИСӘНБӘТ Г. ТУКАЙНЫҢ АКАДЕМИК БАСМАЛАРЫ ТУРЫНДА

***Ф.Х. Миңнуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

XX йөз татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы, драматург, шагыйрь, тел-әдәбият галиме, халык авыз иҗаты белгече Нәкый Исәнбәт – милләт рухының байлыгы сагында торган, мирасын туплауга, өйрәнүгә, үстерүгә үзенең талантын багышлаган, халкыбызның үткән сәхифәләрен бүгенге көн һәм киләчәк белән тыгыз бәйләп торучы каләм иясе. Ил, милләт өчен катлаулы елларда үз кыйбласын саклап калган шәхес ул. Аның иҗатында татар халкының тарихы, яшәеше, рухи дөньясын биләгән өмет-хыяллары, фаҗигаләре чагылыш тапты. Әлеге мәкаләдә Н. Исәнбәтнең Г. Тукай мирасын халкыбызга кайтару эшенә керткән өлешенә, дөресрәге бөек шагыйрьнең академик басмаларына карата булган таләпләренә, кимчелекләренә тукталыныр. З. Рәмиев билгеләгәнчә: «1929–1986 елларда чыккан Тукай күптомлыкларының берсендә дә Нәкый Исәнбәт төзүче яисә фәнни редактор сыйфатында катнашмаганлыктан, сүз кузгатырга нигез дә юктыр, бәлкем. Әмма, аның язган мәкаләләрен барлап чыксаң, кайбер чыгышларын хәтердә яңартсаң, әлеге мәсьәләгә караган фикерләре, һичшиксез, томнарны әзерләгәндә өйрәнелгән һәм томлыкларның текстологик сыйфатын күтәрүгә хезмәт иткәнлеген, яисә хезмәт итәргә тиеш булганлыгын күрербез» [4: 111]. Н. Исәнбәтнең «Совет әдәбияты» журналының 1945 елгы 5 нче, 1949 елгы 7 нче саннарында чыккан язмаларнында Г. Тукайның Академик икетомлык басмасы бәяләнә. «Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре» һәм «Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре» исемле мәкаләләрен «Казан утлары»ның 1966 елгы 4 нче һәм 1969 елгы 4 нче саннарында укыйбыз. Язмаларында галим, текстологик тикшеренүләрнең бурычлары арасында иң мөһимнәре итеп текстларның авторлыгын ачыклау, текстларны басмаларга дөрес урнаштыруны билгели. Н. Исәнбәт Г. Тукай иҗатын мөмкин кадәр тулырак басмаларда чыгару турында кайгырта. Академик басманың икенче томына «Ялт-йолт» журналындагы текстларның бары тик 20–25 саннарындагылары гына алынып, аның 30 лап саныннан алынмауны, шулай ук «Уклар» һәм «Яшен» журналларыннан аз кертелүне «псевдонимнарны ачу өстендә җитәрлек гыйльми тикшеренүләр уздырылмау» нәтиҗәсе итеп саный [4: 110]. «Тукай! прозасы» исемле язмасында Н. Исәнбәт шулай ук СССР ФА Казан филиалы ТӘҺТИ чыгарган икетомлык Академик басманың икенче томы, дөресрәге, анда урнаштырылган проза әсәрләре хакында сүз алып бара, аларның югары дәрәҗәдә булуын, шигырьләреннән аермалы буларак бер генә өметсезлек күренеше, мотивы күренмәвен ассызыклый. Әлеге язмада Х. Хисмәтуллин тарафыннан язылган «Сүз башы» танкыйтьләнә. Шагыйрь иҗатында гәүдәләнгән идеяләрнең, каршылыкларның һәм, гомумән, аның иҗтимагый нигезләрен, юнәлешләрен күрсәтү, шуларга бәйле рәвештә күренекле язучыбызның үсү юлларын дөрес билгелү кирәклегенә басым ясала. «Сүз башы»нын төп кимчелеге итеп, Г. Тукайның урта гасырчылык белән көрәшүче дип билгеләүне күрсәтә. Н. Исәнбәт керешнең уңай *якларына* тукталып, шагыйрьнең тәнкыйть турындагы мәкаләләрендәге мөһим фикерләрне туплап тәртипкә салынуын уңай күренеш буларак бәяли, алга таба шагыйрьнең тәнкыйтькә

карашын бер системага салу мөһим гыйльми эш дип белдерә. Галим басманың төзелү системасында үз бәясен бирә, андагы шартлы бүленешләрнең китапның эчтәлегенә берникадәр хилафлык китерә дип нәтиҗә ясый. Академик басманың икенче томында хатлар һәм истәлекләрне китапның башлам өлешендә урнаштыру белән ул ризасызлык белдерә. Биредә хатларның, истәлекләрнең соңгы бүлектә бирелергә тиешлеген искәртә. Хезмәтнең кереш өлешендә Г. Тукайның сатирик әсәрләре хакында сүз булса да, китапта аларның башка бүлекләрдә сибелеп бирелүе, шул рәвешле басманың эзлеклелегенә зарар китерүенә дә игътибар итә. Мондый тәртипнең дөрес түгеллеген, жанрларның чуалуын, әдип иҗатын аңларга комачаулавын тәнкыйтьләп чыга. Автор раславынча, әлеге томнарда Г. Тукайның сатирик һәм публицистик әсәрләре дә тупланып бетмәгән. Иң җитди хаталарның берсе итеп, Н. Исәнбәт Г. Тукай тарафыннан язылмаган аерым әсәрләрнең язучыныкы итеп күрсәтүне саный. Шундый хаталарның бер күренеше итеп, бу томда «Кәфештатыюш» имзасы белән алынган «Казаннан Думага телеграмма», «Хәйран булып калдык», «Татар мәҗлесе» мәкаләләрен аерып чыгара. Әлеге язмаларның Г. Тукай стиленә якын да килмәвен, «Кәфештатыюш» имзасының Тукай вафатыннан соң «Ялт-йолт»та күренеп китүен искәртә. Шулай итеп, Н. Исәнбәт «Кәфештатыюш» имзалы текстларны томга кертүгә каршы чыга, чөнки Тукай бу вакытларда инде каты авыру хәлдә Клячкин шифаханәсендә ята һәм, әйтик, һич тә үзе катнашмаган җыелышның отчетын – «Татар мәҗлесе» исемле мәкаләне яза алмый [4: 100]. Шул уңайдан, ул язучы әсәрләрен табу, псевдонимнарны ачу өстендә гыйльми тикшеренүләрнең кирәклеген ассызыклый. Басмада шигырьләр шактый бозып бирелгән, сүзләр алмаштырыла, яисә төшереп калдырыла, тыныш билгеләрен дөрес куймау күзәтелә. Галим фикеренчә, төзүчеләр гарәп-фарсы алынмаларын ялгыш язалар, мәгънәләрен дөрес бирмиләр. 1960 еллар ахырында Н. Исәнбәт Г. Тукайның тугыз шигырен «Казан утлары» журналында тәфсилле аңлатмалар белән бастырып чыгара. Юкка гына ул аларны үзенең мәкаләләрендә «әлегәчә игълан ителмәгән», «моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән» дип атамый, чыннан да, аларның җидесе Г. Тукай томлыкларында урын алмаган була. Мәсәлән, «шагыйрьнең соңгы академик басмаларында «Бичура» псевдонимы Тукайныкы итеп алынган; шушы псевдоним белән басылган шигырь-мәкаләләр Тукайныкы итеп басылганнар. Шулай булгач, бу «Авыл җырлары» да аның әсәрләре рәтендә басылырга тиеш. Моңарчы Тукай томнарында 5 көлтә «Авыл җырлары» билгеле. Монысы 6 көлтә була», – дип яза мәкалә авторы [2: 124]. Академик басманың беренче томында күп кенә ялгышлар таба һәм Г. Тукай шигырьләрен шагыйрь язганча дөрес иеп бастырып чыгарырга кирәк дип белдерә. Н. Исәнбәт белән якыннан аралашып, киңәшләшеп яшәгән Рашат Гайнанов икенче дүрттомлыкны һәм биштомлыкларны әзерләгәндә боларны җентекләп өйрә һәм томлыкларга урнаштыра [4]. Г. Тукайның академик басмаларына мөнәсәбәтле уй-фикерләрен Н. Исәнбәт 1969 елда «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре» мәкаләсендә дә язып чыга. Биредә ул гарәп-фарсы сүзләрен татар орфографиясенә көчләп буйсындыру нәтиҗәсендә Г. Тукай әсәрләренең ритмик яктан бозып бастырылуына басым ясый. Шулай ук, мәкалә авторы игътибарыннан академик басмаларда бирелгән белешмәләрне яңадан гыйльми яктан җентекләп эшләү кирәклеген белдерә. Мәкаләдә Тукайның «Кәраван» дин исемләнгән

чәй компаниясен рекламалап язган игълан-шигырьнең 1907 елларда бик ашыгыч рәвештә язылуы һәм шигырьгә Г. Тукайнын имзасы куелмавы билгеләнә. «Күнел җимешләре» (1911) җыентыгында басылган берничә өземтә юлларга гына карап әлеге игълан-шигырьнең Тукайныкы булуы фаразланса да, җыентыкта урын алган әсәрнең аннан нык ук аерымлануын белдерә. Н. Исәнбәт раславынча, Г. Тукай бу игълан-шигыреннән «баш тарткач», берничә юлын алып, сонрак «Иртә» дигән исем астында икенче бер әсәр бастыра. Шушы уңайдан Н. Исәнбәт Г. Тукай басмасының икенче томында (1948) урын алган искәрмәгә туктала. Биредә ул «Иртә» «Күңел җимешләре» исемле җыентыкта басылган һәм рус телендәге «Утро» исемле шигырьдән файдаланылган дигән юлларга каршы чыга, әлеге фикернең дәлилсез булуын, темасы, формасы, мотивлары, сюжет-композиция ягыннан аларның рус шигыренә туры килмәвен искәртә. Бу әсәр «Каравай» дип исемләнгән чәй компаниясенә игълан-рекламадан камилләштерелгән дигән фикерне алга сорә. Н. Исәнбәт фикеренчә, восток-мәшрикъ сүзенең очравына нигезләнеп кенә аны рус телендәге «Утро» шигыреннән файдаланып язылган дип күрсәтүне зур хата дип саный һәм файдалану булган очракта исә, төзүчеләр моны исбатларга тиешләр иде. «Тукайдагы “Иртә” шигырендә 16 юл. Тукай аннан файдаланып язган дип китерелгән бу русча шигырьдә дә 16 юл. Шулай булгач, бу китерелгән 16 юллык русча текст үзенең бер генә сүзе белән булса да Тукайның аннан кичек “файдаланган” булуын исбат итәргә тиеш иде. Ләкин ичмасам бер генә шуңа мисал сүз табылса икән. Хәер, бер сүз бар икән барын: ул да русчадагы “восток”, Тукайда “мәшрикъ ягы” (көнчыгыш) дигән сүз очравы. Шул бер сүз аның русча шгырьдән “файдаланып язылган, булуына дәлил була аламы? Андый “восток” сүзе кергән шигырьләр табылачак бит. Татарда да “шәрык”, “көнчыгыш” кебек сүзләр кергән шигырьләр бер Тукайда гына түгел. Аннары тагын Тукай файдаланган шигырьнең русчасы шушы дип китерелгән әсәрнең авторы күрсәтелмәсә дә, ул Пушкин әсәре бит әле Анысы бик яхшы. Тик шунысы гына бераз сәер: ул Тукайга каравай чәенә игълан язу өчен дә шулай Пушкин томнарыннан актарып, илһам һәм материалны аннан эзләргә кирәк булды микәнни?» [2: 125]. Шул ук мәкаләсендә Исәнбәт үзе тапкан «Тәүлек» шигыренә гаять тулы һәм кызыклы аңлатма бирә. Шулай итеп, Н. Исәнбәт Г. Тукай басмаларына мөнәсәбәтле рәвештә төп текст, аларны урнаштыру принцибы, тәкъдим итү кебек мөһим текстологик мәсьәләләрне күтәрә. Әдәби мираска мөнәсәбәтле әсәрләрне укучыга җиткергәндә аңлатма һәм искәрмәләрне төгәл бирү кирәклеген белдерә.

Н. Исәнбәтнең Тукайга багышланган «Тукайның яңадан Казанга сәфәре», «Тукай Казанда» фельетоннары, Ә. Фәйзи белән берлектә язылган «Тукай-Кырлайда яңалык» очеркларында шагыйрьнең милләт, татар халкының киләчәге өчен җан атуын билгели.

ӘДӘБИЯТ


1. Исәнбәт Н. Тукай прозасы // Совет әдәбияты. – 1944. – 1949. – № 7. – Б. 102–107.

2. Исәнбәт Н. Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре // Казан утлары . – 1964. – № 4. – Б. 124 –127.

3. Исәнбәт Н. Тукайның соңгы академик басмасы турында // Совет әдәбияты. – 1945. – № 5. – Б. 59 –73.

4. Рәмиев З. Тукай һәм замандаш әдипләр: «Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлекбелешмәсенә материаллар. – Казан: ТаРИХ, 2004. – 111 б.

УДК 398

# НАУЧНЫЕ АСПЕКТЫ ИЗУЧЕНИЯ ВЗАИМОВЛИЯНИЙ ТУКАЯ И ТАТАРСКОГО НАРОДНОГО ТВОРЧЕСТВА

***Л.Х. Мухаметзянова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье поднимается вопрос о возможности изучения взаимовлияния Тукая и татарского фольклора в нескольких аспектах. Автор дает свою оценку литературным переложениям народных сюжетов, использованных Г. Тукаем в его произведениях; наряду с именами таких творческих деятелей XX в., как Г. Ибрагимов, Г. Рахим, Х. Бадиги, Ф. Амирхан, Ф. Туйкин и др., критические заметки поэта о народной литературе оценивается автором как теоретическое осмысление и изучение жанров народного творчества на начальном этапе национальной фольклористики; по последним экспедиционным материалам автор выявляет образ Тукая в татарских фольклорных произведениях. В статье определяется большой потенциал для дальнейшего изучения взаимовлияний Тукая и национального фольклора во всех рассмотренных научных аспектах.
**Ключевые слова:** Тукай, татарское народное творчество, фольклористика, жанры, сюжет, фольклорная память.

The article raises the question of the possibility of studying the mutual influence of Tukay and Tatar folklore in several aspects. The author gives his assessment of the literary transcriptions of folk subjects used by G. Tukai in his works; along with the names of such creative figures of the 20th century as G. Ibragimov, G. Rakhim, H. Badigi, F. Amirkhan, F. Tuikin and others, the poet's critical notes on folk literature are assessed by the author as a theoretical understanding and study of the genres of folk art at the initial stage of national folklore; according to the latest expedition materials, the author reveals the image of Tukay in Tatar folklore works. The article identifies a great potential for further study of the mutual influences of Tukay and national folklore in all the scientific aspects considered.
**Key words:** Tukai, Tatar folk art, folklore studies, genres, plot, folklore memory.

# ТУКАЙНЫҢ ХАЛЫК ИҖАТЫ БЕЛӘН БАГЛАНЫШЛАРЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ ФӘННИ АСПЕКТЛАРЫ

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның милли фольклор белән бәйләнеше – җитди тикшеренү таләп итә торган масштаблы өлкә. Халык иҗатына, аның төрле жанрларына Тукайның мөнәсәбәтен берничә аспектта карарга мөмкин. Беренчесе – Тукайның халык эпосын, ягъни әкият, риваять, дастан кебек әсәрләрне әдәби эшкәртеп, үз иҗатында чагылдыруы, икенчесе исә – аларга аңлатмасы, ягъни фәнни бәяләмәсе. Әлеге аспектлардан тыш халыкның үзеннән язып алынган фольклор үрнәкләренә Тукай образы килеп керү – фольклористика өчен шулай ук мөһим элемент һәм аны «фольклор һәм Тукай» темасында өченче аспект итеп билгеләү дөрес булыр.

Беренче аспектка мөнәсәбәттә татар фольклористикасында да, әдәбият тарихында да тикшеренүләр шактый күп булды. Тикшеренүебез югарыда телгә алынган икенче һәм өченче аспектларга, ягъни Тукайның сүз сәнгате буларак рухи мирасыбыз турындагы фикерләренә аерым игътибар юнәлтү һәм бүгенге көн халык иҗатында Тукай образының чагылышын өлешчә барлау, күтәрелгән мәсьәләләрнең мөһимлеген ассызыклау, Тукайны бу юнәлештә ачу потенциалының зурлыгын ачыклау максатларын күздә тота.

XX йөз башында ук халык иҗатының асыл сыйфатларына игътибар юнәлткән, милли фольклористикабызның башлангыч этабында ук халык иҗаты әсәрләренә күзәтү ясап, әлеге күзәтүләрен махсус хезмәт итеп теркәгән Тукайның фольклор фәнендә һичшиксез аерым урыны бар. Татар халык иҗаты үрнәкләренә зур әһәмият биреп, аларны үз иҗатында тирәнтен һәм гаять белеп файдаланган бөек шагыйрьнең исеме милли фольклорыбыз тарихын өйрәнүчеләр рәтендә иң тәүге баскычларның берсендә тора дисәк, хата булмас.

Бүгенге көндә дастан, әкият, риваять, сөйләк, мәкаль һәм әйтемнәр кебек аерым жанрлар буларак карала торган эпик фольклор әсәрләрен теге я бу термин белән атау, аларны фәнни классификацияләү үз чорында, ягъни шушы әсәрләр халык арасында актив таралган этапта булмаган һәм була да алмаган. Татар фольклорының үзенең дә илленче еллардан соң гына татар халык иҗаты термины белән аталып йөртелә башлавы билгеле [4: 6]. Бүгенге көндә эпик фольклор төшенчәсе белән мәгълүм әсәрләрнең татар дөньясында элек-электән бик әһәмиятле урын билгеләве – мәгълүм факт, әмма татар халык фольклорын жанрларга бүлү һәм өйрәнү тарихын, чыннан да, озын һәм тирән дип билгеләп булмый. XX йөз башына халык иҗатын теоретик өйрәнүдә Ф. Туйкин, Х. Бәдигый, Г. Рәхим кебек белгечләрдән тыш тыш бөек Тукайның да бу эштә актив катнашуы чор өчен табигый күренеш буларак кабул ителә. Үз милләтенә тирән мәхәббәт белән сугарылган шәхеснең халык иҗатына карата үз карашлары, әлбәттә, булган һәм алар шактый кызыклы.

XX йөз башында татар әдәбияты белемендә фольклор мәгънәсендә халык әдәбияты дигән сүз йөргән. Тукай бу терминга: «Бу нәүгы әдәбият – әле дөньяда язу сәнгате булмаган чактук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан – атага, атадан – балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбиятдыр» – дигән билгеләмә биргән [3: 165]. Шунысына игътибар итәргә кирәк: фольклорга Тукай биргән әлеге билгеләмә, гасырдан артык чор узуга карамастан, «фольклор» сүзенә билгеләмә биргәндә әле дә актуаль һәм бу сүзне аңлату өчен бүгенге көндә дә Тукай билгеләмәсе нигез итеп алына. Моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт: Тукай билгеләмәсенә фольклорга хас булган төп үзенчәлек һәм билгеләрнең иң төп дип саналганнары сыйган. Фольклор әсәрләре дип санала торган ядкарьләрнең асыл сыйфатлары – телдән иҗат ителү һәм телдән-телгә күчеп яшәү; коллектив-күмәк иҗатны тәшкил итүе; вариантлылыгы; синкретик иҗат; традиционлык һәм дәвамлылык-күчүчәнлек; милли-этник характерда булуы. Татар халык иҗатының үзенчәлекләре турында уйланган шәхес буларак, Тукай үзенең 1910 елда Казанның Шәрекъ клубында укыган һәм «Халык әдәбияты» дип аталган лекциясендә татар халык иҗаты иңли торган сыйфатларны барлаган, аларга этрафлы аңлатма бирүгә ирешкән. Соңыннан аның бу чыгышы күләмле мәкалә булып басылып чыккан булуын беләбез [3].

Тукай эшчәнлек иткән XX йөз башы – татарларның үз даирәсендә халык эпосына игътибар бермә-бер арткан чор. Нәкъ менә шушы чорда дастаннарга аерым әһәмият бирелү бу жанр әсәрләренең чынбарлык вакыйгаларына, тарихи шәхесләргә багышланган булуларыннан килә. Илдәге вәзгыять эпик фольклорның тарихи һәм романтик вакыйгаларга багышланган төрләрен – героик һәм романик дастаннарны алгы планга чыгара. «Каһарман Катил», «Түләк китабы», «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», «Таһир – Зөһрә», «Ләйлә – Мәҗнүн», «Йосыф китабы» кебек элек кульязмалардан укылган

әсәрләрне Казан, Оренбург, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге татар матбагачылары кат-кат китап итеп бастырып чыгара. Аларга халыкның ихтыяҗы зур булуны басылып чыккан китапларның тиражларының күплеге үк раслый.

Г. Тукай – бу күренешкә, ягъни татар дөньясында эпос-дастаннарның күпләп басылуына һәм таралуына беренчеләрдән булып мөнәсәбәт белдерүче. Татар кульъязма һәм басма китаплары арасында эпик фольклор үрнәкләренең күплегенә бәя биреп, шагыйрь болай ди: «Бу кем китабы? Татар китабы. Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер»[3: 177]. Дөрес, XX йөз башында да әле Г. Тукай да, дастаннарга игътибар юнәлткән кайбер башка авторлар, әйтик, М. Акчурина [1], Г. Гобәйдуллин [2] һ.б. да кульъязмасы кулдан кулга күчеп укылган, XIX йөз ахырыннан басылып та чыккан әсәрләребезне эпик фольклор жанрында караудан ерак тора. Бу – татар филологиясендә кайбер терминнарның әле ныгып урнашмаган булуыннан килә торган күренеш. Гомумән татар фольклористикасында жанр атамаларына ачык, төгәл билгеләмә бирү, жанр чикләрен билгеләү кебек проблемалар Тукай чорында гына түгел, әле бүгенге көндә дә бар, бу – халык иҗаты әсәрләренең синкретиклыгы белән аңлатыла торган үзенчәлекле күренеш.

Көнчыгыштан кергән сюжетлы эпос-дастаннарга Тукайның мөнәсәбәтенә килсәк, шагыйрь аларны татарга аңлаешлы телдә булмалары җәһәтеннән телгә алган. «Таһир – Зөһрә», «Йосыф китабы» мисалындагы төрле вариантта таралыш алган дастаннар турында Тукайның: «Алар кем телендә? Алла белә, җен телендә» [3: 178] дип дәвам итүендә хаклык бар. Чыннан да, XX йөз башында да әле дастаннарыбызның теле гарәп-фарсы алынмалары белән генә түгел, кыргыз, казакъ сүзләре белән дә нык чуарланган, гади халык өчен аңлауда зур кыенлыклар тудыра торган тел булуы мәгълүм. Бу, әлбәттә, дастан жанрының элитар жанр булуыннан, аның укымышлы катламга нисбәтле таралуы белән бәйле күренеш. Әмма әдәби тел формалашу чорында Тукайның эпос-дастаннарыбыз теленә шундый бәя бирүен аларның тарихилык һәм тел ягыннан беренче кат фәнни бәяләнүе дип кабул итәргә кирәк. Тукайның дастаннар теленә биргән бәяләмәсе бүгенге көндә дә бик актуаль. Әйтик, дастан текстларын рус теленә тәрҗемә итә мәсьәләсендә аларның теленең шушы дәрәҗәдә чуарлыгы бик зур катлаулылыклар китереп чыгара. Бөек Тукай бу мәсьәләгә йөз башында ук игътибар юнәлткән һәм аңа халык теленә нигезләнгән әдәби тел яссылыгында ачык һәм төгәл бәя биргән.

Шул рәвешчә, Тукай фольклор мәсьәләләренә XX йөз башында ук игътибар юнәлткән, беренчеләрдән булып бу хакта язып чыккан һәм аның бәяләмәсе проблеманы төгәл күрү һәм көн кадагына кую характерында булуы белән бик әһәмиятле. XX гасыр башы фольклористикасы татар халык иҗаты турында уйланулар һәм күзәтүләр рәвешендә аерым хезмәтләр язган әдипләр Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һәм фольклорның төрле жанрына мөнәсәбәтле текстларны туплап бастырып чыгарган Г. Рәхим, Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Г. Рәшиди кебек фольклорчылар эшчәнлегеннән гыйбарәт булса, шушы ук чорда, ягъни татар фольклор фәненең башлангычында шагыйрь Г. Тукайның аерым урын биләгәнлеге бәхәссез.

XX йөз башында халык авыз иҗаты әсәрләрен халыктан җыю, аларны матбугатта бастырып чыгару эше киң колач белән барган. 1907–1913 еллар-

да тугыз дистәгә якын фольклор җыентыгы басылып чыгу шул хакта сөйли [4: 20]. Тукай яшәгән чорга хас әлеге вәзгыять һәм шагыйрьнең халык әсәрләренә җитди игътибары Тукайның шәхси иҗатына да турыдан-туры йогынты ясаган, әдипнең балаларга атап язылган күп әсәрләренең нигезендә фольклор ятканлыгы шул хакта искәртә.

Соңгырак чорда Тукайны укып үскән, бу шәхеснең үзен күреп белгән кешеләр тарафыннан сөйләнгән тарихи риваятьләрдә, сөйләк, истәлекләрдә шагыйрь образы гәүдәләнү – фольклористикада аерым әһәмият таләп итә торган юнәлеш. Халыкның эпик иҗатында тарихи затларга киң урын бирелә, соңгырак чор фольклорында шундый реаль шәхесләр рәтендә күренекле шагыйрьнең пәйда булуы – заман фольклорына хас күренеш.

Әйтик, 2013 елда Мамадыш районы Үсәли (Өчиле) авылында Фазылов Мансур Фазыл улыннан (1939 елгы, 74 яшь, һөнәре белән инженер-механик, хәзер пенсиядә) комплекслы фәнни экспедиция вакытында язып алынган тарихи-топонимик риваятьтә Тукай образы чагылыш тапкан. *«Монда Габделхәй хәзрәт булган бик атаклы. Тумышы белән Түбән Ушмыныкы булган бу хәзрәт. Аның атасы – Түбән Ушмының Мөхәммәдмәгъсүм хәзрәт. Бу Габделхәй хәзрәт Катмыш кызы Мәрьямгә өйләнеп, Үсәли мәдрәсәсендә җәдитчә укыткан. Алар Габдулла Тукайны белгәннәр. Өчилене, Өчиле урманнарын Тукай бик үз иткән. Килә торган булган монда. Мәрьям абыстай үзе сөйли торан ые Тукай белән аралашуларын: "Бик ябык ые инде Тукай", – ди торган ые».* Үсәли авылына багышланган риваятьнең өчтән бер өлешен диярлек Тукай хакындагы мәгълүмат биләү – игътибарга лаек факт.

Г. Тукай шәхесенең хәзерге фольклорда чагылуына мисалны соңгы еллардагы башка экспедиция материалларыннан да табарга мөмкин. Татарстанның Азнакай, Мөслим районнары авылларында өлкән яшьтәге берничә информант үзләренең әби-бабаларының яисә таныш элгәрләренең Тукайны күреп белүләре, ат арбасында Җаеккка барышлый шәкерләрнең япь-яшь Габдулланы күреп сөйләшүләре турында, аның кымыз эчүе, хәтта шигырь укуы хакында күп кызыклы хикәятләр сөйләделәр (2018, 2019). Самара (2014), Чиләбе (2016) өлкәләренә узган комплекслы фәнни экспедицияләрдә дә бөек шәхесебез турында *«Тукайны минем бабам (яисә бабамның бабасы) үзе күреп белгән, алар фәләненче елда фәлән урында күрешкән булганнар»* характерындагы сөйләкләрне информантлар авызыннан еш ишетергә туры килде. Болар, әлбәттә, фольклор контаминациясе белән керешкән халык истәлекләре. Әмма әлеге материалларда хакыйкать бер: милли фольклорның асылына төшенеп, рухи мирасыбыз ядкарьләре нигезендә гаҗәеп әсәрләр калдырган Тукай үзе дә халык хәтеренә тирән уелган.

Тукайның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге, аның халык иҗатына мөнәсәбәте һәм киресенчә, фольклорның бөек шәхесебезгә мөнәсәбәте – әлеге юнәлешләрнең барысын бер түбә астына җыйнап, махсус фәнни эзләнү алып барганда һәм монографик хезмәт язганда бик кызыклы булыр иде, чөнки Тукайның үзенең халыкка биргән бәясе югары булган кебек, халык вәкилләре дә әлеге шәхескә зур ихтирам белән карыйлар, бу тенденция бүгенге көндә дә бик актуаль. Заман фольклоры мисалында моны тоемлау кыен түгел. Тукайның халык иҗатына якынлыгы аның әсәрләрендә чагылыш табу белән бер рәттән әдипнең XX йөз башы фольклористика тарихында үз эзен калдыруына да йогынты ясаган, шул ук вакытта мәшһүр шагыйрьнең исеме бүгенге көндә дә халык әсәрләрендә еш телгә алыну

факты фольклорыбызның милли характеры хакында сөйли һәм рухи мирасыбызны мәшһүр шәхесләребез хакындагы мәгълүматларга баета.

ӘДӘБИЯТ

1. Акчурина М. Иске әдәбиятымыз // Шура. – 1911. – № 16. – Б. 508–510.
2. Гобәйдуллин Г. Сәед Баттал Гази хикәясе турысында // Шура. – 1911. – № 22. – Б. 682–685.
3. Тукай Г. Халык әдәбияты. – Казан: «Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов матбагасы, 1910. – 22 б.
4. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.

УДК (093)821.512.145

## МАТЕРИАЛЫ О ТУКАЕ В ФОНДЕ Б. УРМАНЧЕ

***З.Г. Мухаметшин***
*Государственный музей изобразительных искусств РТ (Казань)*

В статье, на материале рукописных записей и печатных материалов известного татарского художника и скульптора Б. Урманче, анализируются дополнительные источники, освещающих личность и творчество Тукая. Эти материалы, послужившие основой для создания образа Тукая в изобразительном искусстве, раскрывают внутреннее состояние поэта, мировозрение и взгляды на мир и отвечают на некоторые спорные вопросы тукаеведения. В статье также упоминаются художественные способности поэта.
**Ключевые слова:** Б. Урманче, Г. Тукай, изобразительное искусство, Тухфатуллины, медресе «Мухаммадия».

In the article, based on the material of handwritten notes and printed materials of the famous Tatar artist and sculptor B. Urmanche, additional sources covering the personality and work of Tukai are analyzed. These materials, which served as the basis for creating the image of Tukai in the visual arts, reveal the inner state of the poet, his worldview and views on the world, and answer some controversial questions of Tukai studies. The article also mentions the poet's artistic abilities.
**Key words:** B. Urmanche, G. Tukai, Visual art, Tukhvatullins, madrasah «Muhammadiyah».

## БАКИ УРМАНЧЕ ФОНДЫНДА ТУКАЙ ШӘХЕСЕ

***З.Г. Мөхәммәтшин***
*Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее (Казан)*

Б. Урманче – XX гасырда булып узган тарихи вакыйларны үз язмышы аша уздырган, шул гасырда күренекле эз калдырган зыялы шәхесләр белән якыннан аралашкан яисә күреп белгән, күп вакыйгаларның шаһит булган һәм хәтер сандыгында саклаган Бөек Шәхес.

XX гасыр – татар халкының милли аңы уяну, шәрык мәдәнияты инде искелек итеп кабул ителеп, яшь буын татар зыялыларының Европа һәм рус мәдәнияте, әдәбиятына тартыла башлаган бер дәвер. 1907 елның көз аенда булачак бөек рәссам Казанга шул заманның күренекле мәдрәсәләрнең берсе «Мөхәммәдия»гә укырга килә, шул елда ук елның октябрь аенда Уральскидан инде шактый танылган шагыйрь Г. Тукай Казанга кайта. Россиядә кара реакция башлануга карамастан, Казанда милли мәгарифнең юл ярып барган һәм татар матбугатының күтәрелеш алган, милли әдәбият, театр,

җыр сәнгатенең беренче адымнар ясаган чоры бу. Б. Урманче истәлекләре раслаганча, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә иҗатка тартылу, иҗат белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырылган: мәдрәсәдә иҗат түгәрәкләре эшләгән, дивари газеталар чыгарылган. Кызганыч, Урманче истәлекләре арасында 1907–1910 еллар аралыгында Тукайны күрүе, шагыйрьнең мәдрәсәдә булуы хакында мәгълүмат очрамады. Дөрес, соңрак, ягъни Тукай «Амур» кунакханәсенә күчеп яши башлагач, Ф. Әмирхан һәм Г. Тукайны күрер өчен шәкертләр белән әлеге кунакханәнең чәйханәсенә баруларын «Фатих Әмирхан белән очрашуларым» язмасында искә алып китә [1: 384–388]. Якыннан аралашуы билгесез. Шуңа карамастан, шагыйрь татарның беренче профессиональ белем алган рәссамы, рәсем сәнгатендә дә беренчеләрдән булып Тукайны сурәтләүче, шагыйрь китапларына тәүге график рәсем ясаучыларның да берсе. Урманченең шәхси архивында бу вакыйганы ачарлык бер кызыклы язма бар. Шунысы ачык: Тукайның кайбер шигырь җыентыклары төрле иллюстрацияләр белән басылган. Тәкъдим ителәчәк язма – шул вакыйганы ачкан һәм авторлыкны билгеләгәндә мөһим роль уйнаган чыганак. Рәссам: «Тукайның 19 елда басылган мәҗмугасында Арсланов рәсеме диеп күрсәтелгән иде исә, Арсланов эше түгел. Алар “Җуаныч” 1909 елда ук басылып чыккан иде, ташбасма белән. Бу эшләрнең кем кулыннан булуын аңларга теләсәк дә ирешмәс. Ш. Әхмәров Харитонов матбагасында эшләүче бер сурәтче бар иде, таштасмада шул эшләде, диде», – дип, Тукай иҗатын өйрәнүчеләрне, беренчедән, авторлык мәсьәләсен ачыклауда сак булырга өнди, икенчедән, киләчәк тикшеренүчеләр алдында яңа бурыч та өсти [2]. Хәер, Тукай замандашы Урманче язмалары арасында Тукай замандашлары шактый һәм алар төрле яктан тәкъдим ителәләр. Мәсәлән, Тукайны өйрәнүчеләр арасында Мотыйгулла һәм Камил Төхфәтуллиннарның Тукай шәхесен формалаштыруда роле зур булуы, бер яктан, сорау калдырырга тиеш түгел сымак. Әмма шәхси архивта бу фактны шик астына алган чыганак – күренекле әдәбият галиме һәм язучы Ибраһим Нуруллинга атап, белгечлеге буенча табибә, Рәмзия Кәлим (Кәлимулла) кызы Шәмсетдинова тарафыннан 1987 елның февралендә язылган күләмле хаты да саклана. Наҗия Әхмәрованың 1982 елның 31 декабрендә язган хатында Тукайның 1912 елгы җәй көнендә Габдерахман Әхмәров йортында кунак булу вакыйгасы сурәтләнгән [4]. Бу истәлек Тукай хакында тупланган «Тукай ядкәрләре» китабына да кертелгән [5: 728–729]. Ләкин ул язма тулы түгел. Бу язма «Казан утлары» журналының 1985 елгы 3 нче санынан кыскартылып, шактый редакцияләнеп дөнья күргән. Китапны төзүчеләр текстны шуннан алуларын искәртәләр. Хат бүгенгесе көндә Б. Урманченең шәхси архивында саклана. Язма автор Габдерахман Әхмәров дачасына Тукайның ничек килүе, өйдә кайда утыруы, ничек каршылауларын барысы да искә алынган. Язмада китерелгән фактларда игътибарга алырлык фикерләр бар. Мәсәлән, Тукайның Троицкка килгәндә хәлен аңларлык түбәндәге фактны китерә: «Тукай безгә рәхмәт әйтте, мактады. Без су буена төшеп каекны чәчәкләр белән гирляндалап бизәдек. Өйгә менеп Габдулла абыйны су буена каекка йөрергә чакырдык. Тукай елмаеп рәхмәт әйтте: «Мин, кызлар, таулардан менеп төшәргә хәлем юк шул», – диде. Тукай рәсеме хакындагы бәхәсле мәсьәләләр бүген дә кузгалып тора. Хатта әлеге мәсьәләгә дә җавап бирелгән. Журналда һәм китапта басылган текст бу урын нык кына үзгәртелгән. Шул сәбәпле Тукай фикере ачык яңгырасын өчен, өзекне тулысы белән

китерү, үзгәрмичә тәкъдим итәм. Хатта вакыйга түбәндәгечә сурәтләнә: «Сүз арасында Тукайның рәсемнәре тугрысында сөйләшкән арада бездән зурырак булган Сара апа (аңа 14 яшь иде) гаҗәпләнеп Тукайдан сорады: "Сез үзегезнең рәсемегезгә бер дә охшамыйсыз", – дигәч, әти аның сүзенә кушылып китте. Тукайның шигырь китапларында булган рәсеме берничә әүвәл симез генә яшь егет, башында кара түбәтәй, бәйләнгән чуар галстук, фәс төшкән. Шул рәсем хакында сүз чыккач, Тукай болай диде: "Ул рәсемдә мин түгел. Халыкның минем шигырьләрмә мәхәббәт булсын өчен, минем авыру күрсәтүне белдергән рәсемнәрдән ваз кичеп, китап басучылар башка бер кешенең рәсемен Габдулла Тукай рәсеме диеп халыкка таратканнар", – диде». Хат авторы наширлар тарафыннан тәкъдим ителгән сурәтнең Тукай булмавын раслап фикерен болай дәвам итә: «Тукайның безгә килгәндәге тышкы күренеше «Клячкин» шифаханәсендә ятканда ике кулы башның аркасына куеп ятканда төшкән рәсемгә бик охшаган иде», – дип язган [6]. Фикере, язган сүзләре бәхәсле һәм булган бәхәсләрне кабат яңартырлык. Шуны да искә алырга кирәктер: хат авторына бу елларда 8–10 яшь чамасы, күргән кешеләрне, сурәтләрен хәтердә калдырырлык яшьтә. Димәк, Б. Урманченең шәхси архивында сакланган хатта урын алган әлеге фикер киләчәктә Тукайны өйрәнүче, Тукай фәнен дәвам итүчеләргә азык булачак.

Б. Урманченың кульязмалары арасында «Тукай һәм сынлы сәнгать» исемле мәкаләнең каралама хәлдә сакланган, төрле кәгазь битләренә язып куйган фикерләре дә кызыклы. Дөрес, бу язма мәкалә хәленә китерелеп Флора ханым Әхмәтова-Урманче төзеп нәшер иткән «Баки Урманче и татарская культура» исемле китапка кертелгән [1: 381–384)].

Мәгълүм ки, Тукай Казанда яшәгәндә, 1908–1909 елларда бастырылган «Яшен» журналына корикатуралар өчен идеяләр бирүче, кайбер очраклар да үзе дә ясаучы, 1910–1918 елларда чыккан «Ялт-йолт» журналында да әдәби әсәрләре белән генә түгел, корикатуралар ясау буенча да актив катнаша. Ягъни татарда профессиональ рәсем сәнгате булмаса да, сатирик характерда, шактый дәрәҗәдә гади ясалган рәсемнәрне татар укучы күргән. Тукайлар буыны башлаган сатирик сурәтләр татар сынлы сәнгатен башлангычы дип әйтерлек. Тукай – иҗатта шагыйрь-публицист кына түгел, рәссамлык сәләтенә ия Шәхес. Урманче бер кульязмасында шагыйрьнең рәссамлык сәләтен болаерак тасвирлый: «Тукайның сынлы сәнгать белән кысыксынуы мәгълүм. Әгәр ул рәсем дәресләре бирелә торган мәктәптә укыган булса, ихтимал, Бодлер, Лермонтов, Шевченко кебек үзе дә сурәт төшерә белә торган һәм безгә рәсемнәр калдыр иде», – дип, аның киңкырлы иҗади талантына игътибарны юнәлтә [9]. Дөньяда аңа мисаллар җитәрлек. Б. Урманче мәкаләсендә игътибар итәрлек бер фикер, ул да булса, Тукайның шигъриятенең халыкчанлыгы һәм сынлы сәнгать өчен чыганак ролен үтәве. Фикергә өстәп Урманченең китаптаи басылган мәкаләсеннән өзек тәкъдим итү урынлы булыр. Ул: «Тукай иҗатының төп табигате – сурәтчелек дип әйтергә мөмкин. «Шүрәле», «Таз», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» һәм башка әсәрләрен алыгыз. Никадәр сурәтләр күз алдына килә! Сурәт ясау өчен никадәр мул һәм кызыклы материаллар бирә бу әсәрләр!

Аның абстракт-философик темага язылган «Чын вә ялган» шигырендә дә чын белән ялган күренеп торган кыяфәтләре белән күз алдына киләләр. Шул сәбәптән булса кирәк, безнең халыкның әле сабый хәлендә булган сынлы сәнгатендә иң күп урын алган әдип Тукайдыр. Тукайның

үзенең дә сынлы сәнгать белән җитди кызыксынуы һәм сынлы сәнгатьнең безнең мәдәниятыбызда гражданлык алу өчен чынлап хафалануы билгеле. Әгәр Тукай хәзерге заман шәраитендә тәрбия ителгән булса иде, ул сынлы сәнгать белән шөгыльләнгән булыр иде һәм, шөбһәсез, сурәт ясауда да зур маһирлык күрсәткән, дөньяга данлыклы әдипләрдән Новаи, Рабиндранат Тагор, Бодлер, Гоголь, Шевченко кебек үзенең сынлы сәнгать әсәрләрен дә калдырыр иде».

Мәкаләдән аңлашылганча, Урманче Мәскәүдә укыган елларында Тукай образына мөрәҗәгать итеп, аның беренче тапкыр портретын ясый [6]. Соңрак бу портретының югалуын да искә төшерә. Мәкаләдә бу хакта фикер күренмәсә дә, мәкалә язар өчен фикерләрен теркәп барган кәгазь битләренә язылган сүзләргә игътибар итмичә булмый. Язманың каралама вариантында (мәктәп дәфтәренә язылган) портрет турында: «1921 елда Мәскәүдә укыган заманда беренче портретын ясаган идем. Бу портрет югалды булса кирәк», – дип искә төшерә [7]. Икенче бер кульязмасында рәссам Тукай образы белән 1919 елдан ук кызыксына башлавын яза. Кульязмадан күренгәнчә, булачак рәссам шәкертлек елларында бер ике тапкыр күрүен ассызыклый. Ул бу хакта: «Юкса, шул бер-ике мәртәбә генә күргәндә Тукайга караш, аның кыяфәте белән кызыксыну үзенә хас рәвештә булыр иде. Шулай да булса 19 еллардан бирле минем Тукайның сыны һәм аның иҗатлары белән кызыксыну, анарга мөнәсәбәтем инде сынлы сәнгать эшчесе карашы булып әверелә. Татар шагыйрьләре арасында гына түгел, гомумән, шагыйрьләр арасында Тукай әсәрләре сынлы сәнгать өчен бетмәс-төгәнмәс сурәт материалы бирә» [8], – ди, һәм Тукай образы, иҗаты сынлы сәнгать өчен чыганак ролен үти алуына басым ясый. Кульязманың башы-ахыры юк, күрәсең, ул «Тукай һәм сынлы сәнгать» мәкаләсенең караламасы булгандыр, каралама хәлендәге язмадагы фикерләр чагылып китә. Б. Урманче сынлы сәнгатьтә Тукай образына, иҗатына профессиональ дәрәҗәдә мөрәҗәгать итүчеләрнең берсе, аны югары күтәрүчеләрнең беренчеседер, мөгаен. Мәкаләдән шул аңлашыла.

Б. Урманченең кульязма һәм нәшер ителгән язма материаллары арасында Тукайны шагыйрь генә түгел, рәссамлык сәләтенә ия шәхес булуы ассыклана. Шунысы кызык: Б. Урманче татар халыкының талантлы рәссамы дәрәҗәсенә ирешсә дә, үзе өчен генә шигырьләр язып, сәләтле шагыйрь икәнен дә раслый. Дөрес, аның шигырьләреннән Тукай стилен, шагыйрь алымнарын табу авырырак мәсьәлә. Шагыйрьнең тәэсире бик аз. Ул үзенең шигърият рухы белән күбрәк Дәрдемәнд, шәрыкның классик шагыйрьләренә тартыла, аларны кыйбла итеп ала. Ләкин шагыйрь кульязмалары арасында игътибар итәрлек бер язма бар. Рәссам Тукайның «Шүрәле» шигъри әсәренә таянып балалар өчен «Шүрәле» исеме белән бер кечкенә генә пьесасының (Урманче аны «тамаша» дип ала) планын төзи, образларга бүлә [10]. Ул кульязма мәктәп дәфтәренә һәм аерым кәгазьгә языла башлаган. Кызганыч, язарга дип планлаштырган язма шул хәлдә шәхси архивта калган.

Кыскасы, Б. Урманченең шәхси архивына күзәтү ясаганда, рәссамның Тукай образын сынлы сәнгатьтә сурәтләү ниятеннән шактый чыганаклар туплаган. Алар шагыйрьнең эчке психологик халәтен, дөньяга карашларын тасвирлауда мөһим роль уйнаганнар. Бу материаллар Тукай шәхесен ачуда өстәмә чыганак булу ягыннан да әһәмиятле. Б. Урманче гомере буенча шигъриятькә гашыйк, шигырьләр язган шәхес тә. Шуңа карамастан, Урманче

Тукай әсәрләрен сынлы сәнгатьтә мәңгеләштерүдә зур роль уйнаса да, язма чыганаклары арасында, аерым алганда, шигырьләрендә Тукайга мөрәҗәгать итүе юк дәрәҗәсендә. Шәхси архивта кульязма хәлендә сакланган шигъри әсәрләре шуны раслый.

ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәрова Н. Хат. Кульязмада. //Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
2. Әхмәрова Н. Шагыйрьне без дә күрдек // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 2 т.: Мәкаләләр, шигырьләр, төрлеләр / Төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миннуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 728–729.
3. Урманче Б. Фатих Әмирхан белән очрашуларым // Баки Урманче и татарская культура. – Казань: Фән, 2005. – Б. 384–388.
4. Урманче Б. Кульязма // Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
5. Урманче Б. Тукай һәм сынлы сәнгать // Баки Урманче и татарская культура. – Казань: Фән, 2005. – Б. 381–384.
6. Урманче Б. Тукай һәм сынлы сәнгать. Кульязма. //Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
7. Урманче Б. Кульязма // Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
8. Урманче Б. Кульязма // Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
9. Урманче Б. Шүрәле. Кульязма //Татарстан Республикасы Сынлы сәнгать музееның фәнни архивы. – 15 ф. – 1 тасв. – 14 э. б.
10. Шамсутдинова Р. Письмо. Машинопись. В Академию Наук ТАССР им. Ибраһимова Деректору, филологических наук, профессору И.З. Нуруллину // Научный архив Музей Изобразительного искусство Республики Татарстан. – Ф. 15. – Оп. 1. – Д. 14.

УДК 372.882

## ИЗУЧЕНИЕ СКАЗКИ-ПОЭМЫ Г. ТУКАЯ «ШУРАЛЕ» НА ЭЛЕКТРОННОЙ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ПЛАТФОРМЕ

***Г.Н. Мухарлямова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань),*
***Г.М. Фахретдинова***
*МБОУ «Гимназия № 20 имени Абдуллы Алиша» (Казань)*

В статье рассматриваются особенности изучения сказки-поэмы Г. Тукая «Шурале» на электронной образовательной платформе. Современные образовательные платформы, как требование времени, дают возможность более полного и глубокого усвоения учебного материала. Поставленные перед учащимися учебные цели при изучении поэмы Г. Тукая достигаются выполнением на платформе учебных и проверочных заданий разных уровней сложности, а также заданий творческой и исследовательской направленности.
**Ключевые слова:** Электронная образовательная платформа, Г. Тукай, сказка-поэма «Шүрәле», учебная цель, учебные задания, проверочные задания.

The article deals with the features of studying the fairy tale-poem of G. Tukai Shurale on an electronic educational platform. Modern educational platforms, as a requirement of the time, provide an opportunity for a more complete and deep assimilation of educational material. The educational goals set for students when studying the poem of G. Tukai are achieved by performing educational and test tasks of different levels of complexity, as well as creative and research-oriented tasks on the platform.
**Key words:** Electronic educational platform, Tukai, fairy tale-poem «Shurele», educational goal, educational tasks, test tasks.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ШҮРӘЛЕ» ПОЭМАСЫН ЗАМАНЧА ЭЛЕКТРОН БЕЛЕМ БИРҮ ПЛАТФОРМАСЫНДА ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Г.Н. Мөхәрләмова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ (Казан),*
***Г.М. Фахретдинова***
*Казан шәһәренең «Абдулла Алиш исемендәге 20 номерлы гимназия»се (Казан)*

Бүген электрон белем бирү платформаларында төрле фәннәрне укыту заман таләбе булып тора. Әлеге платформаларда белем алу материалны аңлау-үзләштерүдә укучыларга зур мөмкинлекләр ача. Билгеле булганча, онлайн уку-укыту дәрестә һәм дәрестән тыш вакытта укучыларның мәгълүмат киңлегендә ориентлашу, мәгълүмат белән гамәли эш алымнарын үзләштерү, яңа техник чаралар ярдәмендә аның белән алмашу-уртаклашу күнекмәләрен булдыру, укучының шәхси позициясен формалаштыру мөмкинлеген бирә.

Моңарчы башлыча өстәмә белем алу өлкәсендә кулай дип саналып килгән заманча белем бирү платформалары бүген уку-укыту процессында үз урынын алды. Мондый платформалар электрон уку-укытуны гамәлгә ашыруда укучылар һәм укытучылар өчен белем бирү контентын тәкъдим итәләр.

Хәзерге көн белем бирү киңлегендә күптөрле электрон платформалар уңышлы гына эшләп килә. Шулар арасында кулланылу дәрәҗәсенә, ешлыгына һәм нәтиҗәлелегенә бәйле рәвештә гамәлдәге барлык платформалар арасында РЭШ, Учи.ру, Яндекс.Учебник, ЯКласс, Открытая школа, Платформа новой школы кебекләре аерым урын алып тора.

Белем бирү платформасы дигәндә, без уку-укыту белән идарә итү системасын күз алдына китерәбез. Ул махсус программалаштырылган гамәли укыту рәвешен ала, аннан уку-укыту процесында барлык катнашучылар да иркен файдаланырга мөмкин. Шул ук вакытта төп игътибар укучыларга, аларның белем алу нәтиҗәлелегенә ирешүләренә юнәлтелә. Мондый электрон платформалар, иң беренче чиратта, белем алу процессын җиңел һәм кызыклы булуын тәэмин итәләр. Билгеле, өйрәнә торган фәнгә кызыксыну, белем алуга теләк тудырылганда гына укучыларның яхшы уку өлгерешенә ирешеп була.

Әлеге мәсьәлә туган (татар) теле һәм әдәбияты предметлары өлкәсенә дә кагылышлы булып пандемия шартларында үткән соңгы елда көн үзәгендә торды. Шуңа бәйле рәвештә электрон белем бирү платформасы өчен татар теле һәм әдәбиятыннан махсус контент булдыру бурычы куелды. Әлеге максат белән бу предметлардан уку-укытуны платформада оештыру юнәлешендә яңа үрнәк белем бирү программаларына мөрәҗәгать итеп эшләү күздә тотыла.

Шул рәвешле, белем бирү платформасында татар әдәбияты буенча 5–9 сыйныфлар өчен программа кысаларында күрсәтелгән әдәби, теоретик, биографик материал, матур әдәбият әсәрләре урнаштырыла.

Төп мәктәп өчен төзелгән яңа программаларда Габдулла Тукай иҗаты аерым урын алып тора. Шагыйрьнең «Милли моңнар», «Туган җиремә», «Туган авыл», «Пар ат», «Җәйге таң хатирәсе», «Милләткә», «Тәэсир», «Ана догасы» шигырьләре, «Шүрәле» поэмасы, «Исемдә калганнар» кебек

автобиографик әсәре, «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәле өйрәнү өчен тәкъдим ителә.

Мәктәптә Г. Тукай иҗаты белән танышу «Шүрәле» поэмасыннан башлана. Биредә ул әдәби әкият төшенчәсен үзләштерүгә бәйле алып барыла. Шуңа күрә әсәрне анализлау барышында бирелә торган сорау-биремнәр дә турыдан-туры автор әкияте дигән күренешкә барып тоташа.Теманы өйрәнүнең төп идеясе буларак «Әкиятләрнең дә авторы була» дигән җөмлә алга чыгарыла. Шуңа бәйле рәвештә һәм мотивлаштыру максатын күздән тотып, укучылар алдына «Автор язган әкиятләр халык әкиятләреннән нәрсә белән аерыла?» дигән проблемалы сорау куела. Бу проблемалы сорауга укучылар теманы өйрәнү барышында җавап бирергә тиеш булалар. Алга таба Шүрәле рәсеменә игътибарны юнәлдереп укучыларның әлеге персонаж белән таныш булу яки булмаулары ачыклана. Мотивлаштыруны тәэмин итү өчен өстәмә эш төре буларак Шүрәле мультфильмын карарга тәкъдим итү дә отышлы.

Алга таба үзлектән өйрәнү өчен биремнәрне үтәү барышында укучыларның үз алдына куйган уку максатларына яраштырып платформа тәкъдим иткән төрле эшчәнлектә катнашуы күздә тотыла. Аерым алганда, әкиятнең эчтәлеген үзләштерү һәм белү дәрәҗәсен тикшерү өчен укучы төрле сорауларга җавап бирә, төрле таблицалар тутыра, тест эшли, аудиоязма тыңлау, видео карый һ.б. шундый эш төрләрен башкара.

Шулай ук сорауларга җавапларны, төркемнәргә бүленеп бирү яки уен рәвешендә оештырып теманы үтү тәкъдим ителә. Әкиятнең эчтәлегенә нигезләнеп, рәсемнәр ярдәмендә вакыйгаларны дөрес эзлеклектә урнаштыру, Шүрәле әкиятеннән алынган өзектә төшеп калган сүзләрне өстәп язу, әкиятнең эчтәлеге буенча аерым сорауларга җавап бирү файдалы була, бу эчтәлекне тагын да тирәнрәк үзләштерү мөмкинлеген бирә.

Укучы үз алдына әдәби әкият геройларына бәя бирү белүне максат итеп куеп Шүрәле образын характерлый. Мәсәлән, «Шүрәле усалмы?» исем астында тәкъдим ителгән биремдә «Шүрәле» әкиятендә булган образларны барлау, Шүрәле образына аерым игътибар итеп, аның ни рәвешле тасвирлануын, уңай яки тискәре герой булуын ачыклап таблица тутырыла. Укучылар Шүрәленең хис-кичерешләренә бәйле рәвештә аның ни өчен күңелсез хәлгә калуын характер сыйфатлары аша шуларга бәя биреп билгелиләр.

Программада Шүрәленең мифологик образ булуына игътибар итү дә каралган. Шул уңайдан платформада әлеге образының Г. Тукай әкиятенә килеп керү юлларын фаразлау, ачыклау да уңышлы булачак, укучыларда теманы дәвам итеп өйрәнүгә кызыксыну уятачак.

Былтыр образы да игътибардан читтә калмый. Белем бирү платформасында аңа кагылышлы сораулар да байтак. «Ничек уйлыйсың, Былтыр Шүрәленең бармагын кыстырып дөрес эшләдеме, аңа нинди киңәш бирер идең?» дигән сорау укучыдан геройга бәя бирүне күздә тотып, аңа үз мөнәсәбен формаштыру мөмкинлеген бирә.

Теманы өйрәнүдә күрсәтмәлелек булып файдаланыла ала торган сәнгать әсәрләре белән танышу да укучыларга бу әсәр турында өстәмә мәгълүматка ия булуын тәэмин итә.. Аерым алганда, «Шүрәле» балетын карау ике төр әсәодәге Шүрәле образына чагыштырма характеристика бирү аны тагын тирәнрәк төшенүгә мөмкинлек бирә.

Укучылар балеттагы Шүрәле образы белән Г. Тукай әкиятендәге Шүрәлене чагыштырып, балеттагы Шүрәленең ямьсезрәк күренүен, коточкыч, усал, мәкерле булуын билгелиләр.

Платформада үзләштергән белемнәрне тикшерүне күздә тоткан биремнәрдә төрле сыйфатлардан Шүрәлегә генә, яки Былтырга гына хас булганнарын аерып күрсәтү белемнәрне тагын бер кат ныгытып тикшерү өчен отышлы булып санала.

Укучы алдына куела торган уку максатларының берсе буларак платформада әдәби әкиятнең художестволы үзенчәлекләрен, әдәби алымнарны билгели алу максаты алга чыга. «Шүрәле» әкиятендә табигать күренешләрен күзәтү, аларның ни өчен бирелгәнлеген тикшерү, табигать күренешләре бирелгән урыннарны укып, үз сүзләре белән тасвирлап бирүне, текстта төрле сурәтләү чараларын табуны күздә тоткан биремнәр тәкъдим ителә.

Әйтергә кирәк, платформада биремнәр вариантлап тәкъдим ителә ала. Укучыга үзе көче җитәрлек, яки үзенә ошаган биремне сайлап алу эшләү мөмкинлеге бирелә. Укучыларны биремнәрне эшләүгә кызыксындыру уяту максатыннан бирем исемнәрен үзенчәлекле, кызыклы, игътибарны җәлеп итәрлек бирүдщ отышлы санала. Мәсәлән, «Бармаклары ярты аршыннан озын...», «Нәрсә бу? Качкынмы? Җенме?», «Шүрәленең хәле ничек?», «Шүрәле»дә ниләр бар?», «Кысканга былтыр, кычкыраларммы быел?» һ.б. Шул рәвешле алда күрсәтелгән сорау-биремнәр, эш төрләренең катлаулылык буенча икенче дәрәҗәне тәшкил итә.

Катлаулылык буенча өченче дәрәҗәдәге биремнәр аоасында әсәрнең темаын, идеясен билгеләү белән бәйле текст өстендә эшләүгә юнәлдерелгәннәре бар: Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкиятен ике өлешкә бүл. Өлешләргә исем бир. Һәр өлештә сүзнең нәрсә турында барганын билгелә яки Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкиятендә авторның геройларга карата мөнәсәбәте билгелә? Габдулла Тукай бу әсәре белән безгә нәрсә әйтергә тели? кебек сорауларга җавап бирү күздә тотыла.

Платформада иҗадилыкны күздә тоткан биремнәр дә тәкъдим ителә. Бу вакытта укучылар хикәя, инша язу, рәсем ясау, тикшеренү үткәреп проект әзерләү һ.б. эшләрен башкаралар. Г. Тукайның «Шүрәле» әкияте белән бәйле рәвештә бу очракта әкият буенча сценарий язу, укучының иң яраткан әкияте буенча инша язу кебек эш төрләре кулланыла.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, заманча электрон белем бирү платформалары укучының уку материал үзлектән үзләштерү мөмкинлеген бирүе белән әһәмиятле. Бу бигрәк тә мөмкинлек яки зарурлык туганда, билгеле бер шартларны исәпкә алып, мәсәлән, дистанцион белем алуда бик отышлы булып санала. Иң мөһиме – бала бу очракта белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштерү әһәмиятен аңларга тиеш була. Платформада эшләү шулай ук турыдан-туры дәрестә укытучы белән бергә эшләгәндә дә уңышлы гына кулланыла ала. Бу укучыга да, укытучыга да шактый зур мөмкилекләр бирә. Эшчәнлекне төрләндерү, дәресне өстәмә уку яки күрсәтмә материал белән тулыландыру укучыларның белем алуга ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм үстерү юлында тиешле нәтиҗәләргә китерәчәк.

УДК 82-1/29

# ЖАНРОВЫЕ ВОПРОСЫ ПЕРЕВОДА СТИХОТВОРЕНИЙ Г. ТУКАЯ

***Э.Ф. Нагуманова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье рассматриваются переводы В. Думаевой-Валиевой стихотворений Г. Тукая в жанре китга (кыйтга) на русский язык. Произведения Г. Тукая переводились на русский язык многими известными русскоязычными поэтами и переводчиками с национальных языков. Переводы В. Думаевой-Валиевой наиболее полно передают поэтику тукаевских стихотворений. В ходе анализа двух произведений Тукая мы приходим к выводу, что Думаева-Валиева, интерпретируя стихотворение, базируется на его «объективном смысле», сводя к минимуму субъективное и произвольное вмешательство в текст оригинала.
**Ключевые слова:** жанр, китга (кыйтга), перевод, В. Думаева-Валиева.

The article deals with the translations of G. Tukay's poems in the genre of kyitga into Russian made by V. Dumaeva-Valieva. The poems of G. Tukay were translated into Russian by many well-known Russian-speaking poets and translators from national languages. The poetics of Tukay's poems is most fully conveyed in the translations of V. Dumaeva-Valieva. While conducting the analysis of two Tukay's works, we come to the conclusion that Dumaeva-Valieva, interpreting the poem, considers its «objective meaning», minimizing subjective and arbitrary interference in the original text.
**Key words**: genre, kitga (kyitga), translation, V. Dumaeva-Valieva.

Китга (кыйтга) – жанр малой поэтической формы, восходящий к традициям литератур Востока, в нем особое место занимают философские темы и идеи. Как отмечает А. Тамимдари, китга – «стихотворная форма, в которой первая мисра не имеет рифмы, а каждая вторая мисра каждого байта рифмуется» [4: 193]. «Название это пошло от того, что этот тип стиха похож на отрывочные байты в середине касыды. В китга преимущественно говорится о нравственных проблемах и даются соответствующие назидания, а также встречается инвектива, элегия, панегирик, оплакивание и поздравление», – пишет исследователь [4: 193].

В центре нашего внимания два стихотворения Г. Тукая: «Мөхәрриргә» («Писателю») и их переводы на русский язык, выполненные В.С. Думаевой-Валиевой. Оба лирических произведения были написаны Тукаем в традициях жанра китга.

Н. Лаисов в работе «Лирика Тукая (Вопросы метода и жанра)» писал: «В лирике Тукая имеются 4 стихотворения, два из которых озаглавлены «Кыйтга» («Пушкин, Лермонтов – два солнца…», «Сил молодых про черный день…», 1913), а два – так же обозначены только в подзаголовке: «Критик (кыйтга)», 1912, «Писателю (Кыйтга)», 1913. Как по содержанию, так и по форме произведения эти по существу ничем не отличаются от таких же других (элегических, сатирических или гражданских) стихов Тукая» [1]. С нашей точки зрения, рассматриваемые нами стихотворения полностью соответствуют жанровому канону.

Цель статьи – рассмотреть способы передачи поэтики тукаевских стихотворений в жанре китга в переводах В. Думаевой-Валиевой.

Проблема переводов стихотворения Тукая «Кытга» на русский язык поднималась в работе Р.Р. Мусабековой «Переводы стихотворения Г. Тукая «Кытга» на русский язык», этого вопроса касались и некоторые современные исследователи творчества татарского поэта [3].

Мы стремимся выявить характерные особенности переводов В. Думаевой-Валиевой по сравнению с другими известными переводами.

В предисловии к изданию стихов Г. Тукая Н. Хисамов говорит о переводах Думаевой-Валиевой следующее: «Переводы стихов «Светлой памяти Хусаина», «Кыйтга» и «Буран» выполнены с большим мастерством. Особенно талантливо и точно переданы образ мыслей Тукая, философский склад его личности и выводы о нравах нашей жизни…» [5: 233].

Обратимся к стихотворению «Кыйтга».

**Кыйтга**

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакъли алмадым.

**Кыйтга («Я силы сохранить мои…»)**

Я силы сохранить мои для чёрных дней никак не мог,
Поскольку белого ни дня средь дней моих назвать не смог.

Преграды были на пути, и больше, чем собак, врагов,
Поскольку с теми, кто сильней, быть заодно не мог.

Неотомщён и изнемог, и сломан меч – таков итог.
Забрызган с ног до головы, но мир отмыть не смог.
(Перевод В. Думаевой-Валиевой).

В этом стихотворении Тукай как бы подводит итоги своей творческой деятельности. Как пишет Х.Ю. Миннегулов, «в произведении, состоящем из трех строф (бейтов), переданы душевные страдания поэта, свеча жизни которого догорает, воплощено его творческое и жизненное кредо... Основанная на внутренней рифме, аллитерации и антитезе последняя строфа, звучит как трагический монолог» [2: 123].

Тукай осознает полную ответственность за свое время, за свое поколение, он понимает, что должен был встать на путь борьбы с врагами, но, но не смог... Все это усиливает трагедию лирического героя, его душевные муки.

«Кыйтга» полностью соответствует формальным принципам жанра: состоит из 3 бейтов, схема рифмовки: а-а, б-а, в-а. Сжатость, афористичность и содержательность выражения мысли, являющиеся отличительными качествами китга, многообразие изобразительных средств и художественные приемы их создания – все эти особенности жанра проявились в стихотворении Г. Тукая.

Тукай размышляет о своем жизненном пути, о тех преградах, которые он не сумел преодолеть: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым» [6: 273]. Поэт использует множество эпитетов и метафорических выражений, его фразы насыщены глубокой мыслью.

К переводу этого стихотворения на русский язык обращались многие авторы: С. Липкин, М. Львов, Н. Ахмеров и Л. Руст, В. Думаева-Валиева и др. Каждый из них стремится донести до русскоязычного читателя глубину авторской мысли Тукая, но при этом не все выдерживают формальные принципы жанра. К примеру, Семен Липкин называет стихотворение

«Отрывок («Сил молодых…»), русскоязычный читатель может понять, что перед ним отрывок из более объемного произведения. Л. Руст дает название произведению: «Про черный день».

В целом все переводчики создают образцы адекватного восприятия тукаевского стиха, в качестве примера приведем перевод последнего бейта:

Кайтмады үч, бете көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.
Хотел я мстить, но ослабел, сломался мой клинок,
Я весь в грязи, но этот мир очистить я не смог.
(Перевод С. Липкина)

Я врагам не отомстил, вышли силы, сломан меч,
В битве с грязью сам погряз, мир очистить я не смог.
(Перевод М. Львова)

Неотомщен и изнемог, и сломан меч – таков итог.
Забрызган с ног до головы, но мир отмыть не смог.
(Перевод В. Думаевой-Валиевой)

В то же время с точки зрения передачи формальных особенностей оригинала и соответствия идейно-тематического уровня русского стихотворения оригиналу, перевод Думаевой-Валиевой наиболее близок к стихотворению Г. Тукая.

В переводе наиболее полно воссоздан основной смысл, заложенный в китга. Как отмечает А.З. Хабибуллина, «китга как жанр малой поэтической формы, по сравнению с романтическим отрывком, видится более целостным и завершённым в смысловом плане произведением, в котором особое место занимают философские темы и идеи [7: 148].

Обратимся к первым двум бейтам стихотворения «Мөхәрриргә» («Писателю»), посвященному вернувшемуся из ссылки Г. Исхаки.

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

О писатель! Кто признанья взглядом-молнией достиг!
О художник! Словом честным чей прославился язык!

Возвратись в страну, довольно, ожидания не дли,
Чтобы ложь и лицемерье взор твой пламенный настиг.
(Перевод В. Думаевой-Валиевой)

Данное стихотворение соответствует жанру китга, начиная с рифмовки, заканчивая образными выражениями, которые использует Тукай.

В китга вечное раскрывается в малом, единичное выражает универсальное, т.е. то, в чем нет сомнения, что воспринимается как непреходящий закон. Однако последняя строка оригинала несет в себе некую недоговоренность, в переводном произведении усилено утвердительное начало:

«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар» дигән төсле Рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя…

Как сказал пророк: «Гумера убоится сам шайтан»,
Остановит лжи потоки взгляд один очей твоих.

*(*Гумер – единомышленник пророка Мухаммеда, полулегендарный халиф).*

То, что происходит по воле Бога, передаётся в этом бейте как истинное, не требующее субъективного истолкования, сомнения, неверия в Его силу. Для передачи высокого слога оригинала Думаева-Валиева прибегает к устаревшей лексике: «взгляд один очей твоих». Переводчик использует эпитеты, которые часто встречаются в стихотворной речи: «взор пламенный», «слово честное», «жизнь мертвая». Думаева-Валиева находит весьма удачные способы передачи метафорических форм оригинала: «Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия – Года пятого витии перегрызлись меж собой».

Как показывает наше исследование, трудности перевода связаны не только с уровнем владения языками, но и с умением переводчика находить в языковых системах те лингвосемиотические закономерности, которые определяют место каждой языковой единицы в структуре переводимых текстов, а также определить факторы, накладывающие ограничения на семиотические и контекстные возможности адекватной передачи содержания оригинала.

Переводы В. Думаевой-Валиевой стихотворений, написанных в жанре китга, несут тот же эмоциональный настрой, что и оригинальные произведения Тукая. Переводчик создает близкие к оригиналу переводы, прибегая в некоторых случаях к лексическим заменам.

ЛИТЕРАТУРА

1. Лаисов Н. Лирика Тукая (Вопросы метода и жанра). – Казань: Таткнигоиздат., 1976. – 167 с. http://gabdullatukay.ru/rus/tukay-science/scientists/naip-laisov-lirika-tukaya-edinstvo-i-mnogoobrazie/index.php?option=com_content&task=view&id=799&Itemid=55 (дата обращения: 20.03.2021).

2. Миңнегулов Х.Й. Кыйтга // Габдулла Тукай әсәрләре. Сүзлек-белешмәлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 479 б.

3. Мусабекова Р.Р. Переводы стихотворения Г. Тукая «Кытга» на русский язык // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. – 2015. – № 4–1. – С. 117–120.

4. Тамимдари А. История персидской литературы. – СПб.: Петерб. востоковедение, 2007. – 240 с.

5. Тукай Г. Избранное / перевод с татарского В.С. Думаевой-Валиевой. – Казань: Магариф, 2006. – 239 с.

6. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 480 б.

7. Хабибуллина А.З. Отрывок, китга и парча: опыт сопоставительного изучения жанров // Ученые записки Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. – 2018. – Т. 160, кн. 1. – С. 145–158.

УДК 821.512.145

## РОМАНТИЧЕСКИЙ ДИСКУРС В КАЗАНСКОЙ ЛИРИКЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

***Л.Р. Надыршина, Л.Ш. Гарипова***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Казанский период творчества Габдуллы Тукая характеризуется новыми тенденциями, одной из которых является усиление позиции романтического дискурса. В результате, наряду с гражданской лирикой, в творчестве поэта отводится значительное место и интимной лирике, раскрывающей духовный мир и личные переживания лирического героя. На материале ряда стихотворений поэта в статье выявлены наиболее частотные темы, мотивы и образы.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, поэзия, лирика, романтический дискурс, тема.

The Kazan period of Gabdulla Tukai's creative work is characterized by new trends, one of which is the strengthening of the position of romantic discourse. As a result, along with civil lyrics, a significant place is given in the poet's work to intimate lyrics that reveal the spiritual world and personal experiences of the lyric hero. The article uses the material of a number of poems by the poet to identify the most frequent themes, motifs and images.
**Key words:** Gabdulla Tukay, poetry, lyrics, romantic discourse, theme.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ КАЗАН ЧОРЫ ШИГЪРИЯТЕНДӘ РОМАНТИК ДИСКУРС

***Л.Р. Надыршина, Л.Ш. Гарипова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Тукай иҗатында сизелерлек сыйфат үзгәрешләре әле Казанга килгәнче үк башлана. 1907 елның башында иҗат ителгән, «татар халкының рухи-мәдәни үзәге Казанга кайту турындагы моңсу, шул ук вакытта ашкынулы уй-хисләрен гәүдәләндергән» [2: 511] «Пар ат» шигырендә шагыйрь иҗатының Казан чорын (1908–1913) характерлаган сыйфатларның берсе – лирик-эмоциональ, романтик аһәңнәргә борылыш ачык чагылыш таба. Шуның бер чагылышы буларак, романтик һәм сентименталь кичерешләр бәйләме төсендә күзалланган күңел лирикасында шагыйрь туган авыл, туган тел, ана, табигать образларына мөрәҗәгать итә, лирик герой хис-кичерешләре сагыну, юксыну, җирсү чикләрендә тирбәлә. Мәсәлән, туган җир, туган авыл образын үзәккә куйган әсәрләрдә һәрвакытта да туган якны сагыну белән алшартланган хәтер мотивы калка. Нәтиҗәдә, мондый әсәрләрдә ретроспектив хатирәләр киң чагылыш таба, үткәндә калган рәхәт, хөр чакларны сагыну хис катламының эчтәлеген хасил итә. Әйтик, «Туган авыл» (1909) шигыренә шагыйрь үзенең сабый чоры үткән якларның гаҗәеп бер матурлыгын, күңел кылларын тибрәтердәй хатирәләргә байлыгын, җанга якын бизәкләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүгә ирешә. Туган авыл – кешенең кендек каны тамган, шәхес буларак формалаша башлаган, аң-белем алган, дөньяның асылын аңлаган сакраль урын булуы Коръән аятьләре, рәсүлемез Мөхәммәд тормышы турындагы дини күзаллаулар ярдәмендә төгәлләштерелә. Шигырьнең икенче строфасында балачакның идеаллаштырылган сурәте лирик геройның ретроспектив хатирәләренең асылын билгели, әсәрне сентименталь укылышка көйли: *Истән чыкмый монда минем күргәннәрем, / Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем; / Абый белән бергәләшеп кара җирне / Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем* [7: 55]. Шигырьнең соңгы строфасында алгы планга чыккан хәтер мотивы язмыш юллары кая гына илтсә дә, туган җир белән бәйле якты истәлек-хатирәләр кешенең җанын җылытырдай төп кыйммәт булып калачак, дигән идеяне нигезли: *Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем, / Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем; /Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә, /Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем* [7: 55].

Гомумән, шагыйрьнең лирик герое еш кына күңел юанычын нәкъ менә үткәннәрдән таба, «үткәнне искә төшереп сагышлану, идеалны үткәннән эзләү мотивы шагыйрьнең романтик иҗатын, фәлсәфи шигырьләрен әйдәп бара» [5: 74–75]. Шушы юнәлештә иҗат ителгән «Исемдә» (1909), «Сагыныр вакытлар» (1912) шигырьләрендә, мәсәлән, кеше гомеренең иң гүзәл бер дәвере – самимилек, гамьсезлек, бәхет көтү белән бәйле балачак еллары, яшүсмерлек чоры – өлкән лирик геройның күңелен еллар үткәч тә җылы-

тып тора: *Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар, / Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар; / Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне, /Теләп яшьрен генә рәхәт, сәгадәтле вакытларны («Исемдә») [7: 17]; Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, – / Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын. / И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы! / И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы! («Сагынып вакытлар»)* [7: 239].

Тукайның бер төркем әсәрләрендә лириклык дини мотивлар ярдәмендә тирәнәйтелә, аерым алганда, дога мотивы «шагыйрьнең идея-эстеитк карашларын, лирик хисләрен укучыга җиткерүнең бер алымы булып тора, күңелендәге иң тирән, иң садә, иң яшерен серләрен ачарга ярдәм итә, җан авазын башкаларга җиткерергә булыша» [1: 65]. Мәсәлән, гаҗәеп лиризм белән сугарылган «Ана догасы» (1909) шигырендә дога кылу мотивы елау мотивы белән бер үремтәдә килә, күз яше түгү, бердән, баласы өчен дога кылган ананың хисләр бәйләмен (сагыну, юксыну, борчылу, хәсрәтләнү) чагылдыра, икенче яктан, ислам фәлсәфәсе белән бәйләнештә каралып, язмышны Аллаһка тапшырудан туган рухи чистарыну мизгеле кебек укыла: *Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь; / Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?* [7: 71].

Тукайның бу чор күңел лирикасында мәхәббәт темасына иҗат ителгән әсәрләр дә зур урын алып тора. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында гыйшык утында яну, мәхәббәт газабы, сөюдән акылны җую, мәхәббәттән күккә ашу, сөйгән ярны идеаллаштыру кебек традицион мотивлар әйдәп бара. Мәхәббәт хисе илһам («Мәхәббәт», 1907), мәхәббәт («Кулың», 1908) чыганагы һәм камилләшүгә этәргеч («…гә», 1908), буй җитмәслек идеал («Бер рәсемгә», 1908) һәм яшәү мәгънәсе («Иһтида», 1911) рәвешендә шәрехләнә [6: 10–11]. Мәхәббәт фәлсәфәсе сөю – кешене яшәтүче, яшәешне мәгънәле итүче көч дигән идея яссылыгында ачыла: *Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, / Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы («Мәхәббәт»)* [7: 265].

Шагыйрь үзе Гёте әсәренә ияреп иҗат ителгән дип күрсәткән «Төш» (1910) шигырендә дә без традицион сурәтләр нигезендә ачып бирелгән романтик кичерешләр дөньясын күрәбез. Шигырьнең исеменә чыгарылган төш мотивы бу очракта чынбарлыкка каршы куелган үзгә реальлек мәгънәсендә реальләшә, мондый семантика әсәрдәге романтик дөнья сурәтен нигезли. Төп мотив шигырьнең композициясен билгели: аның беренче өлеше лирик геройның хыялый хәятен чагылдырган төш рәвешендә корылса, икенче өлештә инде герой реаль чынбарлык белән күзгә-күз кала. Сөю утында янган лирик герой (әсәрдә ул шагыйрь буларак конкретлаштырыла) төшендә үзен «бер зур шаһ», дәүләт иясе итеп күрә. Төштәге романтик кичерешләр чынбарлык белән кисешә, лирик геройның күңел халәте традицион мотивлар аша ачып бирелә (сөйгән яр каршында баш ию, яну/көю): *Таҗлы башым хозурыңда иям, имеш, / «Җанашым, мин сине сөям», – диям, имеш; / Нәрсә генә әйтер сөйгәнем дип, / Эчемнән бик янам, имеш, көям, имеш* [7: 151].

Сөйгәненнән тын да алмый җавап көткән шаһ-шагыйрь уянып китә һәм кичереш-халәтенең иллюзия генә булуын аңлый, ягъни өзелгән төш лирик геройны чынбарлыкка кайтара, «явыз язмыш» метафорик эпитеты белән ачыкланган бу реальлек хис катламындагы әрнүле-ачынулы халәтне нигезли. Лирик геройның психологик кичерешләр бәйләме романтик әдәбиятта

киң очраган елау мотивы белән үстерелә, «мескен гашыйк», «кайнар яшь» гыйбарәләре бу строфаны сентименталь укылышка көйли. Соңгы строфада инде хис-кичерешләр дөньясы бөтенләй башка эчтәлектә ачыла: лирик геройның психологик халәте динамикада бирелә һәм елау мотивы шатлык белән алмашына, мәхәббәттә юану табу рухи яшәешнең матди кыйммәтләрдән өстенлеген раслауга алып килә: *Бераздан соң килде аңар шатлык янә: / Егъласам мин, егъладым, ди, шашып кына. / Мәхәббәтем һаман иске мәхәббәт ич, / Югалтсам мин, югалттым, ди, шаһлык кына* [7: 151].

«Шәйтанның муенына» (1908), «Кызык гыйшык» (1908), «Егет илә кыз» (1908) кебек шигырьләрдә романтик кичерешләр яратып шаярту, үз итеп көлү белән кушылып китсә дә, яшерен сөюдән туган газаплы-ләззәтле халәт дулкынында яшәгән, кыюсыз, хисләрен тирәнгә яшергән лирик герой үзәктә тора. Шундый кичерешләр бәйләме шәкелендә язылган «Актык тамчы яшь» (1910) шигырендә газап мотивы һәр строфада үстерелә килеп (автор моңа гипербола алымы ярдәмендә ирешә), кайчандыр «арысланнан кыю», ә хәзер «яшьрен сөюдән җан көю» сәбәпле юашланган лирик геройның эмоциональ-психологик халәте бөтен тирәнлеге белән ачыла, романтик дөнья сурәтенең үзәгендә яткан көю, елау, гомуми эчтәлектән тоемланган ялгызлык мотивлары, әсәрнең исеменә салынган метафорик эчтәлек белән кушылып, хис катламын экзистенциаль сызлану халәте белән баета. Романтик омтылышларның тәкъдир тарафыннан кире кагылуы шигырь эчтәлеген фаталистик тенденция белән тулыландыра, мәхәббәттә бәхетсезлекне язмышы итеп кабул иткән лирик геройның тәкъдиргә буйсынуы соңгы строфада үлү/бетү мотивы аша реальләшә: *Үлде рух яшьрен мәхәббәттән, – хафа юк үлсә дә, – / Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю!* [7: 145].

1911 елда иҗат ителгән «Иһтида» шигырен әдәбият галимнәре шагыйрьнең мәхәббәт лирикасына үзенчәлекле йомгак буларак карыйлар, акыл белән хисне каршы куеп, сөйгән ярга мәхәббәттән милләткә мәхәббәтнең өстенлеген раслаган әсәр буларак билгелиләр [3: 36–38; 5: 135]. Дөрестән дә, композицион яктан аерымланган бүлекләрдә лирик геройның хис-кичерешләре күчеш-үзгәреше бирелә: шәркый әдәби-сәнгати традицияләрдә язылган беренче бүлектә традицион мотивлар (сөйгән ярга сәҗдә кылу, мәхәббәттән шәмдәй эрү, күңелдәге гөлләр яну, мактау), эмоциональ-психологик экспрессия (Өмид иттем вә куркътым да, кызардым һәм оялдым да) ярдәмендә ачылган сөю – идеал дигән романтик концепция икенче бүлектә, җаһилият дәвереннән соң ислам диненә килгән гарәпләр язмышы белән янәшәлек аша, лирик геройның озак еллар алданып яшәвенә төшенү белән алмашына. Өченче бүлектә Тукай шигърияте өчен традицион булган золмәт / нурлы хәят оппозициясе «вакытлы, мәгънәсе юк хис»тән азат лирик геройның идеалы үзгәрүенә ишарә итә: *Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт! / Яшә, тугъры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!* [7: 187] Шул рәвешле, шигырьнең бетемендә урын алган акыл һәм хис каршылыгында шагыйрь тапкан хакыйкать-идеал раслана: милләткә хезмәт идеясе шәхси хисләрдән югары куела.

Гомумән, Тукай иҗатының бу чорында көчәйгән романтик аһәңнәр, психологик аспектның әһәмияте арту сөю-әрнүләр, борчылу-газаплар, сагыну-юксынулары дулкынында яшәгән лирик «мин»нең эчке дөньясын ачып бирә, шагыйрьнең иҗат дөньясы баюын, яңа сурәтләр белән тулылануын күрсәтә. «XX йөз башы татар әдәбияты күгендә якты йолдыз булып

балкыган Г. Тукай яңа заман шигъриятенең нигез ташларын сала, халыкның моңлы җырчысына, аның рухи таянычына әйләнә» [4: 167].

ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллина Д.М. Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 190 б.

2. Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөх. З.З. Рәмиев. – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б.

3. Ганиева Р. К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 112 б.

4. Закирҗанов Ә.М. Тукай турында яңа китап [бәяләмә: Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886–1907). – Казан, 2018. – 448 б.] // Фәнни Татарстан. – 2018. – № 3. – Б. 167–172.

5. Заһидуллина Д.Ф. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. – Казан: Мәгариф, 2006.

6. Заһидуллина Д.Ф. Национальное и общечеловеческое в творчестве Габдуллы Тукая // Габдулла Тукай и тюркский мир: Материалы международной конференции (Казань, 25 апреля 2016 года). Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан; сост.: Ф.Х.Миннуллина, А. Ф. Ганиева. – Казань: Издательство Академии наук Республики Татарстан, 2016. – С. 7–12.

7. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909 –1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 384 б.

УДК 821.512.145

## РОДИНА ТУКАЯ В ТВОРЧЕСТВЕ ПОЭТОВ СОВРЕМЕННИКОВ

***Н.Ш. Насибуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются поэтические произведения, посвященные Родине Тукая. Тукай родился в селе Кушлавич, за Казанью, и по горькой судьбе жил в семье своего деда, селе Училе, был усыновлен и жил около двух лет в селе Кырлай (Новый Кырлай). Малая родина Тукая – занимает особое место в творчестве тюркских народов и является источником поэтического вдохновения. В статье анализируются мотивы, образы, поэтические детали, эмоциональное и художественное содержание произведений. Отмечается также, что лирический герой произведений чувствуют себя частью родной земли Тукая, её природы и судьбы.
**Ключевые слова:** поэзия, лирика, образ, малая родина, лирический герой, Тукай.

The article examines the poetic works of contemporaries dedicated to the Motherland of Tukay. Tukay was born in the village of Kushlavich, outside Kazan, and by bitter fate he lived in the family of his grandfather, the village of Uchile, was adopted and lived in the village of Kyrlay (New Kyrlay) for about two years. The small homeland of Tukay occupies a special place in the creativity of the Turkic peoples and is a source of poetic inspiration. The article analyzes the motives, images, poetic details, emotional and artistic content of the works. It is also noted that the lyrical hero of the works feel like a part of the native land of Tukay, its nature and destiny.
**Key words:** poetry, lyrics, image, small homeland, lyric hero, Tukai.

## Г. ТУКАЙНЫҢ ТУГАН ЯГЫ – ЗАМАНДАШ ШАГЫЙРЬЛӘР ИҖАТЫНДА

***Н.Ш. Насыйбуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар халкының даһи улы Габдулла Тукай язмышы, иҗат мирасы, яшәештә буыннар алмашынып торуга карамастан, аңардан соң иҗат мәйданына килгән әдип-шагыйрьләрнең игътибарын үзенә җәлеп итеп тора.

Төрки халыклар әдәбиятында Тукайга үз мөнәсәбәтен белдермәгән, аңа күңел түрендәге шигъри юлларын багышламаган бер генә шагыйрь дә калмагандыр. Тукайның гомер юлы бала чактан ук төрле гаиләләргә һәм төрле авыл-шәһәрләргә күчеп йөрүләрдән гыйбарәт. К. Мостафин моны «Юлның дәвамы» шигырендә болай дип тасфирлый: «Ул башлаган юлын Кушлавычтан, / Дәвам иткән Кырлай аркылы.... / ...Көтә аны Җаек калалары, / Нурлы Казан көтә, кил, диеп».

Татар әдәбиятында Тукай образын иҗади югарылыкта яктырткан, аның туган ягы Арча төбәгенә багышланган әсәрләр байтак. Шигъри багышлаулардан С. Хәкимнең «Пар ат» (1939), «Шагыйрьнең балачагы» (1940), И. Юзеевнең «Очты дөнья читлегеннән» (1985), М. Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» (1972–1985), Э. Шарифуллинаның «Без – Тукайлы» поэмалары иҗат ителгән. Шигъри әсәрләр арасында Тукай шәхесен, аның тормыш биографиясендәге аерым сәхифәләрне беренчеләрдән булып сәнгатьчә осталык белән яктырту ягыннан Сибгат Хәким поэзиясе әһәмиятле урыннарның берсен алып тора. Шигъриятендә халык шагыйре үсеп чыккан мохитне тасвирлый, аның акылына һәм җанына азык биреп килгән, Тукай поэзиясенең һәм эшчәнлегенең пафосын билгеләгән халык тормышының бар якларын да яктыртырга омтыла: «Тормыш аны тәпи басу белән / Җитәкләде ике кулыннан, / Һәм билгесез язмыш кай җирләргә / Алып чыгар авыр юлыннан?».

Татар поэма жанрының үсешенә М. Әгъләмов та «Тукайдан хатлар» (1972–1985) һәм башка әсәрләре белән зур өлеш кертте. «Тукайдан хатлар» поэмасы сиксәненче елларның беренче яртысында тәмамлана. Авыл тормышыннан алынган детальләр ярдәмендә шагыйрь Тукай биографиясен яза. Поэмада кайдан килү, кая бару, вакытлар кабатланышы турында мотивлар үзәккә куела: «Кушлавычта тәүге аваз салып / (Бизмәннәрдә үлчәсәк әгәр) / Аны гына кичермәгәнме ул / Апуш чактан Тукайга кадәр! /...Үз дигәнчә бара халык һаман, / Үз дигәнчә бара кешелек. / Казан өязендә кыссаң аны, / Ул Җаектан чыга бүселеп». Бу гыйбарәләр ярдәмендә шагыйрь, аерым шәхес узган тормыш юлын, милләт барышы турында фикерләр җиткерә: «Син сөрәсең аны мәсләгеннән, / Ә ул урап бөтен җир шарын, / Бер гасыр да узмый, кире кайта / Эзләп тамырын, эзләп туфрагын». Поэманың структур өлеше зур гомумиләштерүләргә бай. Шуларның берсе «халык» метафорасы рәвешендә чагылыш таба: «Нишләтергә мөмкин бу халыкны / Җылаганда хәтта җырласа? / Ул барыбер кайта сөргеннәрдән, / Җырда кайта – ни дә булмаса». М. Әгъләмов мәңгелекне, шул исәптән тарих дәвамында тупланган үзаң һәм рухи кичерешләр хакындагы мәгълүматны да аңлатырга тели. Тукайдан сайланган эпиграфлар исә шагыйрьнең туган авылына булган нечкә һәм җылы мөнәсәбәтен чагылдыруга да хезмәт итә.

Әдәбият галиме Т. Галиуллин: «Тукай – егерменче гасыр татар поэзиясенең нигезе. Һәр шагыйрь бу иҗат чишмәсеннән үзенең сәләт көченә, юнәлешенә карап илһам ала» – дип язды [1: 28]. Э. Шарифуллина туган җир матурлыгына, гүзәл табигатенә дан җырлап «Шагыйрь чишмәсе» поэмасы аша Тукайга якын килә: «Үз күзләрем белән карап тордым / Тукай күңеле төшкән чишмәгә. / Изге булгандыр бу салкын чишмә – / Тукай күңеле төшмәс тикмәгә». Шагыйрә үзе тасвирлый торган күренеш вакыйгаларга карата нинди мөнәсәбәттә булуына карап билгеле бер фикерне үзенчәлекле итеп әйтеп бирә белү талантына ия. Сурәт ясауда һәр сүзнең үз урыны бар, үзенә йөкләнгән мәгънә көченә ия.

«Нәселең кайда булса – башкалаң шунда» – диләр халыкта. Тукай өчен Казан арты никадәр кадерле булса, шагыйрьләр өчен дә бу якларының авыллары шундый ук әһәмияткә ия, изге җир. Шигырьләренең исемнәре үк искәртеп тора: «Тукай анасы Мәмдүдәгә» (Б. Рәхимова), «Кырлай юлында Сәгъди абзый белән сөйләшү» (Р. Гатауллин), «Арча ягы» (Р. Зиннәтова), «Хаҗ кылу төбәге син, Кырлай!» (Ф. Гыйззәтуллина) һ.б. шигырьләре татар укучысы күз алдына иксез-чиксез Арча киңлекләрен, шунда яшәгән киң күңелле халыкның образын тудыралар, Кырлайның кабатланмас матурлыгына мәдхия җырлыйлар. Бу әсәрләр аша һәркем Арча якларының ниндидер серле тарту көчен, сихри романтикасын тоя, шул хиснең чынлыгына, кеше өчен кадерле булуына ышана; кайнар мәхәббәт, сагыну үзенә генә хас алымнар белән чагылыш таба, тел байлыгы, бизәкләү чаралары белән үткенәйтелеп, укучыга җиткерелә.

Заман шагыйрьләренең Тукайга багышлап язылган шигырьләрен берничә тематик юнәлештә тикшерергә мөмкин. Беренче төр шигырьләр, мәдхия характерында язылып, Тукайның шигъри осталыгына соклану рухында булса, икенчеләре – Тукай язмышын татар тарихы, татар язмышы, туган тел, туган ягы белән бәйләнештә карала. Татар халык шагыйренең иҗади традицияләренең шифалы йогынтысында формалашкан әдипләр шагыйрьнең туган ягы, тормышы, иҗады турында матбугат битләрендә әледән-әле мәкаләләр, әдәби әсәрләр, гыйльми хезмәтләр, истәлекләр, шигырьләр белән чыгыш ясыйлар. «Тукай Башкортстанда», «Тукайга чәчәкләр», «Мин Тукайга киләм», «Тукайга әйтер сүзем: Башкортстан шагыйрьләренең Габдулла Тукайга багышланган шигырьләре» кебек шигъри җыентыклар аеруча игътибарга лаек. Аларда К. Аралбай, Т. Арслан, М. Әгъләм, Р. Әхмәтҗанов, Х. Бәдигый, Р. Бикбаев, Ш. Биккол, Д. Булгакова, Х. Вәлиди, Т. Ганиева, Р. Гаташ, И. Йосыпов, Ф. Максютова, Р. Миңнуллин, М. Ногман, Г. Рамазанов, Б. Рәхимова, С. Сөләйманова, К. Фасахов, С. Хәким, Э. Шәрифуллина һ.б. шагыйрьләр милли үсешкә мәдәнилек, ватанпәрвәрлек аша ирешеп булуын һәм Тукай иҗаты, аның Ватаны поэтик камиллек өлгесе булуын раслыйлар.

Һәр каләм иясенең гомерлек остазына әйләнгән Тукай туганлык, дуслык хисләрен ныгытып торучы учак та ул. Башкорт шаггыйре Г. Рамазанов «Олы кеше» шигырендә самими, чын хисләр белән: «Туган җирне сөеп өйрәндек без, / Сөйгән кебек Тукай Кырлайны», – дип яза. Шунысы да бик мөһим: шагыйрьләр үз хис-кичерешләрен Тукай яшәгән авылларга бәйле образ-сурәтләр ярдәмендә бирәләр, Тукайның милли, халыкчан хис-кичерешләр җырчысы, укучының рухи дөньясын нурландыручы, сафландыручы, яшәештә инсани кыйммәтләрнең өстен чыгуына өметләнгән иҗатчы булуын ассызыклыйлар. «Шагыйрьләрнең туган җирләре» шигырендә Р. Миңнуллин Тукайның туган йортына чиксез ихтирам белән: «Кушлавычка кайтыйк, / Өчилегә – Тукай туган бөек нигезгә!» – дип өнди. М. Ногманның «Һәйкәл янында» дигән шигырендә дә Тукайга килү шундый юллар белән тасфирлана: «Туган җирләреңә – Кушлавычка / Килдек, Тукай, һәйкәл куярга. / Ул истәлек булып синең данны / Алып барсын озак елларга». С. Сөләйманова «Шигърият язы белән» исемле шигырендә кешенең рухи дөньясы байлыгын, күңел киңлеген, хисләренең сафлыгын чагылдыра, үз эчке дөньясының гүзәллегенраслап: «Күпме килде, күпме китте / шагыйрьләр дә җырлары. / Тукай аһәңнәрен отып / калды Кырлай кырлары», – дип яза. Ф. Максютованың «Тукай туган як» исемле шигырендә кешедә булган

уңай сыйфатлар, мәрхәмәтлелек тамырлары шагыйрь өчен тере табигатькә мөнәсәбәттән, туган җир, туган туфрак, моң төшенчәләреннән башлана: «Гел җырлардан тора икән, Тукай, / Туган ягың, урман, кырларың, / Әкиятләрең кебек серле икән, / Кушлавычың, сөйгән Кырлаең». Укучыларның ихтыярын үзенә буйсындырып, Д. Булгакованың «Халкың кеби» исемле шигырендә дә татар шигъриятенең нигезендә яткан моң тасфирлана: «Сине көтә Шүрәлеле кара урман, / Сагыныплар көтә Кырлай. / Халкың кеби, син көчлесең, син моңлысың, / Син шагыйрьсең, Апуш-Тукай!». М. Шабаевның «Тукайны сагыну» шигыренең үзәгендә дә туган җиргә якынлык хисе моң аша тасвирлана: «Ул моң Кушлавычтан башланган да / Өчилегә күчкән, Кырлайга; / Инешләргә иңгән, урманнарга, / Томан булып сарган тугайга». Тукай моңы сәнгать чаралары ярдәмендә шәхес кичереше, киеренке фикер чагылышы булып К. Аралбайның «Тукай маршы» шигырендә мәгърур таулар биеклегенә күтәрелә: «Урый-урый Казан артын, Кырлайны да, / Уралыма талгын, ярсу моң агыла. / Шушы моңны якын күреп, бердәй көтеп, / Балкантау да, Каратау да гел сагына...». Туган җирне олылау – татар поэзиясенең үзәгендә торган олы хис. Тукайга җан, илһам биргән, шатлыкта да, кайгыда да таянычы, өмет йолдызы булып торган Арча якларына мөрәҗәгать итеп Т. Ганиева «Бабич, Тукай» шигырен яза: «...Кырлайда кем хәзер җырлыйдыр? / Бөек шагыйрь Тукай моңы – анда, / Заманалар калбына ул моң, / Кысаларга гына сыймыйдыр». Нәни Габдулланың аяк эзләрен саклаган газиз җирнең кабатланмас табигатен, аның халкын сүрәтләү Р. Бикбаевның «Тукайга» исемле шигырендә кичереш дәрьясы аша үтеп шигъри юлларга күчә: «Үләннәргә кояш нуры белән / Түгелгәндә моңы курайның, / Күк үләндәй сабый чагың кайткан / Кырларыннан җырлы Кырлайның».

Тукайның туган ягы – шагыйрь тормышының иң четерекле һәм бәхәсле якларыннан, аның шигърияте үзенең тамырлары белән туган ягыннан шифа ала. Тукай турындагы шигырьләрнең бер өлеше – аның үзе уйлап чыгарган геройларын яңадан тергезү булса, икенчеләре – шагыйрьне балачагына, Кырлайга «кайтару» белән бәйле, шагыйрь биографиясендәге теге яки бу чорны бүгенге шагыйрь күңеле аша үткәрүгә юнәлдерелә.

Югарыда кителгән әсәрләрдә Тукайның Ватанына мәхәббәт хисе үтә шәхси, кабатланмас булып, лирик геройның күңел кичерешләре аша аңлатыла, ләкин алар берүк вакытта иҗтимагый әһәмияткә дә ия булып тора. Шигырьләрдә мәгънә катламнарының елдан-ел киңәя баруын төп мотивларның гомумиләшә төшүен күрәбез. Шагыйрьләр иҗатында пейзаж лирикасы беренче чиратта аның Ватанга, туган халкына, туган җиренә, бөтен тере табигатькә мөнәсәбәтен колачлый һәм шулар аның шигъри дөньясының асылын билгелиләр.

Тукай иҗаты йөз елдан артык татар әдәбияты тарихын, аның аерым чорларын, шул чорларда иҗат иткән күренекле язучы-шагыйрьләрнең иҗатын тикшерү белән үрелеп бара. Бу ноктадан караганда, Тукай иҗатын өйрәнү тарихи яктан һәм поэтик яктан ике сукмакка аерыла. Шагыйрьнең юбилейлары һәм туган көннәре уңаеннан шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр ел саен матбугатта басылып тора. Г. Тукай – туган телен, үз халкын саклаучы, милләтен бергә туплап, аны яшәтүче, бербөтен итеп торучы рухи көч булып кала.

Хәзерге вакытта шагыйрь биографиясенә, иҗатына караган яңа фактлар ачыла. Детальләр төгәлләнә. Яңа буын шагыйрьләреннән укучы яңа алымнар, заманча сүз көтә. Шагыйрьнең туган ягы гомуммилләт, гомумкешелек,

ватанпәрвәрлек таләпләреннән чыгып сурәтләнә. Әлеге вакытта Тукайга бәйле хезмәтләрне өйрәнү-тикшеренү дәвам итә. Ничек кенә булмасын, Т. Галиуллинның түбәндәге сүзләре әле дә актуаль булып кала: «Тукай иҗатына гомуми уңай мөнәсәбәт сакланган хәлдә дә, һәр чор аны үзенчә бәяли, үз мәнфәгатьләренә якынайтырга тырыша» [1: 28].

Шулай итеп, һәр буын татар шагыйрьләре Габдулла Тукайның туган ягы белән бәйләнешләрын үзенчәлекле шигъри-сәнгати алымнарда чагылдырырга омтылдылар. Югарыда телгә алынган поэтик әсәрләрнең темалары уртак булса да, һәр шагыйрь аны үзенчә күрә, тасвирлый, укучыга төрле тел бизәкләре, сурәтләү чаралары, әдәби алымнар аша ачып бирә. Андагы сюжетлар Тукайның туган туфрагыннан, балачагы үткән Кырлай якларыннан аерылгысыз. Бу иҗат җимешләренең исеменнән үк күренә: «Шагыйрьнең бала чагы» (С. Хәким ), «Килә иде Кырлай юлыннан» (Р. Әхмәтҗанов), «Шагыйрь чишмәсе» (Э. Шәрифуллина), «Шагыйрьләрнең туган җирләре» (Р. Миңнуллин), «Кырлай урманнарында» (Р. Миңнуллин), «Кырлай юлында Сәгъди абзый белән сөйләшү» (Р. Гатауллин), «Земля Габдуллы» (К. Фасахов), «Тукай туган як» (Ф. Максютова) һ.б.

Күзәтүләрдән чыгып шуны билгеләргә була: Тукай турында һәр шагыйрь табигать яшәргән апрель аенда яңа шигырен иҗат итә. Бу күренеш Тукайның туган көнендә ел саен даими рәвештә уздырылып килә торган шигырь бәйрәме белән дә бәйле. Шулай гадәткә кергән – шигырь бәйрәменә җыелуны һәр милләттәш «Тукайга килү» итеп күрә. Мондый шигырьләрдә милләттәшләр татар шагыйре Тукай белән сөйләшә, Тукайдан үзенә сыену эзли, аның туган якларына барып кайта.

ӘДӘБИЯТ


1. Галиуллин Т. Тукай һәм 20 гасыр татар әдәбияты. Тукай и духовная культура XX века: Материалы научной конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Тукая. – Казань, 1997. – С. 28–32.

2. Мин Тукайга киләм: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 192 б.

3. Тукай Башкортстанда / төз. С. Сафуанов – Уфа, 1966.

4. Тукай Г. Исемдә калганнар // Әсәрләр. 4 томда. IV том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 77.

5. Тукайга әйтер сүзем: Башкортстан шагыйрьләренең Габдулла Тукайга багышланган шигырьләре / төз., кереш мәкаләсе язучы А. Хәлиуллина. – Уфа: Матбугат дөньясы, 2017. – 138 б.

6. Тукайга чәчәкләр: шагыйрь турында шигырьләр һәм фикерләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 132 б.


УДК 82.091

## ПОВСЕДНЕВНАЯ ЖИЗНЬ ТАТАРСКОГО МЕДРЕСЕ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ТУКАЯ И Г. ИСХАКИ


***Э.Р. Набиуллина***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



Статья посвящена изучению повседневной жизни в художественном тексте на примере произведений классиков татарской литературы Г. Тукая и Г. Исхаки. В литературных текстах детально прописываются быт и образ жизни учащихся татарских духовных учебных заведений, таким образом авторы затрагивают темы и проблемы, актуальные для своего времени, такие как устаревшая система образования, невежество, отсутствие интереса к новым знаниям и т. д.

**Ключевые слова:** повседневная жизнь, литература народов РФ, татарская литература, Г. Тукай, Г. Исхаки.

The article is devoted to the study of everyday life in a literary text on the example of the works of the classics of Tatar literature G. Tukay and G. Iskhaki. In literary texts, the everyday life and lifestyle of students of Tatar theological educational institutions are described in detail, thus the authors touch upon topics and problems that are relevant for their time, such as an outdated education system, ignorance, lack of interest in new knowledge, etc.
**Key words:** everyday life, the literature of the nationalities of the Russian Federation, tatar literature, G. Tukay, G. Iskhaki.

## Г. ТУКАЙ ҺӘМ Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЛАРЫНДА МӘДРӘСӘ ТОРМЫШЫ

***Э.Р. Нәбиуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Тарихтан билгеле: революциягә кадәр татарлар яшәгән барлык шәһәр, авылларда диярлек мәктәп-мәдрәсәләр эшләп килгән. Татарлар өчен үз мәхәлләңдә уку йорты булдыру зур абруй саналган. Шул чор татар-мөселман кешесенең шәхес буларак формалашуында зур роль уйнаган, татар мәгарифенең нигезен тәшкил иткән мәдрәсә дөньясы, әлбәттә, әдәбиятка да үтеп кергән. Шәкертләр тормышы, мәдрәсә көнкүрешенең кайсыдыр якларын сурәтләгән әсәрләр күп кенә әдипләрнең иҗатында очрый. Гаяз Исхакый – бу теманы киң планда яктырткан сирәк авторларның берсе. Аның «Мулла бабай» (1910) романын «унтугызынчы йөз азагы һәм егерменче йөз башы мәдрәсәләр тормышын яктырту буенча энциклопедияк әсәр» [4: 409] дип атарга була. Роман китап булып басылып чыккач та, әсәрнең әдәби, иҗтимагый, тарихи, лингвистик әһәмиятен ассызыклап язылган мәкалә дөнья күрә: «Менә безнең аңлавыбызга күрә, мөхәррирнең “Мулла бабайны” язудан мороды … голяма-шәкерт сыйныфының типларының бер энциклопедиясе ясау булырга кирәк. ... Чынлап та әгәр мөхәррирләремез ул типларны шулай язмаган булсалар иде, безнең бу кыяфәтле кешеләремез бөтенләй югалырлар иде» [3].

Гаяз Исхакый мәдрәсә көнкүреше белән яхшы таныш, «Мулла бабай» романында әдип нигездә үзе белгән иске мәдрәсәдәге шәкертлек тормышын сурәтли. Ул төрле детальләргә игътибарлы, һәр нәрсәне документаль төгәллек белән теркәп калдырган. Әсәрнең сюжетын автор берничә катламда тәкъдим итә: иң элек ул – төп герой Хәлимнең 12 ел дәвамында төрле мәдрәсәләрдә белем алып, гади авыл мәдрәсә шәкертеннән «пишкадәм» дәрәҗәсенә күтәрелүе һәм үз авылларына имам булып кайтуы. Икенчедән, Хәлим укыган төрле дәрәҗәдәге мәдрәсәләрнең эчке тәртибе. Болар – авыл, кечкенә шәһәр мәдрәсәсе һәм татарлар өчен белем, мәдәният учагы булган Казан мәдрәсәсе. Биредә Бохара мәдрәсәләре дә ул чор шәкертләре өчен «хыял» образ буларак искә алына. Шулай ук автор мәдрәсә тормышын төрле яктан тасвирлап, бүлекләрнең тематикасын да төрләндерә: әсәрнең төрле өлешләрендә шәкертләрнең көндәлек уку тормышын, ял көннәрен, кыш һәм җәйге чорын, укудан тыш чараларын, мәдрәсәләр арасында «монәзәрә» оештыруларын, төрле тип муллаларны күзәтергә була.

Шәкертлек еллары ике гасыр чигенә туры килгән, татар мәгарифе, үсеше өчен җанаткан, проблемаларын күрсәтеп, аны үзгәртергә чакырган ша-

гыйрь Габдулла Тукай да үз иҗатында мәдрәсә темасына еш кына мөрәҗәгать итә. Аның «Авыл мәдрәсәсе», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре», «Таз» һәм башка әсәрләрендә сурәтләнгән чынбарлык, проблемалар Исхакыйның романы белән аваздаш.

Инде әсәрләрнең үзенә килик. Татарлар арасында укымышлы, белемгә омтылучы кеше һәрвакыт зур хөрмәт казанган. Белем учагы булган мәдрәсәгә карата да аерым игътибар бирелгән, әсәрдә хәтта аны изгеләштереп карау да сизелә, авыл халкы бер-бер артлы йомышлары үз белән мәдрәсәгә «мөрәҗәгать итә»: «*Бер карчык та, «кызым кияүгә тизрәк чыксын» дип, мәдрәсәнең ике ватык күзенә карындык та китереп корды»* [4: 221]. Һәр ана үзенең баласының бәхетен белем туплап, мулла-галим булуда күргән:

*Әллә-бәлли итәр бу,*
*Бохарага китәр бу;*
*Бохарадан кайткачтан,*
*Мулла булып җитәр бу.*
(«Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре»)

Хәлимнең дә эти-әнисе баласының мәдрәсәдәге уңышларына куанып, аны еллар буена һәрьяклап тәэмин итеп тора. Хәтта җәйге ялларга кайтканда, «шәһәр шәкерте»нең дәрәҗәсен генә белеп, аңа артык эш тә кушылмый. Мәдрәсә шәкертләренә карата уңай мөнәсәбәтне бәйрәм көннәрендә, гаетләрдә, үлем-китем булганда да күрергә мөмкин: аларга бу вакытта мулдан ризык таратыла, хәер-сәдака бирелә.

Бу, әлбәттә, шәкерт тормышының тышкы күренешләре генә, ә мәдрәсәнең ябык ишекләре артындагы тәртипләр үзгә. Иң элек күп гасырлар буена мәдрәсә әһелләре арасында билгеле бер иерархия, шәкертләрнең яшенә бәйле үз-үзеңне тоту кагыйдәләре яшәвен искә алырга кирәк. Өлкән шәкертләр – «хәлфәләр» кечеләренә белем бирә, мәдрәсә җитәкчелегенә якын мөнәсәбәттә була. Укудан тыш вакытларда, мәдрәсәнең көндәлек тормышында үз дәрәҗәңне билгеләр өчен шактый тырышырга кирәк. Гади «мужик» гаиләсеннән чыгып та, белемле булып, югары баскычка күтәрелергә мөмкин. Шул рәвешле татар мәдрәсәләрендә гыйлемлелек барыннан да өстен куелган: *«Хәлим, бу бүлешүнең яшь белән түгел икәнене күреп, үз иптәшләре арасында бу – сабагы белән дә бер дәрәҗәдә икәнене күреп, үзене-үзе яхшырак хис итә башлады»* [4: 245]. Тукай да шигырендә зур авырлык белән алынган белемнең матди байлыкка караганда өстен булуын ассызыклый:

*Сәнең фәкърең – дорыр фәхрең, онытма;*
*Моның дик юк фаразла кайгы йотма.*
*Сәнең бу вардыгың юл – раһе әслаф;*
*Бу юл илә йитешмеш җөмлә әшраф.*
(«Шәкерт, яхуд бер тәсадеф»)

Моңа бәйле романның буеннан буена ике төрле тип, ике дөнья капма-каршы куеп бирелә: «мужик» һәм укымышлы кешеләр (мәчет, мәдрәсә әһелләре) – әлбәттә, соңгылары беренчеләреннән өстенрәк. Шуңа күрә Хәлим дә үзен шушы өстен дәрәҗәдәге җәмгыятьтә күрергә тели: *«...күңеленнән мужиклыкны сөйми, ... киләчәктә мужиклыктан чыгуны ... уйлый башлады»* [4: 247]. Аның үсеш баскычы берничә этапта тәкъдим ителә: җәдид (яңа килгән) – шәкерт – тырыша торган – белә торган: *«Шәрикләр арасында элгәре «тырыша торган», ахырдан «белә торган» исемен алды.*

*Үзеннән элгәре «мужик» дип бер туктамаенча көлә торган бер мулла малаена да өйрәтерлек булды»* [4: 245]. Мәдрәсәдә төпле белем алган, «мужик» арасыннан чыккан кеше дә шушы өстенлекле дәрәҗәгә җитә алган. Иске татар мәдрәсәләрендә шәкертләр арасында интеллектуаль ярышлар – «монәзәрәләр» оештырыла торган булган: шәкертләр мантыйк һәм дин белемендә көч сынашканнар. Хәлим шушындый ярышларда катнашып, «монәзәрәче» исеменә дә лаек булган. Ләкин мәдрәсәдә төрле шәкертләр бар: Хәлим кебек өстенлекне белемдә күрүчеләр янәшәсендә «икмәк черткечләр» дә шактый яшәгән. Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигыре нәкъ икенчеләргә аталып язылган кебек:

*Күп яттык без*
*Мәдрәсәдә,*
*Аңламадык*
*Бер нәрсә дә;*
*Селкәнмәдек*
*Таш төсле без,*
*Җилбер-җилбер*
*Җил бәрсә дә.*

Шигырьдә ялкау шәкертләрне тәнкыйть итүдән тыш аларга «гыйлем укыткан» хәзрәт, муллаларга карата да ризасызлык белдерелә:

*Күрдек анлар-*
*дан тик корсак,*
*Алай борсак,*
*Болай борсак;*
*Ай-һай тирән*
*Бирән корсак,*
*Туймас корсак,*
*Тулмас корсак.*

Алар нигездә тар фикерле, яңа белемнәргә чик куючы итеп күрсәтелә һәм бу мәдрәсәдә оештырылган тәртипләрдә сизелә: биредә уен коралларында уйнау, чит әдәбиятны уку, чит тел өйрәнү тыелган эш санала. Исхакый татар авылларындагы төрле тип муллаларның, мәхәллә халкы тормыш-гамәлләрен чагылдыру өчен шәкертләрне монәзәрәгә дип юлга чыгара. Биредә без «ат җене» кагылган надан хәзрәт; күп китаплар укып та, аны гамәлдә куллана белмәгән; артык вакчыл, халык тормышыннан ерак булган муллалар белән танышабыз.

Мәдрәсәдә уку-укыту системасына күз салсак, шәкертләр үзләре аңламаган китаплар өйрәнергә, таныш булмаган сүзләрне ятларга тиеш булалар: *«Хәлим, бу сүзләрдән бер нәрсә аңламаса да, хәлфә артыннан буны да әйтте»* [4: 232]. Шәкертләрнең белемнәре алар укыган китап санына бәйле бәяләнә. Мәдрәсәдә көн тәртибе якынча болай оештырылган: *«Һәркөнне, иртә белән чәй эчкәч, хәзрәт керде; хәзрәт чыккач, кайсы көннәрне аш ашалды; кайсы көннәрне чәй эчелде. Чәйдән соң суга барылды; намазлар укылып, тагы чәй эчелде; хәлфәгә сабакка утырылды; хәзрәт керде; кич булды; йокларга ятылды»* [4: 246].

Шәкертләр буш вакытларында, хәзрәттән качып кына, күңел ачу «калпания» (күрәсең, компания сүзеннән) чараларын оештыралар һәм бу чараларда һәркем яңача, башка яктан ачыла: *«...һәркөн сабак тыңлатканда сугыла торган бер әллә нинди мәһдүм дә бик шәбәеп йөри. Әнә теге аксак та,*

*үзене-үзе бик зур иттереп, һәр кешегә кушып, әмер итеп йөри»* [4: 240]. Бу бәйрәмдә иң тәмле ризыклардан табын әзерлиләр, ярышалар, бииләр, тамаша куялар, уен коралларында уйныйлар. Менә шушындый «калпания»ләрдә катнашкан шәкерт дәрестә ишетмәгәннәрен ишетә, дөньялыкта күрмәгәннәрен күрә, яңа нәрсәләрне үзләштерә башлый – шул рәвешле мәдрәсәдә төрле яклап тәрбия, белем ала, төрле өлкәләрдә ачышлар ясый. Моңа карамастан, Хәлим зур шәһәр мәдрәсәсенә – Казанга омтыла, үзен биредә тәмам белемле шәхес булырмын дип өметләнә һәм, хәзрәтенең фатихасын да алмыйча, провинциаль шәһәр мәдрәсәсен ташлап, калага чыгып китә:

*Хуш, хуш!*
*хәзрәтләр,*
*без киттек;*
*Сездән изге-*
*лекләр көттек;*
*Көтмәдек тү-*
*гел, күп көттек;*
*Киттек шул без,*
*Инде киттек.*

(«Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?»)

Тукайның бу шигыре дә нәкъ менә «Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән Уральскиның «Казан» кунакханәсенә күчкән көннәрендә иҗат ителгән. Күрәсең, кичәге мәдрәсә шәкерте шулай ук уку-укытудагы тәртипләргә ризасызлык белдереп, аны ташлап китә.

Ахырдан Хәлим шәһәр мәдрәсәсеннән качып, калага килгәндәге идеалына ирешә – иске мәдрәсәнең тулы курсын тәмамлаган хөрмәтле кешесе «пишкадәм» булып җитешә. Ә бу – үз чоры өчен иң югары дәрәҗәсе, гарчә тарих, география, чит телләр, медицина һәм башка дөньяви фәннәрдән ул хәбәрдар түгел. 12 ел буе укыган гарәп телендә ул, ниһаять, китаплар укып, аңлый аңлавына чын күңелдән шатлана. Географиядән белемнәре аның шәректәшләр килгән ерак шәһәрләр, ислам мәмләкәтләре дип санаган илләр белән чикләнә: *«Шул "Төрек", "Бохара" мәмләкәтенә әллә кайдан гына "һинд" килеп, мөселман мәмләкәтләре күбәйде. Ул "һинд" дигән сүз йир исемеме, шәһәр исемеме, мәмләкәт исемеме икәнене белмәсә дә ... "һинд басмасы" китаплар күргәне барга ... аны да мөселман мәмләкәтләре арасына кертеп кушты»* [4: 360]. Хәлимнең тарих фәненнән белемнәре аннан да кыскарак: *«Иң әүвәл Адәм галәйһиссәлам булды. Аннан соң сул кабыргадан Хәва яратылды. Аннан ары Нух пәйгамбәр ... хәзрәте Рәсүл, Хәсән, Хөсәен, аннан соң ... бетте»* [4: 361].

Бер яктан караганда, мәдрәсәнең иң белемле шәкерте саналган Хәлимнең бик тар фикерле булуы аптырата да, унике ел буена ул халык арасында зур дәрәҗә казанды бит?! Тик икенче яктан, ул – үз чорының «мәдрәсә җимеше», аңа нәрсә өйрәтәләр, ул шуны сеңдерә.

Шул рәвешле Габдулла Тукай күбрәк мәдрәсәләрдә шәкертләргә аңбелем һәм тәрбия бирүнең кимчелекле якларын ачыктан-ачык әйтеп бирә. Гаяз Исхакый иске мәдрәсәләрдәге тормышны күпмертмичә дә, киметмичә дә, аерым урыннарны яшереп тә калдырмыйча – ничек бар, шулай сурәтли, шул рәвешле аның һәр ягына, шул исәптән җитешсезлекләрен дә күрсәтә. Тик нәтиҗәдә ике әдипнең дә максатлары уртак: яңалыкка ачык булу, мәгариф системасын үзгәртү, уңышлы тәҗрибәләрне кабул итеп, милләтне белемле итү.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахунов А.М. А. Ахунов. Долгое возвращение (135 лет со дня рождения Г. Исхаки) // Казанский альманах. – 2013. – № 11. – С. 128–140.

2. Габдрафикова Л.Р. Повседневная жизнь татарских шакирдов в конце XIX – начале XX в. // Известия Алтайского государственного университета, 2012. – С. 56–61.

3. Җәгъфәр. Гаяз әфәнденең яңа әсәре // Кояш. – 1912. – 24 декабрь.

4. Исхакый Г. Әсәрләр, 15 томда. 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 448 б.

5. http://gabdullatukay.ru/works/poem/

УДК 069.15

## ОФЛАЙН И ОНЛАЙН ПРОЕКТЫ В ЛИТЕРАТУРНОМ МУЗЕЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

***Р.В. Нагимуллина***
*Литературный музей Габдуллы Тукая (Казань)*

В последнее время музеи успешно переносят большинство мероприятий в онлайн, придумывают новые форматы взаимодействия с аудиторией. Статья знакомит читателей офлайн и онлайн проектами Литературного музея Габдуллы Тукая.
**Ключевые слова:** Тукай, музей, экспозиция, проект, онлайн, соцсети.

The cultural sphere supports progress, pushing the boundaries of the usual possibilities towards new things. Among them are museums that successfully transfer most of the events online, come up with new formats for interacting with the audience. The article introduces readers to the offline and online projects of the Gabdulla Tukay Literary Museum.
**Key words:** Tukay, museum, exposition, project, online, social networks.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕНДА ОФЛАЙН ҺӘМ ОНЛАЙН ПРОЕКТЛАР

***Р.В. Нәгыймуллина***
*Габдулла Тукай әдәби музее (Казан)*

Тамашачы музейга белемнәрен тирәнәйтергә, яңа мәгълүмат алырга килә. Мирасханә киңлекләрен өйрәнүдә экспозиция заллары буйлап йөрү, экспонатларны күреп танышу иң отышлысы, әлбәттә. Тирәнрәк кызыксынучыларга өстәмә мәгълүмат бирүдә мультимедиа, интерактив технологияләр ярдәмгә килә. Шулай ук социаль челтәрләрдә онлайн проектлар булдыру да көннән-көн популярлык казана. Бу җәһәттән Габдулла Тукай әдәби музее заманча технологияләр, тирән эчтәлекле һәм шул ук вакытта кызыклы, мавыктыргыч контент тәкъдим итә.

Музейда экскурсантларны робот Апуш каршы ала һәм музейның ачылу тарихы белән таныштыра. Шулай ук Тукай шигырьләрен сөйли. Экспонатлар турында мәгълүмат бирә торган өч телдә «сөйләшүче» роботны балалар гына түгел, өлкәннәр дә ярата.

Экспозиция музей тарихында беренче тапкыр оештырылган бик тә уңайлы «Тукай үзәге» белән башланып китә. Ул бер үк вакытта китапханә дә, экспозиция дә булып тора. Анда 1000 нән артык китап урын алган. Биредә Габдулла Тукайның төрле елларда, төрле телләрдә, төрле шәһәрләрдә нәшер ителгән китаплары белән бергә, аның иҗатына йогынты ясаган һәм туры юл күрсәткән авторларның китапларын да күрергә мөмкин. Алар арасында урта гасыр шагыйре Кол Гали, көнчыгыш шагыйре Суфи Аллаһияр,

тарихчы һәм шагыйрь Таҗетдин Ялчыгол, бөек татар мәгърифәтче-галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдинов, рус әдәбияты классиклары Александр Пушкин, Иван Крылов, Михаил Лермонтов, Лев Толстой, Европа әдәбияты классиклары Вильям Шекспир, Генрих Гейне, Джорж Байрон, Фридрих Шиллер һ.б. бар [5: 4–5].

Монда музей яратучылар тарафыннан бүләк ителгән китаплар да бар. Үзәккә, нигездә, Тукай шәхесе, иҗаты, шагыйрьнең замандашлары турындагы китаплар, галим-өйрәнүчеләрнең хезмәтләре туплана. Моннан тыш, музейга килүчеләрне кызыксындырырлык башка китаплар да кабул ителә. Китапларны кулга алып карарга, кирәксә, өстәл артына утырып укырга мөмкин.

Бу китаплар музейның социаль челтәрләрдәге битләрендә дә күрсәтелә, анда бүләк итүчеләр турында мәгълүмат бирелә, башка әдәбият сөючеләрне дә бу акциягә кушылырга чакыра. Проектка музей яратучы дусларыбыз тагын да активрак катнашырлар дип өметләнәсе килә.

«Тукай үзәге»нә урнаштырылган компьютер һәм башка электрон җайланмалар ярдәмендә Габдулла Тукай сайтына кереп яңалыклар белән танышырга, «Вакыт шкаласы» ярдәмендә шагыйрь белән бәйле вакыйгаларны белергә, «Дөнья картасында – Тукай» проекты аша Казанда гына түгел башка шәһәрләрдә, чит илләрдә Тукай исеме белән бәйле урыннар, һәйкәлләр, оешмалар белән танышырга мөмкин. Электрон китапханә исә Габдулла Тукайның әсәрләрен уку уңайлыгы тудыра. Барлык мәгълүмат та татар, рус һәм инглиз телләрендә тәкъдим ителә.

Экскурсоводтан башка гына музей залларына килгән тамашачылар да Габдулла Тукайның шигырьләрен ишетсеннәр өчен «Милләт үсдекчә үсәр, милләт ашдыкча ашар...» дип аталган төп залда шагыйрьнең иҗатын чагылдырган меппинг эшли. Биредә видеофрагментлар ярдәмендә шагыйрь яшәгән чорны күзалларга, Тукай шигырьләрен рус, татар һәм инглиз телләрендә тыңларга мөмкин.

Музейга барырга мөмкинлеге булмаган тамашачылар өчен хәзерге интернет заманында безгә онлайн проектлар ярдәмгә килә. Габдулла Тукай әдәби музее социаль челтәрләрдә кызыклы язмалар, видео-күрсәтмәләр, онлайн күргәзмәләр тәкъдим итә. Вконтакте, инстаграм челтәрендә музейның үзенең интернет бите булдырылган. Анда һәркөнне яңа язмалар, фоторәсемнәр урнаштырыла, алар ярдәмендә виртуаль рәвештә музейда урын алган экспонатлар, аларның кыскача тарихы белән танышырга мөмкин. Онлайн проект кысаларында музей тарихына кагылган язмалар, ачылыр алдыннан һәм эшләү дәверендә музейда кичерелгән вакыйгалар, төрле елларда эшләгән шәхесләр, музей кунаклары турында кызыклы язмалар тәкъдим ителә.

«Тукай турында замандашлары» сәхифәсе тамашачыларны Габдулла Тукайны күреп белгән, аралашкан кешеләр белән таныштыра, аларның Тукай турындагы истәлекләреннән өзекләр китерелә, фоторәсемнәр бирелә, кызыклы моментлар искә алына. [2: 2 ]

Тагын зур ике проект бар: «Тукайчылар мәктәбе» һәм «Тукай йолдызлыгы».

«Тукайчылар мәктәбе» – музейга килә алмаган тамашачылар өчен уңайлы һәм кызыклы проект. Өйдән чыкмый гына музейның залларын күрергә һәм аның турында мәгълүмат алырга мөмкин. Мәсәлән, «Габдулла Тукай һәм театр» темасында шагыйрьнең Казанга кайту белән аны каршы алган мохит, театр әһелләре белән аралашуы, «Театр» шигыре язылу,

С. Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышлап язылган шигыре – боларның барысы да дәрестә яктыртыла, видео күрсәтмә белән баетыла. Тукайның балачагы, Җаек чоры, Казандагы тормышы, Петербургка сәяхәте, мәхәббәт темасы – аерым дәрес темалары итеп тәкъдим ителә.

«Тукай бүләге лауреаты сүзе» – Г. Тукай әдәби музееның яңа проекты. Айга бер мәртәбә чыга торган видероликта Татарстан Республикасының югары бүләгенә лаек булган әдәбият, сәнгать әһелләре, галимнәр музей экспозициясе фонында киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итеп үзләренең тормышка карашы, кылган гамәлләре, киләчәккә планнары турында сөйли. Бу проект Габдулла Тукай иҗатын күзалларга, лауреатларның бу югары бүләкне алуга керткән хезмәте белән танышырга, бәяләргә мөмкинлек бирә.

Онлайн һәм шул ук вакытта оффлайн формаларны берләштергән проектларның берсе – «Тукай йолдызлыгы». Музейда Г. Тукай белән аралашкан шәхесләргә багышланган аерым зал бар. Экспозициянең түрендә залның күрке – «тылсымлы көзге» тора. Габдулла Тукайның замандашлары музыкаль бизәлеш белән баетылып бер-бер артлы әлеге көзгедә чагыла: Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Камил Мотыйгый, Сәгыйть Рәмиев, Гафур Коләхметов, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Сәгыйть Сүнчәләй... Ә янындагы электрон җайланмада милләтебезнең асыл затлары турында тулы мәгълүмат тупланган. Аларның һәркайсы татар халкының тормышына, милләт язмышына, Тукайның шәхес һәм шагыйрь булып формалашуына, дөньяга карашына йогынты ясаган кешеләр.

Тамашачылар өчен «Тукай йолдызлыгы» темасының интернет киңлекләрендә онлайн видеопроект форматы да алып барыла. Һәрберсе аерым бер шәхескә багышланган музей дәресләренең видеоязмаларда Г. Тукай даирәсеннән булган замандашның фотосы, аның белән бәйле экспонатлар, документлар, истәлекләр тәкъдим ителә. Шагыйрь белән танышу, аралашу дәверендәге кызыклы вакыйгалар бәян ителә. Замандашларның бер-берсенә мөнәсәбәте, бергә эшләгән һәм ял иткән урыннары, сөйләшкән сүзләре аркылы шул заманның әдәби-мәдәни торышын, алдынгы карашлы яшьләрнең яшәү рәвешләрен, кызыксынуларын, гомумән, Тукай яшәгән мохитне күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Апрель аенда Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан онлайн флешмоб оештырыла. Узган ел пандемия белән бәйле чикләүләр чорында «Өйдә Тукайны укыйм» дип исемләнгән флешмобка да киң җәмәгатьчелек актив катнашты. Татарстанда гына түгел, дөньяның төрле шәһәрләреннән Тукай әсәрләрен укып төшерелгән күпсанлы видеолар килде. Алар барысы да Вконтакте, Инстаграм битләренә урнаштырылды һәм караучылар тарафыннан җылы кабул ителде, уңай комментарийлар белән бәяләнде.

Замана үзгәргән саен музей хезмәте дә үсеш-үзгәреш кичерә. Тамашачыларны музейда гына кабул итү заман таләпләренә туры килеп бетми. Музей белән кызыксынучылар, ләкин, мөмкинлеге булмау сәбәпле, килеп карый алмаганнар өчен төрле онлайн проектлар тәкъдим итү уңышлы ысулларның берсе булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Залялова Г.А. Литературный музей Тукая и PR-технологии // Габдулла Тукай и Тюркский мир. Материалы международной конференции. – Казань. 2016. – С. 209–212.

2. Нәгыймуллина Р. Музейга онлайн да барып була // Ватаным Татарстан. – 2020. – 16 ноябрь.

3. Нәгыймуллина Р.В. Тукай үзәге // Мәдәни җомга. – 2020. – № 15–17 апрель.
4. Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма: алты томда / Габдулла Тукай; Татарстан республикасы Фәннәр акад., Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011–2016.
5. Юлъкүрсәткеч. Г. Тукай әдәби музее. – Казан: Фолиант. – 2018. – 48 б.

УДК 82.091

# СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ ИЗУЧЕНИЯ АЗЕРБАЙДЖАНСКО-ТАТАРСКИХ ЛИТЕРАТУРНЫХ СВЯЗЕЙ (на материале творчества Габдуллы Тукая)

***Низами Мамедов Тагисой***
*Бакинский славянский университет (Баку)*

Азербайджанско-татарские культурно-литературные связи давно находятся в центре внимания учёных. Эти связи берут своё начало с XIX в., однако с первых лет XX столетия они ещё более активизировались, благодаря творчеству крупного татарского поэта Габдуллы Тукая, оказавшего ощутимое влияние развитию этих взаимоотношений. Если до 70-х годов личность и творчество Тукая находились в центре внимания азербайджанских писателей, историков, представителей печати, интеллигенции, учёных, то с конца 80-ых годов XX в. Г. Тукай прежде всего интересует наших литературоведов, тюркологов и переводчиков. С указанного этапа В. Кулиев, А. Мамедов, Н. Мамедов-Тагисой, Р. Аскер, А. Биннатова-Ульви, Х. Гумматова, М. Гасанова и др. систематически занимаются проблемами взаимосвязей творчества Габдуллы Тукая с азербайджанской литературой. Исследование творческих взаимосвязей представителей татарской литературы с азербайджанской литературой в наше время входит в новую фазу. Нам думается, что и в последующие годы эти связи получат более приоритетное направление в азербайджанской литературоведческой науке и тюркологии.
**Ключевые слова:** литературные связи, Тукай, современное состояние, литературоведы, тюркологи, приоритетное направление, исследование.

Azerbaijani-Tatar, cultural and literary ties have long been in the center of attention of scientists. Despite the fact that these ties date back to the 19th century, however, from the first years of the 20th century they became even more active, thanks to the work of the great Tatar poet Gabdulla Tukay, who had a tangible impact on the development of these ties. If until the 70s the personality and work of Tukay were in the focus of attention of many Azerbaijani writers, historians, representatives of the press, scientists, then from the end of the 80s of the twentieth century, G. Tukay is more interested in our literary scholars, Turkologists and translators. From this stage, V. Kuliev, A. Mamedov, M. Hasanova, N. Mamedov-Tagisoy, R. Asker, H. Gummatova, A. Binnatova-Ulvi and others systematically deal with the problems of the relationship between the work of Gabdulla Tukay and Azerbaijani literature. The study of creative relationships with Azerbaijani literature is now entering its new phase. It seems that in the coming years these ties will receive a higher priority direction in the Azerbaijani literary science and Turkology.
**Key words:** literary connections, Tukai, current state, literary scholars, Turkologists, priority direction, research.

Азербайджанско-татарские литературные связи имеют давнюю и насыщенную историю. Корни этих связей следует искать глубоко в истории, в частности XIX веке, что, в первую очередь, связано с этногенетическими особенностями азербайджанцев и татар. Эти связи начались ещё тогда, когда выдающийся учёный-лингвист и востоковед Мирза Казем бек в Учёных записках Казанского университета опубликовал свои работы

по истории крымских татар, уйгуров и древних народов Средней Азии. По рекомендации руководства университета он разработал фундаментальный труд «Общую грамматику турецко-татарского языка», которая выдержала несколько изданий на европейских языках. Профессор Мирза Казем бек, прекрасно владея, наряду с родным татарским, персидским, французским и др. языками, а также такими областями наук, как история, право, языкознание и востоковедение, в то же время занимался с подготовкой сочинений сопоставительного изучения русского и восточного языков, готовил труды по арабской литературе, работы относительно сочинений восточных классиков. Его знания в области татарского языка послужили и для определённых знаний в области литературы. Кроме этого, он предпринял попытку совместно с М. Никольским издать в Казани газету «Море новостей».

Основоположник азербайджанской периодической печати Гасанбек Зардаби газетой «Экинчи» («Пахарь») способствовал развитию просветительских тенденций в татарской культуре. Немало было сделано и другим крупным просветителем Исмаилбеком Гаспралы, начавший с 1883 года издания газеты «Терджуман» на крымско-татарском и русском языках. Заметим, что развитию азербайджанско-татарских культурных взаимоотношений способствовал и Юсуф Акчура оглу. Как известно, в числе других представителей азербайджанской, тюркской и татарской интеллигенции, распространявших идеи туречества наряду с профессором Арминием Вамбери, Мирзы Фатали Ахундзаде, Шейхом Сулейманом Эфенди из Бухары, тюрком Ахмед Мидхатом Эфенди, Ахмед Джевдет Пашой, Шейхом Джамалетдином Афгани и другими следует отметить крымских и казанских татар, совместно развивавших национальное своеобразие туречества [25: 6–98].

После закрытия «Экинчи» в Тифлисе братьями Саидом и Джалалом Унсизаде, издавалась недельная газета «Зияи Кавказия», вслед за которой выпускалась новая недельная «Кешкюль», где печатались материалы на разных тюркских языках, из разных регионов. В ней в большей степени увидели свет статьи Исмаил бека Гаспралы. Национальные идеи ещё более укреплялись у издателей этих газет особенно тогда, когда некоторые русские авторы, в том числе Михаил Катков в одной из московских газет выступал критическими статьями в адрес тюрков и мусульман. В тот период И. Гаспралы в газете «Терджуман», наряду с другими регионами, распространял информации из Крыма, Бахчасарая, Казани, Турции, России, Средней Азии, Казахстана, а также из Индии и т.д.

В начале XX в. особо активизируется деятельность Алибека Гусейнзаде крупного поборника идей туречества, призывавший в своих работах сплочению тюркских народов и изучению истории тюрков в журнале «Фиюзат», в газетах «Хаят», «Каспий» и во многих других изданиях. Он же был основоположником создания новых тюркских литератур, в числе которых была и татарская литература [1:7, 9, 13, 15; 10; 2]

В развитии связей азербайджанской литературы с татарской глубоко актуально творчество Габдуллы Тукая. Ещё в годы учёбы в школе Тукай наряду с произведениями русских писателей В.А. Жуковским, А.С. Пушкиным, М.Ю. Лермонтовым и других, знакомился и с поэзией М.А. Сабира, творчество которого оставило неизгладимый след в воображении молодого Тукая. Глубокое постижение особенностей творчества этих поэтов сделало Тукая борцом за свободу и независимость. Острота сатирической поэзии Сабира

дала возможность Тукаю по-новому взглянуть на проблемы татарской действительности.

Знакомясь с творческой судьбой Сабира и Тукая можно найти много точек соприкосновений в жизни и творчестве этих поэтов. Так как для обоих поэтов писать правду о народной жизни было делом первостепенной важности. Тукай, также и как Сабир, хорошо знал проблемы татарской культуры и литературы. Поэтому почти все образцы его пламенных стихов, публицистических произведений и статей вооружали родную литературу новыми жанровыми особенностями и идеями. Вместо религиозно-мистических образов и тем, Тукай предложил совершенно живые формы изображения реальной действительности [7: 3–4].

Здесь же заметим, что активизации азербайджанско-татарских литературных связей помогли и те обстоятельства, что в начале XX в. в Казани жили и учились некоторые представители азербайджанской интеллигенции. Разрабатывая вопросы идейно-творческих взглядов совместно с татарскими друзьями, они стремились к борьбе за объединение и с другими тюркскими народами.

Как верно отмечает Севиндж Алиева, «благодаря произведениям азербайджанских писателей Мирзы Фатали Ахундова, Наримана Нариманова, Джафара Джаббарлы, Наджафа Везирова, посвящённым общественно-политическому, литературно-культурному движению конца XIX – начала XX века, шло формирование татарской сценической литературы и искусства. Азербайджанский театр привлёк татарских артистов своими романтическими традициями. Татарская театральная труппа ставит спектакли с участием азербайджанских артистов… Азербайджанские пьесы активно переводятся на татарский язык и инсценируются» [11].

Достаточно заметить, что драматические произведения Дж. Джаббарлы «Айдын», «Увядшие цветы» и другие не раз с успехом были поставлены в Казанском Государственном академическом театре и в других театрах республики. Театральный критик и переводчик пьесы Дж. Джаббарлы «Айдын» на татарский язык Абдурахман Librarian Мински, касаясь связей Дж. Джаббарлы с татарской культурой, утверждал, что в течение 10 лет пьеса «Увядшие цветы» не сходила со сцены: «Я считаю Джаббарлы, одним из выдающихся театральных деятелей, шагающий в переднем ряду. Джаббарлы бессмертен» [15: 2].

А другой татарский театральный критик и поэт Ренат Харисов, ведя речь о неподдельной искренности и высоте творчества Джаббарлы говорил, что он является драматургом всех эпох, сумевший создать великие страстные сцены. Он создавал подлинный эталон лучших принципов романтического театра не только на азербайджанской, но и во всей мировой театральной культуре [17: 6–7].

Все отмеченное явно подтверждает факт о том, что азербайджанско-татарские культурно-литературные связи развивались и укреплялись с каждым годом. Однако особый импульс этим связям дало творчество Г. Тукая.

О связях Г. Тукая с азербайджанской литературой начала XX в. писали многие. В их числе Мирза Джалил, обративший внимание читателей на кончину Тукая, выражал своё сожаление по поводу его смерти в отдельных номерах журнала «Молла Насреддин». О нём писали Джей Дагестани (точное его имя Джейхун бек Гаджибейли, родной брат Узеир бека Гаджибейли);

публицист, журналист, переводчик Г. Минасазов; выдающийся азербайджанский просветитель, общественный деятель, политик, первый председатель совнаркома Азербайджанской ССР, публицист, писатель, драматург Нариман Нариманов; доктор филологических наук, профессор Панах Халилов, опубликовавший несколько солидных статей, в том числе в связи с 40-летием кончины Габдуллы Тукая; доктор филологических наук, литературовед Г. Мамедли, анализировавший в связи «Молла Насреддина» и Габдуллы Тукая», отдельные проблемы журнала «Молла Насреддин» в его связях с творчеством этого татарского поэта; доктор филологических наук, член. корр. Академии наук Азербайджана Азиз Мирахмедов, изучавший взаимосвязи творчества Сабира и Г. Тукая; уделявший внимание и переводам татарского поэта из сатир Сабира; доктор филологических наук, профессор, заслуженный деятель науки Азербайджана Азиз Шариф, глубоко исследовавший тему «Габдулла Тукай и азербайджанская литература», поэт и переводчик Аббас Абдулла, писавший о некоторых особенностях творчества Г. Тукая и о связях его с азербайджанскими писателями демократического крыла, учившего людей правде, истине и мн.др.

Однако считаем, что в Азербайджане, с конца 80-х годов начинается новый период в изучении развития азербайджанско-татарских связей на материале творчества Габдуллы Тукая. Таким образом, именно с этих времён доктор филологических наук, Лауреат государственной премии Вилаят Кулиев публикует в журнале «Советская тюркология» статью о связях Тукая с азербайджанской литературно-общественной мыслью начала XX в.» [13: 43–50], литературовед-тюрколог Ариф Мамедов представляет материал о связях Габдуллы Тукая с просветительско-религиозным направлением джадидизм [16], востоковед Амир Гасымлы изучает некоторые страницы связей творчества Тукая с азербайджанской литературной средой, уделяя при этом внимание отдельным переводам татарского поэта из произведений Сабира на родной язык [21: 46–51], специалист по азербайджанско-татарским литературным связям Манзар Гасанова в одной из статей детально рассматривает взаимовлияние литератур тюркских народов в связях с творчеством Г. Тукая [4] и т.д.

Старший научный сотрудник отдела Литературы тюркских народов Института литературы им. Низами Гянджеви НАН Азербайджана Хураман Гумматова представляет статью для доклада на Международной научно-практической конференции, посвящённой 125-летию со дня рождения Г. Тукая, проводимой под названием «Наследие Габдуллы Тукая и национально-культурные связи» [6: 119–121].

В том же, 2011 г. по линии Института литературы им. Низами Гянджеви была издана поэма Габдуллы Тукая «Сенной базар, или Новый Кесикбаш» в переводе на азербайджанский язык Хураман Гумматовой [23]. К переводу поэмы предпосланы статьи переводчицы под названием «Поэма Г. Тукая «Сенной базар, или Новый Кесикбаш» на азербайджанском, татарском, тюркском и русском языках, в которых наряду с историей этой легенды, давно бытующей среди тюркских народов, касается и некоторых других вопросов относительно работы над переводом [8: 3–18, 46–73, 92–112, 113–130].

Наряду с названными работами Хураман Гумматова публикует и другие работы, посвящённые отдельным вопросам творчества Г. Тукая, в их числе

статьи «Видимая действительность в поэзии Габдуллы Тукая [9: 436–441] и «Габдулла Тукай и «Молла Насреддин» [7: 155–158].

Систематически и плодотворно работает в области изучения творчества и переводов произведений Габдуллы Тукая на азербайджанский язык исследователь и переводчик тюркских литератур (осуществляющий свои переводы из турецкого, туркменского, узбекского, татарского и других языков) доктор филологических наук, профессор Рамиз Аскер. Плодом его долгих творческих усилий являлась книга переводов с татарского на азербайджанский язык «Габдулла Тукай «Миллетем» [22], к переводу Р. Аскер представил объемистую вступительную статью под названием «Крупный татарский поэт Габдулла Тукай [12: 3–47].

В ряду работ, посвящённых связям Г. Тукая следует отметить работу доктора филологических наук Алмаз Ульви, разрабатывающая тему «Творчество Габдуллы Тукая и узбекское литературоведение» [24: 215–240].

Позднее вышеупомянутый Вилаят Кулиев публикует серию статей «Габдулла Тукай и Азербайджан» (к 125-летию татарского поэта) [14].

Азербайджанско-татарским литературным связям обращается и доктор филологических наук, профессор Низами Мамедов Тагисой. Начиная с 2011 года, он один за другой в азербайджанской печати издаёт материалы, освещающие отдельные стороны связей творчества Габдуллы Тукая с Азербайджаном и азербайджанской литературно-общественной средой [18: 14; 19: 270–284; 20: 34–43].

Заметим, что азербайджанские учёные, занимающиеся отдельными вопросами литературных связей и переводов произведений Г. Тукая на азербайджанский язык, вошли в фундаментальную книгу «Габдулла Тукай. Энциклопедия» [3: 131, 50, 213–214, 412].

В изысканиях современных азербайджанских тукаеведов в центре внимания не только изучения проблем конкретного исторического этапа, но и проблемы взаимовлияния отдельных тем, мотивов и образов с конкретными образцами в нашей литературе. С указанной точки зрения, безусловно, значительный интерес представляют переводы, как мы выше заметили, осуществлённые известным переводчиком из тюркских литератур Рамизом Аскером и Хураман Гумматовой. Если Хураман Гумматова переводит лишь поэму Тукая «Сенной базар, или Новый Кесикбаш» [23: 20–45], представляя при этом оригинал поэмы «Печән базары, яхуд Яна Кисекбаш» [23: 47–72], а также переводы на турецкий язык «Samanpazarı, yahut Yeni Keşikbaş» вместе с предисловием [23: 74–91] и переводным текстом [23: 92–112], и на русском языке [23: 131–150], то Рамиз Аскер в книге «Abdulla Tukay. Millətim» наряду с переводами 70-ти стихотворений на татарском и азербайджанском языках представляет и поэму «Сенной базар, или Новый Кисекбаш» в оригинале и в переводе. Знакомясь с работами каждого из переводчиков, мы приходим к мысли о том, что оба из них стремятся быть как можно ближе к оригиналу. Каждый из переводчиков к задачам перевода произведений Тукая подходит по-своему, сохраняя при этом основополагающие особенности оригинала. Сравнение двух переводов между собой и с оригиналом даёт много пищи для размышления. Исходя из этого, считаем рассмотреть принципы перевода каждого из переводчиков как с точки зрения чисто поэтических задач, так и с точки зрения расхождения между

индивидуальностями и своеобразием переводчиков, чему намереваемся посвятить отдельную статью.

Как мы видим, в последние три десятилетия усиливается интерес наших литературоведов, учёных-тюркологов проблемам связей азербайджанской и татарской литератур на материале творчества Габдуллы Тукая. Нам думается, что глубоко интересных по своей политике произведений Габдуллы Тукая, отличаясь своей оригинальностью и благоуханием, и впредь будут в центре внимания азербайджанских исследователей.

ЛИТЕРАТУРА


1. Bayramlı O. Görkəmli fikir dühası // Əli bəy Hüseynzadə. Seçilmiş əsərləri. – Bakı, «Çaşıoğlu», 2007. – S. 5–20.

2. Veliyev Ş. Füyuzat edebi mektebi. – Ankara: «Ejdat yayınları», 2000. – 388 s.

3. Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казань, 2016. – 864 б.

4. Гасанова М. Факел, «сжигавший людские сердца» (Г. Тукай и азербайджанское литературоведение) // Газета «Каспий». – 2011. – 23 апреля.

5. Гумматова Х. Поэма Габдуллы Тукая «Сенной базар или Новый Кесикбаш» на азербайджанском языке». // Наследие Габдуллы Тукая и национально-культурные связи. Материалы Международной научно-практической конференции, посвящённой 125-летию со дня рождения Габдуллы Тукая, 25 апреля, 2011. – Казань, 2011. – С. 119–121.

6. Гумматова Х. Габдулла Тукай и «Молла Насреддин» // Журнал «Тюркский мир». – 2016. – № 3. – С. 155–158 .

7. Həsənova M. Ön söz // Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında (məqalələr toplusu). – Bakı: «Elm və təhsil», 2012. – С. 3–7.

8. Hümmətova X. Azərbaycan dilində, Tatar dilində; Türk dilində, Rus dilində // Tukay Q. Saman bazarı, yaxud Yeni Kəsikbaş. – Bakı: «Elm və təhsil», 2011. – S. 3–18; 46–73; 92–112; 113–130.

9. Hümmətova X. Abdulla Tukay poeziyasında görünən həyat həqiqətləri // Türk xalqları ədəbiyyatının mənşəyi inkişaf mərhələləri və problemləri. Nizami Gəncəvi adına Ədəbiyyat İnstitutu. Fevral, 2015. – Bakı, 2015. – S. 436–441.

10. Hüseynzadə Ə.Seçilmiş əsərləri. – Bak: «Çaşıoğlu», 2007. – 640 c.

11. Интервью с азербай…m.realnovoe-vremya.ru «Благодаря произведениям азербайджанских писателей формировалась татарская литература» 09.10.2017.

12. Əskər R. Böyük tatar şairi Abdulla Tukay (1886–1913) // Abdulla Tukay. Millətim. – Bakı: «MBM», 2011. – S. 3–47.

13. Кулиев В. Г. Тукай и азербайджанская литературно-общественная мысль начала XX века // «Советская тюркология». – 1988. – № 2. – С. 43–50.

14. Кулиев В. Габдулла Тукай и Азербайджан (к 125-летию татарского поэта // Газета «Зеркало». – 2011. – 23 апреля, 30 апреля, 7 мая.

15. Minski Ə. Teatr nəhəngi (Джаббарлы и его связи с татарской культурой) // «Kommunist» qəz. – 10 oktyabr. – S. 2.

16. Məmmədov A. Abdulla Tukay və cədidizm // «Azərbaycan». – 1996. – May.

17. Tağısoy N. C. Cabbarlının yaradıcılığı digər xalqların səhnəsində // «Kredo» qəz. – 2019. – 18 iyul. – S. 6–7.

18. Tağısoy N. Qabdulla Tukay Yaradıcılığının formalaşmasında Azərbaycan-tatar ictimai-ədəbi fikrinin rolu // «Xalq qəbhəsi» qəzeti. – 2011. – 11 oktyabr. – S. 14.

19. Tağısoy N. Tukay yaradıcılığının formalaşmasında Azərbaycan-tatar ictimai-ədəbi fikrinin rolu. Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında (məqalələr toplusu). – Bakı: «Elm və təhsil», 2012. – S. 270–284.

20. Тагисой Н. Азербайджанско-татарская общественно-литературная среда и творчество Габдуллы Тукая // Учёные записки Бакинского славянского университета. Серия языка и литературы. – Баку. – 2014. – № 2. – С. 34–43.

21. Teymuroğlu Ə. Nəriman Nərimanov və türk xalqları. – Bakı, 2006. – S. 46–51.

22. Tukay A. Millətim / Tərc. edən. R. Əskər. – Bakı, «MBM», 2011. – 268 s.

23. Tukay Q. Saman bazarı, yaxud Yeni Keşikbaş / Tərc. ed. Xuraman Hümmətova. – Bakı: «Elm və təhsil», 2011. – 152 s.

24. Ülvi A. Qabdulla Tukay yaradıcılığı və özbək ədəbiyyatşünaslığı // Qabdulla Tukay Azərbaycan ədəbiyyatşünaslığında. – Bakı: «Elm və təhsil», 2012. – S. 215–240.

25. Yusuf Akçura. Türkçülüyün tarixi. – Bakı: «Qanun», 2006. – 308 s.

УДК 82.091

# О СТИХАХ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ, НАПИСАННЫХ НА РУССКОМ ЯЗЫКЕ

***И.М. Османлы***
*Институт литературы имени Низами Гянджеви Национальной Академии наук Азербайджана (Баку)*

Великий татарский поэт Габдулла Тукай написал прекрасные стихи как на родном татарском языке, так и на русском. Несколько из них он опубликовал в газете «Уралец», изданной на русском языке. Пока известны два его стихотворения, напечатанные в этой газете. В результате исследований стало известно, что в газете «Такамюль», изданной в 1906–1907 годах в Баку, было опубликовано стихотворение великого поэта на русском языке. С точки зрения темы это стихотворение также очень близко к двум предыдущим стихам поэта.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, стихотворение, русский язык, русская литература, газета «Уралец», газета «Такамюль».

The great Tatar poet Gabdulla Tukay wrote beautiful poems in both his native Tatar and Russian language. Some of them were published in the newspaper «Urals» in Russian. So far, two of his poems published in this newspaper are known. As a result of research, it is known that the prominent poet's poem in the Russian language was printed in the newspaper «Takamul», published in 1906–1907 in Baku. From the point of view of the theme, this poem is also very relative to the two previous poems written by the poet.
**Key words:** Gabdulla Tukay, poem, Russian language, Russian literature, «Uralets» newspaper, «Takamul» newspaper.

Интерес великого татарского поэта Габдуллы Тукая к русскому языку и литературе начал проявляться, когда он учился в медресе в городе Уральске. С начала февраля 1895 года он учился в уральском медресе «Мутигия». Его тетя Газиза и ее муж Галиаскер Усманов увидели в нем талант и направили его в русский класс Уральского медресе. В 1897–1898 годах он изучал русский язык у своего учителя, выпускника Оренбургской учительской школы Ахметши Сиразетдинова и через него близко познакомился с русской литературой [2: 293].

В то время на Урале были определенные условия для знакомства Габдуллы Тукая с русской литературой. Так, в день 100-летия со дня рождения великого русского поэта А.С. Пушкина – 26 мая (с новой датой – 6 июня) 1899 года на Урале был открыт Пушкинский народный дом, который стал одним из культурных центров города. «В доме проходились народные чтения, устраивались спектакли. Народная читальня выписывала более десятка журналов. В 1899 году в ней насчитывалось около 2300 книг и посетили ее 22 тысячи человек, 13500 брали книги на дом, другие приходили читать газеты» [2: 279]. Тукай тоже ходил в этот народный дом, где знакомится с произведениями русских классиков, смотрит театральные спектакли.

Тукай быстро выучил русский язык на высоком уровне. Он даже обучал русскому языку других. Позже Наджиб Нигматуллин, работавший буфетчиком в гостинице «Казань», где жил и Тукай, в воспоминаниях о поэте пишет, что Тукай в 1906 году переехал в номер 9 на втором этаже гостиницы «Казань». Мой хозяин Садыг Губайдуллин с намерением дать мне образование или по какой-то другой неизвестной мне причине, платит Габдулле Тукаеву 10 рублей в месяц и просит учить меня русскому языку. Итак, я ходил и учился у Тукая 4–5 месяцев русскому языку, мой хозяин назначил меня в

буфет под тем же номером. Когда я стал буфетчиком, общение между нами и Тукаем увеличилась еще больше» [5: 166].

После окончания медресе в Уральске в 1905 году, Габдулла Тукай работал наборщиком в редакции издававшейся на русском языке газеты «Уралец» в типографии своего учителя и друга Камиля Тухватуллина и научился секретам этого искусства у сотрудника этой типографии Александра Гладышева. «Русским языком Г. Тукай уже в то время владел настолько свободно, что он, по воспоминаниям рабочего А.К. Гладышева, писал стихи на русском языке…» [4: 9]. Это был период митингов, охвативший царскую Россию в 1905 году. И на Урале прогрессивные люди часто выходили на митинги, выступали против колониальной политики царя.

Тукай также впервые вместе с русскими рабочими, с которыми он был знаком здесь, ходил на революционные собрания, участвовал в распространении революционных листовок и деклараций. Александр Гладышев пишет, что в 1905 году на митинг вышли работники типографии, в которой работали оба. Во время митинга Тукай отдал ему это свое стихотворение, написанное на русском языке:

*Отпустили крестьян на свободу*
*Девятнадцатого февраля,*
*Только землю не дали народу –*
*Вот вам милость дворян и царя!*

*Припев:*
*Вставай, подымайся, рабочий народ,*
*Вставай на борьбу, люд голодный.*
*Раздайся, клич мести народной –*
*Вперед, вперед, вперед!*

*Без земли мужики пропадают,*
*А дворяне и рады тому,*
*Что дешевле они нанимают*
*Мужиков на работу свою.*

*Припев:*
*Богачи, кулаки разной своры*
*Расхищают твой тягостный труд.*
*Твоим потом жиреют обжоры,*
*Твой последний кусочек они рвут* [1: 68].

Известно, что в конце 1894 года житель Кушлавуча, который привез Тукая из села Кырлай (из дома Сагди абзы) на Урал, сам Бадреддин Хисаматдинов, дальний родственник Тукая, в 1898 году вместе с семьей переехал на Урал. С этого времени его сын Кямалатдин Хисаматдинов стал близким другом Тукая, жившего в Уральске. В своих воспоминаниях он пишет, что Тукай писал стихи на русском языке и печатал в газете «Уралец»: «Кажется, в то время на Урале выходила русская газета «Уралец». Должно быть, это было время войны между русскими и японцами, однажды Тукай сказал мне: «Я похвалив русских, и показав японцев побежденным, написал стихотворение, отдал редактору газеты». Редактор спрашивает его: «Кто это написал?». «Один ученик», – говорит Тукай. Редактор говорит: «Пусть человек, который писал это, придет сам». Когда Тукай хотел войти, русский, стоящий рядом с дверью, не захотел пропускать его. По словам самого Тукая, во-первых, он был похож на маленького ребенка, а во-вторых, его одежда была

не очень хорошей. Так он и входит. Когда редактор спросил: «Ты написал это стихотворение?» Тукай говорит: «Я написал». После этого редактор говорит так: «Ты всегда пиши такое стихотворение. Мы будем платить тебе пять копеек за каждую строку» [3: 30].

Правда, сегодня трудно подтвердить, сколько стихов опубликовал Тукай в этой газете, так как не все номера газеты «Уралец» есть в библиотеках.

Газета «Такамюль», издаваемая в Баку, также опубликовала на своей странице стихотворение Тукая под названием «Детей продадим ... на позор!», написанное на русском языке:

*Долго стояли они у мечети,*
*Голод созвал их на общий совет:*
*Плачут больныя, голодныя дети –*
*«Хлеба!» а хлеба давно уже нет.*

*Третьяго дня побираться ходили*
*Именем Бога, но Он не слыхал*
*Стоны голодных перед ним заглушили*
*Крики веселья ... пирует Ваал!*

*Долго ли ждать им еще состраданья?*
*Ждали, терпели, но хватить ли сил?*
*Скоро умолкнуть глухия рыданья;*
*Скоро утихнут ... под сенью могил!*

*Злая насмешка: и смерть и свобода!*
*Все, что добились тяжелой борьбой!*
*Братья, да нет ли другого исхода?*
*Как расквитаться с суровой нуждой?*

*Долго стояли они у мечети…*
*Родина! есть ли более укор?*
*Пусть же идут наша юныя дети*
*Прочь от голодных отцов – на позор!*

*Боже! они дочерей продавали…*
*Слезы лилися из впалых очей.*
*«Слава Аллаху!» – лишь дешево брали:*
*Ну, да, лишь сбыть бы товар поскорей!* [6: 5].

Правда, в газете не указали, кто автор стихотворения и кем было отправлено стихотворение из Казани в редакцию. Гипотеза о том, что это стихотворение могло принадлежать Тукаю основана на его близости по идее и тематике к более чем десятку похожих стихотворений, опубликованных в газете «Такамюль».

ЛИТЕРАТУРА

1. Александр Гладышев. Шәкерт тә, остаз да // Тукай турында истәлекләр. Җыентыкны төзүчеләр һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 67–70.

2. Габдулла Тукай: жизнь и творчество. Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886–1907). – Казань, 2018. – 448 б.

3. Хисаметдинов Камалетдин. Бергә булган чаклар // Тукай турында истәлекләр. Җыентыкны төзүчеләр һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр Ибраһим Нуруллин, Риф Якупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 27–30.

4. Нафигов Р.И. Тукай и его окружение. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 207 с.

5. Нәҗип Нигьмәтуллин. Габдулла Тукай Уральскда (Исемдә калганнар) Мотыйгулла Төхфәтуллин истәлекләре // Тукай – ядкярләрдә. 2 томда. 1 т. / төзүчеләр: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 166–168.

6. «Təkamül» qəzeti. – Bakı. – 11 fevral 1907. – № 8. – S. 5.

УДК (054)821.512.145

# ГАЗЕТА «АЛЬ-ИСЛАХ» И ТУКАЙ

***З.З. Рамеев*** *(Казань)*

В статье изучается деятельность Тукая, связанная с газетой «Аль-ислах». Дается краткая характеристика публикациям поэта на страницах этого издания, так же автор приводит примеры рецензий и др. статей, посвященных произведениям и изданным книгам Тукая.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, «Аль-ислах», Ф. Амирхан, татарская периодика, национальная литература.

The article examines the activities of Tukay associated with the newspaper «Al-Islah». A brief description of the poet's publications on the pages of this publication is given, as well as the author gives examples of reviews, etc. articles devoted to the works and published books of Tukay.

**Key words:** G. Tukay, «Al-Islah», F. Amirkhan, Tatar periodicals, national literature.

# «ӘЛ-ИСЛАХ» ГАЗЕТАСЫ ҺӘМ ТУКАЙ

***З.З. Рәмиев*** *(Казан)*

1907 елның маенда «Фикер» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдид» журналы чыгудан туктавы сәбәпле (икесенең дә мөхәррире һәм нашире – Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин), Уральскида биш ай чамасы гомерен вакытлы матбугат мәйданыннан читтә уздырырга мәҗбүр булган Тукай октябрь башларында, ниһаять, Казанга кайтып җитә. Тукай кайткан вакытларда Казанда шагыйрь каләменнән чыккан шигырь һәм мәкаләләре урнашырдай «Йолдыз», «Бәянелхак», «Казан мөхбире» газеталары да басылган. Әйтергә кирәк, алар тоткан мәсләк-позицияләр белән Уральскида чагында ук шактый таныш булган Тукай – әүвәл Казанга аяк басуга дип әйтергә ярый – «Әл-ислах» газетасын нәшер итү эше белән мәшгуль даирәгә килеп эләгә. Әлбәттә, монда, Тукай әле Уральскидан чыгып киткәнче үк, Вафа Бәхтияровның (газетаның булачак рәсми редакторы һәм нашире) аңа ачык хат язуы да билгеле бер роль уйнагандыр. 1907 елның 25 апрелендә Казан губернаторы тарафыннан рөхсәт бирелү белән, В. Бәхтияров «каләмнәре белән мәгълүм булган» язучыларга, шул исәптән, Уральскидагы татар вакытлы матбугатындагы эшчәнлеге белән инде киң танылып өлгергән Тукайга да мөрәҗәгать иткән һәм аннан «Берничә номер газетаңыз чыкмыйча торып, берни дә әйтә алмыйм, үзем көзгә таба Казанга барып чыгачакмын, шунда сезнең белән сөйләшермен» [2: 375] дигән җавап алган була. Тукай Казанга кайтып ирешкән чакларда газетаның ике номеры инде чыгып өлгерә. Беренчесе баш мәкалә рәвешендәге «Казан, 3 нче октябрь» исемле язма белән ачылган. Җиңел аңлаешлы телдә, акцентларны ачык күрсәтеп язылган җыйнак кына текстта татар мәгарифе алдында торган бурыч-максатлар шәрехләнә. Иң мөһимнәре: «Татарның мәгыйшәтене асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк!»; «...тәрбия вә гыйлемханәләремезне әсасеннән ислах итәргә кирәк!»; «икътидарлы, гайрәтле, зыялы татарлар чыгара торган мәктәп-мәдрәсә тәртибе, фәне, мөдәррисләре кирәк!» Билгеле ки, Тукай өчен нәкъ менә бу газета белән хезмәттәшлек итү перспективасы ачык күренеп торган.

«Әл-ислах» газетасы тирәсенә тупланган, аның мәсләген яклаган яшь татар зыялыларын «ислахчылар» дип атап йөртү гадәткә кергән. Әйтергә кирәк, бу демократик матбугат органы кинәттән генә пәйда булмый, аны

гамәлгә кую юлында беренче адым 1905 елда ук ясала: 29 ноябрьдә легаль булмаган, атналык дип уйланылган, гектографик ысул белән әзерләнгән җилем басма – кулъязма «Әл-ислах» газетасы чыга башлый. Ул 1904 ел ахырларында Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә барлыкка килгән, тиздән татар шәкертләренең иҗтимагый, мәдәни, мәгърифәти мәнфәгатьләрен чагылдырган яшерен оешма органы вазыйфасын башкара. Аның төп максатлары – татар мәктәп-мәдрәсәләрендәге укыту системасын үзгәртеп кору, дөньяви фәннәргә зуррак урын бирү, исламият фәннәрен укытуны яңарту, гомумән, татар мәгърифәтен заман таләпләренә туры килердәй рәвешкә китерү. (Шуңа охшаш фикерләр Тукайның «Ислахчыларга» исемле шигырендә дә әйтелә. Ул беренче мәртәбә «4 нче дәфтәр»дә басылган (китапның «Теркәү дәфтәре»нә язылу вакыты – 1908 елның 6 гыйнвары). Билгеле ки, ул элегрәк, газета чыга башлаган айларда ук язылган). Әлеге оешманың эшчәнлегендә җитәкчесе Фатих Әмирхан аеруча зур роль уйный. Касыйм, Оренбург, Троицк, Уфа, Чистай һ.б. шәһәрләрдә аның филиаллары да барлыкка килә. Ислахчылар 1905–1907 елгы инкыйлабый хәрәкәтләрдә бик актив катнашалар, хәтта Казанда шәкертләр забастовкасы да була, ике мәртәбә Бөтенроссия татар шәкертләре съезды чакырыла. Бераздан оешма яшәүдән туктаса да, аның Казандагы тарафдарлары, шәһәрдә чыга башлаган атналык «Әл-ислах» исемле гыйльми, әдәби газета тирәсенә тупланып, эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

«Әл-ислах» газетасы 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр, Вафа Бәхтияров мөхәррирлегендә һәм наширлегендә Казанда чыга, барлыгы 68 саны дөнья күрә. Аның библиографик күрсәткечен (Казан университеты нәшрияты, 1991, 128 б.) төзегән Раиф Мәрданов газетаның журнал форматында чыгарылуын (16 битле), аны чынлыкта Ф. Әмирхан һәм Г. Тукай җитәкләвен, андагы мәкаләләрнең эчтәлеге күпкырлы булуын искәртә.

Газетада Тукай каләменнән чыккан беренче язма – «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер» мәкаләсе. В. Бәхтияров үзенең истәлекләрендә билгеләп үткәнчә, беренче очрашу вакытында Тукай газета эшчәнлеге белән кызыксына, җавабында В. Бәхтияров аны икәү генә (Әмирхан белән) алып баруын әйткәч, шагыйрь: «Алай булганда, мин сезнең өченчегез булам инде» – дип куя. Бәхтияров шунда ук, рәхмәт әйтеп, газетаның «өченче номерына берәр нәрсә язуын» үтенеп тә өлгерә [2: 375]. Газетаның беренче һәм икенче саннары белән танышып алган Тукай әлеге мәкаләне яңа санга тиз вакыт эчендә язып та биргән, күрәсең. «Әл-ислах»та әсәрләре басылган авторлар даирәсен күздән кичереп чыкканда, аның сәхифәләрендә Тукай әсәрләренең 53 мәртәбә басылуы күренә, барыннан да бигрәк шигырьләре урын ала: шагыйрьнең төрле псевдонимнар астында кайбер саннарда 3 әр шигыре урын алган, 1908 елда алар аеруча еш басыла. Шул рәвешле, Тукай «Әл-ислах»-ның «даими язучыларыннан булып китә».

Бу вакытларда Казандагы Шәрәф матбагасы «Шигырьләр көтепханәсе» исеме белән шигъри җыентыклар сериясе бастыра башлый. Аның 3 нче һәм 4 нче «дәфтәр»ләре сыйфатында Тукай шигырьләре дә дөнья күрә. Газетаның актив авторы – танылган шагыйрьнең әсәрләре, ниһаять, бу рәвештә дә укучыларга тәкъдим ителү, билгеле ки, «Әл-ислах»ны чыгаручыларны битараф калдырмаган. Болай да һәр санында диярлек яңа китаплар турында реклама тибындагы язмаларга, бәяләмәләргә урын биреп барган газетада укучыларга Тукай шигырь китаплары хакында да мәгълүмат әледән-әле

җиткерелеп тора. Мәсәлән, газетаның 1907 елгы 8–12 нче, 1908 елгы 13, 14 нче санында – «Габдулла Тукаев шигырьләре (3 нче дәфтәр)», 1908 елгы 15, 16–18 нче санында – «Габдулла Тукаев шигырьләре (4 нче дәфтәр)», 1909 елгы 58, 60, 61, 63 нче санында – «Габдулла Тукаев диваны (8 нче дәфтәр)», 1908 елгы 48, 49, 50, 51, 52, 53–55 саннарында «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» турында хәбәр ителә.

«Әл-ислах» газетасының һәр номерында диярлек төрле эчтәлекле китапларга бәяләмәләр дә басылып торган. Әйтергә кирәк, күбесенең авторы – «Дамелла». Бу имзаны Фатих Әмирхан нәкъ менә «Әл-ислах»ны чыгарганда кулланаышка ала (бөтен иҗат чорында исә әдип унбишләп псевдоним кулланган [4: 231–234]). Шул елларда ул үзен күренекле прозаик, публицист, журналист итеп кенә түгел, бәлки әдәбият тәнкыйтьчесе сыйфатында да таныта. Габдулла Тукай иҗатына беренче җитди бәя бирүче итеп тә нәкъ менә Фатих Әмирханны санарга кирәк. Тәнкыйтьче сыйфатында да ул «Әл-ислах»ны чыгару елларында таныла башлый. «Әл-ислах»та шигырьләре басылу чорында Тукайның сигез китабы да (өчесе, авторы тарафыннан беркадәр үзгәртелеп, ике басмада нәшер ителә) укучыларга барып ирешкән. Аларның беренче басмаларына иң әүвәл башлап бәяләмәләр язып бастыручы – Фатих Әмирхан.

Әле Уральскида чагында ук әсәрләрен китап итеп бастыру ниятеннән Казандагы Шәрәфләр белән элемтәдә торган Тукайның 1907 елда, ниһаять, ике китабы басыла: «Г. Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. Беренче кыйсем. «Шәрәф» матбагасы нәшере, 48 бит) һәм «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем. «Шәрәф» матбагасы, 56 бит).

«3 нче дәфтәр» басылу турындагы беренче хәбәр «Әл-ислах»ның 1907 елның 26 ноябрендә (дүшәмбе; 8 нче санда) бирелгән. Ф. Әмирхан («Дамелла») үз бәяләмәсен исә газетаның киләсе 9 нчы санына ук (дүшәмбе; 3 декабрь) өлгерткән (бу санда аның ике публицистик мәкаләсе дә урын алган). Ул, «3 нче дәфтәр»дә «һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлар» булуны әйтеп, анда иске төрек телендә язылган шигырьләрнең дә күп урын алуын ошатмый, «Шүрәле», «Пар ат», «Теләнче», «Кемне сөяргә кирәк» кебек шигырьләрдә исә «Габдулла әфәнде – бөтенләй татар шагыйре шагыйре, татардыр» дип белдерә.

Озак та тормыйча, Тукайның икенче шигырьләр җыентыгы – «4 нче дәфтәр»е басылып чыгуы «Әл-ислах» газетасының 1908 елгы 15 нче (14 нче гыйнвар), 16 нчы (21 гыйнвар), 17 нче (2 февраль) һәм 18 нче (9 февраль) саннарында хәбәр ителә. Китапка бәяләмәне бу юлы да Ф. Әмирхан үзе («Дамелла») яза һәм аны газетаның 17 нче (2 февраль) санына урнаштыра. Җыйнак кына язылган әлеге текстта Тукайның әүвәлге мәҗмугасы («3 нче дәфтәр») «бөтен татар матбугаты тарафыннан иң гүзәл тәкъризләр белән» каршы алынганлыгы искәртелә. Аныңча, бусында да гүзәл шигырьләр күп, моңа мисаллар итеп бәяләмәдә уннарча әсәрнең исемнәре атала, шул ук вакытта Ф. Әмирхан китапка «Охшату» һәм «Мужик йокысы» шигырьләре кертелүгә каршы да чыга (соңгысындагы «Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән юлларны ошатмый).

Ф. Әмирхан бу бәяләмәсен «халис татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәбез» дип тәмамлаган. Аның бу теләген Тукай игътибарсыз

калдырмаган: мәсәлән, ул 1908 елның октябрендә «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын иҗат итә. Замандашлары истәлекләрендә аны язуга Казанның Никитин циркында атаклы төрек көрәшчесе Карәхмәт чыгыш ясый башлавы этәреш биргәнлеге әйтелә. Карәхмәтле тамаша Казан татар тамашачыларын аеруча кызыксындырган. Моның шаһиты булган Тукайда сатирик әсәр (назыйрә) язу уе туа. Атаклы «Кисекбаш» дастанына ияреп иҗат иткән әсәрен «Татар әдәбиятын сөюче иптәшләр түгәрәге»нә җыелганнарга – ислахчыларга укып күрсәткәч, «һәммәсе Тукайның укып бетергәнен көтә алмый, укыган арада туктатып кул чабалар, Тукайның бетмәс-төкәнмәс һөҗүви куәте белән восторгка киләләр» [5: 272] һәм аны, шактый күләмле булуын күреп, журналда түгел, бәлки аерым китап итеп бастырырга тәкъдим итәләр. Тукай поэманы 1908 елның 14 октябрендә Купеческое собрание залында «Әл-ислах» газетасы файдасына уздырылган әдәбият кичәсендә дә укый (Г. Шәрәф истәлегендә кичә ул вакытларда өмид ителмәгән яхшы сбор бирә, дигән мәгълүмат бар) [5: 272]. Ф. Әмирхан үзе исә Исмәгыйль Аитовка 1908 елның 26 октябрендә язылган хатында бу кичәнең «Әл-ислах»ка бары сигез сум файда китерүен әйтә [1: 259]. Поэма «Шәрәф» матбагасында кыска гына вакыт эчендә ике мәртәбә басылып чыккан. Бу турыда «Әл-ислах»ның 1908 елгы 13 октябрь – 31 декабрь (48–55 нче) саннарында (сигез мәртәбә) хәбәр ителә. «Дамелла»ның (Ф. Әмирханның) поэмага бәяләмәсе дә шул ук вакытларда языла һәм «Әл-ислах»ның 1908 елгы 24 ноябрь (№ 52) санында чыга. Аныңча, әсәр «татар әдәбиятында шигырь белән язылган көлкеләрнең иң мөкәммәл вә максудына иң муафикъ чыкканыдыр». Бәяләмә «Тукаевның бу әсәрен һәм «Яшен»дә көлке шигырьләрен укый торгач, аңар татар галәменең иң оста юмористы диясем килә башлады» дигән юллар белән тәмамлана.

1909 елның башында «Үрнәк» матбагасында Тукайның өченче шигырь мәҗмугасы – «Габдулла Тукаев диваны» басылып чыга. Аңа язган бәяләмәсендә Ф. Әмирхан, чын, милли шагыйрь булып җитешүенә кадәр, Пушкинның «шәкертлек» дәвере булганлыгын искәртеп, Тукайның да гарәп, төрек, соңрак рус шагыйрьләре тәэсирен татыганлыгын әйтә һәм бу «тәэсирләр арасында «Тукаев шигырьләрендә <...> хосуси татарлык рухының аңкуы»на басым ясый. Бу – Тукаевның «озакламый камил мөстәкыйль татар шагыйре булачак икәнчелеген күрсәтәдер», ди Ф. Әмирхан, ә инде «мөстәкыйль шагыйре булган бер әдәбият – бәхетле әдәбият».

Кызганычка каршы, «Әл-ислах» газетасы, 1909 елның 22 июлендә соңгы – 68 нче саны чыгу белән, «цензура кысу һәм акча кытлыгы сәбәпле» [3: 135] тукталып кала. Аның битләрендә хикәяләре, шигырьләре, мәкаләләре, бәяләмәләре әледән-әле басылып тору ике әдипне бер-берсенә бик тә якынайткан. Әсәрләрен укучылар игътибарына тапшыру мөмкинлеге икесе өчен дә кинәттән чикләнеп куйса да, бу хәл озакка бармаган: тиздән Г. Камал һәм Тукай катнашлыгында «Ялт-йолт» журналы чыга башлый, аның битләрендә Ф. Әмирхан язмалары да урын ала. Гомумән, аларның матбугат мәйданында да эчкерсез аралашып, аңлашып яшәүләре Тукай вафатына кадәр дәвам иткән.

ӘДӘБИЯТ


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томда. 4 т: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте. Монографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.

2. Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр // Тукай – ядкәрләрдә: 2 томда. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 375 –377.

3. Нуруллин И. Фатих Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 288 б.
4. Рәмиев З. Әдәбиятчы-текстолог язмалары. – Казан: Ислах, 2014. – 436 б.
5. Шәрәф Г. Тукай турында истә калганнар // Тукай – ядкәрләрдә: 2 томда. 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 270–274.

УДК 82.091

# ТВОРЧЕСТВО ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ: ПРОЕКЦИИ НА РАЗВИТИЕ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ (на примере творчества Хади Такташа в общественно-политическом контексте XX века)

***В.И. Рогачев, К.А. Егорова***
*МГПУ им. М.Е. Евсевьева (Саранск)*

Статья посвящена становлению татарской литературы нового времени в контексте с творчеством Г. Тукая, его влиянию на последующее развитие идейного, тематического и жанрового состава, проекциям на творчество молодых писателей и поэтов, в частности Хади Такташа, оставившего глубокий след в культуре своего народа.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, журналист, редактор, литература, поэзия, проекции, татары, культура, Хади Такташ, лирика, художник, пейзажист, эпоха, революция.

The article is devoted to the formation of Tatar literature of the new era in the context of the work of G. Tukai, its influence on the subsequent development of the ideological, thematic and genre composition, projections on the work of young writers and poets, in particular Hadi Taktash, who left a deep mark on the culture of his people.
**Key words:** Gabdulla Tukay, journalist, editor, literature, poetry, projections, Tatars, culture, Khadi Taktash, lyrics, artist, landscape painter, era, revolution.

Творчество Г. Тукая, классика и одного из основоположников татарской литературы нового времени, всегда находится в центре внимания исследовательской деятельности ученых на протяжении всего XX в. и теперь, уже I четверти XXI в.

Интерес к его творчеству объясним множественностью рецепций, потому что «его литературная и культурная идиентичности формируются на пересечении литератур, культур, языков» [1: 225]. Нам Г. Тукай, видится более как личность универсальная, с просветительским размахом, осваивающая литературные и культурные ипостаси. И по этой причине, вполне справедливо его творчество рассматривается как «открытый текст, обладающий потенциальной множественностью смыслов» [1: 226]. Творчество поэта осложнено особенностью его мировосприятия, стремлением осознать всю сложность жизни в контексте с общественно-политическими, социально-культурными процессами, происходившими в стране, того бурного века, в котором он жил. Его смело можно назвать поэтом-мыслителем, осваивающим особенности бытия тюркского мира. Творчество поэта можно и нужно рассматривать с общечеловеческой и цивилизационной точек зрения, «сквозь призму разнообразных культурных пространств» [1: 228], которые формировали его личность в различные периоды в Заказанье, Уральске, Казани.

Г. Тукай будучи журналистом, редактором, всегда был в водовороте общественных событий, здесь оттачивались его литературный слог и стиль, публиковались острые и актуальные полемически заостренные материалы. Он универсален своем творчестве: пишет стихи, очерки, статьи, фельето-

ны. Г. Тукай изначально в силу своей профессии был прогрессистом, видел перспективу, держал руку на пульсе народной жизни. Само название газеты «Фикер» («мысль») требовало этого. О направлении печатного издания говорится в его стихотворении «Не только в честь газеты «Фикер», где он призывает к развитию общественной мысли, ее распространению в газетах, воплощению в жизнь. Поэт в стихотворении «Манифест» остро реагирует на события 1905 г., он переживает, размышляет, полемизирует. Большинство стихов поэта написаны в публицистическом духе. Его творчество – огонь пылающего сердца, честного, бескомпромиссного, страдающего. Боль его сердца – положение татар, поэт ратует за политическую свободу и социальную активность своего народа. Он является координатором творчества татарских деятелей, устанавливает с ними связи, печатает их работы, стихи, статьи. В газете «Фикер» он проявляет себя как национальный поэт, патриот, публицист. В уральский период деятельности Г. Тукай активно реализует свой девиз «лишь в служении народу признаю за счастье я…» [1: 357]. Насколько он связан и реагирует на общественно-политические события говорит тот факт, что в период первой русской революции поэт за полтора года написал около 20 стихотворений на злобу дня.

Г. Тукаю в начале XX века удалось расширить диалогическое пространство татарской литературы, включить его в общероссийский контекст, наряду с восточными литературами. Он становится человеком мира, деятелем ренессанса татарской культуры, его творчество связано с идеей обновления, преобразования жизни татар. Поэт – поборник национальной культуры – призывает: «Давайте окропим нашу нацию душистым нектаром цветов литературы, овеем ее мягким ветерком газетных вееров и вольем в ее уста живительную влагу объединения и совместного труда; вдохновим ее музыкой, услаждающей душу…» [1: 369].

Лирика поэта, диапазон его душевных переживаний, вмещает все: мотивы любовного страдания, зачарованности, заколдованности этим чувством, страдания народа, общественный подъем, революцию, реакцию, политику, выражает свое отношение к власти, к наживе и эксплуатации людей, власти, к его безнравственным принципам, используемым по отношению к народу. Г. Тукай не просто поэт, а поэт с ярко выраженной гражданской поэзией.

Широко и многогранно творчество Г. Тукая, оно сверкает всеми красками радуги, звенит всеми звуками и мелодиями жизни. Он тончайший лирик, обращенный к восточной поэзии, проявляет себя как утонченный художник, передающий все богатство красок осенней природы, пейзажист, светопись и зарисовки которого являются фоном, передают лирические переживания героя.

Г. Тукай вошел в татарскую литературу и как переводчик А. С. Пушкина, М. Ю. Лермонтова, А. Кольцова. При переводе стиха А. Кольцова «Сон мужика» он использует развитые формы татарского языка, фольклорные приемы и неисчерпаемые ресурсы народной поэзии. Г. Тукаю принадлежит первенство в налаживании диалога с русской литературой. Поэт ищет и обновляет метрические размеры татарского стиха, ориентируясь на русское стихосложение. Он делает это при переводе русских стихов на татарский язык. Опыт, накопленный переводчиком, в дальнейшем вошел в копилку татарской литературы и использовался его последователями.

В целом следует отметить, что разносторонняя и многоплановая творческая деятельность Г. Тукая была своевременной и необходимой для

формирования богатства жанровых форм татарской литературы. Природа его стихов передает живое дыхание жизни, во многом определяется его журналистской деятельностью, оказавшей мощное воздействие на их тематическое многообразие. Исследователями отмечено, что «его поэзия была многоликой в своем идейном, тематическом, жанровом, стилистическом многообразии» [1: 410].

Г. Тукай надолго определил свободу, размах и творческий полет деятелей татарской литературы, основные парадигмы ее развития, жанровое и тематическое богатство, свежесть и чистоту помыслов, многотемье, обращенности к человеку, красоте его души, страданиям на грешной земле. Стихи поэта имеют особый аромат, со страниц поэзии Г. Тукая веют степные ветры, напоенные запахом весеннего разнотравья, ковыли, увлекая нас в мир вечный, живой, такой любимый и желанный, что хочется жить вечно и радоваться своей земной юдоли.

XX век дал татарской и российской литературе другого гения – Хади Такташа – Такташева Мухамметхади Хайрулловича (1901–1931), поэта, драматурга, журналиста, чья судьба удивительным образом перекликается с Г. Тукаем: то же простое происхождения, те же жизненные университеты, такая же работа в редакциях татарских газет и журналов в Оренбурге (1919–1920), Ташкенте (1921–1922), Казани (1922–1931). Будучи романтиками по натуре, Г. Тукай и Х. Такташ, видели свое призвание в служении народу, своей общественной и просветительской деятельностью. Этих людей объединяет напряженный динамичный XX век с его общественными катаклизмами, войнами и революциями, победами и поражениями, ярким социальным оптимизмом, всколыхнувшим мир. Их творчество сходно типологически многотемьем и многожанровостью. Этих поэтов объединяет даже трагически короткий жизненный путь – одному было отмерено судьбой 27 лет, а другому – 30 лет. Г. Тукая не стало в 2013 г., а Х. Такташа – 1931 г. Оба сгорели быстро, как свеча на ветру, посвятив себя служению татарскому народу.

Тюркский мир всегда отличается тесными органическими взаимосвязями. Безусловно, Х. Такташ был под впечатлением и обаянием творческой личности, и произведений Г. Тукая, его плодотворной многоплановой просветительской и поэтической деятельности. Жизненные вешки и та высокая творческая планка, которые были поставлены Г. Тукаем, служили ориентиром для Х. Такташа. Отсюда его такая разноплановая деятельность, результативность, ощущение края и чувства ответственности перед народом: «Кто, как не я, должен это сделать!».

Х. Такташ вслед за Г. Тукаем творил так, как от него требовала эпоха. Критиками отмечено, что у него «хватало духовной мощи, чтобы подняться до уровня великих эпохальных требований, у него хватило мастерства, чтобы его стихи уверенно входили не только в просвещенные дома, но и в темные лачуги» [3: 3]. А все от того, что с детских лет он мечтал о свободе своего народа. Вот как он сам об этом пишет: «Карабкались мы на деревья, / Чтобы мир увидеть с высоты… Как я карабкался на белую березу, / Так к жизни, к свету, ввысь дорогу брал» [2: 7]. Уже его первые поэтические опыты связаны с вопросами социальной несправедливости, неравенства между людьми, угнетения и унижения бедных. В стихотворении «Мокамай» звучит тема красоты детства и трагической, жертвенной гибели подростка, оказавшегося в нищете. Х. Такташ пришел в литературу как поэт-трибун,

привнес комсомольский задор переустройства мира, реализации грандиозного революционного мифа. Поэт сблизился с эпохой, стал ее неотъемлемой частью, смог выразить содержание нового времени, увидеть масштабы, измерить исторические дали, насчитывающие столетия, рассмотреть красоту людей, земляков: «Вот они идут – все эти люди, / – В рваных шапках, в стоптанных лаптях: / Все они мне дороги и любы» [2: 77].

Хади Такташ, как и Габдулла Тукай, близок народу, является неотъемлемой его частью. Он как композитор чувствует музыку народной жизни, переплавляя ее в стих. В автобиографической статье «О себе и других» поэт с гордостью пишет о своей тесной связи с народом: «Я самый счастливый, богатый, когда пишу. Потому что тогда я возвращаю читателям богатства, украдкой, за неделю собранные в их сердца, в их глазах, в их лицах» [3: 8].

Тема революции, изменений в обществе, жизни – одна из ключевых тем в творчестве Х. Такташа. Он выступает за революционное обновление так же как и его современники: Блок, Маяковский, Есенин.

Мимо Х. Такташа не прошли важные политические события эпохи. Поэма «Века и минуты» встает перед нами как документ трагического времени, После свержения царя, самодержавия народ не мыслит себя без, лидера, вождя, взбунтовавшаяся эпоха не может жить без мифического героя. На страницы поэмы врывается ветер перемен, обновления общества. В поэме «Деревня Сыркыды», написанной в год смерти вождя, показывается непримиримое столкновение старого и нового, ожидание людьми торжества справедливости, братства.

Х. Такташ жил в пору революционного подъема, юношеского романтизма и надежды на лучшее будущее. Он пронес в своих стихах веру народа в лице Мухтар-бабая в коллективизацию и лучшую жизнь крестьян, в лице сельского сторожа Шахми, охранявшего сельсовет, – народную мечту о счастье. Простые люди были счастливы от осознания своей исторической миссии строителей нового социалистического мира. Поэту удалось подметить эти настроения и отразить в своей поэзии. Творчество Х. Такташа отличает множественность социальных проекций, идей, иллюзий, которыми была пропитана жизнь первого послереволюционного десятилетия. Тогда еще не наступило разочарование от революционного скоропалительного прожектерства. И лишь потом поэт начинает чувствовать, как и В. Маяковский, что наступает время общественно-политического кризиса, тупика, духовного бездорожья, куда его завели расплодившиеся советские бюрократы.

Сейчас, по истечении времени революционная поэзия 20-х гг. XX в., кажется неактуальной, выцветшей, как и революционные знамена тех далеких лет, хранящиеся в музеях. На самом деле ее важность в том, что она были актуальна и востребована в контексте эпохи, увлекала людей благородством идей, перспективой строительства нового мира. Красные идеи Х. Такташа звали к свободе от рабства, социального бесправия и национального угнетения. Непримиримая классовая вражда оставалась на заднем плане, впереди же был социальный прогресс, равенство между людьми. Это проповедовал поэт, за это мы ценим его творчество, которое перешагнуло в третье тысячелетие. Не случайно отмечается, что «Х. Такташ слился с порывом истории, не противоречил эволюции, не отверг ее» [3: 26 ].

В стихотворении «Октябрьская ночь» он пишет про бунт: «Гуденье набата. / Пусть всюду призывные громы гремят, / Пусть будет сигналом

всемирного бунта… [3: 46 ], Пусть пламя все страны / Охватит, покроет! / Дворцы пусть пылают, / Пусть тюрьмы горят!.. – Стряхнем мы старинные ветхие грузы, Избавимся мы от смертельной обузы... Новый мы путь начинаем, Путь к вечному солнцу, к великим огням!» [3: 48].

Поэт, очарованный романтическим атеизмом, богоборчеством, как и все его ровесники, окунается в борьбу с религией. Воюя против Бога, революционный народ и поэт на самом деле воевали против лицемерных священников. Он мстил мулле, в котором односельчане не видели духовника, заступника, а лишь своего духовного поработителя. Его литературный герой из «Трагедии сынов земли…», поэт Кабил вступает в откровенную схватку с богом, пытается встать с ним вровень.

Сейчас, по происшествии длительного времени, можно говорить о том, что Всевышний пришел к поэту, минуя мечети и лицемерных священников. Он воплотился в любви Х. Такташа к родной земле, ее природе, буйным лесам, перелескам, хлебным полям, теплому лету, солнечным дням и осенним ветрам.

В лирической поэзии Х. Такташа звучит тональность и обращенность к природе Г. Тукая, проекции которого чувствуются во многих произведениях. Гений Х. Такташа так велик и значителен, его связь с природой так органична, что поневоле напрашивается сравнение с С. Есениным:

Юная березка у дорожки
Ухитряется спокойно спать
На одной своей на белой ножке,
А крылатый опьяненный тополь
Наклоняется ее поцеловать [2: 77].

Х. Такташ, лирик и пейзажист, удивляет и восхищает читателя своим стихами о природе, пейзажными зарисовками, подчас не уступающими многим русским поэтам. Встает вопрос, а откуда это у Х. Такташа предельно обостренное, понимание природы? Из глубины нравственной памяти, очеловечивания мира животных, деревьев, цветов, повседневного крестьянского опыта, любви к окружающей природе как своей неотъемлемой части, из еще более глубинного устоя – нравственно-духовного, опиравшегося на нерасторжимые связи крестьянина и природы, языческого очеловечивания мира. Отсюда и эта глубина видения мира родной земли.

И цветы проснулись,
И на поезд,
Вытянув реснички, беспокоясь,
Изо рва глубокого глядят,
А когда промчится поезд.
В травы окунаются назад [2: 77].

Нельзя не предположить, не с этого ли глубинного чувства святительства родной земли своей начинается любовь к людям, Родине у поэта? А оно было под силу тому, кто с колыбели его чувствовал, им жил и творил как духовный подвижник:

Ах! Любил не слишком ли я жадно?
Землю и цветы я целовал.
Каждую подросшую березку,
Будто девушку-подростка,
К тополю-джигиту ревновал! [2: 77].

Тема природы четко прописана в стихах «Лесная девушка», например: «Зарю я буду славить, одинок. / Наедине с рассветным ветром»; «У озера сижу я и пою. / У озера я песни создаю. / Эй, ветер утренний постой! Не вей / Среди ветвей уснувших тальников! / Не вороши листву густую!» [3: 36]. Таково же стихотворение «Лесная сказка», где «Есть лес, есть мрачный лес, он беспределен, / Он полон вечных тайн, он в сумрак погружен» [3: 38].

Творческие проекции Г. Тукая оказали значительное влияние на татарскую литературу в целом и в частности на Х. Такташа, который, обогатившись идеями, пошел дальше своего учителя, создав совершенные образцы лирических шедевров, воспев свою революционную эпоху, время метаний и поисков, время переустройства общества и государства на новых справедливых началах

ЛИТЕРАТУРА

1. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886 / 1907) / З.З. Рамиев, М.И. Ибрагимов, Г.М. Ханнанова и др.; ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. – Казань, 2018. – 448 с.

2. Такташ Хади. Возвращение на родину: Стихи и поэма. – Рузаевка: Типография «Рузаевский печатник», 2000. – 140 с.

3. Такташ Х.Х. Белые березы = Ак каеннар: стихи / [сост. и авт. предисл. К.А. Тангалычев]. – Саранск: Типография «Красный Октябрь», 2011. – 176 с.

УДК 81’373.611

## СЛОЖНЫЕ КОНСТРУКЦИИ В ТВОРЧЕСТВЕ ТУКАЯ

***И.И. Сабитова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются пути образования и структура сложных конструкций в творчестве Тукая. Среди сложных конструкций в лексике Тукая встречаются имена, образованные путём сложения компонентов с сочинительным и подчинительным отношениями. По численности преобладают парные конструкции. Они образованы двумя типами и тремя моделями. Особенно продуктивной оказалась модель «существительное в основной форме + существительное в основной форме».

**Ключевые слова:** сложные конструкции, парные слова, тип образования, модель образования, компонент.

The article deals with the ways of formation and the structure of complex lexical combinations in the works of Tukay. Among the complex combinations in the vocabulary of Tukay’s works there are names formed by adding components with coordinate and subordinate relationships. Paired structures prevail. They are formed by two types and three models. The model «noun in main form + noun in main form» turned out to be especially productive.

**Key words:** complex combinations, paired words, type of formation, model of formation, component.

## ТУКАЙ ИҖАТЫНДА КУШМА КОНСТРУКЦИЯЛӘР

***И.И. Сабитова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Бүгенге көндә Тукай әсәрләре шактый тирәнтен өйрәнелгән. Аның иҗатының милли асылын, кабатланмас шигъри бизәкләрен ачуга юнәлтелгән яңадан-яңа хезмәтләр языла һәм киләчәктә дә язылачак.

Бу мәкаләбездә Тукай иҗатындагы кушма конструкцияләр ясалышына кыскача характеристика бирербез. Билгеле булганча, хәзерге татар телендә кушма сүзләр куш (парлы), саф кушма һәм тезмә сүзләргә бүленеп карала. Тукай иҗатында кушма сүзләр арасында компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалган куш сүзләр күп. Алар арасында исемнәр дә, сыйфатлар да, рәвешләр дә, саннар да, ияртемнәр дә, фигыльләр дә, алмашлыклар да шактый. Материалдан күренгәнчә, сан ягыннан кушма исемнәр өстенлек итә. Алар арасында **компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалган куш исемнәр** аеруча күп һәм ясалышлары ягыннан берничә тибы очрый:

**1. Исем + исем тибы**.

1) *Төп формадагы исем + төп формадагы исем моделе: алтын-көмеш, кайгы-хәсрәт, кош-корт, авыз-борын, тавыш-тын, азык-су, агай-эне, иннек-кершән, читек-кәвеш, ишәк-куй, тау-таш, сый-хөрмәт, җир-су, ата-ана, көн-төн, уен-көлке, моң-зар, аяк-кул, кул-аяк, әдәп-инсаф, чебен-черки, шик-шөбһә, йорт-җир, өс-баш, җил-буран, дуст-иш, ат-сыер, көч-ярдәм, читек-кәвеш, наз-нигъмәт* һ.б. бик күпләр. *Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, **тавыш-тын** юк;Ул шәһәр – гади шәһәр, **алтын-көмеш**, гәүһәр түгел; Хәзер шатлык, **уен-көлке** телим инде җитәрлек күп; Мин аның җыр, **моң-зарын** нәкъ аңлыймын; **Чебен-черки** тотып кайта аналары; Сөям сезнең **әдәп-инсафыңызны**; Барча **кош-корт** йоклаган булганга, урман тын икән; Бер заманнар чалмалыга **кадер-гыйззәт** бар иде.*

2) *Исем + аваздаш сүз моделе: чокыр-чакыр. Татар башы **чокыр-чакыр**, себермәсәң дә такыр.*

**2. Хәбәрлек сүз + хәбәрлек сүз тибы**.

*Хәбәрлек сүз$_1$ + хәбәрлек сүз$_2$ моделе*: *юк-бар. Гыйффәтен сатарга **юк-бар** акчага.*

Анализ күрсәткәнчә, *төп формадагы исем + төп формадагы исем моделе* буенча ясалган парлы сүзләр күп. Лексик-семантик бәйләнеш ягыннан бу сүзләрне түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин:

1) Үзара синонимик мөнәсәбәттә булган парлы сүзләр: *моң-зар, уен-көлке, кайгы-хәсрәт, сый-хөрмәт, әдәп-инсаф, шик-шөбһә, хәйлә-мәкер, рәхәт-сафа, кадер-гыйззәт, гыйшык-мәхәббәт, карак-угъры,иннек-кершән* һ.б.ш. *Парә-парә кисмәсә **гыйшык-мәхәббәт** кайчысы; **Сый-хөрмәтләр** күрер бу; Очрамый юлда җиһанның **кайгы-хәсрәт**, аһына; Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин **карак-угъры** түгел.*

2) Үзара антонимик мөнәсәбәттә булган парлы сүзләр: *юк-бар, көн-төн, кыз-егет, аст-өст, ал-арт, уң-сул* һ.б. *Бара **көн-төн**, һаман ял итми, асла тынмыйдыр үзе; Нә **яшьне-картны** белде, **кыз-егетне** нә фәркъ итте; Карый һәр якны: **алны-артны**, **өстне-астны**, **уңны-сулны**.*

3) Компонентлары бер-берсенә якын булган төшенчәне белдергән парлы сүзләр: *өс-баш, ата-ана, әнкәй-әткәй, хатын-кыз, кыз-хатын, аяк-кул, кул-аяк, ат-сыер, ишәк-куй, мылтык-кылыч, мылтык-ук, ботак-тармак, җен-пәри, күлмәк-ыштан, күркә-тавык* һ.б.ш. *Бик куе булганга, монда **җен-пәриләр** бар диләр; Бер ишан хәзрәт симерттем **күркә-тавык** ашатып; Бөтенләй бәйләнә анда **аяк-кул**; И туган тел, и матур тел, **әткәм-әнкәмнең** теле!*

4) Компонентлары бер-берсенә бөтенгә өлеш караган кебек караган парлы сүзләр: *тау-таш, таш-тау, җил-буран, кар-яңгыр, көл-күмер, җир-*

*су* һ.б. *Борча атмак көлкедер **тау-таш** ватарлык туп белән; Күңле калган **көл-күмергә** әйләнеп, хиссезләнеп; Бабай мескен **кар-яңгырга** карамыйча; Минем көчтән көлеп тора шушы **Таш-тау**!*

5) Беренче компоненты реаль мәгнәгә ия булып, икенчесе телдә мөстәкыйль кулланылмый торган парлы сүзләр: *чокыр-чакыр. Татар башы **чокыр-чакыр**, себермәсәң дә такыр.*

6) Икенче компонентлары парлы сүзгә бернинди лексик мәгънә өстәмичә, бары гомуми билгесезлек төсмере бирә торган парлы сүзләр: *җен-фәлән, уен-фәлән, шәйтан-фәлән* һ.б. ***Җен-фәлән** дип сыйләшүләр искеләрдән калган ул; Хәрам **уен-фәләннәрдән** зарар итмәс, ходай кушса.*

Тукай иҗатында кушма исемнәр арасында компонентлары **атрибутив бәйләнештәге** кушма исемнәр зур урын алып тора. Ясалышлары ягыннан аларның яктан түбәндәге типлары бар.

**1. Исем + исем тибы:** *кулҗаулык (кульяулык), кайнана (каенана), кайне (каенэне), көнчыгыш, көньяк, ханбикә, остабикә, шартаяк, тимераяк, юлбарыс* һ.б.ш. *Кулымдагы **кулҗаулыгым** дүрт почмагы өй хәтле; Кем бу? – Бар **кайнанасы**; Шулай хан **көнчыгышка** бихисап гаскәр рәван кыйлды; Халык ханны сәламли; **ханбикә** баш селкә; Боз өстендә **тимераяк** берлә шуып; **Юлбарыс**, күрсә ишәк-куйны, тизүк ертып ала.*

**2. Исем$_1$ + тартымлы$_2$ исем тибы:** *җир җиләге, кура җиләге, су анасы* һ.б. *Урманында кып-кызыл **кура җиләк** тә **җир җиләк**; **Су анасыны** куарга кутәрелде барча эт!*

**3. Сыйфат + исем тибы:** *ислемай, Кисекбаш* һ.б. ***Ислемай** сөрткән икән дөнья! дидем: бәйрәм бүген! Агълый **Кисекбаш**, моңын-зарын сөйли.*

**4. Сан + исем тибы:** *кыргаяк (кырык аяк). Караңгыда юешкә төште ул нәкъ **кыргаяк** төсле.*

**5. Сыйфат фигыль + исем тибы:** *атланмай (атланган май). **Атланмайны** бик яратам: әнкәй атлый шул аны.*

**6. Аваз ияртеме + исем тибы:** *Мияубикә.*

**7. Сыйфат + исем тибы (компонентлары аерым языла):** *Ак күгәрчен, күк күгәрчен, ала карга, кара козгыз, Ак диңгез* һ.б.ш. ***Ала карга, кара козгын** әрсезләнә, тук була; **Ала карга** кунып сайрый тел очларына басып; **Күк күгәрчен** – күлләрдә, **ак күгәрчен** – сайларда.*

Сүзтезмәләр лексикалашу юлы белән барлыкка килгән кушма исемнәр дә шактый.

**Атрибутив сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе.** Халык иҗаты лексикасында бу ысул белән ясалган кушма сүзләрнең түбәндәге типлары бар.

**1. Сыйфат + исем тибы:** *аккош, каракош, сорыкорт, акшар, ташбака, балавыз, аръяк* һ.б.ш. *Һавадин очкан **аккошның** аузы тулы **балавыз**; Ирек-иркендә үскән яшь **каракош**; **Ташбака** төсле вагон әкрен килә.* Бу тип белән ясалган ялгызлык исемнәре дә очрый: *Агыйдел (Ак Идел), Акбай, Карәхмәт (Кара Әхмәт). Әйдәле, **Акбай**! өйрән син, арт аягың берлә тор; **Агыйделнең** аръягында атлар йөри чабында.*

**2. Сыйфат функциясендәге исем + исем тибы:** *Җантимер, Гаделбану. **Җантимерләрнең** итек астын ялаучы бәндәләр; Әй җанашым, **Гаделбану**!*

**3. Сыйфат + исем тибы**: *Ахмакҗан. Мескен **Ахмакҗан** бабайның.*

**4. Исем + тартымлы исем тибы:** *ат кәмите, күз алмасы. Алдымызда **ат кәмитен** күрәлем; **Күз алмасын** әрле-бирле очыртамын.*

**Компонентлары хәл бәйләнешендәге сүзтезмәләрнең кушма исемнәргә күчүе.** Тукай иҗатында бу ысул белән ясалган кушма сүзләрнең түбәндәге тибы очрый.

**Сан + фигыль тибы:** *алтатар* (*алты атар*). *Ит син шуны* ***алтатар****.*

Шулай ук **сүзтезмәнең *-гыч* кушымчасы алып кушма сүзгә күчү** очрагы да бар: *альяпкыч*. *Ак* ***альяпкыч****, зипун да.*

Күргәнебезчә, Тукай иҗаты теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай. Аның бер өлешен ясалышлары ягыннан төрле типларга караган кушма конструкцияләр һәм тотрыклы сүзтезмәләр тәшкил итә һәм аларның һәрберсе ясалышы ягыннан җентекләп өйрәнүне сорый.

ӘДӘБИЯТ

1. Галиуллин К.Р., Каримуллина Р.Н. Габдулла Тукай шигърият теле. Сүзлек. Ике китапта. – Казан: Мәгариф, 2009.

2. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 271 б.

3. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр. – Т. 1–3, 1975–1976.

4. Ганиев Ф.А. Словообразование в татарском языке. – Казань, 2010. – 727 с.

УДК 82.091

# СМЫСЛОВОЕ НАПОЛНЕНИЕ КОНЦЕПТА «ВӨҖДАН» В ПОЭТИЧЕСКИХ ТЕКСТАХ Г. ТУКАЯ

***Ф.К. Сагдеева***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье концепт рассматривается как смысловой центр, способный формировать тексты. Слово-понятие *вөҗдан* имеет смысловое наполнение, что дает возможность через прямые и опосредованные связи с поэтическим текстом толковать концепт с позиций мироощущения Г. Тукая.

**Ключевые слова**: концепт *вөҗдан (*совесть), поэтические тексты, словарные дефиниции.

In the article, the concept is considered as a semantic center that can form texts. The word-concept of *vujdan* has a semantic content, which makes it possible to interpret the concept from the standpoint of the worldview of G. Tukai through direct and indirect connections with the poetic text.

**Key words**: concept *vujdan* (conscience), poetic texts, dictionary definitions, G. Tukai.

В отечественной науке понятие *совесть* выделяется прежде всего как этическая категория. «Способность личности осуществлять самоконтроль, осознавать нравственные общественные обязанности, требовать от себя их выполнения и производить самооценку совершаемых поступков» – это совесть [2]. Исследователи, изучая индивидуальное моральное сознание рассматривают совесть как часть ее формы наряду с такими категориями, как добро, долг, честь, достоинство и др. По мнению О.Г. Дробницкого, совесть есть «вторичная рефлексия по поводу своих поступков, побуждений и мотивов, возникающая, когда человек бывает способен судить себя с моральной точки зрения, которую он может отличить от своей собственной, частной и субъективной» [5: 177].

Исследование этой категории через призму нашего исследования предполагает обращение к понятию «концепт», служащему для обозначения

элемента картины мира и направленного на изучение языка, сознания и культуры.

Рассматриваемый нами концепт в соответствии с многозначностью его экспонента квалифицируется как многоуровневый (многослойный). Лексический уровень номинации в этом плане является особенно информативным, так как отражает результаты познания в словесных единицах.

Понятийная составляющая концепта формируется, с одной стороны, из семантики членов лексического ряда, посредством которых вербализуется этот концепт, и может быть извлечена из словарных толкований. С другой стороны, на наполнение понятийной составляющей влияют дефиниции, содержащиеся в различных текстах. В нашем случае, в поэтических текстах Г. Тукая.

По определению В.И. Даля, совесть – «нравственное сознание, нравственное чутье или чувство в человеке; внутреннее сознание добра и зла; тайник души, в котором отзывается одобрение или осуждение каждого поступка; способность распознавать качество поступка, побуждающее к истине и добру, отвращение ото лжи и зла; невольная любовь к добру и к истине; прирожденная правда в различной степени развития»[4]. Таким образом, данное слово связано с положительной оценкой человека собственных поступков с чувством достоинства на общественном фоне.

Рассмотрим словарные дефиниции лексемы *вөҗдан,* которые лежат в основе исследуемого концепта. В этимологическом словаре татарского языка Р. Г. Ахметьянова *вөҗдан* «совесть» < гар. w*уҗдāн* «тыныч күнел; актив тынычлык; шатлыклы иминлек» ←*wҗд* «тырышып эзләү һәм табу». Дериваты – *вөҗданлы, вәҗдансыз*. В диалектологическом словаре татарского языка слово *вөҗдан* не указано. Слово *намус*, диал. *намыс* определено как «честь, достоинство (человека); честность». Дериваты – *намуслы, намуссыз; намуслану*, иске *намускяр* («бигрәк тә намуслы кеше») [1: 60]. В трехтомном толковом словаре татарского языка даны следующие значения лексемы *вөҗдан* : 1. Үз эшләрең, үз-үзеңә тотышың очен әхлакый җавап хисе; намус. Дериваты – *вөҗданлы, вөҗданлылык, вөҗдансыз, вөҗдансызлану, вөҗдансызлык.* В однотомном толковом словаре татарского языка (2005) помимо вышеуказанного значения определилась сема – *рухи җаваплылык.* Акцент ставится на понимании совести как способности личности осуществлять духовную ответственность. В современном толковом словаре татарского языка, изданного в 2015 году в понимании значения слова *вөҗдан* помимо указанных выше сем, выделяются семы чувство ответственности перед богом – *Аллаһ алдында*, перед окружающими – *әйләнә-тирәдәге кешеләр* и обществом – *җәмгыять алдында.* В арабско-татарско-русском словаре заимствований понятие совесть определяется следующим образом: *виждан* وجدان *ис.* 1. Вөждан. *Изге виҗдан рәнҗемиме, анда ерткычлар ничек?* (Ш. Баб.) 2. Вөжданнан чыгып үзеңнең эш итүеңә бәя бирү, җаваплылыкны тою. Дериваты – *виҗдани* وجدانى *с.* вөждан(га бәйләнешле), *виҗданән* وجدانًا *р.* вөждан белән, вөждан буенча.

Таким образом, ядром рассматриваемой лексемы является сема «моральное чувство, чувство моральной ответственности за свои дела и поведение, духовная ответственность, чувство ответственности перед богом, окружающими и обществом». Морально-нравственное качество своих деяний личность определяет посредством самооценки.

В поэтических текстах Г. Тукая тема совести является одной из сквозных тем. Все человеческие действия связаны с ней. Понятие *совесть* для автора является объединяющим, всеобщим по отношению к любой деятельности человека и общества, и выступает неотъемлемой частью мировоззрения поэта, т.к. присутствует в различных отношениях.

Основными репрезентантами концепта *вөҗдан* (совесть) в поэтических текстах Г. Тукая выступают лексемы *вөҗдан, намус инсаф, иман, рух, җан, оят, хәя и* однокоренные с ними образования и др.

Совесть является фундаментом духовно-нравственных устоев автора и в его поэзии представлен множественностью смыслов. Совесть – это чувство моральной ответственности за свое поведение перед окружающими. Ответственность обязывает давать отчет в своих действиях, поступках. Когда человек слышит голос совести, это отражается на его жизни. Это качество побуждает поступать так, как должно быть (*гөмүмән мөслимини һәр заман мәэмүре вөҗдан ит, җәхиме дөньяда булдырды инсафымлә вөҗданым, вөҗданың берлән килеш и* др.). Эти языковые выражения основаны на уподоблении совести человеку, отражают одно из ее свойств – управлять поступками, чувствами, мыслями.

Противоположное наполнение имеет понимание того, что спрятавшись от своей совести жить можно легко, обманывать других, но при этом самому не обманываться. Этот смысл объективируется следующими языковыми выражениями: *бертуктамый ялганласаң, тугъры сүзле инсаннарга ялганмасаң, шәйтан төсле тыр-тыр качып.*

Тормак ярый: бертуктамый ялганласаң,
Тугъры сүзле инсаннарга ялганмасаң,
Вөҗданыңнан шәйтан төсле тыр-тыр качып,
Үзең алдап, башкалардан.

Когда кругом разврат не стоит соблюдать приличие и совесть так же не нужна: *ләзем түгел инсаф, вөҗдан – бер данә дә*. Слово *вөҗдан,* включившись в сочетаемость с другими словами, выражает смысл «нравственное падение». Этот смысл передается следующим образом:

Һич кирәкми гайрәт итмәк, мәрданә дә;
Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү
Фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә.

Здесь поэт как бы расширает границы денотативного значения совести. Слова *инсаф* и *вөҗдан* сближаются по своему основному значению.

В татарской языковой картине мира совесть предстает как нематериальная субстанция. У поэта же совесть уподобляется вещи, которую можно продать. Продав веру и совесть, можно легко прожить.

Тор дөньяда: иманың сат, вөҗданың сат, –
Шулай торсаң, гомрең утәр ансат.

Смысл «совесть можно растоптать» передается следующим образом: *И аягың коргыры! намусымызны таптадың...*

У Г. Тукая совесть наделяется антропоцентрическими поведенческими характеристиками: персонифицируется – *син дә вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә*, квалифицируется через состояние человека – *бу үлек вөҗданны җанландыр, җылын берлән җылыт!* В данном случае выражается нравственный смысл совести. Так же совесть может придти, сделать замечание: *Шелтә кыйлырга әллә вөҗданым килә*? В сочетании с глаголами

действия из разряда абстрактного существительного *вөҗдан* переходит в разряд конкретного существительного.

Совесть представляет собой добродетель – высшую нравственную ценность: *Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән.* Прошел по грязи жизни с кристально чистой совестью.

У поэта совесть выступает мерилом нравственности: *Истибдадның намусына тукынмасаң*! Всегда надо поступать так. как велит совесть: *Бар мөселманнарны һәр заман вөҗдан кушканча йорт* . Однако не стоит искать удовольствия в том, что она не велит делать: *Хозур .әзләмә инсаф вә вөҗдан кушмаган әштән*. Совесть отталкивает от порочных поступков и действий.

В то же время Г. Тукай четко осознаёт, что совесть наносит ущерб: *вөҗдан зарары*, иметь совесть – тяжелая ноша, которая потянет тебя ко дну:

Вәләкин йөкләмә арканда *вөҗдан,*
Авыр ул бу йөзүдә кургашындан.
Батарсың син, сине ул төпкә тартыр;
Бу чын сүз: тыңладисәң, фәһмең артыр.

Следуя наивным представлениям, любой анатомический орган, покрытый жиром, плохо функционирует.В поэтическом образе автора покрылась жиром нематериальная субстанция – совесть: *вөҗданы майга капланган* и выражает смысл «бессовестный, наглый», где эмотивная оценка – неодобрение [6].

Если потерять совесть, поступиться ее, можно превратиться в бессовестного человека. Эпитеты, характеризующие бессовестного человека: *бик явыз, йөзе кара, бәдбәхет*, *җалмавыз, оятсыз, азгын бәндәләр и др.*

В поэтических текстах Г. Тукая с концептом *вөҗдан* напрямую связаны концепты *җан и рух*, причем у связь прослеживается очень тесная и многогранная. Отношения в этих парах могут быть сравнительными: *бөтен җанварларның җаны вә бөтен инсаннар вөҗданы*, равноправными: *җаны һәм вөҗданы шул юлда фида, түзмәерди җаннары, вөҗданнары*, подчиненными: *керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк*. Здесь дух обладает приоритетом. Душа, дух и совесть синонимичны и выступают мерилом человеческих поступков.

Таким образом, анализ поэтических текстов. Г. Тукая показывает, что в представлении поэта *вөҗдан* (совесть) обладает такими свойствами, как способность управлять поступками и мыслями людей, вызывает неприятные чувства, предотвращает злые поступки, является своего рода «нравственным регулятором» в поведении людей.

ЛИТЕРАТУРА

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I том (А–Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – 543 б.
2. Бербешкина З.А. Совесть как этическая категория. – М.: Высшая школа, 1986.
3. Габдулла Тукай: Шигърият теле: Сүзлек: 2 китапта. 1 нче китап. – Казан: Мәгариф, 2009. – 503 б.
4. Даль В.И. Толковый словарь живого велирусского: в 4-х т. – М., 1989.
5. Дробницкий О.Г. Проблемы нравственности. – М.: Наука, 1977.
6. Сагдеева Ф.К. Концепт гаделлек (справедливость) в поэтической картине мира Г. Тукая // Габдулла Тукай и тюркский мир. – Казань, 2016. – С. 329–332.
7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 726 б.
8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
9. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009. – 839 б.
10. Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

УДК 792.09

# ОБРАЗ ШУРАЛЕ НА ТАТАРСКОЙ СЦЕНЕ

***А.Р. Салихова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Пришедший из глубины веков образ Шурале является частью духовного мира татарского народа. Благодаря сказочной поэме Габдуллы Тукая он обрел известность и популярность. Шурале часто становится героем театральных постановок. Статья посвящена татарским спектаклям, в которых раскрываются разные стороны образа этого фольклорного персонажа.
**Ключевые слова**: Шурале, театр, драма, спектакль, актер.

The image of Shurale, which came from time immemorial, is a part of the spiritual world of the Tatar people. Thanks to the fairy tale poem by Gabdulla Tukay, he gained fame and popularity. Shurale often becomes the hero of theatrical performances. The article is devoted to Tatar performances in which different sides of the image of this folklore character are revealed.
**Key words:** Shurale, theater, drama, performance, actor.

Незадачливый лесной житель Шурале в Татарстане знаком каждому с самого раннего детства. Он непременный участник праздничных представлений и театрализованных народных гуляний, его нескладную фигуру можно увидеть в парках и скверах, на страницах различных развлекательных изданий. Корни этого, ставшего столь привычным, персонажа уходят в глубокую древность, окутаны таинственными легендами и мистическими поверьями.

Рассказы о Шурале имели множество вариантов. Еще в конце XIX века они были зафиксированы различными исследователями. Следует назвать книгу венгерского ученого Габора Балинта «Изучение языка казанских татар», изданную в 1875 году в Будапеште, работу известного просветителя Каюма Насыри «Поверья и обряды казанских татар» опубликованной в 1880 году, а также сборник сказок Таипа Яхина «Дэфгылькэсэл мин эссаби вэ сабият» 1900 года издания. Один из этих вариантов (где ярче всего показаны находчивость и смелость народа) лег в основу знаменитого произведения Габдуллы Тукая. Так, с легкой руки поэта, Шурале шагнул из области суеверий в мир татарской литературы и искусства. В примечании к поэме Г. Тукай писал: «Эту сказку «Шурале», я написал, пользуясь примером поэтов А. Пушкина и М. Лермонтова, обрабатывавших сюжеты народных сказок, рассказываемых народными сказителями в деревнях» [3: 387].

Сказочная поэма Г. Тукая имела огромный успех. Она была созвучна своему времени и отражала просветительские тенденции в литературе: в ней воспевалась победа человеческого ума, знаний, сноровки над таинственными и слепыми силами природы. Отличался сочностью, выразительностью и доступностью язык поэмы. Г. Тукай с огромной нежностью и любовью воспел и красоту родной природы, и народные обычаи, и ловкость, силу, жизнерадостность сельчан. Эти чувства разделяли и его читатели, воспринявшие сказку «Шурале», как глубоко национальное произведение, по-настоящему ярко и полно выражающее саму душу татарского народа. В результате, Шурале стал как бы неотъемлемой частью родной земли, ее цветущей природы, неисчерпаемой народной фантазии. Неудивительно, что этот яркий запоминающийся образ затем многие годы вдохновлял писате-

лей, художников, композиторов на создание значительных и оригинальных произведений искусства.

Один из самых впечатляющих примеров – первый татарский балет на музыку Ф. Яруллина «Шурале». Он повествует о девушке-птице Сююмбике, попавшей в логово Шурале, и ее спасителе – юноше Былтыре. Основная тема произведения – борьба человека за свое счастье с темными злыми силами и воспевание всепобеждающей силы любви. Традиционный сказочный сюжет получил глубоко оригинальное воплощение в музыке. Фарид Яруллин знал и любил поэзию Г. Тукая, черпал в ней вдохновение для своего творчества. И именно нетривиальностью самой поэмы-сказки «Шурале» обусловлено и своеобразие музыкального материала. Достоинства литературного произведения: совмещение эпического и лирического, вплетение в повествование юмористических элементов, колоритные картины народной жизни и правдивость характеров – стали той основой, на которой оказалось возможным новаторство композитора и хореографов. Балет «Шурале» получил общесоюзное и международное признание. Позднее его поставили почти все крупные оперные театры СССР. Его также танцевали на сценах социалистических стран: Болгарии, Румынии, Чехословакии, Польши, ГДР, Албании, Монголии. В балете «Шурале» блистали такие мировые звезды, как Майя Плисецкая, Юрий Григорович и другие.

Богата и разнообразна судьба Шурале на драматической сцене. Естественно, он частый герой детских и кукольных представлений. Но не только. Случались в этой истории и серьезные, драматичные повороты. Одной из первых постановок Марселя Салимжанова на сцене Татарского государственного академического театра им. Г. Камала стала пьеса Наки Исанбета «Парень из Кырлая» по мотивам произведений Г. Тукая. Начинающий режиссер работал над спектаклем с присущей ему страстностью и самоотдачей. Для него это было этапным событием: после учебы в Москве и освоения русской классики, он впервые окунулся в стихию родного татарского фольклора, постигал и творчески осваивал национальные основы искусства. Эта постановка стала для него и первым тяжелым испытанием: после пары представлений ее запретили.

Образ Шурале нередко встречается в современной драматургии. На конкурс «Новая татарская пьеса» в 2004 году поступило пять пьес с его участием. Интересно, что отношение к этому герою несколько изменилось. В конфликте Человек – Шурале симпатии авторов часто на стороне последнего. Шурале стал флагманом борьбы за экологию, символом естественного, здорового образа жизни, национальных обычаев и мироощущения. Людям же вменяется в вину варварское отношение к природе, погоня за деньгами, пренебрежение к традициям и нравственным законам, которых веками придерживались наши предки.

В плане смещения нравственных и эмоциональных оценок показателен спектакль «Душечка» по пьесе Туфана Миннуллина в постановке Фарида Бикчантаева. Эта музыкальная комедия более двадцати пяти лет с огромным успехом идет на сцене ТГАТ. В ней мелочному и прозаичному миру людей противопоставляются лесные обитатели – шурале (которых язык не повернется назвать лешими). Они элегантно, со вкусом одеты, разговаривают архаичным высокопарным стогом, церемонны и живут высокими идеалами. Эта кампания напоминает современное Тукаю светское татарское общество:

в нем есть свой знаменитый на весь лесной татарский мир поэт, галантные кавалеры, кисейные барышни. Законсервированная эпоха национального возрождения выступает жестким контрастом нашему времени. Именно шурале воплощают в себе национальную культуру, язык, традиции, духовную красоту. Пьеса была очень свежо и интересно поставлена. Все преимущества студийной работы молодых исполнителей с режиссером-педагогом сполна проявились в этом спектакле. Органичность и сыгранность творческой команды, атмосфера легкости и раскованности, смелого творческого эксперимента и искреннего, теплого юмора придают ему особую прелесть [5: 338].

Оригинальные трансформации традиционного образа Шурале наблюдаются и в других постановках ТГАТ им. Г. Камала. Интересна в этом плане фантастическая пьеса «Игра с монстриком» Ильгиза Зайниева. Поставленный с размахом и выдумкой режиссером Радиком Бариевым детский спектакль-феерия стал большим событием для камаловского театра (премьера состоялась 26 декабря 2012 года). Он захватывал динамичным сюжетом, впечатлял зрелищностью и нестандартными приемами. Велика в этом заслуга художника Сергея Скоморохова, композитора Радика Салимова, хореографа Наили Фаткуллиной. Спектакль получился современным как по своему сценическому языку, так и по заложенным в нем мыслям [2: 61]. Очень оригинальным оказался образ Шурале в исполнении Алмаза Гараева. Намного выше человеческого роста, с пружинящей, подпрыгивающей походкой (актер вышел на специальных приспособлениях), он производил впечатление чего-то ирреального, сверхъестественного. Вместе с тем, его разглагольствования о «демократии» имели ярко выраженную сатирическую окраску.

По мотивам тукаевких сказок написана пьеса И. Зайниева «Коза, овца и другие». На малой сцене ТГАТ им. Г. Камала ее поставили Салима Аминова и Ильдус Габдрахманов. Это жизнерадостная музыкальная постановка, с танцами и песнями, наполненная выдумкой, яркими фантастическими образами, добрым юмором. Спектакль поставлен с учетом психологии современного ребенка, герои активно вовлекают зрителей в действие. По-новому преподносится в нем образ Шурале. В обаятельном исполнении Раиля Шамсуарова он становится лирическим, романтическим героем, нежно и трепетно влюбленным в Водяную.

Поучительная детская сказка «Шурале-online» Шамиля Фархутдинова в постановке Рашида Загидуллина идет на сцене Татарского театра драмы и комедии им. К. Тинчурина. Занимательное веселое представление воспитывает в детях любовь к родной земле и родному языку. Оно утверждает важность дружбы и взаимовыручки, доступными средствами доносит до маленьких зрителей нравственные ценности.

В репертуаре Казанского татарского театра юного зрителя им. Г. Кариева достойное место занимает пьеса известного татарского драматурга и публициста Туфана Миннуллина «Расскажи мне, бабочка» по мотивам произведений Г. Тукая. Театр определил жанр постановки как музыкальная мистерия. Огромную роль в ней играют пластика и мимика действующих персонажей (режиссер по пластике – Рустем Фаткуллин). Средствами яркой музыкальной выразительности (композитор Эльмира Галимова) в ней передаются разные состояния души главного героя – маленького сироты Апуша,

который преодолевает чувство страха и одиночества благодаря своим вымышленным друзьям – Водяной, Шурале, Козла, Овцы, Соловья и Чёрной птицы. Спектакль получился необычным, образным, поэтическим.

Сказки Габдуллы Тукая служат неиссякаемым источником для всевозможных детских представлений. Спектакли по мотивам его произведений подолгу и с успехом идут в Татарском Государственном Театре кукол «Экият». Можно назвать «Волшебные сны Апуша» Р. Бухараева, «И, кызык Шурәле!..» Г. Зайнашеваой, «Су анасы» Г. Тукая.

Из последних премьер следует назвать спектакль «Shurale: новая фантазия». Это очень необычная в эстетическом плане постановка. В единое целое соединились средства театра кукол, балета и драмы. Огромное значение имеет работа художника, бутафорских цехов, осветителей. На сцене возникает фантастический мир, в котором переплетаются сон и явь, воспоминания и мечты, в котором легко потеряться и в то же время найти в своей душе, что-то, казалось бы, давно утраченное.

Идея переформатировать «Шурале» изначально возникла у Рустема Абязова, главного дирижёра и художественного руководителя оркестра «La Primavera». Желание не просто исполнить по-новому легендарную музыку на фестивале, но и придать этому событию оригинальную зрелищную форму, побудило его обратиться к Ильгизу Зайниеву. В лице нового главного режиссёра театра кукол «Экият» дирижер встретил живой отклик и понимание. Сроки были ограничены, работа закипела.

Первый показ спектакля состоялся в рамках VII Международного «Абязов-фестиваля» на сцене Государственного Большого концертного зала имени Салиха Сайдашева 7 декабря 2020 года. Он стал ярким музыкальным событием. В оркестровке Рустема Абязова мелодии Фарида Яруллина обрели свежесть, яркость, сочность и глубину. Дирижер очень бережно, тактично обошелся с оригиналом и в то же время придал ему современное звучание. Даже знакомые с классическим произведением Фарида Яруллина слушатели воспринимали музыку как в первый раз: с Большой сюитой из балета Фарида Яруллина «Шурале», написанной Рустемом Юнусовичем много лет назад, произошло очередное перерождение – специально для состава оркестра La Primavera было сделано переложение [1].

Чтобы спектакль не остался лишь разовым фестивальным проектом, было решено его расширить, доработать и включить в репертуар. В конце января состоялась премьера спектакля «SHURALE: Новая фантазия» уже на сцене Татарского государственного театра кукол. Над костюмами и декорациями «колдовал» художник Сергей Рябинин. Внешний облик спектакля получился сказочным, волшебным, в том числе и благодаря приглашенному художнику по свету из Альметьевска Ильшату Саяхову, обладателю «Золотой маски» за спектакль «Зулейха открывает глаза» Башкирского драматического театра имени Гафури [4].

Главные роли исполнили актер Камаловского театра, народный артист Татарстана Ильдус Габдрахманов (Шурале) и актриса театра «Экият» Ляйсан Миннахметова (Сююмбике). Организующим началом постановки осталась музыка. Кроме сюиты по мотивам балета Ф.Яруллина в спектакле звучат произведения Сары Садыковой, Рустема Яхина, Рашида Калимуллина, Алмаза Монасыпова, Загидуллы Яруллина. Языком танца (балетмейстер Салима Аминова) исполнители передают целую гамму глубоких

разнообразных чувств, рожденных художественными ассоциациями. Здесь нет четко выстроенного сюжета. Основное событие – встреча современного человека с миром национальной культуры, духовности. В спектакле объединились разные виды искусств: изобразительное, декоративно-прикладное, музыка, хореография, пантомима. В нем почти нет слов, и на первый план выходит чувственное восприятие. Образ Шурале здесь является собирательным для всего уходящего мира, с его неспешным ритмом, уютным непритязательным бытом, чистыми мечтами и высокими идеалами. Лесной дух здесь больше похож на Бичуру, охраняющего тепло, мир и покой в доме, счастливые детские воспоминания. Художественный язык постановки очень ярок и современен, спектакль богат различными трюками и зрелищными эффектами. Но все же главное его достоинство в том, что он затрагивает глубинные струны души и оставляет ощущение чего-то очень родного и хорошо знакомого.

Образ Шурале в татарском театре играет разными гранями. Это уже не только забавный сказочный герой. Зачастую он становится символом национальной самоидентификации, татарских обычаев, исторической памяти. Разнообразные трактовки этого фольклорного персонажа и появление связанных с ним новых смыслов обогащают художественную палитру, способствуют развитию татарского сценического искусства.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бельцев Зиновий. «Экият» взмывает ввысь на крыльях, сбережённых Шурале. Казанский репортер. 1 февраля 2021. Продолжающееся издание. – [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://kazanreporter.ru/post/4476_ekiat-vzmyvaet-vvys-na-krylah-sberezennyh-surale (дата обращения: 25. 03.2021).

2. Габаши А. Игра с монстриком // Казань. – 1913. – № 3. – С. 58–61.

3. Замалетдинов Л.Ш. О мифологической основе сказки «Шурале» // Слово о Тукае. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 384–392.

4. Ильгиз Зайниев: «Сейчас театр работает на максимальных оборотах, через год мы сбавим темп». Татинформ. 23 января 2021. Автор: Марат Ишкильдин. Продолжающееся издание. – [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://sntat.ru/news/culture/23-01-2021/ilgiz-zayniev-seychas-teatr-rabotaet-na-maksimalnyh-oborotah-cherez-god-my-sbavim-temp-5800668 (дата обращения: 25. 03.2021).

5. Салихова А.Р. Габдулла Тукай и современный татарский театр // Габдулла Тукай и тюркский мир. Материалы международной конференции. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. – Казань, 2016. – С. 337–339.

УДК 82.091

# АКТУАЛЬНОСТЬ НРАВСТВЕННОГО ВОСПИТАНИЯ ДЕТЕЙ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ТУКАЯ

***З.Г. Саляхова***

*МБОУ ««Гимназия № 10» Авиастроительного района г. Казани» (Казань)*

В данной статье рассказывается о воспитательной роли стихотворений и сказок Г. Тукая для детей. Его творчество, не теряя актуальности, до сегодняшнего дня является ценным источником в воспитании молодого поколения. Стихотворения, сказки написанные для детей тематически весьма разнообразны и особенны. Через них пробуждается любовь к родителям, родному языку, родине. Также поэзия Тукая помогает формировать в характере детей такие качества, как трудолю-

бие, острый ум, ответственность. Учит детей быть милосердными, добронравными, бережно относиться к природе и её обитателям.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, стихотворения, поэзия, моральное воспитание.

This article shows the role of poems and fairy tales of G. Tukay in education of young children. His creativity is valuable source in education of young generation and do not lose its relevance. His poems and fairy tales for children quite various and special. Love to parents, native language and homeland is born through them. Also poetry of Tukay helps to form industriousness, sharp mind and responsiveness in children, to be merciful, good-natured, take care of nature and its inhabitants.
**Key words:** G. Tukay, poems, poetry, moral education

## БАЛАЛАРГА ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯ БИРҮДӘ Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНЫҢ АКТУАЛЬЛЕГЕ

***З.Г. Саляхова***
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «10 нчы гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе (Казан)*

Тукай иҗаты татар әдәбият фәнендә, фәлсәфи фикер тарихында төрле яклап яктыртылган. Шулай да аның иҗатының яңадан-яңа якларын тикшерүгә булган ихтыяҗ бервакытта да туктамаячак. Һәр чор «Аның бөеклеге нәрсәдә ?» дигән сорауга үзенчә җавап эзлиячәк.

Тукай калдырган әдәби мирас үзәгендә иң мөһим урынны, әлбәттә, шигърият алып тора. Ил һәм дөнья мәдәниятендә ул бөек шагыйрь буларак тәкъдир ителә. Шунлыктан иҗатының киң һәм иң тирән өйрәнелгән өлкәсе дә – шигърият.

Тукай шигъриятенең тамырлары бик тә тирәнгә – татар халкының фольклорына, борынгы төрки дәвергә, Коръәнгә һәм югары әхлак кагыйдәләренә өндәгән дини-суфичыл әдәбиятка барып тоташа. Узган гасырның икенче яртысында әдипнең иҗатын өйрәнүгә, лирикасы һәм сатирасы үзенчәлекләрен яктыртуга, шагыйрьнең дөньяга карашларын ачыклауга зур әһәмият бирелде. Тукайның фольклорга мөнәсәбәте, балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге дә галимнәр игътибарыннан читтә калмады.

Безне дә, шәхсән, Тукайның киләчәк буынны тәрбияләү мәсьәләләренә карата карашлары кызыксындыра. Габдулла Тукай балалар өчен, нигездә, 1907–1909 елларда иҗат итә. Бу елларда татар мәдәнияте кызу адымнар белән алга китә, ә балалар әдәбияты исә яңа чор таләпләрен канәгатьләндерми, ул башлыча үгет-нәсыйхәт бирүгә кайтып кала. Әдәбиятының яшь буынны тәрбияләүдәге зур ролен тирәнтен аңлаган шагыйрь бу хәл белән килешә алмыйча, җиң сызганып, балалар өчен иҗат итә башлый. Тукай үзенең шигырьләрендә балалар әдәбияты таләпләрен һәрвакыт истә тотып, каләмен, иҗаты аша, сабыйлар тәрбияләүгә юнәлтә. Аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә Сәгадәт Чагатай зур бәя биреп болай ди: «Тукай балалар өчен язып калдырган шигырьләре белән үзенең бала сөючән рухын вә халык өчен бала тәрбияләү киләчәк өчен иң нык нигез булуын күрсәтеп торадыр. Бу, фикеремчә, Тукайның зур кыйммәтле сыйфатларыннан берседер» [3: 74].

Тукай иҗатының тәэсир көче нидә соң? Әлеге илаһи зат балалар өчен иҗат итеп кенә калмый, әсәрләренә кечкенәләрнең үзен – Сабыйны – төп образ итеп алып, аларның рухи дөньяларын ачып бирә. Шушы Сабыйның матур гамәлләре яки ялгышлары аша бала үзенә тормыш сабагы ала, яшәргә өйрәнә. Анда ата-анага, туган тел һәм әдәбиятка, милләткә мәхәббәт уяна,

дөнья һәм табигать турында мәгълүматлары арта. Гомумән, Тукайның балалар өчен язган әкиятләре, шигырьләре тематик яктан гаять төрле һәм үзенчәлекле. Бүгенге көндә балаларны тәрбияләүдә игътибар үзәгендә торырга тиешле татар милләтен, телен, туган җирен, аның гореф-гадәтләрен, әдәбиятын яратуы турында язылганнары аеруча әһәмиятле. Әмма, кыйбласы нинди генә булмасын, тәрбия иң беренче чиратта гаиләдә бирелә. Бүгенге катлаулы заманда гаиләдә дөрес тәрбия бирү көн таләбенә әйләнде. Бу тема беркайчан да актуальлеген югалтмады һәм югалтмаячак та. Бөек Тукаебыз да «Ана мәктүбләре» дигән мәкаләсендә тәрбиянең гаиләдән башлануын ассызыклап, болай дип яза: «Баланы, ир баланы, әйбәт кенә тәрбия ителсә, ата-ана өчен, ... шул бала ата-анасын сакларга күкрәп, нәгърә орып чыкган бер арыслан буладыр.

Кыз баланы бик матур гына тәрбия итсәң, бөтен дөнья байлыкларына сатылмаслык егетләрне, картларны, хәтта хатыннар вә карчыкларны үзенә таба тартып тора торган әллә нинди җазибәле (үзенә тарта торган) бер фәрештә буладыр…Ул үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар, вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр» [2: 41].

Нинди акыллы сүзләр! Шунда ук Тукай татар гаиләсендә тәрбиянең дөрес юнәлештә бармавына борчылып: «Аһ, безнең татар халкында бер дә генә бала тәрбия итүнең нәрсә икәнен белмиләр!» [2: 40] – дип ачынып та куя.

Балаларга әхлак тәрбиясе бирүгә Тукаебыз үзенең шигырьләре аша әйтеп бетергесез зур өлеш кертә. Шул шигырьләр һәм әкиятләрнең кайберләренә күз салып үтик. Г. Тукай үзенең «Су анасы», «Шүрәле» әсәрләрендә балаларны гаҗәеп серле табигать дөньясына алып керә. Матурлык дөньясын тою аларда гүзәллеккә омтылыш хисе уята. Бу әкиятләрнең тәрбияви көченә игътибар итик. «Су анасы»нда бала, читләр ярдәменнән башка диярлек, үз аңы белән иясез әйберләргә тияргә ярамый икән дигән нәтиҗәгә килә. Шулай ук алдашуның да начар гадәт булуын аңлый. «Шүрәле» әкияте исә балаларда кешегә, аның акылына, зирәклегенә, хәйлә катнаш тапкырлыгына, кыюлыгына һәм батырлыгына соклану хисе тәрбияли.

Тукайның хезмәткә кагылышлы шигырьләре дә күп. Ул үзенең «Япон хикәясе» дигән әсәрендә гап-гади ташчы һәм аның авызыннан чыккан сүзләр мисалында дөньяда хезмәткә тиң нәрсә юк, дигән фикерне үтемле итеп балага җиткезә. «Кызыклы шәкерт» шигырендә исә шагыйрь үзенең шигъри юллары белән эшкә, һөнәргә яшьтән өйрәнү кирәклеген, картайгач бу мөмкин түгеллеген бала күңеленә сала һәм аны ныклап кисәтеп:

Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар эш белү уңгайсыз ул! [1: 112] – ди.

Г. Тукай «Эшкә өндәү» шигыре аша зур бәхетләрнең, хөрмәт, дан һәм шөһрәтнең башында тырышлык, эшчәнлек эш сөючәнлек ятканлыгын, бәхетсезлек, оят, хурлык, түбәнлекләрнең чишмә башы ялкаулыкта, иренгәнлектә икәнлеген бала акылына сала. «Ах! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә» [1: 176], – ди ул. Хезмәт – тормыш шатлыгы, бәхет, хөрмәт чыганагы да икәнлеген түбәндәге шигъри юллар белән дә укучы күңеленә сеңдерергә омтыла.

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел [1: 176], –

дип яза ул. Шагыйрь әсәрләрендә авырлыклардан курыкмаучы, хезмәттән качмаучы кеше генә чын мәгънәсе белән бәхетле була дигән фикерне алга сөрә. «Эш беткәч уйнарга ярый», дигән шигыре дә шуңа мисал булып тора. Матди байлыкларны тудыручы хезмәткә дан җырлаган шагыйрь үзенең иҗатында яшь буынны хезмәт белән тәрбияләүнең әһәмияте турында даими төшендереп килә, хезмәтне кешенең акыл һәм әхлак тәрбиясендәге кыйммәтле чыганак итеп карый.

Шагыйрь шул чорда ук бүгенге көндә бик тә актуаль булган табигатьне, андагы җан ияләрен саклау проблемасын да күтәрә. Тукай, гомумән, матурлыкка битараф булмаска, табигатьне сакларга өйрәтә. «Бала белән күбәләк» шигырендәге соңгы строфада күбәләкнең:

Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа! [1:85] –

дигән сүзләренә бер генә баланың да битараф калганы юктыр. Бу юллар бала хәтерендә шулкадәр тирән уелып кала, ул зур үскәч тә табигатьнең бу нәфислегенә кул күтәрә алмый. Бала аңына яхшылык орлыгы ничек иртә салынса, шулкадәр отышлы була. Димәк, Тукайның иң гади шигыре дә бала күңелендә миһербанлылык тәрбияләргә сәләтле икән. Сабыйларда уңай геройларга охшау теләге искиткеч көчле. Шулай ук аның шигырьләре кешелеклелек, тере табигатьнең җан ияләренә мәрхәмәтлелек хисе белән сугарылганнар. «Фатыйма белән сандугач» тагы түбәндәге юллар шуңа мисал булып тора.

Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа:
Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога [1:108].

Г. Тукай шигырьләренең тәрбияви асылы шунда: аның шигырьләре кече яшьтән үк бала күңеленә игелеклелек, кешелеклелек, изгелек орлыклары сала.

Шулай итеп, шагыйрь үзенең әсәрләре аша балаларда халкыбызның борынгыдан килгән асыл сыйфатларын – тырышлык, эшчәнлек, хезмәт сөючәнлек, ярдәмчел булу, һәр эшне җиренә җиткереп эшләү, ата-аналарны һәм олыларны хөрмәт итү кебек күркәм сыйфатларны тәрбияли.

Тукай иҗаты белән танышканда шуңа инанасың: XX йөз башында иҗат итүенә карамастан, ул бүгенге көндә дә актуаль булган проблемаларны күтәрә алган. Шагыйрь үз әсәрләренә яшь буынны тәрбияләү чарасы итеп караган. Әдипнең әсәрләре балаларның өлкәннәрне, әти-әнине хөрмәт итүен, мәрхәмәтле булуны, белем алуда һәм хезмәттә тырышлыкны хуплый, ялкаулык, мактану, мин-минлек кебек тискәре сыйфатларны тәнкыйтьли. Милләтебезнең йөзек кашы булган бөек Тукаебызның бу җәүһәрләре яшь буынга тәрбия бирүдә бүген дә әһәмиятләрен югалтмыйча, кыйммәтле чыганак булып торалар.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Р. Шәйхелисламов, Г.А. Хөснетдинова, Э.М. Галимҗанова, З.З. Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. –384 б.

2. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 4 т.: Проза, публицистика (1907 – 1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.

3. Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз. З.Г. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 190 б.

УДК 82.091

# ПТИЦА-ДУША И БОЖЬИ ПТИЦЫ В ПОЭЗИИ Г. ТУКАЯ

***Э.И. Сафина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье на примере творчества Г. Тукая раскрывается тема обожествления птиц в татарской культуре. Автор показывает, что ещё со времён язычества у тюркских народов существовали верования о том, что после смерти душа человека превращается в птицу и улетает. Тукай отразил эту лингвокультурему в повторяющейся метафоре «птица-душа». В поэтическом творчестве поэта особенно часто встречаются такие названия птиц, как соловей и голубь: они получают интересные символические детали, яркие эпитеты, оформляются при помощи олицетворений. Автор статьи также приводит примеры из творчества предшественников Тукая, что говорит о важном лингвокультурном значении метафоры «птица-душа».
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, орнитологические образы, душа, птица.

The article tackles the works of G. Tucai to explain the deification of birds in the Tatar culture. The author points out that since the times of paganism the Turkic people believed that after death the human soul would tern into a bird and fly away. Turkai reflected this linguoculturema into repeating metophor «bird-soul». In the poet's poems such names of birds as nightingale and dove are especially common: the poet gives them interesting symbolic details. The bright epithets are formed with the help of personification. The author of the article also gives examples from the works of Tukai's predecessors that indicates linguistic and cultural significance of the metaphor «bird-soul».
**Key words:** Gabdulla Tukai, ornithological images, soul, bird.

# Г. ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ҖАН КОШЫ, ХОДАЙ КОШЛАРЫ

***Э.И. Сафина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Бүгенге көн һәм үткән тормыш, фани дөнья һәм ахирәт дөньясы, яшәеш, үсеш-үзгәреш, мәңгелек кыйммәтләр турындагы темалар чагылган әсәрләрдә җан образы аерым урын алып тора. Татар һәм рус әдәбиятында гына түгел, чит ил әдәбиятында да кешенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турындагы уйланулар җан, рух, күңел образлары белән тыгыз үрелеп бара.

Татар әдәбиятында *җан* образы еш кына кош образлары белән бәйләнештә кулланыла. Халык фикеренчә, җан төрле дөньяларны бәйләп тора, үлгәннән соң кешенең җаны теге дөньяга күчә. Төркиләр үлгән кешенең җаны күгәрчен яки башка кош булып оча дип күзаллый. Җанның кош булып очып китүе мифологиядә һәм фольклорда да саклана [3: 5].

Борынгы төрки телдән, халык әсәрләреннән килгән җан һәм кош белән бәйле шигъри образлар дини-суфичыл шигырьләрдә бик күп. Мисал өчен, Ясәвидә *рух кошы, җан кошы*, Котбта *күңел кошы, җан кошы очу, җан*, Кол Шәрифтә *җан кошы* (ак кошка әверелү җан кошының тәннән аерылып, очып китүе белән бәйле), Мәҗлисидә *җан кошы* (*Укысаң гәр, кылыр җан кошы пәрваз*) һ.б. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да шушы ышану чагыла:

*Шәриф тәннән аерылды гъәзиз җаны,*
*Кошка охшап, ул оҗмахка очты инде* [4: 273].

Татар халкының җан турындагы ышанулары, җанның төрле халәттә кеше күзенә күренеп йөрүе турындагы карашлары Г. Тукай иҗатында да

бар. Төрле шигъри әсәрләрендә кулланылган *җан кошы, күбәләк җан, чебен җан* образлары шул хакта сөйли. Мисал өчен,

«Өзелгән өмид» (1910) шигырендә фани дөнья белән хушлашучы җан, кошка әверелеп, киң җиһаннан үзенә ирек эзли:

*Очты күңелем читлегеннән тарсынып күңелем кошы,*
*Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.*

Кешенең өмете өзелгәннән соңгы халәтен тасвирлап, Г. Тукай бу дөнья белән арасын өзгән кешенең үзен үлгәнгә тиңләвен образлар ярдәмендә ачып бирә алган. Чагыштыру өчен, Тукайның «Сорыкортларга» дигән шигырендә җанның кошлар белән түгел, чебеннәр белән бәйләнешенә мисал булырлык юллар да бар: *Чебен җанымны чын юлда бирәм бең кәррә, кызганмыйм* [10: 93].

Шигърият тарихын өйрәнеп, «җан кошы», «күңел кошы» образларының Тукайгача меңьеллык эволюциясе булуын, аларның Кол Гали, Котб, Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр һ.б. лардан ук килүен ачыклаган галим Н. Хисамов «Менә XX йөз башы поэзиясенә Тукай килеп, бу образның гасырлар буенча тупланган нюансларын бергә җыеп ала һәм гаять мәгънәле, тәмамланган метафорик образ тудыра», – ди [11: 186].

Нурания Әмирова-Хәмидуллина истәлекләренә караганда, Г. Тукайның әнисе вафат булгач, кызы Мәмдүдәнең вафаты уңаеннан, Зиннәтулла бабасы мәрсия рухында шигырь язган. Шигырьдән күренгәнчә, Мәмдүдәнең «рух кошы тән читлегеннән очты»:

*Мөргы рухы тән кәфәсеннән тайран иткән дәм мәдам*
*Акты яшем ни кыйлаем әмре хәййүләйәнам.*
*Даре михнәт, даре хәсрәт, даре залим – бу мәкам,*
*Шунча мәхбүбә мөрәссагы дөрне кыйлды инкыйзам.*

*Рух кошы тән читлегеннән очты, дәммәдәм (өзлексез)*
*Яшем акты, ни кыйлыйм, йоклый алмый ятам.*
*Бу дөнья – газап, кайгы, хәсрәт йорты,*
*Шунда тезеп куйган энҗе кук гүзәл сөекле кызымны юкка чыгарды* [1: 22–23].

Мисаллардан күренгәнчә, шигырьләрдә җанның «күңел читлегеннән», «тән читлегеннән» очуы телгә алына һәм кошка бәйле рәвештә *җан, рух, күңел* сүзләре кулланыла. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндәге безне кызыксындырган мәгънәләренә игътибар итсәк, *җан* – «Тәнгә тереклек бирә һәм аннан башка да яши ала торган мәңгелек башлангыч, кот; Кешенең эчке дөньясы: уй-фикере, хисләре, омтылышлары; күңел; рух» [6: 268], *рух* – «Дини ышанулар буенча: кешедә материаль булмаган, үлемсез илаһи башлангыч; җан»; «дингә, мифологиягә, мистикага ышанучылар өчен: табигатьтән өстен, җисемсез зат (фәрештә, җен-пәри)» [8: 753].

XX гасырга кадәр, кош сүзе белән бергә килгәндә, *җан, рух, күңел* сүзләре синонимнар буларак кулланылган дип аңлашыла, ягъни, *күңел* сүзе *җан, рух* мәгънәсендә яки шул мәгънәгә бик якын булып кабул ителә. Бүгенге көндә *күңел* сүзенең мәгънәсен шул дәрәҗәдә үк җан мәгънәсе белән тәңгәл килә дип әйтеп булмый. Аңлатмалы сүзлектә дә *күңел* түбәндәгечә аңлатыла: «1) Кешенең эчке рухи дөньясы; аның хис-тойгылары, кичерешләре; 2) Аерым шәхескә хас рухи үзенчәлекләр; 3) Кичерешләр, хис-тойгылар чыганагы; 4) Сиземләү сәләте, интуиция; 5) Фикер, уй; аң; 6) Зиһен, хәтер; 7) Кәеф, рух; 8) Мәхәббәт, сөю, ярату хисе» [7: 577].

Бүгенге көндә *күңел кошы* сүзтезмәсе *җан кошы, рух кошы* булудан бигрәк, күңел, җан һәм яраткан кеше, сөйгән яр мәгънәсендә күбрәк кулланыла. Әлеге фикерне әдәби әсәрләрдәге мисаллар да дәлилли (*Минә ул, кайчандыр --- төн йокыларын качырган, мәңге сүнмәс утларга салган, хәзер инде тормышыннан мәңгегә югалган күңел кошы – Гөлүсә!* Җ. Дәрзаман. *Хәер, Нәзифә үзе дә аерылып китәргә бик ашыкмый, күңел кошы янында назлану аңа да рәхәт.* С. Сабиров). Ә җанның кош булып очып китүен сурәтләгән очракта, элеккегечә *җан кошы, рух кошы* сүзләре кулланыла. Мисал өчен, күренекле шагыйрьләр хәтта Тукайның җан кошына, күңел кошына да мөрәҗәгать итәләр:

*Булмады Рәсәй илендә*
*Хор яшәүнең яктысы.*
*Сызланды ал читлегендә*
*Тукайның да җан кошы.* (З. Мәҗитов)

*Яхшылыклар эзләп очынучы*
*ап-ак фәрештәләр күчендә*
*суелырга мөмкин Тукайҗанның*
*безгә күчкән күңел кошы да...* (З. Мансуров)

Гомумән, җан кошы образы бүгенге көндә шигърияттә дә, прозада да бик актив кулланыла. Мисал өчен:

*Синең җырны Ярга җырладым төнен...*
*Шул мәл җан кошың очканны кем белгән?!* (Р. Гаташ)

*Төн уртасын сайлап, йөрәгемнән*
*Очып чыгып китте җан кошым.*
*Кайда гына йөри икән инде,*
*Кайсы куак оя биргәндер?* (Г. Гыйльманов)

*Җан кош булып очты ireккә,*
*Ак болытка барып сыенды.* (Д. Йосыпова)

Прозада җан кошы образы Г. Гыйльманов иҗатында аеруча күп очрый (*«Җан кошы озак уйлап тормый, төшкән уңайга, баганага аркасын терәп утырган егетнең күкрәгенә барып куна һәм, шул ук мизгелдә, аның җанбәгыре булып кабат уяна, ул адәм баласын яшәүгә дәртләндерә, аның күңеленә өмет бөртеге сала...»; «Нишләп җан кошы булсын – җан алучы кош ласа ул, үлем хәбәрчесе...»; «Фатыйма карчык, картының тәненнән очып чыгып баручы җан кошын тотып калырга теләгәндәй, кочагын җәеп, түшәк өстенә капланды...»; «Күктәге Тәңре дә моны күргән. Ул, төпчек малайның изгелегенә җавап итеп, җан кошын кабат иясенә кайтарган, ә анага озын гомер биргән»* һ.б.). Әлеге образның киң кулланылышта булуы гаҗәп түгел, чөнки татар халкы элек җан кошына аеруча зур игътибар биргән. Җанның кошка әверелеп үзен озаткан җиргә, каберенә килүен күз алдында тотып, борынгы бабаларыбыз хәтта кабер ташларына җан кошы өчен су чокыры ясый торган булганнар. Филология фәннәре докторы, археограф Марсель Әхмәтҗанов тасвирлаган кабер ташлары арасында да «гөмбәз өстендә «җан кошы» өчен су чокыры» булган [5: 38], «түбәсендә «җан кошы» килү очрагына тәгаенләнгән су чокыры да эшләнгән» ташбилгеләр күп. Җан кошы өчен ясалган әлеге су чокырларының якынча «тирәнлеге – 3 см, диаметры – 9 см зурлыкта» [5: 41].

Җан кош булып очып китә дигән ышану кошларны изгеләштерүгә барып тоташа. Кошларны илаһилаштыру, аерым төр кошларны өстен күрү,

аларны яклаучы, саклаучы, ярдәм итүче дип санау, тотем итеп исәпләү күп халыкларда булган яисә әле дә бар. Мәсәлән, «Халыкның көнкүрешендә күгәрчен, тотем кош буларак, еш кына сакчы вазифасын үтәгән, һәм бу традиция бик озак вакытлар дәвам иткән: тәрәзә йөзлегенә ясалган пар күгәрчен сурәтен хәтта әле бүгенге көндә дә очратып була» [2: 36].

Татар халкының мәҗүсилек чорыннан калган ышану-табынулары, кошларны илаһилаштыру, изгеләштерү Г. Тукайның башка бик күп шигырьләрендә дә чагыла. Иҗатында дини мотивларга күп урын биргән шагыйрь бу очракта Тәңре, Ходай, оҗмах сүзләрен куллана: *Җырлагыз сез күңелегезгә тәңре нәрсә салганын, Мылтыгым да юк янымда, юк, шулай ук, ауларым* («Кошларга», 1910), *Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә, Бөтен бүлмә тулып китте сәвапка* («Ысулы кадимче», 1908), *Ходай кылган мине көчсез кошыннан* («Күгәрчен», 1910), *Миңа, санки, азат иткән өчен, изге дога кылды* («Кошчык», 1910), *Бервакыт чук-чук итеп сайрый ходайның кошлары* («Шүрәле», 1907) һ.б.

Г. Тукай шигырьләрендәге кошлар лирик геройга еш кына «изге дога кылалар». Мисал өчен, «Фатыйма белән сандугач» (1910) шигырендә Фатыйма, читлектән кошны азат иткәч, аннан изге дога сорый. Кошчык, изге җанга әверелә, мәгънә киңәеп китә:

*Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа,*
*Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога...*

Бу фикерне «Кошчык» (1910) шигыре тагын да үстерә:

*...Очып киткәндә, ул шундый матурлап сайрады моңлы:*
*Миңа, санки, азат иткән өчен, изге дога кылды.*

Кошның очып киткәндә моңлы сайравы лирик герой өчен гүя изге дога булып яңгырый.

Кош образларын яратып һәм аларга төрле мәгънә салып куллануы шагыйрьнең балачакта алган тәэсирләреннән, туган як табигатенең сихрилегенә, серлелегенә сокланудан ук киләдер. Югыйсә, Кырлай табигатенең гүзәллегенә мәдхия җырлап, мәшһүр «Шүрәле»сендә (1907) үк:

*Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;*
*Җырлаганда, көй өчен, «тавыклары җырлай», диләр,* яисә:
*Бервакыт чук-чук итеп сайрый ходайның кошлары;*
*Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары*, –

дип язмас иде. Һәрбер кешегә таныш булган әлеге шигырь юлларында Г. Тукайның кошларны кадерләве, олылавы, аларны Ходай яраткан могҗиза итеп кабул итүе сизелә.

Шундый могҗизаларның берсе буларак, Г. Тукай былбыл образын аеруча яратып кулланган. Чөнки халык былбылларда изгелек билгесе күргән. Мифологиядә һәм халык иҗатында былбыллар, сандугачлар элек-электән изге хәбәр китерүчеләр буларак сурәтләнгән. Бу фикерне куәтләп Тукай әлеге асыл кошларны «Ходай былбыллары» дип атый:

*Әй, кояш нурлы, ачылган бакчаларның гөлләре;*
*Яктылык, рәхәт, бәхет! Сайрый ходай былбыллары!*
(«Кичә, бүген», 1910)

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай иҗатында «Ходай кошлары»на зур игътибар бирелә. Орнитологик образлар булган һәр шигырендә шагыйрьнең

кошларны чиксез яратуы, саклык белән каравы сизелеп тора. Тукай кошлар дөньясы аша яшәешнең өзлексез агышын, табигать белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, фани дөнья белән бакый дөнья арасындагы бәйләнешне оста тасвирлый алган. Күптөрле чагыштырулар, метафоралар, символик мәгънәләр ярдәмендә сандугач, былбыл, күгәрчен, лачын, карга, чыпчык, әтәч, тургай кебек бик күп кошларның уңай яки тискәре сыйфатларын сурәтләп, халыкның кошларга мөнәсәбәтен белдереп, үз иҗаты белән шагыйрь кошларның татар лингвомәдәниятендәге урынын билгеләргә ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907) = Материалы к хронике жизни и творчества Габдуллы Тукая (1886–1907) / З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Г.М. Ханнанова, Ә.Х. Алиева, Н.Ш. Насыйбуллина, Р.Ф. Харрасова, А.И. Әхмәтова; З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов редакциясендә. – Казань, 2018. – 448 б.

2. Җамалетдинов Л.Ш. Татар әкиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 264 б.

3. Җәләлиева М.Җ. Шагыйрьнең миф дөньясы // Мәгърифәт. – 1996. – 3 май.

4. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / төз. Н. Хисамов. – Казан: Дом печати, 2008. – 604 б.

5. Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары / төзүче һәм җаваплы мөхәррир Э.И. Сафина. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 360 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унөченче китап).

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г–Й / И.И. Сабитова, Ф.И. Таһирова, А.М. Сәгыйтова, А.Ф. Гайнетдинова, Г.Г. Саберова, Л.Ш. Шәмсетдинова, Г.Р. Сәмирханова, Э.И. Сафина. – Казан, ТӘһСИ, 2016. – 748 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: III том: К / И.И. Сабитова, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова, Э.И. Сафина, А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова. – Казан, ТӘһСИ, 2017. – 744 б.

8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: IV том: Л–Р / Ф.И. Таһирова, Э.И. Сафина, И.И. Сабитова, Ф.Ф. Гаффарова, Р.Т. Сәфәров, О.Н. Галимова, Р.Р. Абдуллина, Г.Р. Сәмирханова, Ф.А. Кушелекова, Г.Г. Саберова. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 760 б.

9. Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 408 б.

10. Тукай Г. Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 510 б.

11. Хисамов Н.Ш. Гасырлар тирәнлегеннән // Казан утлары. – 1973. – № 4. – Б. 181–186.

УДК 82.091

# ТУКАЙ В ПЕРЕВОДАХ НА ТУРЕЦКИЙ ЯЗЫК: НАУЧНЫЙ И ЛИТЕРАТУРНЫЙ АСПЕКТЫ

***Р.Ф. Сафиуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Татарский поэт Габдулла Тукай в своей поэзии и публицистике уделял немалое внимание тюрки-турецкому миру, культуре и общетюркскому (старотурецкому) языку. Знакомство турецкого читателя с творчеством Тукая началось в XX веке, после смерти поэта. В Турции издавались научные работы, посвященные жизненному пути и творчеству поэта. Изучение Тукая Турции в продолжилось в 2000-х годах. Переводы произведений Тукая на турецкий язык выполняются с соблюдением научных и литературных принципов.

**Ключевые слова:** литературный перевод, турецкие издания Тукая.

Tatar poet Gabdulla Tukay in his poetry and journalism paid considerable attention to the Turkic-Turkish world, culture and general Turkic (Old Turkish) the language.

The acquaintance of the Turkish reader with the work of Tukay began in the XX century, after the death of the poet. In Turkey, scientific works devoted to the life and work of the poet were published. The study of Tukay in Turkey continued in the 2000s. Translations of Tukay's works into Turkish are carried out in accordance with scientific and literary principles.
**Key words:** literary translation, Turkish editions of Tukay.

## ТУКАЙ ТӨРЕКЧӘГӘ ТӘРҖЕМӘДӘ: ФӘННИЛЕК ҺӘМ ӘДӘБИЛЕК

***Р.Ф. Сафиуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Төрки телле дөнья Габдулла Тукай һәм аның иҗаты белән яхшы таныш. Шагыйрь вафатыннан соң 1913–1914 елларда ук татар шагыйре турында мәкаләләр, фотоматериаллар тугандаш төрки халыкларның матбугатында, аеруча төрек телендә [1: 110] басыла. Бөек шагыйребез үзе дә төрки дөнья, төрки телләр һәм төрки мәдәният белән Җаекта яшәгән чагыннан кызыксына башлый.

Төркиядә нәшер ителгән газета-журналларда Тукай иҗатына бәйле темалар, фәнни һәм публицистик язмалар совет елларында да дөнья күрә, 1965–1968 елларда, мәсәлән, «Тукай» бюллетененең 24 саны чыга, әмма шагыйрьнең әдәби әсәрләре төрек телендә шактый соңрак басыла [4: 72]. Тукайның әдәби әсәрләре Төркиядә басылмауны капма-каршы идеология астында яшәгән ике ил арасында әдәби, мәдәни багланышлар сакланмау белән бәйләп карарга кирәктер. Идеологик каршылыклар булмаганда, шул ук совет чорында Габдулла Тукай әсәрләре казах, үзбәк, башкорт, чуаш һ.б. төрки телләргә генә түгел, рус, украин, удмурт, немец, венгр һ.б. телләргә дә тәрҗемә ителә [3: 54].

Төркия галимнәре арасында Тукай шәхесенә игътибар шул исәптән эмиграциядәге татар зыялыларның төрек матбугатында даими чыгышларына бәйле булса кирәк. Рәшит Рәхмәти Арат [8: 76], Гали Акыш, Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт [9: 31], Наилә Бинарк; шулай ук Фуат Көпрүлү, Зөлфикар Хәмзә, Төрекмән Фикрәт, Явыз Акпынар, Гүлһан Атнур, Мостафа Өнәр, Узун Мурат, һ.б. галимнәрнең «Казан», «Милли фольклор», «Казан», «Төрки дөньяның тел вә әдәбият журналы», «Кардәш әдәбиятлар», «Түрк күлтүрү», «Билиг», «Төркият мәҗмугасы», «Төркиләр» һ.б. төрек журналларында татар шагыйре иҗатын яктырткан хезмәтләре басыла [4: 72]. Аларда татар шагыйре иҗат иткән тарихи чор һәм милли-сәяси вазгыять; әсәрләрнең тел-стиль, әдәби эшләнеше мәсьәләләре карала. Фән әһелләрен Тукай шигърияте үзенең югары эстетикасы һәм бер үк вакытта тормышчанлыгы, сурәтләү чараларының байлыгы һәм жанр материалларының төрлелеге белән җәлеп итә.

Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнгән төрек галимәсе Фатма Өзкан 1992 елда «Габдулла Тукай шигырьләре: Күзәтү-текст-тәрҗемә» темасына докторлык диссертациясен яклый. 1994 елда Анкарада филология докторы Ф. Өзкан монография һәм шулай ук шагыйрь әсәрләренең юлга-юл тәрҗемәләре дә кергән 951 бит күләмле академик хезмәтен бастыра [10: 102]. Китапта шагыйрьнең байтак шигырьләре оригиналда һәм тәрҗемәдә тупланган.

Фатма Өзканның бай фәнни хезмәтеннән соң төрек галиме Мостафа Акбашның 1996 елда чыккан «Татар шагыйре һәм язучысы Габдулла Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләре» докторлык диссертациясе дә Тукай фәнендәге бер казаныш иде [7: 4].

Тукай иҗаты белән төрки-төрек телле укучыны таныштыру 2000 елларда тагын активрак дәвам итә. Тукайга багышланган фәнни конференцияләр үткәрелү, фәнни җыентыклар басылу белән беррәттән, тәрҗемәләр дә эшләнә. Чираттагы фәнни басма – «Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр»не 2006 елда халыкара ТӨРКСОЙ оешмасы нәшер итә. Китапта татар шагыйренең Фатма Өзкан тарафыннан тәрҗемә ителгән шигырьләре һәм Асия Рәхимова тәрҗемәсендәге кайбер публицистик әсәрләре, шулай ук «Исемдә калганнар» автобиографик бәяныннан өзекләр урын алган [12: 7].

Төрек телендәге Тукай фәнен 2014 елда чираттагы эзләнү тулыландыра. Төзүчеләр Бирсел Оруч Аслан, Йусуф Өзчобан, шулай ук басманы әзерләүдә катнашкан Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ хезмәткәре Фәридә Таһировага бу очракта Габдулла Тукай шигъриятенең гаять бай һәм һәр заманда актуаль икәнлеген, аның шигъри традицияләре бүген дә дәвам иттерелүен күрсәтү мөһим була [4: 73]. Әлеге максаттан шагыйрьнең аерым әсәрләре сайлап алына. Җыентыкта шулай ук татар әдипләренең Тукай традицияләрен дәвам итеп язылган, шагыйрьгә багышланган шигырьләре тупланып, латин графикасы белән татар һәм төрек телләрендә кертелгән.

2016 елда Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулды. Әлеге дата һәм әдәби, һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан игътибарсыз калдырылмады. Төркия җөмһүриятендә Тукай сүзен яңгыратуда чираттагы адым – «Тукайның тууына 130 еллыгына – 130 шигырь» дигән зур проект булды. Әлеге проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә Тукайның әсәрләре төрек телендә нәшер ителде. Бу – Тукай әсәрләрен төрекчәгә беренче тапкыр әдәби тәрҗемә итү [13: 4] иде.

Әдәби тәрҗемә өчен нигез итеп «Габдулла Тукай. Әсәрләр» (2011–2016) алты томлыкның беренче-икенче томнары алынган. Тәрҗемәгә нигезендәге басманың академик булуы, аның Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгәнлеге, Татарстан китап нәшриятында нәшер ителгәнлеге – проектка карашның җитди, фәнни булуы хакында сөйли.

Проект идеясен Татарстан Язучылар берлеге рәисе, язучы Рафис Корбан тәкъдим иткән. Төрек теленә юлга-юл тәрҗемәне язучы һәм тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты Фатих Кутлу башкарган. Яңа китапка шигырьләрне эстетик кыйммәте, миллият һәм төркият кимәлен беренче нәүбәткә куеп, Фатих Кутлу һәм шагыйрь Ркаил Зәйдулла сайлап алганнар. Китап Анкара шәһәрендә, иң зур төрек нәшриятларының берсе – «Бәнгү»дә басылган. Тукай иҗатының төрекчәгә беренче әдәби тәрҗемәсе мәсьәләсенә, шул рәвешле, Татарстан Республикасы тарафыннан гаять зур диккать күрсәтелгән.

Җыентыкның әдәбилек дәрәҗәсе дә югары булсын өчен ТР Язучылар берлеге һәм тәрҗемәчеләр Фатих Кутлу, Али Акбаш тырышлык куйган. Тукай шигырьләренең юлга-юл тәрҗемәсендә Фатих Кутлу тарафыннан иҗек

саны, рифма, стиль үзенчәлекләре оригиналдагыча сакланган. Төрек теленә әдәби тәрҗемәне төрек шагыйре Али Акбаш башкарган.

Шунысы игътибарга лаек, Фатих Кутлу сүзләренә караганда [2: 9], Тукай шигырьләрнең кайберләре («Милләткә», «Хөрриятькә», «Тәрбиятел-әтфальгә») – госманлы телендә язылганнары – хәзерге төрек телле укучыга да аңлаешлы дип фаразланган. Алар, чорның классик телендә язылганга күрә, тәрҗемәсез китерелгән. Сәбәбе: шагыйрь иҗатына төрек әдәбиятының тәэсире көчле була. «Диван шигырьләре белән таныш укучылар да бу шигырьләрне җиңел аңларлар дип ышанабыз», – диелә китапка керештә. Заманында яшь Тукай диван әдәбияты (Якын Көнчыгыш әдәбиятында лирик шигырьләр җыентыгы. Бу төшенчә фарсы теленнән гарәпчәгә, төрекчәгә һәм башка мөселман халыкларның телләренә кергән [2: 9]) белән мавыга. Нәмикъ Кәмал, Абделхак Хәмит, Абделхәмит Зыя паша, Тәүфикъ Фикрәт, Халит Зыя, Абдулла Җәүдәт иҗаты белән таныша, үзе дә шушы стильдә шигырьләрен иҗат итә. Шагыйрьнең Җаек чорында язылган әсәрләрендә госманлы ягъни иске төрек телендәге сүзләр кулланып язылганнары шактый. «Төрек әдәбияты тәхте тәэсирендә язылган шигырьләрендә дә Габдулла әфәнде мөстәкыйль вә гүзәл тасвирлар дәреҗ итәдер», – дип бәя бирә мондый әсәрләргә Фатих Әмирхан [1: 110].

Габдулла Тукайның төрек телендә беренче тапкыр әдәби тәрҗемәдә басылган шигырьләре үз бәясен алырга лаеклы. «Тукайның тууына 130 еллыгына – 130 шигырь» китабына кереш сүздә Ауразия Язучылар берлеге рәисе, доктор Якуп Өмәроглу: «Шагыйрьнең шигыре, һичшиксез, башка телләргә һәм ләһҗәләргә тәрҗемә ителергә тиеш», дип саный һәм әлеге басмага югары бәя бирә [13: 19].

Фәнни (юлга-юл) һәм әдәби тәрҗемәгә мисал буларак, Габдулла Тукайның мәгълүм «Китап» шигырен төрекчә Фатма Өзкан һәм Али Акбаш тәрҗемәсендә китерәбез:

KİTAP

Gönlüm hiç açılmasa, içim sıkılsa,
Kendi kendimi göremeden, ruhum çökse,
Cefâ çeksem, yorulup busem, şu başımı
Koyamasam, cana yakın, sıcak bir göğse.
Hasret sonra, hasret gelse sıra sıra,
Sıkıcı düşüncelerle tamamen dönse baş,
Kurusa büsbütün akmaz olsa,
Gözlerimden durmadan dökülen yaş.
O zaman ben, elime kitap alırım,
Onun faydalı sahifelerini karıştırırım;
Huzura kavuşur o ânda ruhum, bedenim,
Böylece, dertlerime derman bulurum.
Okuyarak buldum doğru yolu ve sözü,
Okumaktır, benim yol gösteren yıldızım;
Sevmemeğe başladım dünyanın küçüklüğünü,
Açılmakta, nûrlanmaktadır gönlüm, gözüm.
Hafiflerim, arınırım okurken,
Teşekkür ederim, okuduğum kitaba.
İtimâdım artar kendi nefsime,
Ümit ile bakmağa başlarım geleceğe.

*Тәрҗемәче:* Dr. Fatma Őzkan

KİTAP

Rûhum açılmasa içim daralsa
Hayattan usansam gönlüm kararsa
Cefa çeksem bunalsam tek
Gönlümde sıkıntı, gözlerimde yaş
Garip fikirlerle dönüyor başım
Ağlayıp dururum ben yavaş yavaş
İşte bu anlarda beni kurtaran
Hürmetle elime aldığım Kur'an
Huzura kavuşur ruhum ve tenim
Okudukça olur derdime derman
Okuduğum her bir âyet, bir çözüm
Karanlıkta yol gösteren yıldızım
Usanırım o an fâni dünyadan
Aydınlanır, açılır gönül gözüm
Hafiflerim huşû içinde o an
Hak var iken ne sıkıntı ne buhran
Güvenirim artık kendi kendime
Şükür bize kitap gönderen Rahman

*Тәрҗемәче:* Ali Akbaş

«Тәрҗемә әдәби жанрлар арасында иң катлаулысы – башка җирлектә һәм башка чорда туган уй-фикерне үз җирендә терелтү ул. Тәрҗемә – уй һәм хисләрнең катлаулы дөньясын баетучы казаныш», – дигән бәя бирә тәрҗемәгә төрек әдибе, фәлсәфәче Җәмил Мәрич [2: 9]. Дөрестән дә, тәрҗемәләр халыкларның аралашуына, рухи хәзинәләр алмашуга хезмәт итә. Татар әдәбиятының дөнья әдәбиятында тоткан урынын, дәрәҗәсен Габдулла Тукай иҗаты ачык күрсәтә. Төркиядә һәм башка дәүләтләрдә дә бөек шагыйребез әсәрләре күп тапкыр, һәрдаим әдәби, мәдәни-сәнгати, фәнни һ.б. аспектларда тикшерүгә, нәшер ителүгә лаек.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширова И. Тукай төрек телендә язганмы?..: [Г. Тукай иҗаты] // Казан утлары. – 2015. – № 4. – Б. 110–120.

2. Кутлу Ф.Тукай шигырьләре – төрекчәдә // Мәдәни җомга. – 2015. – 23 окт. (№ 41). – Б. 9.

3. Мамытов С. Шәркый дөнья горурлыгы // Татарстан. – 2006. – № 4. – Б. 54.

4. Мөбәрәкшина, А. Тукай шигърияте-Төркиядә: [Төркиядә шагыйрь иҗатына игътибар бар] // Безнең Мирас. – 2015. – № 1. – Б. 72–75.

5. Өнәр М. «Тукай – татар халкының бөеклек символы» (Кардәшләр авазы: Төркия) // Татарстан. – 2006. – № 4. – Б. 46.

6. Тукай Габдулла. Әсәрләр. Академик басма: алты томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011–2016.

7. AKBAŞ, Mustafa. Tatar şair ve yazarı Abdullah Tukay`ın eserlerinden seçmeler ve bunlardaki dil özellikleri / Mustafa AKBAŞ. Doktora Tezi. – İstanbul, 1996.

8. Arat, Reşit Rahmeti. Abdullah Tukay/ Reşit Rahmeti Arat // Türk Kültürü. – 1964. – Sayı: 19. – S. 76–81.

9. Devlet, Nadir. Abdullah Tukay'ın Halk Edebiyatı İle İlgili Düşünceleri» / Nadir Devlet // Milli Folklor Dergisi. – Sayı: 16. – Kış 1992. – S. 30–31.

10. Özkan, Fatma. Abdullah Tukay'ın Şiirleri (İnceleme-Metin-Aktarma) / Fatma Őzkan. – Ankara: Türk Kültürünü Araştırma Enstitüsü Yayınları, 1994. – 958 s.

11. Taymas, Abdullah Battal. Kazanlı Şair Abdullah Tukayef Üzerine // Türk Kültürü. – Sayı: 9. – S. 40.

12. Tukay, Abdullah. Seçilmiş Eserler: Şiirler ve Makaleler, (çev. Fatma Özkan – Asiye Rahimova) // Türk Kültür ve Sanatları Ortak Yönetimi yayın 26. – Ankara, 2006.

13. Tukay, Abdullah. Şiirler (Doğumunun 130. Yılında 130 Şiir) // Abdullah Tukay. – Ankara: BENGÜ yayinlari, 2016. – 224 s.

УДК 821.512.145

# СОВРЕМЕННОЕ СОСТОЯНИЕ ИЗУЧЕНИЯ НАСЛЕДИЯ ТУКАЯ В ТУРЦИИ

***А.Т. Сибгатуллина***
*Институт востоковедения РАН (Москва)*

В статье сообщается о новых достижениях турецких литературоведов и историков в деле изучения наследия Габдуллы Тукая за последние десять лет (2011–2021). Эти публикации можно рассматривать в трех аспектах: 1) материалы проведенных в Турции конференций и симпозиумов, посвященных юбилеям поэта; 2) специальные номера журналов, посвященные Тукаю; 3) обзоры и переводы на турецкий язык книг, изданных в Казани. Автор статьи также поднимает вопрос о качестве переводов на турецкий язык произведений Габдуллы Тукая.
**Ключевые слова**: Тукай, татарская литература, исследования на турецком языке, переводы с татарского языка.

The article reports on studies conducted in the last ten years (2011–2021) by Turkish scholars on the heritage of Tatar poet Gabdulla Tukai. These publications can be analysed along three lines: 1) research that has been presented during conferences and symposia conducted in Turkey and devoted to the poet’s anniversaries; 2) special issues on Tukai; 3) reviews and translations into Turkish of books on Tukai published in Kazan. The author of the article also raises the question of the quality of translation to the Turkish language of the works of Gabdulla Tukai.
**Key words**: Tukai, Tatar literature, research in Turkish, translations from the Tatar language.

# ТӨРКИЯДӘ ТУКАЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ

***Ә.Т. Сибгатулина***
*Россия Фәннәр академиясе Шәркыять институты (Мәскәү)*

Төркиядә Казан татарларының тарихын, мәдәниятен, телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә игътибар юк дип зарланырлык түгел. Университетларның күпчелегендә тюркология бүлекләре бар һәм аларда төрки телләрне, шул исәптән татар телен өйрәнү эше яхшы гына куелган. Төрек тел курумы, Төрек тарих курумы, Төрексой, ИРСИКА (Ислам, тарих, сәнгать һәм культураны өйрәнү мәркәзе) кебек дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар да Казан белән тыгыз элемтәдә эшли. Татарстан архивларына килеп эзләнгән, татарларның күренекле шәхесләрен төрек укучыларга таныту максатында гыйльми хезмәтләр язган Ибраһим Мараш, Исмәгыйль Төрекоглу, Әхмәт Канлыдәрә, Али Мәртхан Дүндар кебек бер буын тарихчылар инде бу өлкәдә профессор дәрәҗәсенә лаек булды. Аларның һәм башка галимнәрнең соңгы елларда чыгарган Йосыф Акчура [2], Г. Исхакый [8], Габдерәшит Ибраһим [7] хакында, моңа кадәр исемнәре безгә билгеле булмаган, Госманлы империясе тарихында эз калдырган татар кешеләре [9], Болгар һәм Казан ханлыклары [17], җәдитчелек хәрәкәте турындагы [1] хезмәтләре Төркиядә дә, республикабызда да зур кызыксыну уята. Инглиз телендәге «Татар империясе» китабын [15] да төрек галимнәре бездән күпкә алда, китап басылып чыгар-чыкмас, төрекчәгә тәрҗемә итте һәм яхшы гына тираж белән сатуга чыгарды. Татар теленең грамматикасы [5], сүзлек байлыгы [10], мишәр диалекты [3] хакындагы эзләнүләр дә соңгы елларда төрек тюркология фәне ирешкән казанышлар рәтендә. Татар тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле китапларны бастыру

өлкәсендә аеруча Истанбулдагы «Өтүкән» нәшрияты күп еллар буе уңышлы эшләп килә, соңгы елларда «Догу көтепханәсе», «Кәсит», «Гәҗә китаплыгы» исемле нәшриятлар да татарлар белән бәйле китапларга урын бирә башлады. Төркиягә килен булып төшкән галимә кызларыбыз (Чулпан Зарипова-Чәтин, Рамилә Яруллина-Йылдырым, Ләйсән Шаһин һ.б.) төрле университетларда доцент, профессор буларак дәрес бирә һәм татар мәдәниятен төрек укучыларга танытуда үзләреннән өлеш кертә. Истанбул, Әнкара, Измир кебек зур шәһәрләрдә оешкан татар җәмгыятьләрендә даими рәвештә кичәләр, бәйрәмнәр, төрле очрашулар булып тора, журналистларыбыз (Сәгыйть Хәйри, Раушания Алтай, Роза Корбан һ.б.) ике илдә булган милли яңалыкларны хәбәр итеп торалар. Төрекчә чыга торган «Кардәш каләмнәр», «Идел-Урал араштырмалары» кебек журналларда татар культурасына кагылышлы язмалар басылып тора, мәсәлән, «Кардәш каләмнәр»нең махсус саннары Тукайга, Дәрдмәндкә, Мәҗит Гафурига багышланып чыкты. Телевидение программаларында, бигрәк тә «ТРТ Аваз» каналында татар авыллары, күренекле шәхесләребез хакында документаль фильмнар хәзерләнеп эфирга чыкты. Ике як өчен дә файдалы булган мондый хезмәттәшлекнең дәвам итүе күңелне сөендерә һәм иҗатка яңа мөмкинлекләр ача.

Бу мәкаләдә мин соңгы ун ел (2011–2021) эчендә төрек матбугатында Габдулла Тукай мирасына кагылышлы басылган хезмәтләр белән кыскача таныштырып китәргә телим, уйлавымча, татар укучыларының күпчелегенә болар хакында җитәрлек мәгълүмат килеп ирешмәгәндер, мөгаен. Гомуми рәвештә бу төр хезмәтләр өч өлкәдә алып барыла дип әйтергә була: 1) Тукайның 2011–2016 елда билгеләп үтелгән юбилейлары мөнәсәбәте белән оештырылган гыйльми форумнар һәм аларда ясалган чыгышларның басма текстлары; 2) аерым журналларның Тукайга атап чыгарылган махсус саннары һәм төрле басмаларда урын алган башка мәкаләләр; 3) Казанда басылган китапларның тәрҗемәләре яки аларны танытучы язмалар.

Төрек галимнәре Казандагы Тукай конференцияләренә һәм бәйрәмнәренә бик теләп катнашу белән беррәттән, үзләре дә матур гына чаралар оештырып торалар. Шагыйрьнең туына 125 ел тулу уңае белән Төрексой оешмасы 2011 елны халыкара Габдулла Тукай елы дип игълан итте, Әнкараның бер урамына (Бахчелиевләр префектурасы) Габдулла Тукай исеме бирелде һәм бюсты ачылды. Тукай елын Төрексой җитди генә бер семинар (чалыштай) уздыру белән тәмамлады. 2011 елның 18 ноябрендә Истанбулда ИРСИКА тарафыннан бер форум оештырылды, анда ясалган чыгышларның текстлары да бер җыентык [6] итеп басылды. Төрек тел корумы, Казанда 2011 елының 25 апрелендә узган «Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар» исемле юбилей конференциясе материалларын тиз арада төрекчәгә тәрҗемә иттереп, үз органы булган «Төрки дөньяның теле һәм әдәбияты» журналының Тукай өчен махсус аерылган бер санында (№ 32, 2011) бастырып чыгарды. Бу эшне оештыруда Эгей университеты профессоры Мостафа Өнәр һәм ул вакыттагы Төрек тел корумы җитәкчесе профессор Шөкрү Халук Акалын әфәнделәр башлап йөрделәр. Татар галимнәренең чыгышларын төрек теленә тәрҗемә итүдә яшь тюркологлар Синан Гүзәл, Гөздә Гюнгөр, Мехмет Ясин Кая, Морат Өзшаһин, Өлкү Полат, Динара Дюйсебаева, Сәхәр Мәмиш, Ширин Аксойлар актив эшләде. Казан галимнәренең күпсанлы чыгышлары янында, тагын Мостафа Өнәр әфәнденең, Гөлхан Атнурның, чуваш теле белгече, татар кияве

профессор Бүләнт Бәйрәмнең, М. Кайгананың, Д. Дюйсебаеваның, Ө. Полатның төрки әдәбиятларның күренекле шәхесләре белән Тукай иҗатындагы уртак якларны ачыклауга багышланган мөстәкыйль мәкаләләре дөнья күрде. Әлеге материаллар арасында Рамилә Яруллина-Йылдырымның Төркиядә Тукай хакында басылган кайбер хезмәтләргә кыскача күзәтү ясаган мәкаләсе [21] булуын да монда искәртеп китим.

2016 елда Истанбулның Багҗылар префектурасы һәм Мәхмәд Акиф Эрсой фонды Казанда халыкара «Мәхмәд Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» исемендәге тантаналы симпозиумны оештыручылардан булган иделәр, ул форумда ясалган чыгышлар да Төркиядә җитди бер җыентык хәлендә нәшер ителде [19]. Евразия язучылар берлегенең рәсми органы булган «Кардәш каләмнәр» журналы Тукайның туына 130 ел тулу уңае белән махсус бер сан хәзерләде (№ 112 апрель 2016). 2014 елда Көмән нәшриятында «Мин Тукайга киләм» исемле татарча шигырьләр җыентыгы (Казан, 1996) төрекчәгә тәрҗемә ителеп басылып чыкты [18].

Татар һәм төрек галимнәре азмы-күпме үзара китап алыш-бирешендә булсалар да, Казанда чыккан күп кенә әһәмиятле әсәрләр аларга ирешми кала, шуңа күрә яңа китапларны таныту өчен язылган матбугат хәбәрләренең роле аз түгел. Әйтик, ИЯЛИ дә хәзерләнгән фундаменталь Тукай энциклопедиясе, ике томлык «Тукай – истәлекләрдә» кебек мөһим хезмәтләрне танытып, саллы төрек журналларында хәбәр урнаштыру [14; 16] бик урынлы булды. Минемчә, мондый юнәлештә эшчәнлекне тагын да арттырырга кирәк, югыйсә, татар галимнәренең фәнни табышлары һәм казанышлары, күп очракта тар даирәгә генә мәгълүм булып, үз эчебездә йомылып кала.

Тәрҗемәләр турында сүз чыккач, шуны да әйтеп китим: Тукай турында төрекчә язылган мәкаләләрдә авторлар тарафыннан шагыйрьнең әсәрләрен сүзгә-сүз тәрҗемә итеп бирү очраклары еш күренә. Гадәттә, башта кирилл хәрефләрендәге татарча текст латин графикасына күчерелә, аның янында да сүзгә-сүз төрекчәсе бирелә, бер карасаң, бу бик әйбәт хәл: укучыга оригиналны үзе укып аңлау мөмкинлеге туа. Ләкин күңелне борчыган бер нәрсә бар: ул да булса, татар әлфибасындагы каты *г* һәм *к, ә, ң, э* кебек үзенчәлекле хәрефләренең төрек әлифбасында булмавы, җитмәсә, игътибарсызлык аркасында кайбер сүзләрне тулысынча «төрекчә» итеп уку кебек хаталар текстның оригинальлеген бозуга китерә. Ә инде сүзгә-сүз тәрҗемә мәсьәләсе тулысынча моны эшләгән кешенең татар телен ни кадәр үзләштерүенә һәм әсәрнең контекстын белүенә бәйле. Ни кызганыч, күпчелек очракта, теге яки бу әсәрнең язылу вакыты һәм шул чорның милли-тарихи шартлары авторлар тарафыннан бөтенләй искә алынмый, нәтиҗәдә, татар шагыйренең ни әйтергә теләгәнен төрек укучы аңлый алмый. Бу уңышсыз тәҗрибәләргә бер мисал итеп, «Кардәш каләмнәр» журналында урын алган Тукайның сигез әсәрен һәм аларның тәрҗемәсен [4] китерергә мөмкин: «монда» урынына «мунда», «белән» урынына «билен», моң/мун, кем/ким кебек киң таралган хаталар өстенә, сүзләрнең бер-берсенә кушылып язылуы, үзенчәлекле детальләр өчен бернинди искәрмәләр дә куелмавы, язманың кыйммәтен бик тә төшерә. Ә бит Габдулла Тукайның төрек теленә поэтик әсәрләренең сыйфатлы гына бер тәрҗемәсе билгеле: 1994 нче елда Гази университеты профессоры Фатма Өзкан (милләте буенча Кырым татары) бик җентекләп, бөтен кирәкле искәрмәләрне кулланып, Тукайның 370 ләп әсәренең анализын, транскрипциясен һәм төрекчәгә тәрҗемәсен хәзерләгән һәм Әнкарадагы

Төрки культураны өйрәнү институты нәшриятында бастырып чыгарган иде [13]. 958 битле бу академик хезмәтнең кыйммәтен төрек галимнәре һаман да белеп бетермиләр кебек, югыйсә, аз тираж белән нәшер ителгән әлеге китапның күптән инде яңа басмалары чыгарга тиеш иде.

Тукай мирасы төрек галимнәренең, аеруча яшь тюркологларның дикъкатен даими җәлеп итеп тора, татар шагыйрен беләләр һәм яраталар, үзләренең фәнни эзләнүләре өчен нинди дә булса яңа темалар уйлап табалар, билгеле темаларга исә үз карашларын тәкъдим итәләр [мәсәлән, кара: 11; 13; 20]. Шул ук вакытта, башка татар язучыларын да, мәсәлән, С. Хәким, Г. Афзал, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Р. Мөхәммәдиев кебек шәхесләребезне тануларына, өйрәнүләренә күңел сөенә. Мондый фәнни һәм мәдәни хезмәттәшлек гел шулай дәвам итсен, төрек һәм татар халыкларының тугандашлыгы, якынлыгы мәңгелек булсын иде диясе килә.

ӘДӘБИЯТ


1. Adilhan Adiloğlu. Ceditçilik Dönemi. – Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak ve Hürriyetleri Meselesi. İstanbul, Gece Kitaplığı, 2020.

**2.** Akçura, Yusuf. Sürgünden İstanbul'a. Darülhilafet Mektupları / Haz. İsmail Türkoğlu. – İstanbul: Ötüken, 2016.

3. Alkaya, Ercan. Mişer Tatar Türkçesi. – İstanbul: Kesit Yayınları, 2014.

4. Biray, Nergis. Eynel, Sema. Abdullah Tukay (1886–1913) // Kardeş Kalemler. – 2019. – № 148, Nisan. – S. 13–29.

5. Çakmak, Cihan. Tatar Türkçesi İle Türkiye Türkçesinde Görülen Yalancı Eş Değer Kelimeler. – Gece Kitaplığı, 2016.

6. Doğumunun 125.yılında Abdullah Tukay. – İstanbul: IRCICA, 2014.

7. Japonya Seyyahı Abdürreşit İbrahim'in İzinde / Editör A. Merthan Dündar. – İstanbul: Doğu Kütüphanesi, 2020.

8. Kanlıdere, Ahmet. Sosyalizm'den Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki. – İstanbul: Ötüken, 2019.

9. Nurali bin Hasan. Sultan Abdulhamid'in Sarayında. Bir Tatar Müderrisin İstanbul, Bursa ve Surre Alayı ile Hac Hatıraları (1906–1907) / Arapçadan tercüme Ömer Hakan Özalp. –İstanbul: İşaret, 2021.

10. Öner, Mustafa. Kazan Tatar Türkçesi Sözlüğü. – Ankara: Türk Dil Kurumu Yayınları, 2015.

11. Öner, Mustafa. Abdullah Tukay ve Seyahat Yazıları // Geçmişten Günümüze Seyahat Edebiyatı, Elginkan Vakfı 4. Uluslararası Türk Dili ve Edebiyatı Kurultayı Bildirileri 24–25–26 Nisan 2019 / Yayına Hazırlayan: Emin Gürsoy Naskali. – İstanbul: Elginkan-Kitabevi. – S. 275–286.

12. Özkan, Fatma. Abdullah Tukay'ın Şiirleri, İnceleme-Metin-Aktarma. – Ankara: Türk Kültürü Araştırmaları Enstitüsü Yay.: 136, Seri: IV, N. 38. 1994.

13. Özkaya, Yılmaz. Abdullah Tukay ve Özĕlgen Ömid «Kesilen Ümit» Şiir Üzerine Bir Çözümleme // Yavuz Akpınar Armağanı / Editörler: Nazım Muradov, Yılmaz Özkaya. – Ankara, Bengü Yayınları, 2018. – S. 467–486.

14. Rameev, Z, Rami, İ. «Gabdulla Tukay Éntsiklopédiyesé [Abdullah Tukay Ansiklopedisi], Baş rédaktorı Z.Z. Rameev, Galimcan İbrahimov is. Tél, Edebiyat hem Sengat İnstitutı» // Marmara Türkiyat Araştırmaları Dergisi. –2020. – № 7. – S. 239–242.

15. Ross, Danielle. Tatar İmparatorluğu. Kazan Tatarları ve Çarlık Rusya'sının Oluşumu / Türkcesi: Kadri Mustafa Orağlı. – İstanbul: Ötüken, 2019.

16. Sibgatullina, Alfina. Tukay Yadigarlerde. 2 Cilt / Haz. Prof. Dr. R. İslamov, Doç. Dr. C. Minnullin. – Kazan, Cıyın, 2015. // Türk Kültürü. – 2016. – № 2. – S. 155–157.

17. Tanuğur, Eda. Kazan Bulgar ve Tatar Tarihi. – Ötüken Neşriyat, 2020.

18. Tukay'a Geliş. – İstanbul: Kömen yay., 2014.

19. Türk Dünyasını Aydınlatanlar. Mehmet Akif Ersoy ve Abdullah Tukay Uluslarası Sempozyumu. Kazan-Tatarstan. – İstanbul: Bağcılar Belediyesi, 2016.

20. Uzun, Murat. Abdullah Tukay'in Tatarca Üzerindeki Etkileri // Turkish Studies – International Periodical For The Languages, Literature And History Of Turkish Or Turkic Volume 8/4 Spring 2013. – S. 1423–1440.

21. Yarullina-Yıldırım, Ramile. Abdullah Tukay'in Sanatinin Türkiye'de Araştirilma Düzeyi// Türk Dünyası Dil ve Edebiyat Dergisi. – Sayı 32, 2011. – S. 217–222.

УДК 81/8

# ЯВЛЕНИЕ ОМОНИМИИ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ТУКАЯ

**_Р.Р. Салахова_**
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В данной статье предпринята попытка анализа *употребления* омонимичных единиц, придающих особую экспрессию творчеству Г. Тукая.
Произведения Г. Тукая расскрывают не только богатство татарской литературы, но и многогранное наследие татарского языка, открывшее возможность художественного использования общенародного языка. В его поэзии как средство своеобразной звуковой игры используются омонимические рифмы. Применяя омонимию в качестве рифмующихся слов, Г. Тукай использует и омофоны, и омоформы, и омонимичные суффиксы, которые в стихотворном контексте делают рифму интересной и удивляют своей неожиданностью. Исследование омонимичных отношений в литературных произведениях позволяет определить особенности, связанные с довольно сложными отраслями языкознания, такими как морфонология, морфология, стилистика, синтаксис.
**Ключевые слова:** омонимия, омофон, омосуффикс, омоформа, татарский язык.

This article is an attempt to analyze the use of homonymous units that give special expression to the work of G. Tukay.
The works of G Tukay are not only the richness of the Tatar literature, but also the multifaceted heritage of the Tatar language, which opened up the possibility of artistic use of the national language. In his poetry, homonymous rhymes are used as a means of a kind of sound play. Applying homonymy as rhyming words, G. Tukay uses homophones, homoforms, and homonymous suffixes, which in a poetic context make rhyme interesting and surprise with their unexpectedness. The study of homonymous relations in literary works allows us to determine many features associated with rather complex branches of linguistics, such as morphology, morphology, stylistics, syntax.
**Key words:** homonymy, homophone, homosuffix, homoform, Tatar language.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ОМОНИМЛЫК КҮРЕНЕШЕ

**_Р.Р. Сәлахова_**
*Казан (Идел буе) федераль университеты (Казан)*

Мәгълүм булганча, XX гасыр башында халык теленә нигезләнгән әдәби телнең киң кулланылышка керүе матур әдәбиятның жанр һәм стиль ягыннан баюына китерә. Г. Тукайның бу өлкәдә керткән өлешен бәяләп бетергесез. Шагыйрьнең теле ул иҗат иткән чорның әдәби телен тәшкил итә, шуңа күрә аның әсәрләренең телен тикшерү шул чорның әдәби теле торышын гына түгел, аның тарихын, үсешен һәм телнең төп үзенчәлекләрен өйрәнү өчен дә кызыклы материал булып тора. Г. Тукай әсәрләре әдәбият хәзинәсе генә түгел, ул гомумхалык телен сәнгатьчә файдалану мөмкинлеген ачкан татар теленең бай мирасы да. Габдулла Тукай иҗатының тел-стиль үзенчәлекләре, аның әсәрләрендәге сурәтләү чаралары байтак кына фәнни хезмәтләрнең нигезен (Х. Курбатов, В. Хаков, И. Абдуллин, И. Бәширова һ.б. [1], [2]) тәшкил итүгә карамастан, әдипнең әсәрләрендә күзәтелгән төрле лингвистик күренешләр тулысынча өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Әлеге мәкаләдә Г. Тукай иҗатында омонимлык күренешенә күзәтү ясала.

Татар телендә омонимлык күренеше лексик мәгънәгә ия булган мөстәкыйль тел берәмлекләре, төрле функция үтәгән һәм төрле мәгънәгә ия булган кушымчалар арасында, шулай ук сүзләр белән кушымчалар арасында күзәтелә. Сүзләр арасындагы омонимлык күренешен билгеләү

элләни авырлык тудырмый, чөнки алар лексик мәгънәгә ия. Кушымчаларның омонимлыгына килгәндә, хәл бераз катлаулана төшә, чөнки аларның мәгънәләре һәм функцияләре бары тик тамырга яки нигезгә ялгану аша гына ачыклана. Сүзләр һәм кушымчалар арасындагы омонимлык мөнәсәбәтләре шик тудырмый, чөнки алар икесе ике төрле тел берәмлеге һәм, безнең фикеребезчә, аваз тәңгәллеге аларны омоним дип билгеләү өчен нигез була ала [3], [4].

Габдулла Тукай әсәрләрендә телнең теләсә кайсы берәмлекләре арасында омонимлык күренешен күзәтергә мөмкин. Түбәндәге мисалларны карап китик:

**1. Сүзләр омонимлыгы**:

а**)** ***лексик,*** ягъни бер үк сүз төркеменә карый торган аваздаш тамыр сүзләр:

*Уйласаң ул якты көнне, килә күз* ***яшь;***

*Хозур ла соң! Инсан өчен бу хәл, бу* ***яшь****!(Бәйрәм вә сабыйлык вакыты)*

ә) ***лексик-грамматик,*** ягъни төрле сүз төркеменә караган омоним сүзләр:

**Омофоннар:**

*Ә шулаймы? – Акча* ***барда*** *бар да дуст шул, бар да яр,*
*Акча исе чыкмый торса,* ***бар да*** *яныңнан таяр! (Теләнче).*

Әдипнең иҗатында кушымчалар омонимлыгына да байтак мисаллар табылды:

2. **Кушымчалар омонимлыгы**

а) ***лексик,*** ягъни яңа лексик мәгънә ясый торган сүз ясагыч аваздаш кушымчалар:

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр там****чы****сы;*
*Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһам****чы****сы (Мәхәббәт)*

ә) ***грамматик***, ягъни сүзнең грамматик мәгънәсен үзгәртә торган форма ясагыч һәм бәйләгеч(төр һәм төрләндергеч) омоним кушымчалар:

*Һәм бер эшне әнкәемнең иснә төш****ер,***
*Дисен аңар бер фәрештәң: «Коймак пеш****ер****!» (Йокы алдыннан).*

*Җиһанда, санки, бер сатлык товар****сыз,***
*Имамнар кайда аударса – авар****сыз*** *(Татар кызларына).*

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөнья-****сы-н,***
*Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калма-****сын****.*

б**)** ***лексик-грамматик***, ягъни сүз ясагыч һәм граматик (форма ясагыч һәм бәйләгеч) кушымчаларның аваздашлыгы:

*Тырышма нафилә җиргә вакты гаҗзеңне икърар****га:***
*Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и кар****га****! (Мөтәшагыйрьгә).*

*Тегермән әйләнә; әйләнсә дә, тартылмыйдыр яр****ма;***
*Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын яр****ма*** *(Мөтәшагыйрьгә).*

*Тип! Дөньяда ач-ялангачларны бел****мә,***
*Иске дөнья тузанын ит күзгә сөр****мә***
*(Дөньяда торыйкмы? – дип киңәшләшкән дустыма).*

*Бәхил бул, дуст! Мин һәм тиздән менәм дар****га****, –*
*Туйсын ашап җансыз тәнне козгын, кар****га;***
*(Дөньяда торыйкмы? – дип киңәшләшкән дустыма).*

*Бер тигез җирдер дисәм, бассам аягымны – бат**а**;*
*Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып кош дип бак**а** (Өмид).*

*Караңгыдыр, күңелсездер гомер юл**ы**.*
*Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,*
*Шиксез, аның җәрәхәте күкрәгендә*
*Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тул**ы** (Сәрләүхәсез).*

*Сабит сорый җентекләп, һәр нәрсәне бөртек**лә-п**,*
*Әти белән әнисе җавап бирә бик ип**ләп** (Сабитның укырга өйрәнүе).*

*Сүз юк күзсез*
*Татарларга,*
*Сүз бар күзле*
*Хәзрәт-**ләр-гә**:*
*Чакырмыйлар*
*Халыкны безнең*
*Хәлне аз-маз*
*Рәт-**лә-ргә** (Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр)*

*Китә башлады бездән инде кош-**лар**;*
*Алар бездән ерак җирләрдә кыш-**ла-р** (Сәрләүхәсез).*

Омонимлык күренешенең өченче төренә сүзләр һәм кушымчалар арасындагы аваздашлыкны мисал итеп китерергә мөмкин. Г. Тукай әсәрләрендә мондый төр омонимнар да шактый күп:

3. **Сүзләр һәм кушымчалар омонимлыгы**:
а) **тамыр сүз + сүз ясагыч кушымча**:

*Синең якты көнең кемнәргә тан**сык**?*
*Кирәксә, яшь җиренә кара кан **сык**! (Кемне сөяргә кирәк?)*

*Синең төсле бераү ул: бергә-бер **сез**,*
*Көрәшкәнне җиңалмый ул кабер**сез** (Тормыш).*

*Сезнең әүлядыңыз сездәй әдәп**сез**,*
*Әдәпсезлектә сабит сез, әбәд **сез** (Татар кызларына).*

*«Юк ла, и Арба, Чана! – ди, – сезгә тормыш бик уң**ай**,*
*Эшләсәгез алты ай сез, ял итәсез алты **ай** (Арба, чана, ат).*

ә) **тамыр сүз + грамматик кушымча:**

***Без** сугышта юлбарыстан көчле**без***
***Без** тынычта аттан артык эшли**без***
*(Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре).*

***Сез**и күрдек гасырларча көтеп без, –*
*Килер**сез** дип, һәмишә күз тотып без*
*(Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә).*

б) **ярдәмлек сүз (кисәкчә, теркәгеч) + грамматик кушымча**

*Бөтен дөнья аппак булып кар яуган**да**,*
*Ишек алды, урам, түбә агарган**да**,*
*Аппак булып кайтып килә безнең Бабай,*
*Безгә төрле-төрле уенчык алган **да** (Ак бабай).*

*Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кич**тә**!*
*Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;*
*Утырасыз рәхәтләнеп, тезелешеп, –*
*Шатлык сезгә, уңайсызлык килми һич **тә** (Кышкы кич).*

*Күп яттык без*
*Мәдрәсә**дә**,*
*Аңламадык*
*Бер нәрсә **дә** (Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр).*

Югарыда күренгәнчә, шагыйрь иҗатында омонимлык күренеше шактый киң кулланылган. Аеруча лексик-грамматик, ягъни сүз ясагыч һәм граматик (форма ясагыч һәм бәйләгеч) кушымча омоморфемалар шактый күп очрый.

*Да, дә, та, тә* кисәкчәләренең урын вакыт килеше кушымчаларына (*-да*/*-дә, -та*/*-тә*) аваздашлыгы еш күзәтелде. Аларның кулланылышында кызыклы бер үзенчәлек, Г. Тукай беренче юлда, гадәттә, кушымчалы вариантны бирә, икенче юлда гына кисәкчә варианты куллана:

*Күрәмсез, дустларым, күз килде тыш**та**;*
*Озак тормас, килер ак тунлы кыш **та** (Күз).*

*Күп яттык без мәдрәсә**дә**,*
*Аңламадык бер нәрсә **дә** (Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр).*

Ә менә тамыр һәм кушымчаларның омонимлыгына мисалларда ике төрле кулланылыш күзәтелә:

*Синең төсле берәү ул: бергә-бер **сез**,*
*Күрәшкәнне җиңалмый ул кабер**сез**(Тормыш).*

*Сезнең әүлядыңыз сездәй әдәп**сез**,*
*Әдәпсезлектә сабит сез, әбәд **сез** (Татар кызларына).*

Борынгы формаларның омонимлык мөнәсәбәтен тикшерү өчен дә Г. Тукай иҗаты кыйммәтле материал ролен үти ала. Морфемаларның омонимлыгын билгеләү барышында без моңа тагын бер кат инандык: Мәсәлән, инфинитивның ***-мага/-мәгә*** формалары исем ясагыч ***-ма/-мә*** һәм юнәлеш килеше ***-га/-гә*** комплексыннан торган кушымчаларга омоним булып тора:

*Үтте аннан, китте башка бүл**мә-гә**,*
*Шундый күренеш – кызганычтыр күр**мәгә***
*(Печән базары Яхуд яңа кисекбаш).*

Мисаллардан күренгәнчә, Г. Тукай иҗатында омонимлык күренеше, нигездә, тамыр һәм кушымча (суффикс) арасында күзәтелә. Бу телнең агглютинативлыгы белән аңлатыла.

Омонимлык күренешен матур әдәбиятта шигъри сурәт ясау чарасы буларак тикшерелгән хезмәтләр юк түгел. Мәсәлән, И. Абдуллин «Г. Тукай иҗатында каламбур һәм сүз уйнату дигшн мәкаләсендә омонимнарны комик эфект тудыра торган тел-сәнгать чарасы буларак билгели. Автор мисал итеп шагыйрьнең түбәндәге шигырьләрен китерә:

*Бу көнгәчә булган хәлне монда **яздым**,*
*Яза-яза артык язып китә **яздым** (Бәхресани).*

*Ул Баш әйтә; «Син вагоннан төш хәзер,*
*Бик якынлашты кирәклк төш хәзер (Печән базары).*

*Яхшылыкка эреп китәм – **балавыз мин**,*
*Мактап сөйлим изге эшне – **бал авыз** мин (Бер татар шгыйренең сүзләре).*

*Яратмыйм бер дә **остабикәләрне**,*
*Сези алдарга **оста бикәләрне** (Татар кызларына).*

И.Б. Бәширова билгеләвенчә, әлеге хезмәттә омонимнар сәнгатьле сөйләм берәмлеге буларак тикшереләләр. «Тел күренеше булган омоним сөйләм

эчендә башка исем белән – каламбур дип атала һәм сатирик-юмористик максатларда, сүз уйнатып, сурәт-образ барлыкка китерүнең бер өлеше буларак анализлана» [1: 186].

Галимә аваздаш сүзләрнең язма текстларда кулланылыш үзенчәлекләрен билгеле бер эзлеклелектә ныклы системага утыртып тикшерү зарурлыгын ассызыклый. Без бу фикер белән тулысынча килешәбез һәм матур әдәбият әсәрләрендә омонимлык күренешен тикшерү барышында сүзләр омонимлыгын гына түгел, ә кушымчаларның да үзара омоним була алуларын, гомумән, омонимлык күренешенең телнең төрле берәмлекләре арасында күзәтелүен дә исәпкә алу кирәк дип саныйбыз.

Шулай итеп, телдә омонимлык күренешен билгеләгәндә, телнең морфонологик үзенчәлекләрен исәпкә алу бик мөһим, чөнки морфемалар чигендә күзәтелгән төрле аваз үзгәрешләре омонимик мөнәсәбәтләр туугa сәбәп була алалар. Телдәге мондый мөнәсәбәтләрне тикшерү әдәби әсәрләрнең телстиль үзенчәлекләре белән беррәттән, морфонология, морфология, синтаксис, сүзъясалышы кебек тел белеменең шактый катлаулы тармаклары белән бәйле күп кенә үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Бәширова И.Б. Татар әдәби теле. Семасиология. – Казан, 2010. – 532 б.

2. Курбатов Х.Р. Грамматические омонимы в татарском языке // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – С. 307–311.

4. Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка. – Казань: Gumanitarya, 2007. – 204 с.

5. Татар грамматикасы: Өч томда. – Т. 1. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 642 б.

6. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 511 б.

УДК 82-94

## МОТИВ СИРОТСТВА В ПОВЕСТИ Г. ТУКАЯ «ИСЕМДӘ КАЛГАННАР»

***С.Г. Самитова***

*Казанское высшее мусульманское медресе*
*имени 1000-летия принятия Ислама (Казань),*

***И.Г. Закирова***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В данной статье анализируется психологический трагизм героя автобиографической повести «Исемдә калганнар» Габдуллы Тукая. Социальные и эмоциональные проблемы, которые проявились в жизни и творчестве поэта, раскрываются через призму его сиротства. В статье выявлены причины затруднений в общении современниками и взаимодействии с противоположным полом.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, автобиографическая повесть, мотив сиротства, психология.

This article analyzes the psychological tragedy of the hero of the autobiographical story «Isemde kalgannar» Gabdulla Tukai. Social and emotional problems that manifested themselves in the life and work of the poet are revealed through the prism of his orphanhood. The article identifies the reasons for the difficulties in communication with contemporaries and interaction with the opposite sex.

**Key words:** G. Tukai, autobiographical story, motive of orphanhood, psychology.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ИСЕМДӘ КАЛГАННАР» ПОВЕСТЕНДА ЯТИМЛЕК МОТИВЫ

***С.Г. Сәмитова***
*Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исем. Казан югары мәдрәсәсе (Казан),*
***И.Г. Закирова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Татар әдәбиятында ятимлек темасын яктырткан шактый әсәрләр бар. XX йөз башы татар әдәбиятында ятим балаларның ачы язмышы, нечкә психологик халәте аеруча Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» (1909) һәм Фатих Әмирханның «Ул үксез бала шул» (1913) әсәрләрендә чагыла.

Без бу мәкаләдә Г. Тукай иҗаты аша ятимлекнең бала психологиясенә тәэсирен ачыкларга омтылдык. Бу теманың актуальлеге беренче чиратта, Г. Тукай иҗатының ятим бала трагедиясе аша махсус өйрәнелмәве, икенче яктан хәзерге заманда да ятимлек мәсьәләсенең көнүзәгеннән китмәве белән аңлатыла. XX–XXI йөздә төрле социаль-иҗтимагый вакыйгалар – инкыйлаб, сугышлар һәм ачлык – илдә ятимлек артуга китерә. Моннан тыш ятимлеккә китергән башка социаль сәбәпләр дә күп. Бу – бүгенге яшьләрнең җаваплылыгы, гаилә корырга әзер булмавы, бала алдында җаваплылык тоймау, наркомания, алкоголизм кебек күренешләр. Мәкаләдә баланың ятимлекне ничек кабул итүе, аның киләчәгендә бу фаҗиганең кайтавазы Г. Тукайның «Исемдә калганнар» автобиографик повесте һәм шигырьләре аша ачыла.

Габдулла Тукай үзенең «Исемдә калганнар» повестена сүз башында түбәндәге фикерне искәртеп үтә: «Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде» [2: 5 т., 133]. Бу повестьның автобиографик характерда булуы, аның укучыга тәэсир көчен тагын да арттыра гына. Г. Тукай үзе күргәннәрне, үз башыннан кичергәннәрне тәфсилләп, яңадан бер кабат кичереп бәян итә. Тәрҗемәи хәлен яза башлаган автор, коры гына, фактларны язу белән генә чикләнә алмый. Башыннан кичкәннәр, авыр хатирәләр һәм якты истәлекләр аны яңадан балачакка алып китә.

Бала туу белән ана белән бала бер-берсеннән аерылгысыз симбиозны тәшкил итәләр. Ананың җылысы, ул башкарган бишек җырлары аша бала тәүге тапкыр әйләнә-тирә дөнья белән таныша, туган телен һәм көен ишетә. Шушы авазлар һәм көй кешене олы тормышка әзерли. Тик Апушка ана кочагында озак назланырга насыйп булмый. Ул туып 5 ай үтү белән әтисез кала һәм беркадәр вакыттан сон әнисе Мәмдүдә дә, аны авылның ярлы карчыгына (Шәрифә карчыкка) тәрбиягә биреп калдырып, кабат кияүгә чыга. Г. Тукайның 1910 елда иҗат ителгән «Өзелгән Өмид» шигырендә дә сүз шул хакта, ул үзенең тормышына «Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы» дип бәя бирә, алдарак язылганча тормышының «шактый ямьсез, шактый караңгы» булуын үз дә ятимлек, әнисез калу белән бәйли.

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!
Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы [2: 2 т., 152].

Шәрифә карчык Апушның ачы язмышының беренче сәбәпчесе була. Ул бу хакта: «Хәзер авылда минем вакъты сабавәтемне күргән карчык вә

хатыннар мөрәббия карчыгымның минем илә начар мөгаләмәдә булганлыгын үземә хикәят итәләр», – дип искә ала [2: 5 т., 134]. Г. Тукай, үзенең яше кечкенә булуга бәйләп, бу вакыйларны онытуын яза. Шулай да, повесть дәвамында төп каһарманның аерым вакыйгаларны, бигрәк тә фаҗигале һәм аның балалыгында тирән психологик киенкелек тудырган вакыйгаларны, үксезлектән күңеле китек баланың авыр тормыш вакыйгаларын махсус онытырга теләве яки аң алды катламын чыгарырга тырышуы ачык сизелә.

Бу урында шуны да әйтеп китү урынлы, кечкенәдән ятим калган балаларның психологик яктан тиешенчә җитлекмәве, аларның җәмгыятьтә үз урынын табуда һәм кешеләр белән узара мөнәсәбәтләр урнаштыруда, шәхес буларак формалашуда тайпылышлар китереп чыгара. Бу тайпылышлар, иң беренче чиратта, капма-каршы җенес вәкилләре белән мөнәсәбәтләр төзүдә ачык чагыла. Элемтәнең бик иртә өзелүе тагын да куркынычрак нәтиҗәләргә китерә. Психологлар фикеренчә, шәхеснең киләчәктә, ягъни балигъ булгач тормышын коруында да, ир-ат һәм хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләренең асылында, гаиләдә ата-анадан алган беренчел тәҗрибә ята. Атаның кызына, ананың ир балага булган мөнәсәбәте алдагы көндә каршы җенес вәкилләре белән аралаша белүгә нигез сала. Габдулла Тукайның балачагында ата-ана назына, мәхәббәткә булган ихтыяҗы, аларны ала алмавы, үсеп җиткәч тә, шагыйрьнең кешеләр белән мөнәсәбәтләрендә чагыла. Ул яратырга тели, әмма үзе мәхәббәттән кача, кешеләргә артык ышана, һәм шул ук вакытта бер кешегә дә ышанмый да.

Туган гаиләсендә үсә алмау, гаилә үрнәгенең, ягъни паттерн юклыгы шагыйрьнең киләчәктә кызлар белән дуслашу-аралашудан куркуына китергән. Ул күзе төшеп йөргән кызы Зәйтүнә Мәүлүдовага карата туган хисләрен күрсәтергә курка, яшертен утта яна, кечкенәдән үзенә карата якынлык, җылылык хисләре күрмәгәнлектән, Зәйтүнә дә аның сөюеннән баш тартыр, үзеннән көләр, дип борчыла. Бу хисләр шагыйрьнең иҗатында да ачык күренә. Аның «Гашыйк бу, йа» [2: 1 т., 82], «Кызык гыйшык» [2: 1 т., 240], «Мәхәббәт» [2: 1 т., 265] һәм башка шигырьләрендә лирик геройның бу хисләрдән куркуы, мөнәсәбәтләрдән качуы бәян ителә:

> Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! –
> Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы? [2: 1 т., 265].
>
> Мин моны яздым, бу – гышкым миследер;
> Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
> Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам –
> Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам [2: 1 т., 240].

Габдулла Тукай үлеменнән соң, Җ. Юмаев «Яшерен мәхәббәт сәрләүхәсе» [3] дигән мәкаләсе дөнья күрә, ул шагыйрьнең бәхетсезлегендә яшь кызны, Зәйтүнә Мәүлүдованы, гаепләргә омтыла. Бу мәкаләгә Гаяз Исхакый җавап бирә, ул кешенең эчке дөньясын тирәнтен аңлаган шәхес буларак, бу кызның шагыйрьгә иҗат итәргә илһам бирүен билгеләп үтә. Тик замандашлары вакытсыз үлеменең сәбәпләрен бәхетсез мәхәббәттән күрсәләр дә, төп сәбәпне «күгәрченнән арасында бер чәүкә» булып яшәү, ач-ялангач йөреп үпкә чире эләктерүе белән бәйләмиләр [1: 31].

Ятимлек балаларның гомуми үсешендә генә түгел, ә билгеле бер дәрәҗәдә эмоциональ үсешенә дә тискәре йогынты ясый. Мондый балалар үз хисләрен төгәл һәм тулысынча күрсәтә белмиләр, һәрдаим борчу

һәм үзләрен кире кагудан яки кабул итмәүдән курку халәтендә яшиләр. Алда әйтелеп үткәнчә, ятим балаларның тирә-юньдәгеләр белән аралашуда кыенлыклар кичерә: берәүләре танышлары белән сөйләшергә яки дуслар табарга курка, ә икенчеләре тиешле дистанцияне саклый алмаудан җәфа чигә. Шәхес булып формалашкан чорда ата-анасыннан читтә калган балалар, гадәттә, хис-тойгыларын күрсәтмиләр, барысын да үзләрендә яшерәләр һәм дә тискәре эмоцияләр һәм уйлар туплыйлар. Мондый балалар яшьтәшләре белән дә һәм өлкәннәр белән дә мөнәсәбәтләрен җайга сала алмый. Нәтиҗәдә, бу курку, депрессияләргә һәм үзен түбән бәяләү хисенә китерергә мөмкин. Г. Тукайның җәмгыять һәм кешеләр белән мөнәсәбәте аның балачагында кичергән трагедиясенең эзсез югалмавын күрсәтә. Шагыйрь үзенең яраланырга торган нечкә күңелен чәнечкеле холкы һәм ачы теле белән якларга һәм сакларга омтыла. Чәнечкеле холык артында «наз күрмәгән бала» торуын сирәк кеше генә аңлый ала. Шул сәбәпле ул шактый замандашлары белән конфликтка керә, аңа гафу үтенү һәм гафу итү дә соң дәрәҗәдә авыр бирелә. Бу күренеш шагыйрьгә тормышта да кыенлыклар тудыра. Мәсәлән, апасы Газизә Госмановага язган хатында шул хакта мәгълүмат бар: «Әле Оренбургдан да мине чакырып хат килде; «Вакыт» гәзитендә, «Шура» журналларында эшләргә; 40 тәңкә айга жалуние бирәләр. Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбур язучылары илә гәзитә аркылы бераз чәкәләшеп алган идек» [2: 5 т., 200]. Аңлашылмаучылык аркасында килеп чыккан конфликт ике якның да бер-берсеннән гафу үтенүе белән тәмамлана [2: 1 т., 348–350; 5 т., 385]. Шуңа да карамастан, хатыннан чыгып фикер йөртеп булганча, бу тәкъдим Г. Тукайның күңеленә хуш килүгә карамастан, аны кабул итә алмый. Шагыйрь тормышында мондый вакыйгалар тагын да булган. Һәм алар, беренче чиратта, Г. Тукайның ятим балачагы, кире кагылудан куркуы, яралы күңеле белән бәйле.

Гаиләдән гаиләгә күчеп йөргән кечкенә Габдулланың да психикасы ата-ана назына сусап, әйләнә-тирәсендәге өлкәннәрнең мәхәббәтенә һәм ышанычына омтылып үтә. Ләкин Шәрифә карчыкта да, Өчиле авылындагы бабасы гаиләсендә дә, соңрак Сәгъди абый йортында да ул бу хисләрне күрми. Җае чыккан саен аны «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде», дип яки «Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр», дип кагалар. Балага карата булган мондый мөнәсәбәт, һичшиксез киләчәктә эмоциональ салкынлыкка кына китереп калмый, бәлки сәламәтлеккә дә төзәтеп булмаслык зыян сала. Ата-ана җылысы һәм кайгыртучанлыгы җитмәгән балаларның коммуникациядәге, укуда һәм башка эшчәнлектәге проблемалары күрергә була.

Габдулла Тукай берничә тапкыр үз-үзенә сорау бирә: «Моны ни өчен яздың? – диерләр.

Ни өчен языйм? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәт эзе булганга, тоттым да яздым» [2: 5 т., 141]. Бу сүзләр шагыйрьнең күргән авырлыкларының тәнендә сакланган яра, күңелендә онытылмаслык җәрәхәт булуын ассызыклап үтә.

Кечкенә Апуш авыр балачагы хәтирәләрен барлаганда берничә кешенең исемен ярату, алар белән аралашкан вакытны сагыну хисе белән искә ала. Шулар арасында Яңа бистәдәге Газизә апа белән Мөхәммәтвәли абзый, бабасы йортында Сәҗидә апасы һәм Сәгъди абзый. Ятим балаларга гына хас булган бер сыйфатны автор бик ачык тасфирлый. Ятим сабыйга еш кына үзе

турында бераз гына кайгыртучанлык күрсәтсәләр дә, ул кешеләргә дә нык бәйләнә. Шул көнгәчә күрмәгән игътибар аны үзенә тарта. Саҗидә апасы, үз әнисеннән качып булса да, булачак шагыйрьне юатырга тырыша. Бу гамәле белән ул Апушка киләчәккә ышаныч уята сыман. Киләчәктә позитив нотадагы иҗаты, балалар өчен язылган купсанлы әкият-хикәятләре белән Тукай шушы кешеләргә бурычлы.

Кырлай авылы, Сәгъди абзыйда яшәгән чорны Г. Тукай бик җентекләп яза. Әлбәттә, бу чор, бер яктан, авторның «Дөньяга иң элек күзе ачылган урыны» булса, икенчедән ул яше белән дә яшүсмер чорына кереп килүче егет булуы белән анлатыла. Бу авыл белән бәйле хәтирәләрнең барысын да ул тәфсилләп сөйли. Сөйләү рәвешеннән автор кичергән бөтен хисләрне дә танырга мөмкин. Килү белән үк әти-әни булыр кешеләрнең аны яратып каршы алуы, тамак туйганчы катык белән икмәк ашау, җәйге кыр эшләре вакытында беренче хезмәт тәҗрибәсе, беренче сабак алу кебек вакыйгалар хакында язганда якты тоннар өстенлек итә.

Сонрак үги әнисеннән «Үксез бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр» сузләре Габдуллага ятим булуын онытырга ирек бирми. Гаиләдә булган бөтен күңелсезлекне ятим бала белән бәйләп аңлату, кечкенә Апушны янә бала назыннан мәхрүм итә.

Повестька янә бер психологик күзлектән күз салсак, биредә баланың әти-әнисеннән аерылу, кат-кат аерылышу фаҗигасен кичерү күренешен күзәтәбез Бу кадәр аерылу фаҗигасе норма түгел. Мәгълүм булганча, кеше үз гомерендә ике тапкыр сепарация этабын кичерә: беренчесе балигъ булгач, туган оясыннан китә, икенчесе үзе әти-әни булгач үсеп җиткән балаларын яңа тормыш юлына озата. Бу этаплар икесе дә кешенең шушы аерылышуларга психологик яктан әзер булган вакытына туры килсә, тормыш алга таба дөрес юлдан китә. Психологик яктан әзерлеге җитмәгән кешеләр индидуацияне тиешенчә авыр уза. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» повесте сепарация һәм индивидуация процессының нормадан тайпылышының төп сәбәпләреннән берсен ачып сала. Бала, әле аңы өлгереп җитмәгән сабый килеш ятим кала икән, аңа әти-әнисе терәгеннән башка мөстәкыйль тормышка чыгу да, үсеп җиткәч нык басып тору да авыр бирелә. Гаиләдә дөрес аралашу бәрәбәренә баланың үзендә дә билгеле күзаллау барлыкка килергә тиеш: ул үзен кем һәм нинди булырга тиешле хакында төгәл анларга, үзалдына максат куя белергә тиеш. Шул рәвешле ул әти-әнисенә охшаш, тик яңа бер берәмлек, яки шәхес булып формалашса гына, ул үз көченә, үзенә ышанып яши. Яшьтән ятим калган һәм чын мәгънәсендә таянычы булмаган баланың формалашуын без Г. Тукайның үз язмышыннан күрәбез. Г. Тукайның үзе язганча тормышында «караңгылык» күп булу, аның кешеләргә ышанырга теләп тә, ышанып бетә алмавы, көндәлек тормышта үз-үзенә ышанычы җитмәү, ачы теллелек кебек сыйфатлары барысы да балачакта күргән ятимлек ачысы белән бәйле.


ӘДӘБИЯТ

1. Сәмитова С.Г. Гаяз Исхакый иҗаты (1914–1917). – Казан: КДУ, 2005. – 121 б.

2. Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.; 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 384 б.; 3 т. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 415 б.; 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.; 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 415 б.; 6 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 471 б..

3. Юмаев Ж. Яшерен мәхәббәт сәрләүхәсе // Сөембикә. – 1914. – 2 июль

УДК 346+821(091)

# УЧИТЕЛЬ КЫЯМЕТДИН КАДЫРИ И ЕГО ВОСПОМИНАНИЯ О Г. ТУКАЕ

***Н.И. Таиров***
*Казанский государственный институт культуры (Казань)*

17. Исәнбәт Н. Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре // Казан утлары. – 1966. – № 4. – Б. 124–126.
18. Исәнбәт Н. Тукайның соңгы басмасы турында: [Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты тарафыннан төзелгән I том, 1943, 468 б. Төз. Агишев һәм Хисмәтуллин, жаваплы ред. Х. Ярми] // Совет әдәбияты. – 1945. – № 5. – Б. 59–73.
19. Миннуллина Ф. Исәнбәт Накый // Габдулла Тукай. Энциклопедия. – Казан: ИЯЛИ, 2016. – Б. 294–295.
20. Рахмани Р., Миннуллина Ф. Наки Исәнбет // Татар әдәбияты тарихы 8 т. – Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 378.
21. Тукай Г. Сайланма әсәрләр / Г. Тукай; җав. ред. М. Җәлил. – Казан: Татгосиздат, 1938.
22. Хабутдинова М.М. Наки Исанбет и татарская детская литература // Идел. – № 12. – С. 20–22.
23. Хәбетдинова М.М. «Чорлар рухание»// Казан утлары. – 2020. – № 1. – С. 150–162.
24. Ханзафаров Н. Нәкый Исәнбәт драматургиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 192 с.

УДК 81’271

## ПОЭЗИЯ ТУКАЯ – БЕЗГРАНИЧНЫЙ ДУХОВНЫЙ МИР

***Э.М. Хамматова, З.А. Ибятова***
*Казанский государственный институт культуры (Казань)*

В статье говорится о том, что чем больше вчитываешься в его поэзию, тем более раскрывается она новыми гранями, тем больше открываются они своей поэтичностью, духовностью, и затрагивают глубинные струны человеческой души. На занятиях сценической речи наши студенты стараются передовать безграничный духовный мир поэзии Тукая.
**Ключевые слова:** Г. Тукай, поэзия, духовность, сценическая речь, чтец, студент, работа над текстом.

The article says that the more you read into his poetry, the more it reveals itself with new facets, the more they open up with their poetry, spirituality, and touch the deep strings of the human soul. In the classroom of stage speech, our students try to convey the boundless spiritual world of Tukay’s poetry.
**Key words:** G. Tukay, poetry, spirituality, stage speech, reader, student, work on the text.

# ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕ – ЧИКСЕЗ РУХИ ДӨНЬЯ

***Э.М. Хамматова, З.Ә. Ибятова***
*Казан дәүләт мәдәният институты (Казан)*

Рухи-әхлакый тәрбия бирү – ул әлбәттә, иң беренче чиратта кеше шәхесен рухи яктан баету дигән сүз. Ул – матурлыкка омтылу, интеллектуаль һәм эмоциональ яктан эчке дөньяңны камилләштерергә тырышу. Гел үзгәреп торучы бүгенге тормышта үз урыныңны табарга омтылу һәм барлык сәләтеңне, талантыңны, иҗади мөмкинлекләрне барлап тормышка ашыру дияр идек.

Шулай итеп яшь кеше театрда, я булмаса эстрадада артист булып эшләү теләге белән безгә укырга килә. Беренче очрашу, беренче дәресләрдән үк укытучы яшь кешенең сәләтен, «интеллектуаль багажын», рухи дөньясын сиземләп ала. Безнең максатыбыз студентны артист осталыгына өйрәтү булып тора, ә сәхнә теле дәресләренең төп максаты рольләр өстендә эшләгәндә сүз сәнгатен аңларга ярдәм итү. Сәхнә теле фәнен өйрәнгәндә сүзнең мәгънәсен текстның эчтәлегеннән, төп фикердән чыгып аңлау кирәк. Сүз сәнгатенә автор фикереннән килә белергә кирәк һәм «тел асты»н дөрес ачыклау зарури. Сәхнә теле фәне өчен бу метод зур әһәмияткә ия. Ул сөйләм техникасын, текст өстендә эшләүнең төрле ысулларын билгеләүдә төп система булып тора. Шунлыктан без дәресләребездә әдәби материал итеп төрле жанрда язган авторларның прозаик, поэтик һәм нәфис әсәрләрен кулланабыз. Нәфис сүз – тыңлаучы, тамашачының гына түгел, шулай ук аны башкаручы яшь артистның да күңеленә үтеп керергә, әсәрләрне башкарганда аңа үз фикерен җиткерергә, билгеле бер югарылыктагы граҗданлык позициясен дә белдерү сорала.

Автор сүзе, әдәби образлар студентның үзаңын арттыра, фикер йөртергә өнди, безне чолгап алган дөньяны, аерым кешеләрнең хисләрен, фикерләрен аңларга өйрәтә. Безнең һәм шулай ук укчыларыбызның иң яраткан авторларыннан берсе – ул татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай.

Кайчандыр Фатих Әмирхан әйткән: «Әле ул бик яшь чагында ук халык аны үз шагыйре итеп кабул иткән. Тукай нәрсә турында гына язмасын, ул халык күңелен чагылдыра» [4: 96].

Тукайның замандашлары шагыйрьнең халыкчанлыгы нидә – дигән сорауга җавап эзләгәннәр һәм аның шигъриятен халык иҗаты белән янәшә куйганнар, аны шундый ук җирлектә чәчәк аткан гөлгә тиңләгәннәр. Интеллигенциянең алдынгы карашлы даирәләрендә Тукайны, бәхәссез, халык шагыйре итеп таныганнар һәм моны Тукайның халык уйлары, хиссияте белән яшәүдән күргәннәр, кайберләре исә аны милли шагыйрь дип тә исемләгәннәр.

Әдәбият белгече һәм тарихчы Гали Рәхим: «Ул халык үзе тапкан һәм сайлап алган җырчы... һәм ул гомергә безнең беренче халык шагыйре булып калачак» [4: 113].

Сәхнә теле дәресләрендә без үзебезнең эшебезне гадәттә шигъри формадан, Г. Тукай шигырьләреннән башлыйбыз. Аның иҗаты бай, чиксез, Тукай әсәрләре гуманизм, толерантлык, халыкка, туган җиргә, телгә мәхәббәт, төрле телдә аралашучы күп милләт кешеләренә дуслык белән сугарылган.

Тукай шигырьләре безнең тормышыбызга, кечкенәдән, балачактан килеп кереп, дәвам итеп, гомер юлында озата баралар. Тукайның «Туган тел» шигырен белмәгән, җырламаган татар гаиләсе юктыр ул.

XXI гасырда яшәүче кешелек буыны бөек шагыйребезнең иҗат юлын өйрәнергә, сакларга һәм аның яңа якларын ачарга тырышсын иде. Бөек Тукайның фәлсәфи фикерләре, халкыбыз тормышының төрле якларын сурәтләгән шигърияте, публицистик әсәрләре, гасырдан артык вакыт үтүгә карамастан, бүгенге көнебезгә, яшәешебезгә аваздаш булып кала.

Еш кына безнең студентлар Казан дәүләт мәдәният институтының театраль эстрадасында бөек шагыйрьнең әсәрләре белән чыгыш ясарга яраталар. Менә аның мәшһүр шагыйрь А.В. Кольцов шигыре буенча ирекле тәрҗемәдә язылган «Мужик йокысы» шигыре яңгырый:

Ник йоклыйсың, мужик?
Яз җитте, һәм үсте
Чирәмнәр йортында;
Тор, уян, күтәрел!
Үз-үзеңә кара:
Кем идең, кем булдың?
Нәрсә бар милкеңдә?

Үз вакытында тәңкыйтьче Белинский Кольцовның бу шигырен рус поэзиясенең әһәмиятле әсәрләреннән берсе дип атаган. Күрәсез, гади халыкның тормышы, эше, уйлары, бөек шагыйре Г. Тукай өчен дә чит булмаган, ул аны югары поэтик биеклектә иҗат иткән, реалистик эшчәнлеген ачып салган. Һәм татар шигриятендә, татар телендә гади крестьянның трагик көндәлек тормышын чагылдыру тирән бер яңалык булып яңгыраган. Г. Тукай үзенең әсәрендә гади җир кешесенең авыр хәлен сурәтләгән, ул аңа ярдәм итәргә тели, мескенлек, ярлылык баткагында яшәүчегә үзенең уңай нәтиҗәгә ирешерлек программасын тәкъдим итә. Бу әсәрне укучы студент укый шигъри юлларны картина рәвешендә күзалларга, сүзләр коры яңгырмасын өчен текстның эчке фикерен, «тел астын» билгеләп, максатчан хәрәкәт итеп укырга тиеш. Башкаручы студент үзенең күзаллавы белән тамашачы карашында да укыла торган әсәрнең эчтәлеген чагылдырса үзенең максатына ирешкән булып санала. Әлбәттә инде моның өчен язучының иҗатын өйрәнергә, текстны тирәнтен аңлап, авторның фикерләрен үзеңнеке итеп үзләштерергә кирәк. Шулай ук авторның шигъри телен яратырга, аның стилистик язылуын аңларга һәм сиземләргә тиеш.

Тагын бер еш сөйләнелә торган «Көз» шигырен искә алып үтәсе килә. Анда Тукай көзге табигатьне бар чынбарлыгы белән сурәтли.

Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.
Мисале зәгъфыран саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.
Такыр калды татар башы кеби кыр;
Азык эзли – оча тургай да пыр-пыр.

Безнең күз алдыннан күңелсез, моңсу чор картиналары үтә. Укучы кеше көзнең атмосферасын сиземләргә, көз пейзажын «эчке күзе» белән күрергә һәм тулысы белән тәкъдим ителә торган хәлләрне ачык итеп тасвирларга тиеш була. Шунысы кыйммәтле, Тукай табигатьнең көзге чорын сурәтләү белән генә чикләнми, шушы вакыт аша үзенең эчке кичерешләрен, психологик хәлен безгә җиткерергә тели. Тукайның көз турында уйланулары,

сагынып язны көтүләре, киләчәктә халык тормышының яңару хыялларына барып тоташа.

Кайчан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең!
Кайчан китәр кичең, килер нәһарең?
Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай нинди тема яктыртмасын, ни турында гына язмасын, аның иҗаты тирән хисләргә бай, эмоциональ һәм эчке темперамаентка ия. Тукай шигырьләре чыннан да «җанлы», алар яшиләр, аларда халык күңеле, борчулары, авыртулары. Аның поэзиясен тирәнтен укыган саен, ул синең алдында үзенең яңа яклары белән ачыла, шигърилеге, рухи байлыгы белән таң калдыра һәм кеше күңеленең тирән, кылларын чиртә.

ӘДӘБИЯТ


1. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908). – 407 б.
2. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). – 384 б.
3. Халит Г. Габдулла Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.
4. Халит Г. Тукай һәм аның замандашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 228 б.



УДК 821.512.145


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ И ГАЛИАСКАР КАМАЛ


***Г.М. Ханнанова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



Среди представителей татарской интеллигенции, игравших значительную роль в жизни Г. Тукая, есть и Г. Камал (1979–1933) – основоположник национальной драматургии, прозаик, издатель, редактор и публицист. Еще до приезда Казань Тукай интересовался периодическими изданиями, в которых трудился Камал. Сам драматург также был осведомлен о литературных успехах поэта. В Казани между этими двумя литераторами устанавливаются отношения дружбы. Результатом этой дружбы становится их плодотворное сотрудничество в журналах «Яшен» и «Ялт-Юлт».


**Ключевые слова:** Г. Тукай, Г. Камал, журнал «Яшен», татарская литература.



Among the representatives of the Tatar intelligentsia who played a significant role in the life of Tukai, there is also G. Kamal (1979–1933) – the founder of the national drama, novelist, publisher, editor and publicist. Even before the arrival of Kazan Tukai was interested in the periodicals in which Kamal worked. The playwright himself was also aware of the poet's literary success. In Kazan, these two writers establish relations of friendship. The result of this friendship is their fruitful cooperation in the magazines «Yashen» and «Yalt-Yult».


**Key words:** G. Tukay, G. Kamal, Yashen magazine, Tatar literature.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ГАЛИӘСГАР КАМАЛ


***Г.М. Ханнанова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*


1907 елның көзендә Тукай Казанга ашкынулы, өмет тулы хисләр белән рухланып килә, мондагы әдәби-мәдәни мохит аны үзенә тарта [10: 57], Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, В. Бәхтияров, Г. Камал, Ә. Хәсәни һ.б. шәхесләр

белән аралашу, матбугат, сәнгать дөньясында кайнау Тукайның дөньяга карашын киңәйтә, иҗатын яңа сыйфатлар белән баета. Шагыйрьнең Казандагы фикердәшләреннән берсе – XX йөз башы татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышында әһәмиятле роль уйнаган, үзәк фигураларның берсе булган, энциклопедик характердагы эшчәнлеге белән аерылып торган Г. Камал (1879–1933) – Казанның «Госмания» мәдрәсәсендә, соңрак «Мөхәммәдия»дә белем алганда ук матбугат белән «җенләнә». Үзенең «Яза башлавым тарихы» исемле истәлегендә бу хакта Камал: «*... Борһан Шәрәф белән бергәләп, юка кәгазь астына копировка кәгазьләре куеп, мәдрәсәдәге хәлләренең җитмәгән якларыннан көлеп, «Телескоп», «Мәнзарател-галәм» («Дөньяга күзәтү») дигән газеталар чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә ташлыйбыз*» [5: 311], – дип искә ала. Яңалыкка омтылу, фикерләрен, язмаларын үзе кебек алдынгы татар яшьләренә матбугат аркылы җиткерергә ашкынуы белән Г. Камал замандашы, алга таба фикердәше, хезмәттәше һәм якын дустларының берсе булып китәчәк Г. Тукайны хәтерләтә.

Мәдрәсә тәмамлаган Галиәсгар мулла булудан баш тарта, хатынының атасы Садыйк хаҗи ярдәмендә 1901 елны китап сәүдәсе ача. Башта аның ширкәте «Китапчы Галиәсгар Галиәкбар улы Камалетдинов» исеме белән йөрсә, алга таба «Мәгариф көтепханәсе» дип атала башлый. 1908 елны Шәрәфләр кулына күчкәч, «Мәгариф» нәшрияте дип исемләнеп, үзенең эшен 1922 елга кадәр дәвам итә [11: 126, 162]. Г. Тукай әсәрләренең шактый өлеше шушы нәшрият басмасында дөнья күрә.

1905 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, җәмгыятьтә барган хәрәкәт татар дөньясын да уята. Илдәге яңа вазгыять татар җәмәгатьчелегенә милли матбугат булдыру хакында хыялланырга мөмкинлек бирә, һәм 1905 елның 29 декаберендә Казанда беренче татар газетасы – «Казан мөхбире» дөнья күрә (нашире һәм мөхәррире – Сәетгәрәй Алкин (1867–1919), фактик редакторы – Йосыф Акчура (1876–1935)). Г. Исхакый (1878–1954), Ф. Туктаровлар (1880–1938) кебек алдынгы фикерле шәхесләр белән беррәттән Г. Камал да бу газетада языша башлый. Әмма «Иттифак эл-мөслимин» партиясе органы булган газетаның либераль юнәлеше радикаль карашлы Камалның иҗтимагый мәсләгенә туры килеп бетми, һәм шул сәбәпле әдип «Казан мөхбире»ннән читләшә. 1906 елның 1 февралендә мөгаллим һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Апанаев (1862–1919) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә (фактик мөхәррире – Г. Камал) «Азат» газетасы чыга башлый. Биредә Камалның язмалары башлыча «Г.К.», «З. Г-ва», «Саип», «Һади» имзалары белән басыла. Басманың гомере озын булмый, «Азат» газетасының ябылуын Г. Тукай үз иҗатында берничә тапкыр искә ала («***Кыямәт якын килде – җир сораучы ярылды...», «Озын колак хәбәрләре» һ.б.). Мәсәлән, «Озын колак хәбәрләре» (1906) исемле язмасында, газетаның сәламәтлекне саклауга караган озын мәкаләләр бастыруыннан көлеп, үз сәламәтлеген саклый алмыйча вафат булуы турында яза [14: 303]. «Азат халык» исемле газета чыгару теләге дә җимерелгәч (аның 15 саны гына дөнья күреп кала), Г. Камал яңадан «Казан мөхбире»нә урнашып карый, ләкин монда да озак эшләми, китәргә мәҗбүр була һәм күренекле мәгърифәтче, педагог Һади Максудиның (1868–1941) «Йолдыз» газетасына сәркәтип булып эшкә керә.

Бу вакытта Уральск шәһәрендә яшәп иҗат итүче, үзе дә матбугат эшләрендә «кайнаган» Тукай Казан вакытлы матбугатын зур кызыксыну

белән күзәтеп бара һәм Г. Камалның «Йолдыз» газетасына эшкә керүен игътибарсыз калдырмый. Моңарчы социал-демократлар йогынтысында булган әдипнең либераль юнәлештәге газетага күчүен хупламый һәм үзенең «Дөнья бу, йа» (1906) исемле шигырендә бу хакта: «*Социал «Азат халык»-ны черносотенный ясап, / Һади абый мәсләген мәсләк дидерткән дөньядыр*» [12: 129], – дип яза. Үз чиратында, Г. Тукайның Уральскидагы «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдид» журналы кебек вакытлы басмаларда урын алган әсәрләре Г. Камалда да кызыксыну уята, үзенең бер истәлегендә ул бу турыда: *«...шул газета һәм журналларда Г. Тукай имзасы белән җитмеш-сиксән проценты гарәпчә-төрекчә, калганы татарча сүзләрдән төзелгән шигырьләр басылып чыга башлады. Ул чакларда яңа темалар да, бик саф булмаса да, татарча язылган шигырьләр булганлыктан, Тукайның шигырьләре бик тиз күзгә бәрелде. Мин шул килгән газета һәм журналлардан Тукайның шигырьләрен эзләп барып укый башладым*» [3: 323], – дип искә ала.

1907 елның көзендә Г. Тукай Казанга килә һәм Г. Камал хатирәләренә караганда, аларның шагыйрь белән беренче очрашулары «Йолдыз» газетасы редакциясендә була. Бу турыда Г. Камал үзенең «Габдулла Тукай турында истәлекләр» исемле язмасында искә ала [3: 324].

Замандашлары истәлекләренә караганда, Тукай Казанга килгәч, театр сәнгате белән кызыксына, спектакльләргә йөри, «Сәйяр» труппасы артистлары белән якыннан танышып, артистлар һәм Г. Камал белән якыннан аралаша, репетицияләргә йөри. Шагыйрьнең замандашы, актер Касыйм Шамил бу турыда: *«Кичләрен «Сәйяр» номерына керә анда, Галиәсгар Камал һәм артистлар белән бергә шаярып, төрле көлке сүзләр сөйләп вакыт үткәрә»* [9: 340], – дип искә ала. Шулай итеп, театр сәнгатенә булган мәхәббәт, уртак фикерләр Г. Тукай белән Г. Камал арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыта, үзара якынайта.

«Йолдыз» Г. Камалның «Яңа әсәрләр», «Яңа китаплар» рубрикасында дистәләрчә рецензиясе басыла. Мәсәлән, 1907 елның 15 ноябрендә Казанда Шәрәфләр матбагасында Тукайның беренче шигырь җыентыгы – «Г. Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. Беренче кыйсем) дөнья күрә. Камал бу җыентыкны да зур кызыксыну белән кабул итә, һәм, китап басылып чыгу белән, «Йолдыз» газетасы битләрендә аның «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензиясе дөнья күрә. Җыентыкка: «*Мәзкүр әсәр (искә алынган китап. – Г.Х.) әдәбияты җәдидәбездә (яңа әдәбиятыбызда. – Г.Х.) күрелгән әсәрләрнең яхшыларыннан саналырга яраклы.... бу әсәр әдәбиятбызның гүзәл баласыдыр*» [4] дип, гаять җылы һәм уңай бәяләмә бирелә.

1908 елның 3 августында, татар җәмәгатьчелеге тарафыннан озак көтелгән, Казанда нәшер ителгән беренче сатирик журнал – «Яшен» дөнья күрә. Журналның нашире һәм мөхәррире – Г. Камал, секретарьлек эшен Г. Тукай алып бара. «Яшен»нең беренче санында ук Тукайның шигырь һәм мәкаләләре урын ала, шулар арасында журналның нәшер ителә башлау уңае белән язылган «Август башы» мәкаләсе һәм «“Яшен” журналы хакында» исемле шигыре, «Сыбызгы», «Тотса Мәскәүләр якаң!», «Ысуле кадимче» һ.б. бар. Шагыйрьнең замандашы Г. Шәрәф әйткәнчә, журналның беренче номерында «башынннан ахырына кадәр Тукайның каләме йөри» [15: 271]. Әлеге журнал өстендә бергәләп эшләү Г. Тукай белән Г. Камал арасындагы дуслыкны тагын да ныгыта. Тукай «Яшен» журналында бик яратып эшли,

һәр номерга кызыклы яңа материллар кертергә тырыша, Камал белән берлектә рәсем асларына язмалар әзерли. Журналдагы рәсемнәр, карикатураларның шактый өлеше Г. Камал кулы белән ясала.

«Йолдыз» газетасы мөдире һәм сәркатибе вазыйфаларын башкаруын дәвам иткән Г. Камал һәр номерны яңа хәбәрләр, кызыклы материаллар белән тәэмин итәргә тырыша. Берничә тапкыр аңа, хәбәрче буларак, Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсенә сәяхәт кылып, андагы вакыйгалар турында хәбәр бирергә туры килә. Шул сәяхәтләренең берсенә ул үзе белән Тукайны да чакыра, һәм 1908 елның 5 августында алар икәүләп Мәкәрәҗәгә юл тоталар. Мәкәрҗәдә алар Тимерша Соловьев (1875–1947) идарәчелек иткән «Двухсветная» гостиницасына урнашалар. Тукай башта ярминкәне зур кызыксыну белән карап йөри, соңрак, игътибары сүрелгәч, бу вакытта Мәкәрәҗәдә булган «Сәйяр» труппасы артистлары һәм Г. Кариев (1886–1920) белән аралаша, репетицияләрдә катнаша, спектакльләренә баргалый. «Сәйяр» труппасы артистлары белән берлектә, Тимерша Соловьев тәкъдиме буенча, «Двухсветная» кунакханәсе залында концертлар куюда катнаша. Биредә милли шигырьләр укыла, милли җырлар җырлана. Тукай концертның программасын төзи, репетицияләрдә катнаша, хор белән милли җырлар башкаручы артистларга булышлык итә. Габдулла Кариев бу турыда: *«...Габдулла әфәнде Тукаев, җырлаган вакытта, безнең алда халыкка арты, безгә алды берлә, капельмейстер (дирижер – Г.Х.) шикелле, куллары берлә болгап торадыр иде»* [8: 672], – дип искә ала.

Мәкәрәҗәдән кайткач, Тукай Камал белән берлектә яңадан «Яшен» журналына материаллар әзерләү эшенә керешә. Нәкъ шушы вакытта, август ахырларында, бертуган Никитиннар циркына Карахмәт исемле төрек көрәшчесе килә. Аның катнашындагы тамашалар «Печән базары» тирәсендә әйләнгән публикада зур кызыксыну уята. Г. Камал, шуларны күздә тотып, Тукайга, Карахмәт белән бәйле, Казан базарчыларыннан көлеп берәр әсәр язарга тәкъдим итә [8: 326]. Тиз арада Г. Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» исемле поэмасын иҗат итә, ләкин аны «Яшен»дә бастырмый – Гыйльметдин Шәрәфкә тапшыра.

1908 елның 8 ноябрендә Г. Тукайның «Җуаныч» исемле китабы басылып чыга. Шагыйрьнең дусты Г. Камал бу вакыйганы күз уңыннан читтә калдырмый һәм «Йолдыз» газетасы битләрендә бу турыда: *«...Г. Тукаевның әсәрләреннән «Җуаныч» нам бер китап нәшер ителеп, китап базары тәзәйен ителмеш (бизәлгән. – Г.Х.) иде»* [6], – дип хәбәр бирә.

1908 елның 14 ноябрендә Казанда «Сабах» көтепханәсе, И.Н. Харитонов матбагасында Г. Тукайның «Алтын әтәч» исемле китабы басылып чыга. Китапның тышлыгында «Пушкин хикәясеннән алынды» дип искәртелгән. 1909 елның февраль аенда исә шул ук матбагада әлеге экият-поэманың икенче басмасы дөнья күрә, һәм Г. Камал, «Йолдыз» газетасында, әлеге китап чыгу уңае белән язылган кыскача бәяләмәсендә: «*Ошбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде. Берсе – Габдулла Тукаев тарафыннан назым илә язылган «Алтын әтәч» нам бер хикәядер»* [7: 171], – дип, хәбәр итә.

Матди кыенлыклар, цензура кысулары нәтиҗәсендә «Яшен» журналы 1909 елның июнендә нәшер ителүдән туктый. Казан сатирик журналдан мәхрүм кала, Г. Тукай белән Г. Камалның мавыгып, бик яратып башкарган эшләре туктала. Әлеге вакыйгадан соң сигез ай вакыт үткәч, Г. Тукай

һәм аның фикердәшләре тырышлыгы белән Әхмәт Урманчиев (1880–1922) «Ялт-йолт» исемле сатирик журнал чыгаруга рөхсәт ала [2: 142]. 1910 елның 15 мартында Ә. Урманчиев редакторлыгында һәм нәширлегендә «Ялт-йолт» сатирик журналының беренче номеры дөнья күрә. Секретарь вазыйфаларын һәм төп эшне Г. Тукай алып бара. «Ялт-йолт» – рәсемле сатирик журнал, Тукай биредә дә дусты белән хезмәттәшлеген дәвам итә, журналдагы күпчелек рәсемнәр һәм карикатуралар Г. Камал тарафыннан эшләнә.

1910 елның 5 ноябрендә дуслары, фикердәшләре тарафыннан Г. Камалның әдәби эшчәнлегенең 10 еллыгы билгеләп үтелә. Юбилей кичәсе «Новый клуб» залында үтә, биредә Тукай да катнаша. Кичәдә «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы һәм «Бүләк өчен» комедияләре куела. Тукай юбилей кичәсендә алган тәэсирләре белән уртаклашып «Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсы» исемле мәкаләсен яза. Мәкалә 22 ноябрьдә «Йолдыз» газетасы битләрендә дөнья күрә. Тукай дустының иҗаты турында: «*Минем күңелемдә Галиәсгар әфәнде әсәрләренә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымда ук мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде*» [13: 142 ], – дип яза. Шагыйрь күңеленә чәчелгән әлеге орлыклар, Камал әсәрләре белән күбрәк һәм якынрак таныша торгач шытып чыгып, күңелдә инде тамыр җәйгәннәр дип белдерә. Татар тормышын, Казан мещаннарының яшерен почмакларын сәхнә аркылы күрсәтә алган әдипне «татар Островские» дип атый, «Бәхетсез егет» һәм «Бүләк өчен» пьесаларында чын татар тормышы тасвирларлануын билгеләп үтә.

1912 елның көзендә Төркия белән Балкан берлеге дәүләтләре (Болгария, Греция, Сербия, Черногория) арасында Беренче Балкан сугышы дигән низаг башлангач, «Йолдыз» газетасы мөхәррире Һади Максуди Г. Камалны Төркиягә махсус хәбәрче итеп җибәрә. Шулай итеп Г. Камал, Казаннан 1912 елның ноябрь ахырларында китеп, 1913 елның февраль башларына кадәр Истанбулда яши. Төркия хөкүмәтенең эчке һәм тышкы сәясәте, сугыш чоры вазгыяте, халкының тормыш-көнкүреше, сугышка мөнәсәбәте һ.б. турында «Йолдыз» газетасына озын-озын мәкаләләр рәвешендә хәбәрләр җибәреп тора. Г. Камал Истанбулда салкын тидереп, нерв авыруы белән чирләп китә. 1913 елның февраль аенда Казанга кайтып озак тормый, авыруы көчәеп, аяк-кулдан кала һәм больницага керергә мәҗбүр була. Дусты Г. Тукайның да үпкә авыруы көчәеп, докторлар һәм дуслары киңәше белән Клячкин хастаханәсенә керергә җыенып йөргән вакыты. Г. Камал белән Г. Тукайның авыруы һәм хәлләренең торышы турында «Кояш» газетасы кыскача мәгълүматлар биреп бара. Мәсәлән, 24 март санында дөнья күргән «Авыруларымыз янында» исемле язмада «Берәү» башта – Клячкин хастаханәсендә ятучы Г. Тукайның хәл-әхвәлләрен, аннары клиникада дәваланучы Галиәсгар әфәндене сәламәтлеге турында хәбәр бирә. Г. Камал турында язганда: *«... Галиәсгар һаман иске Галиәсгар, Камал шул ук Камал, шат, кайгырмый. Уен-көлке арасында үзенең авыруы арту, кимүне сөйли. Тукайның кәефе ничек? Кызулыгы ничә градус? Үзен ничек хис итә? дип аны сораша»* [1: 733], – дип, һаман да дусты Тукайны кайгыртуы турында хәбәр итә.

1913 елның 15 апрелендә Г. Тукай мәңгелеккә күчә... Г. Камал, дустын соңгы юлга озата алмыйча, авыр хәлдә клиникада ятып кала. Ел ярым дәвамында авыру белән көрәшеп, көч-хәл белән аякка басканнан соң гына, Тукай каберенә барып, дустына сәламен бирүгә ирешә.

ӘДӘБИЯТ

1. Берәү. Авыруларымыз янында // Тукай – ядкярләрдә. 2 томда. 1 т.: истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 733.

2. Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 271 б.

3. Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлекләр // Камал Г.Г. Әсәрләр: 3 томда. 3 т.: хикәяләр, рецензияләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 323–328.

4. Камал Г. Габдулла Тукаев шигырьләре // Йолдыз. – 1907. – 5 декабрь.

5. Камал Г. Яза башлавым тарихы // Камал Г.Г. Әсәрләр: 3 томда. 3 т.: хикәяләр, рецензияләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 308–312.

6. Камал Г. Яңа әсәрләр («Балалар дөньясы», беренче китап – «Кечкенә Рәшид») // Йолдыз. – 1908. – 11 декабрь.

7. Камал Г. Яңа китаплар // Камал Г.Г. Әсәрләр: 3 томда. 3 т.: хикәяләр, рецензияләр, истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 171.

8. Кариев Габдулла. Тукай Мәкәрҗәдә // Тукай – ядкярләрдә. 2 томда. 1 т.: истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 671–674.

9. Касыйм Шамил. Г. Тукай турында истәлекләрем // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т.: истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 337–344.

10. Надыршина Л.Р. Габдулла Тукай шигъриятендә экзистенциаль мотивлар // Фәнни Татарстан. – 2019. – № 4. – Б. 55–65.

11. Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

12. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 407 б.

13. Тукай Г. Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсы // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 4 т.: проза, публицистика (1907 – 1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 139–142.

14. Тукай Г. Озын колак хәбәрләре // Тукай Г. М. Әсәрләр: 6 томда. 3 т.: мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр (1904–1906). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 303.

15. Шәрәф Г. Тукай турында истә калганнар // Тукай – ядкярләрдә. 2 томда. 1 т.: истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 265–275.

УДК 811.512.145’367

# ВЫРАЖЕНИЕ ПОЯСНИТЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

***Л.Г. Хабибуллина***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

Статья посвящена исследованию пояснительных отношений в языке художественных произведений классика татарской литературы Габдуллы Тукая. Проводится анализ пояснительных конструкций в плане их семантической и структурной организации. Для анализа привлечены примеры из стихотворений, воспоминаний, басен и рассказов для детей автора.
**Ключевые слова:** пояснительная конструкция, поясняемый компонент, поясняющий компонент, язык произведений Габдуллы Тукая.

The article is devoted to the study of explanatory relations in the language of literary works of the classic Tatar literature Gabdulla Tukai. The analysis of explanatory constructions in terms of their semantic and structural organization is carried out. Examples from the author’s poems, memoirs, fables and stories for children are used for the analysis.
**Key words:** explanatory construction, explanatory component, language of works by Gabdulla Tukai.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНДӘ АНЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТ БИРЕЛЕШЕ

***Л.Г. Хәбибуллина***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Габдулла Тукай мирасы – халкыбызның чиксез байлыгы. Аны төрле яклап анализлауга багышланган күпсанлы фәнни хезмәтләр язылуга карамастан, әдип иҗаты әле һаман да фәнни тикшеренү объекты итеп алына. Әлеге мәкалә Тукай әсәрләре телендә аныклаулы мөнәсәбәт бирелешен өйрәнүгә багышлана. Анализ өчен авторның төрле жанрга караган әсәрләре – шигырьләр, истәлекләр, мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр алынды.

Аныклаулы мөнәсәбәт синтаксик берәмлекләрдә информация күләмен киңәйтү яки тарайту юлы белән барлыкка килә торган мәгънәви-синтаксик категория санала. Семантик планда аныклаучы компонент коммуникатив факторга бәйле рәвештә мәгълүматны я тулыландыра, киңәйтә (бөтеннән өлешкә), я гомумиләштерә, тарайта (өлештән бөтенгә). Мәгълүматны киңәйтү очрагында өстәмә хәбәрләр бирелә, тарайту исә тыңлаучының игътибарын актуаль фактка юнәлтү өчен кулланыла. Шулай итеп, синтаксик берәмлекләрдәге мәгълүмат күләме буенча аерыла. Аныклаулы мәгънә нәрсәдер нигезендә чагыштырыла һәм тасвирлана торган ситуациядә иерархик бәйлелек белдерә торган мөнәсәбәтләр белән бәйле.

«Аныклау – бер үк денотатның ачыклау максаты белән кабатлануы. Аныкланучы һәм аныклаучы элементлар бер референтка карый» [2: 9]. Аныклаулы конструкцияләрдә үзенчәлекле интонация мөһим роль уйный. Күтәрү интонациясенә якын интонацион пауза ярдәмендә аныкланучы компоненттан аныклаучыга күрсәтү функциясе үтәлә, аныклау характеры билгеләнә: ***Без – руслар белән татарлар*** *– һәрвакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз* («Мич башы кыйссасы»).

Аныклаулы конструкция компонентлары бер-берсе белән түбәндәге логик мөнәсәбәтләрдә була:

1) тәңгәл төшенчәләр арасында урнаша торган тигезлек. Бу очракта аныкланмыш һәм аныклагыч синонимнар булалар. Мәсәлән: *Алар* ***әбәттән (көндезге аш)*** *соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, җан тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде* («Исемдә калганнар»). Мондый мисалларда аныкланмыш һәм аныклагычның урыннарын алыштыру алар арасындагы тәңгәллек логик мөнәсәбәтен бозмый, мәгънә мөнәсәбәте характеры саклана: *Алар* ***көндезге аштан (әбәт)*** *соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, җан тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде*;

2) өстәмә мәгълүмат. Бер төшенчәнең мәгънә күләме икенчесенекеннән киңрәк булганда күзәтелә: *Мәсәлән,* ***бервакыт, әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта,*** *мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдыртмаска азапланганымны, тартышканымны беләм* («Исемдә калганнар»);

3) тәңгәл булмаган төшенчәләргә хас мәгънә киселеше. Бу очракта бер төшенчәнең күләме икенчесенең күләменә өлешчә генә керә, алар эчтәлеге буенча тәңгәл түгел. Мәсәлән: ***Бервакыт көз көне, өйләдән соң****, әти белән әни ындырда иде*… («Исемдә калганнар»); ***Кичкә таба, икенде-ахшам арасында****, Сапый абзыйның илтүендә җизниләргә киттем* («Исемдә калганнар»); *Бизгәк, мин* ***иртәге чәйне эчеп бетерер алдыннан (сәгать беренче яртыда)****, көтелгән кадерле кунак шикелле, миңа рәхим итеп, тәнемдә*

*күпме тамыр бар исә, һәммәсен селкетеп, мине хәрәкәттәге поезд шикелле итә иде* («Мич башы кыйссасы»).

Мәгълүм булганча, аныклаулы конструкция компонентларын үзара бәйләү һәм алар арасында төрле мәгънә төсмерләрен урнаштыру өчен, *ягъни, башкача әйткәндә, гомумән, бер сүз белән, икенче төрле әйткәндә, башкача, мәсәлән, шул исәптән, шул җөмләдән, хәтта, бигрәк тә, аеруча, аерым алганда* кебек теркәгеч сүзләр кулланыла. Әсәрләренең телен тикшерү күрсәткәнчә, Тукайда алар еш очрамый: *Кая барсам да мине, мулла баласы дип, халык башка малайлардан аерганга,* ***хәтта*** *җыеннарда яшьтәш кызларым илә «таккаравыл» уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем* («Исемдә калганнар»).

Аныклаучы компонент ярдәмендә тулы бер ситуация барлыкка килә. Шулай итеп, аныклауда төрле семантик төсмерләргә ия имплицит мәгълүмат була. Мәсәлән:

– Вакыйгаларны пространство яки вакыт ягыннан аныклау: *Электә бер Ташчы торган бу дөньяда,* ***Безнең җирдә түгел – ерак Япониядә*** («Япон хикәясе»); ***Соңыннан, Җаекка килгәч****, белдем ки, «өлкән» – «олугъ» дигән сүз икән* («Исемдә калганнар»).

– Аныклаучы компонентка ялгызлык исем аша белдерелгән индивидуальләштерү хас булырга мөмкин: ***Ун яшьлек бала – Шәмсетдин****, үз авылларында бер бай кешегә барып, үзенә хезмәт сорады* («Баланың ата-анасын сөюе»).

– Аныклау сүзнең ешрак кулланыла торган атамасы, синонимы була ала: *Кайсы динсезләрдәдер, Оракул исемендә агачтан ясалган бер* ***мәгъбүд (санәм)*** *бар иде* («Оракул»).

– Конкрет атама аныклагыч ролендә килә ала: *Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә* ***тозлы балык – вобла*** *һәм симәнкә алып ашадым* («Исемдә калганнар»).

– Аныклаучы компонент максималь төгәллек кертү максатында кулланыла ала: *Моннан соңра атам, икенче мәртәбә өйләнүе уларак,* ***Өчиле карьясе Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызыны (минем анамны)*** *алмыштыр* («Исемдә калганнар»); *Бу гаиләдә* ***һәммәсе (бер җитеп килә торган Саҗидә исемле кыздан башкасы)*** *минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде», – дип кенә караганнар* («Исемдә калганнар»).

– Сүзгә аңлатма бирү максатында барлыкка килгән аныклаулы мөнәсәбәт: *Шунлыктан бу җәем* ***уйныйсы килгән балалар өчен зур газап булган нәрсә – эш*** *белән үтте* («Исемдә калганнар»); *Кайчакта мин, шул «Фәвакиһел җөләса» тәэсире илә, Гайшә абыстайның* ***кер юган җиренә – кара өйгә*** *барып, аның белән кычкырыша торган идем* («Исемдә калганнар»).

– Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүз арасындагы аныклаулы мөнәсәбәт Тукай иҗатында шактый еш очрый: *Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач,* ***бөтен авыл халкы – хатыны-кызы, баласы-чагасы*** *болынлыкка төштеләр* («Исемдә калганнар»); *Аның өстенә* ***сәнәкләр, мылтыклар, этләр – барчасы*** *моңар касд кыйлалар* («Аю»); ***Шәһәрнең фәкыйрьләре, толлары, ятимнәре – барчасы*** *җыелышып, Миронның капкасы төбенә бардылар* («Мирон»).

– Габдулла Тукай әсәрләре телендә аныклагычлар еш кына образлы чагыштыру чарасы буларак килеп керә: *Ничектер, белмимен, бер көн* ***идән***

***асты кошы – тычкан*** *Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән* («Сөткә төшкән тычкан»); *Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры Тәгәридер ул* ***матур кыз – язның*** *алтын фәйтуны* («Кышка бер сүз»).

Аныклаучы компонент, кагыйдә буларак, аныкланучының мәгънәсе җитәрлек күләмдә ачылмаган очракта барлыкка килә. Аныклаулы конструкция компонентлары мәгънәсенең абсолют туры килмәве, үз чиратында, тасвирлана торган объектларның яңа үзлекләре һәм сыйфатлары ачылуга китерә.

Җөмләдә аныклаучы компонентның барлыкка килүе грамматик яктан фаразланмый (чөнки аның җөмләдәге синтаксик позициясе аныкланучы компонент белән эксплицит белдерелә), төрле коммуникатив-прагматик максатлар белән билгеләнә.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 480 б.

2. Захарова Л.В. Обособленные второстепенные члены предложения со значением уточнения в современном русском литературном языке: автореф. дис. ...канд. филол. наук. – Ставрополь, 2008. – 21 с.

УДК 821.512.145

## ТВОРЧЕСТВО Г. ТУКАЯ В ЛИТЕРАТУРНОМ ПРОЦЕССЕ XX–XXI ВВ.

***А.С. Хайруллина***
*Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета (Елабуга)*

Изучение творчества Габдуллы Тукая в школе начинается со дня публикации его первого стихотворения. В зависимости от идеологии эпохи, его произведения преподносились читателям по-разному. В школах-медресе организовываются уроки, посвященные творчеству Тукая, и эта традиция продолжается до сих пор. В статье рассматриваются некоторые его произведения, включенные в школьную программу по родной (татарской) литературе.
**Ключевые слова**: Тукай, татарская литература, поэзия, образ.

The history of studying the work of Gabdulla Tukai at school begins with the publication of the first the poet’s poem. Depending on the ideology of the era, his work was presented to readers in different ways. Lessons dedicated to the work of Tukay are organized in madrasah-schools and this tradition continues to this day. The article examines some of his works included in the school curriculum on native (Tatar) literature.
**Key words**: Tukai, Tatar literature, poetry, image.

## XX–XXI ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ

***Ә.С. Хәйруллина***
*Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты (Алабуга)*

Габдулла Тукай – үзенең исеме һәм иҗаты белән татар әдәбияты тарихында урыны иң түрдән алган, әдәбият күгендә иң якты янган йолдыз. Ул калдырган әдәби мирас, андагы рухи байлык – милләтебез мактанычы, горурлыгы. Табигать аңа ялкынлы йөрәк, туган халкын чиксез ярату хисе биргән. Җирдәге гомеренең кыска буласын пәйгамбәрләрчә сизенгәндәй, Тукай алтынга торырлык вакытын юк-барга әрәм итмичә, үз иҗатында халык мән-

фәгатьләрен, милли әхлак кануннарын, телне саклап калу ихтыяҗларын белеп яши. Халыкка хас мондый гүзәл мирасның яшь буынга да тапшырылуы мөһим. Менә ни өчен беренче сыйныфтан алып мәктәпне тәмамлаганчы укучыларның Тукай әсәрләрен укып үсүенә зур игътибар бирелә. Укучыда Габдулла Тукай шәхесенә, аның иҗаты һәм эшчәнлегенә мөнәсәбәт нәкъ мәктәп елларында формалаша. Шуңа күрә шагыйрь мирасын өйрәнүнең куелышын, торышын һәм аны камилләштерү, заманчалаштыру юлларын ачыклау әһәмиятле мәсьәлә булып кала бирә. Дәрес эшләнешләре, рекомендацияләр тәкъдим иткәндә моңа игътибар бирелде.

Г. Тукай иҗатын мәктәптә өйрәнүнең олы тарихы бар. Ул шагыйрьнең беренче шигъләре басылып чыгуга ук башлана. Мәсәлән, аның балаларга адресланган «Җуаныч» исемле җыентыгы төсле рәсемнәр белән бизәлеп (рәссаме С. Ахун), 1907 елда ук дөнья күрә. Аннары бер-бер артлы башка җыентыклары да басылып чыга: «Энҗе бөртекләре», «Балалар күңеле», «Күңелле сәхифәләр», «Күңел җимешләре», «Җан азыклары». Боларның һәммәсе мәктәп-мәдрәсәләрдә уку китаплары буларак файдаланылалар. Тукай үзе дә хрестоматияләр төзү остасы буларак таныла. 1909 елда ул «Яңа кыйраәт», 1910 елда «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дип исемләнгән уку китаплары төзеп бастыра. Аларда, әлбәттә, үз шигырьләренә дә урын бирә. Шуннан соң инде мәктәп-мәдрәсәләрдә Тукай иҗатына багышланган дәресләр оештыру матур традициягә әверелеп китә. Д.Ф. Заһидуллина язганча, «Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен төзелгән татар әдәбияты дәреслек-хрестоматияләрендә (XX гасыр башы) Г. Тукайның күп әсәрләре урын алган. Әле Октябрь революциясе булгач та әдәбият дәреслекләрендә, мәсәлән, «Азат мәктәп» (1925), «Тышкын» (1930) дип исемләнгән уку китапларында Тукай шигырьләре дә урын алуы билгеле. 1917 елга кадәрге методикада Г. Тукай укучыга милләт хәлен җырлаучы кебек тәкъдим ителә [4: 6].

1925–1930 еллардан башлап һәм аннан соң стабиль программалар буенча укыта башлагач та Г. Тукай әсәрләре, әдәбият курсында әйдәп баручы урында калса да, аларны укыту тәртибе, юнәлеше үзгәрә: идеологик максатка буйсындырыла. Шунысын да искәртергә кирәк, төрле чорларда Тукайны дәреслекләрдән чыгарып ташлау омтылышы да булган. Узган гасырның егерменче елларында «Шүрәле», «Су анасы» кебек әсәрләрне балаларга укыту-укытмау хакында да бәхәсләр күп була. «Шүрәле» әкият – поэмасындагы Былтырны нинди герой буларак тәкъдим итү дә четерекле сорауга әверелә: Шүрәлене хәйлә ярдәмендә җиңгән уңай героймы, төнлә урманга утын ярырга килгән тискәре персонажмы? Бәхәстә хәтта шул заманның күренекле кешеләреннән М. Горький, Н. Крупскаялар да катнашкан [4: 6].

Ничек кенә булмасын, халыкны шагыйрьнең мирасыннан бөтенләй үк читләштерә алмаганнар. Шулай да Тукай иҗаты, чор идеологичсенә карап, укучыларга төрлечә тәкъдим ителгән. Ул атеист шагыйрь буларак та, социализм идеяләре өчен көрәшче буларак та бирелгән. Тукай иҗатын мәктәптә өйрәнүдә идеологик тайпылышлар булуга борчылып, булса кирәк, Хатип Госман «Әдәбият кешене матурлык тойгысы белән тәрбияли» исемле мәкаләсен [2: 32–37] язып бастыра. Анда автор Габдулла Тукай лирикасының әдәбиятта тоткан урынына, тәрбия һәм белем бирү роленә югары бәя бирә, иҗат үзенчәлеген билгели дә шагыйрь әсәрләрен мәктәптә өйрәнүгә кагылышлы кыйммәтле фикерләр әйтә: Тукай поэзиясен бөтендөнья сәнгать хәрәкәте фонына куеп өйрәнү, аның катлаулы көчләрнең дәһшәтле

коллизияләре уртасыннан авыр юл салып баручы, шул юлда ныгыган, көч – көдрәт алган лирик героена җитди игътибар бирү, шагыйрь әсәрләрендәге тирән һәм сулышчан философияне, сәнгатьчә матурлыкны балаларга җиткерү. Хәзерге вакытта Тукайны ничек бар – шулай өйрәнү, шулай укыту мөмкинлеге туды. Шагыйрьнең «Шагыйрьне искә алу дәрес»ндә, «Су анасы», «Шүрәле» әкият-поэмаларына кыскача тукталып китик. «...әсәрнең идея-эчтәлегенә игътибар биреп, биредә яхшылык белән яманлык көрәше гәүдәләнүе ачыклап үтелә». Шуннан соң дәрес бик кызыклы, әмма, нәкъ менә әдәби әсәр өйрәнү логикасына бик үк сыешып бетмәгән нәтиҗә белән тәмамлана: «Ә менә бүген урманнарыбыз киселә. Шулай булгач, анда урман ияләре дә юкка чыгарыла, табигать ярлылана. Ике әкияттә дә экологик проблемаларның кискенләшүенә ишарә ясала. Тукай яшь буыннарны әнә шундый куркынычтан кисәткән» [*А.Х.*].

Әлбәттә, әдәбият дәресләрендә экологик проблеманы да күтәрү мөһим. Әмма моның өчен башка әсәрләрне, әйтик Г.Бәширов «Җидегән чишмә»сен алу күпкә уңышлырак. «Шүрәле» поэмасында исә төп игътибарны урманнарның киселеп юкка чыгуларына түгел, ә авыл табигатенең гүзәллегенә, шул авыл халкының көнкүрешенә, иң мөһиме – әсәрнең сәнгатьчә камиллегенә юнәлдерү, күпкә отышлы булыр иде.

1950-1960 еллардан әсәрләрнең эстетик кыйммәтенә игътибар бирү, балаларга Тукайны татар әдәбиятының иң якты йолдызларыннан берсе буларак таныту омтылышы беренче планга чыга, ләкин Г. Тукай иҗаты нигездә социаль проблемалар кую, аларны чишү яктылыгында өйрәнелә. Шагыйрьнең иҗтимагый яңгырашлы шигырьләре («Китмибез!», «Государственная думага», «Сайфия» һ.б.) игътибар үзәгенә куела. Шулай да, шагыйрь иҗатын өйрәнү, әсәрләрнең сәнгатьчә кыйммәтен укучыларга җиткерү юлларын эзләү өзлексез бара. Берничә хезмәтне генә китерик: И.З. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1982) [7], С.Г. Исмәгыйлованың «IX–V классларда лирик әсәрләрне өйрәнү» (1985) [5] һәм «VIII класста әдәбият дәресләре» шулай ук «Игътибар: әдәбият дәресе бара...» (2004) [6], А.Г. Яхинның «Әдәбият дәреслекләре буйлап» (2006), М.Ш. Җәләлиева, Д.Ш. Сибгатуллинаның «5 нче сыйныфта әдәбият укыту» (2008) [3] кебек хезмәтләрендә укытучылар өчен мөһим методик проблемалар күтәрелә, аларны чишү юллары эшләнелә. Шулай булмый мөмкин түгел. Чөнки Тукай иҗатына әле дә булса әдәбият программасында шактый зур урын бирелә.

Хәзерге укытучы традицион программалардан, ддәреслекләрдән тыш, аларның альтернатив вариантлары белән дә эш алып барырга мөмкин. Бу – программаның эчтәлегенә, укучылар белән эшләү методикасына да кагыла.

Билгеле булганча, А.Г. Яхин программасы буенча төзелгән дәреслекләр, әсәрне сәнгать, хис-кичерешләр дөньясы буларак караудан бигрәк фикерләүне күздә тоталар. Галим, мәсәлән, Г. Тукайның «Туган җиремә» шигыренә анализ ясаганда әсәрдәге каршылыкны баланың үзеннән эзләп таптырырга һәм аңлатырга Габдулла Тукайның авылны ярату хисенең дәрәҗәсе турында сөйләтергә тәкъдим итә. Әсәрнең сәнгатьчә үзенчәлеген танып белмичә, мондый биремнәр үтәргә укучы әлегә хәзерлексез булуы мөмкин. Шулай да, шигырьләргә анализ ясау алымнары укучыларның фикерен активлаштыру юнәлешендә сайлануы яхшы, әлбәттә.

Шунысы игътибарны җәлеп итә, әдәбият галимнәре һәм методистлар татар балаларына рус әдәбиятын укытуда да Г. Тукай иҗатына мөрәҗәгать

итүне кирәк дип саныйлар. «Изучение русской литературы в татарской школе предполагает установление ассоциативных связей между русской и родной литературой учащихся, что очень важно для выявления черт общности в двух литературах. Поэтому лирика А.С. Пушкина, М.Ю. Лермонтова, Н.А. Некрасова будет восприниматься учащимися глубже, если будут созданы условия для «диалога культур». Этого можно добиться, обращаясь к лирике Тукая», – дип яза М. Әхмәтҗанов [1: 22].

Күрәбез мәктәпләрдә Г. Тукай иҗатын өйрәнүнең XX гасыр башыннан ук юл ала. Шуннан соң да аның әсәрләре программа һәм дәреслек битләреннән төшми. Дөрес, методик карашлар каршылыксыз гына бармый. Монда камиллшү процессының да ныгый баруын билгеләп үтәргә кирәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәтҗанов М. Лирика Г. Тукая в контексте «диалога культур» // Мәгариф. – 2006. – № 1. – С. 22 – 24.

2. Госман Х. Әдәбият кешене матурлык тойгысы белән тәрбияли // Совет мәктәбе. – 1965.– № 2.– Б. 32–37.

3. Җәләлиева М.С., Сибгатуллина Д.Ш. 5 нче сыйныфта әдәбият укыту. – Казан: Мәгариф, 2008. – 127 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 434 б.

5. Исмәгыйлова С.Г. V– IX классларда лирик әсәрләрне өйрәнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985 – 184 б.

6. Исмәгыйлова С.Г. Игътибар: әдәбият дәресе бара...: методик кулланма. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2004. – 94 б.

7. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты: урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982 – 288 б.

УДК 811.512.145

# ФОНЕТИЧЕСКИЕ И ЛЕКСИЧЕСКИЕ ДИАЛЕКТИЗМЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ТУКАЯ

***А.Я. Хусаинова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В данной статье рассматриваются фонетические и лексические диалектизмы в творчестве Г. Тукая. Приводятся примеры, характерный, как для среднего диалекта татарского языка, так и для западного. При интерпретации приведены сравнения из различных говоров и языков. Анализ диалектизмов показал, что в произведениях Г. Тукая они использованы в соответствии со стилем, для более образного представления недостатков общества того времени, а также форм говоров родного языка.
**Ключевые слова:** говоры, фонетические диалектизмы, фонетические варианты, лексические диалектизмы, интерпретация диалектизмов.

This article discusses phonetic and lexical dialectisms in the works of G. Tukai. Examples are given that are typical for both the middle dialect of the Tatar language and the Western one. When interpreting, comparisons from different dialects and languages are given. The analysis of dialectisms showed that in the works of G. Tukai they are used in accordance with the style, for a more imaginative representation of the shortcomings of the society of that time, as well as the forms of dialects of the native language.
**Key words:** говоры, фонетические диалектизмы, фонетические варианты, лексические диалектизмы, интерпретация диалектизмов.

# Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФОНЕТИК ҺӘМ ЛЕКСИК ДИАЛЕКТИЗМНАР

***А.Җ. Хөсәенова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Җирле сөйләм, гадәттә, персонаж телендә ишетелә, аның кайсы тарафтан булуын, тел культурасын тойдырырга, типиклаштырырга, индивидуальләштерергә булыша. Җирле сөйләмнең матур әдәбиятта законлы урыны, диалект һәм милли телнең үзара бәйләнеше, йогынтысы белән билгеләнә. Диалектлар – халыкның тел диңгезен тулыландырып торучы чишмәләр алар. Ул чыганаклардан уртак телгә мәшәкатьсез аңлашылырдай сүзләр, гыйбарә, фразалар керә тора. Язучы да, берәр сүз әдәби телдә булмаганда, җирле сөйләмгә мөрәҗәгать итә һәм кайбер сүзләр әдәби сүзгә әйләнә [5: 121]. Диалекталь сүз әдәби телгә түбәндәге очракларда килеп керә: 1) әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаса; 2) персонажның сөйләм үзенчәлеген сурәтләү өчен; 3) язучының үз хикәяләвендә милли колорит бирү өчен; 4) этнографик лексиканы бирү максаты белән. Диалекталь сүзләрне куллану әсәрнең темасына, сурәтләү объектына, авторның максатына, аның эстетик идеалына, осталыгына бәйле. Татар язучыларының күпчелеге авылдан чыкканга күрә, һәр язучы үзе яшәгән төбәкнең диалекталь лексикасын куллана. Бу – автор сөйләмендә дә, персонаж сөйләмендә дә күзәтелә, хәтта аерым очракларда публицистикада да урын ала. Матур әдәбиятта диалектизмнарның мәгънә төрлелеге күзәтелә. Автор аның мәгънәсен юл астына төшерергә мөмкин, сүздән соң җәя эчендә бирергә мөмкин, куштырнаклар эчендә күрсәтергә мөмкин; автор һәм персонаж тарафыннан мәгънәсе тасвирлап күрсәтелергә мөмкин [6: 158].

Поэзиядә диалектизмнарны әсәрләр тукымасында куллану традицияләре бөек классикларыбыз шигырьләрендә үк чагыла. Күренекле галимебез, Д.Б. Рамзанова Г. Тукай әсәрләрендә диалектизмнар чагыштырмача аз очрауын ассызыклый, һәм Г. Тукай әсәрләренең телендәге җирле үзенчәлекләргә күзәтү ясау да аның бай мирасының әлегә кул тимәгән сәхифәләре бар икәнен күрсәтә. Әдибебезнең иҗаты, фикер-фәһем тирәнлеге генә түгел, шуларны белдерә торган сүзләр һәм формаларның күптөрлелеге белән дә гаять бай һәм зур кызыксыну уята дигән фикердә була [1: 34–37]. Г. Тукай әсәрләрендә диалектизмнар куллануга кайбер мисаллар китерик (Г. Тукайның 1955–1956 елларда чыгарылган 4 томлык сайланма әсәрләреннән, һәм 2003 елда басылган сайланма әсәрләреннән). Мәкаләдә фонетик һәм лексик диалектизмнарның кулланышын тикшерәбез.

Беренче төркем фонетик диалектизмнар, ягъни авазлар кулланылышы белән бәйле үзенчәлекләр.

Ике сузык арасындагы [д] авазының яңгыраулашуы: йозрык (сөйләм телендә йозырык) – йодрык. Мондый фонетик күренеш казан арты, минзәлә, бөре сөйләшләрендә билгеле бер төркем сүзләрдә күзәтелгән фонетик күренеш. Ягъни әдипнең туган сөйләшенә хас үзенчәлек.

Мәсәлән,

*Сиздем шунда: тәнем җылынып китте, кызып,*
*Дөп! дөп! итә мине сыйлап төшкән йозрык* [4: 268].

Урта диалект сөйләшләренә җ-ләштерү характерлы, ягъни күпчелек очракта *җ* авазы *й* авазына тәңгәлләшә. Мәсәлән: җәшел – йәшел (яшел), җул – йул (юл). җегет – йегет (егет) һ.б.

*Җырласаң да, җегет, ачы җырла,*
*Уяу җаткан кызлар җокласын* [4: 346].

*Җул тып - тын.* [4, 2003: 347].

[ң] авазы янында [ғ], [г] авазы өстәлү. Мәсәлән: иңгүче – иңүче, исеңгә – исеңә, нәселеңгә – нәселеңә, өстеңгә – өстеңә һ.б.

*Бар күңел хәдсез, хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы,*
*Санки күңлең җиргә күктән иңгүче рәхмәт юлы* [4: 247].

*Әгәр исеңгә төшсә кайсы чакта,*
*Кайчандыр уйнаганы бу яңакта* [Тукай, 2003: 79].

Бу күренеш тә Г. Тукайның туган сөйләшенә хас үзенчәлек. Билгеле булганча, ул хәзерге Татарстанның Әтнә, Дөбъяз, Арча, Биектау районнарында һәм шулай ук Мари Элнең Бәрәңге төбәгендә актив күзәтелә торган үзенчәлекләрнең берсе [3: 19–78].

Икенче төркем диалектизмнарны Г. Тукай әсәрләрендә кулланылган диалекталь сүзләр тәшкил итәләр. Бу төркемгә күптөрлелек хас.

*Күршеләрнең рәнҗи ирде җаннары,*
*Түзмәерди җаннары, вөҗданнары.*

*түзмәерди* [Тукай, т. I: 27] – түзми иде.

*Дәрдемәнд мәсьүл улырмы? Мөбтәлаем,ниләем?*
*Җиceме җанымлә бәрабәр бер бәлаем, ниләем?*
*Агыйделнең аръягында атлар йөри чабында;*
*«Чүкеч» сабын кимереп елый, «Яшен» суккан чагында.*

*чабын* [Тукай, т. II; 15, 279] – әд. чабынлык,

Чабын – 1. Лш., минз., стрл. чабынлык (покос, место косьбы). Элек чабын ийе, печән чабалар ийе. – стрл.; 2. Лш., минз., болын, печәнлек (луг). Әле чабында печән чабабыз. – лш., 3. Минз. печәне чабып алынган җире (скошенный луг) [2: 722].

*Гаҗәпләнеп бүз тургайга: басып сайрый кургайга;*
*Һич кешгә белдермәймен – зарый кылам ходайга.*

*Бүз тургай* [II, 325], *бастурғай* кмшл. бүдәнә, бытбылдык (перепёлка). *Бастурғай дигән қош бар.* [2: 102], *бистурғай* кмшл. тургай (жаворонок) [2: 124], *бустыр'ай* кас. тургай (жаворонок) [2: 13], *бүзтурғай* әстр. чыпчык (воробей) [2: 141].

*Хәстә төсле* [Тукай, т. II: 47] – авыру төсле, хаста йату лмб. авырып яту, чирләп яту (болеть, лежать в постели). *Ылы биг аwыр хаста йата* [2: 699].

*Үзеңдә ялкаулык,*
*Хатыныңда аңкаулык;*

*аңкаулык* (Тукай, т. I: 4) – аңгыралык, ахмаклык, аңқау бгрс., әстр., аңқау тмн. аңсыз, надан. *Аңқау бит инде әwәлге халық, башы эшләмәгән бәрәңге чәчәргә.* – бгрс. [2: 46].

Шулай итеп, Л.Т. Мәхмүтова һәм Н.Б. Борһановаларның казан арты сөйләшләрендә йомышлы татарларның (башта алар мишәрләрдән генә

торганнар) эзе калган булу турындагы фикерләре XIX йөз азагы – XX йөз башындагы җирле сөйләш материаллары белән раслана [1: 35].

Әдипләр иҗатында әдәби тел белән поэтик таләпләр нигезендә җирле сөйләш сүзләре һәм грамматик күренешләре дә урын алырга мөмкин. Шагыйрьләр, язучылар әсәрләрендә кулланылган диалектизмнар – аларның туып-үскән төбәк сөйләше белән бәйләнешен билгеләүче күренеш.

ӘДӘБИЯТ


1. Рамазанова Д. Б Г. Тукай әсәрләренең үзенчәлекләре бүген дә актуаль // Фән һәм тел. – 2010. – № 1. – Б. 34–37.

2. Татар теленең зур диалекталогик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

3. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. – Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.

4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 480 б.

5. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары,педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. –Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Раннур. – 2002. – 352 б.

6. Хусаинова А.Я. Җирле диалект лексикасы // Татар теле лексикологиясе:өч томда. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – Б. 136–220.



УДК 821.512.145


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ В ВОСПОМИНАНИЯХ МИРГАЗИЗА УКМАСИ


***Г.А. Хуснутдинова***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



В статье в обзорном плане рассматриваются воспоминания о Тукае его современника М. Укмаси. Эти воспоминания являются ценным источником в изучении творчества и биографии поэта. На основе письменных свидетельств воссоздан образ Тукая.



**Ключевые слова:** Г. Тукай, М. Укмаси, татарская литература, воспоминания.



The article reviews the memoirs of his contemporary M. Ukmasi about Tukai. These memories are a valuable source in the study of the poet’s work and biography. On the basis of written evidence, the image of Tukay was recreated.



**Key words:** G. Tukay, M. Ukmasi, Tatar literature, memoirs.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ – МИРГАЗИЗ УКМАСЫЙ ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ


***Г.А. Хөснетдинова***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*


Татар әдәбияты XX йөз башында аеручa зур иҗади яңарыш кичерә. Ул әдәбият һәм сәнгать әһелләре тарафыннан милләт тарихында яңа заман башлану дип кабул ителде, чөнки бу чор тарихи, иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең күп булуы ягыннан гына түгел, бәлки әдәбият, сәнгать, мәгариф үсеше нисбәтеннән дә үзенчәлекле иде.

1905 елгы инкыйлаб тәэсирендә вакытлы матбугатның тууы, китап басуның киң колач алуы, әдәби хәрәкәтне нык җанландыруга, яңа әсәрләрне

укучы игътибарына тәкъдим итәрлек мәйдан, фикер алышулар өчен мөмкинлекләр ача. Иҗат мәйданына Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Дәрдемәнд кебек әдипләр килә. Бу классик шагыйрьләр белән бер үк заманда, бер үк иҗтимагый мохитта дистәләрчә язучылар да иҗат иткән. Шуларның берсе – Миргазиз Укмасый. Озак вакытлар – 1930–1940 елларда аның иҗат мирасы барланмый, өйрәнелми, укучылар игътибарына тәкъдим ителми кала бирде. Ниһаять, 1950 елларда гына укучылар М. Укмасыйның аерым әсәрләрен укый алдылар: 1958 елда «Сайланма әсәрләр»е басылды, шигырьләренең беркадәресе «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956), «Татар шигърияте: XX гасыр башы» исемле җыентыкка урнаштырылды; күптомлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томында (1986) кайберләренә кыскача гына булса да бәя бирелде.

Соңгы елларда әдәбият галиме, текстолог Зөфәр Рәмиевнең вакытлы матбугат битләрендә бастырган мәкаләләре һәм, ниһаять, 2018 елда дөнья күргән «Миргазиз Укмасый. Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» китабы М. Укмасыйның тормыш юлын, аның үзенчәлекле иҗади эшчәнлеген ачыграк күзалларга мөмкинлек тудыра.

Миргазиз Укмасыйның язма мирасы күпсанлы тезмә әсәрләрне, шулай ук берничә хикәяне, мәкалә, пьеса һәм истәлекләрне эченә ала. Вакытлы матбугатта аның әсәрләре 1905 елда, ягъни татар телендә көндәлек матбугат туганнан соң гына күренә башлый. Беренче шигырьләр җыентыгы Казанда 1906 елда «Хатирә, яки дустларыма сүзләрем» исеме белән басылып чыга. Шигырьләрендә ул халыкны белем алырга, һөнәрле булырга өнди. Ә инде «Алданма кызыл алмага» (1907), «Миргазиз Укмасый шигырьләре» (1909), «Өмид йолдызым» (1912) кебек шигъри җыентыкларында шагыйрь милләтнең тормыш-көнкүрешен, туган җир табигатен сурәтләүгә игътибарын юнәлтә. Алар заманында халык арасында яратып укыла һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан да уңай бәяләнә.

М. Укмасыйның иҗатына Г. Тукай да игътибар итә, аның шигърияте белән кызыксына. Ул 1910 елда Казанда «Сабах» көтепханәсендә басылган «Халык әдәбияты» китабында М. Укмасыйның «Килен» (1910) шигырен талантлы каләм белән «халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене белән язылган» әсәр дип югары бәяли, аның «Зиләйлүк» вә яки «Әллүки» көйләренә башкарылу мөмкинлеген ассызыклый [1: 175].

Тукай Укмасыйның авыл табигатен, аның сихри матурлыгын балалар күңелен белеп, гади, җиңел аңлаешлы образ һәм сурәтләр аша гәүдәләндергән берничә шигырен («Мазарстанда», «Таң») балалар өчен төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911) хрестоматиясенә дә кертә. Мәгълүм булганча, шагыйрь хрестоматиягә эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше балалар әдәбияты таләпләренә җавап биргән авторлар әсәрләренә генә мөрәҗәгать итә. Бу үз чиратында Тукайның Укмасыйга биргән зур бәясе дә.

Укмасый үзе дә Тукай эзеннән барып, 1912 елда башлангыч сыйныф укучылары өчен «Алтын таҗ» дигән әдәбият уку, халык иҗаты әсәрләрен җыйнаган «Көйләр тарихы вә җырлар» исемле биш кисәктән торган китапларын бастыра.

Әдипкә үз гомерендә татарның күренекле язучы һәм мәгърифәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре, заманасының алдынгы кешеләре белән аралашырга туры килә һәм әйтергә кирәк, алар, һичшиксез, аның күңелендә тирән эз калдырган, аны истәлекләр язуга өтәргән [3: 15]. Безнең өчен аның Г. Тукай

хакында язылган истәлекләре аеруча кыйммәтле. Аларның билгеле булганнары икәү: берсе «Габдулла Тукай хакында кайбер истәлекләр», икенчесе – «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» дип исемләнгән. Әлбәттә, күп еллар элек булып үткән вакыйгаларны искә төшереп язганда, аерым фактларда, вакыйгаларда читкәрәк тайпылулар, төгәлсезлекләр булуы да мөмкин. Шулай да һәрбер истәлек әдип тормышындагы бер моментны яктырту ягыннан кызыклы һәм алар шәхеснең фәнни тәрҗемәи хәлен тулыландыруга азмы-күпме булышлык итәләр.

М. Укмасый «Габдулла Тукай хакында кайбер истәлекләр»ен 1939 елның 31 декабрендә язып тәмамлый. Анда 1909–1910 елларда булган вакыйгалар хакында сөйләнә. Истәлек Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Беренче тапкыр «Тукай – ядкярләрдә» җыентыгының 1 нче томында [2: 320–332], аннан соң Зөфәр Рәмиев тарафыннан төзелгән «Миргазиз Укмасый. Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» [3: 275–287] җыентыкларында басыла.

Истәлек М. Укмасыйның Кузнецкий өязе Кынады авылыннан, пароход белән, Казанга кайтуын сурәтләү белән башланып китә. Ул Казанны, Тукайны, Камалларны, Урманчиевларны сагынган, алар белән күрешүне түземсезек белән көтә. Үзенең хәләте хакында: «мин хәзер бай, укытып кайтып киләм, кесәдә 80 сумнар чамасы акчам бар... кыш буена укытып, мин арыгын, гәзитәләрдән читтә торып, Казанны бик сагынган» [3: 276], дип яза. Шагыйрьнең кайту шатлыгы, сагынуының никадәр көчле булуы аның инде бик таныш булган «мәдәният-культура казаны» Казанны тасвир итүеннән дә күренә. Язучы Кремль, Сөембикә манарасы, хәтта алтын гөмбәзле чиркәүләрнең матурлыгына да соклана, аның өчен шәһәрдә яшәгән барлык халык «бөтен көчләрен адәмчелек бәхете өчен генә агызалар төсле булып тоела» [3: 276]. Әдип истәлекне мавыктыргыч итеп, үзенә хас тел белән хикәяли, чагыштырулар кулланып җанлылык өсти.

Укмасый извозчик яллап, татарларның әдәби үзәкләренә һәр яктан якын булган, әмма иң мөһиме Тукай да шунда яшәгән «Болгар» номерларына урнашырга килә. Парадныйда ук Тукай белән очраша. Шагыйрь аның хакында яратып, үз итеп «минем сагынган Тукаем» дип яза һәм кыяфәтен тасвир итәргә керешә. «Уртача буйлы, миңа караганда аз гына тәбәнәгрәк, ләкин киңчәрәк, йөзе сары, киңчә, күз төшүгә, күзендә ризасызлык, боеклык, өстбашы да простой тужурка, простой чалбар, ләкин алар нык таушалганнар, аякта шиблит, бавы бер-ике җирдән өзелеп төйнәлгәннәр, озын, ләкин таралмаган тәртипсез чәч, башта фуражка» [3: 277].

Алар бик җылы итеп, якын туганнар кебек кочаклашып күрешәләр. Тукай Укмасыйны үзенә чакыра. Кунакханәнең икенче катында урнашкан бүлмәне Укмасый болай сурәтли: «бер тәрәзәле тар гына бүлмә, сул якта бер кешелек начар гына тимер креват куелган, аның өстенә сүрүе дә күптән җуылмаган, кап-кара, бик каты бер мендәр, одеал белән караваты аннан-моннан гына бик начар итеп җабылган сыман иткән. Өстәл өстендә җанып аз гына бетми калган шәм ... пепельница, ул пачкасы 5 тиенлек «Богатырь» окуркасы белән тулган, пачка кәгазе, папирос беткәч, идәнгә ыргытылган ... өстәл өстендә: кичә чәй китергән су чәйнеге ... бер дистәметр (*дециметр*) киңлегендә буйга байтак озын, гәзиткә язган мәкаләләргә охшаган, кичә төннә язылган 4 данә яки «багана» кәгазьләр ... Эстинада бер пальто

һәм бер брюка эленгән, ... бер шиблет, тәрәзә төбендә каралган бер ак яка җата. Караватка бер галстук элеп куелган» [3: 278–279].

Укмасый белән Г. Тукай еш очрашканнар булса кирәк. Алар төрле темаларга – иҗат, әдәбият, вакытлы матбугат хакында сөйләшкәннәр, бәхәсләшкәннәр. Шулай бервакыт (вакыйга 1910 елда булган) Г. Тукай кисәктән, бүлмәсенә килгән Г. Камал, З. Бәшири, Ш. Гайфи һәм М. Укмасыйга, шигырь язганда кемгә, ничек, кайвакытта илһам килүе белән кызыксынып, сорау бирә. Әлбәттә, җаваплар төрле була. Укмасый «минем илһамым баш чыгарган арыш басуы эчендә, ташланган һәм әремнәр үскән, кеше йөрми торган юлдан, тынлыкта, ялгызлыкта, тургайлар сайравын тыңлап барганда, кыр уртасында үскән ялгыз каеннар, еракта, арыш басуы аркылы томансу булып кына күренә торган урманнарны яисә яшел болын уртасын җырлап үткән, җалкылдап җата торган су буйларында, ләкин тынлыкта», дип җавап биргәч, Г. Тукай: «Син шуңар күрә һаман табигать кенә җырлыйсың шул. Ну нечего, матур нәрсә» [3: 281], дип иҗатын хуплый.

Истәлектә Тукайның, буржуа корбаннары булган халыкны газаптан, коллыктан коткару мөмкинлекләрен, юлларын эзләве хакындагы уй-кичерешләре дә сурәтләнә. Чөнки шагыйрь, бигрәк тә реакция елларында, милләт өстенә төшкән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне үз күңеле аша үткәрә, байларга, алпавытларга нәфрәт белән яна. Фикерен дәвам итеп: «Ак якалы халыкларга караганда, әнә шул сал өстендә ага торган, тәкәллефне (*ясалмалыкны*) белми торган рабочийлар минем өчен туганнар, якыннар» [3: 283], ди. Укмасыйга мөрәҗәгать итеп: «Кайчан адәм балалары тигез, рәхәт көн күрә башларлар? Без күрербез микән шуны, Укмасый?» дип, сорау бирә, үзенең халыкка ярдәм итә алмаганлыгына борчыла.

Икенче – «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» дигән истәлек беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналының 1946 елгы 4 нче санында басыла. М. Укмасый аны Г. Тукайның апасы Сажидә Хәбибуллина сөйләгәннәрдән файдаланып язган. Истәлек Тукайның ятимлектә үткән авыр балачагы хакында тәфсилле итеп сөйләү белән башлана. Бу ягы белән ул шагыйрьнең «Исемдә калганнар» (1909) автобиографик повесте белән охшаш, аваздаш. Сөйләүчесе «Тукайга бөтен гомерендә күңел җылылыгын бирүче, аны яратучы, аның өчен кайгыртучы кеше» [3: 294] Сажидә апасы булганлыктан, сурәтләнгән вакыйгалар аларның икесе арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен, дустанә булып яшәүләрен тасвирлаудан гыйбарәт.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: Миргазиз Укмасыйның иҗаты әдәбиятчы галимнәр тарафыннан җентекләп тикшерүгә лаек. Аның шигырьләре, прозасы әдәбиятыбызны тагын да баетыр, тагын да югарырак күтәрер иде. Ә инде аның Тукай хакында язылган истәлекләре шагыйрьнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г.М. Әсәрләр. Академик басма. 6 томда. – 4 т.: проза, публицистика (1907–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Г. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 431 б.

2. Тукай – ядкярләрдә. 2 томда. – 1 т.: истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар / төз.: Р. Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – 968 б.

3. Укмасый М. Әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр / төз. Зөфәр Рәмиев. – Казан: ТӘҺСИ, 2018. – 356 б.

УДК: 894.343:398.22

# ФОЛЬКЛОР В ТВОРЧЕСТВЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

***Н.А. Хуббитдинова***
*ИИЯЛ УФИЦ РАН (Уфа)*

*Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ и АН РБ в рамках проекта № 19-412-020008 «Архаический эпос башкирского народа: художественно-стилистический аспект (эпосы «Урал-батыр», «Акбузат», «Заятуляк и Хыухылу»)»*

Классик татарской поэзии Габдулла Тукай, чье творчество также было близко и культуре башкирского народа, внес огромный вклад в сохранение устной поэзии и как общественный деятель, и, прежде всего, как поэт и гражданин. Его трепетное и бережливое обращение с традициями фольклора, понимание всей важности их сохранения, при этом, не ограниваясь лишь родным татарским народным творчеством, говорит о высокой культуре самого певца свободы и света.
В статье рассматриваются некоторые поэмы, в которых Г. Тукай мастерски использовал фольклорные традиции. Этим он обогатил художественно-эстетическое, идейно-тематическое составляющее не только своих произведений, но и татарской поэзии в целом. Эти традиции также являются традиционными и для башкирской культуры, устного народного творчества, что говорит об общности, их принадлежности к художественным универсалиям культуры.
**Ключевые слова:** поэзия Габдуллы Тукая, поэма «Шурале», лекция, устное народное творчество, литература, традиции.

The classic of Tatar poetry Gabdulla Tukai, whose work was also close to the culture of the Bashkir people, made a huge contribution to the preservation of oral poetry both as a public figure and, above all, as a poet and citizen. His tearful and frugal treatment of the traditions of folklore, an understanding of the whole importance of preserving them, while not limiting itself to his native Tatar folk work, speaks of the high culture of the singer of freedom and light himself.
The article examines some poems in which G. Tukai masterfully used folklore traditions. With this, he enriched the artistic and aesthetic, ideological and thematic component not only of his works, but also of Tatar poetry as a whole. These traditions are also traditional for Bashkir culture, oral folk art, which indicates community, their artistic universality of culture.
**Key words**: poetry of Gabdullah Tukai, poem «Shurale», lecture, oral folk art, literature, traditions.

Несмотря на то, что в начале XX века литературная мысль народов России переживала новый виток в своем развитии, сопряженный с тяжелой социально-политической обстановкой в стране, а также зарождением и усилением в последующие годы национального самосознания людей, национальная художественная словесность развивалась в ногу со временем. Например, башкирская литература как никогда сблизилась с жизнью народа, которая ярче всего отразилась в его устно-поэтическом творчестве. «С одной стороны, она отстаивала общенациональные интересы башкир, их право на духовную и национальную самобытность, призывала народ к борьбе против незаконных захватов и расхищения башкирских (вотчинных. – *Н.Х.*) земель, с другой – довольно ярко стала отражать классовую дифференциацию в обществе, поднимала острые социальные вопросы» [1: 207].

В этот период связь между фольклором и литературой проявлялась во всей своей многообразии: одни писатели напрямую обращались к устно-поэтическому народному творчеству, фиксировали и публиковали отдельной

книгой или в различных газетных, журнальных изданиях, в своих публицистических выступлениях призывали к борьбе за чистоту родного языка путем обращения к фольклору, другие творчески осваивали фольклорные традиции – мотивы и сюжеты сказок, эпоса или кубаира в своих произведениях, создавали на их основе собственные произведения и т.д. (С. Якшигулов, Д. Юлтый «Положение башкир», М. Тангатаров, С. Якшигулов «Обращение к братьям башкирам», Ф. Туйкин «Башкирская женщина», написал поэму «Идельбай», драму «Сыновья Отчизны» и т.д.).

Подобную картину можно было наблюдать и в творчестве татарских писателей, которые также обращались к устно-поэтическому наследию своего народа, «обозначив тем самым главной своей целью поиск и идеологическое определение дальнейших путей развития нации, сохранение ее конфессиональной и культурной самобытности» (Г. Исхаки, Г. Тукай, Дэрдмэн, Г. Камал, Ф. Амирханов, Ш. Камал, Г. Ибрагимов и др.) [2:10]. Например, в поэмах великого татарского классика Габдуллы Тукая «Шурале» (1907), «Водяная ведьма» (1908) нашли художественное воплощение демонологические образы. С усилением национального самосознания среди татарского народа в начале XX в. также активизировалась деятельность по собиранию и популяризации устного народного творчества. На страницах печати в разные годы издавались статьи и материалы по теме («О татарских песнях» Максютова (Шура, 1911), «О наших песнях» А. Валиди (Шура, 1911), «Песни края (иль)» Г. Юлдаша (Шура, 1911) мн. др.) [3: 28].

Известно также, что Габдулла Тукай также не остался в стороне от этого движения. Он ратовал за сохранение и бережное отношение к фольклорному наследию. В частности, в своих лекциях по народной литературе, т.е. по устному народному творчеству, фольклору, от 15 апреля 1910 г. (?) прочитанных для публики, высоко ценил значение народной песни и призвал заботиться о ее сохранении. При этом он вел речь не только о татарских, но башкирских национальных протяжных песнях и, в отличие от представителей официальной науки, утверждал, что забота о сохранении этого феномена есть гарантия сохранения самого народа. Будучи в Уфе в 1912 году по пути в Троицк, Тукай с восхищением слушал такие песни в исполнении некоего Ахматфаиза Даутова. Об этом в своих выступлениях, в частности, подробнее всего высказался известный ученый-фольклорист А.М. Сулейманов.

Г. Тукай очень трепетно относился к традициям устного народного поэтического творчества. Как поэт, видимо, его духу ближе всего были народные песни. Во время своей вышеупомянутой лекции он, в частности, сказал следующее: «Халыҡ йырҙарының … гәүһәр вә яҡуттарҙан да ҡиммәтле бер нәмә булғаны өсөн дә, уларға әһәмиәт бирергә кәрәк. Уларҙы юғатмаҫҡа ижтиҡад итергә (тырышырға) кәрәк. Белергә кәрәк ки, халыҡ йырҙары – халҡыбыҙ күңеленең һис тә тутыҡмаҫ вә күгәрмәҫ саф вә рәүшан (яҡты) көҙгөһөлөр» (в переводе на русский язык звучит буквально так: «Народные песни … дороже всех жемчугов и бриллиантов, поэтому на них надо обратить внимание (придать значение). Надо стараться беречь их (не потерять). Надо знать, что народные песни – это отражение не ржавеющей и не плесневеющей светлой души народа») [11: 174]. Лекция Г. Тукая о народном творчестве была опубликована отдельной книге в издательстве библиотеки «Сабах» в Казани в том же году.

В своей лекции поэт затронул такие народные песни и баиты, как «Тафтиляу», «Езнэкэй», «Башмак», «Ашкадар», «Сак-Сук» с приведением их легенды. Как писал А.М. Сулейманов, половина приведенных шедевров относится и башкирскому народу. Так, баит «Сак-Сук» и сегодня можно найти среди башкир («Саҡ-Суҡ», «Һаҡ менән Һуҡ», «Һаҡ-Һуҡ» и др.), он является одним из широко распространенных произведений двух соседних народов. А на мотив легенд псесен «Езнэкэй» или «Еҙнәкәй», «Башмағым» или «Башмаҡ көйө» башкирским драматургом и композитором Хабибуллой Ибрагимовым создана пьеса, которая на сцене сменила не одно поколение артистов башкирского и татарского театров.

Среди прочего интерес представляет произведение «Тафтиляу». Татарская версия песни заключает в себя историю драматической любви татарской девушки и юноши француза и звучит как лирическая песня.

В башкирской одноименной песне содержание восходит к кровавой истории народа, в которой свой след оставил историческая личность А.И. Тевкелев. Песня звучит скорее как адресованное ему проклятие народа. Кутлу-Мухаммед Теевкелев мурза из рода Тевкелевых, принял православие, служил дипломатом, является основатель Челябинска, дослужился в чине генерал-майора (1755). В истории башкирского народа известен как руководитель в операции жестокого и хладнокровного подавления башкирских восстаний 1735–1740 годов. Известна трагедия в деревне Суянтус (ныне территория Аскинского района РБ). Так в исторической монографии об Оренбургском крае В.Н. Витевский писал: «Тевкелев разорил дотла около 50-ти деревень, сотнями загонял башкир в пустые амбары и сжигал их, жен и детей башкирских отдавал солдатам, а мужей и отцов подвергал самым жестоким пыткам и казням» [5: 143]. Если сказать точнее: В январе 1736 года отряды под командованием Алексея Ивановича сожгли около 50 башкирских деревень на территории Сибирской даруги, было убито около 2 тысяч человек. Всего за март-апрель 1736 года силами во главе с Тевкелевым было сожжено 503 деревни, убито не менее 3042 человек, а за весь 1736 год, по оценке А.И. Румянцева – не менее 10 тысяч [6].

Так в народе зародилась протяжная песня «Тафтиляу», сложенная как свидетельство этих кровавых событий:

…Тәфтиләү ҙә баяр урманында
Аҡ яурынлы бөркөт ояһы.
Утҡа янһын, көлдәр ҙә булһын
Тәфтиләү ҙә баярҙың донъяһы!

Ҡара ла ғына урман, ҡая бите
Шаулайҙыр ҙа кисен, ел саҡта.
Ташҡайҙарға соҡоп, яҙҙым ҡарғыш,
Ейәндәрем уҡыр бер саҡта [7: 56–57].

Своим глубоко реалистическим и трагическим содержанием отличаются эти две песни, известные под одним именем «Тафтиляу» у татарского и башкирского народов. Это как омоним, пишется и звучит название песни одинаково, но в содержании несет противоположенные смыслы. Как писал А.М. Сулейманов, различия составляют также их мелодии, которая в башкирской песне звучит трагично.

Трепетное и дрожайшее отношение к фольклорным традициям поэта ярче всего видно в его собственном поэтическом творчестве. Ярким примером его обращения к ним, как к художественно-поэтическим деталям, являются его знаменитые стихотворения «Шурале», «Водяная ведьма», «Таз» и др. Образ водяной – һыу эйәһе – су анасы в поэме «Водяная дева» в башкир-

ском народном творчестве, кроме верований в существование мифической хозяйки воды, вызывает реминисценцию на образ Хыухылу из эпоса «Заятуляк и Хыухылу». Здесь она репрезентируется как дева вод – дочь царя озера Асылыкуль, расположенного на юго-западе республики Башкортостан у подножия горы Балкан-тау. В отличие от зловредной тукаевской Водяной ведьмы, она изображается как добродушная девушка, ставшая затем невестой героя Заятуляка [8: 178–220]. Образ хозяев воды является традиционным и для туркмен (хозяйка воды – сув-эйеси, русалка – сув-периси, водные девы – сув-гызы), у славян (русалка), в древнекитайской мифологии Цзяожэнь» – «человек водного племени» и т.д. А Таз из одноименного стихотворения Г. Тукая отсылает нас к герою Плешивому – Тазу – герою из башкирских народных новеллистических сказок, где он представляется ловким и находчивым егетом, сумевшим выйти сухим из любой сложившейся в не его пользу ситуации. В данной статье мы пристальнее остановимся на первом из этих произведений, а именно на знаменитом «Шурале». Наличие этих образов в фольклоре башкир и татар, а также и других тюркских и иных народов, говорит о репрезентации художественных универсалий культуры.

Раньше верили, что природа в сознании древнего человека оживлялась, персонифицировалась, каждая местность – лес, луг, поля, рощи, горы, реки, озера и т.д. имели своего хозяина – эйа: урман эйахы, тау эйахе т.д. Одним из подобных хозяев дремучих лесов, куда не ступала нога человеческая, считался шурале (возможно произошел от шурляу – бояться чего-либо. – *Н.Х.*).

Вследствие мифологического мышления наши предки наделяли их устойчивыми чертами. Многих считали антропоморфными существами. К примеру, бэрей (или бире), как и люди, играли свадьбу, женились между собой, заводили детей. Но нельзя было их путать с людьми, так как некоторые из них были однополые: албасты, убыр, шурале – носители женского начала; бисура, бире, ен, шайтан – мужского. А юха-оборотень имела способность оборачиваться в любой вид, в том числе в животных [9:12].

Поэтизация этих демонологических образов во многом восполнила и гармонизировала суеверное представление этих народов, их единую картину мира, целостную духовную культуру.

Согласно мифическому верованию башкир и татар шурале обитает в дремучих лесах, при встрече с людьми своими длинными пальцами любит щекотать их до смерти. В народе известны существования своеобразных правил поведения при встрече с подобными демонологическими существами.

У Г. Тукая наблюдается эксплицитная отсылка на эти общепринятые верования и предрассудки. Этот культурный феномен можно обнаружить в башкирской народной сказке «Абзелил». В ней при встрече с ен-шайтаном герой также проявляет смекалку и ставит перед лесным чудом ряд условий. Конечно, хитрость срабатывает, и демоническое существо остается ни с чем [10: 28–30]. У Тукая мы читаем:

«…Дух лесной! Давай сначала поработаем вдвоем,
На арбу с тобою вместе мы бревно перенесем.
Щель большую ты заметил на другом конце бревна?
Там держи бревно покрепче, сила вся твоя нужна!..»

…И джигиту не переча, согласился шурале.
Пальцы длинные, прямые положил он в пасть бревна…
…Вот и вылетел со свистом толстый клин, исчез во мгле…
Прищемились и остались в щели пальцы шурале [11: 78].

В другой башкирской народной сказке об Алдаре также повествуется о том, как в лесу герой избавляется от встретившегося шурале сходным образом: обманом прищемляет его длинные пальцы в расщелине бревна. Также, назвав себя именем Былтыр (т.е прошлый год), уходит восвояси. Так егет, следуя народному обычаю, верованиям, обманув и удручив лесного духа, благополучно избавляется от него и отправляется домой.

Таким образом, в поэмах Г. Тукая «Шурале» нашли художественное применение мифические образы, суеверные верования и мифологические воззрения народа. Как и в рассмотренной поэме, так и в «Водяной ведьме» они представляются не в первозданном виде, а как явления культурной антропологии в их новом прочтении. Демонологические персонажи пережили культурное наслоение, но узнаваемы по сохранившемуся характерному облику и выполняют в произведениях идейно-художественные функции согласно фольклорным традициям. В этом отношении огромное значение имеет его трепетное отношение к народным песням, любовь к которым он впитал молоком матери. Современным ученым фольклористам сегодня нужно брать пример с поэта татарской классики в бережном обращении с образцами устного народного поэтического творчества с тем, чтобы их сохранить будущим потомкам.

Общность историко-культурного наследия и тесная вазимосвязь татар и башкир отразилась в общих мифо-фольклорные традициях, в способах интерпретации и функционирования в культурной жизни общества.

ЛИТЕРАТУРА


1. Кунафин Г.С. Культура Башкортостана и башкирская литература XIX – начала XX века. – Уфа: Китап, 2006. – 280 с.

2. Миннуллин К.М. Поэзия и песенное творчество. – Казань: Магариф, 1998. – 287 с. (на тат. яз.)

3. Миннуллин К.М. Песня сквозь года. – Казань: Магариф, 2003. – 400 с. (на тат. яз.).

4. Тукай Г. Произведения / подг. текст. Р. Гайнанова и Л. Гайнановой. –Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. Т.4: Проза, публицистика (1907–1913). – 400 б. (на тат. яз.)

5. Витевский В.Н. И.И. Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 года». – Т. 1. – Казань, 1889. – 176 с.

6. Рапорт генерал-лейтенанта А. И. Румянцева от 20 июля 1736 г. // РГАДА. Ф. 248. Кн. 11131. Л. 737–738.

7. Башкирское народное творчество: Песни / сост., авт. вст. сл., коммент. С.А. Галина. – Уфа: Башк. кн. изд-во, 1974. Кн. 1. – 386 с. (на баш. яз.).

8. Башкирское народное творчество: Эпос / сост. А.М. Сулейманов; авт. вступ. сл. М.М. Сагитов. – Уфа: Китап, 1998. – Т. 3. – 448 с. (на баш. яз.).

9. Башкирское народное творчество: Обрядовый фольклор / сост., авт. предислов. ком. А.М. Сулейманова, Р.А. Султангареевой. – Уфа: Китап, 1995. – 557 с. (на баш. яз.).

10. Башкирское народное творчество: Шуточные сказки и кулямасы / сост. А.М. Сулейманов; вступ. статья Л.Г. Барага и А.М. Сулейманова. – Уфа: Башк. кн. изд-во, 1992. – 464 с. (на баш. яз.).

11. Тукай Г. Стихи. Поэмы. Сказки: Избранные / сост. М. Садри; пер. с татар. яз. на рус. яз. С. Липкина. – Казань, 1969. – 420 с.

УДК 821.512.145

# Г. ТУКАЙ – ПОЭТ ТАТАРСКОГО НАРОДА

***Г.Х. Шамсеева***
*Казанский юридический институт МВД России (Казань)*

В статье описано, что творчество поэта во многом повлияло на становление татарского литературного языка. Подчеркнута роль татарского языка и татарского народа в творчестве Габдуллы Тукая. Осиротевшее детство, без сомнения, оказало влияние на становление тукая как поэта и гражданина. Тукай – гордость татарского народа.
**Ключевые слова:** творчество Тукая, осиротевшее детство, родной язык, поэзия, татарский литературный язык, многогранное творчество.

The article describes that the poet's work largely influenced the formation of the Tatar literary language. The role of the Tatar language and the Tatar people in the poet's work is emphasized. The orphaned childhood undoubtedly influenced the formation of the personality of the poet and citizen. Tukay is a multifaceted master of words.
**Key words:** creativity of Tukay, orphaned childhood, native language, poetry, Tatar literary language, multifaceted creativity.

Как известно, каждый язык – это уникальный ключ к сокровищнице духовного и культурного наследия народа. Татарский язык не является исключением. Бережно сохранив и впитав в себя богатство минувших дней, приумножив и обогатив его, он остается уникальным материалом для исследования. На протяжении всей своей истории, изменяясь, и совершенствуясь, он прошел непростой путь вместе с татарским народом, служа ему верой и правдой. Он, словно звенящий ручей, не раз пытался вырваться сквозь оковы на волю, даже тогда, когда его мощь насильно пытались приглушить.

Я считаю, что у татарского языка и татарского поэта Габдуллы Тукая много общего. Тукай – это очень символичный образ, образ дитя, который рано осиротел, и испытал все тяготы лишений, к великому сожалению, был мало любим, и многим не нужен, а потому очень остро чувствовал любую несправедливость и ложь, неискренность и фальшь, но, тем не менее, не перестающий ценить и благодарить за любовь и доброту.

Видный и достойный сын своего народа, его несомненная гордость Габдулла Тукай (1886–1913) – не просто поэт, он воспеватель татарского языка и народа, его души и чести, борющийся за свободу и разумные перемены, разоблачая пороки и безнравствие пережитков прошлого, и оголяющий перед своим читателем свою израненную временами душу.

Рано оставшись сиротой и потеряв родителей, он переходил от одних воспитателей к другим, от одной приемной семьи к другой, переезжая из одного дома в другой, бережно храня в маленьком сердечке, словно сотканные из сотни маленьких «кружев» воспоминания о детстве….воспоминания, некоторые из которых он бы, наверняка, предпочел бы забыть… Об этом детстве невозможно читать без слез и глубокой нежности … Детство… Оно бывает разным… Тукай, вне всяких сомнений, был сыном своего народа, его вырастил образ народа, в лице самых простых людей: добрых и сердечных, злых и скупых, великодушных и щедрых. Первые услышанные сказки, басни, предания, мифы и легенды татарского народа легли на благодатную почву, по истечении небольшого количества времени Тукай отдаст

все сполна. Как мы знаем из произведений поэта, чувство благодарности к его людям никогда не покидало его.

«...Чувства выше нет на свете, чем любовь к тебе, народ…»

Но особую, ни с чем несравнимую любовь поэта являет собой язык, татарский язык, родной язык, язык матери, такой многогранный и богатый, временами певучий и могучий, порой острый и безжалостный, как острие кинжала и нежный как песня матери у колыбели младенца:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Язык – это душа народа, его сердце, его радость и печаль, надежды и тревоги, мечты и радости, молитвы и проклятья… Все в нем… Как видно, поэт избрал форму непринуждённого, доверительного монолога, в ходе которого делится своими размышлениями с читателем, повествуя о том, как велик и могуч родной язык. Воспевая и поя оду языку, его богатству, и звучанию, Тукай делится с нами сокровенными мыслями, приподнимает завесу и впуская нас в святая святых – к себе в душу. А душа у него – чистая, искренняя, готовая делится с нами, с читателями живущими уже теперь в XXI веке, тем небольшим опытом прожитого, мыслями, переживаниями и советами. Так, в произведении «Совет» («Киңәш»), которое было написано в 1908 году, автор дает нам понять, что он одинок, ему не с кем поделиться сокровенным, он предостерегает нас от опрометчивых откровений, о которых мы, читатели, и по-разумению автора, близкие друзья, впоследствии можем пожалеть:

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.
Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.
Ачып яшьрен хәзинәңне йөрәктән,
Сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән.

Искренность, душевность, легкость, простота, гармоничное переплетение слов в стихотворные строфы делают произведения Габдуллы Тукая уникальными и неповторимыми. Следует отметить, что поэтический стиль поэта сформировывался вместе со становлением нового татарского литературного языка. Будучи одним из основоположников зарождения национальной татарской поэзии, которая в начале прошлого века укреплялась на собственной национальной почве, Тукай высоко прославлял идеи народности, гражданственности и реализма.

Габдулла Тукай, словно бриллиант на небосклоне татарской поэзии ярок и многогранен: он – мастер лирического психологизма, тонко чувствующий все вокруг себя; просветитель и борец за свободу; воспеватель народного фольклора; художник слова, открывающий новые перспективы перед национальной татарской литературой. Без сомнения, в его многогранном поэтическом наследии содержатся непреходящие художественно-эстетические ценности. За свой огромный исторический вклад в развитие всей тюркоязычной литературы и за прогрессивные передовые идеи он считается народным поэтом. Его величайшая заслуга в том, что он смог осуществить переоценку истории и культуры татарского народа, что, несомненно, явля-

ется великим достижением для мастера и гражданина, которому удалось это благодаря уважительному отношению к своему народу и языку и искренним интересом русской литературой, которая во многом ему была интересна.

Тукай жив и сегодня, его поэмы, герои и лирические персонажи всегла на злобу дня, потому как не теряют своей актуальности его мотивы. Они переведены на многие языки народов мира, воспоминания и очерки, вечера памяти имеют место быть. Тукай – навечно молодой, а 26 апреля – навсегда его день…


ЛИТЕРАТУРА

1. Айди Т. Общие ценности (на татарском языке) // Казан утлары (Огни Казани). – 1993. – № 12. – С. 160–161.

2. Желтяков А. Печать в общественно-политической и культурной жизни Турции. – М., 1972.

3. Ганиева Р.К. Духовное наследие поэта (Из материалов, подготовленных для энциклопедического словаря-справочника) «Габдулла Тукай». – Казань: ТаРИХ, 2002. – 112 с.

4. Мустафин Р. «Хазрат Пушкин и Лермонтов, Тукай – три звёзды...» (на татарском языке) // Татарстан. – 2006. – № 4. – С. 32.

5. Сабирзянов Н.Н. Творчество Габдуллы Тукая в контексте литературы тюркских народов / Н.Н. Сабирзянов, Г.Ф. Мамина // Современная филология: материалы I Междунар. науч. конф. (г. Уфа, апрель 2011 г.). – Уфа: Лето, 2011. – С. 119–123 // URL: https://moluch.ru/conf/phil/archive/23/653/ (дата обращения: 27.03.2021).



УДК 811. 371


## ЯЗЫКОВЫЕ ОСОБЕННОСТИ ТРУДА «НАРОДНАЯ ЛИТЕРАТУРА» («ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ») Г. ТУКАЯ


***М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина***

*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*



В статье проводится языковой анализ теста «Народной литературы» татарского поэта Габдуллы Тукая. В ней обращается внимание на словарный состав труда с точки зрения происхождения, сферы употребления. Также изучается структура предложений, употребление автором фразеологизмов, пословиц и поговорок.


**Ключевые слова:** Тукай, языковые особенности, народные песни, татарский язык.



The article presents a language analysis of the test of «Folk Literature» by the Tatar poet Gabdulla Tukai. It draws attention to the vocabulary of the work in terms of origin, scope of use. The author also studies the structure of sentences, the use of phraseological units, proverbs and sayings by the author.


**Key words:** Tukai, language features, folk songs, Tatar language.


## Г. ТУКАЙНЫҢ «ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ» ХЕЗМӘТЕНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*


Татар халкының күренекле шәхесе, бөек шагыйре Габдулла Тукайның иҗаты бүгенге көндә киңкырлы өйрәнелгән булуга да карамастан, әлеге бай иҗат тел һәм әдәбият белгечләренең игътибарын әле дә үзенә җәлеп итә. Г. Тукай шагыйрь булудан тыш халык авыз иҗаты әсәрләрен яхшы белгән, халык иҗатын җыйган һәм аны пропагандалаган, хезмәтләрендә аларны еш

кулланган белгеч тә. Г. Тукайны татар халык иҗатының теоретик нигезләрен билгеләүчеләрнең берсе дип атау да ялгыш булмас.

1910 елның 15 нче апрелендә Казанда «Шәрыкъ клубы»нда Г. Тукай «Халык әдәбияты» дигән темага лекция укый. Шушы елны «Халык әдәбияты» аерым китап булып басылып та чыга.

Әлеге хезмәттә кечкенәдән җырларга яраткан, хисле, моңлы шагыйрьнең күңелендә йөрткән халык җырлары, аларның тарихы, халык әдәбияты турындагы фикерләре урын алган. «Халык әдәбияты»нда шагыйрь үзе белгән «Тәфкилев» көе, «Ашказар» көе, «Сак-Сок» көе, «Касимский Ибырай», «Җизнәкәй», «Башмак» көе кебек халык җырларының тарихларына тукталa.

Г. Тукай халык әдәбияты төшенчәсенә үзенчә билгеләмә бирә: «Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер» [1: 189].

Г. Тукай халык җырларына да билгеләмә бирә: «Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр» [1: 192]. Г. Тукай халык җыры нинди булырга тиешлеген дә ачыклый: күңелгә хуш килергә тиеш; аның үз көе, үз үлчәве, ритмы була; аны салкын кан белән тыңлап булмый, ул дулкынландыра, хисләндерә; халык җырларында хис, мәгънә була; халык җырларын тыңлаганда, аркаларга кан йөгерергә тиеш; халык җырларының беренче ике юлында юк кына сүзләр әйтелә, аннары соңгы икесендә мәгънәле, күтеп алынган сүз кулланыла; халык җырлары җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле булганга, аларга әһәмият бирергә, аларны югалтмаска кирәк; халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгеседер [1: 192].

Шагыйрь фикеренчә халык җырлары аша халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын күреп була [1: 194]; «халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр» [1: 195].

Әлеге хезмәт гади, аңлаешлы телдә язылган, аңа кыскалык һәм фикерне төгәл итеп әйтү хас. Автор мәкаль-әйтемнәргә еш мөрәҗәгать итә: уеннан уймак чыгара; җырның җыртыгы юк; эт симерсә, иясен тешләр; керпе үз баласын йомшагым һәм аю үз баласын аппагым дип әйтә, ди һ.б. Текстта фразеологик әйтелмәләр дә еш очрый: колаклар тору, салкын кан белән тыңлау, аркаларга кан йөгерү һ.б.

Җөмлә төзелешенә килгәндә, автор кушма җөмләләрне һәм аерымланган рәвеш хәлле гади җөмләләрне күп куллана: Кызлар төрлечә көйләр чыгарып карыйлар, ләкин берсе дә түрә кызының күңеленә ошамыйлар [1: 188]; Бу җырчы кызлардан бернәрсә дә чыкмагач, түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашказар» көен җырлап җибәрә [1: 188] һ.б.

«Халык әдәбияты» хезмәтенең төп лексикасын төрки-татар сүзләре тәшкил итә. Алынма сүзләр дә юк түгел. Башка телләрдән кергән сүзләр арасында гарәп сүзләре (халык, әүвәл, мәсьәлә, вакыт, хәтер, *кыйсьме – өлеше, мәзмун – конспект* һ.б.), рус сүзләре (сумала, келәт, гәзитә, мужик, гармун, остроумие һ.б.), фарсы сүзләре (өмет, хуш, һәм, дустанә, палас һ.б.), шулай ук латин (оригиналь, форма), грек (оркестр), француз (пьеса), итальян (мандолина) сүзләре бар.

Г. Тукай архаиклашкан кушымчаларны актив куллана: җырларымыз – җырларыбыз, үземезнеке – үзебезнеке, укыдыгым – укыдым һ.б.

1) **...җырларымызның** барчасын укып чыгарга тугъры килмәде. 2) Безнең **җырланмакта** булган **көйләремезнең** һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да, мәгаттәэссеф, аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал булмады. 3) Әмма менә бу кыйммәтле мирас **дидекемез** халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады.

Шулай ук текстта бүгенге көндә искергән дип саналган сүзләргә дә мисаллар табып була: вә, тугърыда, өмид, соңра, гакыл һ.б.

1) Җырларымыз **вә** көйләремез тарихын... тикшерергә берзаман махсус хезмәт куярмын да, **шаять**, халыкка шул **тугърыда** әсаслырак мәгълүмат бирермен дигән **өмидем** бар иде. 2) Авыл халкы, бу усал Шүрәлене ни рәвешчә, ничек итеп үтерү **тугърысында** күп киңәштән **соңра**, аны базга салып, өстенә керосин сибеп яндырып үтерергә карар бирәләр һәм шулай эшлиләр. 3) Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң **бәһале** бер мирастыр.

«Менә бу кеби хикәяләр халык хикәяте, халык әдәбияты дип аталалар» җөмләсендә бу алмашлыгының кеби (кебек) бәйлеге белән дөрес формада кулланылмавы, «тутасычөн кайгырмыймыз» дигәндә өчен бәйлегенең алдагы сүз белән кушылып язылуы игътибарны җәлеп итә.

Сүз уртасына ң, г хәрефен өстәү очрый: уңгайлап – уңайлап, яңлыш – ялгыш һ.б.

Текстта диалекталь сүзләр дә бар: аты **шапырма** тиргә баткан (шабыр тиргә бату), дөньяда язу сәнгате булмаган **чактук** (чакта ук), **җыру** (җыр), бер кадак **симәнкә** (көнбагыш) һ.б.

1) Иртә берлән, эшкә җигәргә дип атны алырга барса, ни күзе белән күрсен: атын **шапырма** тиргә баткан, төн буе әллә ничә йөз чакрымнарны бер дә туктамастан чапкан кеби, тәмам хәлдән тайган көе таба. 2) **Җырулар** вә көйләремез тугърысында тарихи вә әсаслы мәгълүмат бирә алмыйм. 3) **Җөрмә** монда, кайт иленә, илеңдә иген игәрсең.

Г. Тукай фикеренчә, җыр халык рухынча язылырга тиеш. Автор «рух» сүзен еш куллана: рух вә илһам [1: 188], рухлану [1: 188], халык халәте рухиясе [1: 192] һ.б. Чын халык рухын бары тик халык җырында гына табып була, ди ул. Шагыйрь һәр халыкның үз моңы, үз көе булуын да ассызыклый: «...һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә» [1: 195]. «Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела», – ди Г. Тукай [1: 202]. Шагыйрь халык җырын рус теленә тәрҗемә итеп тә күрсәтә:

Калфагым бар, шәлем юк,
Шәл алдырмый хәлем юк;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Сине алмый хәлем юк.

У меня колпак есть, но нет шали,
Необходимо мне купить шаль.
По мне нет любимой, кроме тебя,
Необходимо мне жениться на тебе [1: 195].

Әлеге тәрҗемә белән автор билгеле бер халыкның җырын башка телгә тәрҗемә иткәндә, аның мәгънәсен тулысынча ачып булмауны, һәр сүзнең

билгеле бер функция башкаруын ассызыклый. Тәрҗемәдә телнең бөтен нечкәлекләрен биреп бетереп булмый, ул коры, кытыршы чыга [2: 189].

Димәк, Г. Тукайның «Халык әдәбияты» хезмәте бай, фәнни, шул ук вакытта халыкчан булуы белән аерылып тора. Шагыйрьнең «җыр яратуым аркасында туган телгә сөю туды» дигән фикерләре белән бик килешәсе килә. Дөрестән дә, халык телен, халык рухын, халык моңын җырда табып була шул.

ӘДӘБИЯТ


1. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. 2 т.: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз.: Н. Хисамов, З. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 383 б.

2. Шакурова М.М. Халык җырлары турында Г. Тукайның карашлары // Развитие научно-методической мысли: достижения, проблемы, перспективы: Сборник материалов II Республиканской научно-методической конференции (07 апреля 2014 г.). – Казань: Отечество, 2014. – С. 188–190.


УДК 821.512.145

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ И ПОЭТ СИРИН


***А.М. Шарипов***

*Набережночелнинский государственный педагогический университет (Набережные Челны)*



В статье рассматривается вопрос влияния творчества Габдуллы Тукая на творчество татарского поэта Сирина Батыршина (псевдоним – Сирин). Произведения Тукая с юношеских лет притягивают к себе молодого поэта Сирина (1896–1969). В 1935–1940-х годах Сирин был репрессирован. Любовь к творчеству Тукая сопровождают его в течение всего творческого пути. Через творчество Тукая Сирин приобщается к классической восточной поэзии, осваивает ее классические жанры.


**Ключевые слова:** поэт, творчество, образ, общество, влияние, жанры.



The article examines the influence of the work of Gabdulla Tukai on the work of the Tatar poet Sirin Batyrshin (pseudonym – Sirin). Since his youth, Tukay's works have attracted the young poet Sirin (1896–1969). In the 1935–1940s, Sirin was repressed. Love for Tukay's creativity accompanies him throughout his entire creative path. Through the work of Tukay, Sirin joins classical oriental poetry, masters its classical genres.


**Key words:** poet, creativity, image, society, influence, genres.


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ СИРИН


***Ә.М. Шәрипов***

*Яр Чаллы Дәүләт педагогика университеты (Яр Чаллы)*


Габдулла Тукай иҗаты әле ул үзе исән чакта ук киң популярлык ала, әсәрләре татарлар яшәгән барлык төбәкләргә тарала. Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы Ютазы төбәгенең Кәрәкәшле авылында дөньяга килгән Сирин дә, балачагында ук Тукай турында ишетеп, аның әсәрләрен укып үсә. Шул вакыттан алып Тукай образы, Тукай иҗаты Сиринне бөтен тормыш юлы буена озата бара. Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган чакта (1910–1914 еллар) ул үзенең беренче иҗади тәҗрибәләрен ясый. Шунда ук, Тукай әсәрләреннән өйрәнеп, классик шигъриятнең газәл, касыйдә, мәснәви кебек жанрларын үзләштерә. Ә бераз соңрак, Бөгелмәдәге укытучылар һәм тәрбиячеләр әзерли торган семинариядә укыган чакта (1918–1921 еллар), Сирин, Тукай иҗатыннан үрнәк алып, үзенең берничә шигырен ул иҗат иткән те-

маларга багышлый. Сириннең 1920–1930 еллардагы әсәрләре белән Тукай әсәрләре арасында типологик параллельләр үткәрергә мөмкин.

Шуңа игътибар итик: Сирин яшь ягыннан Тукайдан ун яшькә кечерәк, ул 1896 елда туган. Тукай белән Сириннең тормыш юллары һәм иҗат юнәлешләре арасында беркадәр охшашлык та, зур гына аерма да бар. Охшашлык – алар икесе дә мәдрәсә белеме алганнар, иҗатларында Көнчыгыш классик поэзиясе йогынтысын кичергәннәр (Сирин ул йогынтыны беренче чиратта Тукай әсәрләре аша алган). Аерма шунда – алар икесе ике төрле җәмгыятьтә яшиләр, икесе ике төрле идеология вәкиле: Тукайның бөтен гомере 1917 елгы революциягә кадәрге капиталистик җәмгыятьтә уза; ә Сирин, гомеренең 21 елын революциягә кадәр яшәгән булса да, бөтенләй башка идеология йогынтысында тәрбияләнгән кеше, ул – совет чоры шагыйре. Сирин баштарак, бөтен күңеле белән, революциядән соң яңа, гаделсезлекләр булмаган, бәхетле тормыш төзибез дип шулкадәр тирән ышана ки, үзенең әсәрләрендә еш кына патша чорын – ач-ялангачлар тормышы, ә совет чорын бәхетле, якты тормыш итеп сурәтли. Шушы караш Сириннең Тукайга ияреп яки Тукай әсәрләренә җавап рәвешендә язган шигырьләрендә дә ачык чагыла.

Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» (1909) белән Сириннең гражданнар сугышы чорында иҗат ителгән «Авыл кызына» (1920) әсәре арасында ук охшашлыклар бар: ике әсәр дә яшь татар кызының елавына багышланган; икесендә дә «мәюсь», «залим», «күңел» кебек уртак сүзләр кулланыла. Әмма Тукайда «залим» булып татар бае саналса, Сириндә «залим» дип иске тормыш күз алдында тотыла. Тукайда татар кызының чарасызлыгы сурәтләнә, ә Сирин исә гражданнар сугышына киткән егетен сагынып елаучы кызны: *«Күп тә үтмәс, менә кайтып җитәр / Җан сөеклең көләч йөз белән»; «Менә киләчәгең нинди матур, / Рәхәтләнеп гомер итәрсең»*, – дип юата. Аны киләчәкнең якты булачагына өметләндерә.

«Диңгезгә» дигән шигырен (1920) дә Сирин Тукайның «Даһигә» (1913) әсәренә нигезләнеп иҗат иткән. Ике әсәр дә идеал темасына багышланган, икесе дә мәснәви формасында язылган. Бу әсәрләрнең иҗат ителүләре арасында нибары 7 ел вакыт үткән. Тукай үз әсәрендә милли азатлык хәрәкәте турында уйлана һәм газиз халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән даһи образын иҗат итә. Тукай яшәгән җәмгыятьтә, алда ялтыраган нәрсә ут түгел, ә алтын (ягъни байлык) икән һәм ул «нәрсәдә» нур да, күңел өчен җылылык та юк икән; җәмгыятьнең нигезендә алтынга табыну, байлыкка омтылу ята икән.

*Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул – алтын ул;*
*Юк мөкатдәс нур да анда, юк җылылык – салкын ул*, –

ди Тукай. Һәм Тукай әлеге даһины үзе бара торган юлдан тайпылмаска, үз идеалына барганда туктап калмаска чакыра:

*Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;*
*Алга барганнарга тик табла табылса – Алла ул.*

Сириннең «Диңгезгә» шигырендә исә идеал булып яңа тормыш өчен көрәштә бернәрсә алдында да туктап калмый торган, диңгез дулкын-упкыннарына да буйсынмас, көчле, ашкын, бунтарь образы калкып чыга. Сириннең лирик образы, диңгезгә эндәшеп, болай ди:

*Нинди дулкыннарга атсаң да, барыбер батмамын!*
*Һәм үлеп, суың төбендә дә череп ятмамын!*

*Миндә көч, гайрәт вә дәрт бар, күкрәгемдә ут яна,*
*Мин күрәмен алда – анда ялтыраган ут, әнә!*
*Ул шулай күзгә күренә, ут түгел, юк, нур бит ул!*
*Пакь вә саф, ап-ак күңелле бер фәрештә нур бит ул!*
*Тарта яшь, дәртле күңелне үз янына, алга ул,*
*Киң колачлап мин йөзәм, шунда минемчөн Алла ул!*

Димәк, алда күренгән нәрсә ул нур икән; ул күңелне үзенә тартып, кызыктырып тора; ә бу нур, – Сирин фикеренчә, совет җәмгыятенең якты киләчәге.

Шунысы кызыклы: Тукайның «Булмаса» газәленә (1908) ияреп, Сирин дә «Булмаса» дигән шигыр (1920) язган (әмма газәл формасын сайламаган, ә ирекле рифмалар кулланган). Ике шигырь дә 15+15 үлчәме белән иҗат ителгән. Тукай үз әсәрендә шагыйрь күңелен дәртләндереп торучы былбылга (гүзәл затка, гүзәллек шаһына) мәдхия җырлый:

*Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?*
*Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл булмаса?*
*...Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;*
*Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса.*

Ә Сирин үз шигырен иҗтимагый темага багышлый: «коммунист» исемен йөрткән кешенең совет җәмгыятендә зур дәрәҗәсе, җаваплы вазифасы, «гали фәрештәлеге» барлыгына басым ясала. Анда: «Ярлы халыкка, ач-ялангачларга чын күңелең белән хезмәт итәргә теләгең булмаса, син коммунист булма да», – дигән фикер үткәрелә:

*Булмаса күңелдә халыкка мәхәббәт хисләре, –*
*Булма коммунист, якын килмә бүтән уйлар белән.*
*Янмаса күкрәгеңдә ярлы халыкның уйлары, –*
*Ул гали фәрештәлек, басма аяк-герләр белән.*

Әсәрдә 1920 елларда совет җәмгыятендә махсус күпертелгән сыйнфый көрәш темасы да чагылып ала: коммунист образына кулак образы каршы куела. Шигырь болай тәмамлана:

*Булмаса хезмәт уең ач-ярлыларга, – кит ерак.*
*Мин беләм: син – күп ятимнәр күз яшен түккән кулак.*

Бу инде Сириннең шул чор җәмгыятендә актуаль булган теманы үз иҗатында күтәреп чыгуын, әлеге тема белән уйланып яшәвен күрсәтә.

1923 елда Тукайның үлеменә ун ел тулу уңае белән, Сирин «Безнең яшьләр (Тукайның «Яшьләр»енә ияреп, җавап урынында)» дигән шигырен иҗат итә (шигырь «Татарстан» газетасының 1923 елның 15 апрелендәге якшәмбе санында, беренче биттә бердәнбер шигырь булып басылган). Бу әсәрне шагыйрь, Тукай кебек үк, касыйдә жанрында язган. Тукай әсәре дә, Сириннеке дә классик касыйдә жанрына куела торган барлык таләпләргә дә җавап бирә: икесе дә – аа, ба, ва, га ... тәртибендә рифмалашып килә торган икеюллыклар, ягъни бәетләр белән иҗат ителгән. Хәтта күләмнәре дә бер үк диярлек – Тукайныкы ун бәеттән торса, Сириннеке тугыз бәеттән гыйбарәт. Әмма Тукай белән Сирин шигырьләренең идея юнәлеше монда да төрлечә: әгәр Тукай әсәре 1905 елгы революциядән соңгы кара реакция елларында язылган һәм төшенкелек, киләчәккә өметсезлек мотивлары, яшьләрдә егетлек, кешелек сыйфатларының юклыгына зарлану фикерләре белән сугарылган булса, Сирин шигырендә киресенчә: әсәр революцион романтика,

авторның яңа, якты тормыш төзүгә ныклы ышанычы, барган юлдан һичкайчан тайпылмау, ахырга кадәр җиңеп барырга омтылу кебек хис-тойгылар, ниятләр белән өретелгән.

Тукай шигырендәге өметсезлек мотивларының үз сәбәпләре бар. Аның «Яшьләр» шигыре 1910 елның 15 июлендә «Ялт-йолт» журналында басылып чыга. Бу – кара реакциянең милләтләрнең үсешенә, хөр фикерлелеккә каршы аеруча көчле көрәш алып барган чоры. 1906–1908 елларда чыгып килгән «Милләт», «Азат», «Өлфәт», «Әхбар», «Ватан хадиме», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы», Тукай яратып эшләгән «Әл-ислах» һәм «Яшен» кебек газета-журналлар ябыла. Илдәге вазгыять үзгәрү сәбәпле, яшьләр дә милләтнең үсеше өчен көрәштән читләшә. Мондый хәлләр Тукайда да төшенкелек, киләчәккә өметсезлек тудыра. «Яшьләр» шигырендә Тукайның нәкъ әнә шундый рухи халәте чагыла да. Шигырьнең беренче юлларында ук Тукай болай ди:

*Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,*
*Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.*
*Кичә якты вә милли бер күңелдән*
*Бүген тычкан утыдай нур табылмас.*

Ә Сирин исә, Коммунистлар партиясе идеяләре белән рухланып, үзенең шигырен романтик пафос, Тукай фикерләренә капма-каршы булган фикерләр белән башлап китә:

*Йөрәктә ут кабынган, мәңге сүнмәс,*
*Яна күкрәктә дәртләр, һич суынмас.*
*Көч алдык, калтырау юк юлыбызда,*
*Диябез яшьләр:*
*«Бу күкрәк мәңге туңмас!»*

Шуннан соң Тукай үз чорындагы яшьләрнең вак, көндәлек идеаллар белән рухланып, милләт проблемаларын читкә ташлап, акча-байлыкка табынып яшәүләрен тәнкыйтьли; аларның, тәти уенчык тапкан сабый бала кебек, байлык белән мавыгуларын әйтә:

*Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,*
*Көмеш, алтын санәмнәргә табынмас?*
*Тәти тапса сабый барган юлында,*
*Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.*
*Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,*
*Баюдан башкага күңлен дә салмас.*

Сирин дә Тукайның фикер сөреше артыннан бара, әмма Тукай чорындагы яшьләрдән аермалы буларак, «яңа яшьләрнең», алтын-көмешләргә табынмыйча, халыкка хезмәт итүләрен, искелекләрне җимереп, яңа тормыш төзүләрен, шул алган юлларыннан читкә тайпылмаячакларын белдерә:

*Күңелдә кайный хезмәтләр халыкка,*
*Чын ир алтын-көмешләргә табынмас.*
*Җимердек искелекләрнең барын да,*
*Аларга инде артык кайту булмас.*
*Ышандык без кызыл көчкә, юл алдык,*
*Турайдык сафка, нык юл, һич таелмас.*

Тукайны хәтта кайбер язучы-шагыйрьләрнең дә, байлыкка алданып, акча эшләү юлына кереп китүләре борчый. Шигырен ул болай дәвам итә:

*Сатучылык итә бездә мөхәррир,*
*Әдип исме аңар таглыр-тагылмас.*

Ул үз чорындагы яшьләр күңеленә егетлек, олпатлык, кешелеклелек сыйфатлары салынмаганлыкка зарлана, яшьләрнең үзләренең тарихтагы шанлы-данлы, фидакяр бабалары эшчәнлекләренә лаек булган эш-хезмәтләр майтара алмаганлыкларына, көчсез булуларына әрни:

*Яралганмы бу яшьләр күңле әллә*
*Мөрәүвәт маддәсе яглыр-ягылмас?*
*Ышанабыз халык көчсезлегенә,*
*Бабайлар шөһрәтен сагныр-сагынмас.*

Ә Сирин Тукайга «яңа яшьләр» – һәрберсенең күңеленә иман нуры тулган, ярлы илне бәхетле итү өчен көн-төн эшли торган яшьләр образын күтәреп куя:

*Иман күкрәктә һәммәбездә тулган,*
*Табылмас, безгә көчсезләр тагылмас.*
*Көрәштә без ныгыйбыз көн дә, көн дә,*
*Эшлибез ярлы ил бәхте юлында,*
*Кылыч, балта, чүкеч кулдан салынмас.*

Күренә ки, Сирин монда өчьюллыкны файдалана, шуның исәбенә бер икеюллыкны кыскартып, шигырьне бары тугыз бәеттән генә төзи.

Тукай үзенең шигырен «Милләт байрагын тотып юлга чыксак та, ерак китә алмадык, егылдык» дигән фикер белән тәмамлый:

*Тотып милләт ливасын, юлга чыктык,*
*«Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас».*
*Җыгылдык без, ике-өч чакрым да китми, –*
*Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры, булмас!*

Тукайга җавабында Сирин, үзләренең милләт байрагы түгел, ә интернациональ эчтәлектәге кызыл байрак тотып юлга чыгуларын һәм үзләренең соң-ахыргача барырга ният кылуларын каршы куя. Яшьләрнең нык, көчле икәнлекләрен күрсәтү өчен, кулларын «Тимер куллар» дип атый:

*Яңа дөнья төзибез, һәркем эшләр,*
*Тимер кулларга шәйтаннар сарылмас.*
*Кызыл байрак тотып без юлга чыктык,*
*Барырбыз соңгача, һичкем абынмас.*

«Безнең яшьләр» шигыре, әлбәттә, Сириннең чын күңелдән яңа, гадел җәмгыять төзибез дип ышанып яшәгән чагын, ягъни аның әле иҗатының башлангыч чорын характерлый. Бу әсәрне көч-энергиясе ташып торган 27 яшьлек Сириннең 24 яшьлек Тукай белән бәхәсе-әңгәмәсе дип тә кабул итәргә мөмкин.

Ә бер мәсьәләдә Сирин үзенең остазы Тукай белән фикердәш була. Ул – шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны, роле мәсьәләсе. Сирин бу теманы совет шагыйрьләреннән беренче булып күтәреп чыга. «Йөрәк каны белән» шигырендә Сирин үзенең поэтик иҗатын болай сурәтли:

*Бу – минем*
*уйларым.*
*Бу – ритм.*
*Бу – минем*
*йөрәгем тибүе.*

*Бу – минем*
*канымның*
*тәнемнән*
*Җыр булып*
*кәгазьгә*
*күчүе.*

Төзелеп килә торган җәмгыятьтә шагыйрьнең миссиясен ачыграк күзаллау өчен, ул үз-үзенә шундый сорау бирә: *«Ни өчен, ни өчен мин болай / Ак кәгазь өстендә кан коям? / Каләмнән тамдырып канымны / Үземне вакытсыз ник суям?»* Шушы сорауга бәйләп, ул үзенең төп фикерен әйтә: шагыйрьнең тормыштагы вазифасы авторның шәхси мәнфәгате, эгоистлыгы, дан-шөһрәткә омтылуына бәйле түгел. *«Шөһрәт кирәкме? – Кирәкми / Мин үлгәч, шөһрәт нәрсәгә?»* – ди. Сирин үз алдына куйган сорауга үзе үк: «*Киләчәк тормышны күрәсе һәм шунда яшисе килә», –* дип җавап бирә. Ә киләчәк тормышны ул матур итеп күзаллый: «*Киләчәк елларның тормышы / Уемда бик матур корылган. /Шул елларның нигез ташына / Безнең еллар өеп куелган».* Әмма ул матур киләчәкне кул кушырып утырып кына яки елмаеп, эшләр-эшләмәс йөреп кенә якынайтып булмый. Шагыйрь кәеф-сафа корып, бизәнеп, үз-үзеңә сокланып кына, эшсез утыруга каршы чыга: «*Ни булыр иде соң / мин, Сирин, / Гөлсирин булып, гел бизәнсәм? / Яз саен яшәреп, / Таң саен зәп-зәңгәр чәчкәдә утырсам?»* – ди ул. Һәм Сирин, якты киләчәкне тизрәк җиткерү өчен, үзенең шигърияте, ялкынлы сүзе белән көрәшәчәген, хәтта шушы юлда үзен корбан итәргә дә әзер торуын белдерә:

*Юк,*
*каным жәл түгел,*
*коелсын чәчкәм дә,*
*Каләмнән тамдырып*
*канымны,*
*кәгазьгә чәчәм дә,*
*Җыр итеп*
*тезәм мин.*
*Беләм мин:*
*корбансыз*
*җиңү юк,*
*Авырлык күрмичә,*
*рәхәтләр күрү юк.*

Күренә ки, Сирин шагыйрьнең тормыштагы миссиясен поэтик югарылыкка күтәреп тасвирлый: үзен шагыйрь дип исәпләгән иҗат кешесенең бары тик янып, халыкның кайгы-шатлыкларын үз йөрәге аша үткәреп кенә, «йөрәк каны белән» генә язарга тиешлеген белдерә. Тукай да шундый ук карашта. Ул да, билгеле булганча, шагыйрьлек вазифасын бик югары бәяләде: ул үзенең иҗатын шәхси мәнфәгатенә түгел, ә халыкка хезмәт итүгә багышларга тиеш. «Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга түзмәккә!» дигән чакыру ташлады. Ул, үз чорының вазгыятеннән чыгып, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси ролен «йоклаган» татар халкын уятуда, тергезү-терелтүдә күрде. Тукай бу мәсьәләдә үз чиратында рус классиклары А.С. Пушкин белән М.Ю. Лермонтовка таянды, алардан үрнәк алды. «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам / Әкренәкрен югарыга үрләп барам», – дип язды ул үзенең «Бер татар шагыйренең

сүзләре» шигырендә (1907). Монда шундый типологик параллельлек үткәреп була: 1826 елда – Пушкин, 1841 елда – Лермонтов «Пәйгамбәр» («Пророк») дигән әсәр яза һәм шагыйрьнең җәмгыятьтәге миссиясен пәйгамбәрлек миссиясе дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлый. Тукай да «Пәйгамбәр (Лермонтовтан үзгәртелгән)» (1909) шигырендә шагыйрьнең миссиясен пәйгамбәр миссиясе югарылыгында күрә һәм Сирин әсәрендәге фикергә охшаш фикер әйтә – шагыйрь үз халкы өчен армый-талмый хезмәт итәргә тиеш: «Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә / Ашамый-эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә»; шагыйрь рухани ут белән янарга тиеш: «Янып рухани ут берлә, ашыккан хәлдә юл тотсам», – ди шул ук «Пәйгамбәр»шигырендә Тукай. Рус галиме И.Г. Пехтелев язуынча, Тукайның бу фикерләре үзенең остазлары Пушкин һәм Лермонтов фикерләренә аваздаш [2: 105–111]. Шулай итеп, Сирин фикерләре Тукай фикеренә дә, Пушкин һәм Лермонтов фикерләренә дә аваздаш булып чыга. Бер үк фикердәге Пушкин – Лермонтов – Тукай – Сирин дигән чылбыр барлыкка килә һәм Сирин бу чылбырда ахыргы бербуын ролен үти. Гомумән, Сириннең «Йөрәк каны белән» әсәре 1920–1930 елларда гына түгел, ә бөтен XX гасыр татар поэзиясендә гражданлык лирикасының иң матур үрнәкләренең берсе булып санала ала. Әдәбият һәм сәнгатьнең җәмгыятьтәге урыны, иҗади хезмәт темалары Сириннең аннан соң иҗат иткән «Гейне фикере» (1929), «Тормыш юлына басып» (1933), «Җиңел эшләр» (1933), «Гадәт» (1958), «Минем гаскәрем» (1960) кебек әсәрләрендә дә чагылыш тапты.

Сириннең Коммунистлар партиясе идеяләренә ихлас күңелдән бирелгәнлеге, совет системасының кешеләргә яхшы, матур тормыш бирәчәгенә ышанычы бөтен гомере буена бармый. 1930–1933 елларда ул инде совет җәмгыятендә дә гаделсезлекләрнең күп булуына төшенә, алар белән килешә алмый, аларны аяусыз тәнкыйтьли, сатира утына ала башлый. Аның 1930–1935 еллардагы иҗаты тулаем диярлек совет җәмгыятендәге икейөзлелекне, астыртынлыкны, тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүгә багышлана. Нәтиҗәдә, Сирин, кулга алынып, биш ел буе рәхимсез, кеше ышанмаслык кыргый тәртипләр хөкем сөргән Сиблаг лагерьларында җәфа чигәргә мәҗбүр була (искиткеч ачлык хөкем сөргән лагерьда ул могҗиза белән генә исән кала). Әмма сөргеннән кайткач та ул җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүдән туктамаган: сөргеннән соң иҗат иткән 90 шигырь арасында тәнкыйди мотивларны күтәргән әсәрләр дә очрый (мәсәлән, «Кыскартуга эләккәннәр» [1: 17]).

1930 елларда Сирин җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне тәнкыйть итү өчен төрле алым-формалар кулланган: мәсәл жанры, хат формасы, телеграмма формасы һ.б. Шулар арасында аның «Тукаевтан Сирингә телеграмма» дигән шигыре дә бар (1933 ел). Сирингә мөрәҗәгать итеп, Тукай болай ди:

*«Син үзең ничек яшисең,*
*Бармы соң ашарыңа?*
*Бармы соң эшләү шартың,*
*Квартирың язарыңа?*
*Сез инде яңа тормышта, –*
*Без күргәнне күрергә*
*Туры килмәс, идән себреп,*
*Шигырь язып йөрергә.*
*Дөньяда ничек яшиләр? –*
*Белгәнем юк бик күптән.*

*Барысын ачык, дөрес итеп,*
*Яз әле бер хат, көтәм.*
Тукаев.»

Шулай итеп, Сирин, гомере буена Тукайдан өйрәнеп, үрнәк алып, күңеленнән аның белән сөйләшеп-фикерләшеп иҗат иткән. Бу, әлбәттә, Сирин иҗатына уңай йогынты ясаган.

ӘДӘБИЯТ
1. Мәдәни җомга. – 2021. – № 4 (5 февраль саны).
2. Пехтелев И.Г. Тукай и русская литература. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. – 182 с.

УДК 7.072.2

# ОБРАЗЫ *СУ АНАСЫ* В ДЕКОРАТИВНОМ ИСКУССТВЕ ХУДОЖНИКОВ ТАТАРСТАНА

***Л.М. Шкляева***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассматриваются произведения таких известных художников декоративного искусства Татарстана как: М. и Р. Кильдибековы, А. Фатхутдинов, А. Иванов, Н. Галявиева, Р. Шамсутдинов. Работы объединены темой, т. е. сюжетом сказки Г. Тукая «Су анасы», запечатленные действия происходят на лоне природы. Воплощая Водяную, авторы внесли собственную интерпретацию образа героини, продиктованную их творческой индивидуальностью и особенностями технологий выбранного вида декоративного искусства. Композиции отражают идею произведения в соответствии с замыслом художников, являющихся носителями культурных кодов своего народа, идеалов и реалий современности. Одни из них отдают предпочтение основополагающим сельским традициям, другие выражают высокие эталоны городского мироощущения.
**Ключевые слова:** декоративное искусство, художники Татарстана, Водяная, Габдулла Тукай.

The article deals with the works of famous artists of Tatarstan. Their creativity is united by an interest in the fairy tale of G. Tukai «Su Anasy». The works of decorative art depict a Tatar village, a lake and a Water mermaid. Each artist has drawn his own image of a mythological creature.
**Key words:** decorative art, artists of Tatarstan, Vodyanaya, Gabdulla Tukay.

В литературном наследии Габдуллы Тукая выделяются литературные сказки, основанные на фольклорных источниках. Их сюжеты и персонажи привлекали внимание художников еще при жизни поэта и продолжают служить источником вдохновения по настоящее время. Одним из наиболее популярных образов оказалась Су анасы – Водяная (1908), запечатленная в различных видах художественного творчества.

В нашей статье мы рассматриваем образы Су анасы в декоративном искусстве, с целью проведения сравнительно-сопоставительного анализа, позволяющего раскрыть стилевые особенности, созданных произведений, отличающихся используемыми материалами и технологиями изготовления. Одни художники стремились точно соответствовать описанию, данному поэтом, другие старались передать собственное видение мифического создания. Образы Водяной в современном искусстве характеризуются отсутствием канонических принципов.

Художники Р. Кильдибеков и А. Фатхутдинов, являясь носителями архаичных национальных кодов, воплощали в произведениях мифологические образы Водяной. Ее изначальное возникновение в культуре человечества относится к раннеродовой эпохе, когда повсеместно почитались земля, вода, огонь и ветер [4]. Наиболее древние пласты народного сознания хранят веру во всеобщую одухотворенность природы, т.е. анимизм [5]. Развиваясь, анимистические представления наделяли указанные стихии качествами живых существ, часто очеловечивались. Через столетия эти духи, уже утратившие статус божеств, именовались уважительно отец земли, мать земли, отец воды, мать воды и т.д. [1: 29].

Именно такой образ Водяной оказался близким для художников Марии (1932–2017) и Рустема (1934 г.р.) Кильдибековых, заслуженных деятелей искусств Республики Татарстан [2:34]. Они воплотили «Су анасы» (2010), в технике одностороннего безворсового ткачества, выполнив гобелен ручной работы. По замыслу авторов намеренно создан упрощенный образ «Матери воды», что приблизило их манеру исполнения к примитивному стилю. В центре плоскостной композиции находится светлое и зыбкое, как туман изображение Водяной, расположенное анфас на фоне темно-синей глубины прямоугольника, который воспринимается как условное обозначение ее дома, каким его рисуют дети. Это впечатление усиливается раскинувшейся над ним радугой, покрывающей ее жилище словно крыша. Силуэт Водяной напоминает ромбовидный абрис «палеолитической Венеры» с ярко-выраженными зрелыми женскими признаками. Перед нами плодовитое создание, почитаемое, как источник жизни. Плавные изгибы рук сходны с домоткаными полотенцами, оформленными по краям бахромой. Из щедрых пятипалых кистей струится вода, запечатленная художниками в виде шести симметричных ломаных линий. Оправданно отсутствует изображение гребня. Для матери воды, исполненной неспешного достоинства, ни к чему человеческие забавы. Природное сходство полотна с водной стихией подчеркивается серебристо-синеватыми сочетаниями цвета. За пределами обиталища Водяной господствует асимметрия, как визуальное выражение нестабильности мира. Здесь художники в профиль запечатлели тех, кому «Мать воды» обеспечивает существование. Авторы тщательно проработали все второстепенные образы, находящиеся по обе стороны от главного персонажа. По краям нижней линии расположились рак и рыба, над ними распустились озерные растения. На среднем уровне, по одну руку Водяной изображена корова в ракурсе по вертикали, по другую – сельская татарка в этнической одежде, хозяйка домашних животных. Над их головами запечатлены водяные лилии, выше которых, вровень с радугой плывут навстречу друг другу утки. Мастера сознательно нарушили пропорции обитателей реального мира – они все одинаково мелкие по сравнению с мифическим обликом Су анасы.

В другой культурной парадигме мощь Матери воды трансформируется, она обретает роль «иеси» хозяйки местной реки или озера. Тюркские народы, населяющие эти территории, понимали, что включались в органическое единство и взаимосвязь с ними. Ссорится с «иеси» никто не стремился, напротив их старались задобрить. Такую Су анасы запечатлел Ахсан Фатхутдинов (1939–2012), заслуженный деятель искусств Республики Татарстан. Обращаясь к раскрытию образа Су анасы (1990), художник наделил ее опоэтизированной женственностью [6: 21]. Произведение выполнено из дерева,

секреты обработки которого он воспринял от отца. Художник воспитывался на бережном и уважительном отношении к природе, поэтому использовал для работы только части погибших деревьев. В облике его стройной Водяной отсутствуют архаичные черты древнего материнства. Плавная округлость линий грациозного тела органично прикрыта струящимися волосами. Рисунок вьющихся прядей возобновляется в линиях синих волн, создавая орнаментальный ритм, созвучный вибрации мирового океана. Вырезанные в контурной технике плавные линии широкой деревянной рамы, продолжают ритмическую игру волнообразных узоров. Вертикальные изгибы многократно повторяются, выделяясь на темном фоне крон и стволов деревьев, растущих по обе стороны тихого озера. Водяная изображена на берегу, среди причудливых изгибов стволов, образующих заостренную арку, под которой в небе располагается круглая луна. Вокруг светила, по ночному небу расходятся круги сияющего нимба. Они отражаются на зеркальной глади озера. В лунных лучах сказочно преображается веками нестареющая Водяная. У ее ног раскрываются красные и синие волшебные цветы, обогащая колористическое решение работы. Ничто не нарушает покоя Су анасы, задумчиво созерцающей ночные виды. Она опустила удлиненные руки с гребнем и очень серьезно, без улыбки вглядывается в каждого зрителя, рассматривающего запечатленный фрагмент угасающего мира прошлого. Художнику удалось, обращаясь к осмыслению до религиозного мировосприятия татарского народа, передать свое сожаление об уходящей красоте хрупкой гармонии отношений человека и природы, которые он впитал с детства, благодаря рассказам бабушки.

К началу XX в. анималистические верования утратили свое значение для миропонимания татарского народа, переместившись в область мифологических историй и сказок, подпитывая суеверные воззрения и оказывая слабое влияние на обрядовую практику. Под влиянием религиозной идеологии негативную интерпретацию получили все культовые существа прошлых верований [8:57], так Су анасы обрела черты ведьмы, безобразного женоподобного существа. Именно такой она описывается в сказке Габдуллы Тукая. Александр Иванов (1952 г.р.), художник декоративного искусства, мастер художественной обработки металла, точно следовал характеристике Водяной (1995), данной поэтом [7: 26]. Он воплотил замысел, применяя выколотку, ковку, гравировку и чеканку. По периметру украсил медное панно богатым растительно-цветочным орнаментом. Такие узоры вышивали татарские мастерицы на текстильных изделиях, украшающих их жилища. Будущий художник рос в окружении подобных самобытных вышивок, исполненных мамой и бабушкой. В реалистической манере автор создал Су анасы с жабьей головой. Ведьма, занимая видное место, расположилась на мостках, свесив ноги и расчесывая седые космы сверкающим гребнем. Нарядно одетая, Су анасы не доставляла беспокойства озерным птицам и лесным зверюшкам, они доверчиво отнеслись к ее присутствию. Напротив Водяной, за раскидистым деревом спрятался мальчик, прибежавший на озеро из татарской деревни, расположенной рядом. Автору удалось запечатлеть бытовую достоверность сельского вида в ясный летний день. Художник, стремясь по-своему раскрыть идею сказки Габдуллы Тукая, противопоставил человека, нарушающего покой обитателей озера, и безмятежную нечисть, являющуюся частью этого сказочного уголка природы.

Наиля Галявиява (1955 г.р.), заслуженный деятель искусств Республики Татарстан, также обратилась к разработке темы «Водяная» (2021). Она, создавая сочность и яркость цветовых сочетаний, использовала технику объемной аппликации и лоскутного шитья, традиционного для декоративно-прикладного творчества татарских мастериц. Рамка, выполненная средствами текстильной мозаики, придает произведению созвучность веселому народному празднику. Автор изобразила эпизод погони Водяной за мальчиком, убегающим с гребнем. Он запечатлен, в опасной близости от цепких длинных пальцев Су анасы, которая мчится вдогонку. Ведьма дана фрагментарно, мы видим только верхнюю часть ее зеленого тела, устремленного вперед. Страшная Водяная в трактовке художника выглядит смешной, нарядившись в нарядное платье и крупные украшения. Она, словно, стремится подражать деревенским женщинам, одна из которых видна на дальнем плане за околицей села, раскинувшегося на берегу озера. Н. Галявиевой удалось передать своеобразие национальной сказки.

Рушан Шамсутдинов (1946), заслуженный деятель искусств Республики Татарстан создал образ Водяной для мозаики, украшающей станцию метро «Кремлевская» в Казани. Он оправданно обратился к эстетике оформления дворцовых залов тюркской знати. Композиция произведения делится на три уровня: основное центральное место занимает Су анасы, нижний уровень – обитатели озера, рыбы, верхний небесный – речные чайки. Они даны в реалистичной манере, с проработкой деталей, их силуэты по контуру подчеркнуты темной линией. Светло-зеленым цветом обведен абрис озерных растений и цветов лаконичного пейзажа. Все немногочисленные элементы композиции гармонично взаимосвязаны и представляют собой единое целое с утонченным обликом Водяной. В выражении ее тюркского лица читается затаенная грусть. Взмах грациозных рук, словно замер в танцевальном движении. Красавица Су анасе расчесывает свои роскошные волосы, их масса бирюзовых, изумрудных, темно-синих и зеленых прядей дана в сочной палитре цветов. Она контрастно выделяется, в соседстве со сдержанным колоритом обрамляющего поля, за границами фигурной арки, отделяющей изобразительный сюжет от орнаментального геометрического коврового декора. В художественном решении произведения ощущаются отголоски эстетики восточных миниатюр, переосмысленных в рамках другой культурной эпохи и адаптированных к возможностям монументально-декоративного искусства. Таинственное глубокое мерцание мозаики в искусственном освещении метро словно исходит от изображений на панно. В трактовке Р. Шамсутдинова Су анасы оказалась близка к европейским образам русалок конца XIX – начала XX века, с их вечной молодостью и притягательной красотой, также аналогии можно провести с изображениями Лореляй с неизменным золотым гребнем в руке.

Обобщая вышеизложенное, можно сделать вывод, что современные художники декоративного искусства Татарстана создали разноплановые работы, раскрывающие различные грани образа Су анасы. Для М. и Р. Кильдибековых и А. Фасхутдинова решающей оказалась идея близости Водяной мифологическим верованиям татарского народа. В их произведениях воплотилось понимание созидательной и незаменимой силы Воды, как источника жизнеобеспечения людей, в свою очередь нуждающегося в защите от разрушительной наступающей цивилизации потребления. А. Иванов и

Н. Галявиева руководствовались представлениями деревни конца XIX века о зловредной и некрасивой ведьме Су анасы, запечатленной в произведении Г. Тукая. Художественное решение образа Водяной Р. Шамсутдинова было продиктовано осознанием того, что тысячи людей будут оценивать дорогую для татарского народа Водяную, и она должна внешне соответствовать общемировым стандартам привлекательности. Таким образом, каждый из художников внес свою лепту в создание неоднозначного образа Су анасы, обогатив наши представления о ней.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бакиров М.Х. Татарский фольклор: монография. Второе дополненное идание. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2018. – 406 с.

2. Валеева Д.К. Рустем Кильдибеков. – Казань: Заман, 2016. – 160 с.

3.Замалетдинов Л.Ш. Татарская народная сказка и литературные сказки Г. Тукая: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1993. – 24 с.

4. Красников А.Н. Традиции связующая нить // Религии в истории народов мира. – М.: Республика, 2005. – 543 с.

5. Урусбиева Ф.А. Метафизика колеса. Вопросы тюркского культурогенеза. – Сергиев Посад, 2003. – 207 с.

6. Шагеева Р.Г. Ахсан Фатхутдинов. –Казань: Рухият, 2002. – 220 с.

7. Шкляева Л.М. Чеканные образы Александра Иванова // Казань. – 2018. – № 2, февраль. – С. 24 – 27.

8. Стародуб Т.Х. Исламский мир. Художественная культура VII–XVII веков: архитектура, изображение, орнамент, каллиграфия. – М: Восточная литература, 2010. – 256 с.

УДК 821.512.145

# СУФИЙСКАЯ СИМВОЛИКА В ПОЭЗИИ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ: ОСОБЕННОСТИ ТРАНСФОРМАЦИИ

***Н.М. Юсупова***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет,*
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань);*
***А.Ф. Юсупов***
*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*

В статье раскрывается функциональное и смысловое поле суфийских символов в поэзии Габдуллы Тукая. На материале романтических произведений утверждается, что ориентация на светскую литературу, смена классического типа культуры неклассическим способствуют трансформации суфийских символов. Поэт использует и традиционные суфийские символы в исконно суфийском контексте, и трансформированные образы-номинации для передачи светских идей и философских воззрений. Трансформация является неотъемлемой частью основного механизма символизации в поэзии Г. Тукая, направленного на пробуждение ассоциаций, т.е. на процесс смыслопорождения, смыслового наполнения символа в структуре художественного текста. В суфийских символах наблюдаются особенности смыслопорождения, коррелирующие с национальной культурой, национальным восприятием мира и мироощущением, складом мышления.
**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, символ, трансформация, татарская поэзия, суфизм.

The article reveals the functional and semantic field of Sufi symbols in the poetry of Gabdulla Tukay. Based on the material of romantic works, it is argued that the orientation towards secular literature, the replacement of the classical type of culture with a non-classical one contribute to the transformation of Sufi symbols. The poet uses both traditional Sufi symbols in a primordial Sufi context, and transformed nomination

images to convey secular ideas and philosophical views. Transformation is an integral part of the main mechanism of symbolization in G. Tukai's poetry, aimed at awakening associations, i.e. on the process of generating meaning, meaningful filling of a symbol in the structure of a literary text. In Sufi symbols, there are features of the generation of meaning, correlating with national culture, national perception of the world and attitude, mentality.
**Key words:** Gabdulla Tukay, symbol, transformation, tatar poetry, sufism.

В начале XX столетия татарская литература, генетически связанная с литературой арабо-мусульманского Востока, прежде всего развивала присущие последней особенности символизации [10: 138]. По утверждению А.М. Саяповой, в этом плане особо следует отметить «традицию суфизма, философско-эстетические основы которого были близки к символизму, эта традиция придала в целом светской, европеизированной поэзии национальный восточный колорит, расширив и обогатив ее художественное и эстетическое содержание» [7: 97]. Татарские поэты начала XX века постоянно обращаются к образной и интонационной системе суфийской поэзии. Суфийские культурные коды присутствуют, в основном, как устойчивые символы, номинативные единицы, имеющие суфийское и светское содержание. В татарской поэзии данного времени наблюдается наличие трансформированного, нового семантического пространства суфийских символов. Они, с одной стороны, несут в себе мистическое содержание, с другой – трансформируются и приобретают «светское» содержание, начинают служить основным средством изложения, наименованием той или иной философской концепции, оценки жизни, бытия. Трансформация воспринимается как один из способов смыслопорождения в системе суфийских символов.

Такая тенденция намечается и в творчестве Г. Тукая. Его стихотворения «Алла гыйшкына» («Ради любви Аллаха», 1905), «Гыйшык бу, йа!...» («О, это любовь!», 1906), «Ифтиракъ соңында» («После расставания», 1906), «Мәхвидәрмесән?» («Ужель не полюбишь?», 1906) и др. написаны с использованием суфийской символики. Как уже известно, образ-символ «соловей» в романтической поэзии имеет идейно-эстетическую нагрузку: с его помощью раскрывается гармоничный мир человеческой души. В романтической лирике Г. Тукая, например в его стихотворениях «Хур кызына» («Что за цена красе твоей», 1908), «Фатыйма һәм сандугач» («Фатима и соловей», 1910), «Җәйге таң хатирәсе» («Летняя заря», 1910), «Мәхәббәт» («Любовь», 1911), «Иһтида» («Постижение истины» 1911), образ соловья использован в основном в трансформированном виде и символизирует душевную гармонию, авторскую концепцию индивидуального человеческого бытия, идеал свободы и душевного полёта. Трансформированная параллель «цветок-соловей» возрождает фольклорные традиции и выражает любовь поэта к возлюбленной:

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас –төшми яңгыр тамчысы;*
*Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы* [8: 114].
*Без дождя поникнет колос и погибнет вешний цвет, –*
*Как стихи писать, коль рядом вдохновительницы нет?*
Перевод Я. Хелемского.

В татарской поэзии начала XX века чаще всего используются парные символические образы «бабочка-свеча». Г.П. Козубовская считает, что «об-

раз полета бабочки к свече обнажает двойственность оценки, обусловленную «двойным бытием» («Я же не знаю, что добровольным зовется и что неизбежным на свете»)» [5: 153–154]. Подобная «двоякость» обнаруживается и в стихотворениях Г. Тукая.

В стихотворении «Гыйшык бу, йа?..» («О, это любовь!», 1906) многозначность таких суфийских символов, как красивая девушка, прекрасное лицо, мотылек, огонь, вино, обеспечивая мерцание в структуре религиозно-суфийских и восточных культурных пластов, предоставляет возможность прочтения текстов в религиозно-суфийском и светском (романтическом) контекстах. По мнению Ю.Нигматуллиной, в творчестве Г. Тукая воедино совмещаются в пределах одного художественного произведения несколько поэтических систем и имеет место «постоянное сопоставление в поэтическом сознании прошлого и настоящего» [6: 112]. Такая тенденция ярко прослеживается и на примере стихотворения «Гыйшык бу, йа?..» («О, это любовь!», 1906), где суфийские символы выступают центром синтеза нескольких пластов, наименованием разных явлений. По мнению Р. Ганиевой, это «стихотворение можно интерпретировать в трех направлениях – собственно суфийском, в духе философии земной любви или концепции литературного творчества» [2: 9]. Несмотря на отсутствие в тексте образа свечи, она явственно ощущается благодаря образу огня. Г. Тукай обращается также к мотиву опьянения и кружения:

*Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;*
*Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем...*
*И гүзәл, кил каршыма, кил, елмайчы рәхим итеп,*
*Мин дә синең әйләнәңдә әйләнием, әйләнием...* [4: 55].

*Хоть я бедняк, но пожелай – тебе я душу подарю.*
*Приди, и я, как мотылек, в твоем огне сгорю, сгорю...*
*Как высшей милости прошу: моя красавица, приди!*
*С улыбкой ласковой в глаза мне погляди, о погляди!*
*Перевод В. Тушновой.*

Присутствие традиционной суфийской символики и мотивов позволяет увидеть субъективный, скрытый смысл – подтекст. В суфийской философии и практике существует ритуал кружения, в процессе которого человек входит в транс. В условно-символическом подтексте парная символика «мотылек – свеча» равнозначна традиционной суфийской интерпретации символа «роза – соловей» и передает мотив любви. Образы бабочки и свечи в суфийском прочтении символизируют Бога и влюбленного в него суфия, описывают момент слияния человека с Богом. Лирический герой предстает в роли суфия, влюбленного в Бога и стремящегося к Нему. Любовь к Богу воспринимается как источник душевной гармонии.

Такая трактовка присутствует и в стихотворении Г. Тукая «Алла гыйшкына» («Ради любви Аллаха», 1905). Однако в тексте намечается и трансформация мотива. Поэт выдвигает новую формулировку: оппозиция «Бог – человек», доминировавшая в суфийской традиции, трансформируется и представляется как оппозиция «Бог – народ, нация». В данном ключе божественная любовь перенаправляется к любви своей нации. Д.Ф. Загидуллина подчеркивает, что «исламская философия, таким образом, переосмысливается с позиций этноцентризма: служение нации определяется для мусульманина как необходимость (фарыз)» [3: 687].

Кроме того, в восточных литературах мотылек символизирует влюбленную душу, символика огня становится выражением любви, мотивы кружения и опьянения направляются на раскрытие земной любви:

*И гүзәл, кил каршыма, кил, кыйл тәбәссем лотфы идеб;*
*Бән дә хәүләндә сәнең дәүранаем, дәүранаем* [4: 55].

*Приди, красавица, приди, улыбнись, пожалуйста*
*Хочу кружиться и кружиться я вокруг тебя.*
*Перевод В.Тушновой.*

Так происходит трансформация символа, в подтексте лирический герой воспринимается как носитель земной любви к девушке и душой стремящийся к Аллаху. Лирический герой возводит возлюбленную до божественных высот, обожествляет ее, о чем свидетельствуют такие суфийские символы, как лицо и никаб (покрывало). Лицо в суфийской поэзии указывает на божественную субстанцию, интерпретируется как божественная Истина, а никаб «призван отметить своим присутствием границу между выразимым и невыразимым, материальным и духовным, феноменальным и трансцендентным» [9: 254]. Трансформируя суфийские символы, поэт констатирует, что возвышенная любовь приносит душе счастье, радость, которая согревает человека до самой смерти. Суфийские символы несут в себе значение любви и передают философско-эстетическую концепцию автора, выстраивают философскую идею: любовь прекрасна. Так любовь к возлюбленной в рамках стихотворения предстает источником душевной гармонии.

Подобная трансформация символа зафиксирована также в стихотворениях «Мәхәббәт» («Любовь», 1908), «Иһтида» («Постижение Истины», 1911), где символ «огонь» выступает символом «поэтического вдохновения, формой духовного и творческого самоопределения личности» [1: 97]. Кроме того, любовь интерпретируется как обожествленная, пророческая миссия, под знаменем которой человечество должно исполнить свой гуманистический долг перед Богом. В стихотворении «Иһтида» («Постижение истины») образы свечи и Меджнуна, влюбленного в Лейлу, служат наименованием возвышенной, божественной любви:

*Мәхәббәттән эреп шәмдәй үзем, күңлемдәге гөлләр*
*Янып җиргә сыгылдылар, һавага очтылар көлләр.* [8: 186]

*Как свеча я растаял, цветы, что я в сердце лелеял,*
*Почернели, сгорели, и ветер их пепел развеял…*
*Перевод Р. Морана.*

Таким образом, в поэзии Г. Тукая возникает стилизация под суфийские символы, обеспечивающая вариативность прочтения текстов. Поэт использует и традиционные суфийские символы в исконно суфийском контексте, и трансформированные образы-номинации для передачи светской идеи и своих философских воззрений. Трансформация является неотъемлемой частью основного механизма символизации, направленного на пробуждение ассоциаций, т.е. на процесс смыслопорождения, смыслового наполнения символа в структуре художественного текста.

ЛИТЕРАТУРА

1. Аминева В.Р. Габдулла Тукай и русская литература XIX века: типологические параллели. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2016. – 160 с.

2. Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.

3. Загидуллина Д.Ф. Тукай // Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 5. – Казань: Ин-т Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. – С. 687–688.
4. Ил корабын җил сөрә. – Казан: Мәгариф, 2001. – 208 б.
5. Козубовская Г.П. Поэзия А.Фета и мифология. – М.: Флинта, 2013. – 320 с.
6. Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Изд-во «Фэн» АН РТ, 1997. – 192 с.
7. Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. – Казань: Алма-Лит, 2006. – 246 с.
8. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 271 б.
9. Шукуров Ш.М. Об изображении пророка Мухаммеда и проблеме сокрытия Лика в средневековой культуре ислама // Суфизм в контексте мусульманской культуры. – М.: Наука, 1989. – С. 252–267.
10. Юсупова Н.М. Образ-символ как система номинаций в татарской поэзии первой половины XX века: дис. ... д-ра филол. наук. – Казань, 2018. – 399 с.

УДК 398.2=512.145

## ИЗ ОПЫТА ИЗУЧЕНИЯ БАИТОВ О ТУКАЕ

***И.И. Ямалтдинов***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В статье рассмотрены два варианта баита, посвященного смерти поэта Г. Тукая. Баит – произведение лиро-эпического жанра татарского народного творчества – является своеобразным способом реакции на то или иное общественно значимое событие, чаще – переживанием горя. В этом отношении баиты Тукая свидетельствуют не только о широком признании творчества поэта, но отражают всенародную любовь к нему.
**Ключевые слова:** баит, Габдулла Тукай, варианты баита, композиция.

The article considers two versions of the bayit dedicated to the death of the poet G. Tukay. Bait-a work of the lyric-epic genre of Tatar folk art-is a kind of reaction to a socially significant event, more often-an experience of grief. In this respect, Tukay’s baits show not only the wide recognition of the poet’s work, but also reflect the popular love for him.
**Key words:** bayit, Gabdulla Tukay, variants of bayit, composition.

## ТУКАЙ ТУРЫНДАГЫ БӘЕТЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

***И.И. Ямалтдинов***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Тукай бәетләренең «Шагыйрь Тукай бәете», «Тукай бәете» исемнәре белән басылып чыккан ике варианты бар. Төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребездән язып алынган әлеге бәетләр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фольклор фондында саклана. Беренчесе халкыбызның бөек шагыйре Тукай үлеменә багышлап, «Тукай үлү мөнәсәбәт илә. Илаһи бәет» исеме белән тәүге тапкыр «Кояш» газетасында «Г» имзасы белән басыла [7]. Бәетнең кайда язып алынуы һәм язып алучының фамилиясе газетада күрсәтелмәгән. Соңрак әлеге вариант, тулысынча яисә кыскартылып, «Татар халык иҗаты» һәм «Бәетләр» җыентыкларында (1951, 1954, 1960, 1983) урын ала. Бәетне матбугатка тәкъдим итүче кеше кайсыдыр бер авыл яшьләренең яраткан шагыйрьләре үлүен ишеткәч үк бәет чыгаруын хәбәр иткән, аның аңлатмасында мондый юллар бар: «Безнең авылга мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаев җәнапларының вафат хәбәре шимбә көн сәгать 10 да килеп житте.

Килү белән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгергән. Шул көнне килгән ике нөсхә «Кояш», өч нөсхә «Йолдыз» йорттан йортка йөртелеп укылган. Яшьләр, картлар, карчыклар – авыл халкы аның яшьли заигъ булуына чын күңелдән кайгырганнар. Кич, ясигъдан соң, күл буена төшеп утырдым. Миннән ерак та түгел, бер мунча янында, авыл яшьләре җыелып, касдан моң гына, зәгыйфь кенә чыгарылган гармонь тавышына бер-икесе авылда гына була торган саф тавыш белән җырлыйлар, башкалары тыңлыйлар иде. Җырлары ачык ишетелмәсә дә, арада «шагыйрь Тукай» дигән сүзләр ишетелә иде. Мин: «Бу ни! Болар ни җырлыйлар? дип чынлап тыңлап карасам, үзләренең шагыйрьләре хакында бер бәет тәртип кылып, шуны көйләп утырганлыкларын сиздем. Иртәгесен бәетләрен табып алдым» [7].

Икенчесе турында «Тукай Башкортстанда» (1966) китабының аңлатмалар өлешендә 1948 елда Башкортстанның Чакмагыш районы «Йөрәктау» колхозчысы Шаһибәк Биктимеров кульязмаларыннан күчереп алынганлыгы, башлап «Башкорт халык иҗаты» җыентыгының I томында (1954) басылганлыгы әйтелә, ләкин «Татар халык иҗаты. Бәетләр»нең (1983) искәрмә һәм чыганаклар өлешендә Тукай бәете алда аталган «Башкорт халык иҗаты» җыентыгыннан алынганлыгы күрсәтелсә дә, «кемнән язылганы күрсәтелмәгән» дигән хәбәр бар [3: 296].

Халыкның Тукайга кайнар мәхәббәтен чагылдырган бу бәетләрнең башлам өлешендә, XIX йөзнең урталарыннан алып революциягә кадәр чыгарылган бәетләргә хас булганча, «бисмиллаһи вә биллаһи» белән башланып, традицион рәвештә вакыйганың елы, ае, көне күрсәтелә һәм сүзнең кем турында баруы белдерелә. Бу традиция, нигездә, безнең тарихи бәетләребез өчен хас күренеш. XVI йөзләрдә язылган бәетләрдә үк кереп киткән бу традиция соңгы чорларда да дәвам иткән.

Бисмиллаһи вә биллаһи, укыдык корбан гаетен,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз Тукай шагыйрь бәетен.
Тукыз йөздә унөч елда, апрель икесендә,
Тукай мескен вафат булган Клячкин больницасында [3: 37].

Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте корбан гаете,
Без әйтәек, сез тыңлагыз мәрхүм Тукай бәетен.
Тарих мең дә тугыз йөздә унөч елы бу вакыт,
Апрельнең икесендә җырчыбыз Тукай вафат [6].

яисә икенче вариантта:

Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте корбан гаете,
Без әйтәек, сез тыңлагыз мәрхүм Тукай бәетен.
Тарих мең дә тугыз йөздә унөч елы бу вакыт,
Унбишенче апрелендә җырчыбыз Тукай вафат [3: 38].

Әлеге юллардан күренгәнчә, шагыйрьнең вафат булган көне беренче вариантта икенче апрель дип юлиан, ә икенче вариантта унбишенче апрель дип григориан календаре – яңа стиль буенча күрсәтелгән.

Тукай бәетләре фаҗигале. Алардагы фаҗига аерым шәхес фаҗигасе генә түгел, ә вакытсыз үлем нәтиҗәсендә барлыкка килгән халык фаҗигасе буларак яңгыраш ала. Халык үзенең яраткан бөек шагыйрен бик яшьли, бик иртә югалта, бәетләрдә дә шуңа басым ясый, ә беренче вариантта, килешмәскә тырышып, Әҗәлгә дәгъва да белдереп ала:

Ак келәтнең келәсен элә белми элә́сең,
«Әҗәл» агай, син нишлисең, килә белми киләсең [3: 37].

Яшьли китте шагыйрь Тукай, чәчә-чәчә нурларын,
Аллы-гөлле күп чәчәкләр куйды халык каберенә [3: 38].

Беренче вариантта халык үзенең сөекле шагыйрен бик иртә югалтуын, аның яшен күрсәтеп, аерым юллар аша да бирергә тырыша:

Ак келәтнең алдында калды бәнем җиләнем,
Егерме алтыда үлеп китте Тукай шагыйрь, сөйгәнем [3: 37].

Институт архивында сакланган кулъязма битләрдәге юлларда Тукайга үпкә белдерү дә сизелә:

Ташладың син безне, Тукай, мәңгелеккә ташладың,
Инде дөньяда түгел син, үзгә хәят башладың [10: 5–6].

Авыл яшьләре дә, картлар да Тукай үлеме турындагы хәбәрне ишетү белән тирән кайгыга чумалар:

Ызба артында алмагач, кисеп җиргә салмагач,
Җырла, моңай, саргай, үл, матур Тукай калмагач.
Тауга менсәм – тау биек, түбән төшсәм – тамырлык,
Тукаен җуйган яшьләргә ходай бирсен сабырлык [3: 37].

Алар турыдан-туры Тукайга эндәшү аша мәңге истә тотачаклары турында вәгъдә һәм шул ук вакытта, яраткан шагыйрьләренең әйләнеп кайтмый торган бакый дөньяда булуына ышанмыйчарак, үгетләү катыш сорау да бирәләр:

Тукай абзый, яшь чагыңнан белә идек без сине,
Онытырлар дип уйлама, онытмабыз без сине.
Алма бирдем – алмадың, тәңкә бирдем – сайладың,
Безнең матур дөньябызда ник ике-өч ел калмадың? [3: 37].

Тукайның 26 яшендә үк вафаты – көтелмәгәндә чыккан бәхетсез хәлләр нәтиҗәсендә килеп туган драматик фаҗига – трагизм категориясе белән якын гына тормыйча бер-берсенә күчә – тиңдәшсез зур югалту булып аңлашыла. Бу – фаҗиганең аянычлы нәтиҗәсе, аның кайтара алмаслык олуг югалту кичерүе.

Шагыйрьләргә шагыйрь иде ул Тукай заманында,
Куркып тормыйча әйтер иде яхшысын, яманын да [3: 38]

яисә архивтагы кулъязма битләрендәге юллар:

Син идең бит һәммәбезнең моңлы җанлы шагыйре,
Син идең бит халкыбызның солтаны һәм шаһ ире,
Син идең бит барча акын, бар шагыйрьнең акыны,
Бар кешенең, бар халыкның җан-күңелдән якыны.
Ни дигән сүз: милли шагыйрь Габдулла Тукай вафат?
Бумы? Бу бер якты йолдыз яки нурлы ай вафат [10: 5–6]

Мәсҗет башы манир-манир, манир саен бер талир,
Безне ятим калдырып, китте безнең шәп шагыйрь. [3: 37] һ.б.

